
ISSN 0206-4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

11.2004




1864
1923
ZE
МУСА АКЪЕГЕТ

# Казан утлары
# Qazan utları

2004

11

(985)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*редакциянең хезмәт коллективы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Ихтыяр Гаязов, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎: Баш мөхәррир — 92-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 92-36-49.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 92-38-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 92-39-63,
гамәли хезмәткәрләр — 92-39-65.
Исәп-хисап бүлеге — 92-93-16.
**Факс** — (8432) 43-56-12.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

*Бу санда*

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Лена ШАГЫЙРЬҖАН. Әдәбият корабы. *Шигырьләр.* 5
Хисам КАМАЛОВ. Үксезләр. *Роман.* 11
Газинур МОРАТ. Вакыт безне ваксытмады бугай... *Шигырьләр.* 79
Роза ХӘБИБУЛЛИНА. Миләш елы. *Повесть.* 83
Шамил АНАК. Эңгер язмаларыннан. *Шигырьләр.* 121

**КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНА 200 ЕЛ**

Сәвия МИХАЙЛОВА. Казан университетының Идел буе һәм Урал төбәге халыкларының мәдәни һәм иҗтимагый тормышында тоткан урыны. 124

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Рафаэль ХӘКИМ. Кайда безнең кыйбла? 139

**ДИСКУССИЯ: "БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЕ"**

Рифат СВЕРИГИН. Яңа замана, яңа геройлар. 159

**ХӘТЕР**

Ләбибә ИХСАНОВА. Шагыйрьнең култамгасы. 169
Шәрәф МӨДӘРРИС. Минем антым. *Шигырьләр.* 170

**ФӘН**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. 173

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ. "...Мәңгелек дип гүя пышылдый". 180

Хатлардан юллар. 184
"Казан утлары" архивыннан. 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. 189

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

"Проза и поэзия": роман Х. КАМАЛОВА "Сироты" (продолжение), повесть Р. ХАБИБУЛЛИНОЙ "Год рябины"; стихи Л. ШАГИРЗЯН, Г. МУРАТА, Ш. АНАК.
"К 200-летию Казанского университета": статья С. МИХАЙЛОВОЙ "Казанский университет в культурной и общественной жизни Поволжья и Приуралья".
"Публицистика": Р. ХАКИМ. "Где наша Мекка?"
"Наука": А. ТИМЕРГАЛИН. "Словарь нации".
Дискуссия "Герой нашего времени": статья Р. СВЕРИГИНА "Новые веяния, новые герои".
"Память": статья Л. ИХСАНОВОЙ к 85-летию Ш. Мударриса и стихи поэта.
"Книжное обозрение": рецензия М. ВАЛИЕВА на книгу Р. Курбанова "Рана".
Строки из писем.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: картина Р. Ш. КАРИМУЛЛИНА "Уголок"; писательница Г. ГАЛИЕВА.

## IN THIS ISSUE:

"Prose and poetry": H. KAMALOV'S novel "Orphans" (continuation), R. HABIBULLINA'S story "Year of a mountain ash"; poems by L. SHAGIRZJAN, G. MURAT, S. ANAK.
"To 200-anniversary of the Kazan university": article by S. MIKHAJLOVA "The Kazan university in cultural and public life of the Volga region and TransUral".
"Publicism": R. HAKIM. "Where is our Mecca?"
"Science": A. TIMERGALIN. "Dictionary of the nation".
Discussion "Hero of our time": article by R. SVERIGINA "New trends, new heroes".
"Memory": article by L. IKHSANOVA to S. MUDARRIS'S 85-anniversary and verses of the poet.
"Book review": M. VALIEV'S review of R. Kurbanov's book "Wound".
Lines from letters.
From photo archive of magazine.
Diary of public-cultural life.
On our covers: R.S. KARIMULLINA'S picture "Corner"; Writer G. GALIEVA.

*The magazin edits monthly*

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 19-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 26.10.2004 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 7025. Заказ Э—787
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2004 ел.



## Лена Шагыйрьҗан

### Әдәбият корабы

*Татарстан Язучылар берлегенең
70 еллыгына багышлыйм.*

**Дәү бер кораб йөзә Идел-суда,
Гигант аккош—горур, мәһабәт.
Хәтер дулкыннарын ярып барган
Чал тарихка гүя шаһәдәт.**

**Ул корабның биек колгасында
Бөек Колгалинең әләме
Җилфер-җилфер килә—гасырлардан
Әдип-шагыйрьләргә сәламе.**

**Бу корабка газиз милләтемнең
Асыл хәзинәсе төялгән.
Татар рухы әнә шул хәятка—
Бай Әдәбиятка төйнәлгән.**

**Тел-логатьнең алтын келәте ул,
Ачкычы һәм аның йозагы...
Ак каендай илаһ күңелләрнең
Ил-Ватанга иңгән йөз агы...**

**Йөзеп бара дәү бер милли кораб,
Калышмыйча инсаниятттән.
Һич ватылмас нәфис көзгебез ул,
Яралганга иң саф нияттән.**

**Шул корабта—Татар дөньясының
Үткәне дә, Киләчәге дә.
Гасыр арты гасыр көтеп арган
Тансык җимеш бирәчәге дә...**

Лена ШАГЫЙРЬҖАН – *шагыйрә; "Мөлдерәмә күңел", "Иман Әлифбасы", "Ышанам йөрәгемә", "Бөҗрә вә хөҗрә" һ. б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

Каурый-каләм аша үткән уйлар
Чынга аша җиһан-галәмдә.
Мең бурычлы булып калыр Кеше
Изге китап белән каләмгә.

Утта янмас, суда батмас кораб,
Җидегән йолдыз аның маягы.
Яшим дисә халык, шул ноктага—
Әдәбият-телгә таяныр...

Йөзеп бара Әдәбият-кораб,
Җилкәннәрен меңнәр күтәргән.
Шул дәүләткә ия булган халык,—
Хакың бармы синең бетәргә?!

*2004, июль*

## Халыкара тигезлеккә сусап...

Тартышамын Татар өчен мин дә,
Үз-үземне белгән көннән алып,—
Халыкара тигезлеккә сусап,
Яшәр өчен лаек урын табып...

Шуңа күрә газиз милләтемнең
Үстерәсем килә дәрәҗәсен.
Күзе төшкән берсе соклансын дип,
Саф тотасым килә тәрәзәсен.

Шуның өчен—милләт туфрагына
Яңгыр булып явып торыр идем.
Кирәк булса, әверелеп җилгә,
Афәтләрен кире борыр идем.

...Бу дөньяның сукмак-юлларыннан
Атласаң да башны артка чөеп,
Бер көн килеп, каршы очраганнар
Сорашачак барыбер, "Син кем?"—диеп...

Мин татармын, диеп, шул чагында
Гарьләнмичә, аңа кулың бирсәң,
Дәлил өчен батыр Җәлилләрен.
Тукайларын яттан укып бирсәң,

Тезеп китсәң олугъ эшләреңнең
Дөнья сәхнәсендә дан тотканын,
Җир шарының тоташ офыкларын
Казан утлары да балкытканын,—

Син яшисең димәк, милләт булып,
Җир-Ананың татар баласы син.
Зур учакка утын салсаң гына,
Мәңгелеккә Җирдә каласы син...

Тартыш, дускай, Татар өчен син дә,
Үз хәлеңне белгән көннән алып.
Халыкара тигезлекне даулап,
Яшәр өчен лаек урын табып...

*2003*

## Яшьләр хәтеренә бер сүз

Хәтер кыры безнең буш калмаган,
кирәк түгел кабат чәчәргә.
Чәчкәннәрне урып йөргән көндә
бер сүз әйтеп калыйк яшьләргә:

Хәтер йөгебез шул артык авыр,
тартып барыр өчен дәрт-дәрман
бик куәтле булса гына бүген,
үргә таба менәр йөк-арбаң.

Гел яманны гына тотсаң истә,
хәтер дигәне дә хәтәр ул.
Йөрәгеңне көн-төн чагып торган
зәһәр елан булып ятар ул.

Елан агуын да дару итеп,
дөрләтик без арган каннарны.
Хәтер күгендәге дан йолдызын
кабызып нурлыйк сүнгән җаннарны...

Онытa күрмик һәрбер яңа көннең
булачагын тарих дәвамы.
Җәрәхәтсез тарих юк җиһанда,
Вакыт үзе табар дәваны...

Туй да үтми үкенечсез генә,
үкенечсез тарих, әйт, кайда?!.
Җиңелгәнбез, җигелгәнбез, ди-ди,
көн-төн зарланудан ни файда?!.

Гыйбрәтләрдән тарих гыйбарәттер,
сабак алыйк, егылып еламыйк;
Узган эшкә салават, ди халык,
киләчәккә карап, юл алыйк.

Гасырдан да озын көннәр була,
хәтер көнең кыска булмасын...
Тарих бабаң белән җитәкләшеп
барачаксың мәңге юлда син...

Хәтер кыры безнең буш калмаган,
кирәк түгел кабат чәчәргә.
Насыйп булсын ләкин сезгә, яшьләр,
һәркөн җиңү яулап яшәргә.

*2002*

## Без шул инде бәләкәйләр түгел...

Туктап кала күрмә!.. Көч бирергә
кем дә килмәс хәзер кызганып:
Без шул инде бәләкәйләр түгел...
Үзен-үзе өнди безнең күңел—
без китәргә тиеш кузгалып...

Зарланма да, сукранма да,—безнең
моң-зарларны һичкем ишетмәс.
Без шул инде бәләкәйләр түгел...
Бик катлаулы хәзер безнең күңел—
гап-гадиләр безне иш итмәс...

Боегып кала күрмә, бөек күңел!
Бел, беркем дә безне юатмас...
Тик калкынып барма, бераз чүгел—
уйлый күрмә—арттан хөсет күңел
качып кына, диеп, ук атмас...

Сына күрмә! Зинһар, сынатма...
Һичкем коткарышып хупламас.
Без шул инде җитеп җитлеккәнбез,
безне саклар өчен бер "патша" да
коралланган гаскәр тупланмас...

*2002*

## Түбәсе юк сыман бу Җирнең...

Карап торам төнге тәрәзәдән,
ялангач һәм ятим дөньяга.
Түбәсез һәм шыксыз Җир йөзенә
Галәм аша төпсез күк бага.

Кышкы урам буп-буш... бер эт тә юк...
Җепшеп ята пычрак җир кары...
Шомга баткан утсыз тәрәзәләр,
бер сакчысыз калган Җир шары.

Галәм карашыннан өреккәндәй,
җиргә чүккән йортлар, биналар.
Үз-үзенә гүя сыенган күк,
әллә ничек, сәер, тын алар...

Һичбер яклаучысыз, саклаучысыз
кара төндә җиргә елышып,
Утыра алар, кызганыч бер хәлдә,
оныткандый, тормыш җылысын...

Шулкадәрле бушап калган чагын
күргәнем юк иде урамның.
Мин юксындым хәтта эт өерен,
Исерекләрен, җилен-буранын...

Шәрә тынлык... Юаш түбәләргә
яп-ялангач бушлык текәлгән.
Түбәләрнең кат-кат түбәсе юк...
чиксезлеккә алар текәлгән...

Җил-давылдан безне шыклап торган
дивар-түбәләрне ни саклый?...
Берни дә юк! —Ачык космоста без...
Безне япан Галәм кочаклый...

Баксаң, без яшибез "шыр" Галәмдә...
Күк гөмбәзе—гүзәл хыялмы?...
Батсаң,ябышырга бер салам юк—
җил тузгытыр... "салам" ояңны...

*2000-04*

## Манарага йөз тотып...

Кыйбла якка тотып йөзем,
Офыкларга теким күзем:
Йа, Ходаем, бирче түзем
Әйтеп бетерергә сүзем...

Офыкларда—манзаралар,
Гасырлардан калган алар—
Манаралар, манаралар
Якты нурга манар алар
Диварларны, түбәләрне,
Биекләрне, түбәннәрне...
Олугъларны—галиләрне,
Кечеләрне—гадиләрне...

Һәммәсенә төшәр нуры—
Аллаһ бүләгенең зуры...
Манарага карап атла,
Булмыйм дисәң адәм хуры...

*2002*

## Мин язларны гына
## күтәм хәзер...

Мин язларны гына көтәм хәзер,
бүтән көтәр нәрсәм калмады.
Ә ул килмәс борын китеп бара,
Монысы да тагын алдады...

Мин йөгергән булам яз артыннан,
Китсәң, нярт мине үзеңә...
Яз, яулыгын болгап, юкка чыга,
колагын да салмый сүземә...

Йә, кайларга китим яз артыннан,
Ияримме җитез җилләргә?
Сәяхәткә билет сатучы кыз,
Яз иленә мине җибәр лә!?.

Бик ерак ул, бик кыйммәт ул, дисең,
утыр көтеп кабат килгәнен...
Колагымда язгы мизгелләрнең
үчекләпме мине, көлгәне?...

Мин язларны гына көтеп яшим,
шул өметтән генә җилкенәм.
Язлар китә... Минем кебек, моннан
беркая да китми җил генә...

## Һомай кошым

Таңда бер кош очып килде дә,
тәрәзәмә какты канатын:
Апам, торчы, күрче, күгеңдә
шундый якты булып таң атты...

Ач күзеңне, ышан сүземә,
бәхетеңнең сукты сәгате.
Күкләр суза синең кулыңа
көтеп алган хак сәгадәтең.—

Түзгән өчен кырыс көннәргә,
шыксыз, ямьсез кара төннәргә,
Кояш суза сиңа ал нурын,—
күтәр башың, ятма мендәрдә,—

Үз сүзеңне саклап илләрдә,
баш имәгән өчен меңнәргә,
Ашыкмаган өчен менәргә
сатлык сүзләр сөйләп, мөнбәргә,—

Чыдаганың өчен чынлыкка,
бирелмичә ялганчылыкка,
Өмет кошын көтә белгәнгә,—
сына-сына син бит чыныккан...

Уян, кузгал, ач тәрәзәңне,
каршы ал син Һомай кошыңны.
Бу таң сиңа—язмыш бүләге,
җуя күрмә ләкин һушыңны...

Җимнәр сибеп Өмет кошына,
өшетмичә суык кышында,
Җыр кадәрле җырны сакладың,
ышанычын илнең акладың...

*2003*

**Хисам Камалов**

# ҮКСЕЗЛӘР

РОМАН

6

Шаяз белән Лениза язылышканнан соң озак та үтмәде, Ленизаның абыйсына майор дәрәҗәсе бирелүе, аны Түбән Камага күчерүләре турында беленде. Анда бишьеллыкның зур төзелеше башланган, шуңа анда ниндидер идарә оештырганнар, ди. Нефть-химия комбинаты салалар икән.

Абый кеше Шаязны гаражына алып керде. Ул түгәрәк, ягымлы, матур йөзле, киң җилкәле. Анардан ниндидер ышанычлылык, төплелек сизелеп тора иде. Ленизa әйтүенчә, ул тыштан мәһабәт, эчтән бик кырыс икән. Шулай икәнлеге аның тәгаен сөйләшүеннән дә тоела иде. Менә, диде, “Москвич”ны сезгә калдырам. Пока доверенность белән. Аннан күз күрер. Син һәр эшкә җаваплы карый торганга охшагансың, таянырга була. Бу машинаның төзеклегенә гарантия инде. Ризамы?

—Ә үзегезгә?—диде Шаяз, бу кешенең кинәт юмартлануына ышана алмыйча. Әллә шаярта, әллә сынар өчен әйтә.

—Анда минем персональ машина...

—Ленизa каермадымы?—Шаяз һаман моңа ышанып җитмәвен шул сүзләр артына яшерде.

—Без туганнар,—диде абый кеше, кырыслыгын бер дә сиздермичә.—Просто шундый җай чыкты. Саклап йөртсәң, машина әйбәт әле. Бары унөч мең ара үткән...—Ул машинаның арткы ишеген ачты да, тәрәзәсе кырыендагы кнопкасына басып, кире ябып куйды. Шаязның машинага кызыкканлыгы кыяфәтенә чыккан иде. Һәр ир-атның хыялы машина инде. Ләкин Шаяз хыялының канатлары күптән сындырылган, тапталган иде. Ул хыялын машинага хәтле очыртып менгерә алмый иде.

—Әллә алырга йөрәгең җитмиме?—Абый кеше хәерхаһ төстә хөрмәт белән кеткелдәде.—Безнең семьяга кушылдың—исәп-хисаптан котылдың, дигәндәй...

—Ленизaның бирнәсе шикелле була инде бу, ә?—Шаяз югалып калмас өчен генә шулай әйтте. Әрсезлегем сизелмәсен дип, тыныч кына кет-кет көлеп торды. Ул үзе тир түгеп тапмаган әйбергә бер дә кызыкмый. Бушка килгән нәрсәдән тайчына. Иң шүрләгәне—бүтәннәргә бурычлы булып калу иде. Бурычлы булу—кол булу инде ул...

---

*Дәвамы. Башы 10 санда.*

—Курыкма,—диде абый кеше, Шаязның кыюсызлыгын сизеп.—Машина төртеп, мине үз кубызларына "папанскийга" биетерләр дип шикләнәсең бугай. Әйе, хатын-кыз каршында сынган чакларың булыр. Хатын-кыз усалланды. Аларда права күбрәк. Лениза минем сенел горур, чибәрлеге белән дә һавалы. Үзенчә булырга ярата. Сигезне бетергәч, әнигә буйсынырга теләмичә, өйне ташлап чыгып китте. Эшкә керде, кеше почмагында яшәде. Кичкедә укыды. Ир-ат: "Лениза, син гүзәл, кояш кебек нур чәчеп торасын",—ди-ди аны үсендерде. Бу шәһәргә күчеп килеп тә семьяга кайтмады. Горурлыгына зыян килә, имеш. Үзе эшләп, үзе юллап фатир алды. Чибәрлеге дә роль уйнады булса кирәк. Башта начальнигы белән дус кына булдылар. Ләкин гайбәт зур көчкә ия бит. Араларыннан кара мәче узды...

Абый кеше Ленизаның элек эшләгән жирендә начальник белән булган мажарасын өстән-өстән шудырып сөйләп алды. Аннары Шаязга төбәлеп:

—Син Ленизаны каты тот,—диде, көчле йодрыгын төйнәп.—Йомшаклыгыңны сизә күрмәсен. Башыңа менеп атланыр... Холкы үзгәреп тора. Кайчак бик акыллы була, ә икенче вакытта—жил баш...—Ул үз туганы турында бик үк яхшы булмаган сүзләр ычкындыруына уңайсызлангандай, машинаның арт тәгәрмәчләренә аягы белән типкәләп алды.

—Сез инде моны безне кайгыртып әйтәсез,—диде Шаяз, абыйга ярыйсы килгән шикелле.

—Именно! Молодец, аңладың!—Абый кешенең тавышында шатлык сизелде. Ул, Шаязның учына жиз алкалы ачкычлар салды, машинага доверенностьны бирергә дә онытмады. Шаязның жилкәсенә кулы белән жиңелчә шапылдатып алды да, гаражлар арасындагы сукмактан китеп барды.

Шаяз гараж ишеге төбендә уйланып басып торды. Кинәт шундый хәл килеп чыгуына ул әзер түгел иде. Соңы ничек булыр икән?—дигән уйлары миендә бөтерелде. Шайтан, яхшылыкны да тыныч кабул итеп булмый... Ярар, алда күз күрер тагын, ди-ди, үзен тынычландырырга тырышты. Гаражны бикләде дә өйгә керде.

Ишекне ачуга, каршысына Лениза очып килде, кулларын чәбәкли-чәбәкли:

—Абый безгә машина бирә! "Москвич"ын безгә калдыра!—дип, кычкырды. Шаяз, кулын алга сузып, аңа учын ачып күрсәтте.

—Менә!—диде.

Лениза чыдап кала алмады, жиз алкалы бер ачкычны алып күзләренә китереп карады, аннары Шаязның учына кире куйды.

—Сиңа бирнә итеп бирде, син бирнәле кәләш!—дип шаяртты Шаяз. Лениза тузган чәчле башын кыегайтып, аңа сынап карап тора башлады.

—Абый белән нәрсә турында сөйләштегез, ә?

—Юк, берни турында да түгел,—диде Шаяз, һаман шукланасы килеп.

—Абый минем гайбәтне саткандыр әле? Ул туган дип тормый. Каты кылана.

—Юк, юк,—диде Шаяз, бу хакта сүзне озайтасы килмичә. Ленизаның йөзе яктырды. Кәефе күтәрелде. Ул чытлыкланып иркәләнергә тотынды. Шаяз исә чишенде, юынды. Әзер өстәлгә утырдылар. Ашадылар, чәй эчтеләр. Лениза үзенең элекке гозерен тезә башлады:

—Кайчан Әлмәткә күчеп киләсең? Синнән башка мин бер көн дә чыдап тора алмыйм. Ну, калын тиреле аю кебек син, Шаяз. Нигә бер сүз дә әйтмисең? Бик акыл иясе булып тыңлап утырасың?

—Лениза,—диде Шаяз,—белеп торасың бит, әти бик каты авырып ята. Чәчү иң кызган вакытта ничек эшне ташлый аласың? Әйдә, үзең безгә килеп яшәп кара булмаса. Көн дә иртән машина белән эшеңә илтеп куярмын. Алып кайтырмын. Ничек уйлыйсың?

Аңа жавап итеп, Лениза борынын гына жыерып куйды. Шаяз стенадагы сәгатькә күз төшереп алгач, кузгалды. "Москвич" белән тизрәк авылга кайтып күренәсе килә иде. "Юк,—дип Лениза торып басты һәм ике беләге белән Шаязның муеныннан кочып алды.—Мине яратмыйча жибәрмим... "Ну, кызый,—ди Шаяз, башын як-якка чайкап. Аңа ничек карыша аласың

инде? Шушы тикле ак гүзәл кулларда таш та йомшарыр...

Шәһәрдә коммуналь йортларга газ колонкалары кую бара иде. Болар йортына куеп та киткәннәр икән. Лениза тиз генә душ кереп чыкты. Инenә озын йөнтәс халат кына элеп, чәчләрен бигуди кәтүкләренә чорный-чорный йокы бүлмәсенә атлады. Караватк кырыена утырганда чабуы ачылып матур йомры ботлары күренеп торды. Шаязның әллә кай төшләре кайнарланып, кызыша башлады. Лениза карватка менеп чалкан ятты.

—Син мине бүген озаграк яратырга тиеш,—диде, челтер-челтер көлеп.

—Артыкка китсә бал да ачы була башлый.—Шаяз да шаяруны кабул итеп шулай диде.

—Яратудан туя алмыйм.

—Нәрсә татлы, шул зарарлы, диләр...—Шаязның шаяруы йөзенә чыкты.— Әнә шикәр дә татлы. Күпме кеше шикәрне күп кулланудан сырхаулый.

—Ну, чагыштырдың! Ярату бөтенләй башка...

Бераз яратышкач, Лениза татлы ыңгырашып алды һәм күзләре йомылган килеш мәрткә киткән кебек тынсыз ятты. Ике-өч минуттан күзләрен ачты. Тагы сөйләшә башладылар.

—Мин,—дип пышылдады Лениза, халат чабуларын аяклары белән кыса-кыса,—мине яратканны гына ярата алам. Яратмаган агачына кош та оя ясамый.

—Хатын үзе яратмаса, ир аны ничек яраттыра алсын? Көч белән яраттырып буламыни?

—Көч белән түгел, ә яратып яраттырырга кирәк. Хатынның яратуы ирләрдән тора. Ярату бит ике яклы...—Ленизаның тавышы өйрәтү тонында иде. Ул иренә ярату ликбезе уздыра иде сыман.

—Ягъни, уртак?—дип куйды Шаяз, юри анларга тырышкандай. Чөнки болар барсы да уен, яшьлек шуклануы булып тоела.—Ике як та үзен яраттыра белергә тиеш? Шулаймы?

—Шулай да, шулай да түгел,—диде Лениза, чыннан шаяруга күчеп. Үзен яраттырасы килеп, Шаязны кочаклый, тарткалый башлады.

—Тукта, анлатып бетер әле,—диде Шаяз, хатынның ак кулларын муеныннан ала-ала.

—Менә мин гыйшык тотып сина бардым. Әйе бит?—Ленизаның күзләре озын керфекләре астында елык-елык килеп алды.—Бу әле тышкы ярату. Рухи гына. Рухи гыйшык күпкә бармый, бетә. Рухины "физик" ярату алыштыра. Ягъни син мине "физик" ярату белән үзеннеке итәргә тиеш!

—Юк, жир упсын, анлап житмим,—диде Шаяз, Ленизаның күнелен төшермәс өчен елмаеп.

—Хатын-кыз катлаулы зат!—Ленизаның тавышында горурлык сизелде.— Тормыш бит хатын-кызлардан башланган. Хәзерге дөньядагы барча кешеләр хатын-кыз күкрәген имеп үскәннәр...

—Анысы шулай,—дип каршы төшәргә жөрьәт итте Шаяз,—әмма ләкин тормыш хатын-кызлардан түгел, ир-атлардан—Адәм атабыздан башланган, кадерлем. Ә Һаува анабыз аның кабыргасыннан яратылган, ди бит изге Китап. Шуна да ир-ат үз "кабыргасыннан" башка яши алмый бит инде.

Лениза бәхәсләшеп тормады. Динне белмәгән башы белән ничек бәхәсләшәсең. Нибары:

—Бабайлар сүзен сөйлисең,—дип, томса йөзен һәм ярату белән өретелгән күзләрен Шаязга юнәлтте.—Эшенә сонарасың, бар,—диде, ике кулы белән аның күкрәгеннән этеп. Шаяз ике кулы белән Ленизаны кочаклап алды, күкрәгенең тыгыз катылыгын бар тәне белән тойды. Озак кына тәмләп үпте.

—Минеке булдыңмы?—диде шаярып...

—Синеке, синеке!—диде Лениза, тора башлап...

Шаяз таркау хисләр, чуалган уйлар белән китте. Ленизаны анламассың, бүген болай, иртәгә тегеләй. Абыйсы каты тот дигән иде дә бит, ничек ана каты буласың. "Катылык дигәндә бездә юк инде. Ярар, бала тапкач, семья арбасына жигелгәч, басылыр әле..."

Утыз-кырык минутта кайтып житте. Авылга кермәде, мастерскойга да сугылмады, туры чәчүчеләр янына элдерде. Аларның эшләгәне һавага күтәрелгән тузан болытыннан шәйләнә иде. Корылык болай ук тыр дип белмәгән иде, үз күзләре белән күргәч, эченә пошаман йөгерде. Барча нәрсәләрне оныттырды. Туфрак кибеп өлгергән. Бөртекне тирәнрәк күмдерәләр дә бит, янгыр яумаса эш харап. Рәис безне судка тарттырыр, үзе читтә калыр. Вәзыйх та, мин дә тапланган биографияле кешеләр. Әх, сыек селитра сибеп чыксаң иде, ләкин безнең андый агрегатлар юк. Соң нишләргә? Вәзыйх та бик борчыладыр. Кыр станында куна-төнә ята...

Юлга якын гына бер агрегат чәчүдән туктаган иде. Шаязны күреп, тракторчы йөгереп килеп житте. Ул бик ачу белән бүртенгән. Нәрсә булды? Тракторчы Имай шунда миңа иске трактор бирдең, дип Шаязны аты-юлы белән тиргәп ташлады. Шаяз эндәшмәде. Әйдә, ачуын чыгарып бетерсен. Имай әллә ничә катлы итеп сүгенеп, эчен бушаткач, нәрсә ватылганын әйтте. "Муфта сцеплениедә" май кимегән һәм бер деталь кырылган..."

Шаязның машина багажнигы буш түгел иде. Ул таңнан торып, Иван Мөхәммәтович ярдәмендә байтак дефицит детальләр юнәтте. Иван Мөхәммәтович берәр кешегә хилафлык кылса, сонынннан ана яхшылык эшли. Начарлыгын төзәтә. Бу эшне һич тайпылышсыз башкара. Әҗәтне артыгы белән кире кайтара. Монда да шулай эшләде. "Селхозтехника"га үзе барып, арт ишектән генә жибәрелә торган запчастьләрне алып бирде дә, кыр станына юнәлде. Анда Вәзыйх чәчкечләргә симәнә, ашлама салуны оештырып, барлап йөри иде.

—Янгыр яумаса, мин беттем, парин,—дип уфтанды ул. Һәм стандагы йорт күләгәсенә чүгәләде. Кырынмаган иде. Ике көн кырдан кайтканы юк икән. Шаяз аның янына чүгәләде. Вәзыйх сумкасындагы барометр приборына карап тора башлады. Шаяз күз кырыен шунда юнәлтте.

—Кара, кара, угы түбәнгә шуыша түгелме соң монын?—Шаяз шатлангандай тавышын көр чыгарды, иптәшенең кәефен күтәрергә теләгәндәй.—Шуышамы, әллә...

—Сизелмәслек кенә шуыша шикелле, шайтан алгыры!—дип куйды Вәзыйх, үртәлүле төстә.

—Ярый, паникага бирелмик әле...

—Теге янгыр теләнчесе дигән кош бар бит әле. Урманда һаман анын авазы: чик, чик, чик... Ул янгыр тамчысыннан башка су эчми икән. Шуңа һәрвакыт янгыр теләп аваз сала... Шунын шикелле без дә янгыр теләнчесе булып беттек инде.

—Авыл кешесе шул инде: жир кимерә, күккә карап тилмерә,—диде Шаяз, авыр сулап.

—Солыңаны бетерәм дип чәчүне соңарту ике теләйле,—дип зарын түкте Вәзыйх.—Йә пан, йә пропал! Юк, болай ярамый! Нигә без генә башны балта астына куябыз? Начальниклар кушканча чәчәргә, и бетте!—Анын чыраена үртәлү, гажизләнү, эчтән сызлану галәмәте чыкты.

—Әйтмәсән дә. Ел елга туры килсә, ни әйтер иден. Һәр ел үзенчә...

—Һаман каршылыкка бару да ахмаклык инде,—Вәзыйх жиргә төкереп куйды.

—Әмма барасын, бармыйча булдыра алмыйсын.

—Без дураклар. Табигать шулай яраткан. Әhe-he-he!—Вәзыйх тагы сумкасындагы барометрга күз төшереп алды.—Иртә чәчү һәр яктан әйбәт тә бит, шул каһәр солыча булмаса...—Ул тәмам кайгыга баткан иде. Шаяз анын "Москвич"ны күрүен теләгән иде. Бәлки әз генә мактанып аласы килгәндер. Юк, карамады, дикъкать итмәде. Ул арада нәрсәседер ватылган тракторчы килеп житте. Багажниктан кирәкле детальне эзләп алдылар. Майлы запчастьны газетага төреп трактор янына киттеләр.

Ул идарәгә эңгер-меңгер вакытында кайтып керде. Анда Ирек кенә иде, аңа карчыга кебек ташланды.

—Кайда тырай тибеп йөрисең?—диде, күзләрен усал елтыратып.—Ике агрегат туктап калган?..—Ул хәзер идарәдә көч ала башлады, чөнки

барысыннан иртә тора, эшкә булдыклы. Колхозны рәистән ныграк кайгыртучан булып бара. Шаяз аның каты бәрелүенә ачуланмады. Ирек эш өчен борчыла иде.

—Әлмәттән запчасть алып кайттым, ике тракторны да худка җибәрдем...

—Шулай дисән генә...—Ул каты бәрелүен кире алырга теләгәндәй елмайды, күзендә ачу очкыннары сүрелгән иде. Ишек төбендә торган "Москвич"нын рәиснеке түгел икәнен тәрәзәдән күрде дә, шуна башы белән ымлап:

—Бу кемнеке тагы?—дип, кызыксынуыннан тыелып кала алмады. Шаяз сүзсез генә, минеке дигәнне аңлатып, күкрәгенә учын куеп алды. Көнләшеп, бер-бер этлек эшләмәгәе дип, Ирекка дөресен әйтмәскә булды. Аның чыраеннан беленде, ул Шаязга ышанмады.

—Горком списать иткәнне сатты,—диде Шаяз, дәлилләргә тырышып. Ирекнең ирен кырыйларында ышанмау елмаюы яктырды.

—Йә шыттырма, алар частныйга сатмыйлар. Колхозга биргәннәр инде алайса.—Тавышында кинаяле куаныч чагылып китте.

—Юк, лично үз акчамны түләдем. Әлбәттә, кыйбат түгел...—Шаяз бик житди кыяфәт белән ышандырырлык итеп әйтте. Ирек башын як-якка селкеп торды, йөзендә соры күләгәләрнең күчәнеп әле бер, әле икенче битенә күчүе аның эчендә фикер көрәше барганлыгын сиздерә иде. Ничек инде ышанычсызлык пичәте белән йөри торганнарга очсызга машина тиклем машина саталар? Әллә барыш үзгәрә башладымы, авызын корт чаккыры?

Шаяз бик нык арыган, хәтта әнисе белән сөйләшергә дә хәле калмаган иде. Кухняда ашап-эчте дә бүлмәсенә кереп ауды. Ә янәшә якта әтисе белән теге ташбаш Фәтри дигән бәндә сөйләшәләр, бәхәсләшәләр. Әти аны нигәдер кумый. Фәбри әтине утыртуда катнашкан. Гаебен ярлыкатырга йөриме әллә? Бал алып килә. Кесәсендә шешә була.

—Ул чактагы хәлләрне үзең дә беләсең,—дип сөйләнә Фәтри, үзен хаклы тойган тавыш белән.—Тикшерүче бугазга ябыша: ул синең дустың, син аны якларга тиеш!—ди. Чын дуслар берсе өчен берсе тора белә. Бергә ашап-эчеп утырганда ул тайпылышлы фикерләр ычкындыра идеме? Шундый сорау куя. Мин әйтәм, андый фикерләрен ишеткәнем булмады, дим... Алдыйсың!—дип кычкыра сорау алучы. Димәк, син дустыңны сатасың. Дөресен әйтмичә, дустыңны батырасың. Аның гаебен арттырасың гына, ди.

Менә шулай мәче-тычкан белән уйнаган кебек минем белән уйный тикшерүче. Аларда бит бер гаепсезгә—нульдән сине төрмәгә утырта торган хәйлә механизмы эшләнгән. Ул механизм шул тикле камилләшкән. Ана каршы беркем дә чыдый алмый. Җанны какшата торган сүзләр белән һөҗүм итә: власть сине ашата-эчертә, укыта, яраткан эшенне эшләргә ирек бирә. Ә син шул властька төкерәсең. Әйе, әйе, битенә төкерәсең. Менә синең үз иптәшең турында дөресен сөйләмәвең сине хөрмәт иткән властька төкерү ул! Димәк, син ватаныңны яратмыйсың? Ватан—ана дибез. Ягъни син газиз анаңны да санламыйсың...

Әнә шундый намусны айкый торган сүзләр белән җанына тукына. Адәм баласының явызлыкка фантазиясе бик зур. Тәрәккый иткән. Мисал: без бер кешенең әшәкелек кылганын ишетсәк, шунда ук йөз процентка ышанабыз. Ни өчен? Чөнки үзебездә явызлык күп. Ә кешенең яхшылыгы турында әйтсәләр, без ана ышанмыйбыз. Ни өчен? Чөнки күңелебездә яхшылык бик әз. Яхшылык бездә күбәя алмый, ник дисәң, берәрсенә яхшылык итсән, үз башына тукмак төшә. Ит изгелек—көт явызлык, ди бит халык.

Тикшерүче һөҗүмен дәвам итә. Шамкин фәлән җирдә фәлән дип әйттеме?—ди. Мин әйтәм: юк, дим. Ул нәтиҗә ясый: димәк, әйткән, ди. Минем сине яклау, ышыклау позициясендә торганымны сизә дә, барысын да кирегә юнәлдерә. Тагы әллә ниләр китереп чыгара. Тәмам башны бутап бетерә. Һаман мине тизәк итеп калдыра. Шундый хәлдә иптәшеңне сатканыңны үзең дә сизми каласың...

—Юк, Фәтри, мин сине гаепләмим,—дип гыжылдый Шаязнын әтисе. Теге һаман сөйли.

—Синең мине гаепләргә, бәлки, хакың бардыр? Син—минем йөрәгемдә төзәлмәс яра. Нигә безне бер-беребезгә дошман ясадылар? Монардан кемгә ни файда? Менә шул нәрсәне анламыйм, Закир. Бер-берсе белән ихлас дусны дошманлашырга мәҗбүр итте. Юк, моны аек акыл кабул күрә алмый...

—Кем гаепле, кем гаепсез икәнне аерып булмый, менә бәхетсезлек шунда,—дип куйды әтисе. Шаязнын ата кеше белән мөнәсәбәте юк диярлек. Алар сөйләшмиләр. Закир абый улымның дәрәҗәсенә, эшенә хилафлык китерә күрмим дип шулай эшли. Чөнки белә, моны испкә алып торучылар бар.

—Без ничек яшәдек?—дип, Фәтри сүзен дәвам итте.—Ялганны чын дип исбатларга күпме көч сарыф иттек. Ялганлыйсын да, дөрес ялганладым микән дип куркасың. Дөрес ялганламаган булсам, нинди җәза бирерләр икән дип төн йокыларың кача. Гомер буе шулай. Ялганга җайлаша алмыйча газап чигәсең.

—Шөкер, ул көннәр үтте, Фәтри!—диде Закир.—Кешеләр иркен сулыйлар. Тоясыңмы, ил нинди адымнар белән алга китте. Партиядә батыр йөрәкле чын кешеләр бар икән. Шуларга рәхмәт!..

—Гаделлек барыбер өскә калкып чыга. Майть якасына! Әйдә, тот, шуның өчен!

## 7

Идарәгә Лотфуллин керсә, тавыш чыкмый калмый. Әчүдән туктагач, бик эшлекләләнеп китте ул. Әчкәне өчен аны партиядән чыгарганнар иде. Ләкин горкомда карарны расламаганнар. Ул безнең кеше дип яклап калдырганнар. Шуны кайтарырга теләпме, бик эшем кешесе булып йөри. Ул җыелышта сайравын ишетсәң, аңардан аек, аңардан эшлекле адәм юк дип уйларсың.

Рәис, бухгалтер кәгазьләренә ышанып җитмичә, үзе чут салып тикшереп утыра иде. Лотфуллин аңа бәйләнергә тотынды.

—Нишләп миңа чөгендерне шул тикле күп куйдыгыз, ә? Үзем булмагач, ә? Үзе юкның, күзе юк, дидегезме?

—Туй үткәч дөмбергә,—дип, Вил Садриевич башын күтәрде.—Кыштан ук бүленде бит.

—Миңа алай күп тиеш түгел. Һәрвакыт авыр башы миңа.

—Ул синең болын җир, чөгендерне кабырга басуга чәчеп булмаганын беләсең бит. Әллә юри ачу чыгарасың килә инде?—Рәис дикъкатен үз эшенә юнәлтеп, счет төймәләрен чарт-чорт итеп салгалап куйды.

—Аны ничек эшкәртеп бетерим мин, ә? Шунда хикмәт...—Ул авызындагы сигаретын иреннәренең бер кырыеннан икенче кырыена күчерде. Ябалакныкыдай керфексез күзләре зураеп киткәндәй булды.

—Алайса, гариза яз,—диде Вил Садриевич, кискен генә.—Баш тарт...

—Синең инде миннән котыласың килә, беләм, беләм! Әмма чамала, үзеңне тәгәрәтеп куймасыннар. Һе!—Лотфуллин канәгать төстә, ияген бер якка кыегайтып чөеп алды.

—Һи—и,—диде Вил Садриевич, шатлыклы тавыш белән,—шушы үгез камытыннан бушатсалар, мең рәхмәт әйтер идем. Лотфуллин, син горкомга минем өстән җалоба яз: бу ат тарта алмый башлады, алыштырыгыз, диген. Сыйлармын үзеңне шуның өчен.

—Йә, сүз паносы ясама, Вил Садриевич,—диде теге, күзләрен кыскалап.—Күпме кешеләрне аударып ирешкән постыннан тиз аерыла алмассың. Юк! Нигә без бүрәнә аша бүре сугыштырабыз. Димәк, бакча кисү чарасын кулланырга мөмкин. Беркөн партактивта үзәктән килгән вәкил әйтте: бөек максат һәртөрле чараны да аклый, диде...

—Җылы урынны ташлыйсың килми, ә!—дип, Вил Садриевич көлеп

жибәрде. Лотфуллин дә көлде, тик көлгәндә папиросы идәнгә төшеп китте.
—Чукынган татар син, Вил Садриевич,—диде Лотфуллин, рәисне яраткан тавыш белән. Ул коридорга таба борылып, партком бүлмәсенә атлады.
Ишектә бик йончылган кыяфәтле, начар гына киенгән бер хатын күренде. Ул кыюсыз, чигә чәчләрен ашыга-ашыга яулыгына жайлый-жайлый рәис каршына килеп басты.
—Утыр, Сәрдә апа,—диде Вил Садриевич, хәерхаһ төстә.—Ни йомыш?
—Беләсен, Вилдан туган,—дип, бераз каушаган тигезсез тавыш белән тезеп китте.—Ирем эчә, балаларнын ашарына бетте.—Ул оялудан бөрешеп калды, учын учка алып, кулын күкрәк турына кысты.
—Ирен нефтедә иде,—диде рәис, рәсми тонда.—Эчкәнгә аннан сөргәннәр. Тагы колхозга кайтып егылды. Инде нишләргә? Син фермада бозау карыйсын. Эшенне мактап торалар. Молодец!
—Әдәс тә хәзер каравылда эшләп йөри.
—Беләм. Нигә һаман акылга килә алмый ул?
—Аптыраш инде. Эчкәненә үкенеп, гарьләнеп жылый кайчак...
—Ярар, менә ике центнер бодай...—Ул, бер бит кәгазьгә язып, хатынга сузды.
—Рәхмәт, Вилдан туган,—диде хатын, оялчанлыгын жинә алмыйча.—Безнекен, дим, дәваларга жибәреп булмасмы, ә? Үлә бит инде, дүрт бала?..
—Телиме сон?
—Һи-и, теләмиме сон. Үзе дә эчүеннән гарык лабаса! Махмыр вакытларында үлемнән чүт кенә кала.
—Моны авыл Советы, район комитеты оештыра. Свердловскига жибәрәләр. Алты кешелек исемлекне районга тапшырдык. Анда Әдәс тә бар.
—И, рәхмәт төшкере,—диде хатын, чыгарга чигенә-чигенә.—Тизрәк булсыннар иде...
Тегесе чыгуга кыяфәтеннән үк авыр тормышлы икәне беленеп торган икенче хатын күренде. Жыерчыклы, карасу чандыр чырайлы. Өшәнгән гәүдәле, тик күзләре кашсыз мәнгае астында тере нокталар шикелле кейриләр.
—Безнен сыерны чирлегә чыгарганнар иде,—дип, ояла-ояла аваз салды ул.—Балалар ризыксыз калды. Фермадан балаларга сөт арттыра алмассызмы?
—И-и, апа, фермада сөт бик чутлы шул,—дип, Вил йөзенә чын үкенүжәлләү чыгарды.—Бер литр сөт кимесә, бюрога чакыралар... М-м, әнә аерткан сөт алыгыз, пожалыста, ә? Көн саен ун литр. Катыкка тук булырсыз, ә?—Ул, хатыннын йөзендә ризалык, канәгатьлек яктысы шәйләп, ярты биткә рөхсәт язуы язып хатынга сузды...

Тышта тарантас килеп туктады. Аннан Вәзыйх белән Варис төште. Варис жилкәсенә капчык күтәргән иде.
—Тагы ватылдымы?—дип каршылады аларны рәис. Варис ватылган детальне күтәргән дип белде.
—Күз тимәсен, барсы да сәгать кебек эшли,—диде Вәзыйх, тузанланган кепкасын башыннан алып кага-кага.—Ай яктысында төнлә дә чәчтеләр. Шаяз шунда калды...
—Хуп!—диде рәис, канәгать төскә кереп. Варис өстәл өстенә капчыгын куйды. Кырыйларын кайтара-кайтара ачты. Анда өч соры йөнтәс йомгак кыймылдап ята. Әнекәй генәм, бүре балалары! Яктыдан качарга итеп, башларын яшерәләр. Күзләре елтыр-елтыр көйри. Тук, ирәм күренәләр. Кешеләр өстәл янына жыелдылар. Вариска сорау белән төбәлделәр.
—Узган көз зәптә шәйләдем мин аларны,—дип башлады ул. Быел тагы күзгә чалындылар. Аталы-аналы Бишмунча ягына элдерәләр. Әһә, мин әйтәм, оялары Еланлык ярындадыр. Имән таяк алдым да киттем. Ешкынлык, чытырман жирдән текә яр астына тар сукмак төшә. Карыйм, актарылган агач төбендә шушы йөнтәсләр әүмәкләшә. Аяк тавышына эчкә кереп постылар. Таякнын кәкре башы белән тартып чыгардым да—

капчыкка! Ярдан тырмашып мендем, як-якны күзәтәм. Фу, чурт, йөз метрлар ары агачлар арасында ике соры юан "түмәрләр" утырган. Боларның ата-аналары! Шүрләп кала яздым. Куркуымны җиңәр, тегеләрне куркытыр өчен кычкыра, таяк белән куакларга сугарга тотындым. Ташланмагайлары дим. Юк, кымшанмадылар да...

—Нәкъ безнең татарлар кебек икән,—дип көлде кайсыдыр.—Аларның балаларын чит-ятлар тартып алып китә. Кыл да кыймылдатырга куркып калалар...

Аңа кушылып көлделәр дә бетерделәр. Ата, бала мәсьәләсе, бигрәк тә милли вәзгыять нечкә, куркыныч тема иде.

—Варис, сиңа колхоздан бер сарык тиеш!—Вил Садриевичның кәефе килгән чак, чөнки чәчү эшләре җайлы гына тәмамланута таба бара. Алдынгы механизаторга берни жәл түгел. Бигрәк тә Варис кебек риясыз ике кешелек эшләүчегә. Варис, елмаеп, рәхмәт әйтте. Ревком Мөхетдинов аны бухгалтериягә алып кереп китте. Бу эшкә протокол язылырга, имзалар куелырга тиешле. Варис бу җәнлекләрне бүген үк Әлмәткә зооүзәккә илтергә Мөхетдинов белән килеште.

Барсы да киткәч, эчке уйларыннан рәиснең чырае сытылды, кашлары йөнтәс күбәләк кортын хәтерләтеп маңгаенда бөгелгәләде.

—Бу Лотфуллин белән нишләргә инде?—диде ул, гаҗизләнгән төстә.—Һаман канга тоз сала.—Ул амбар кенәгәсендәге графадан карады да чут сала башлады. Ә Вәзыйх: "Нигә бу хакта минем фикерне беләсе килә икән?"—дип уйлады. Бая әйткәләшкәндә Лотфуллин аңа:

—Үзенне урыныңнан өшкетмәсеннәр, һе—диде.

Бу исә рәиснең йөрәгенә барып тигән булырга тиеш. Герой исеме алырга омтылганда ул урыны өчен бик куркып тора иде. Вәзыйх бер сүз дә әйтмәгәч, рәис үзе сүзне ялгады:

—Безне "ежовый руковицада" тоту өчен район аны яклый, ә?

—Ихтимал,—дип куйды Вәзыйх.—Аны өлкән брат ярата. Теге елларда органнарда эшләгән, ди.

Рәис аңа ачуланып карады. Вәзыйхның сөйләү тоны аңа ошамады, авырткан чуанына тигән кебек булды. Бу мәсьәләдә үзенең дә гөнаһсыз булмавын шәйләргә мөмкин иде.

—Сиңа органнарда эшләгән һәр кешенең кулы пычранган күренә, ахры,—диде нәфрәтле күзләрен алартып.—Үзең укыган кеше, механизмны белмисең. Аппараттагы кеше шестерня. Тешләре белән икенче шестерня тешләренә тоташкан. Ул өченчегә... бергә генә әйләнә алалар. Арадан бер шестерня әйләнми торса шунда ук порошок булып уала... Кайсы шестерняны гаепли аласың? Һе!

Халык арасында сөйлиләр: Вил белән Таһия идарә тирәсендәге яшь белгечләрне рәис урынына исәп тотмыймы дип бик нык тикшерәләр, ди. Вәзыйхны да бик озак сынадылар. Карьерага омтыламы, юкмы? Таһия психологик якны күзәтә. Алар Вәзыйхның эшләрен күрмәмешкә салындылар. Чәчү җирләренә туфрак бонитеты буенча план-картография эшләүне, агролабораторияне худка җибәрү кебек хезмәтләрен чутка алмадылар. Эшенә битарафлык сизеп тору бик авыр ул. Әмма Вәзыйх рәнҗетелүгә күнеккән инде, исе китмәде. Бераздан аның карьерага кызыкмый, рәис урынына омтылмавын чамалагач, хезмәтләрен телгә ала башладылар. Вил район газетасына мактап мәкалә чыгарттырды. Әмма ихлас булмаган икән. Теге чакта Вәзыйхны эштән алгач, Вил Садриевич бу хәл белән шунда ук килеште. Эче беленде. Вәзыйх кебек грамоталы, эшчән, булдыклы кешенең еractaрак булуы хәерле аңа. Герой исеме алырга комачау итүе юк түгел. Әнә шулай карьерист кеше үзе тирәсеннән булдыклыларны читләштерә. Бернигә дәгъвасы булмаган хөрәсәннәрне үзе тирәсенә ияләштерә. Райкомда, Авыл хуҗалыгы идарәсендә, колхоз, сельпо идарәләрендә дә шундый вәзгыять... Эш мәнфәгате күз алдында тотылмый. Ә менә ни кызыл Зәйнагов һәм чуар йөрәкле Үтәгәнев Вәзыйхның эштән алынуы белән килешмәделәр. Чөнки эш интересын алга сөрәләр иде. Ә

Вилдә бары карьера кайгысы гына. Нигә бүләкләр вәгъдә итеп кешене бозалар икән? Вәзыйхнын районда күргәне бар, бүләк дип маньякка әйләнгән затларны очратасын...

Рәис Шаязны да күп сынады. Анын карьера эшләргә омтылышы сизелә иде. Эшчән, төгәл. Һәркемнән иртә торып эшкә тотына. Ләкин анын минуслары бар: холкы йомшаграк, кешене жәлли. Өстәвенә биографиясендә дә чатаклык бар... Юк, дип Шаязнын үзенә көндәш була алмавын ачыклады рәис. Аны эш аты итеп файдалануны ният итте.

Һаман вәгъдә ителеп торган Хезмәт Герое исемен эләктерер өчен Вил Садриевич колхоз ләмкәсен жене өзелерлек булып тарта бирде. Тизрәк бирсеннәр иде инде. Нигә сузып, желеген суыралар? Ул ихлас күнел белән тырыша бит. Колхоз күп кенә күрсәткечләр буенча өченче урында бара... Вәзыйх рәиснен кыяфәтенә карагач, аны жәлләп куйды һәм беркатлыланып:

—Вил Садриевич, берәр чатаклык килеп чыкса, мина гына сылта?— диде. Аһ, ялгышрак ычкындырды Вәзыйх. Ә гамәлдә рәис һаман шулай эшли, Вәзыйхны, Шаязны, Варисны гаепләп калдыра. Моны белмиләр дип йөргәндер инде. Менә рәиснен шул астыртын эшен Вәзыйх уйламастан фаш итте кебек. Рәиснен йөзенә кара сызыклар типте, бик каты тетеп атар төсле тоела иде, борын яфраклары селкенә, өске ирене борынына таба күтәрелеп дерелди башлады. Ләкин яшен яшьнәми калды, ишек ачылып, анда Сәрия гәүдәсе алга сузылды.

—Вил Садриевич, Авыл хужалыгы идарәсеннән, срочно телефонга!— диде ул бусагадан атламыйча.

—Сәрия, без икебез дә монда юк, кыр станында!—Вил Садриевичнын чырае житдиләнде, мәшәкатьләргә кайтты.

—Һаман ялганлыйм, Вил Садриевич?!—Сәриянен йөзе чытылды.

—Дипломатиягә өйрән!—Рәис кулын селтәде. Сәрия ишекне япты. Кемнендер аяк тавышы ишетелде. Ветсанитар Мотыйк икән. Ул ишектән үк:

—Теге сыернын,—диде,—ите әйбәт чыкты. Механизаторларга бүлеп өләшергә кирәк. Иртәгә бозыла башлар?

Алар сөйләшкән арада Вәзыйх тизрәк ишек ягына атлады.

Вил Садриевич белән Үтәгәнов коридорда очрашты. Эшләр турында сөйләшә-кинәшә, болдыр аша баскычтан төштеләр. Үтәгәнов каршыдагы кибеткә юнәлде. Рәис тагы нинди эшләр онытыла икән дип уйланып торганда, анын янына Чамай килеп басты. *(Исеме Сәмикъ булса да аны шулай атап йөртәләр).* Әле иртә булуга карамастан, ул кызмача иде инде. Вилнен беләгеннән тотып алды. Эре гәүдәле, зур башлы, үжәт мангайлы бу кешедән болай гына котылыйм димә. Чамай кыстарга тотынды:

—Вил Садриевич, телисенме, әйдә, коньяк белән сыйлыйм үзенне? Без күпме дошманлашып беттек ләбаса. Мировойга берне, ә? Юк, чын күнелдән, сине хөрмәт иткәнгә генә...—Ул Вилнен беләгеннән һич ычкындырасы түгел иде.

—Хөрмәт итмисен, ялганлама, Чамай,—диде Вил, кырыс кына.—Ни жомга, ни шимбә, көпә-көндез, эш өстендә сәрхүшләнеп йөрисен. Колхозчыларны котыртып. Кешеләрне тәртипсезлеккә өндәгән шикелле...

—Юк, бернине дә котыртмыйм. Мин премия алдым, сигез мен, бер кварталга. Шуна күрә сине махсус коньяк белән сыйламакчы идем. Чөнки син мине колхоздан жибәрмәс өчен кан тартыштын. Шулай бит? Тик мин барыбер киттем. Менә хәзер помбур итеп күтәрделәр:—Кулы куен кесәсенә тыгылды, аннан катыргы тышлы кечкенә книжкә чыгарды да Вилгә сузды. Вил катыргыны ачып, укырга тотынды. Юри озак укый иде. Вакытны суза, анарчы бу зәхмәттән котылу сылтавы табылмасмы, йә булмаса берәрсе килеп чыкмасмы дип уйлый. Чамай усал кеше, анын белән әчелешле булырга һич ярамый. Үч алуы бар. Болай да ул Вилгә эчендә үч йөртә булыр. Шунын өчен йонын унай якка сыпыра торган мөнәсәбәт күрсәтергә кирәк. Вил озак укыды, книжкәне иясенә сузып:

—Молодец, булдыргансың,—диде елмаеп.—Син алтын куллы бит, шуна колхоздан җибәрергә теләмәдем дә.—Ул Чамайга салам кыстыра һәм йөзенә карап чамалый, салам кыстыру бата үзенә. Әнә хәзер ирен кырыйларында горурлык сызыклары пәйда булды.

—Күпме киртәләр куйдың мина каршы, районда барысы да синең алда биеп торалар иде бит. Әмма алар да ярдәм итә алмады. Синекеннән көчлерәк куллар бар икән, шулаймы, Вил Садриевич! Хикмәт кулда гына түгел, теге заманнар үтте. Ә син һаман теге заман гадәтләрен куасың. Син калдың, Вил Садриевич, ә поездың китте. Утыра алмадың, ә? Нигә эндәшмисең, гаепле кеше кебек.

—Хәзер сезнең заман, хак әйтәсең, Чамай, хак,—дип, Вил аның сүзен җөпләргә мәҗбүр булды. Сөйләшкәндә шулай бара инде. Гаптәшең җаена ятсаң хәерле. Бу сүзләр генә, эш түгел. Биредә теләсә ничек сөйләшергә мөмкин. Тик ике араны кискенләштерүдән качарга кирәк. Сүз-мүз өчен нигә кеше белән конфликтка керергә? Ахмаклар гына бер сүз өчен чәчрәп чыгалар. Сүз сөйләнә дә бетә ул. Ә исерек кеше белән сөйләнә торган сүз—җил тек җил. Тот аннары җил коерыгын.

—Әйе, хикмәт заман гамәлләрендә, Вил Садриевич. Минем сина һич тә ачуым юк, ышанасыңмы? Эчтә ачу-үч саклап йөртә торганнардан түгел мин. Гәрчә үчләнергә нигезем булса да. Син бит минем братны утырттың...

—Мин түгел, суд утыртты,—дип, ипләп кенә бүлдерде Вил.

—Дөрес, суд утыртты,—ди-ди, Чамай йодрыгын авызына китереп ютәлләп алды.—Ләкин алып калырга синең бер сүзең җитә иде.

—Мин җәмәгатьчелек түгел, ул сүзне җәмәгатьчелек әйтсә генә...

—Вил Садриевич,—дип бүлдерде Чамай.—Ул сүзне әйтергә әле соң түгел, братны порукага алырга була. Закон бар, ә?

—Җәмәгатьчелек эшне кузгатсын, мин каршы түгел,—диде Вил, ничек тә ышандырырлык тавыш белән. Әмма Чамайның йөзендә ышанмаучылык чалымнары тагы да куергандай булды.

—Син минем белән уйнама, Вил Садриевич,—дип куйды ул, кулын селтәп. Вил эчтән чынлап та Чамайның тәкъдименә каршы түгел иде. Чамайлар эшчән, уңган кешеләр. Аларда ялкаулык, ялагайлык юк.

—Мин ихластан әйттем, ышану-ышанмау синең эш! Ярый, мин ашыгам, Чамай, минем синеке кебек ял көнем юк,—дип, Вил алга таба карап алды.—Аннары житди мәсьәлә турында кызмача көе сөйләшмиләр...

—Менә монысы дөрес, Вил Садриевич,—дип, хуплап алды Чамай.—Мин теге авыл гадәте кыюлык өчен генә бераз төшергән идем. Ә коньяк белән сыйларга теләвем чын, ихлас! Әйдә, вакытың булса, ә? Бүген бит Корбан бәйрәме икән...

—Вакытым булса да, бармаганны син беләсең бит,—дип, кимсенгән тавыш белән әйтеп куйды Вил—Син акыллы егет, шуны чамаларга тиеш иден...

—Вил Садриевич, зинһар гаеп итмә,—диде, өтәләнә башлаган Чамай. Братын порукага алу мәсьәләсендә Вил аны үзенең кире тормавына ышандырган иде.

Фаяз кайтканда кухняда кайнана, Рабига һәм колхоз бухгалтеры Сәрия чәй эчеп утыралар иде. Ул тиз генә үз ягында өстен алыштырды да, утынлыкка чыкты. Түмәрләр байтак иде, шуларны яргаларга тотынды.

Сәрияне ире ташлап киткән иде. Ирәчтән ерак түгел Акчишмәдә кибетче булып эшли. Сәрия бөтен булганы белән ирен үзенә кире кайтарырга йөри. Ире бүтәннәр аша ишеттергән, Сәриянең үзенә дә әйткән: син бака кебек салкын, бер назың юк, дигән, имеш. Салкын булганга баласы булмаган, имеш. Ни өчен аерылыштыгыз дип кызыксыналар икән ирennән. Ул бер генә җавап әйтә икән, безнең фазалар туры килми, дип. Хатын-кыз һәм Сәрия үзе дә баш вата: нәрсә икән соң ул фазалар туры килмәү? Безнең кайнана грамоталы, аңлата икән: менә ике проводканы бергә китереп ялгыйсың, әгәр фазалар туры килмәсә, лампочка янмый. Ир белән хатын

арасы да шулай. Фазалары туры килмәсә, ярату кабынмый. Ярату кабынмагач, бергә йоклау хайваннарныкы шикелле генә була, ди. Сәрия шул мәсьәләдә Казаннан килгән профессор хатынга күренгән. Ул әйткән, имеш: иренә син һәр көн яна бул. Кичәгедән үзгә бул. Чисталыкны әйтмим дә, ирен белән йоклау алдыннан кайнар суга утырып ал. Чөнки ирләр һәр көн яна нәрсә телиләр, аларга һәр көн яна булсын. Менә фермада эшләп, сыер савып эт булып арып кайта хатын-кыз. Ничек ул иренә яна була алсын? Ул тузган башмак кебек була инде. Тузган башмакны аяк сизми, диләр ирләр, дип Сәрия профессорга сөйләгән... Профессор уйланып калган. Әгәр иренне үзеннән биздерәсең килмәсә, эштә нинди арыган булсаң да, үзенне янартырга әмәл тап. Бары шул гына. Ялгыз каз кебек ялгыз кангырасын килмәсә, кызыкаем, дигән профессор.

Кайнана хатын-кызны "янарту"нын кайбер серләрен белә, имеш. Профессордан кинәш, әмәлләр ишетеп кайткан Сәрия белән кайнана яккан мунчада бик озак юыналар, нәрсәдер эшлиләр. Башта Рабиганы яшь кычыткан суында тоталар. Аны кайтарып куйгач, ике ахирәт үзләре генә калып, мунча пәриләренә әйләнәләр. Кайнана янарту серләрен кызы алдында кулланырга унайсызлана, ахрысы! Чыннан да Сәрия кайнана мунчасына йөри башлагач, янарып, "свежий"ланып бара шикелле. Дикъкать иткәндә, күзгә күренеп яшәргәнлеген шәйләргә мөмкин. Кызы Рабиганы шулай терелтсен, яшәртсен иде ул. Әмма кайнана кызыннан өмет өзгән шикелле.

Сәрия иренең сельпога товар алырга киләсен алдан белә. Ул көнне эшкә бәйрәмчә киенеп килә. Биек үкчәле шпилькалы туфлиен, тар кара юбкасын һәм изүе кайтарулы ачык ак кофтасын кия. Зәнгәр төстәге юка кашнесын муенына сала. Жилфер-жилфер генә йөри. Ул көнне Сәрия елмаеп кына тора, ниндидер күзгә күренмәс канатларда оча. Юк сәбәпне бар итеп урам аша гына булган сельпога керә. Ул холкы-фигыле белән кырыс кына, бигрәк тә ир-ат халкына каты. Ә бу көнне Сәрия йомшаклана. Ушлырак ирләр шунардан файдаланалар. Ниндидер четерекле кәгазьләргә кул куйдырырга киләләр. Сәриянең бүген кәефе күтәренке, юк-барга бәйләнеп тормый, имзасын селти. Юк, ул башын җуймый. Бухгалтер һәрчак аек акыл белән эш итә. Шулай да бүген Сәрия белән уртак тел табып була.

Ирен бер күреп калыр өчен дә ул сельпога чаба. Бервакыт ирен үзенә алып кайткан, дип тә авыз чайкадылар. Имеш, Сәрия шул качкан иренә әйтә икән: мине Казаннан килгән профессор хатын дәвалады, манипуляцияләр ясады. Шул процедураларны алгач, карады һәм әйтте: син хәзер кызлыгына кире кайткансың, диде. Чын-чын! Ышанасыңмы, син хәзер гыйффәтле кыз кебек, диде. Ышанасыңмы, ышанмасаң менә сынап кара...

Шул сүзләрне ишетүгә ире тиз-тиз чыгып сызган, ди. Сельподагыларга: "Сәрия әллә бераз нитә-ычкына башлаганмы, тузга язмаган нәрсәләр сөйләнә",—дип әйткән. "Ул сине бик ярата бит, беткәнче бирелеп ярата, ул яратудан ычкынырсың да шул",—дигәннәр ана. Ир башын чайкаган да бүтән сүз әйтмәгән...

Вәзыйх башта көзге бодай басуын карады. Ала-кола җирләре шактый, күз унайсыз килде. Егерме өченче октябрьдә кар яуды. Аннары кинәт җылытты. Кар җепшекләнде, эреде, ләкин эреп бетмәде. "Соры ботка" булып торды. Көтмәгәндә салкын куырды. "Соры ботка" бозга әйләнде һәм уҗымны җирдән аерды. Тамыры җирдә булмаса, үсенте бетә. Уйдык-уйдык каралар шул афәт галәмәте. Бозып, янадан чәчәрлек тә түгел, күпме җир буш ятачак. Әһ-һе-һе!

Күк рәхимле дә, кайвакыт рәхимсез дә ул. Күпме көч түгеп җирне йомшартасың, ашлыйсың, зур өметләр белән буразнага бөртек сибәсең. Бар карап торганың, яшәвең шул бөртекләрдә. Күккә күзенне төбәп янгыр көтәсең. Теләк телисең, Аллага ышансаң-ышанмасаң да, Аллага ялварасың. Ә күк миһербансыз, бер тамчы янгыр төшерми. Хет ятып җир кимер, юк!

Күк адәм зарын ишетми, ачы күз яшен күрми. Адәм баласы күпме мактанса да, яңгыр яуса—иген була, яңгыр яумаса—иген юк. Ә бит күп тә кирәкми югыйсә, үз вакытында ике мәртәбә коеп кына яуган яңгыр булса—шул җитә. Руслар әйтә: „Два дождя, два грома, и не нужно агронома",—диләр.

Бездә корылык ике елга бер булып тора. Моны исәпкә алып бетермиләр. Бишьеллык планнарда уңышны һаман арттырып язалар. Күк исә синең планыңа төкерә, яңгыр яудырмый. Соң нишләргә кирәк? Корылыкка чыдам иген сортлары булдырырга. Канадада корылыкта да ярыйсы уңыш бирә торган сортлар бар, ди. Бездә яңа иген сортлары чыгару утыз-кырык елга артта калган. Яңа сорт бодай, арыш, башка культуралар бары генетик ысул белән генә чыгарыла. Ә бездә генетик галимнәрне тар-мар иткәннәр. Лысенко шикелле үзешчән галимнәрнең сүзе өскә чыккан.

Институтка кергәч, занятиеләр башланганчы Вәзыйхларны Мәскәү янындагы Ленинские горы хуҗалыгына экскурсиягә алып бардылар. Биредә Лысенконың тәҗрибә участоклары икән. Очы-кырые күренмәгән пыяла белән төрелгән теплицалар. Анда ниндидер кечкенә машиналар, кешеләр эшли. Селекционерлар, дип аңлатты экскурсовод. Шушы тикле зур хуҗалыкны җитәкләү өчен бик башлы кеше булырга кирәктер. Ә Лысенконы самоучка, диләр. Самоучка-академик була микәнни? Аны Сталин күтәргән, имеш. 1935 елда колхозчылар съезды була. Докладчы сөйли: яңа сорт ашлык-бөртек чыгару өчен ун-унике ел вакыт кирәк, бу бик нәзберек, авыр хезмәт, ди. Президиумда утыручы агроном Лысенко кычкыра: "Мин яңа сортны биш елда чыгарам",—ди. Сталин моны ишетә һәм әйтә: "Браво, товарищ Лысенко!" һәм бетте. Лысенконы шунда ук Мәскәүгә алалар. Зур тәҗрибә станциясенә баш итеп куялар.

Лысенкога дан китергән "Пукс" ("Путь к социализму") дигән гибрид үсемлекне күрсәттеләр. Шундый гибрид: өстәге сабакларында кечкенә-кечкенә томат-помидорлар үсә, ә тамырларында бәрәңге бүлбеләре. Томатны өзеп кайсынадыр бирделәр, ул тешләп карады... Бу вегетатив метод белән чыгарылган гибрид-үсемлек. Ягъни күзәнәккә физик ялгау аша барлыкка китерелгән. Мичурин тәгълиматын иҗади үстерү дип бәяләнә икән. Ашлык бөртеге яңа сортын да вегетатив юл белән чыгару мөмкин микәнни? Моны күз алдына китереп булмый. Әмма академик Лысенко шул методны алга сөрә, ди. Генетиканы тулысы белән инкарь итә, аны буржуаз фән дип карый...

Зал шикелле зур кабинетка алып керделәр. Стена буена урындыклар тезелгән. Түрдә гөмбәзле ике зур тумбалы өстәл артында таза инле, зур башлы, тәбәнәк маңгайлы, зур кылыч борынлы кеше утыра. Лысенко шушы икән. Өстендә капчыклана башлаган пиджак, яшькелт күлмәгенә галстук таккан. Ләкин гаҗәп бер нәрсә күзгә ташланды, пиджагенең терсәкләренә ямау салынган иде. Кат-кат күзлим, чын ямау. Моңарчы Мао Цзэдун ямаулы чалбар киеп йөри икән дип ишеткән бар иде. Әллә бу коммунистларның яңа модасымы, ходавәндә?

Ул башын күтәрде, керүчеләргә кинаяле елмаю белән карап торды. Аңа сорау бирделәр. Менә вегетатив метод белән чыгарган гибрид-үсемлекләрне күрдек, ә бу ысулны хайваннар дөньясында ничек кулланырга?

Лысенконың күзләре сүрәнләнде, сорауны ул үзен төп башына утыртырга теләп бирелгән дип кабул итте.

—Әйдә, бәхәсләшәбез?—дип куйды ул горгылдап. Тамагында рак, имеш.—Ләкин бүген срочно эш. Икенче вакытта инде...—Шуны әйтүе булды, түрдәге ишектән әллә ничә кеше килеп керделәр һәм академикны чолгап алдылар...

—Соныннан беленгәнчә, конкрет бәхәстән ул хәйләләп кача торган булган. Ә генетик галимнәрне тар-мар итүе белән фәнгә, илгә бик зур зыян ясаган. Бу очракта ирекне кысу икмәксез калуга китерә. Генетик галимнәр ел коры килгәндә уңыш бирә торган яңа сортлар чыгарган булырлар иде. Ирек һәм икмәк, бер-берсенә бәйләнгән шул. Демократия булган илләрдә икмәк тә бар. Сугыштан соңгы елларда ачлык шул тикле

фаҗигале булмас иде. Гади халык егерме еллап ипи күрмәде. Ялгыш идеология аркасында бер кеше илгә күпме зыян китерде. Бары Татарстан нефтен сата башлагач кына, чит илдән ашлык алу өчен валюта булды. Нефть аркасында гына ничә еллар икмәккә тиендек. Моны халыкка белгертмәделәр. Халык үзебез үстергән ашлык дип белде. Үзебезне генә түгел, демократик ил дигән союзникларны да туйдырырга кирәк иде...

Вәзыйх чәчүчеләр яныннан тиз китте. Монда—Шаяз, ул булганда тыныч йокларга мөмкин. Кинәт көн суытып җибәрде, җил төньяктан исә икән. "Әллә кар яварга исәпли инде",—дип куйды Шаяз, плащлы инен кыймылдаткалап. Ул арада вагоннан Ленизa килеп чыкты. Ул сырган куртка һәм джинсы чалбардан иде.

—Ә-ә, иртәгә шимбә көн ләбаса. Мин кырда булырга, учакта пешкән аш ашарга яратам,—дип көлде ул. Вәзыйх исә: "Монын авырга узып маташкан чагыдыр",—дип уйлады. Андый вакытта хатыннар, үзләре дә белмәстән, төрле капризларга биреләләр.

Ул авылга кайтып кергәндә күз бәйләнгән иде. Урамда кул арбасы тарткан ике хатын очрады. Вәзыйх аларны таныды. Арбада картаеп бетәшкән Мәсәппиха карчык иде. Аны бер малаеннан икенчесенә алмаш-тилмәш йөртәләр. Өч малае авылның өч төбәгенә төпләнгән. Әмма карчык бер улына да сыймый. Чират белән генә тоталар. Ә малайлар нефтьтә эшли. Таза тормышлылар. Шифер белән япкан алты почмаклы йорт. Кайнар су белән җылытыла торган казан куелган. Мунча, абзар-кура. Малны күп асрыйлар. Машина үз кулларында. Тик бер әниләренә генә урын юк. Нәрсәдән бу? Элек бит крәстиян тормышы чагыштырмаслык авыр булган. Аягы—чабатадан, башы нужадан чыкмаган. Әмма ата-ананы күпсенү ише әхлаксызлыклар булмаган... Киленнәре башка авылдан, бик усал, гуҗлар ди. Өй җиһазы, келәм, холодильник һәм башка әйберләр туплау буенча үзара ярышалар. Күзләренә ак-кара күренми, ди.

Өйдә Рәмисә аны ачу белән каршылады.

—Ну, сволочь син, Вәзыйх,—дип кычкырды.—Бүген мунча якканны белдең бит, белдең... Акча алдыңмы?

—Җир упсын, истән чыккан, Рәмисә. Акча да булмады!?

—Акча булса, бүген унай көнем иде. Уф, синең белән мөмкин түгел!

—Әле суынмагандыр, әйдә.

—Акча булмады дисең бит?

—Унай көнең бетмәгән бит әле?

—Юк, кәефемне җимердең! Сволочь син!—Рәмисә пыр-пыр килде дә караватына менеп ятты. Вәзыйх бер сүз кайтармады. Гаилә низагында иң отышлы нәрсә дәшмәү икәнен үзләштергән иде инде. Чишенде дә ашамый-эчми генә диванына сузылды.

Хатын белән бозылышу җаңга авыр, күңелне гел тырнап-талкып тора. Вәзыйх Рәмисә белән килешеп яшәү әмәлен эзләде, әмма таба алмады. Хатынында ялган горурлык бик көчле, Вәзыйхта да җитәрлек. Мондый холык начар тормышта үскән кешеләрдә була. Бер өйдә бер-беренә ышкылып йөргәндә эндәшмичә, сөйләшмичә, бер-беренә арка белән тору бәгырьне сава. Менә ничә көн инде алар сөйләшмиләр. Өйдә әллә нинди яный торган шомлы тынлык хөкем сөрә. Вәзыйх эштән кайта да диванына сузыла. Әмма озак йоклый алмый. Әйләнә-тулгана. Диван пружиналары шыгырдаганга уңайсызлана. Рәмисәнең дә караваты тавыш чыгаргалап куя. Нишләргә? Ник кешеләр бер-берсенә булган ачу, үпкә сызыгын үтә алмый газапланалар? Нәрсә тота, мин-минлекме, кирелекме?..

Иртән идарәдә Вәзыйхка сәер эш куштылар. Хикмәт шунда: кичә төнлә Чияле буендагы умарталыкны басканнар, ди. Биш умартаны машинага төяп алып киткәннәр... Ревком кешесе буларак, шул чэпэны урында тикшерергә кирәк. Умартачы Әгъзам астыртын кеше. Кемнәр беләндер сүз берләшеп, кыек юлга озатмады микән дигән чыш-пыш шикләр дә йөри. Ревком Мөхетдинов районда киңәшмәдә икән. Югыйсә, бу аның эше.

Вәзыйх ишек төбендәге җигүле тарантаска утырып, дилбегәне кулына алуга, әллә каян теге тиле Атаян килеп чыкты. "Кая барыш? Мине дә ал әле",—дип, тарантас читәненә тотынды. Умарталыкка дисән, тагылачак. Әллә инде кая барасымны белгән, йөзе кара? Вәзыйх тиз өлгерде:

—Эх, парин, Әлмәткә сручны чакырдылар!—диде, йөзенә кайгы чыгарып. Атаян кулын өметсез селтәде дә калды. Ни акыллы, ни дурак, диләр аны. Сәер эшләрен сөйлиләр. Авылга нефтьчеләр, юл салучылар, машиналар килеп тулган елларда крестьянның гомерлек юлдашы чабата кинәт юкка чыккан. Кешеләр ботинка кигәннәр. Атаян исә үзләренен урам коймасына чабата элеп куйган, кырыена: "Сау бул, чабата!"—дигән язу кадаклаган. Ә Вил Садриевич беренче тапкыр килгәндә идарә ишек төбендә Атаян очраган да:

—Нишләп синең авызың зур, әллә син кеше ашаучымы?—дип әйткән. Вил Садриевич, шомарган таш, ачуланмаган, көлгән дә бетергән. Бераздан колхоз милкенә ягылуда тотылган өч-дүрт кешене рәис арестовать иттергәч, "Әллә син кеше ашаучымы" дигән сүзләрне халык исенә төшергән. Дөрес сүзне диванадан ишетерсең, ди.

Умарталыкка Рәмисәне дә алып барырга кирәк. Юлда сөйләшерләр, аңлашырлар. Ахмак мин-минлек киртәсен үтәргә сәбәп булыр... Өй бусагасын атлауга, теге почмакта тегү машинасында утыручы хатынына дәште:

—Рәмисә, безне ахириең Мәвия умарталыкка кунакка чакырды?—дип ничек тә җитди, ышандырырлык итеп әйтергә тырышты. Рәмисә борылып карады, йөзенә икеләнүле елмаю чыкты. Иренен шаяртканын сизгәндәй булды, шулай да күңеле йомшады шикелле.

—Шыттырмыйсыңмы?—диде йөзен күтәреп һәм шаяру кабул итәргә әзер кыяфәткә кереп.

—Карета ишек төбендә! Киен дә чык!—Вәзыйх, ара җайлана башлаганга куанып, тарантас төбенә салырга иске юрган шаламасын култыгына кыстырып тышка атылды.

Рәмисә кешелеккә киенгән. Аксыл-соры костюм-юбка, модалы зәңгәрсу болонья плащ, аягында лаклы туфлиләр. Ул юрган почмагы белән аякларын төргәләп утырды. Дилбегәне тотып Вәзыйх аның кырына урнашты. Зур юлга чыгуга җирән ат элдереп алып китте. Үкличәне узгач, юл такыр басу межасыннан барды. Ат ыргылып-ыргылып юырта, юл сикәлтәле. Рәмисә иренең беләгенә тотынды. Юбкасы сыдырылып капрон кигән аякларының матур аклыгы күзне кытыклап ала иде"

—И-и, Рәмисә, синең аякларың бик аппетитлы икән?—диде Вәзыйх, шаян тавыш белән кеткелдәп.

—Ә-ә, аякларым гынамыни?—Рәмисә дә көлеп җибәрде. Вәзыйх атны тыя төште, дилбегәне ике куллап тартты.

—Юк, син болай да күз яндырырлык анысы...

—Ник аякларга ирләрнең исләре китә?

—Белмим. Кеше хатыны булсаң, тагы да матур булыр идең?

—И, чукынган адәм,—Рәмисә җилкәсе белән Вәзыйхның иңенә төртеп алды. Үзе тыенкы гына көлде. Шулай арадагы боз эри башлагандай тоелды.

Алда урман күренде. Ул каралы-яшелле төскә кергән. Каен, усаклар яфрак ярган, ә имән белән юкәләр кара булып утыралар. Юлдан ерак түгел түбә җирдә факел янып тора иде. Ялкыны зур кызыл флагны хәтерләтеп җил унаена әле болай, әле як-якка сөрлегә, шомлы кыштырдау авазы ниндидер дәһшәт тудыра. Җанны куркуга охшаш хис били. Дини карчыклар факелны җир астыннан тәмуг уты чыгып яна дип ышаналар. Догаларын укый-укый ашыгып китәләр.

Юл ике урман арасына килеп керде. Ачыклыкта сөзәк кенә тау. Анда сарык көтүе таралган. Юл буенда траншеяга салырга әзерләнгән самовар юанлыгы торбалар ята. Озынлыклары егерме метрлап булыр... Кинәт көтүче этенең чиный-чиный ыргылганы күзгә чалынды. Вәзыйх атны туктатты. Кызык бит. Икенче мигелдә саргылт-кызыл йомгак шикелле нәрсәнең әле

болай, әле тегеләй зигзаг ясап сикергәләп чыкканын күрделәр. Бу төлке икән. Эт чиный-чиный шуны куа иде. Менә эт тегене куып житә, эләктерә дигәндә, төлке торба эченә кереп китмәсенме. Эт килгән кызуга торба эченә башын тыкты, ләкин гәүдәсе сыймагач, елый-шыңшый кире чигенеп чыкты. Көтүче килеп житте. Башын селкеп торды да, тизләнде, битен жиргә терәп, торба эчен күзәтә башлады. Ары башын томала да, тимерчыбык белән тартып аларсың, дип кычкырды Вәзыйх. Эт чиный-чиный бөтерелә, хуҗасына карый. Көтүче торып басты:

—Күренми ул анда,—дип кулын селтәде. Шул мәлдә эт томырылып алга ыргылды. Торбаның ары башында сары йомгак тәгәрәгәне күзгә чалынып калды. Көтүче: Әх!—дигән ымлык белән ухылдап шунда чапты. Төлке дә, эт тә күздән югалдылар. Агачлар арасында төлкене бер эт тә тота алмый инде.

Вәзыйх дилбегәне тартты. Умарталыкка тиз барып життеләр. Зур гына аланда әллә ничә рәт тезелеп киткән оялары. Ничектер әкияти курчак шәһәрне хәтерләтеп тора иде алар.

Умарталык өе янында брезент түбәле "ГАЗ-66" тора. Милиция килергә дә өлгергән. Вәзыйх атын тукталып маташканда өйдән ике сержант чыкты, һәм, машиналарына утырып, китеп тә бардылар. Ул арада:

—И-и, Рәмисә Салаховна, сезне дә кузгаттылармыни?—ди-ди, Мәвия пәйда булды. Умартачы Әгъзәм хатыны мәктәптә жыештыручы, Рәмисә белән серләре килешә. Анарда әллә ни кайгыру сизелми. Шулай да күз кырыйлары кызарган, керфекләре дә укмашлы. Милиция алдында елагандыр, ахры.

Өйгә керделәр. Ак такта белән бүленгән бүлмәләр. Иң түр бүлмәдә зур өстәл, анда коштабакта пешкән кукәй өеме, эмаль савытта кәрәзле бал кисәкләре елтырый. Милицияне сыйларга әзерләгәннәр булса кирәк. Ләкин алар табынга утырмаганнар, күрәсең. Рәмисәне Мәвия эчкәре алып кереп китте. Вәзыйх ана иярә иде, ян бүлмәдән Үтәгәнов килеп чыкты да аның жиңеннән тотты. Ул инде сәрхүшләнгән иде, күзләрендә энәләр елтыравы күренә. Вәзыйх аны күрүгә шат иде, теге вакытта эштән алганда Үтәгәнов аны яклады. Бергә эшләгән дуслары, үз шкураларын саклап, Вәзыйхны тибәргәндә, Үтәгәнов аларга каршы чыкты. Вәзыйхны аралап калды... Вәзыйх Үтәгәновның керделе-чыктылы холык-фигылен белсә дә, ул чактагы тәвәккәллеген онытмый.

—Сез минем "ангел-хранитель"—диде ул, аның кулын кайнар кысып. Үтәгәнов ияген генә селкетеп куйды, Вәзыйхны дворга алып чыкты. "Мин Әлмәттә милиция белән бер ишек алдында,—диде ул Вәзыйхның сораулы карашын чамалап.—Шуларга эләгеп килдем..." Амбарлар янына атладылар. Теге кырыйдагы амбарның ишеге ачык иде. Бусагада кочагына чирекле зур шешә кыстырган Әгъзәм тора иде. Сүрән генә исәнләштеләр. Ишек төбендәге эскәмиягә утырдылар. Әгъзәм чирекләне кочагыннан төшермәгән көе хәлне аңлата башлады.

...Караңгыда утарга йөк машинасы килеп кергәне ишетелде. Фаралары яктыртмый. Мин чыгарга итеп, ишеккә бардым. Этәм, ачылмый. Тышкы яктан терәү салганнар икән. Тәрәзә капкачлары да тыштан ябылган иде. Мин кычкырдым да кычкырдым. Тегеләр биш умартаны төягәннәр дә шылганнар... Иртән хатын килгәч кенә ишектән терәүне алып чыгарды...

Вәзыйх кыр сумкасыннан кәгазь-каләм алды да, тезенә катыргы куеп, акт яза башлады. Ревизия өчен рәсми документсыз булмый. Әгъзәм сөйләгәннәрне дә тәфсилләп теркәде.

—Стройбатныкылардыр, мөгаен,—диде Әгъзәм, нәтиҗә ясагандай итеп.—Тайсуганнан Бишмунча аша Азнакай юлына асфальт тоташтыралар...

—Нигә алардан шикләнәсең?

—Машиналары "Урал" иде кебек. Аларда гына. Еш кына үкличәләрдән сарыклар да югала.

—Бүген булмаса, иртәгә тотачаклар,—диде Үтәгәнов, тәмәкесен бик тәмләп суыра-суыра.

—Ай-һай!—дип, Әгъзәм башын як-якка чайкады. Мондый хәл узган елда да булган. Әллә Әгъзәм берәр ерактагы шофер белән сүз берләшеп эш итәме дигән чыш-пыш сүзләр йөри иде. Умартачының бик ышанычлы төстә баш чайкавы ничектер шул шикләрне хәтергә китерде. Ләкин Вәзыйх моны кычкырып әйтмәс. Кешегә нигезсез бәла салудан курка ул... Вәзыйх акт язып бетерде дә, Үтәгәновтан, Әгъзәмнән кул куйдырды. Аннары үз имзасын селтәде. Төп эш эшләнгәнгә канәгать булып, өйгә керделәр. Өстәл артында Рәмисә белән Мәвия сыйланып утыралар иде инде. Авызлары авызда. Әгъзәм стаканнарга күрән төстәге эчемлек салып чыкты. Эчемлек кырку-зәһәр иде. Коньяк диярсең. Чынлап та ут кайнарлыгы белән аякларга төште, аннан кулларга, башка менде. Рәмисә исә: ике аягымның берсен дә тоймыйм, нәрсә эчерттегез?—дип, шырык-шырык килеп алды. Әгъзәм тагы берне салып эчергәч, бөтен тәнгә рәхәтлек тулды. Баш миендә әллә нинди акыллы уйлар кузгалып, телдән ычкынырга сорыйлар иде...

Вәзыйхлар кайтып китте. Үтәгәнов калды. Ачы бал пары тәэсирендә Вәзыйх үзенең “Семеновод” тикшеренү-тәҗрибә совхозына күчәсе килү хыялын әйтте. Анда перспектива, аспирантура, диссертация, диде. Хатыны Рәмисә, аны тыңлагач, тирән итеп көрсенде:

—И, Вәзыйх,—диде,—сине беренче имтиханда ук кисәчәкләр бит. Неужели үзеңнең статусыңны әзрәк чамаламыйсын?..

Вәзыйх бер сүз дә әйтә алмады.

Шул кичне мунча кереп чыккач, Рәмисәнең кәефе тагы да күтәрелде. Икесе хозурланып чәй эчеп утырганда, ашыкмыйча салмак кына тәфсилләп, ул үзенең үткәнен сөйләп алды. Тирән итеп уфтанганда уенчык туптай йомры күкрәкләре бер менеп, бер төшеп тибрәнделәр.

—Әни мине кечкенәдән үк яратмаган,—дип сөйләп китте ул.—Мин бишектә чакта башыма мендәр каплаган да, үзе лапаска чыгып киткән. Янәсе, ашыгыч эш белән. Очраклы гына күрше хатыны килеп кергән, мендәр астында гырылдаган аваз ишеткән. Мендәрне читкә эткән, минем зәңгәрләнеп килгән борын, авызымны шәйләгән. Соңгы сулышымны алып ятам икән...

Әти сугышка киткәндә әни еламады. Кара коелып йөрде. Бүтән хатыннар күз яше койдылар, әнинең күзләрендә чык та булмады. Озатканның икенче көнендә әнинең йөзе яктырган, нииндидер эчке канәгатьләнү белән нурланып тора иде... Күп тә үтмәде, әтинең үле хәбәре килде. Мин почтада идем. Бүлмә рәшәткәсенә тотынып басып торам. Теге яктан почтальон апа мина кара пичәтле кәгазь суза. Авыз эченнән мыгырдый: әтиең сугышта үлгән, ди. Мин әле берни аңышмыйм. Башым буталды. Кабатлап сораштым. Апа төшендерергә итеп сөйләнде. Мин кәгазьне тотып өйгә чаптым... Өйдә беркем дә юк. Әни мәктәп китапханәсендә эшли. Барырга курыктым. Бу кәгазь ялгыш түгелме дигән уй килде башыма һәм мин тагы авыл Советына чаптым, кәгазьне почтальонга суздым. И, бала, бала, ди-ди уфтанды хат алучы апа. Әниең кулына бирермен. Шулчак бер кулы яраланып кайткан кеше бүлмәгә туп итеп килеп керде. Ул ярыйсы ук салмыш иде. Кызып, кычкырып сөйләнә. Сүз арасында:

—Ризак мәрхүм булган икән,—диде.—Авыр туфрагы җиңел булсын инде. Мин армиядә чакта минем кызга өйләнгән. Әмма—язмыш. Банат хәзер минеке! Едерино майть!—Шулай мактанды да чыгып китте. Мине күз кырыена элмәде. Бу Шәкер исемле кеше икән.

Бер-ике атна үтте микән, теге: Банат минеке! дигән кеше безгә килеп яши башлады. Әнинең шатлануын күрсәң... Артта сөйләнделәр: “Бәлки Ризак исәндер, үлмәгәндер. Андый хәлләр булып тора. Банат бигрәк оятсыз кыланды инде! Страм! Мәет өстенә ятырга Шәкернең ничек намусы барды икән?!.”

Бу кешедән мин курка идем. Шуңа аңа кырын торам, бүре кебек ачулы карый идем. Табында утырганда әни минем җилкәмне бора, нигә кырын утырасың, бу синең яңа әтиең, ишетәсеңме, син аңа “әти” дип дәш, йәме?—ди-ди сабак бирә. Мин, борылып, аңа туры карый алмыйм. Тамагымнан

берни үтми башлый. Табыннан ач көе торып китәм. Шәкер какча битле, зур шөкәтсез борынлы, зур авызлы, озын буйлы адәм. Өрәге бик каты аның. Эчкә баткан күзләре синен эченә үтәрдәй итеп, сине капшап карыйлар. Ул колхозда амбарчы булып эшли. Акмаса да тама дигәндәй, табында бөртек ризыгы күренгәли. Йә катлама, йә борчак кумәче. Элек бәрәңгегә дә тиенми идек.

—Шәкер-әтиен булмаса, бу арыш катламасы төшенә дә кермәс иде,—ди-ди, әни ашаган саен тукый. Ашаган сыныгын белән башка суккан кебек итә.

Мина бер дә рәт калмады. Биш классны көчкә-көчкә өчкә тәмамладым. Шәһәрдән әтинен туганы кайткан иде. Минем хәлләрне күреп, гаҗәпкә калды. Сине теге китаптагы усал үги ана кулындагы ятим кыз иткәннәр икән",—дип, бик җәлләде. Мин дә еладым. Ул мине үзе белән алып китте. Алар 1-Малая тыкрыгында частный квартирада яшиләр икән. Анда тирән чокыр-ярлар. Чокыр буйларында колач юанлыгы юкә агачлары. Җәй өчен бик күнелле җирләр. Чокырны чыккач та, мәктәп бар икән. Мин шунда өч ел рус мәктәбендә укыдым. Бик русча укырга теләгән идем. Теләгемә ирештем. Ләкин хәерченен алдына ипи куйсан, аны карга алып китә, ди. Һич көтмәгәндә, япь-яшь килеш, әтинен туганы вафат булды. Сугышта анын башы яраланган булган... Мина эш эзли башладылар. Күршедә генә үз йортлары белән югары катлам кешеләре—яһүдләр яши икән. Ире институтта профессор, хатыны теш врачы. Бер малайлары бар. Ни укымый, ни эшләми. Бик бай яшиләр. Минем эш: базарга барып азык-төлек алып кайту һәм шуларны табынга әзерләү иде. Чехов базары якын гына. Бик тиз барып кайтам" Минем аш-суны яраттылар. Мин иренмим, мичкә ягып, шулпалы өчпочмак пешереп өлгертәм. Үзләре дә акча турында вакчыл түгелләр. Профессорнын мине институтка кертергә нияте бар иде. Кемнәр беләндер сөйләшүләр алып барды шикелле. Шул елларда Израиль дәүләте төзелде. Бер кичне яһүдиләр җыелып шул вакыйганы бәйрәм иттеләр. Кочаклашалар да елыйлар: терәгебез булды, без хәзер юкка чыкмыйбыз, ди-ди сөйләнәләр. Кешеләрдә милли хиснен нинди тирән һәм фаҗигале булуын шунда күрдем.

Ләкин әти-әнисе эшкә киткәч, теге эшлексез егет мина бик хәтәр бәйләнә иде. Анардан качып чыгып китәм. Шунсыз мөмкин түгел. Ике кулымны бергә китереп тота да чишендерә башлый. Профессор эштән кайтканда мин каршына килеп басам: менә улыгыз мина бәйләнә, Владимир Лазаревич, дим, өйдә бер минут тынгылык бирми, өстемне салдыра, нишләргә? Менә әбәд әзерләргә комачаулады...

Кич белән хуҗалар кинәш кордылар. Хуҗабикә мина шунда ук җай чыгып торганын әйтте. Дус хатыны өй карауччы таба алмассынмы дип үтенгән икән.

Яна хуҗаларым Гоголь белән Зур Кызыл урамы кисешкән почмак йортта яшиләр икән. Өч бүлмә, барча унайлыклары бар. Үзләре бары өч кеше. Хуҗа кеше таза, нык гәүдәле, кабактай зур шәп-шәрә башлы, калын иренле, эре тешле, юаш кыяфәтле. Ул Нур Вафа дигән күренекле шагыйрь, имеш. Хатыны чегәнне хәтерләткән карасу озынча йөзле, зур авызлы, сузан буйлы Ирина Моисеевна. Анын яһүди булуы әллә каян беленеп тора иде. Ул мине беренче күрүдә үк ошатты булса кирәк, ачылып сөйләшә башлады. Ин беренче эш итеп мине өченче кечерәк бүлмәгә алып керде. Анда стена буенда ике карават тора. Түрдәгесендә бер җыерчык битле, тиле-милерәк карашлы, башына ак яулык бәйләгән карчык утыра иде. Ул безгә башын да бормады, үзалдына мәрткә киткән сыман бөрешеп тын гына тора. Ирина Моисеевна коридорга чыккач анлатты. Минем төп эшем менә шушы карчыкны карау икән. "Бу карчык иремнен әнисе, бераз аны тегеләйрәк, әле яна гына "сары йорттан" чыкты. Ангы-минге вакытлары була, ычкынып китә. Хаҗәтен үти алмый. Кайчак өйдән чыгып югала. Шәһәр бетереп эзләргә туры килә..."—диде ул мина.

Хуҗабикә шактый кырыс, нервылы икән. Кайчак кинәт шырпыдай

кабынып китә торган өянәге бар. Андый чакта иренә дә кычкыра, яман сүзләр белән тетеп ташлый. Миңа да, карчыкка да эләгә. Әмма үзе болай әйбәт, вакчыл түгел. Ул Нур абыйны иртән ашагач-эчкәч үз бүлмәсенә кертә, өстәл артына утырта да өстеннән бикләп ала. Шулай итеп эшләтмәсәң, берни язмый ул, ялкау, ди. Кич белән эше турында отчет сорый. Үзе бер авыз сүз татарча белми. Нур абый аны теләсә ничек "утырта" ала, билгеле. Өйдә үзара русча гына сөйләшергә, шундый тәртип куелган. Әмма Иринаның татарларны өнәмәвен белгертәсе килми. Миңа карчык белән татарча сөйләшергә рөхсәт итә. Өй караучыны башта ук татарка булсын дип куя. Билгеле нәрсә, эчке яратмау һәрчак тышкы "ярату" бизәкләренә төренгән була.

Карчык бик еш матавык чыгарып тора. Кай арададыр серванттан хрусталь рюмканы эләктереп ала һәм мендәр астына яшерә. Яисә матрац арасына куеп вата. Иринага зур эш булгандай, тавыш кубарырга җитә кала. Нур абыйга очып куна: бар, әнә анаң тагы кофемолканы урлаган, тоткасын сындырган дип чәр-чәр килә. Нур абый нишләргә белми. Кофемолканы карчык кулыннан тартып ала. Аны җиңелчә төрткәли-төрткәли караватына китереп яткыра. Ирина миңа каеш тоттыра. Тәртип бозып, тыңламый башласа, карчыкны каеш белән сыптырырга куша. Врачларның рекомендациясе шулай, ди. Мондый авыруларга бердәнбер килешә торган "дару" каеш белән сугу икән. Әмма карчык мине күпме генә газапламасын, бер тапкыр да сугарга кулым бармады.

Әмма өйдә кайчак иркенлек булып ала. Эш шунда, Ирина еш кына Мәскәүгә китә. Үзе Мәскәүнеке икән ул. Анда әти-әнисе, зур квартиралары бар, ди. Кызлары шунда музыка мәктәбендә укый икән. Ирина китүгә Нур абыйның кыяфәтенә шатлык нурлары тибеп чыга. Без туйганчы татарча сөйләшәбез. Нур абый кайчак матур бер яңа көйгә җырлап та җибәрә. Минем сүзләргә композитор яңа көй чыгарган, дип аңлата ул.

Мин Нур абыйны нигәдер җәлли идем. Юаш, намуслы кешегә нинди явыз хатын туры килгән бит! Мөгаен, ялгышкандыр. Мәкерле кызлар башта биреләләр дә, авырга уздым, дип, егетне үзләренә өйләнергә мәҗбүр итәләр икән. Нинди кешене эләктергән бит әҗәткана! Хәлләр китереп кыскач, Нур абый да бу усалдан котыла алмагандыр шул. Партиядән өрдерүләре бар. Аннары бөтен биографиянә кара ягыла.

Нур абыйның миңа дикъкате ничектер үзгәрәк була башлады. Үзе аска гына карап йөрсә дә, күз кырые минем арттан иярә иде. Аркам белән карашын тойган кебек булам. Әрсезләнеп алга чыгып торган күкрәкләрем астан гына аның карашы тиеп узганын сизми калмыйлар. Ара-тирә сүз алышканда йомшак мөгамәләле була бара. Ир-атның үзеннән күпкә яшь туташка күзе януы, бәлки, аның ихтыярыннан тыш та буладыр. Бернинди исәп-хисапсыз, бернинди өмет-нигезсез. Биредә өметләнергә тамчы да шанс юк. Чөнки җирлеге юк, киләчәге бары һәлакәт кенә. Үзе теләп кем һәлакәткә барсын?

Бер көнне Ирина Мәскәүгә китте. Өйгә кинәт җан кергәндәй булды. Нур абый шатланып бүлмә-читлегеннән чыкты. Коридор буенча эре-эре атлап йөренә иде. Аны гүя алыштырып куйдылар. Хатыны барда мәче кебек шыпырт кына, йомыкый гына сөйләшә торган кеше ерткычтан котылгандай башын күтәреп, күкрәген киерә. Таш астыннан чыккандай билен яза, турая, кулларын як-якка чайкый. Күзләрендә, чыраенда күтәренке дәрт очкыннары биешә.

Нур абый, кулы белән ымлап, мине үз бүлмәсенә чакырды. Ул үзенең эш өстәлендәге култыксалы урындыгына утырды. Мин өстәл башындагы урынга чөмәштем. Халаттан гына идем, ачылган тезләремне тиз-тиз япкан иттем. Нур абый башын иеп утыра, уйга чумган иде. Менә ул башын күтәрә төшеп, урындыгы белән миңа таба борылды, учын тамагына куеп алды. Муен төене селкенә иде. Ниндидер бик әһәмиятле нәрсә әйтергә җыенган шикелле ничектер унайсызлана. Шома битләренә беленер-беленмәс алсу тасмалар ясалган.

“Рәмисә, зинһар мине шашкан кешегә санама,—дип, төерле тавыш белән башлады ул. Тамагын кыргалады да дәвам итте.—Син бик гүзәл кыз. Яшьлегең белән матур, болай да гаҗәп вәсвәсәле! Сине беренче күрүдә үк әллә нишләп киттем. Барча тойгыларым ургылып ташыган кебек булды. Уйларым, хисләрем сиңа төбәлде. Ходавәндә, нәрсә бу, дим, үземә эчтән? Бу хәлгә ышанып җитмим. Өч-дүрт көн аңгы-мингә йөргәннән соң, сине өзелеп яратуымны аңладым. Юк, мин сине ышандырырга теләмим. Мин яратуның ни икәнен белми идем. Яшьлегемдә дә белмәдем. Менә хәзер аның нәрсә икәнен аңладым. Ни хәл итәсең, аек аның әйтә, бу һәлакәткә китерә торган ярату, ди. Моңа худ бирергә ярамый... Әйе, әйе, Рәмисә, бу төш кенә, нинди татлы төш. Төш булып калсын!..—Ул кинәт кузгалды, кулларын сузып, мине үзенә тартып алды. Кочагына кысып, битләремнән, ачылган күкрәкләремнән үбәргә тотынды. Шашып, үзен белештерми үбә иде. Мин дә исемне җуйган кебек булдым. Халат чабуларым ычкынып, ботларым ачылды. Әмма Нур абыйның куллары аякларыма орынмады. Зиһенем эшли, ир-ат якынлык кылырга омтылмый икән, димәк, чынлап ярата. Ярату ихлас икән, якынлык кылу истә булмый, диләр...

Андый хис биләп алганда да, ир-ат, чын күңелдән ярата икән, үзен тыеп калырлык көч таба аладыр, мөгаен. Югыйсә, мин ул гыйфрит кочагыннан ычкынып, бүлмәдән атылып чыга алыр идемме икән, белмим.

Мин төне буе йоклый алмадым. Нәрсә бу? Ирина Моисеевна сизә калса, мине урамга куып чыгарачак. Ин ачы хәл шунда, Нур абый мине яклый алмаячак. Ул хатынынннан куян бүредән курыккан кебек курка. Бел, әгәр мине тыңламасаң, тиешле җиргә барып әйтәчәкмен, дип котын ала ул аның...

Ике-өч көн качып-посып йөрдем. Нур абый да исән җыярга өлгергән иде, ахрысы. Бу “подпольный” сөюнең беленүе ихтималын күз алдына китерә булыр. Бүлмәсендә ах-ух килеп йөренгәне колакка чалына иде.

Ул бер көнне бик җитди, уйчан чырай белән ишектә күренде һәм мине үзе янына алып керде. Машинкасы өстәленә утырган иде. Эчендәге хисләр давылы бераз тына төшкән шикелле. Тик соры ягымлы күзләре генә очкынланып янганы беленә.

“Их, Рәмисә,—дип, тоныкт тавыш белән керештe ул.—Минем шашынуны чынга алма! Миңа хисләрен уяна күрмәсен, яме? Синең бәхетең алда. Вакыты җитәр... Шуны әйтергә телим, Рәмисә, сине күргәч, миндә илһам вулкан булып кузгалды. Бер атна эчендә бер җыентык булырлык шигырьләр язылган. Нинди ихлас тойгылы, тирән фикерле әйберләр. Укыйм да, аптырыйм, неужели болар минем каләмнән төште икән, дим...

Әмма безнең мөнәсәбәт үзгәрмәсен, минем хакта син юкларны фантазияләп алданма! Бу хәл ике арада гына калсын бер истәлек булып, тамыр җибәрмәсен берүк!

Мин кызарып, ияк кактым. Ул дәвам итте:

—Күпме көчләр сарыф итеп төзегән тормышны җимерү мәгънәсез эш. Алданырга ярамый. Мин алай артык талантлы булмасам да, төшеп калганнардан түгел. Менә СССР Верховный Советы депутаты иттеләр. Мине руслар бик ярата. Язалар: “Нур Вафа большой друг русского народа”,—дип. Ни өчен? Беләсеңме, татар шагыйрьләре, язучыларында милли шаукым булгалый. Җаннарын милли корт кимерә. Ә мин башкачарак уйлыйм. Аларны тәнкыйтъ иткәлим. Эшемне бәялиләр. Депутат итү алар гамәле. Менә бу шигырьләрне иң яхшы рус шагыйрьләре тәрҗемә итәчәк. Сталин премиясенә үткәрергә вәгъдә итәләр. Бар гамәлләр руслар кулында бит!.. Ә-ә-ә, тукта, Рәмисә, нигә йөзең кара коелып китте, ә? Әллә мине милләтен сатучы дип уйладыңмы? Юк, бу сату түгел, бары шартларга җайлашу гына! Шартлар, хәлләр адәм баласыннан көчле, өстен, беләсеңме, Рәмисә, татарны рустан ныграк күрәлмаучы татарлар бик күп. Барсы да тормыш җае, карьера өчен! Җайлашмасаң—бетәсең. Әнә Грозный вакытында татар җайлаша белмәгән. Шуның аркасында күпме кан түгелгән? Ә башкортлар җайга ятканнар, акыллырак булганнар. Киләчәк буынга җайлы мирас

калдырганнар. Ә татар киләчәк буынга русларның безгә кырын каравын гына калдырган...

Бер-ике көннән Ирина Моисеевна кайтты. Нәрсәдер сизенгән кебек бик игътибар белән күзәтеп йөри башлады. Миңа шуны белдерде: без тиздән Мәскәүгә күчәбез, Нурның депутат эшләре дә шунда була. Үзенә урын табарга кара...

Нур абый: "Хәзергә бездә торсын, мин ана унайлы эш җайлармын",— диде. Шуңа Ирина күтәрелеп бәрелде: "Әһә, сез шулаймы: Вон! Вон!"— ди-ди, төнлә мине өйдән сөрде.

Мин Царицино авылы янындагы Азино поселогында баракта торучы таныш апа янына киттем. Ишеге бикле иде. Шунда синең котельныйга килеп кердем...

—Син моны ни өчен миңа сөйләдең?—дип сорады Вәзыйх.—Менә миңа нинди зур кешеләр гашыйк булганы бар, син кадеремне белмисен, дип әйтү өченме?

Рәмисә эндәшмәде, үпкәләгән сыман, икенче якка борылып утырды. "Ул шагыйрь аламасы Рәмисәне "үтүкләгәндер", мөгаен. Хатыны юкка гына куалап чыгармагандыр,—дигән уй килде Вәзыйхның башына.—Әйдә булсын, ул мәсьәләдә мин единоличник түгел..."

Вил Садриевич үз бүлмәсендә бухгалтер керткән кәгазьләрне карап утыра иде. Күз төпләре шешенкеләнеп тора, йөзенә саргылт тут йөгергән. Вәзыйх барча эшләр, кирәк-ярак, бугаздан топкан хәлләр турында сөйләп бирде. "Чәчү эшләре төгәлләнеп килә",—диде. Рәис, гадәтенчә, үзенең күрсәтмәләрен әйтте.

Тәбәнәк буйлы хәрәкәтчән берәү килеп керде. Алдынгы комбайнчы Җәмлиев икән. Култыгында тар гына фанер кисәге. Алар озын гына бер чокыр аймагында яшиләр. Хәер, авылда бер төзек урам да юк. Тау да чокыр, аларны үзәннәр, ташлыклар тоташтыра. Болар үзәнен җен чокыры дип йөртәләр. Җәмлиев узган көз районда иң күп икмәк суктырып алучы булды. Шул җәһәттән алар яши торган чокырга Җәмлиев Җәдит урамы дигән исем бирелгән иде. Авылга аз булса да культура чаткысы керергә тиештер бит... Җәмлиев туры рәис каршына килеп култыгындагы фанерын өстәлгә куйды.

—Урам исемен зинһар миннән алыгыз,—диде һәм фанерга төртте. Анда майлы кызыл буяу белән: "Җен Җәдит Шайтанович Җәмлиев" дип язылган иде.

—Безнең авыл мәрәкәсез булмас.—Рәиснең хәтәр ачуы чыкты. Күз аклары әйләнеп, ялтырап китте.

—Бала-чага кулыдыр инде,—Вәзыйх моңа әһәмият итмәскә кирәк дигән төстә иде.

—Минем балаларны, вак женнәр, дип ирештерәләр,—дип еламсырады Җәмлиев.—Елап керәләр. Ул чокырдан минем исемне, зинһар, алыгыз. Башка исем бирегез!

—Участковыйга әйтербез?

—Идарә ул чокырдан минем исемне алырга дип карар чыгарсын!

—Шул гынамы кайгың? Ярый, синең хакка эшләрбез,—диде рәис, тегенең күзләре шулпалана башлаганын чамалап. Җәмлиев, оялудан башын якаларына яшереп, чыгып китте. Керүчеләр аңа каршы очрады. Авылның диванасы Атаянны милиционер беләгеннән тотып алып керә иде. Хикмәт шунда: идарә каршындагы "чыжым" баганасына репродуктор куелган иде. Эшләпә шикелле конус, алюминий төсенә буялган. Кара таңнан алып төн уртасына кадәр шаулап-кычкырып тора. Янында ике кеше сөйләшә алмый, колак тонып бетә. Атаян кебекләргә тавыш хәтәр икән. Әллә шуңардан Атаян репродукторга ау мылтыгыннан аткан. Бүре ядрәләре белән. Теге, билгеле, ватылган, тавыш тынган. Ләкин моны районга житкергәннәр. Идарәдә сорау алганда да үзенчә бик әзлекле җавап кайтарды:

—Көн-төн ялган сөйли,—диде.—Коммунизм төзелә дип өрә, ә минем

әбинен ашарына юк. Татар русчаны анламый, нигә бушка көч сарыф итәләр? Шул электр көче ферма малларына су жылытыр өчен тотылса да ярар иде...

Гадәттә, болай логикалы сөйләми ул. Милициядән куркудан зиһене ачылдымы? Ул Казанда юләрләр йортында яртышар ел торып кайта. Чырае көл кебек соры, аскы ирене кайтарылып иягенә төшкән, канлы бөрчекләре бар. Өсте-башы шалама, ниндидер тузган шинель киеп йөри.

—Иптәш рәис, сина минус! Кабатланмасын!—Участковый коры кырыс кыяфәт белән читкә карап шулай диде.—Анлашыламы?—Ул, эре адымнар сала-сала, ишеккә юнәлде. Рәис анын артыннан:

—Шыла, шыла,—ди-ди үчекләп калды. Аннары өч пот онга язу язып Атаянга тоттырды. Теге чыгу ягына өстерәлгәндә:

—Ни булмаса бездә, авызын себерим,—дип, культурно гына сүгенеп куйды. Кәгазьләрен катыргы эчендә ипләде дә беләге белән кочаклап бухгалтерлар бүлмәсенә кереп китте.

Кәпитән тавы буеннан Әлмәт—Азнакай асфальт юлы уза. Юлнын сул ягында урман буенда нефтьче хәрби янгын командасынын практик занятиеләр уздыру корылмалары. Берничә металл вагон, электрлы, жылыткычлы. Янгынчылар белән алдан сөйләшеп, механизаторларны шунда урнаштырдылар. Килгәндә, борчылып, Вәзыйх сумкасындагы приборны кат-кат карады. Барометр теле төшә, әмма болытлар бик сирәк. Бүген-иртәгә яумаса, эш харап. Бодай, арпа сон чәчелде. Туфракта дым аз иде. Тишелми ятса, нишләрмен. Минем күзне дә ачырмаячаклар!

Вагоннар янында беркем дә күренми иде. Пешекче хатын да бүген вагонда, ахрысы. Вәзыйх атын бәйләде дә вагонга кереп ятты. Балта чапканчы түмәр ял итә.

Тыштан ниндидер тавыш килә иде, Вәзыйх, уянып, исен жыеп, тынлап ятты. Варис белән Яшә нәрсәгәдер әйткәләшәләр. Алар гел шулай. Варис бик унган, япьтәш егет, Яшә бераз пошмасрак. Варис звеновод, ул кызулый, тегенен бик ашыгырга исәбе юк. Яшә үзенә бер тракторда, башка загон алып эшли. Варис белән бер загонда эшләүдән баш тарта. "Ул каудар кеше,—ди,—кая ашыкканын үзе дә белми",—ди. Алар бер-берсен өнәмиләр. Шулай да әйбәт кенә эшлиләр. Варис исә Яшә хакында: "Анын колагын кисеп алып китсеннәр, ул борылып та карамый, шундый үшән",—дип әйтеп куя. Ләкин Яшә эшне жиренә житкереп башкара, шуна күрә ана ышаныч та зуррак. Дөрес, Варис та эшне жиренә житкереп эшли, эш өчен бернәрсәсен дә жәлләп тормый ул. Авыр булганда бераз сыкраучан, хаклык таләп итеп сүз кузгатучан, ә Яшә ни генә булса да дәшми, эшли генә. Авыр булса да, анардан бер ым ишетмисен.

Әмма бу ике тракторчынын шәхси каршылыклары бар иде. Моннан ике ел элек Варис армиядән кайтып, Энже исемле кызга өйләнә. Варислар тырыш кешеләр, терлек-туарны күп асрыйлар, туйны да бик шәп уздыра. Сер сынатмый торган горур затлар. Туй чынлап та бик мулдан була... Ләкин ике-өч атнадан Энже Варистан китә дә бара. Өенә кайтмый кыз, ә туп-туры Яшәләргә килә һәм Энжене биредә якты йөз белән каршы алалар. Бу хәл күпләрне гажәпкә калдыра. Варислар кебек баллы-майлы йорттан кеше китәме, юләр! Энженен акылы юк икән? Бераз ычкына башлаганмы әллә ул кыз? Шундый егетне кемгә алыштырган бит? Варисларнын кукрайган борыннарына чиертте, ансы әйбәт, әмма кызнын үзе өчен начар булды шикелле? Бай йортны ташламаска кирәк иде, дип, төрле сүзләр, юраулар китте. Ә ни өчен Варисны ташлаган? Барысынын да әнә шуны беләселәре килә. Бу мәсьәләдә башсыз кешенен дә фантазиясе эшләргә тотына. Варис армиядә чакта Энже белән Яшә йөргәннәр икән, сүз дә куешкан булганнар, ләкин Варис кайткач кызны үзенә карата алган. Варис булдыклы кеше. Ул берәр нәрсәне бүтәннен авызыннан тартып алырга ярата, бу анын көченнән килә торган гамәл. Варис сизеп ала, кызнын күнеле бераз Яшәгә таба авыша төшкән һәм бик тырышып

Энженең йөрәген яуларга тотына. Яшә исә бу көрәшкә катнашмый, әйдә, кыз үзе теләгәнен итсен, Варис та үзе теләгәнен итсен, дигән кебек сабыр гына читкә тайпыла. Алар, гомумән, гаугага керергә базмый торган нәселләр. Каршылыкка килсәләр, барыбер җинелеп калачаклар. Шуны эчтән тоеп, читкә авышалар: талаша-кычкырыша белмиләр, кешене сүз белән җиңәргә тырышу сәләте аларга бирелмәгән. Варислар кешене сүз белән дә, эш белән дә җиңә алалар, үткеннәр, унганнар. Унганлыклары ихаталарыннан да күренеп тора. Биек койма, калай түбәле сигез почмаклы йорт, таш келәт, ак мунча, ул абзар-кураларда тычкан да йөрешле түгел. Өе дә аның пар белән жылытыла. Колшәрип станциясеннән күмер алып кайтып өйгән, әллә ничә елга җитәрлек. Пар казаны аерым бүлмәгә урнаштырылган, мунчага да шуннан кайнар су килеп тора. Кыскасы, оҗмах. Энҗе шул оҗмахны ташлаган да киткән. Ул абруйлы сыер савучы, үзенә-үзе хуҗа. Кулына йөз житмештән ким алмый. Нигә ул кеше корган оҗмахка кызыксын? Бу бик анлашыла, күпләрне гаҗәпләндерми дә. Иң аптыраштa калдырганы шул: Энҗе туп-туры Яшәләргә килә. Ә Яшә һәм әнисе Энҗене кабул итеп алалар. Энҗегә бер караңгы чырай күрсәтмиләр. Яшә мин-минлекле кеше түгел, юкса әйтер иде: кешедән калганны мин ник алыйм?—дип. Үзе әйтмәсә, әнисе малаен котыртыр иде: бераз кешеләрдән унайсызлан, үзеңне ташлап, дөресрәге, үзенә хыянәт итеп, бүтәнгә чыкты, ә син шул түбәнлекләрне онытып аны кабул итәсең? Кешеме син моннан соң, әллә хайванмы?.. Кайбер ана шулай әйтеп, улын астан чарлар иде. Ә Яшәнең әнисе Әкълимәттәй Энҗене кунак итеп каршы ала, аның кулындагы чемоданны да күрмәмешкә салышамы, күрмиме, чәй әзерләргә керешә, табын янына утырта. Чәй эчә-эчә сөйләшеп китәләр, Әкълимәттәй шунда чемодан турында сүз куша: "Болай чемоданнар белән кая барасын, кызым?"—дип сорап куя. Энҗе турысын әйтеп сала:

—Мин, Әкълимәттәй, Baристан киттем, менә Яшәгә килдем,—ди.—Ул кабул итсә, сездә калам, кабул итмәсә—өйгә!

—И-и, бала җаным,—дип өзгәләнә Әкълимәттәй. Яшә теге якта йоклаган чак икән. Яшәгә кычкыра. Яшә чыга. Энҗене күрә дә, сөенечтән елмая. Хәлне тиз аңлап ала, гүя бары да шулай буласын алдан белгән, сабыр итеп, Энҗене көтеп торган.

—Алар барысы да минем өстән командалык итәргә тотындылар,—дип сөйләп бирде Энҗе.—Хәтта Варисның энесе дә миңа тегене ник эшләмәдең, моны ник болай иттең, дигән була. Үләрсең хурланып. Әллә мин аларга асраумы? Вәт...

—И-и, бала җаным, шулай булмый соң? Син дә фермада уйнап йөрмисең...

Энҗе тагы бер-ике сәбәп әйтә дә, боларга карап, нәрсәдер көтә. Яшәгә төбәлә. Варис Яшәнең дусты. Бергә үстеләр, бергә укыдылар. Менә хәзер шундый хәл. Яшәнең йөзендә елмаю бетә, аңа эчке уй төшә. Энҗе белә, әгәр Яшә күп уйланса, карарсызлана гына, шуның өчен ул аны карашы белән ашыктыра.

—Йә, Яшә, ни дисең, ни дисең?—дип, башын кызуырак эшләттерә. Һәр ымын аулап кына тора.

—Рас син шулай телисең икән, Энҗе, мин инде, үзең беләсең...—ди Яшә ныклы гына итеп һәм елмаюы нурлары бөтен битен тутыра. Хәтта әрекмәндәй зур колаклары елмая Яшәнең.

Шулай бергә тора башлыйлар. Тормышлары бер көйгә салына бара. Ләкин күп сүзләр ишетергә туры килә Әкълимә апага да, Яшәгә дә. Ә Энҗе бик әйбәт, аңа да гайбәтне олаулап ишеттерәләр. Кеше гайбәт сүз сөйләргә бик ярата бит! Кайбер кеше гайбәт сүз ишетсә, чиреннән терелеп китә, билләһи! Бигрәк тә хатын-кыз арасында шулай. Хатын-кыз бер-берсен аяп тормый. Психологлар моны аңлаталар, бу нәрсә аларның табигатеннән килә, имеш. Булса да булыр. Тормыш бит хатын-кыздан башланган. Башта алар ир-атны үзләре сайлап алганнар һәм тормыш итәргә өйрәткәннәр. Үзләрен баш итеп караганнар, бар кешеләрне үзләренә буйсындырырга

яратканнар... Шул властьне бүлешергә омтылучы икенче хатын-кызны дошман күргәннәр. Хәзер дә шунын бик ерагайган чалымнары беленеп куйгалый икән, нишлисен?

Варис баш ия торган түгел, ярый хатын китте әле, дип көлгән, шатланган булып сөйләнеп йөри. Бәлки эчтән генә өмете дә булгандыр, Энже кире кайтыр, әмма мин аны кабул итмәм, дигән кинәнүле, рәхәтне татырга әзер торган уйлары да булгандыр. Ул горур кеше, бер яктан егетлеге дә шунда дияргә була. Озак та үтми икенче авылдан бер кыз алып кайта. Яшәп китәләр. Кемнен кемдә эше бар?..

Вәзыйх тракторлар янына чыкты. Баш тракторчылар бәхәсләшә, ә ярдәмчеләре заправка белән йөгерешә, солярка, су ташыйлар иде. Варис бик хәсрәтчел кыяфәттә үзенекен анлата.

—Юк, син тракторыннын маен алыштырырга тиеш,—дип, Варис Яшә тракторына таба атлады. Анын картерын ачып, мерник белән майны учына алды да күрсәтә-күрсәтә:

—Кара, әнә төсе дә үзгәргән, бармагына буяп тикшер, ябышкаклыгы беткән, сизәсенме? Ышкылу сыйфаты кубәйгән. Йә, сизәсенме?

—Ну, сизәм, шуннан ни?—Яшә бер дә ачусыз гына тынлый, әйдә, такылда инде такылда дигән сыман.

—Майнын ышкылу үзлеге зурайгач, системанын да көче кими, димәк, мотордагы узеллар бер-берсен кыршыйлар, ашыйлар, бетерәләр. Мотор берничә мәртәбә тизрәк туза. Ә безнен экономия буенча йөкләмәбез бар... Һе...

—Син мина әлифба өйрәтмә, мин аны гына беләм. Ә майны еш алыштырсан, май күп китә бит, экономия шул буламы?

—Нәрсә әле нервыга тиясен? Мотор—бөтен система, фил белән кырмысканы чагыштырып булмый. Моторнын гомерен озайтырга кирәк, май ул нәрсә?

—Беләм, майны еш алыштырсан, мотор көчлерәк була, күбрәк тарта һәм тизрәк туза да...

—Юк, тизрәк тузмый, гомере озая, озаккарак чыдый. Без бер үк дәрәҗәдә моторнын гомерен озайтырга һәм күбрәк эшләтергә тиеш... Механизм әйбәт эшләгәч, ягулык та әз тотыла...

—Ике куянны берьюлы тотып булмый... Син әйтерсен инде...

—Безгә ике куянны берьюлы атып алырга кирәк тә...

—Ике дип, берсеннән коры калуын бар,—ди Яшә, киная белән...

Шул чак аш әзерләүче хатын вагонынын ишеген ачып кычкырды:

—Ашлама килеп житмәгән әле, кече әбәд ясап алырга була.

Барысы да кулларын чүбек кисәкләре белән сөрткәләп, аннан юынгычта сабын белән юып, вагонга керделәр. Вәзыйх та юынып керде. Өстәлдә пешкән кукәйләр өелеп тора, савыт белән атланмай, шикәр һәм күпереп пешкән ап-ак күмәч, буы бөркелеп торган кайнар чәй.

Тиз-тиз генә бик тәмләп чәй эчтеләр, шул арада ашлама төягән машина да килеп житте. Ишекне чыкырдатып ачып, эре кыяфәтле Даян төште.

Варис, Яшә, Вәзыйх, һәм бүтән механизаторлар кәгазь капчыклар белән ашлама күтәреп, тракторлар янына киттеләр. Пешекче апа вагон кырыендагы өстәлгә ашамлыклар куеп, Даянны сыйлый башлады.

—Ничек сон, Фәнүзә белән борчак пешәме?—Апа сөйләнергә, сер алырга, серне башкаларга чәчәргә ярата иде.

—Пешәр дип өмет итәбез,—диде янаклары ризык кабудан бүлтәйгән Даян.

—Кыз бик һавалы, борнай гына, баш бирерме?

—Ничауа, тәртә арасына кергәч...

—Характерын күрсәтер әле, күрсәтер. Нык тор! Нәселләрендә бар. Фәнүзәләрдә яшәргә сөйләштегезме?

—Әйе.

—Лесничийнын барча байлыгы үзенә була инде. Йорт-абзар житкереп

чиләнәсе юк. Алпавыт йорты кебек. Фәнүзәнең йөргән егете бар икән, дип ишетелгән иде. Ташлаштылар микәнни?

—Әйе, ташлашканнар.

—Әйләнә-тирәдә тилгәннәр очканы сизелмиме? Матур кызга тәмгы сузучылар күп була. Матри малай!

—Сизелә, апа, сизелә. Фәнүзә өчен көрәш байтак булды, әле дә тынып беткәне юк,—диде Даян, нindидер хәстәрле хужа кеше кебек.

—Шулай булмый ни, Фәнүзә үткер, байлыгы да бар.

—Апа, мине санлар микән ул, ә?

—Хатынны баштан өйрәт, колынны яшьтән өйрәт, ди.

—Ай-һай, өйрәтерсең аны! Сине, апа, ирең ничек өйрәтте?

—Безгә ир сайлау тәтемәде, энем. Без: ирең эт булсын—китергәне ит булсын, дип тордык...

## 9

Төн урталары булгандыр, кемдер ишекне дөбердәтте. Эчтә ишек келәсе чылтырады, баскычка Шаяз чыкты. Ул өйалды лампочкасын кабызды һәм аксыл плащ кигән фельдшер хатынны күрде. Теге ашыгып аңлатырга тотынды: шул Әдәс хатыны—бозау караучы Сәрдәнең хәле начар, Әлмәткә илтергә машина кирәк. "Мондый эшләр белән Ирек шөгыльләнә, нигә аңа бармадың?"—диде Шаяз йокылы-уяулы.

Фельдшер кулын гына селтәде:

—Шул гаунага ялынергамы? Ул игелек эшләсә шунын хакын кайтармый калмый. Тизәген бизмәнгә сала бит ул! Һи-и-и!—Ул Ирекне шәхсән өнәми иде. Араларында нидер булган, ахры.

—Минем дә машина юк, хатын права алган, үзе йортә. Нишләргә сон?—Шаяз тиз-тиз өстенә киенде. Алар Югары очка таба атладылар. Урам тып-тын. Тузан һәм чык исе борынга керә, төнге салкынлык аркага үрмәләп чымырдатып ала иде. Баганадан төшкән ут челтәре аша бик куе томан булуын шәйләделәр. Кесәл кебек куе томан ера-ера шофер өенә життеләр. Симәнә алмаштыру өчен кичтән икмәк төяп элеваторга киткән иде. Кайтып житмәгән, ахрысы? Шулай да хужа хатынны уятырга туры килде. Юк, кайтмады, диде хатын, канәгатьсезлеген яшермичә. Икенче шофер тагы да еракта—яр астында яши иде. Аны да кузгаттылар. Ул илтергә риза, ләкин машинасы ватык, йөрми икән. Нindидер детале ашалып чыккан.

Янә бер шоферга сугылдылар. Әле күптән түгел генә кемгәдер утын алып кайтырга урманга киткән. Менә сиңа кирәк булса! Нәрсәдер эшләргә кирәк бит. Аптырагач, идарәгә кайттылар. Шаяз үзе белгән телефоннарга чылтыратырга тотынды. "Ашыгыч ярдәм"не алып булмасмы? Юк, берсе бер җавап бирми. Шәһәр йоклый, телефоннарны өзеп куйганнар. Алар фельдшер белән үз машиналы кешеләрне барладылар. Монсы саран, бер тиен өчен чукыныр, дип фельдшер кире какты. Кешеләр бүтәннәр өчен бирәр эш эшләргә бер дә теләмиләр. Өченчесенә дә әйтәсе килми, чөнки үткәннәр белән күзгә төртә: колхозда мине кыерсыткан идегез, әнә нефтькә кердем дә хезмәт ударнигы булдым. Шуңа машина чиратсыз бирделәр. Әһә, кирәк булдыммы? Кешегә санамаган идегез... Юк!

Ахырда Сөләй очына килделәр. Анда бер аяксыз сугыш инвалиды Ильяс абзый тора. Аның быел гына кайтарылган "Запорожец"ы бар. Ике малае да механизатор, әтиләренә машинаны сәгать кебек итеп көйләп торалар.

Ильяс абзыйны уяттылар. Мәсьәлә ун минут эчендә хәл ителде. Малайлар машинаны кызу-кызу әзерләделәр. Ильяс абзый ак яка, галстук, эшләпә киеп баскыч башына чыкты. Баскычтан төшү аңа кыен иде. Ике малае ике ягыннан җинел генә кул очларына тоттылар да, күтәреп килеп "Запорожец" кабинасына кертеп утырттылар. Фельдшер да алга урнашты. Машина, билгеле, ручной иде. Ильяс абзый кабызды да авыруны алырга элдерделәр.

Шаяз идарәгә сугылды. Сәгать биш тулып бара икән инде. Нәрәт алырга бригадирлар килә башлады. Рәис өйдә булмау сәбәпле, бүген нәрәт эшләре

белән Ирек шөгыльләнергә тиеш. Әһә, әнә үзе килеп житте. Шаяз иркен сулап куйды. Бригадирлар Ирек бүлмәсенә керделәр. Ул бригадирларга бик кырыс, бернинди сәбәп белән исәпләшми. Рәистән каты кылана. Анардан шүрлиләр. Ул конкрет, кыска сөйләшә... Үзе әйтмешли, анын "тәртәсе кыска!"

Бригадирлар белән күп эшләрне жайга салгач, Ирек рәисне белешергә китте. Ат караучы Кәли радио бүлмәсеннән тирләп чыкты. Нигәдер ашыкмады. Шаяз янына килеп чүмәште. Чыраенда тиккә кимсетелү сызыклары беленә иде. Папиросын иреннәре арасына кыстырды да, зарын сөйли башлады:

—Менә ат белән эшләүчеләр атны өйләрендә тоталар. Арба буш кайтмый. Акмаса да тама... Ә атсыз эшкә йөрүчеләр алардан көнләшеп дау кубаралар, нигә аларны гына баетасыз, диләр?

—Идарә карары булды түгелме сон?—Шаяз үзенә туры кагылмаган бу мәсьәләнең нечкәлекләрен белеп житкерми иде. Нигәдер Кәли ана бик жәл тоела. Бик риясыз бирелеп эшли ул. Әмма шунын бәрабәренә һаман кагу-сугу, шелтә күрә. Ана йокы бик әз эләгә. Әнә күз алмасы тамырларына кан сауган. Янак сөякләре очланып чыккан. Тәне дә шыр сөяккә генә калган шикелле. Анардан шәхси зар бервакытта ишетмәссен. Кулы сынса да жиненә яшерә торган кеше. Язмышы шулай күнектергәндер инде.

—Карар белән ни...—диде Кәли, үртәлгән тавыш белән. Ул жәмәгать эшен үзенең шәхси эше итеп күрә.—Атны өйдә тоттырмасагыз, без аттырвәләй нефтькә ычкынабыз, дип янадылар. Вил Садриевич кул селтәде... Матавыгы безгә калды. Ат белән, яки атсыз эшләүчеләрне чиратлаштырып булмый. Анын өчен ат кулдан кулга күчә. Берсе дә атны юньләп карамый. Ат эштән чыга. Атны үзе генә жиккән кеше аны тәрбияләп йөртә. Үзеннән кушып ашата. Сбруйларын да карый, төзәтә. Эшне дә әйбәт эшли. Бар яктан наять. Әмма күпсенүчеләр күзне ачырмый. Ник аларны единоличник итәсен, дип бәйләнәләр. Адәм затындагы көнчелек тикле явыз нәрсә юктыр, валлаһи!

—Кешеләрнең тормышы тигез була алмый инде,—диде Шаяз, Кәлинен борчылуларын уртаклашырга теләп.—Менә бармаклар да тигез түгел.

Шаяз, менә тагы бер өзекне ялгап жибәрдем, дип, күнеллеләнде. Мастерскойга сугылам да өйгә кайтырмын, диде, матаена утырып. Хәтеренә Лениза килде. Нилектән әле? Әһә, бала хакында сүз чыккач, Лениза әйтте: "Әзрәк үзебез өчен яшик, житешербез әле",—диде Шаяз өчен бу көтелмәгән нәрсә иде. Үзен өчен яшәү ничек була, дип, баш ватты. Ленизадан гел көтелмәгән нәрсә чыгып тора. Бүген арыдым, сина мәхәббәтем юк, ди. Мәхәббәтсез бер-береннен кочагына ничек кермәк кирәк... Авыл кешесе көн дә эштә арый, алар мәхәббәтсез генә кушылалармыни?.. Мөгаен, шулайдыр. Инстинкт теләген канәгатьләндерү өчен генәдер. Мәхәббәт өчен дә көч, саулык һәм вакыт кирәк бит. Көчен булмаса, нинди мәхәббәт булсын!

## 10

Вәзыйх вагонда тәне кызышып, авырып ята иде, ат килеп туктаганын ишетеп, баскычка чыкты. Вил һәм Үтәгәнов ана усал күзләрен акайтып карадылар.

—Тракторлар нишләп туктаган?—дип кычкырды рәис. Вәзыйхнын авыруы төсенә чыккан, иреннәре купшакланган, эче калтырый иде.

—Кем эше бу безобразие?—Үтәгәнов та усал тавыш белән Вәзыйхка шелтә яудыра иде.

—Төне буе ремонт белән жыкландык,—дип, агроном сүзен көчкә-көчкә әйтә алды. Ана дикъкать итмәделәр. Авыру булуын исә юри күрмәмешкә салышалар шикелле.

—Гәрүчи китермәгәннәр дисен, син ни карадын?

—Яшә киткән иде, нигәдер бик сонарды. Ватылып ятамы?

—Күпме эш тоткарлана, авызын себерим! Берәү үз эшенә төкереп караганга күрә!—Рәис ачу шырпыларын кабартып әрле-бирле йөренә башлады.

—Күпме простой булган?—Үтәгәновның да чырае тартылган, иреннәре җептәй сызылып кысылган. Күзләре элеккеге хәерхаһлык чалымнарын җуйганнар иде. Әһә, дип уйлады Вәзыйх, рәисне районда утлы табага бастырып кайтарганнар, ахрысы. Шуңа бик ярпачлана.

—Мең бәла белән нефтьчеләрдән запчасть юнәттек,—дип, Вәзыйх башлыкларның ярсыган ачуларын сүндерергә итә иде.—Яшә белән бер-бер хәл булганмы димәсәң...

—Кукуруз чәчкәндә таркаулык! Моны ничек аңларга?—Үтәгәнов үзенең вәкиллек вазифасын күрсәтергә теләгән шикелле, һаман һәр эшне сәясәткә бәйләргә генә тора. Рәиснең дә, вәкилнең дә шелтәләре хаклы, шуңа Вәзыйх бер сүз кире кайтара алмый. Әмма Яшәнең болай соңга калуы тиккә булмаска тиеш, дип, эчтән пошына иде. Ул һәр эшне төгәл башкаручан, әллә кыек юлга кердеме? Әһә, әнә ул килә түгелме соң? Вәзыйхның күз алдында ак мамык кисәкләре очып йөри. Тәне тагын да кайнарланган, аяк очы күкрәгенә тигән чакта пешереп ала. Әйе, "Беларусь" тракторы. Ул мичкәләр төягән арба тарткан. Урман буендагы загон башына юнәлде. Вәзыйх читән арбага утырып, дилбегә кага-кага, шунда китте. Рәис белән Үтәгәновның чырайларында тырпайган энәләр кире яттылар. Пешекче апа аларны чәй эчәргә вагонга чакырды. Алар тәмәкеләрен ташлап, баскычка атладылар.

Вәзыйх барып җиткәндә Яшә белән Даян әйткәләшәләр. Даян машинасын куеп, тракторга утырган иде.

—Син анда күкәй басып чеби чыгарып яттыңмы әллә?—Даян кузовтан гына заправка ясарга шланглар өстерәп маташа.

—Ну, бигрәк озак бозауладың!—Вәзыйхның тавышы теш арасыннан кыжраулы чыкты.

—Зарифуллин бакчасын сөрергә куштылар. Миңа ни?—Яшәнең төсендә гаебен тану чалымы бар иде, Вәзыйх аңа ышанмады, сызгырып куйды. Йотардай булып Яшәгә төбәлде... Зарифуллин сельпо рәисе. Барча тормыш кирәк-ярагы аның кулында. Кем генә булмасын аңа ярарга тырыша. Аш янында куштан бар. Шулай да бик гуҗлана башлады ул. Печәнлек персональный, ике-өч еллык утыны әрдәнәләнгән. Бакча эшләре ин элек аныкы башкарыла. Үзе кыл кыймылдатмый, барсын куштаннар бер-берсеннән уздырып эшлиләр.

Рәис белән вәкил чәй эчеп чыкканнар да вагон күләгәсендә тәмәке көйрәтәләр иде. Арбадан төшеп, Вәзыйх алар янына килде.

—Җайландылармы?—Вил Садриевич битараф кына әнә шулай сорыйсы итте. Вәзыйх аяк кенә кагып алды, эчендә ачу кайный иде.

—Вил Садриевич, Яшәгә Зарифуллинның бакчасын сөрергә куштыңмы?—Вәзыйхның тавышында нервы сизелеп китте. Рәис аңа кинәт төбәлде.

—Белмим, юктыр,—диде ышанычсыз гына. Вәкил алдында сер бирергә теләмичә. Кушкан булуы йөзен читкә алуыннан да беленә иде.—Бәлки, заправкадан соң дип әйткәнмендер?

—Юк, хәзер сөр дигәнсең!—Вәзыйхның йөзе чигенми торган сызыклар белән тулган иде. Рәис йомшый төшеп, әйтте:

—Ярар, Вәзыйх, куертма!

—Күпме вакыт җилгә очты! Кукуруз чәчеп бетергәнче Зарифуллин үлмәс иде әле!

—Әйе, бер йомышны да тыңламас иде.

—Колхозның аңа ни гозере төшсен? Шәхси йомыш кына...

Үтәгәнов та шаян ым белән сүз кыстырды:

—Колхоз эше, шәхси эш... Колхоз эше арткы планда? Үзеңнеке—үзәктә, диләр.

—Юк, алай түгел ул, Ариф туган,—дип, Вил җитди тон белән әйтте һәм

төртелеп калды. Тормышның нинди чатакларына төртелеп сүзе өзелде икән? Аннан Вәзыйхка борылды:

—Син авырыйсың бит, парин,—диде. Бар кайт. Без чәчеп бетергәнне көтәбез. Әнә иреннәрең резинкадай күгәреп тора. Бар!—Ул чын кайгырту белән әйтә иде. Вәзыйх ана, күз угын тигереп алу белән шуны чамалады, һәм аяк какты да, арбага таба атлады.

Кайтып медпунктка керде. Температурасы утыз сигез дә өч иде. Сестра хатын шунда ук ниндидер дару эчерде. Бер ун-унбиш минуттан хәле җиңеләеп киткән кебек булды. Амбарларда, мастерскойларда эш бар иде, ләкин анда барырга ерак, башы да чатный. Шуңа идарәгә керде. Зәйганов бүлмәсендә тавышлар ишетелә иде, ни бар икән дип ишекне ачып карады. Зәйганов аны кул ымы белән үзенә чакырды. Нәрсә бар? Өстәл артында Зәйганов, аның каршындарак эретеп ябыштыручы Сарыймов утыра. Стена буендагы урында Фаяз чөмәшкән. Кыяфәтендә аптырау шикелле чалым. Сарыймов какча битле, бөкшәйгәнрәк юка гәүдәле, кырган башының ике ягында әрекмән колаклар тырпаешкан. Ул эш киеменнән—саргылт кожан пиджәктән һәм чалбардан. Зәйганов, башын Фаяз белән Вәзыйхка таба борып, сөйли башлады:

—Менә карагыз, бездә музейга куярлык кешеләр бар,—диде.—Безнең Сарыймов әкәмәт күрсәткән. Фаязның кайнанасына бер яртылык сорап кергән. Элек тә алган булган икән. Бурычыңны түләмисең, дип тегә карулашкан. Әһә, ышанмыйсыңмы, мә, кызыл билетымны, зарплата булу белән килеп алырмын дигән. Кайнана бер яртылык чыгарып сузган. Әмма Сарыймов партбилетын килеп алмаган. Кайнана Фаязга кушкан, мә, Зәйнаговка илтеп бир, бәладән башаяк, дигән... Йә?—Ул Сарыймовка башын сузып текәлде.

—Берни хәтерләмим, Мөнир Сөнгатович. Билетым югалган дип уйлап йөри идем.

—КПССны яртыга алыштыргансың? Төшенәсеңме? Ленинны сатканcың?

—Берни хәтерләмим, җир упсын! Уф-пуф!

—Нинди ансат җавап, ә? Белмим, имеш. Белмәгәч, ник коега барып төшмисең, ә?

—Мине лечениегә җибәрегез, зинһар!—Аның тавышы тамак төбенә тыгылды, бүтән сүз әйтә алмады.

—Эчмәгәндә әйбәт, честный кеше! Авызына әз генә эчемлек кердеме—тизәккә әйләнә. Бер эчә торган адәм ничә кешенең тормышын боза! Җитмәсә, партийный! Чыныn әйт әле, тагы шулай тизәккә әйләнерсеңме, ә?

—Үземә ышанып җитмим, Мөнир Сөнгатович.

—Әйе, син ант итәсең, антыңны пычратасың.

—Эчәсе килүне аң-акыл көче белән җиңеп булмый, Мөнир Сөнгатович! Бу катлаулы тормышта шайтан суы эчмичә буламыни?!

—Телисең икән, була! Үзеңне йөгәнли белергә кирәк! Үзеңне кулга алырга!

—Менә шунысын булдырып булмый шул! Лечение ярдәм итәр дип өметләнәм!

—Ансың Әлмәт белән сөйләшербез. Бөтен хикмәт үзеңдә, Сарыймов. Күпме вакыттан бирле син безне газаплыйсың?

—Үз йөзенә үзең төкереп булмый...

—Бу аракы нинди иблис? Нишләп ул адәм балаларын җиңә?—Зәйнагов Вәзыйх белән Фаязга карады. Әйтерсең, алардан җавап көтә иде.—Кешеләр әллә нинди көчләрне җиңәләр, ә аракыдан җиңеләләр. Хикмәт нәрсәдә?

—Табигать сере инде,—диде Фаяз.—Белеп бетерим димә. Әнә кырмыскалар. Аларның личинкасын ашаучы бер бөҗәк бар. Шул бөҗәкнең тәне исерткеч бүлеп чыгара. Кырмыскалар шуны ялыйлар да исерәләр. Рәхәт чигәләр. Ә теге личинкаларны кыра. Шул рәвешле нәселләрен эчеп бетерәләр. Кырмыска җәмгыяте яшәүдән туктый. Җансыз кырмыска түмгәге

күрсәгез—нәселен эчеп бетерү әсбабы. Кырмыскада аң юк...

—Адәмдә ан булса да, эчеп, нәселен бетерә.—Вәзыйх та бу хикмәтле сөйләшүгә кушылды...

—Бетерә, бетерә,—диде Зәйнагов бизенгән, ни кылырга белмәгән чырай белән. Аның йөзе чытык, күзләре әрле-бирле тәгәрәшә иде. Ул кызыл яфрак кебек кызыл билетны учында әйләндергәләп карады да Сарыймовка сузды. Теге исә алды да тагы да бөкрәя, бөрешә төшеп ишеккә таба аякларын көчкә өстерәп китте. Зәйнагов уйланып торды, ах-ух килеп, авыр уфылдады.

—Сез икегез дә партиясез большевиклар инде,—диде.—Нигә бу кешене партиядә тотасыз, дисез. Әйтмәсәгез дә йөзләрегез шуны белгертә. Һаман төзәлмәсме дип өмет итеlә. Чөнки бик яхшы кеше. Чыгарсак, бөтенләй чокырга тәгәрәр. Ә болай—партиягә тотынып дигәндәй, өскә үрмәләргә җай була. Нишлисең, тормыш бик катлаулы...

Зәйнаговның бу уфтануларына каршы Вәзыйх, Фаяз әйтергә сүз тапмадылар. Парторг ачы хакыйкатьне тасвирлый иде. Ул рәсми коры кеше. Карьера өчен очко тупламый. Үзенә йөкләтелгән эшне булдыра алганча намус белән эшләп бара. Районда аны либераллыкта гаеплиләр.

Шул мәл бүлмәгә шау-шу килеп кешеләр керде. Парторгка да бер дә тынгылык юк иде. Вәзыйх белән Фаяз чыгып киттеләр.

Даян эштән кайтып килә. Урам уртасыннан атлый ул. Йөрүендә кешенең холык-фигыле чагыла. Аның почмакка, кырыйга посарга кырын эшләре юк, барысы да ап-ачык, күз алдында. Үзе белән бергә. Холкында ятимлеккә үртәлү бар. Шуның өчен дә, бәлки, урамның нәкъ уртасыннан йөри. Кинәт бер капка ачыла, аннан күбәләк кебек чибәр кыз атылып чыга. Кулында китап-дәфтәр.

—Даян абый!—дип, күгәрчен гөрләгән тавыш белән гөрелдәргә тотына.—Тагы авыр мәсьәлә бирделәр, чишә генә алмыйм.—Үзе әз генә кызара, битендәге кызылы әле иягенә төшә, әле муенында пәйда була.—Берсекөнгә контрольный...

—Каяле, һи-һи!—Даян капка төбендәге эскәмиягә утыра. Кәгазь-каләмне алып, мәсьәләгә төбәлә. Даян бөтен дөньясын оныта. Ул кызу-кызу язарга керешә. Берничә формула чыгарып ташлый. Кызның күзләре түгәрәкләнә, күкрәкләре тирбәлә. Даян берни күрми, белми, мәсьәлә чишә. Катлаулы мәсьәлә. Тиз-тиз яза, фикерләрен кулы язып җитешә алмый. Үзе һаман нәрсәнедер яңа белгән кебек: әһә-әһә, әйтеп куйгалый. Яза-яза дүрт-биш бит тула. Мәсьәлә чынлап та катлаулы икән шул. Ниһаять, Даян мәсьәләне чишеп бетерә һәм кызга аңлата башлый. Теге әле аңлап җитми, сораулар бирә. Даян тиз-тиз аңлата һәм калганын үзең аңла, дип, кәгазь-каләмен куеп китеп бара.

Ул тагы урам уртасына төшеп, шуннан әкрен генә атлый. Бераз киткәч, тагы бер капка биге шылтырап ачыла. Кулына китап-дәфтәр тоткан, ак алъяпкыч бәйләгән, толымнарын күкрәк өсләренә үреп салган, буйлы гына бер кыз килеп чыга. Ул әрсезрәк, тегеннән үк Даян абый, дип кычкыра. Аны чакырып китерә, үзе килми. Горур кыз, чөнки чибәр, үзенең бәясен хәзердән үк белә ул. Әтисе дә дәрәҗәле, сельпо бухгалтеры...

Ә түбәккә төшеп җиткәч, аның каршына тагы бер кыз чыга. Моның әтисе дә, әнисе дә гади колхозчылар, нәселләре белән бик тырыш, тәртипле кешеләр. Алар барын да үз көчләре белән табалар, китапча әйткәндә, "гомуми нигезләрдә" яшиләр. Бу кыз үз тырышлыгы белән укырга омтыла. Әмма ничаклы тырышсаң да, математик мәсьәлә бик катлаулы, аны чишеп булмый. Нишләмәк кирәк, кеше һәр нәрсәне кечкенәдән өйрәнергә тиеш. Кызны кечкенәдән өйрәтмәгәннәр, үзе дә өйрәнмәгән. Даянны да беркем дә өйрәтмәде, ул кечкенәдән саннарны яратты. Уенда, гел математика, физика булды. Шуны күзәтә иде: күп әдәби китап укыган балалар математиканы начар үзләштерәләр, йомшак беләләр. Балага бит иң элек әдәби китап тоттыралар, ә математика китабы түгел. Китапханәләрдә дә әдәбият китабы. Нигә шулай? Ә шул әдәбият урынына математика-физика,

химия китаплары булса? Ул китапларны әдәби китап кебек укырга алсалар? Кешеләр акыллырак булмас иде микән? Әллә артык акыллы булырга ярамый микән?

Биредә тынрак урам, чирәм бар, Даян шунда утыра да майдан каралып беткән бармакларына каләм ала, биремне укый. Ул үзен иркен тота, бу кыз аларга кергәләп йөри. Көянтә-чиләк белән әнисенә су да кайтаргалый. Бер генә дә үзен бүтәннәргә бурычлы итеп калдырмас, бик намуслы кыз... Даян мәсьәләнең бөтен нечкәлекләрен аңлата-аңлата чишә. Менә бу буынны болай эшләргә кирәк, чөнки аның гади формуласы менә ничек... Яза, сыза, барын да бәйнә-бәйнә чәйнәп бирә. Кыз аның белән бәхәскә керә, чөнки ул тунбаш түгел, үзенең шөрепләре дә эшли. Ул тырыша, мөстәкыйльлеккә омтылуы сизелеп тора.

—И-и, Даян абый,—ди кыз, соклануын тыя алмыйча.—Синең баш булса миндә?!

—Бәхетең булмаса, баш белән генә булмый,—дип, Даян урыныннан тора. Кыз аның сүзләрен аңлап бетерми, күзләрен зур ачкан килеш карый...

Сәрия тышкы ишекне дөбердәткәнгә уянып китте. Тәрәзәгә карады, төн урталары бардыр. Ул халатын киеп, курка-курка гына өйалды ишегенә килде. Тынланып торды. "Кем бар?"—дип аваз салды. Илфир икән. Отпускага кайткан солдат. Алар узган кайтуында танышканнар иде. Ике атна элек Әлмәттә очрашып, бергә киногa да кергәннәр иде. Илфир болай кыюсыз сыман тоелды, тегенди-мондый яшертен нияте бер дә сизелмәде. Әллә үзем ансыз рәвештә артык ачылып ташладыммы? Нәрсәгә өмет итеп, минем дәрәҗәне төшерә? Салган инде, билгеле, шуна батырайган. Ир-ат әз генә аракы капса, ана хатын кирәк була башлый инде. Табигый хәл. Ләкин мин ана болай җилбәзәкләнергә бернинди ым да белгертмәдем шикелле? Аннан тыш минем күзем, йөзем саткан булса гына инде...

—Юк, ачмыйм, Илфир! Үзеңнең абруеңны төшерәсең, минекен дә! Әмма Илфир ишетергә дә теләми. Ач—бетте! Юк, ачмыйм!

Сәрия өйгә керде. Илфир һаман китмәде. Сәрия ут кабызды. Өйалды ишеге шатыр-шотыр килде. Лом белән ишекне каерган, котырган нәрсә! Менә Илфир бусаганы атлады, ул чынлап та котыруы житкән кыяфәттә иде. Әзмәвердәй таза гәүдә, дугадай көчле куллар аны кочып алды, күтәреп диванга салды. Сәрия кочу рәхәтенә чәйгә салган шикәрдәй эреде дә китте. Аның да туплый алмый калды ул. Ә кыз кочагында Илфир үзен җылы, йомшак, рәхәт караңгылыкка чумгандай хис итте. Сәрия исә, рәхәтлектән һушын җуя язып, үләм, үләм, дип пышылдады...

Иртән Илфиргә шулпалы тәбә әзерләп йөргәндә Сәрия: менә шулай урлап яратышудан да татлырак нәрсә бар микән, дип уйлады. Алдан әзерлексез, көтмәгәндә генә килеп чыккан сөюдә нииндидер бер комар бар. Моның гөнаһлы эш икәнен аң искәртә дә, шул гөнаһны яшерү ләззәте ике йөрәкне бер-берсенә ныграк бәйлиме?

Сәрия ана китәргә вакыт икәнен әйтте. Мактамадан фатир хуҗасының кайтып төшүе бар, диде. Илфир кыерсытылганлык тойды, йөзенә мескенлек чалымнары чыкты. Ул никахсыз туган, ятим үскән малай. Андыйларны авылда гөнаһ балалары дип йөртәләр. Әз генә читләтүне дә сизеп ала ул һәм кәефе китә иде.

—Әх, Сәрия, бәлки без тиз генә очраша алмабыз? Шушы бер-ике көнне мәңге истә калырлык итик, ә?

Аның еламсыраган тавышында нииндидер моңсулык, нииндидер бер фаҗигане алдан сизгәнгә охшаган чалым бар кебек иде. Сәрияне шул нәрсә туктатты... Нишләп болай бу, бер ир белән дә бу тикле хатын-кыз бәхете татыганым булмады, дигән уйлар башыннан кичте аның. Мондый рәхәтлекне сизми идем. Әллә без Илфир белән бер-беребезгә физик яктан туры киләбезме? Ир-ат белән хатын-кыз кушылганда туры килү һәм туры килмәү була, дип сөйлиләр. Илфир аның уйларын бүлде:

—Бер елдан хезмәтемне бетерәм дә туры сина кайтам, Сәрия?!—Күзенә

төшкән маңгай чәчләрен өскә тарады, хатынга сыек зәңгәр боз ярчыклары төсле күзләрен текәде. Сәрия озын халатыннан чыккан йомры тез башларын чабуы белән япкалый иде.

—И, Илфир,—диде,—ул вакытта син бөтенләй икенче кеше булачаксың. Үзгәрәчәксен, барысын онытачаксын?

—Онытмыйм, Сәрия! Юк!

—Ант итмә, Илфир! Кеше йөз мәртәбә ант итә, йөз мәртәбә антына хыянәт итә. Чөнки кеше көн дә үзгәрә. Шартлар аны бәргәли-суккалый. Молотилка барабаны көлтәне ничек сукса, шулай итә.

—Син ышанмыйсын инде?

—Армиядә барысы да бушка бит. Менә тормышка кайт, шестернясының бер тешенә эләк. Аяусыз әйләндерә башлар үзенне. Күпме ышанычын калыр икән?

—Син дә тормышның бер шестернясы. Шулай бит? Мин дә!

—Ну син бик ушлы!—Сәрия халатка төргән йомры күкрәкләрен тибрәтә-тибрәтә көлә башлады.

—Менә ике шестерня тешләре бер-берсен яратып кушылдылар. Бер-берсен әйләндереп алдылар, нинди әйбәт булды. Тормыш механизмы шулай инде, Сәрия!

—Карасана, мин сине егет дип торам, ә син тәҗрибәле ир икән.

—Тел белән тегермән тарту, Сәрия!

—Соң мин сиңа ошадыммы, ә?

—Бик! Син кура җиләге, Сәрия. Әх!—Ул хатынны кулларыннан тотып үзенә тартты, тезләренә утыртып көчле кочагына кысты, сытырдай итеп күкрәкләрен уа-уа яратырга тотынды...

Икенче көнне иртән Сәрия үзләренә Илфирнең әнисе Мәсүфәттәй килеп кергәнен күрде һәм, тиз генә киенеп, алгы якка чыкты.

—И, Мәсүфәттәй, ишекне ватып керде, билләһи менә! Мин гаепле түгел,—диде Сәрия, аның ачулы йөзен күреп.—Башы-күзе тонган иде!

—Шул инде аракыга әз генә авызы тисә, нишләгәнен белми,—дип, Мәсүфәттәй бу бәлане уртаклашкан шикелле итте. Ул Сәриягә болай да каты бәрелә алмый иде. Ни булса да, аңа эшең төшми калмый. Сәрия иркен тын алып куйды. Валчык хәтле бәхет тә бушка гына бирелми. Теге як бүлмәдән суырылган, таушалган кыяфәтле Илфир чыкты. Урта бүлмәдәге өстәл кырыена утырыштылар.

—И, бала, бала, син монда икәнсең,—ди-ди еламсыраган, сукранган тавыш белән ана кеше шелтәләргә тотынды.—Кайда икән дип йөрәгем өзелде. Кем сине болай адаштырды?—Мәсүфәттәйнең тавышы елауга охшаш шыңшуга күчте. Ул тамак төбендәге төерен йотты да, чылана башлаган күзләрен яулык очы белән сыпырып алды.—Кышлык утын әзерлим диган идең. Бакча киртәләре җимерелгән. Мал керә...—Ана Сәриягә зәһәр карашлы күзләренең угын кадап алды. Каты сүз ычкындырудан курка иде. Шулай да бу хатынга нәфрәте бөтен кыяфәтенә чыккан иде. Шуны сизеп торган Илфир телгә килде:

—Әни, Сәриянең гаебе юк.—Ул башын игән, туры карарга кыймый иде.

—И, Мәсүфәттәй,—дип уфтанды Сәрия, ананың хәленә ярарга тырышкандай.—Эчсә, аны тыя торган түгел икән.

—Шул шайтан аның башына җитәр, ахрысы.—Ана юка иреннәрен кыймыл-кыймыл китереп эчтән дога укыгандай итеп алды.

—Син, әни, минем нинди җирдә хезмәт иткәнне белмисен. Бәлки бүтән кайта алмам. Күпсенмәгез күп тормабыз, диләр. Утын булыр ул, ә мин булмам.—Ул борынын тартты. Исереклеге чыгып бетмәгән иде әле. Шул йомшатты, ахрысы.

—Илфир, бар өеңә кайт инде,—диде Сәрия, йомшак кына. Илфирнен йөзендә карышасы килү чагылды, әмма икенче минутта үзен мәҗбүр иткәндәй, ярар сезненчә булсын, дигәндәй, кулын селтәп куйды да урыныннан кузгалды.

—Мәсүфәттәй, моны кешегә чәчеп йөрмәссең инде—диде Сәрия, тагын

да куштанланып. Ана эндәшмәде. Чыкты да, улының киенгәнен көтеп торды.

Илфирнең кыланышлары моның белән генә бетмәде. Бер кичне ул үзен ятим иткән әтисен—Мөхетдиновны кыйнап ташлады. Билгеле, исерек баштан. Моны әнисе ягыннан бабасы Нурмый карт котырткан дип тә сөйләделәр.

Иртән нәрәт биргәндә шушы хәлне Вил Садриевичка әйттеләр. Ул бу вакыйгага аптырап калды, ышанып житмәде. Эшләрен Шаязга тапшырды да Мөхетдиновларга китте. Мөхетдинов үзәктән еракта авылның Бишмунча очы дигән төбәгендә яши иде.

Вил ишектән керүгә караватта ниндидер гәүдә ятуын шәйләде. Марля уралган башы мендәргә чумган, чыраен-битен күрерлек түгел иде. Фатихмы соң бу?—дип икеләнә калды. Өйдә беркем юк. Ул карават кырыена килеп басты. Фатих ыңгырашып черем итә иде шикелле.

—Фатих, ни булды?—дип дәште Вил. Ләкин гәүдә кыймылдамады. Вил баш чумган мендәрнең бер колагын үзенә таба тартты. Һәм күрде, Фатихның йөзен танып булмый иде. Янаклары яшькелт-сары, кан таплары беленә. Кабаклары шешенеп, күз чокырларын каплаган, бите буйлап сыдырылган. Өске ирене бияләй шикелле калынаеп аскы иренен каплап киткән. Вил тагы дәште. Мөхетдиновның бинт ураган кулы кыймылдады. Ул, кулын күзенә китереп, бармаклары белән күз кабагын ачты һәм Вилне күрде. Ул нәрсәдер аңлатырга тели, тик иреннәрен ача алмый, гажизлектән күз алмасы әрле-бирле йөренә иде. Бүлмәгә Мөхетдиновның хатыны Мөзәянә килеп керде. Вилнең исәнләшүенә жавап бирмәде. Тырт-пырт йөренде. Ул Таһияне кан дошман күрә иде. Таһиядән курыкмаган, авылда аның йөзенә бәреп әйтә торган ике-өч хатын булса, берсе Мөзәянә иде: "Сез помещиклар, гади кешеләрне эксплуатациялисез, эшләтәсез дә хак бирмисез. Өй караучы, тегүче тотасыз, бер тиен бирмисез!.." Очрашкан саен Таһия белән Мөзәянә әнә шулай чәкәләшмичә калмыйлар. Вилгә дә эләгә: "Син Фатихка үз эшләреңне өясең, барысын аңардан эшләтәсең. Таптың бер күндәм эш аты. Акыллының йөге жилкәсендә, ди. Шул инде..." Мөзәянәнең кыяфәте Вилгә каты нәфрәт чаткылары белән тулган. Вил моны бик тиз күрде һәм бер сүз дә эндәшмәде. Мөзәянә авыруның башын авырттырып күтәрде һәм иреннәрен бармаклары белән каерып, авызына нидер сала, эчерә башлады. Хуш исле настойка иде шикелле. Ниндидер дару үләннәре салып төнәтелгән булса кирәк... Мөзәянә тагы бер кружка алып кереп эчерде. Ачу белән шак-шок килеп чыгып китте. Мөхетдиновка да бераз жан кергән кебек булды. Сынар күзендә чаткы әсәрмәте беленә иде. Вилнең йөзендә сорау тулган, Фатих моны күреп, иреннәрен жайлады да сакау гына сүзләр әйтә башлады. "Фельдшерица Дамирә килеп яраларны бәйләп китте,—диде.—Ишеткәнсеңдер, армиядән отпускага кайткан Илфир кыйнады мине. Караңгыда су буенда болында бозау эзләп йөри идем, эләктереп алды. Ник минем әнине алдадың?—дип кыйнарга тотынды. Куллары таш кебек каты... Ни дип жавап бирәсең? Ничек ул хәлне аңлатырга? Мәсүфә ул чакта яшь иде, дәшеп керттe дә үз кочагына яткырды... Моны Илфиргә ничек әйтәсең инде?"—Ул, хәле бетеп, тынып торды да әйтте:

—Юк, үземә дә әйбәт булып калды әле,—диде. Вил аны аңламады, исерде, ахры, дип уйлады.—Чын, чын,—дип дәвам итте Мөхетдинов.—Жинаять эшемә жәза алдым. Һәр жинаять жәза алырга тиеш! Илфирнең миннән үч алырга хакы бар иде. Минем гомер буе аның турында йөрәгем сызлады. Бәгыремә кадалып торды. Менә хәзер жиңеләеп калды шикелле...

Вил аны саташа дип уйлады. Әмма Мөхетдинов үз акылында иде. Минә урынбасар итеп Ирекне алу бик шәп булды бит әле,—диде Мөхетдинов идарә эшен кайгыртып.—Синеңчә ничек?

—Бик шәп,—диде Вил, болай сүз өчен генә әйткәндәй.—Шаяз белән икесе барча эшне алып баралар.

—Өчесе диген, Вәзыйхны кая куясың? Эшнең юан башы аның жилкәсендә?

—Әйе, әйе,—дип Вил, көчәнеп кенә килеште. Мөхетдинов кулы талгач, кабагын ычкындырды, күз йомылды. Ул ничектер йокы исереклеге белән озын-озын сулыш ала башлагач, Вил чыгып китте.

Анын Илфирне күреп сөйләшәсе килә иде. Ләкин ул ярты төндә үк авылдан чыгып сызган икән. Авылда бу хәлне тикшергәндә ир-атлар нигәдер дәшми уздылар. Үзләренең гонаһларын уйлыйлар, ахрысы. Хатын-кыз төрлечә чәпчи. Кайсы: “Шул кирәк андый этләргә!”—ди. Кайсы Мөхетдиновны жәлли. Сугыш вакытында колхоз рәисе булып эшләгәндә кешеләргә рәхимле булды. Беркемне дә төрмәгә утыртмады, ничек итсә итте, хөкем кулына бирмәде, дип яхшылыгын онытмыйлар.

## 11

Тәҗрибә өчен илле гектар чамасы көзге бодай чәчтергәннәр иде. Әмма ел унай килмәде. Кар юка гына булып яткан чорда кинәт жылытты, жепшетте. Икенче төнне кинәт суытты. Юеш кар шакырдап бозга әйләнде. Боз ужымны жирдән йолкып үзенә ябыштырды. Тамыры жирдән аерылгач, ужым һәлак булды. Көз көне булган хәл язын карлар беткәч ачык күренде. Жир ала-кола булып калган. Ашъяулык кадәр жирләрдә яшел ужымнар тернәкләнеп маташа. Янәшәсендә уйдык-уйдык кап-кара жир. Нишләргә? Көзге бодайга аеруча әһәмият бирәләр. Ул кукуруз кебек сәяси культура. Бу брак өчен баштан сыйпамаслар, дип Вәзыйх бик борчылды.

Районнан Баш агрономны чакырмый булмады. Яна кеше икән. Никтер, вәкил Үтәгәновны үзе белән бергә алып килгән. Менә өчәүләп жир башында басып торалар. Ужым кыры имәнгеч төстә иде. Ә күктән бертуктаусыз чырый-чырый иткән тургайлар жыры коела. Ул жыр моннары кояш нуры жепселләре буенча агыла да агыла шикелле. Тургайлар да харап булган ужымны кызганып чурылдыйлар сыман. Үтәгәновнын чырае караңгы. Анын башы чатный булса кирәк. Кичә артыграк сыйланып ташлагандыр да, бүген баш төзәтергә өлгерә алмагандыр, күрәсең.

—Күпме уңыш бирер бу?—дип баш агроном Үтәгәновка карады. Күзлеге яшькелт булганга күзләренең ни белгерткәнен чамалау мөмкин түгел. Шулай да Вәзыйхка түбәнсетеп каравы сизелеп тора. Чөнки аңа карамый, аркасын куя иде.

—Ходай бирсә, 6-7 центнер чыгар?—Үтәгәновнын тавышы үчекләүле төксе иде. Үзен бергә алып килгәнгә кәефе киткәнлеген яшерә алмый.

—Бәлки шул көе калдырыргадыр?—дип сүзгә кушылды Вәзыйх, ул туфракнын шактый кибүен күз алдында тота иде.—Бозып, бүген ашлык чәчсән дә, тишелми калуы ихтимал бит.

Ләкин баш агроном анын сүзләрен колагы артыннан уздырды. Ишетмәгән төстә һаман Үтәгәновка карап торды.

—Нигә Ходай бирсә була, дисең, иптәш Үтәгәнов?—Баш агроном гажәпсенгән чырай белән аңа таба ияген селкетеп алды.

—Әллә дөрес әйтмимме, ә? Янгыр яумаса, берни дә үсми ләбаса. Сез, бәлки, үстерәсездер?—Үтәгәнов тавышы тагы да үчекләүле, зәһәрле иде. Әмма баш агроном моны сизмәмешкә салышкан кебек:

—Ходайга таянмыйбыз, шуңа күрә үстерәбез,—дип куйды.

—Сез янгыр яудыра ала торган кодрәт иясе кебек сөйләшәсез?—Үтәгәновнын гаре кузгалгандай булды. Тегенә шырпыны ничек тә авырттырыбрак кадыйсы килә кебек иде. Баш агрономның чырае сүрәнләнде, урта бармагы белән борын өстенә төртеп, күзлеген рәтләде.

—Вәкилне рәтле кеше дип әйткәннәр иде,—диде ул, иреннәрен кысып. Вәзыйхка таба борылды. Әмма өстән карачан чалымы бетмәде.

—Практикада нишли идегез?

—Төрлечә,—диде Вәзыйх,—буынга сикергәч, мал кертергә туры килде. Сөреп, люцерна чәчү дә үзен аклый...—Ул азык берәмлекләре турында сүз куертты. Ни чәчсән, күпме азык берәмлеге чыга... Баш агроном йөзен

читкәрәк алып уйланып торды. Ул да азык бирәмлеген хисаплый иде шикелле.

—Тары чәчегез!—диде Баш агроном, ияген янга кыегайтып. Вәзыйх баш кагып куйды һәм хәзер тары чәчү мәгънәсез икәнен аңлата башлады. Тары, тишелеп, өч-дүрт кыяклы булгач, бер айлап үсми тора, чөнки бу вакытта бик күп тамырлар җибәрә. Аның тамырлары эре була. Менә шул ай буе үсмәгән чорда аны чүп үләннәре басып китә дә томалый...

—Ник гербецид кулланмыйсыз?—Баш агрономның тавышы һаман Вәзыйхны санга сукмау чалымы белән тулы иде.

—Гербицид овсюгны зарарламый...—Вәзыйх тагы нидер дәлилләргә итеп, тегенә карады. Баш агрономга аның сүзләре стенага борчак сибү белән бер иде. Шуңа каушап калды. Җирне харап итә бит бу! Үзенең властен күрсәтер өчен файдалы җайны исәпкә алмый. Зарар булсын, әмма мин-минлеге тантана итсен. Менә ничек кешене үсендергәннәр. Эш урынында ялагайлар үзен күккә чөеп мактыйлардыр. "Сез бик башлы, талантлы!"—дип куштанланалардыр. Адәм баласы йомшак, мактауга мөкиббән китә. Чынлап та мин талантлы дип ышана... Ә бу бәндә тырманы сәнәктән, бодайны борчактан аера белми шикелле. Вәзыйх зиһенен җыеп торды, бәхәсләшеп бары үзенә зыян китерүен сизде һәм сумкасыннан кәгазен алды да баш агрономга сузды. Кулына кәгазь кергәч, баш агроном аны шактый озак укып торды. Үтәгәновка таба борылды:

—Кул куегыз,—диде, кәгазьне аңа сузып. Үтәгәнов карап та тормады.

—Юк, мин махинациядә катнашмыйм,—дип, иреннәре арасына папирос кыстырды.

—Ник алай әйтәсез?

—Җир белгечен тыңламыйсыз...—Үтәгәнов хәзер тары чәчү ярамаганлыгын аңлаганга түгел, бәлки тегенең кәпәренеп кабарган куыгын бераз шиңдерергә теләп шулай шырпыланды шикелле.

—Идарә механизмы өстән аска таба гына эшли бит...—Баш агроном моны ничектер мыгырданып кына әйтте. Акт кәгазен һаман өйрәнә иде. Әллә кул куюдан арт тайдырамы? Вәзыйх та хәзер ушлы, мондый эшләрне үз җаваплылыгына алгалап берничә мәртәбә янды ул. Җилкәнә атланып барырга торучылар бик күп. Шул үз дус-иш, танышларың. Адәмнең һәркайсы үзе яңашәсендәгеләрне ничек тә оту ягын гына карый. Бер авызың пешкәч, салкынга да өрәсең. Актта баш агроном имзасы булса, синең өскә гаеп сылый алмыйлар. Кәгазьне чыгарып күзләренә төртәсең...

Баш агроном актка кул куйды. Төсе барыбер ачылмады. Ул үз исәбенә йотылган, төксе кыяфәттә иде. Үтәгәнов белән бергә тарантаска утырып кайтып киттеләр. Баш агрономны анда машинасы көтеп тора иде.

Вәзыйх кыр станына барды. Таң беленү белән бу җиргә дискалы культивация керттерде. Аннары, кире беткән башлык әйткәнчә, тары чәчтеләр.

Атна-ун көннәр үтте микән, Баш агроном иске бер тиен кебек тагы күренде. Тары белән кызыксынды. Менә тагы ызанда басып торалар. Җирне тоташ овсюг, алабута, сөтле билчән каплап киткән. Кая монда тары? Вәзыйх чүпләрне утый-утый бер-ике тары үсентесе тапты. Өч-дүрт колаклы. Әмма аңа үсәргә бернинди җай калмаган. Куе чүп үләннәре басып киткән. Баш агроном тарының һәлак булуын үз күзләре белән күрде. Ләкин мин-минлекле үҗәтлеге өскә калкып чыкты. Үзенең ялгышуын танысы килми. Моның ансат юлы хезмәттәшеңне гаепләү.

—Чүпне эшкәртмичә чәчкәнсең! Мина ачу итеп!—Баш агрономның йөзенә усаллык билгеләре чыкты. Чырае караңгыланды, кашы-мангае җыерылды, борын яфраклары селкенгәләп тора башлады. Вәзыйх сөтле билчән йолкып алды да агроном янына ук килде. Билчән сабагын сындырды. Сынган җирдә бер тамчы чыкты. Сыер моны ашаса сөте арта, диләр. Ул шул хакта Баш агроном белән кешеләрчә сөйләшергә теләде. Ләкин тегенең кырыс чырае, агу чәчкән күзләре берни күрми, аңардан җавап көтә иде.

—Дискалы культивация, тырма...—Вәзыйх каушап китә язды. Гаебең

булмаган көе сиңа гаеп ташласалар шулай була. Карасана, нинди ертлач, үзе чәчтерде, хәзер миңа аудара.

—Алдама!—Баш агрономның кәтүк гәүдәсе сикереп куйгандай булды. Хәер, ник гаҗәпләнергә, һәрчак стрелочникның гаепле булуы гамәлгә кергән. Нәчәлникләрнең кайчан гаепле саналганы бар? Хәлбуки, төп гаеп аларда булса да... Баш агроном яшькелт күзлеге артына посып, тагы уйланып калды... Аннары:

—Яхшылап эшкәрт, чөгендер чәч!—диде, кискен боеру тоны белән. Вәзыйх аптыраган төстә аңа карап куйды. Әллә ычкына башлаганмы бу адәм? Югыйсә, туфракның бик коры булуын шәйләмәве мөмкин түгел.

—Тишелмәячәк, дым юк,—диде ул, ипле итеп, килешергә теләгән рәвештә. Баш агроном аек акыл белән үзенең мин-минлеген җиңәргә тиеш дип өмет итте. Ләкин бу кешенең тәбәнәк гәүдәсендә ниндидер "пружина" хәрәкәткә килде, ике кулы Вәзыйхка таба сузылды, муены җилкәләреннән купкандай булды. Күксел яңакларында кызыллыклар тибеп чыкты.

—Син кем?—дип кычкырып җибәрде ул. Аның эре саргылт тешләре күренеп китте.

—Кем дип, кеше,—диде Вәзыйх, тәмам аптырауга калып.

—Син кеше түгел, фекал!—Баш агрономның тавышы чырылдап чыкты.

—Фекал, ярар, сезнеңчә булсын,—Вәзыйх кызып китүдән көчкә тыелды.—Җирне әрәм итәргә ярамый!..

—Әйткәнне эшлә—все!—Ул кычкырганда аякларын җиргә тибеп-тибеп алды.—Матри аны!—Хәтәр яный-яный китеп барды... Вәзыйх нишләргә белмичә басып торды. Чөгендергә дым күп кирәк. Хәзер орлыкка тәэсир итәрлек дым юк. Үлән чәчсәң, көз көне сыерларга чабып ашатырга яшел масса өчен мач буласы иде. Илле гектар җир бит, юләр!

Әмма начальник кушканны үтәми мөмкин түгел. Идарә механизмы бары өстән аска таба гына шул.

Вәзыйх Иван Мөхәммәтович белән бер сөйләшкәндә, чыдамады, эчендә яткан гарьне чыгарды.

—Ул нинди самодур, каян килгән?—дип ычкындырды.

—Чү-чү, Вәзыйх,—диде, һәрчак яхшы күңелле Иван Мөхәммәтович.—Син алай пионерларча кыланма. Үзеңә җайсыз булыр. Аның әтисе беләсеңме кем? Обкомда бүлек мөдире! Шул туганлык аша районга ун яңа комбайн алдык. Май кап! Күп сөйләшмә!

—Шул тикле баламут ничек аппаратта эшли?

—Йә, йә, шыбыртама! Ул комбайннар безнең төшкә дә керми иде. Күпме тишек-тошыкны шулар белән ямадык! Барыш шулай, брат, барыш—алыш, дип юкка әйтмәгәннәр.

Иван Мөхәммәтович үзеннән әз генә югары торганнарга каршы сүз әйтергә кыймаучы юашрак кеше. Ә үз буйсынуындагыларга шактый каты ул. Өлкәдә кодрәтле арка таянычы булган баш агрономга каршы ничек сүз әйтә алсын инде? Юк. Әмма җирне кадерсезләү бер дә ярый торган эш түгел! Бу җирдә бит һәркемнең өлеше бар. Өлкәннәрдән алып бишектәгеләргә кадәр! Берәү сабый кулыннан аның ашый торган ипиен тартып алса, ул әтрәкәләмне ничек кенә каргамаслар, ләгънәтләмәсләр иде! Биредә исә җирне пүчтәк адәмнең капризын канәгатьләндерү өчен әрәм итәләр.

Җиргә кадерсез карау ерактан, тарихтан килә. Маркс әйтә: безне аграр программагыз эшләнмәгән дип тәнкыйть итәләр, ди. Шәһәр авылны эксплуатацияләп яши дип тә өсти. Адам Смит өйрәтүләрен исәпкә алып житкерми. Большевиклар да җиргә җылы караш юнәлтмиләр. Столыпин гына җир реформасы кертә. Зур авыллардан чирәм җирләргә күчәргә рөхсәт итә. Шул рәвешле чәчү җирләрен арттыра. Бер-ике елдан моның яхшы нәтиҗәсе күренә. Илдә икмәк күбрәк житештерелә һәм ачлык беразга бетеп тора. Иң әшәке коллык—ул ачлык,—дип яза Столыпин, Толстой белән хат алышканда. Толстой әйтә: җиргә хосусый милек булырга тиеш түгел, ди. Гаделсезлек, тигезсезлекләр җирнең аерым кулларда булуыннан килә. Шул

ук вакытта жиргә бер хужа булу зарури, дип тә өсти... Менә аңла син аны!

Колхоз исә жиргә әнә шундый зарури хужа инде. Башкача ничек? Әгәр утызынчы елларда күмәк хужалыклар төзелмәгән булса, илленче елларда барыбер шул чараны үткәрергә туры килер иде... Жирне кадерсез итүнен тагы бер сәбәбе шул: властьлар жиргә завод-фабрикага караган кебек карыйлар. Заводка фәлән деталь эшләп чыгарырга план төшерден—бетте! Крестьянга, фәлән тонна ашлык житештер дип боерык бирден—үтәлергә тиеш, диләр һәм таләп итәләр. Ләкин жир тимер түгел. Тимергә дә амортизация чыгымы каралган. Жиргә берни дә бирелми, аннан алырга гына беләләр. Ә жир тере, жанлы организм. Ул арый, йончый, кайчак авырый, ана органик матдәләр житми. Арыган, хәлсезләнгән жирне солыча басып китә. Иген булмый. Жир үз өстендә төрле чүп үләннәре үстереп, үз-үзен дәвалый, ди. Алты ел буе шулай дәвалана ул. Шуннан соң гына иген үстерерлек булып сихәтләнеп китә.

Юк, жиргә, игенчелеккә формаль караш бик зарарлы. Авыл хужалыгынын хәле жирдән генә тормый, ә күбрәк "һава кәнсәләренә" бәйләнгән булуы һәркемгә ачык. Ә һаванын һәр сәгать саен үзгәреп торуы белән исәпләшергә теләмиләр. Бер елнын һава торышы икенче елныкына бер дә туры килми. Һәр елны үзгә, һәр елны башкача. Кышын яз, жәй өчен планнар әзерлисен. Үткән елгы житешсезлекләрне исәпкә аласын. Әмма яз житә, синен планнарынны чәлпәрәмә китерә дә ташлый. Житмәсә, социалистик ярыш белән тенкәгә тияләр. Зарарлы бюрократия. Крестьян тормышы билгесезлек һәм өмет белән бәйләнгән булганга күрә гаять катлаулы. Ул жиргә бер караса, күкне йөз мәртәбә күзәтә. Өмет бармы, юкмы? Янгыр яумаса, кара кайгыга бата. Янгыр артыкка китсә дә кайгыра... Жиргә ул һәр нәрсәне тудыручы итеп карый. Шуна жиргә жаны-тәне, тамырлары белән тоташа. Жир крестьяннын ан-фигылен билгели. Бу жир аны. Бүтән аннарга анда урын калмый. Шул сәбәпле, советлар крестьянны һәр прогресска каршы торучы, властьны яратмаучы кара, архаик көч булган карашны гамәлгә керттеләр. Крестьян, димәк, артта калган анлы, түбән зат. Аны житәкче урынга кую юк. Гәрчә ул талантлы, эшчән булса да. Пролетар чыныгуы үтмичә, аны югарыга үрләтмиләр. Бер крестьяннан чыккан бөек галимне пролетар чыныгуы алдырыр өчен сабын заводында истопник итеп эшләтәләр...

"Власть" дигәннән, институтта заочно имтиханнар биреп йөргәндә, завуч Вәзыйхны эчкәре бүлмәгә алып керде дә сораша башлады. Көтелмәгән сораулар бирә иде. Сүз арасында кыстырды: "Син нишләп властьны яратмыйсын, ә?"—диде. Вәзыйх каушап калды. Ул үзенен властьларны яратмавын белми иде. Үзе белми, ә бүтәннәр әнә белгәннәр. Сынар өчен әйтәдер дигән уй килде ана һәм ул: "Белмим"не анлатып жилкәләрен селкеткәләп алды.

Соңыннан бу хакта уйланып йөрде. Неужели мин властьны өнәмим икән? Власть, имеш... Власть гомуми сүз. Халык дигән кебек. Ә бит халык та, власть та аерым кешеләрдән тора. Кешеләрнен исә төрлесе бар. Бар яхшысы, бар яманы. Авыл советы рәисе, колхоз рәисе, сельпо рәисе... Болар бездә, парторгтан кала, барысы да бармаклары үзләренә кәкре гужлар, комсызлар. Гаделсезләр. Властьны түгел, мин власть тотучы әнә шундый бәндәләрне генә өнәмим. Ә идеология кушуы буенча мин шул әшәке затларны яратырга, аларны тынларга тиеш. Менә нәрсә жанга бик авыр. Жан кабул итми. Мине властьны яратмый дип кыерсыталар, кимсетәләр. Нишли аласын? Шулай да XX нче съездан сон, бераз "епшетү" сизелгәндәй булды. Имтиханнар вакытында артык бәйләнмиләр, кабат-кабат бирдереп газапламыйлар. Әмма барыбер кырын карау төртеп чыга, йөзгә бәрә. "Кыска курс"тан имтихан тапшырганда аны батырмакчы булдылар. Сорау революция хакында иде. Анысын сөйләгәч, өстәмә сорау: "Что такое повивальная бабка революции? Маркс об этом что говорит?" Вәзыйх югалды да калды. Мангаена тир бөрчекләре бәреп чыкты. Култык астыннан кайнар тир

акканын сизде. Имтихан алучы озынча битле профессорга, кырыенда утыручы житди йөзле аспирантка һәм таркау чырайлы аспирант кызга күз йөртеп алды. Берәр ым беленмәсме? Юк, тукта, “Повивальная бабка” кендек әбисе дигән сүз бит? Революциянең кендек әбисе була микәнни? Нәрсәнедер аңлап житмим, ахрысы? Чөнки минем фикер турыдан гына йөрүчән... Багана кебек дәшми тору да хәтәр. Тисә тиенгә, тимәсә ботакка дип: “Әллә Надежда Константиновнамы?”—дигән тәгъбир теленнән ычкынды. Аспирант кыз: “Дөрес!”—дип әйтеп куймасынмы? Ә аспирант авызын күтәреп көләргә тотынды. Профессорның йөзе карага коелды. Кызга акаеп-акаеп карап алды. Як-ягына ялт-йолт башын боргалады. Үзе дә каушаган шикелле иде. Зачеткага билге куя-куя: “Төп сорауга җавап бирдең. Өчле!”—диде һәм аңа сузды.

Вәзыйх бу сорауга җавапны озак эзләгәннән соң гына тапкандай булды. Иске властьны корал көче белән көчләп бәреп төшерү һәм яңа властьның тууына ярдәм итүче Маркс образлы итеп: “Повивальная бабка революции—насилие”—дип әйтә. Чөнки иске власть болай гына төшми, аңа көчләү-корал көче кулланырга кирәк ди. Соңыннан Вәзыйх үзенең нинди беркатлы мокыт булуыннан көлеп, оялып йөрде.

Кыр станында әбәд ашап утырганда, күмәк хуҗалык хакында сүз куерды. Жан башына тиешле жир бүлеп бирсәләр, алыр иденме?—дип, ин элек Яшәне кытыклап карамакчы булдылар. Яшә, алдындагы ризыгын ашап, сөяк кимерә иде. Сөяген читкә куйды да:

—Ни чуртыма ул чиләнергә?—диде. Шулай да бу фикер аны уйландыра, ахрысы.—Ә кем бирә аны?—димичә булдыра алмады.

—Юк, примиргә генә әйтәбез, фараз итеп кенә.

—Белмим, жир алучы хәзер табылыр микән? Ул жирдә бит көн-төн эшләргә кирәк. Барча семьяң белән. Алай да тулык чыгара алмыйсың. Нигә, колхоз ошамыймыни?

—Колхозны үзең беләсең, дисциплина начар, үземнеке дип эшләмиләр?

—Юк, ул гына түгел,—дип, Варис сүзгә кушылды.—Колхозда ялкаулар күбәйде. Кара эшне өнәмәүчеләр. Укып чыгалар да кара эштән йөз чөерәләр. Ә кара эш эшләмичә иген үстереп булмый.

—Ә тракторист эше кара эшме, ак эшме?—Даян, итен ашап бетереп, майлы кулларын чалбарына сөрткәләде дә, тәмәке кабызып җибәрде.

—Кара эш, билгеле,—диде Вәзыйх.—Тракторист кара крис, дип юкка әйтмиләр. Майга, корымга батып йөрисең.

—Кием буялу бер нәрсә, ә физик кара эш эшләмисең. Техника белән идарә итәсең. Димәк, акыл эше, ак эш эшлисең булып чыга?—Даянның логикасы дәлилле иде. Шуңа уйланып, тынып калдылар.

—Кыш көне тракторны кабызганда ак йоннарың чыга?

—Юк, кара эш ул: көрәк белән жир казу, урман кисү,—дип, Вәзыйх тезеп китте.—Утын яру, фермада мал астын чистарту, җилкә белән капчык ташу...

—Крестьян мондый эшләрне көн дә башкара бит,—диде Яшә.—Димәк, авыл кешесе кара эшче?

—Колхозчыны кара эшче дип әйтмиләр, кызартып сөйлиләр.

—Ә бит гамәлдә һәр колхозчы, идарәдә утыручылардан башка, кара эшче,—Варис төгәл, гадел булырга ярата.— Идарәдәгеләр дә үз хуҗалыкларында кара эш эшлиләр.

—Колхозда чиләндерә торган кара эш юк, анысы хак. Чокырны да экскаватор казый,— дип, Даян йомгак ясагандай әйтеп куйды.

—Хуҗалыкта исә барысы да кара эш әле...

—Кара эш, ак эш бергә катнашкан.

—Хәзер күпләрнең принцибы: өйгә буш кул белән кайтма, стаканнан авыр нәрсә күтәрмә!—Варис сүзен әйтеп бетергәнче көлә башладылар. Чөнки бу күпләргә ишарәле иде. Шуны сиздермәс өчен көлә-көлә урыннарыннан кузгалдылар. Эшкә тотыныр вакыт житкән иде.

***

Шаязның әтисе авыр хәлдә. Вакыт-вакыт аның җуя. Янында теге вакытта үзен утыртуда катнашкан иптәше Фәтри иде. Кичтән хәле мөшкелләнде. Саташкалап куйгалады. Фәтри бәхиллек алу өчен форсат килгәнне чамалап, иплән кенә дәште:

—Закир, хәлең ничек, әйдә бәхилләшеп калыйк!—диде. Закирның күз кабаклары ачылды, зәңгәр күзләре нәрсәдер исәпләп торган кебек иттеләр.

—Закир туган, бәхилме, ә?—Фәтринең тавышы кечелекле, ялагайлы иде.

—Юк, Фәтри, бервакытта да бәхил түгел, мәңге бәхиллегем юк!—дип, Закир ак мендәр өстендәге башын икенче якка борды.

—Йә инде, Закир, алай итмә, дөньяныкы дөньяда калсын! Бәхил булышыйк!—Фәтри урындыктан торып, мичкә аркасы белән барып сөялде дә, Закирга төбәлеп хөкем көтте.

—Син мине сатып, үзеңә һәм балаларыңа җайлы тормыш кордың. Ничек бәхилли алыйм? Бәхилләсәм дә, минем анда күргән газапларым, түбәнсетелүләрем сине мәңге каһәрләячәк! Ул каһәр сиңа төшсә, көлең генә калыр. Төшми шул. Вөҗданың шайтанга сатканнарны каһәр сукмый. Ә бәлки бер сугар да әле...

—И, Закир туган, мин сиңа ничек шулай килеп чыкканны аңлаттым бит.—Фәтринең тавышы еламсыраулы иде.

—Сатлык җан син, нәҗес!—дип гыжылдады Закир. Аның сүзләрен ишектән кереп килүче Закирның туганы ишетте. Ул Фәтригә барып тотынды: "Син сатлык сабакы, һаман мондамыни? Бар, аттыр? Тагы кемне сатарга йөрисең?"—ди-ди, тегене җиңеннән алды да, җилтерәтеп, тышка чыгарып җибәрде. Фәтри исә: "Закир миңа бәхиллеген бирде инде, хәзер үлем исереклеге аның кыйшатты",—дип сөйләнә-сөйләнә, үзенекен тукыды. Үзен юата, аклый иде.

Төн урталарында Закир өзелде. Әнисе, йөгереп, Шаяз ягына чыкты. Шаяз әтисенең үлгәнлеген әнисенең күз карашыннан аңлады. Әтисе ягына керде. Ана, мәетнең ияген яулык белән алып, баш түбәсенә бәйләп куйды. Шаяз әтисенең озын булып сузылган гәүдәсенә карап, карават башында басып торды. Менә мәңге аерылышу минуты сукты. Бергә һәм аерым узган гомерләре күз алдына килде. Әтисе-әнисе кушуы буенча, гариза язып, атадан баш тарткач, Шаяз бик авыр кичерешләр эчендә йөргән иде. Эчендә нәрсәдер өзелгәндәй булды аның. Ләкин тормыш көчле, аны кирәксез кичерешләрдән арындырды. Әкренләп барысы да тоныкланды. Тормыш үзенекен итте. Ләкин әтисенең "тегеннән" котылып кайтуы тагы хәлләрне катлауландырды. Монда да әтисе акыллы булды. Карчыгына әйткән: "Без Шаяз белән аралашырга тиеш түгел. Минем белән бәйләнешле булу аның тормышын гына бозар",—дигән. Әнисе бу дәлил белән килешкән. Аларны чәй эчәргә бер табынга утыртмады. Шаяз үзе дә әтисенә шикләнеп карый иде. Арага үпкә-рәнҗү тулган. Әтисе халык дошманы булмаса, ул шундый кыенлыклар күрер идеме? Армиядә стройбатта газапланды. Кайткач та кыерсыттылар. Механизаторлар мәктәбенә көчкә эләкте. Иреннән законлы аерылгач кына, әнисенә укыту эшен рөхсәт иттеләр. Әтисе акланып кайткач барыбер куркып никахны яңартмадылар. Тыштан аклаган итсәләр дә, гамәлдә кимсетүләр дәвам итә иде. Әнә Шаязны һаман баш механизатор итеп күтәрмиләр. Партияле, әмма надан кешене баш итеп йөртәләр.

Шулай да Шаязда яшьлек кызыксынуы көчле иде. Әнисенең тыюына карамастан, әтисе ягына кереп сөйләшеп утыргалады. Әтисе ятып кына тора иде инде. Анда күргән бер-ике хәлне сөйләде. Сорау алганда аны ике яшь кеше идәнгә егып кыйнаганнар. Берсе моның өстенә кече хаҗәтен иткән...

Өйдә чарасызлык һәм авыр, үле тынлык хөкем сөрә. Әнисе кайчак, эче янудан арынырга итеп, уф-уф килеп йөри. "Нишлисең инде, улым, дөньясы шулай булгач?"—дип, авыр итеп көрсенә. Бер ноктага текәлеп, сүзсез генә боегып утыра. Шаяз үпкәләгән чырай чыгарып, үз ягына атлый. Ул һич

шуны кара акылы белән аңлап житә алмый: без, ана, балалар ачык сөйләшеп, фикер алышып, туганнарча бер-беребезне яратып, иркенлек белән яшәсәк, тормыш итсәк, моның кемгә зыяны тияр иде икән соң? Юк, бер дә нормаль хәл түгел инде бу? Кемдер безнең семьяга читтән китереп таккан бәла.

Лениза килен дә бу авыр тынлыкка жан кертә алмады. Хәер, ул авылга сирәк кайта иде. Сагынышканга күрә, бер-берсенең кочагына сеңәләр. Өйдәге хәлне белгертергә теләмичә Шаяз үзе хатыны янына еш баручан булды. Йөрәгендә купкан каршылыклы кайнар уйларын эш белән сүрелдерә, эштә тигезли иде. Таң белән эшкә торып чаба, кич исә эт булып арып кайта да, үз ягына кереп ава. Кыйналган, сындырылган кешеләр якты көнгә, сынык икмәккә шөкерана итеп яшиләр. Гомер буе рия белми эшлиләр. Берни таләп итмиләр. Әнә радиодан: "Аерма мине сөтле чәемнән", дип жырлыйлар. Халык хезмәт белән яшәргә күнеккән. Коры-сары тормышка да риза. Артта сөйлиләр: өч йөз төр товар-продукты авылга бөтенләй кайтарылмый икән.

Шаяз әтисен соңгы юлга озата барды, әмма женазасын күтәрешмәде. Зират капкасына тикле килде, ләкин эчкәре үтәргә жөрьәт итмәде. Бу исә әтисенә кара-каршы позициядә торганлыгын, дингә ышанмавын күрсәтү өчен кирәк иде.

Ул әтисенең жәсәден кабер кырыена китереп куйганчы киртә аша карап торды. Аннары, борылып, башын түбән игән килеш, кайту ягына атлап китте. Тамак төбенә әрнетә торган ачы төер утырды. Ни эчкә йотып булмый, ни тышка төкерү мөмкин түгел. Тын алу авырайган кебек иде. Ул һаман тамагын кырды. Башта уйлары агыла: бер яктан жилкәсеннән авыр йөк төшкән сыман тоелды. Әтисенең четерекле язмышы анның язмышына да сукты. Хәзер ничек булыр икән? Әмма бу уйларыннан ул оялды: ата кеше хакында шулай исәп йөртергә ярыймы соң? Бу бит намусынны жую дигән сүз. Тик алай уйларга һич теләми ул, шулай уйларга гамәл, тормыш мәжбүр итә! Бала атасының үлемен котылуга санасын әле, кая китә бу? Әх, егетләр! Туганнар бер-берсенә дошман, ата белән бала бер-берсенә каршы. Шушы булдымы гадел, коммунистик тормыш?!

Әтисе вафатын әйткәч, Лениза бер дә көенмәде: и, апа котылган икән. Аны карап бик жәфалана иде, дип кенә куйды. Бүген ул Шаязга аеруча игътибарлы иде. Барча теләкләрен каударланып үтәде. Әмма Шаязның эчен нидер авырттырып талый иде...

***

Даян белән Фәнүзәнең туе билгеләнгән вакыттан берничә мәртәбә чигерелде. Хикмәт кызда иде. Фәнүзә Әлмәттә кооператив техникумны тәмамлагач, Туктар поселкасында кибеттә эшли башлады. Авылдан бик ерак. Шуңа күрә ата-ана кызны үзләренә тарта иде. Биредә абзар-кура, йорт-жирләр бик шәп. Чөнки ата кеше объездчик Шәрәп сугыштан кайткач та, урман эшендә эшләп мыштым гына баеган, май жыйган. Бетон белән катырган нигезгә салынган сигез почмаклы, калай түбәле йорт. Такта белән тышланып сыек зәңгәргә буялган. Эче нефтьчеләр куйган кайнар су казаны белән жылытыла. Ишегалдында артезиан колонкасы. Ак мунчага су ташыйсы юк, үзендә су колонкасы куелган. Шәрәпнең гел кызлар гына. Шуңа кияүне йортка кертү ниятка бик муафыйк булыр дип исәплиләр. Бу тикле хужалыкны төзек тоту өчен ир-ат кулы кирәк. Шәрәпнең үзенә генә авырга туры килә башлаган иде. Хәзер исә бердәнбер өмет Фәнүзәне үзләренең авыл кибетенә эшкә күчерү һәм кияү белән икесен төп йортка төпләндерү. Кияү буласы егет Даян ата-анага ошый, үзләренә кулай күрәләр. Гәрчә Даян ятим үскән булса да, ярап торыр, диләр. Анын эчкәләү гадәтен дә бик үк күпертмиләр. Тәртә арасына кергәч, жайланыр, дип уйлыйлар. Әмма Фәнүзә шактый һавалы кыз. Әтисе аны Әлмәттә рус мәктәбендә укытты. Ул ягы да борынны югары тотарга бер сәбәп.

Чибәрлеге юк түгел: янадан-яна модалы киемнәр, яшьлек кызны мөлаем һәм әгъвәле итә. Саргылт чәчен баш артына төйнәп куйган, ачык муены мәрмәрдәй ак, шома. Түгәрәк битле, уймак иреннәре елмаерга гына тора. Күз-кашлары да бик килешле, йөзенә әллә нинди ягымлылык бирә. Алга таба омтылган таза күкрәкләре егетләр эченә ут чаткысы салмыйча калмый. Шундый кыз шофер Даянга тәтемәгән булыр иде, әмма Фәнүзәнең бер минусы булды. Ул моннан ике ел элек бик кыска арада кияүгә барып кайткан иде. Хәтта язылышмаган да булганнар, дип сөйләделәр. Хәзер кияүгә барып кайтулары модада, имеш. Ул моданы кем тотсын, сатучы кызлар да тотмагач. Даян әйткән, имеш, ат иясенә килгәч абынмасын. Кыз ни, хатын ни—барыбер түгелмени? Кыз дип алып, хатын булып чыкса нишләрсең? Ә биредә бернинди шиккә урын юк... Фәнүзәнең әти-әнисе Даянның шул сүзләрен бик ошатканнар, ди. Кыз башта Даянны өнәмәгәнлеген сиздереп алган, әмма кайгыртучан ата-ана кызны һаман Даян ягына аудара барганнар. Даян хуҗалыкчан, ятим булуы да әйбәт. Ул гел үзебезнең улыбыз кебек булачак. Үги әтисе белән тынышмавы да бик унай. Егет тулысы белән аларга бирелеп яшәячәк. Хуҗалыкны үземнеке дип кайгыртачак. Һәр яктан кулай килгән мондый кияүне туры китерү җиңел түгел. Иң мөһиме, әлбәттә, Даянның ипле холык-фигыле. Күндәм, сүз тыңлаучан. Фәнүзәнең ата-анасы Даянның әнә шул сыйфатлары өчен ана чатырдап ябыштылар. Фәнүзәнең чая бераз җилбәзәк холкына Даян кебек егет нәкъ савытына күрә капкачы дип фикер йөрттеләр.

Даянның үги әтисе үзенә күрә түгел, объездчик Шәрәп кызына йортка керүгә каршы. Бераз салмыш булды исә, эчендә ни барын тышка чыгара. Эчмәгәндә авыл халкы бик кыюсыз. Барысын буена сендереп тора. Ләкин әз генә салып алгач, теге эчтә җыелып яткан нәрсәләр үзләреннән үзләре тышка агыла. Аларны ике-өч йөз грамм аракы хәрәкәткә китерә. Су зур тәгәрмәчне хәрәкәткә китергән шикелле.

—Йортка керү—утка керү инде ул,—ди үги әти.

—Синең штамповка балаларың янына нинди кыз килсен? Безнең өйне генә түгел, нәселне өч чакрымнан урап үтәләр! Һе!—Даян да салып кайткан, бик кыю сөйләшә. Салмаганда үги әтисеннән шүрли ул. Кечкенә чакта нык тәпәли иде. Шуннан шүрләп калынган. Хәзер Даян үзе эшләп таба. Ничу аннан куркып торырга.

—Шәрәпкә батрак кирәк,—диде үги ата, тавышын әкренәйтә төшеп.— Син анда эш аты булачаксың.

—Булса соң? Әллә син эш аты түгелме? Барыбыз да эш атлары инде...

—Ярар, ярар, синенчә булсын. Мин әйтмәдем, син ишетмәдең...—Үги әти, тәмәке төпчеген җиргә атты да, нindiдер тынычлану сиздереп, өйгә кереп китте. Аның шул кыяфәтеннән Даян үзенең үги әтисенә әйткән сүзләре дөрес булуын аңлагандай булды.

Даян Фәнүзәләргә килде. Тиздән туйга дип Шәрәп абыйларда әзерлек барганлыгы өйнең, ихатаның тышыннан ук беленә иде. Ә Фәнүзә белән туйганчы дигәндәй сөешкәннәре юк. Фәнүзәнең һаман вакыты булмый. Туктар поселкасыннан кайтып йөрүнең авырлыгын сылтау итә. Анысы чынлап та шулай. Ә биредә нефтьчеләр яңа кибет ачтылар. Фәнүзә шунда эшкә күчәргә йөреп караган иде, юк, дигәннәр. Менә ике арада—бер турда дигәндәй, килеп сарып газапланырга туры килә. Хәер, өйләнешкәч, биредә эшләргә төпле нигезләр була. Күчермичә булдыра алмаслар.

Даянны күтәреп алгандай иттеләр. Ләкин Фәнүзә кайтып җитмәгән иде. Машина туры килмәгәндер, диде Шәрәп абый, гаепле кеше сыман. Чәй әзерләделәр. Даян күңелсез генә бер чынаяк эчте дә, рәхмәт әйтеп, кузгалды. Шунда аны Фәнүзәнең сигезенчедә укучы сеңлесе тотып, икенче якка алып чыкты. Дәрес хәзерләп утыра икән. Математикадан мәсьәләсен эшли алмый. Даян бу йортка аяк баскан саен кызга ярдәм иткәли. Мәсьәләләрнең ничек чишелү техникасын өйрәтә. Әмма кыз бик ушлы түгел. Өйрәткәннәр бер колагыннан керсә, икенчесеннән чыга. Даян бик сабыр рәвештә бер үк

нәрсәләрне кат-кат тукый. Кызның түгәрәк битендә алсу таплар пәйда була. Ул алсулыклар битеннән ак иягенә күчә. Аннан тагы битләренә менә. Кечкенә тупчыклар шикелле тыгыз күкрәкләре лепердәп тора. Мәсьәлә чишү кагыйдәләрен төшенергә, ахрысы, әнә шул лепердәп торган күкрәкләре комачау итә булса кирәк...

Байтак вакыт дәрес өйрәтеп утырды ул. Фәнүзә кайтмады. Югыйсә, бүген кайтасы көне иде. Ул биш көн эшләп, ике тәүлек ял итә. Берәр күрелмәгән эш килеп чыккандыр инде. Тормышта болай уйлап планлаштырасың, әмма икенче төрле эшләргә мәҗбүр буласың... Аны бездә генә кун дип кыстадылар, Даян каласы итмәде, башын иеп, боек кына кайтып китте.

Туй алдыннан сөйләделәр: Фәнүзәнең Даянга бик барасы килеп тормый икән. Әти-әнисенең сүзен тынлап риза булган, имеш. Әти-әнисе Даянга чыгуын теләп бик ялынганнар. Ахырәте Зөмәрәгә Фәнүзә әйткән: "Болай яратып түгел, әти-әни ризасызлыгыннан куркып кына чыгам",—дигән, имеш. Яратмыйча ничек тәвәккәллисең инде?—дип иптәш кызы төпченгән. Фәнүзә әйткән: "Мәхәббәт ул никахтан соң килә!"—дигән. Ә никахтан соң да мәхәббәт килмәсә, нишләргә?—дип, иптәш кызлары үзләре өчен дә кайгырып сөйләнәләр. Чөнки Фәнүзә кияүгә барып кайткан, тәҗрибәле. Фәнүзә ни әйтергә белми торганда бер кыз әйтеп куя:

—Никахтан соң да мәхәббәт килмәсә, димәк, язмыш, ә язмыштан узмыш юк!—ди.

Туй алдыннан авыз чайкаулар күп булды. Ниһаять, туй көне житте. Моны кабат чигереп булмый иде. Фәнүзә шомырт чәчәгедәй ак челтәр фата кигән, башында бизәкле калфак. Йөзе аксыл, монсу. Күз төпләре күкселләнеп тора. Ул аларны кершән белән агарткан. Иреннәрен чия төсле итеп матурлаган. Аягында лаклы лодочкалар. Даян киң җилкәле, таза муенлы. Ак күлмәк һәм кара пиджак кигән. Алар язылышырга барырга җыендылар. Тик шул мәл авыл советыннан кемдер хәбәр китерде: секретарь кызны күрше авылдан машина килеп ашыгыч кына алып киткән. Әнисе хәл эчендә икән... «Әх, майть якасына!»—дип үртәлде Даян. Күңелсезләнеп, кулын селкеде дә, кунакларга табынга рәхим итәргә кушты... Олы якның әйберләрен чыгарып, озын өстәл сузылган. Ике якта венский урындыклар. Нәкъ шәһәрдәгечә. Табында ниләр генә юк. Элек бер "взвод" шампаннар сафы. Аннары ак башлылар ротасы парадка тезелгәннәр дә команда көтеп торалар. Кунаклар үз урыннарына урнаштылар. Беренче булып табак битле, кыска буйлы сөйкемле кыз торып басты. Ул мәктәптә пионер вожатые, комсорг. Җәмәгатьчелек исеменнән кыскача гына речь белән туйны ачып җибәрде. Аннары көләч йөзле шаян Ирек тезгенне үз кулына алды. Ул тамада икән. Табын караучы ак өчпочмак яулыкларын баш артына бәйләгән ике апага ияк кагып боерды. Рюмкалар эчемлекләр белән тутырылды. Беренче тостны Ирек әйтте:

—Менә ике яшь йөрәк—яшь ата шайтан белән яшь ана шайтан яңа тормыш корыр өчен кушылалар. Яшь ата шайтан—Даян, син шайтаныңны бик узындырмассың инде (Ирек аның салгалавына төрттерә). Яшь ана шайтан Фәнүзә, син дә пәриләренне моннан соң йөгәнләрсең (Фәнүзәнең җилбәзәклегенә ишарә). Штубы-то—каз боты, дигәндәй, икенче елга кечкенә шайтаннар идәндә йөгереп йөрсеннәр. Яшьләргә бәхет, тигезлек теләп, әйдәгез, дәррәү күтәрдек...

Шуны гына көтеп торгандай барысы да рюмкаларын күтәреп авызларына чөнкәйттеләр. Закускалар капкалаган арада, Ирек шуклыгын янә худка җибәрде:

—Туйга соңарган берәү ишектән керүгә мине күреп алды.—Гафу, сезме кияү кеше?—диде. Юк, мин әйтәм, тыныч кына тегеңә карап.—Мин чирек финалдан ук төшеп калдым, дим. Шуның кебек ярым финалдан төшеп калучылар да булгандыр әле, ә, Фәнүзә?

Фәнүзә кулын селтәп көлеп җибәрде. Башкалар да көлде.

—Финалга Даян чыкты.
—Даян отты барысын да!—диешә-диешә көлештеләр.—Молодец!
Фәнүзәнең дус кызы укытучы Зөмәрә торып басты, тулы матур битләренә алсулык йөгерде.
—Мин ике яшь күнелнен ихлас бергә берләшүен, арага җил дә кермәслек дус булып яшәүләрен телим,—диде.—Булса булсын чын мәхәббәт, ятлар кулын сузмасын, әмма ләкин, чөнки, бәлки, дигән сүзләр булмасын!..
Көлешә-шатлана тагы эчеп куйдылар. Табындагыларга җан керә башлады. Тартынып сөйләшмичә утыручыларнын телләре чишелде. Сөйләшәләр, көлешәләр. Эчемлек кыюсызларга кыюлык өстәде.
Матрос телняшкасын кигән берәү мәзәккә керешге. КПЗда ике арестант утыра. Бер арестант икенчесеннән сорый: "Сине ни өчен утырттылар?" "Эш вакытында форточка ачкан өчен". "Син кайда эшли идең соң?". "Су асты көймәсендә".
Тагы бер арестант икенчесенә дәшә:
—Сине ни өчен яптылар?..
—Насморк өчен. Бер өйгә ачкыч яратып кердем. Бер сандыкны ача башлаганда кинәт төчкереп җибәрдем. Һәм мине шунда тотып алдылар...
Ике яшь ир кемнең хатыны яхшы булуы турында сөйләшәләр. Берсе әйтә:
—Минем хатын шундый әйбәт, эштән кайтуга пальтомны салдыра, аякка йомшак башмак бирә һәм кулга пирчәткә кигерә.
—Пирчәткә?—дип гаҗәпләнә иптәше.
—Әйе, резин пирчәткә, табак-савыт юар өчен...
Түшәмне күтәрерлек итеп шаркылдап көлеп җибәрделәр дә рюмкаларына тотындылар. Һәркем үзе салып эчә иде. Табындагыларнын дөньялары түгәрәкләнә башлады. Дошманнар дуска әйләнде. Мөнәсәбәтләрдәге чатаклыклар тигезләнгәндәй булды. Бер-берсенә булган үпкәләр язылды. Әүвәл чәкәләшеп, бер-берсе белән исәнләшми йөргәннәр дә йомшады, сөйләшеп киттеләр. Бер-берсенә кул бирделәр... Кайсыдыр җыр сузарга маташты. Баянчы, тез өсләренә баянын җайлап, сыздырып җибәрде. Ниндидер, әле генә авылга кайткан яна көй.

*Сау бул, яшьлек, рәхәтеңне*
*Татырга өлгермәдем.*
*Болай тиз үтәрсең диеп*
*Һич кенә дә белмәдем.*
*Яшь чаклар сиздерми үтә,*
*Үткәнен күрсәң иде.*
*Үткән чакта тотып алып,*
*Кирәген бирсәң иде.*

Җыр бетүгә баянчы шып туктады, бүтән көйгә күчмәде. Туйнын программасы шулай, ахрысы. Тамада Ирек торып басты, кулы белән тынычланырга кушты. Даянга сүз бирде. "Яшьлегең белән саубуллашуынны формула белән әйтеп күрсәт",—диде. Чөнки Даян математик формулалар белән сөйләшергә ярата. Бу шуна ишарә иде.
—Яшьлекне х (экс) дип алсак,—диде Даян.—Болай: Экс—(минус) Даян = (тигез була) Фәнүзә! Янсә: Даян—(минус) яшьлек = (тигез була) Фәнүзә!
—Тегеләй дә Фәнүзә, болай да Фәнүзә, ә?—ди-ди, көлешә башладылар.—Дөнья Фәнүзәгә барып терәлә.
Шул мәл Варис белән Яшә басып торган Даян артына килеп бастылар һәм кинәт әллә каян алып Даянга өр-яна каеш камыт кигереп куйдылар. Кемнәрдер көлә-көлә кул чаптылар, шау-гөр килделәр, чынлап та кызык иде. Монарчы күрелгән нәрсә түгел. Даян үзе дә аптырап калды һәм сер бирмәс өчен елмайды. Камытны салмакчы итеп йомыры башын як-якка чайкаган итте. Янәсе, камытны яратмыйча чыгымчылый. Ирек шунда Даян янына килде, кесәсеннән кәгазь алып укырга тотынды:

*Фәнүзә,*
*Коштай матур син үзең,*
*Кашыңнан кара күзең.*
*Приказ көткән кебек Даян*
*Көтеп тора һәр сүзең!*
*Фәнүзә,*
*Бер хәзинә син үзең!*
*Даянга камыт кигездең,*
*Шалтай-балтай йөрмәсен,*
*Тормыш арбасына җиктең,*
*Тартсын, камыт тимәсен.*
*Нужа чыбыркысы куа:*
*Еш кына сыртка төшә.*
*Арбаны алга тартасың,*
*Ыңгырчак иңне кисә...*

Шул юлларны укыганда Варис, шайтан, каяндыр чыгарып Даян артында чыбыркы шартлатып куйды. Егылып, бот чабып көләргә тотындылар. Варис анын саен Даянның артына суккан кебек итеп чыбыркы селтәп шартлата. Ирек кулын күтәрә, чыбыркы туктый. Ирек укуын дәвам итә.

*Әмма чыдыйсың, атлыйсың*
*Җилкәңне уа-уа,*
*Арбаңны юлдан сөйрисең,*
*Ә тормыш һаман куа,*
*Аның йөге шундый авыр,*
*Йөрәгеңне какшата.*
*Әмма Фәнүзә көч бирә,*
*Тормыш гадел, бер әчесен,*
*Бер татлысын каптыра.*
*Һәрчак шулай ымсындырып,*
*Авыр йөкне тарттыра...*

Уку беткәч, табын көлә-көлә кул чапты. Варис белән Яшә камытны Даян муеныннан салдырып алдылар. Даян якаларын рәтләштереп үз урынына утырды. Фәнүзә аңа башын якынайтты, нәрсәдер әйтте. Икесе дә бәхетле көлеп куйдылар. Тагы нидер серләштеләр. Шул мәл кайсыдыр: "Горько! Ачы! Ачы!"—дигән аваз салды. Аңа дәррәү кушылдылар. Теге почмактан да шул сүз яңгырады. Фәнүзә белән Даян җансыз гына ияКләренияккә тигезеп алдылар. Табындагыларны бу гамәл генә канәгатьләндермәде. Тагы: "Ачы! Ачы!"—дип шәрран яралар иде. Кешеләрнең каннары кызган, кәефләре күтәренке, бер-берсеннән уздырырга тырышып кычкыралар. Берсен-берсе бүлдерәләр. Фәнүзә торды да баянчыга ымлады. Өстәлнен бер яктагы урындыкларын җыеп алдылар, бер почмакка өйделәр. Баян танго уйнарга кереште.

Фәнүзә белән Даян танго биюенә керделәр. Яшьләр һәрберсе үз иш егетләр, кызлар белән парлап тансы көенә әйләнәләр. Яшьләрнен ин яратканы тансы инде.

Табынның икенче ягындагы ирле-хатынлылар һаман сәрхүшләнүләрен беләләр. Хатыннары ирләрен эчүдән тыя, тозлы сүзләр ычкындыралар. «Йә инде кеше бул, хайван булма! Моны эчсәң, дуңгызга әйләнәсең, йә инде, йә! Кара ничек кәпрәйдең? Өйгә кайтасынны онытасың... Кайткач кикриген бик тиз шинәр. Мина ялынычын төшәр. Матри, малай, күпме гозерләнсәң дә, теләгән нәрсәң тәтемәс! Чамала! «Ир тәмам мәлҗерәгән: «Энже, жир упсын, менә соңгы мәртәбә! Бүген кочагына кертерсен инде, Энже, ә?» «Юк, юк,—ди хатын.—Юк, өмет итмә, сүз дә катма?..»

Икенче почмакта бер гарип ир-ат утыра иде. Гарипләргә хас булганча тавышында ниндидер ачы моң чагыла. Ул иштелер-ишетелмәс кенә озын

бер көйгә җыр сузып утыра. Тавышы моңлы булгангамы, җыр тавышында моң тагы да мул булып чыга.

*Уйлаганың бармы, дустым, шуны:*
*Безнең араларны кем бозган?*
*Мине теләп син килерсең, әмма*
*Ул чагында инде мин булмам.*
*Язмыш безне кагып-сугып йөртә,*
*Туганнардан хәтта аера.*
*Кая барма, язмыш үги ана,—*
*Үксез канатларны каера...*

Ул арада тансы тукталды. Ирек барысын да табынга утырырга чакырды. Урындыкларны алып, элеккеге урыннарына тезделәр, урнаштылар. Табынга яңа ризыклар килде, яңа шешәләрне ачтылар. Өр-яңадан сыйлану, кәефләнү башланды.

Даян белән Фәнүзә үз урыннарына килеп утырдылар. Тансыдан соң Фәнүзәнең кәефе күтәрелгән күренә. Киң маңгае өстенә алсу нәкышлы тар калфак кигән, аның өстенә өрфия ак челтәр япкан. Ул аеруча гүзәл, матур булып нур чәчеп утыра. Даянның колагына иелеп, нидер әйтә дә кыска гына көлеп куя. Әйтә дә көлеп куя. Даян исә бар нәрсәне кулында тота торган хуҗа кыяфәтендә. Күкрәк киерелгән, авыз ерылган. Зур канәгатьлек белән тулган төстә. Аның эчтән җиңү тантанасы кичергәне сизелеп тора. Иптәшләре рюмка тотырып киләләр дә бергә эчәргә кыстыйлар. Даян гаять җиңүчән төстә алардан баш тарта алмый иде. Шуңа күрә шактый мәлҗерәгәне беленә башлады. Фәнүзә аның рюмкаларын читкә алып куя башлады. Тәмам каны кызышкан кемдер тагы: "Ачы! Ачы!"—дип тәкрарлады. Бу юлы Даян батырланып, хуҗаларча Фәнүзәне кысып үбеп алды. Фәнүзә шунда: "Фу, тәмам исергәнсең!"—дип, аны этеп куйгандай итте.

Бераздан тәнәфес игълан ителде. Дәррәү ишек алдына агылдылар. Саф һавада баян бию көен сыздырды. Ишегалдына якты лампочкалар элengән иде. Бию җыр белән алышынды.

Фәнүзә исә, Даянны иптәшләре карамагына калдырды да, Зөмәрә белән үз бүлмәсенә кереп бикләнде. Анда диван, карават, зур көзге бар иде. Фәнүзә көзге каршында битен-күзен караштырып алды да диванга килеп утырды. "Уф, әллә нишләп арып киттем",—диде. Зөмәрә биек караватка арты белән сөялгән иде.

—Син Даянны яратып бетермим дигән идең түгелме соң?—диде Зөмәрә, сынарга иткән төстә.

—Әти-әни сүзен тыңлаган идем, хәзер җанга үкенү үрли башлады. Нишләргә инде,—дип Фәнүзә чын кайгыга төшкән кебек әйтеп куйды. Зөмәрә гаҗәпкә калып карап торды. Ни әйтергә белми иде. Шулай да дустын юатасы килде:

—Тора-бара яратырсың, диләр тәҗрибәле хатыннар...

—Даянны куеныма алып карадым, әмма без бер-беребезгә туры килмибез. Юк!—Фәнүзә учлары белән битләрен каплады. Башын алга таба иеп, уйга калды. Зөмәрә аны аңлап җитми. Чөнки мондый хәлнең үз башына төшкәне юк иде.

—Җайланырсыз әле. Даянның холкы әйбәт бит?

—Ул кимчелекне әйбәтлек белән тутырып булса иде? Ә синең Фаяз абый белән ничек?

—Берничек тә түгел,—диде Зөмәрә, рәнҗетелгән төстә.—Аның кул-аягы тышауланган.

—Яратамы?

—Анарда ихлас хис, миндә дә...

—Неужели шулай яратышасыз, ә?—Фәнүзәнең ышанмый каравы Зөмәрәне аптырашта калдырды.—Ирләр яратуы якынлык кылганчы гына бит?

—Фаяз абый андый түгел,—дип, Зөмәрә ахириен ышандырырга тырыша иде.—Ярату чын булганда якынлык кылу уйга килми, ди.

—Ә син үзең теләсән, ә?—Фәнүзә көлеп куйды.

—Ул нәрсәгә кызыкмыйм, ди.

—Юк, ул яратмыйдыр, баш тартмас иде?

—Мин аңа ышанам әле.

—Син анын белән бәхет таба алмассын, кызыкаем. Үз җаенны кара,—диде Фәнүзә, чын иптәшләрчә кайгыртkan итеп. Киңәш бирергә кем генә оста түгел.

—Күңелем Фаяз абыйда шул,—дип авыр сулады Зөмәрә.

—Хис адаштыра гына, безгә аек исәп кирәк,—диде Фәнүзә, тагы көзге алдына килеп, үзен караштыра башлады.—Син, ничек дим, архаик димме, Зөмәрә? Хис заманы үтте бит. Исәп-хисап вакыты хәзер...

...Туй мәҗлесе иртәнгә хәтле барды. Кайсылары идәндә йоклап уянганнар да өстәлдәге нигъмәтләр белән баш төзәтергә керешкәннәр. Кызарга да өлгергәннәр. Даян кайда, Фәнүзә кайда! ди-ди, тавыш куптаралар. Эзли торгач, Даянны эчкәрге бер чоланда табалар. Уяталар, ләкин үлгән кебек ятуын белә. Ыжлап та кармый. Фәнүзәне эзлиләр, таба алмыйлар. Нәрсә булган боларга? Фәнүзәнең әнисе ягына керәләр. Фәнүзә кайда? Әнисенең күзләре шар була. "Шаяртмагыз, йөрәгем бик начар, кая китсен ул? Без простойларны басымчак итәбез дигәч тә. Әллә ахирәтләренә кергәнме?.." "Юк, бар төштән дә эзләдек, тапмадык... Нәрсә бу, адәм страмы? Фәнүзә әллә юләрләнеп үз-үзенә бирәр хәл кылганмы?.." Эзлиләр, мунча, келәтләрне тикшерәләр... Егетләрдән кемдер: "Фәнүзә мөгез чыгарырга ярата инде. Тагы нәрсәдер шаярта булыр. Пәри кызы! Бер ана әйткән бит: мин җылыймын биргәнчә, алган җылар үлгәнче?—дигәндәй",—дип көлгән итте. Фәнүзә муллык белән иркәләнеп үзындырылган. Объездчик Шәрәп һәрчак бай булды. Кызыннан берни эшләтмәде, аны чикләмәде... Әнисе Зөмәрәләргә барып килде. Юк. Бер-ике егет Даянны һушына китерә алмыйлар. Колакларын уалар да уалар. Колак яфраклары кып-кызыл булып чыкты. Ләкин йөзендә бернинди җанлану сизелми. Торгызып, утыртып карыйлар, юк, һаман мыш-мыш йоклавын белә. Чыраена салкын су бөркеп карадылар, юк, һаман үлгән шикелле җанлылык галәмәте сизелми. Фәнүзәнең сенелләреннән сорыйлар: "Апагыз кайда?"—дип. "Юк, күрмәдек. Без келәттә йокладык",—дип, күзләрен чет-чет йомгалап торалар.

Даянны кич кенә исенә китерделәр. Ләкин ул башына берни кабул итә алмый иде. Фәнүзәнең югалуын әйттеләр. Бер дә исе китмәде. "Ашаган җиренә сыер да кайта",—дип мыгырданды. Бер стакан аракы салды да тагы ятагына ауды.

Өченче көнне генә Фәнүзә турында кайбер хәбәрләр ишетелде... Фәнүзәнең торговый техникумда укыганда йөрешкән егете булган. Ул Урыссуда база мөдире икән. Сирәк-мирәк очрашкалаганнар. Фәнүзә аңа хат язган: "Бүтән килеп йөрмә, мин кияүгә чыгам",—дип. Хатны алуга егеттә үртәлүле, үчле сөю хисе дөртләп кабынган. Машинасы белән Әлмәткә килеп тә җиткән. Анда дуслары, Фәнүзәнең хәлен-көен белеп торалар икән. Кайсыдыр шаярып: "Әллә урлыйбызмы?"—дип әйтеп ташлый, бер-ике рюмка салгач, каны кызгач, егет көлеп җибәрә. Шулай шаярып сөйләшәләр. Гайрәтләнәләр, бер-берсен үртәшәләр. "Юк, сез куян йөрәкләргә тагы!"—дип, берсе янган утка бензин сибә. Егет әйтә: "Минем ният бик житди, егетләр, уен-муен түгел",—ди. "Алайса, әйдә, бүген туй, киттек Ирәчкә?" "Фәнүзә киреләнеп, тавыш чыгарса?" "Чыгармый,—ди егет, ышанычлы итеп,—ул минем өчен барысына да әзер иде. Хәзер дә әллә ни үзгәрмәгәндер әле..."

Тәвәккәлләп, егетләр кичтән Ирәчкә киләләр. Асфальттан ерак түгел юл өсте танышларына төшәләр. Бер апа аша Фәнүзәгә язу җибәрәләр. Килерме, юкмы? Ярты төн авышканда Фәнүзә килә. Каушаган, сүзен әйтә алмый. "Мин сине алырга килдем",—ди егет. "Юк, юк,—ди. Фәнүзә,—син нишлисең? Юк!" Егет аны иненнән, аягыннан тотып күтәреп ала да машинага утырта... Калганы техника эше...

Даян исенә килгәч, айныгач, баш вата: үзе теләпме, әллә көчләп алып киттеләрме?.. Менә бәла! Әти-әниләре ояттан кеше күзенә күренергә читенсенеп, өйдән баш күрсәтми яталар...

12

Нәкъ вакытында, заказ белән булгандай, каты яңгыр коеп китте, сөрү, культивация эшләрен туктатты. Чәчү бетте диярлек. Машина белән җиргә кереп булмый иде. Механизаторлар кырдан кайтты. Мунча яктылар. Әле анда, әле монда мунча төтене күтәрелә. Зәйнагов бу форсатны файдаланып калырга булды, КПССның яңа программасын өйрәнүне горком бик каты куйган иде. "Кайсы бүлегенә җиттегез?"—дип, көн дә төпченәләр. Лекция укырга бүген лектор җибәргән. Парторог Зәйнагов ашыгыч рәвештә активистларны идарәдәге үз бүлмәсенә җыйды.

Лектор ак якага кызыл галстук таккан, кара костюмнан, кабактай зур шәрә башы нечкә муен өстендә глобусны хәтерләтә. Соры пыялалы күзлеге аның күзләрен ачык күрсәтми. Карашының нәрсә белгерткәнен белеп-күреп булмый. Аның тук чырае, үзен генә хаклы санаган, өстән караган кыяфәте кара эш башкаручыларда ана каршы хис уята кебек иде. Моны үзе дә сизә булыр, бер дә кәгазьгә карамыйча сөйли. Ана бик бәйләнчек сораулар бирәләр. Аның ялганын тотарга итәләр. Бер төр авыл кешесе шуны ярата. Лекторны төп башына утыртырга чамалап, сорау яудыралар гына. Әмма лектор бик шомарган нәрсә, чат-чат җавап биреп бара. Бигрәк тә Варис лекторларны стенага терәргә хирыс. Бүген дә шул гадәтен куды:

—Менә,—диде,—коммунизм принциплары хакында сөйләдегез. Һәркемнән—сәләтенчә, һәркемгә—хаҗәтенчә. Шулай бит? Әйтик, мин сәләтсез кеше. Табигать кыерсыткан. Көтү көтүдән башкага ярамыйм. Сәләтем юк, әмма хаҗәтем зур. Тәмле ашарга, яхшы киенергә, унайлы йортта яшәргә телим. Минем хезмәт белән алай житеш яшәп булмый, дөресме? Мин теге сәләтлеләр өлешенә керергә тиешме? Юк, алар үзләреннән бирмәсләр. Әйе! Һаман арта барган хаҗәтемне канәгатьләндерер өчен мин нишләргә тиеш, ә?

—Урларга тиеш буласың инде,—дип сүз кыстырды Фаяз, бик житди тавыш белән. Кемнәрдер тыенкы гына көлеп алдылар. Барысы да лекторга төбәлгәннәр иде.

—Юк, урларга ярамый,—диде Варис һәм бармаклары белән рәшәткә ясап күрсәтте: төрмә бар бит. Фаяз уйлады: карасана, урлау коммунизм принцибының нигезенә салынган икән ләбаса. Лектор эшнең кая барганын бик тиз сизеп алды һәм бәхәскә кереп тормады. Ирен кырыйларында ригая сызыклары сызылды, йөзеннән канәгатьсезлек шәүләсе шуып үтте. Тагы кемдер сорау кычкырды:

—Дәүләт малына кул сузучы кайбер партработниклар бар, алар сәләте юк, хаҗәте зур булган затлармы?

Лектор башын кыегайтып, иреннәре белән түбәнсетүле көлемсерәп:

—Марксизмда бу сорауга әлегә җавап юк,—диде һәм нигәдер өстәл өстендә яткан тузган-кыршылган портфеленең аелын чыртлатып ачып-ябып куйды. Варис бу җавап белән килешмичә, нидер әйтергә иткән иде, Вил Садриевич аңа башын борып бер акайды, теге шунда ук тынды. Баядан бирле Ирек кыбырсый иде, ул ялагай чырай белән эчендә яткан борчуын әйтте. Ул Сталинны хөрмәт итә, шунлыктан аның канлы эшләренә ышанасы килми иде.

—Бик күп җинаятьләр эшләнгән, боларны Сталин белмәгәндер, мөгаен, шулаймы?—Ирекнең йөзендә эчке ышаныч чагыла, "белмәгән" дигән сүз ишетәсе килә аның.

—Тәгаен генә әйтеп булмый,—диде лектор, төшенке тавыш белән.— Әмма барысын да белгән дигән версия бар...

—Белмәгән, белмәгән!—дип тавышын күтәрде Ирек бирешмичә. Лектор аның сүзләренә ригаяте елмаеп кына куйды һәм әңгәмәнең беткәнен

белгертеп, портфеленә тотынды. Вәзыйх Ирекнең Сталинга бирелгән булып кылануына каш җыерды. Чөнки ихлас түгел икәнен белә. Бары карьера өчен шулай икейөзлеләнә. Вил Садриевич һаман әүвәлгечә сталинистларны астан гына үзенә якынайта. Элегрәк Сталинны мактаган булып күпме юньсезләр эш башына менеп утырды. Ул чакта карьерага бердәнбер юл Сталинны тоташ мактап йөрү иде. Сталинның канлы эшләре фаш ителсә дә, түрә-мүрәләр аңардан баш тартмыйлар. Астан гына аны сагыналар. Чөнки астан йөри торган гамәл һаман Сталинча бара. Төгәл һәм кискен корылган механизм. Ул әле озак еллар дәвам итәчәк. Сталинизмның әйләнеп кайтачагына өмет бетмәгән.

Лектор киткәч, рәис үз бүлмәсенә юнәлде. Беркемне дәшмәсә дә, идарә әһелләре һәм кайбер куштаннар аңа иярде. Ишекне ябып, озын өстәл тирәсенә тезелеп утырдылар. Сүз көндәге мәшәкатьләр тирәсендә куерды.

—Кайчан чәчүне төгәлләргә мөмкин булыр, әһ, соңга калынды. Колак итен кимерерләр инде.—Пошынудан Вил Садриевичның җилкәләре салынды.

—Көн кояшлы килсә, бер тәүлектән...—диде Вәзыйх, ышанычлы тавыш белән. Вил Садриевичның йөзе җыерылды. Чәчүдә соңару Вәзыйхның үзсүзлелеге, принцибы аркасында иде.

—Чәчүлек җирләрдә ничә факел яна?—Рәис бу хакта белсә дә, сүз куерту өчен сорады. Чөнки бу хәл дә эчне пошырып тора иде. Ирек үзенең булдыклылыгын күрсәтергә ашыкты. Җиде-сигез факел чәчүлек межаларында яна,—диде каударланып. Аның кин, түгәрәк битле йөзенә ярашу нурлары типте.—Ә Бишмунча басуында өч факел чәчүлек уртасында...

—Узган ел анда чөгендер иде, быел бодай...—Вәзыйхның кашлары маңгай эргәсендә кушылып тоташты. Ул Ирекнең ярарга тырышып, үз вазифасына кермәгән нәрсәләргә борын тыгуын өнәми иде. Дөрес, Ирек бик булдыклы, өлгер егет. Бер нәрсәне дә онытмый ул. Кайчак хәтеренең үткенлеге белән шаккаттыра. Шуна тиз арада рәиснең уң кулына әйләнде. Рәис хәзер күп кенә эшләрен әнә Ирек белән хәл итегез дип кенә җибәрә иде.

—Факел тирәли егерме биш метр калдырган идек. Бодайга иркенрәк итәрбез...

—Ялкын унике метрлы торба өстендә яна,—диде Ирек, белгәнлеген күрсәтер өчен.—Неужели очкын игенгә кабар?

—Көчле җил булса, хәтәр инде.—Рәис шикләнүен яшермәде.

—Арыш уртасында ике факел янып торганые, берни булмады. Дөрес, факел тирәли кырык метр иде.—Вәзыйхның йөзе сүрелде, нигә барыбызга да мәгълүм нәрсәләр турында чүбек чәйнәргә?

—Игеннәр җиткәндә факелны сүндертергә кирәк!—Ирек һәр эш аның кулыннан килә кебек итеп кыюлана иде. Вәзыйх һәм бүтәннәр елмаештылар. Чөнки Ирек беркатлы уйлый иде. Нефтьчеләр эшен, аларның халыкара сәясәткә эшләвен белеп җиткерми бугай ул.

—Һе, бер скважинаны ярты сәгатькә туктату халыкара скандалга китерә,—дип кулын селтәде Вәзыйх. Ирекккә, белмәсәң, катышма, дигән төстә.—Нефтьне "Дружба"га куалар. "Дружба" бөтен Европага ташый. Политбюро үзе контрольдә тота...

—Шулай булмый ни, барча валюта нефтьтән килә бит!—Рәис бу әйтергә ярамаган сүзләрне ычкындырганда өстәл янында утыручыларның йөзләренә карап-карап алды.

—Шефлар зяб сөрергә биргән тракторларын алып киткәннәр бит әле!—диде Вәзыйх, тавышында борчылу һәм үртәлү белдереп.

—Ремонтка-мазарга мәллә?

—Китсәнә, күпме майладык мәнсезләрне,—диде Ирек, алдануына исе китеп, башын як-якка селкеп торды.—Атна саен сарык суйдык. Ашаган табакларына кәк иткәннәр.

—Алдан йөри торганны куймагансыздыр,—диде Зәйнагов көлеп.

—Адәм баласының ачкычы аракы шул, нишлисең...—Кайсыдыр авыр көрсенеп әйтте.

—Без көчләрәк ачкыч кулланырбыз,—диде Вил Садриевич, тавышын күтәрә төшеп.—Горком аша эш итәрбез. Лениногорскига үземә барырга туры килер.

—Юк, башта контора директоры Тугаев белән сөйләшергә кирәк,—дип, Вәзыйх эшнең җаен искәртте.—Тугаев бик горур зат, горкомга белгертсән, җене кузгалуы бар.

—Ә-ә, әйе, дөрес әйтәсен,—диде рәис, бу фикергә сөенгәндәй. Каш ясыйм дип күз чыгарырга без барыбыз да чос.

—Майламыйча таба купмый,—дип кыстырды берсе.—Элек тә шулай булган, хәзер дә...

Ишектә соргылт кожан куртка, калын кепка кигән, арыган чырайлы Шаяз күренде. Анын мастерскойдан кайтып килеше. Рәис, дикъкатен көчәйтеп, тагы синдә нәрсә бар, дигәндәй ана сораулы карашын төбәде. Мастерской—колхозның иң мөһим участогы.

—Камилов ике көн шунда эчеп яткан,—диде Шаяз, өстәлнең аргы башына килеп, солдатча рапорт биргән төслерәк.—Хисамовка бәйләнгән. Сугышканнар. Икесе дә салмыш. Хисамов тегененң беләген очлы тимер белән яралаган. Без бәйләп маташканда әллә кайдан патрульләр килеп керде. Хисамовны милиция алып китте...

—Эх, гөмбә башлар, ник бирдегез!—Рәис үзе дә сизмәстән шулай кычкырып җибәрде. Барысы да тынып калдылар. Хисамов хисаплы фрезер станогында катлаулы детальләрне кыра алучы бердәнбер оста иде. Аз сүзле, тыныч холыклы. Салгач кына бераз теле ачыла. Камилов ана бәйләнеп тәмам аны чиккә житкергәндер, юньсез. Дөрес, Камилов та "Дип" станогында эшләү остасы. Хисамов исә сәгать частьләре кебек нечкә детальләрне коеп куя белә.

—Ике кулсыз иткәннәр бит, авызын корт чаккыры!—Рәис, ачуына чыдый алмыйча, карандашы белән өстәлгә чыртлатып сугып алды. Янә тынлык урнашты.

—Иртәгә үк Хисамовны милициядән йолып алырга кирәк,—дип, Ирек рәис теләген куәтләде. Үзенең колхоз интересын кайгыртучы булуын һәр унай моментта искәртүчән булып бара иде.

—Алырсың эт авызыннан сөякне!—диде кайсыдыр. Рәис анын сүзен ишетмәгән кебек итте. Кашлары җыерылган, яңак сенерләре кыймыл-кыймыл килә. Нииндидер карарга килергә белми. Эчтә купкан ачулы фикерләре белән тартыша шикелле иде. Рәиснең кара коелган йөзе дәһшәтле сызыклар белән тулды, өстәл артындагыларны шомландырды. Ул бер кызып китсә, хәтәр эшләр майтара, кискен карары белән сине бетереп ташлавы да мөмкин. Шуңа анардан куркып торалар. Рәис башын күтәрә төшеп, парторгка карады.

—Мөнир Сөнгәтович, анда синен танышлар бар, Шаяз белән фрезеровщикны алып кайтыгыз, пожалыста,—диде ул, гозерле рәвештә.—Юкса кыр эшләре өзелә бит?

Зәйнагов, син моны чынлап әйтәсенме, әллә шаяртасынмы, дигән кебек, рәискә туры төбәлеп торды, йөзеннән канәгатьсезлек шәүләсе узганы сизелде.

—Һе, шул хулиганны аралап йөрисем калды менәтерә!

Рәис мондый җавап көтмәгән иде булса кирәк, барча керпе энәләре тырпайды. Һәм теленә килгән фикерне әйтеп ташлады:

—Мөшкел моментта колхоз өчен шуны да эшләмәгәч, син пычагымамы кирәк?!—Ул, ачуын тыя алмыйча, кинәт калкынып торды да тәрәзә каршына барып басты. Әрле-бирле йөренде. Чырае бүртенеп чыккан, йодрыктай алга калкып торган ияге дерелди иде.

—Ярар, барыгыз, кайтыгыз!—диде ул, активистларга кул селтәп. Аннары шкафын ачып андагы кишәләрдә актарынырга тотынды. Аркасы белән тойды, бүлмәдә кеше калмады шикелле. Әмма ялгышты, борылса, Зәйнагов өстәлнең теге башында турсайган чырай белән утыра.

—Вил Садриевич, син нигә халык алдында минем авторитетны

төшерәсен, ә? Беренче мәртәбә генә түгел. Болай килешми, понимаешь!— Зәйнаговның тавышында көч һәм хаклык сизелде.

—Бер сүз әйтергә ярамый, кыйгаерга гына торалар, анасын сатыйм,— диде рәис, тагы да ныграк кайнап.—Мин әйткәнне эшләсәң, халык алдында абруең бер вершок күтәрелер иде.

—Эчкечене йолып, без эчүчелекне купайтабыз. Менә хикмәт нәрсәдә!

—Синең сыныкка сылтавың астында кара уй ята. Син чәчүне өзеп, миңа аяк чалмакчы буласың, әйе, әйе! Чөнки фрезеровщиксыз машиналар эшләмәячәген белеп торасың!—Рәиснең күз аклары ялт-йолт килде. Зәйнагов та ачуына чыдый алмыйча торып басты. Бер-берсенә каты-каты сүзләр әйтешергә тотындылар:

—Синең үз принцибың юк, хатының ни әйтсә, шул. Гайбәтләрне чыңга аласың. Һаман район түрәләре тирәсендә бөтереләсең. Аларга колхоз балын ташыйсың...—Зәйнагов әнә шулай, эчендә йөргән зәһәрле сүзләр ычкынганын сизми дә калды.

—Үзеңне бел, сине дә хатының үз ягына магнитлап кына тора. Халуйлык белән күтәрелгән, кулы чиста түгел, дип сөйлисең икән. Әмма иптәш, беләбез, синең кулың да ак булмаска тиеш?—Рәиснең борын яфраклары лепе-лепе килеп селкенәләр иде.

—Юләр сатма, Вил Садриевич!—Зәйнаговның тавышы рәнжүле иде.— Адәм баласы үз нәфсенә баш була алмаса, әнә нинди хәлгә төшә!—Ул капыт кына борылды да кепкасын башына рәтли-рәтли ишеккә юнәлде.

Вил өенә кайтканда да тынычлана алмады. Күнитектән иде, пычракка бата-бата атлавын да абайламады. "Зәйнаговка артыграк бәрелдем, ахры, дип уйлады ул,—юк, үкенмим, аның эленке-салынкы эшләвенә ачу килеп йөри иде. Әнә чын "нутро"сы да беленде: миңа "герой исеме бирү ихтималы аның эчен кыра икән. Таһия сиздергән иде, ышанмаган идем. Хәзер ачыкланды. Әйе, кешеләрне бер-берсеннән көнләшү кимерә. Парторгта ул хис булмаска тиеш иде, югыйсә".

Урыс капканың кече ишеген ачты гына, елт итеп Таһиянең тегүче хатыны чыгып китте. Таһия авылда беренче мода тотучы, барча киемнәрен сызым буенча шул төлкегә охшаган чырайлы хатыннан тектерә. Өйдәге гайбәтне шул читкә чәчеп йөрми микән?.. Ул, тавык кетәгенә кереп, ялгашка чүпле бодай салды. Алар тавыктан башка кош-корт тотмыйлар. Курма кирәк түгел. Рәис үзенә печән-салам кайтарды, ә безгә юк дип артта шыңшый алмыйлар. Утын ягыннан да эш җайланган. Бу зур йортны нефтьче түрәдән сатып алган иде. Түрә шәһәргә күчте. Ул өйне җылытуны паровойга көйләгән. Вил Бөгелмәдән әллә ничә елга җитәрлек күмер кайтартты. Мичкә бер чиләк кертеп саласың, тәүлек буе өең май. Утын-печән буенча күзгә төртүләрдән азат. Утын-печән мәсьәләсе һәрчак бик кискен тора. Һәр көн һәркемгә кирәк ул: урлашу, караклык чыганагы... Курма урлап ничә кеше зинданга эләкте. Курма, утын авыл кешесенең башына җитә торган нәрсә. Коммунистик принцип та аны бетерә алмады. Әнә лектор да: караклык мәсьәләсе марксизмда каралмаган, ди.

Чәй эчеп утырганда Таһия серле йөз белән Вилгә бер газет тоттырды. "Әнә, тар гына колонкадагы вак хәреф белән баскан, астына мин сызган төшне укы",—диде. Вил, мәкаләгә күз йөртеп алгач, кинәт җитдиләнде, куркынган кебек күз аклары эргәдән чыкты.

—Иптәш Сталинны Мавзолейдан алганнар! Съезд карары белән,—дип, муенын Таһиягә таба сузып пышылдады ул.—Кара, ничек яшереп кенә басканнар. Димәк, халыкка әйтергә ярамый, ә?

—Юк, бу минем башыма сыймый,—диде Таһия дә пышылдап.—Неужели сәясәт үзгәрер икән?

Башларына кинәт китереп суккандай, икесе дә телсез калып тордылар. Таһиянең биек күкрәкләре бер мендә, бер төште, тибрәнүдән туктамады. Вил муен артын кашып-кашып алды. Бу хәлне зиһене кабул итәргә теләми кебек иде.

—Безнең ише сталинистларны кыса башларлар микәнни?—Таһиянең

тавышы пышылдап чыкты, һаман куркуыннан кайта алмый.
—Җайлашырга кирәк булыр, битлек кияргә!—Вил исен җыйды.
—Болай да битлек белән яшәдек бит?—Таһиянең йөзендә кайгы сорылыгы иде.—Ә сина "герой" бирү мәсьәләсе нишли? Геройны бит хезмәт өчен генә түгел, идейный булган өчен бирәләр?
—Да, бу мәсьәләдә осечка булуы мөмкин...—Вил газетаны читкә куеп, чынаягындагы суынган чәйне шөбер-шөбер уртлап алды.
—Без өйләнгәч, төн кыскарды, дигәндәй, авызын себерим! Тир түгүләр җилгә очар микәнни? Юк, шалишь! Райисполкомда эшләгәндә дә мина герой исеме бирергә дигән "мнение" йөргән иде. Син, ул чагында унсигез яшьлек кыз, муеныма асылындың да үзеңнеке иттең. Карьера да, "геройлык" та челпәрәмә булды. Ике бәхет бергә килми, диделәр...—Вилнең янакларында үкенү, үртәлү билгеләре беленде.
—Үткән-беткән инде, ничу үкенергә! Хәзергесе турында уйларга кирәк,—диде Таһия, кинәт купаеп киткәндәй.—Үзем йөреп, кылларын тартып карыйм әле. Шишка-мишкалардан әшнәләрем бар минем.
—Ике аягыннын берсен атлыйсы булма! Болай да Таһия Виле дип йөртәләр. Янәсе, хатын табаны астында.—Вил ир буларак үзенең баш иканен искәрткәндәй итте. Таһия кулын гына селтәде.
—Эт өрер, бүре йөрер,—диде.—Нигә мин гайбәткә карап ниятемне туктатыйм? Төкерәм мин аларга...
Таһия үз дигәнен эшләми калмый. Вил каршы килгән саен отыры үҗәтләнә. Әрепләшүдә файда юк, хатын ягына аварга туры килә. Мин-минлегенне учына йомарлап булса да...
—Бездә мәктәптә "чепе" булды бит әле,—дип Таһия иренен күнелен табарга теләгәндәй күзләрен ялык-йолык китереп сөйләп китте.—Русча укуга күчү мәсьәләсендә, инспектор килгән иде. Фаяз Бортасов каршы чыкты, татар мәктәбе бетсә, татар бетә, ди. Инспектор Фаязны ронога алып китте.
—Һе, бетерерсен татарны!—Вил башын чайкап алды.
—Ә русча уку кирәк,—диде Таһия, дәвам итеп.—Менә егетләр бер авыз сүз русча белмәгән көе армиядә ничек хезмәт итә алсыннар, ә?
—Әйе, армиядә хәзер нинди катлаулы техника. Русча белмәү бәхетсезлек ул,—дип, Вил хатынына ярарга тырышкандай яктырып китте.—Ну, Таһия, шуңа сөенәм, Сәнифәне рус мәктәбенә бирүенә акылын җитте! Молодец! Мин юләр, каршы килеп маташтым. Русча укымаса, маляр-мазар булып, акбурга батып йөрер иде. Башы бер дә булмады. Русча уку аркасында әнә нинди җайлы урында эшли. Бер дигән егетне эләктерде. Байрак нефть остасы. Ышаныч казанган. Шмаревнын "любимчигы" бит. Шуңа Байракны Иранга нефть чыгарырга җибәрделәр дә. Менә кемгә герой исеме шәйләнә...
—Анда да эшләре җайлы бара икән,—диде хатын, эчтәге шатлыгыннан нурланып.—Узган айда Мәскәүгә кайткан иде бит. Люберцыдагы заводтан долотолар алырга. Алдан хәбәрләшү буенча Сәнифә шунда барып торды. Атнадан артык бергә яшәгәннәр.
—Сәнифәгә синең уңганлык күчкән,—диде Вил, хатынын тагы купайтып һәм чынаяк-савытларны кран астына куйды, чүмеч белән кайнар су салды. Кечкенә мунчала кисәге белән юа башлады. Үзе һаман Таһиянең эшләрен мактый. Синдә фикерләр, хәлләрне алдан чамалау бик көчле, синдә "железная логика" дип тә җибәрә. Таһия исә һәр мактаганны чын дип кабул итә, күнеле канатлана. Әнә урын җәярга очынып чыгып китте. Ятар алдыннан сүз туры китереп, Таһияне мактау Вилнең тактикасы иде. Шулай итсән, яткач Таһия артык ялындырмый, җылы кочагын бик тиз ачып куя...
Иртән чәй эчеп утырганда капка төбендә "Москвич" белән Шаяз килеп туктады. Вил тәрәзәдән карады һәм барысын да анлады: Хисамовны юлларга Зәйнагов алынмаган икән, үземә чабарга туры килә инде".. Ул тиз генә киенеп чыкты.
Билгеле нәрсә, рәшәткә артына бер эләккән кешене болай гына йолып алу мөмкин эш түгел. Горкомнын икенче секретаре Митрофанов алдында

йөз суы түгәргә туры килер, ахрысы. Аны борчыйсы килми иде. Шаяз Ленизаның эшләгән жиренә керде. Шул эшләр буенча баш прокурор ярдәмчесе Ленизаның яхшы танышы икән. Машинага утыртып шуңа килделәр. Бу Сачков фамилияле эре, мәһабәт гәүдәле, миһербанлылыгы йөзенә чыккан рус кешесе иде. Андый кешеләр вакчыл булмыйлар. Иң мөһиме: курыкмыйлар. Лениза аңлатып бирде. Сачков шунда ук бланкка рөхсәт кәгазе язды.

КПЗ кайту юлы өстендә иде, Хисамовны алып чыкканда матавык булмады. Ленизаның шулай файдасы тигәли иде.

13

Контракт буенча бозау жыярга чыккан активистлар башта Түрфәндә ихатасына килделәр. Хатын болдыр баскычында иде, боларны күреп алды һәм максатларын да чамалады. Хәзер! Хәзер!—дип кычкырды ул аларга. Бозавын муенчаклап алып чыкты да, ипи каптыра-каптыра килә. Ирәм генә кызыл бозау... Хатын үзе дә бик ыспай киенгән. Өйдә дә, эштә дә өс-башын пөхтә йөртә. Чәчләрен баш артына төйнәп куйган. Аксылалсу битләрендә ниндидер мәрхәмәтлелек нуры. Күп еллардан бирле алдынгы сыер савучы. Авыл советы депутаты. Бар жире килешле, мөлаем. Аны президиумнарга утырталар. Бүтәннәрдән ул киң күңелле, юмарт жанлы булуы белән аерылып тора. Шуңа аңа гайбәтләр дә күп ябышмый...

Ул бозауны олаучыга тоттырды. Аны арбага урнаштырган арада Рәмисә, Зәйнагов белән тегене-моны сөйләшеп торда да, капканы ябып, йортка таба атлады. Түрфәндә бай биографияле хатын...

Әтиләре сугышка китеп, бер-ике ай эчендә юкка чыккач, алар булдыксыз, юбалгы әниләре кулында дүрт бала калдылар. Түрфәндә өлкәне, жәй буе утауга йөрде. Урак башланганнан бирле борчак сугу машинасында салам селкүдә эшли. Кыр станында көндез бер мәртәбә ашаталар иде. Өйдә берни юк... Ул эштән кайта да, хәлсезләнеп, сәкегә ава. Мич артыннан башын сузып, әнисе елый-елый кызны тиргәргә тотына. "Нигә әзрәк борчак алып кайтмадың? Бу сабыйлар ачка үләләр бит, ый-ый..." Кечкенәдән ул Түрфәндәне күрәлмый. Бишектә чакта анардан котылырга теләгән. Бала әнисенең кызлык хыялларын чәлпәрәмә китерүгә сәбәпче булган, имеш? Шуның ачуын шуңа күчергән. Ул Түрфәндәне әз генә гаебе өчен дә кыйный, һаман кыерсыта иде. Кече яктан ажгырып чыга да кызның чәчләреннән учлап ала һәм сәкедән өстерәп төшерә, ишек тупсасына китереп ташлый. "Ник кесәнә борчак салып кайтмадың, ә?! Юньсез нәрсә!" Түрфәндә кычкыра, балалар акырышалар. Ашарга сорыйлар. Ана бик каты ярсыган. «Үтерәм»,—дип ачудан ысылдый. Түфәндә, коты алынып, ишектән атылып чыгып чаба. Күз бәйләнгән чак. Урамнан бик күп олаулар-транспортчылар узып бара. Ул уйсыз-нисез саклану инстинкты белән генә соңгы олауның артына барып ябыша. Йөк өстенә зур кочак печән-вика төйнәп салган. Кыз арбага менеп шуның артына поса. Ни булса шул...

Төне буе бардылар. Яктырганда Биектау буенда атларны хәл алдырырга туктадылар. Атлар башына солылы торба элделәр. Олаучы карт шунда Түрфәндәне күреп алды һәм бер дә гажәпләнмәде. Кыз ялганлады: авыр, яралы әтине Бөгелмә госпиталенә кайтарганнар... Карт, арбасына сөялеп, куенынннан ипи сыныклары алып капкалый. Кызга да жир кебек кара сынык бирде. Ипи бик тәмле иде.

Бөгелмәдә әллә ничә төн вокзалда аунады. Шундагы базарчыкта калдыкпостык белән ризыкланып, жан асрады. Аны милиция тотып, частькә алып керде. Русча белми, татар кешесе сорау алды. Түрфәндәнең ялганлаудан башка чарасы юк иде. "Әти сугышта һәлак булды, әни дә гүр иясе. Безне Норлатка китерделәр дә ташлап киттеләр. Бер әйбәт милиционер мине Бөгелмәдә детдом бар дип поездга утыртып жибәрде..."

Шул рәвешле Түрфәндә Хәким хуторындагы детдомга эләкте. Монда

ашаталар, иске-москы кием дә бирәләр. Ин элек чабата урынына иске брезент ботинка кигерделәр. Русча белмәү суя иде. Кагалар, кыерсыталар, порциясенә ягылалар. "Чаплашка! Желудок!" дип үртиләр. Башта елый иде, аннары үзе дә этләшә башлады. Яшәү өйрәтә. Аларны подсобный хуҗалыкта эшләтәләр: бәрәнге алдылар, подвалга ташыдылар. Суыткач, кәбестә кучәне чаптылар. Малларнын тиресен чыгардылар.

Кышка таба ундүрт-унбиш яшь тирәсендәгеләрне җыеп, Казанга ФЗӨгә озаттылар. Килгән урыннары—житен фабрикасы икән. Бар төштә сүс, болыттай тузан. Тулай торак ягылмый диярлек, салкын. Укыталар, эшләтәләр. Түрфәндә машинага сүс учмасы биреп тора. Эре җепселле сүсләр мамыкка әйләнеп чыга. Аннан эрләү машинасына керә... Әмма ашау бик начар. Карточкага тигән ипине дә китермиләр. Түрфәндә үзенең чәчләрендә теге "аксыл җанварлар"ны күреп имәнеп китте. Ашау житмәүдән инде бу галәмәт. Казанны ач як дип сөйлиләр иде, дөрес икән, дип уйлады ул. Юк, моннан тизрәк ычкынырга кирәк, дип фикер төйнәде.

Бер атна дигәндә үзенең детдомына кайтып егылды. Бетләрдән арынырга чак өлгерде, аны эзләп милиция килде. ФЗӨдән качкан өчен закон бар икән. Кулга алып, суд ясап, Бөгелмә төрмәсенә ябып та куйдылар. Тормыш бик аяусыз, ул беркемне дә җәлләми.

Ярым карангы подвалда ике катлы нарлар. Ана урын юк иде. Матрасын "параша" лаканыннан ерак түгел идәнгә куйды. Өч көннән сон гына бер почмак бушады.

"Подъем", "параша", "оправка" дигән командалар анын миенә уелдылар. Хатыннар бик ачулы, үчлеләр. Бер-ике хатын үзара гел талашып торалар. Арада кешечә якты йөзлеләре дә күренә. Алар китап укыйлар. Түрфәндә русча анлый, кайтарып әйтергә дә өйрәнеп килә иде. Шуны белде: бу камерада сәяси гаеп белән хөкем ителгәннәр утыра. Берсе дә үзен гаепле дип санамый. Шуна бик ярсулы-ачулылар. Түрфәндә анына барып житми торган нәрсәләр турында өзлексез бәхәсләшәләр, тузынып китәләр. Арада ин сабыры, ягымлысы Зинаида Алексеевна—тетя Зина. Ул Түрфәндәне җәлләп, үз канаты астында тота. Оправка вакытында әйберләрен юыша. Надзирательләрнең башбаштаклыгыннан аралый. Тетя Зина нинди хәлдә дә итәгатен җуймый. Ул Үзәк Комитет каршындагы югары курсларда укыган, комсомол өлкә комитетында эшләгән. Ләкин ана күрше нардагы меньшевиклар яклы булган өчен утыртылган карчык бәйләнә. Иске чабата чырайлы, какча гына бик тере нәрсә. Үзе Мәскәүнеке, ди. «Большевиклар, дип сөйләнә ул, башта ук: максат чараларны аклый дигән көчләү, мәҗбүр итү системасын хуп күрделәр. Һәркем үзе теләмәсә дә, янындагы иптәшенә шик белән карый, ана донос ясый. Кешеләр бер-берсенен башын ашый. Система исә шул системаны төзүчеләрнен үзләрен кырырга керешге. Сине дә Зина якын иптәшләрен доносы белән төрмәгә тыкканнар... Юк, кешеләр гаепле түгел, система гаепле!»

Карчык сүзләренә Зинанын һич тә исе китми, гүя ишетми. Ул бу карчык белән бәхәсләшеп арыган, үзенекен исбат итеп көч түкми. Өстәл өстенә үкчәләре тишек оекларын җәеп салган. Тишек-тошыкларын ямый, ике оектан берне ясый.

Мен тугыз йөз кырык дүртенче елнын башы фронттагы зур җинүләр гамәли тормыштагы кырыс киеренкелекне азайта төште. Камерада бу сизелде. Чөнки газеталар бирә башладылар. Менә "Комсомольская правда"да зур битне тутырып Краснодонда яшьләрнен оккупантларга каршы ничек көрәшүләре турында язганнар. "Яшь гвардияче"ләр немецларнын складларын, ягулык базаларын шартлатканнар. Һәр төштә зыян салганнар. Театр бинасына кызыл флаг элгәннәр... Ләкин аларны үз иптәшләре саткан. Шул хыянәтчеләрнен берсе Зинаида Алексеевна Вырикова икән. Әйе, тетя Зина. Камерадагылар ышанмыйлар. Әллә бу синен туганындамы? Юк, булмас. Зинаида Алексеевна газетны укый, йөзе бер агара, бер күгәрә. Сулышы кысыла. Тамак астына учын куеп тора. Барысы да ана кадалып карыйлар. Тетя Зина еламый, чөнки гаделсезлекләрдән бәгыре каткан. Ул анлатырга мәҗбүр булды:

—Әйе, газетада минем хакта язылган. Ләкин фамилиямнән башка монда бер дөрес сүз юк. Чөнки мин күрше Сталин өлкәсендә эшләдем. Безнекеләр аннан чигенгәч, Краснодонга—үз поселкабызга кайттым. Поселок шәһәрдән читтәрәк. Оккупация вакытында шунда яшеренеп яттым. Беркем күзенә күренмәдем. Яшь гвардиячеләр турында да берни белмәдем, ишетмәдем. Дөрес, нindидер малай-шалайлар театр бинасына флаг кадаганнар дип сөйләнгәннәр иде... Яз көне шәһәрне безнекеләр алды. Немец пособникларын арестовать итә башладылар. Урта мәктәп комсоргы Лядскаяны һәм мине кулга алдылар. Ә Лядскаяны полиция арестовать иткән булган, аннан гаепсез дип чыгарган. Шуңа ана каты хөкем булды, биш ел бирделәр. Ә миңа гаеп тага алмадылар. Миңа хәтта суд та булмады, һаман да юк...

Арестантлар ышанырга да, ышанмаска да белмәделәр. Тетя Зина моңа әһәмият итмәде. Ул күптән башлаган эшен—Түрфәндәне таш капчыкта тотуның бернинди законга да сыймавын исбатлау эшен тагы да үҗәтләнеп дәвам итәргә кереште. Законнарның чыгармаларын, искәрмәләрен яхшы белә иде. Үзен гаепсез саный һәм шуңа бер дә курыкмый. Күп инстанцияләргә прошениеләр язды. Барысын да Мәскәүдә югары урыннардагы танышларына юллый. Хат-гаризаларын монда алмасалар, ачлык игълан итә... Нәчәлникларның җанына тия торгач, Зинаида Алексеевнаны каядыр озаттылар. Ә Түрфәндәне аралап язган кәгазьләрнең тәэсире булды. Фронттагы җиңүләр уңаеннан була торган амнистиягә Түрфәндәне дә керттеләр.

Ул авылга кайтты да сенде. Көн-төн колхоз эшенә җигелде. Усал әнисенә бирешми иде инде. Зинданнан күп нәрсәләргә өйрәнеп, акыл җыеп кайтты. Бер бала үлгән, икенчесе ФЗӨгә киткән. Шулай да ничек кирәк алай тернәкләнделәр. Авыл кырларында нефть табылгач, тормыш уңайланды. Бер нефтьченең Түрфәндәгә күзе төште, йортка керде. Өйне яңа бүрәнәләр белән сипләде. Буровой такталарыннан болдыр-өйалды эшләде. Ләкин ике елдан аның гаиләсе—баласы барлыгы беленде. Ул баламны сагынам дип шунда китте... Әнисенең дә зәһәрлеге сүрелде, ул сукырайды, бетәште. Әнә таякка таянган да абзарга таба бара.

—Түрфәндә, бозауны бәйләденме, бакчага керде микән?—ди-ди, сукранып атлый.

Шул тавыш Түрфәндәнең ачы уйларын бүлде. Нигә ул күптән үткән нәрсәләр бозауны биреп җибәргәндә хәтеренә килде икән? Бу хәтерне һич анламассың.

Ул арада активистлар исемлек буенча чираттагы хуҗа капкасына килеп туктадылар.

Ишегалдында бер карчык, аның артыннан чыр-чу килеп тавык-чебеш өерелеп йөри. Ул, озын, тар ялгашларга иелеп, җим болгата. Ирек килеп кергәнен күрде дә, турайды, башына бәйләнгән ак яулык кырыйларына чәчләрен тыккалады. Ирек бик кечелекле итеп исәнләште һәм йомышын әйтте. Карчыкның җыерчыклар ермачлаган чырае кинәт караңгыланып китте. Иреннәре ачу белән бөреште... Бозауны көчләп алу юк, ул иртә язда ук хуҗа биргән ризалык буенча алына. Ләкин дөрестән дә кичәге исәп бүгенгә ярамый шул. Кешеләрнең фикерләре үзгәргән. Ирек моны сизеп, телдәрләнергә кереште:

—Әби, бозау өчен бодай быел күп итеп бирелә, идарә карары шулай,—диде.—Ашлык кирәктер бит?

—И-и, кирәкмәгән кая?—дип, карчык кырын торуыннан кайта төште, тураеп карады.—Дүрт бала! Ир-ат инде эчмичә тормый. Киленнең дә эше әллә ни түгел...

—Менә запас булыр!—дип, Ирек бик житди кыяфәттә карчыкка туры төбәлде. Аның кырысланган чырае бозауны тизрәк чыгар, дигән боеруны сиздертә иде. Кешеләр белән эш иткәндә йомшаклык күрсәтергә ярамый. Зыян гына китерә. Карчык та ачулана күрмәсен бу калай әтәч, гозер һаман шуна төшә дигәндәй, тиз-тиз абзарга таба китте.

Бозау матур гына иде. Ул һаман муенчактан ялгашка таба тартыла. Ирек, муенчакны үзенә алды да, бозауны алга өстери башлады. Әмма бозау дүрт аягын терәгән дә тик тора. Бортасов Фаяз килеп керде, ул да бозауны тарткалады, эткәләде. Бозауның гәүдәсе урталай бөгелеп килә. Ләкин дүрт аягының берсен дә җирдән кубармый. Кай арададыр җим болгатып йөрүче кара чутыр ике малай килеп бозауның муенын кочаклап алдылар. Башын сыпыралар, сөяләр. "Юк, тимәгез!"—диде өлкәнрәге. "Бозау үзебездән артмый!"—диде кечерәге. Малайлар чәтертән кебек тереләр. Бозауны ычкындырырга исәпләре юк. Әби ясалма ачуланган булып аларга кычкырды. Ләкин һич тыңламыйлар. Ирек белән Бортасов малайларны юмаларга керештеләр. Үскәннәр, бозау өчен күп итеп бодай бирелә, күмәч ашыйсыгыз килмимени? Ипи тегермәнегез әнә шәп эшли булыр, ә?

Юк, малайлар бозауны җибәрми. Әби йөзенә унайсызлану төсе чыгарды. Ул, җил-җил атлап килде дә, иплән кенә башта бер малайны, аннан икенчесен бозаудан аерып читкә этәрде. Малайлар җиргә утырып елый башладылар. Ирек белән Фаяз бозауны алга өстериләр. Бозау кузгалмый, башын малайларга борып күзенең акларын чыгарган. Бу хәлне капкадан күзәткән Рәмисәнең күңеле бозылды. Балаларның ашый торган ризыкларын кулларыннан тартып алу кебек бит бу!—дигән уйлар баш миен сызып узды. Аларның җиргә баш игән килеш ихлас яшь түгүләре күңеленең кай төшенәдер барып тиде. Ә Зәйнагов белән авыл советы секретаре Акчуакова исә үзләре генә белгән нәрсә хакындамы сөйләшеп, елмаешып торалар. Бу чибәр хатын янында Зәйнаговның йөзе нур чәчеп яктыра иде. Ул арада алапалы, таза олаучы килеп керде дә бозауны ал, арт саннарыннан гына тотып кочагына күтәрде һәм алып чыгып китте. Ирек белән Бортасов аның артыннан атлыйлар. Ирекнең чырае җинүле горурлык белән тулган. Ә Фаязның исә нигәдер кәефе киткән күренә. Бертуктаусыз тәмәке тартә. Бер папиросы беткәч, шуның уты белән икенчесен кабыза. Малайларның елашып җирдә утырып калулары аның да күңеленә тигән булса кирәк.

—Үксез балалар, бозауларының да үксез булачагын сизенеп елыйдыр бу сабыйлар...—дип сөйләнә ул үзалдына.

Ләкин җәмәгать кануны бар нәрсәләрдән өстен. Һәркемнең кәефен исәпләп тору мөмкин түгел. Һәркемгә ярасаң, бер эш булдыра алмыйсың. Тормыш каршындагы бурычың үтәү өчен һәр адәм тырышырга тиеш.

Активистлар Ершов капкасында килеп туктадылар. Бу әсирлектә булган кеше. Аннан кача, ләкин үзебезнекеләргә чыга алмый. Бер авылда "местный житель" булып китә. Фамилиясен шунда үзгәртә. Андыйларны концлагерьга япмыйлар, ә эшкә урнаштыралар. Җан асрарлык кына ашаталар. Шулай исән кала... Элеккеге Шәйхетдинов—хәзерге Ершов. Кара, ничек баеган. Нефтьче подсобкада гына эшли югыйсә. Эшче сыйныфка сан бар шул. Алар крестьяннан бер башка югары дәрәҗәдә.

Өйдән янаклары эчкә баткан кара кучкыл битле, урта буйлы, ачулы хатын чыкты.

—Ершов абый белән сөйләшенгән, килешенгән иде,—дип, Ирек йомышны аңлатты.

—Юк, юк,—диде хатын, биек күкрәкләре турында ике кулы белән кире кагу хәрәкәте ясап.—Сез аны пленда булган дип, эчертеп какшаткансыз. Йөз грамм өчен ул анасын сатар...

—Сөйләшкәндә ул ап-аек иде, валлаһи менә!—дип чәчрәде Ирек.

—Юк, әйтмә дә, сөйләмә дә, сез аңа салдыргансыз... Бу йортка хәзергә мин баш әле... Юаш дигәч тә... Минем белән сөйләшмәдегез?

—Менә сөйләшеп торабыз түгелме соң?—дип, Ирек кырыс кына аңлата башлады.—Сездән бозау алу каралган. Көзен өчләтә бодай бәрабәренә.

—Юк, безгә нефть конторы бодай онын теләсә күпме биреп тора. Әнә кладовщик Фәүзидән бар да ал!

—Малларны бодай оны белән туйдырып булмый. Колхоздан печән, салам аласыз?

—Сез нәрсә, әллә нефтьчеләрне раскулачивать итәргә чыктыгызмы?—

Хатын чат-чат килде.—Син, Баррай, простой халыкны кысрыклап, нәчәлникларга ярарга тырышасың...

Хатын әрепләшкән арада Зәйнагов белән Акчуакова абзар капкасын ачып, эчкә күз салдылар һәм күзләрен кырынайтып карап, Ирекка ым кактылар. Бу ымны шәйләп Бортасов белән Рәмисә дә якын килделәр. Карасалар, бер почмакта бишекле мотоцикл тора, ана чүмәләмә яшь люцерна төялгән иде. Тау буенда чалгыга эләгерлек булган дигәннәр иде.

—Әнә күр!—диде Зәйнагов, Ирекка карап.

—Әйе, люцерна, Чагыл буеннан чапкан!—Ирек, барып, йөктән бер учма люцерна печәне алып килде.

—Син ревком ярдәмчесе, колхозның завхозы,—диде Зәйнагов, һәр сүзенә мәгънә салып.—Монардан ни исе килә, чамалыйсыңмы?

—Төймәдән дөя ясамагыз әле пожалыста, кыерсытабыз дигәч тә!—Хатын йөзен-кашын җимереп, кычкырырга ук тотынды.—Юл буеннан чапкан үлән өчен...

—Кая үлән! Люцерна!—дип тавышын күтәрде Ирек.—Акчуакова, моны болай калдырырга ярамый, протокол яз! Шаһитлар да бар...

—Юк, юк, зинһар!—ди-ди хатын кулларын алга сузып бутады, йөзекыяфәте кинәт юашланып, бөрешкәндәй булды.—Бозавымны түгел, танамны бирәм, бәлали генә күрмәгез, Ирек туган?—Аның тамагына төер утырып, сүзе бүленде.

—Колхозны тәмам таларга керештеләр, понимаете ли!—Зәйнагов абруйлы сүз әйтергә кирәклеген сизде.—Протокол да язарбыз, бозауны да алырбыз...

—Парторг безне пленда булган дип һаман кыерсыта инде. Әллә үзен колхоздан файдаланмыйсыңмы?—Хатын борынын лышкырдатып, учы белән күзләрен сыпыргалап алды.

—Туктагыз, сез бигрәк,—диде Рәмисә, ныклы, сүзе үтә торган тавыш белән.—Әз генә курмы өчен кешене бәлаләргә тагы! Бозауны үз ризалыгы белән тапшыра бит.

—Пожалыста!—дип, хатын җанланып киткәндәй булды.

—Бернинди протокол кирәкми,—диде Бортасов, Рәмисә сүзләрен куәтләп. Тегеләр берсе дә каршы ләм-мим. Хатын каш астыннан гына парторг белән Ирекка күзләрен атып алды да, дәртләнеп, абзарга кереп китте.

Менә таза гына бозауның муенчагы Бортасов кулында.

—Апа, ирексезләп алдылар дип чәпчеп йөрмәссен бит?—дип әйтеп куйды ул.

—Юк, юк, кая ул!—Хатынның тавышы килешүле иде.

—Рәхмәт апа, син дә тыныч бул!—Бортасов бозауның муенчагын тартты. Ул бер дә карышмый атлый иде... Активистларның чырайларына яктылык чыкты. Хужабикәгә баш ымы кагып, саубуллаштылар да бозау артыннан иярделәр... Алар бу хатынга барыбер бәла ясамаслар иде. Чөнки эчләрендә ачу-кычу юк, хаерхаһлык кына. Тәҗрибәләре күп, кешеләрне үзенә дошман ясаудан беркемгә дә файда булмый.

Зәйниев Ислам йорты башкалар белән чагыштырганда ярлырак күренә иде. Бердән, нефтедә эшләүчесе юк, икенчедән, атлы эштә йөрми. Атлыга акмаса да тама, арба төбендә ни булса да кайта. Боларның—юк. Шуның өстенә язмыш үги ана тарафыннан һаман кыерсытылалар. Фермада алдынгы сыер савучы кызы законсыз бала тапты. Кардага килеп, кызны алам дип алдаган. Үзенең күрше авылда өч балалы гаиләсе бар икән... Моның хурлыгыннан ата-ана тәмам сынып төштеләр. Чырайларында адәм нуры, өн калмады. Сугышка киткән уллары алган ярасыннан тәмам сукыр булып калган. Казан урамнары чатында соранып утыра икән. Әти-әнигә тере хәсрәт, йөк буласым килми дип әйтә ди. Бу да ата-ананың йөрәген өзеп, әрнетеп тора инде. Уртанчы уллары Минзәлә авыл хуҗалыгы техникумында укый иде. Бар өмет шуңа төбәлгән. Әмма бер килмәсә килми бит. Көз подсобкада бәрәңге алганда шәһәр һәм авыл малайлары якалашканнар, ә бу үз иптәшләрен яклаган. Беркадәр вакыттан соң, аны

бик каты кыйналган килеш кенбагыш сабаклары арасыннан тапканнар. Гипста ята. Зинадан туган малае да игелек күрсәтмәде, ни эшләмәде, ни укымады... Ата-ананы, барысыннан да бигрәк, балалар китергән кайгы бетерә инде.

Активистларга бу хәлләр таныш иде, жил капкадан йортны күзәтеп торгач, кинәшә башладылар.

—Бозавын калдырырга кирәк,—диде Фаяз, бер папиросыннан икенчесен кабызып.—Хәерчене талаган шикелле килеп чыга болай.

—Әйе, әйтмәсән дә, просто унайсыз!—Рәмисә Бортасовны тизрәк якларга ашыкты.—Ни йөз белән дигәндәй...

—Болар безотказныйлар,—дип, Ирек аларга каршы төшкән кыяфәт чыгарды.—Биргәннен битенә бакма.

—Син, Бортасов, һәрчак диярлек "политический незрелость" күрсәтәсен!—диде Зәйнагов, кашларын хәтәр жыерып.

—Шул политика дип кешене тәмам изәсез инде!—Бортасов кызып китте. Мангай тамырлары бүртеп зәңгәр сызыклар булып беленде.—Хәлен анларга кирәк! Сезгә политика-карьера ясау инструменты...

—Ярар, Бортасов, тирәнгә кермә, юкса чыга алмассын!—Рәмисә гадәтенчә тынычландырмакчы, мөнәсәбәт кискенләшүдән тыймакчы булды.

—Юк, минем бу йортка аягым тартмый!—Бортасовнын тавышы тыныч һәм житди иде.

—Мин дә керә алмыйм,—диде Рәмисә, Зәйнаговка карап.

—И-и, черек интеллигент жыбыткылары!—Зәйнаговнын тавышы теш араларыннан кыжрап чыкты.—Сез нәрсәгә генә ярыйсыз соң? Халык анын бутарга гына беләсез! Сез әзергә бәзер!—Ул капка биген ычкындыра башлады. Ләкин бозавын мунчак белән житәкләгән хужабикә әби капкага таба килә иде.

—Олы башыгызны кече итеп йөрисез, рәхмәт төшкерләре,—ди-ди сөйләнеп, әби бозауны капкадан ук чыгарды.—Сезне жәлләп куйдым...—Ул бозау мунчагын Зәйнаговка тоттырды. Үзенен сүзе бетмәде.—Безнен малыбыз да, жаныбыз да колхозныкы булды,—диде.—Бозау нәрсә ул! Егерме алты ел бушка эшләдек. Хәзер, шөкер, эшләгән өчен бирәләр. Совет властена рәхмәт! Тамагыбыз тук, түбәбездән янгыр үтми.

—Рәхмәт әби, анлы, башлы икәнсен!—Зәйнагов әбине мактарга жай чыкканга сөенеп, матур сүзләрне сипте генә. Әби өенә кереп киткәч, жинүле, үзен өстен сизгән рәвештә Бортасовка шелтәле карады.

—Бортасов, әнә күрәсенме?—диде.—Сез халыкны белмисез! Анын психологиясен анламыйсыз! Сез...—Ул иптәшләренә күз төшерде, берсе дә аны тынламый иде. Читкә караганнар. Зәйнаговнын кызыл авыз икәнен беләләр, кызыл булуы аркасында гына дәрәжәдә торуын анлыйлар иде.

Кирам ишегалдында мотоциклы янында маташа иде. Бу шактый бай, саран, усал кеше. Нефтьтә помбур булып эшли. Сугыш вакытында Ростовта немец пленныйларына конвой хезмәтендә булган. Ышаныч казанган кеше. Шуна ана помбур эшен ышанып бирәләр. Буровойга болай гына эшкә урнаша алмыйсын. Ул, боларны күреп, капкага килде.

—О-о, дуслар килә икән, түрдән узыгыз!—дип сөйләнде ул. Анын кызарып күпшенгән чырае кызмача икәнен сиздерә иде. Әйтеп тормыйча да боларнын йомышларын анлады.

—Түлке мин бозауны Зәйнагов белән Акчуаковага гына бирәм,—диде, кинәт житди төс чыгарып. Иптәшләрнен елмаюларын күз кырые белән шәйләп:—Әйе, принципиально аларга гына бирәм!—диде, тагы да ышанычлырак төстә. Активистлар ни әйтергә белмиләр. Кирам шаяртмый шикелле иде. Хәер, салмыш кешедән теләсә ни көтәргә мөмкин. Киреләнсә, бөтенләй куып жибәрергә дә күп алмас.

—Кирам, нигә бозауны безгә генә бирәм дисен, ә?—Зәйнагов хужага төбәлеп, нindидер сер белергә теләгән кызыксыну белән әйтте.

—Алырга теләмисенмени?—Кирамнын күз керфекләре керпе энәләре

кебек тырпайды.—Алайса, барыгыз, шуыгыз моннан! Шуыгыз!—Ул кулларын активистларга селтәде.

—Йә, ярый, ярый,—диде Зәйнагов, килешеп.—Синенчә булсын!—Ул, иптәшләренә таба борылды да, аларга Арьяк урамына барырга кушты. Капка төбендә олаучы гына калды. Башкалар икенче олауга утырып кушкан җиргә китеп бардылар.

Кирам бу ике активистны лапаска алып керде. Эчтә формасыз таштан эшләнгән мал сарае бар иде. "Бозау шунда",—диде Кирам. Зәйнагов карады, зур гына бозау ята. Кешеләр күренгәч торды. Зәйнагов бозауның мунчагын улак башыннан чишә башлады. Ләкин һич чишә алмый мәшәләнде. Бар, син дә булыш, диде Кирам Акчуаковага. Ул шатлыгыннан елмая-елмая эчкә кереп китте. Чөнки бозау бик асат кулга керә бит болай булса... Шулай уйларга гына өлгерде, Кирам, чыгып, ишекне тышкы яктан бикләп тә куйды. Болар кечкенә тәнлек-тәрәзәдән төшкән эңгер-меңгер караңгылыкта калдылар. Зәйнагов бик тиз аңына килде:

—Кирам, шаярма,—дип кычкырды.—Кулың эшләгән эшкә башың белән җавап бирерсең, Кирам! Кирам!

Ләкин Кирамның мотоцикл тавышы гына ишетелеп калды.

Олаучы капка төбендә бозауны алып чыгалар дип көтә иде. Бик озаклагач, шиккә калды. Кирам, киткәндә, капканы әллә ничек хәйләле итеп бикләп мәшәләнгән иде. Нәрсәдерматаштырган мәллә, йөзе кара! Эчкә үтешле түгел, биек койма койган... Олаучы тагы байтак вакыт көтте. Аннары нидер этлек сизенгәндәй булды. Атын борып, юырттырып идарәгә килде. Вил Садриевич анда иде. Хәлне аңлатып бирде. Ул арада Арьякта эшне тәгәлләп Ирек, Бортасов, Рәмисә дә кайтып керделәр. Кирамнарда ни булганын әйткәч, бик хәтәр ачулары кабарды.

Ирек белән Бортасов пекарнядан Кирамның хатынын алдылар да өйгә чаптылар. Хатын зар елады: "Эчә, талаша, үзе бер тиен өчен чукыныр. Ичмаса унбиш суткага утыртсыннар, бераз акыл кермәсме",—ди-ди шыңшый иде.

Капканы бакча аша ишегалдына төшеп ачтылар. Лапас эчендәге сарайдан тавышлар ишетелде. Башта Зәйнагов атылып чыкты. Эшләпәсен күзенә төшергән, кыяфәте карарга куркыныч, ачуы ташып йөзенә җәелгән, хәзер үк кемнедер өзгәләп ташлар шикелле иде... Бер сүз дәшми, тешләрен шыкырдатып кыскан килеш, тиз-тиз атлап капкага китте. Акчуакованың мөлаем йөзендә гаепле елмаюга тартым төсмер. Артык борчылу сизелми кебек.

Иң мөһиме: бозауны алып чыгып олауга салдылар.

Идарәдә Зәйнагов рәис кабинетына узды. Ишекне бикләп сөйләштеләр. Вил шунда туры прокурорга чылтыратты. Рәиснең сүзе закон, тикшерелми.

Сәгать ярым вакыт үтте микән, Кирамны алган "Черный ворон" машинасы урам буйлап асфальт юлга чыгып бара иде.

Ләкин тамаша моның белән генә бетмәде. Зәйнаговның мәктәптә эшләре күп иде. Кәефе бик нык кырылган, эшләрнең кайсын болай, тегеләй түнтәреп, өйгә соңрак кайтты. Ләкин хатыны Дәрига барча пәриләре белән котырып каршылады. Бар әнә мәткәң янына. Ике-өч сәгать сарайда бикләнеп яткансыз, ди-ди, ут-ялкын чәчә иде... Зәйнагов, аптырап, катты да калды. Кем, кай арада житкереп өлгергән? Ну, бу халыкны, Менә аның өчен тир түгеп, нервы бетереп йөре!.. Акчуакованың итәгенә салам ябышкан, синең тез башларың әнә... Дәрига шул сүзләрне чәрелдәгәндә Зәйнагов ишектән чыгып бара иде. Хатын бик ярсыган, ни әйткәнен, ни кыланганын белми. Аңа суынырга ирек бирергә кирәк... Зәйнагов мәктәптә үз кабинетында кунды. Икенче көнне дә Дәрига ирен бусагадан сөрде. Зәйнагов икенче төнне дә шунда үткәрде. Дәриганың бер туганын "парламентер" итеп җибәрде. Ләкин нәтиҗә булмады. Дәриганың җене тагы да ныграк котырган. Зәйнагов тагы берничә ышанычлы димче җибәреп карады. Хатын аларны әче теле белән "типкәләп" дигәндәй озаткан. Бер көнче-явыз хатын ун шайтанга тора дип белми әйтмәгәннәр...

Аларны Вил Садриевич үзе килеп кенә килештереп китә алды...

Ин соңгы гектарларга карабодай чәчелде. Бу ерак почмактагы ташландык булып яткан көлсу туфраклы җир иде. Быел чәчү мәйданнарын арттыру турында Үзәк комитет карары чыкты. Әмма җир мәйданын ничек киңәйтергә мөмкин? Җир резина түгел, киңәйми, берни үсми торган вак ташлы берничә карыш җиргә ашлама кертеп, талымсыз иген сорты чәчәргә туры килә. Болыны булган авыллар печәнлекләрен бозып чәчтеләр. Бу инде итәкне кисеп җиңне ялгау. Чөнки болын печәне үзе икмәккә торырлык лабаса.

Чәчүне тәмамлау уңаеннан, механизаторлар башлыгы Шаяз Шамкин кичкенә мәҗлес оештырып, тузаннарны кагып алырга исәпләгән иде. Идарәдә шул хакта сүз кузгаткач, юк, диделәр. Болай да хатыннар, ирләрне эчертәсез, дип, күзне ачырмыйлар. Әмма шул эшкә завхоз Ирек алынгач, эшләр җайланды. Ирекнең абруе зур. Чөнки эшкә бик уңган, карусыз. Идарәгә иң иртә килә, өлкәннәр күренгәнчә күп эшләрне хәл итеп куя. Бу минем эш, теге—аныкы дип тормый. Барсына да өлгерә. Өлкәннәр янып йөри алмыйлар. Үзләренең эше эшләнеп куюга үтә канәгатьләр. Шуңа Ирекнең ниятенә каршы килергә көчләре җитми. Шуның өстенә Ирек ниндидер хөрлек белән дә файдалана кебек. Кыскасы, механизаторларга кыр станы өендә табын әзерләнде. Нигъмәтләр шәһәрчә иде. Берничә савытка салат-винегрет салынган, сыр туралган. Аннары итле токмач—калҗалы шулпа чыгачак. Ирек өстәлгә шешәләр тезде. "Ак юк, егетләр, портвейн гына",—диде. Егетләрнең кашлары җыерылды. Ирек шәбәеп: «Акчагызны басып кала торган түгел, бушка», дигәч, тиз үк язылды. "Безнең корсакка нәрсә дә бата",—диештеләр. Хатыннан йөз граммлык теләнү ише түгел, шунсы гына ни тора.

Бу кызыл эчемлекнең шунсы бар, ул тиз башка китә, минут эчендә канны кыздыра. Әмма куәте озакка бармый. Менә кырлы стакан белән берәрне эчеп куюга, берсе кызып:

—Их, дөньяда яшәве алай ук хөрти түгел икән!—дип әйтеп ташлады.

Егетләрнең йөзендәге җыерчыклар яктырды, күзләре елтыраша башлады. Кайсының борыны, кайсының колагы кызарды. Телләрнең төене чишелгәне сизелеп тора. "Аек чактагы уйларын, исергәч, телдән ычкыныр",— дип куйды кайсыдыр, кет-кет көлеп. Икенчесе:

—Шайтан үзе башкара алмаган эшкә аракыны җибәрер, ди. Аракы ача алмаган ишек юк, чыны да шул,—дип шукланды кайсыдыр. Варис әз генә эчте, башка китәр, Яшә алдында оятка кала күрмим, дип сагая иде. Яшәдәге хатынына, начар яктан күренеп, сөендерәсе килми, иде.

—Аракы браттан өстен була башлады, кая китә бу?—диде ул, табынга карап. Ләкин аны беркем дә тыңламый иде инде. Барысының да каны кайнарланган, теле бәйдән ычкынган. Шаулашалар, көлешәләр. Һәркем үзенекен сөйли. Бүтәннекен ишетми иде.

Вәзыйх белән Шаяз әз генә уртладылар да стаканнарын куйдылар. Ирек моны шәйләп, шаярулы-ачулы төстә төрттерде: "Нәрсә сез акыллы булып кыланасыз, ә? Эчмәү белән генә яхшы булган кеше пүчтәк ул",— диде. Боларның мин-минлегенә тиясе килә. Үзенең өстенлеген күрсәтергә тели. Вәзыйх белән Шаяз аның өстенлеген танырга теләмиләр. Шуңа Ирекнең бераз эче тырнала шикелле иде. Ул шактый кызып алган, Шаязга бәйләнә: "Менә мин синең механизаторларың өчен тырыштым, ә син мине хөрмәт итмичә аек көе утырасың. Вәзыйх, бу бит әйбәт түгел, ә?"

—Без сине хөрмәт итәбез, эчмәү але ул хөрмәт итмәү түгел,—диде, Вәзыйх елмая-елмая.

—Юк, хөрмәт итмәү!—дип, Ирек стаканнарга эчемлек салганда тышта җигүле ат килеп туктаганы ишетелде. Пешекче апа: "Әйдә, Кәли абзый, мактап йөрисең икән",—ди-ди, аны өйгә кыстады. Кунних Кәли икән. Ирәм буйлы, какча гәүдәле, аркасында калак сөякләре пиджагеннән беленеп

тора. Шаяз, торып, аны Вәзыйх янына утыртты. Стакан сузды. "Мин ашыга идем",—дигән булды Кәли кужулланып, агач тамыры кебек каралып сөялләнеп беткән кулына стаканны алып.—"Ярый, сыйлаганда су эч",—дип, бик тиз аударып куйды. Аңа тагы өстәде Вәзыйх. Кәли монысын да каплап куйды, сыр кисәге капты. Вәзыйх бу кешене җәлли иде. Бик карусыз, булсынга эшли. Бригадир Лотфуллин көн-төн айнымый, ә бу аның барча эшләрен башкара. Үзен яклап бер сүз әйтә алмый, чөнки әсирлектә булганлык гаебе бар... Кәлинең башына китте, күз аклары елтырады. Ул Вәзыйхка таба борылды.

—Иптәш Надыйров,—диде,—мин синең әтиеннең яшь чагын беләм...—Вәзыйх аптырап калды. Әтисе турында "байкалар" ишеткәләгәне бар иде...—Мин бит Әлмәт малае,—дип сөйләп китте Кәли.—Надыйров шунда комсомолда эшләде кебек. Без ШКМда укый идек. Дингә каршы көрәш бара иде. Бер җәйге караңгы төндә Надыйров безне иске, ташландык зиратка алып килде. Анда убыр йөри дип куркыталар иде. Әллә кайдан бер сәнәк салам зурлыгында саргылт утлы шар пәйда була да тәгәрәп йөри ди. Шуңа юлыккан кеше телсез кала, имеш. Менә зур гына саргылт ут шары әллә каян чыкты да безгә таба тәгәри башлады. Убыр! Без чигендек. Надыйров убырга таба китте. Үзе шырык-шырык көлә. Куркуын җиңү өчен көлә, дибез. Менә Надыйров ут шары эчендә калды. Бетте!—дип тынсыз булдык. Ә ул ут эчендә куллары белән бутала... Ут минут эчендә юк булды. Надыйров тагы шаркылдый. Дураклар, берни түгел ул дип аңлата, кеше сөягендәге фосфор астан чыгып кислород белән кушыла да шул яна, ди. Ну, әтиенә охшаганмы, ә?

—Рәхмәт, Кәли абзый, охшаган,—дип, Вәзыйх аңа тулы стакан тоттырды. Хисләнмәде, чөнки әтисен белми иде. Кәли тамак төерен селкетә-селкетә эчте дә кузгалды... Вәзыйх аны озата чыкты. Кәли себерке чыбыгы алырга килгән икән, шул арбасына утырды да китеп барды. "Әйе, безнең әти дә дуамалрак булган икән шул",—дип уйлады Вәзыйх.

Сүнгән учак янындагы бүрәнәгә урнашкан Шаяз белән Ирек нәрсә турындадыр бәхәсләшәләр иде. Шаяз кулын болгап сөйли:

—Нигә теге запчасть поршеньнарны алып кайтмады дип Вил Садриевичка әйттең? Мин белгертми тор дип үтендем. Ярар, дигән идең. Ә нишләдең? Бу иптәшеңне сату була түгелме?—Шаязның түгәрәк калынча битләрендә буй-буй алсулыклар. Ул дулкынланган, әмма кызмачалыгы юк иде.

—Мин эш интересы өчен әйттем,—диде Ирек, үзен хаклы, өстенлекле сизеп.

—Ә ул мине: әй, син пешмәгән кәлҗемә, дип сүкте. Миңа бик авыр булды.—Шаяз учы белән күкрәк турын ышкып торды.—Мин ул поршеньнарны бүтән төштән барыбер таптым...

—Сүкмәгән булса, таба алмас идең. Димәк: файдага? —Ирек ачу китергеч итеп, кет-кет көлгән булды.—Бер-беребезне төрткәләп тормасак, эш алга бармый ул.

—Минем эшне тукынасың. Миндә нинди ачуың бар?—Шаязның тавышы юаш чыкты.

—Нинди ачу! Мичтә янган кисәүләрне кисәү агачы белән суга-суга яндыралар. Эш тизрәк барсын өчен бит! Ә син шуны авырга аласың?

—Беләсең бит, мин бурычымны үтәми калмыйм. Мин бурыч кешесе!—Шаязның тавышында рәнҗү ишетелде.

—Без янмый торган кисәүләр түгел, Ирек!—Вәзыйх сүзгә кушылды. Аның Шаязны яклыйсы килә. Иреккә үзенең дә дәгъвалары бар. Ул аның эшенә дә борын тыга һәм еш кына кырын китергәли иде. Вәзыйх сүзгә кушылгач, Шаяз кыюланып киткәндәй булды. Дәгъваларын бер-бер артлы тезә башлады.—Берничә тузган сеялканы списать итеп, санны ким күрсәтеп, яналарны сорарга дип уйланылган иде. Ә син, район комиссиясенә ялагайланып, яшергәнне күрсәтеп, эшне тизәкләдең! Тагы миңа җавап бирергә туры килде?—Шаяз аңа кинаяле итеп карап алды.

—Синең ниятеңне мин белмәдем. Ник алдан әйтмәдең?—Ирек күзен дә

йоммый, үзен һәр төштә хаклы саный иде.
—Белгертсәм дә, серне чишәр иден?
—Район түрәләре алдында синен хисапка үзенә очко эшләгән ул?—Вәзыйх сүзен ышанычлы, кырыс итеп әйтте. Ирекнен чыраендагы уенчаклык чалымнары кинәт бетте, янаклары сорыланды, кашлары жыерылып, мангай өстенә өелеп торды.
—Карасана, нинди барышнялар, бер сүз әйтергә ярамый,—диде ул эчке зәһәрлек белән.—Серкәләре су күтәрми?
—Син колхозда жаваплы кеше,—диде Вәзыйх, тавышын ачуланышмау жаена көйләп.—Шулай икән, өйдәге чүпне тышка чыгармаска тиеш! Әллә син генә колхозны кайгыртучымы?
—Юк, мин алай димим...—Ирекнен тавышы килешүчән, бирешә барган шикелле иде.
—Чәчү вакытында, вакытны сузар өчен мин лавировать иттем: чәчәбез, ләкин трактор ватылды әле, дип сводка бирдем. Чөнки овсюг тишелергә өч-дүрт көн кирәк иде. Тишелгәч, тырмалыйсын, аннары гына чәчәргә...—Вәзыйх, тартмый торган кеше, папирос алып кабызды. Эчендәге ачуын, рәнжүен басарга теләгән шикелле иде.—Ә син Иван Мөхәммәтовичка; юк, чәчми ул!—дип әләкләгәнсен. Нәтижә нәрсә: Иван Мөхәммәтович атылып килеп житте дә чәчтерә башлады. Әнә тиешле процедура уздырылмыйча чәчелгән жирне барып кара, тоташ овсюг кына! Менә синен түрәләргә ярарга тырышуынньн нәтижәсе!
—Мин Иван Мөхәммәтовичка берни дә әйтмәдем, Вәзыйх, чын менә! Жанына гөнаһ алма!—Ирек берни булмагандай барсын да кире кагып ташлады. Вәзыйхнын шаһитлары бар иде. Ирекка тамчы да ышанмады. Кулын селкеп, башын икенче якка борды.
—Ирек, син боларны үзен эшлисенме, әллә берәрсе кушамы?—Шаяз йомшак кына итеп әйткән иде, Ирекнен йөзе икенчеләнде, күзләре зур булып ачылып торды. Кеше икейөзләнергә күпме өйрәнсә дә, кай минутта югалып кала икән. Ләкин шунда ук үзен кулга алды.
—Кем кушсын, што сез, әллә мине тегеләй... Мин эшебез әйбәт барсын өчен генә! Үзегез дә күреп торасыз ич!—Ирек авызын ерып елмайды, гөнаһсызга рәнжетелгән кыяфәткә керде.
—Син мине килмешәк дип чит күрәсендер инде,—диде Вәзыйх, шулай ук рәнжешле төстә.—Беләм, бүтәннәрнен чит сөяк итүен тән тиресе белән тоеп йөрим.
—Юк, Вәзыйх,—диде Шаяз ныклы итеп.—Сине якын итәләр, яраталар. Син бу мәсьәләдә хаклы түгел!
—Ярар, килешәм,—диде Вәзыйх, кинәт үзгәргәндәй булды.—Нигә эчтәге рәнжешләрне чыгарабыз әле? Калсын, бетсен, шулай бит!?
—Берни эшләмәгәннәр генә кычкырышмый анысы,—диде Ирек, һаман үзенен позициясен бирәсе килмичә.—Менә әйткәләштек, анлаштык, күнелгә әйбәт булып китте, ә, Шаяз?
—Син, Ирек, властьны безгә арттырып кулланма!—дип Шаяз, тагы кирегә сукалаган кебек итте.
Ирек тиз генә бер шешә белән стаканнар алып чыкты. "Әйдә, мировойга салабыз!"—ди-ди өтәләнде. Егетләрне юмаларга, мактарга кереште.
Шаяз мин моторда, дип баш тартты. Вәзыйх сәбәбен әйтмичә генә кулы белән кире тибәреп: Юк, юк, диде. Ирек стакан, шешәләре белән өйгә кереп китте. Аларнын Ирек белән якынаерга күнелләре тартмый иде. Моны ачык билгертергә ярамый. Ирек аларга барыбер этлекләр эшләячәк. Күп сынап белгән хәлдә, бу кеше белән якын бәйләнешкә керү куркыта иде. Ирек дус булган булып тар тупикка китереп кыстыра да, үзе котыла, сине шунда калдыра... Анардан читтәрәк йөрү хәерле...
Шаяз кайтырга мотоциклын кабыза башлады. Вәзыйх та ана утыру исәбе белән әйберләрен алырга өйгә керде. Варис белән Яшә хатыннары белән мактанышалар иде. Аларнын хатыннары алмашынган. Һәрберсе хәзерге хатынын купайтып күрсәтә.

—Минем хатын назга бик бай, һәрчак яңа!—Варис баш бармагын тырпайтып күрсәтә, Яшәне үкендермәкче буламы инде.

—Юк, наз ягыннан минем хатынга житми,—ди Яшә авыз суларын китерерлек итеп.—Һәрвакыт свежий, жиләк инде, жиләк!

—Назы булмаган хатын белән ирләр ничек тора икән, ә?

—Назы юк салкын хатын белән яшәү—жәза инде ул, зиндан белән бер...

—Әй, кырчыннар,—дип сүзгә кушыла апа.—Наз дигән буласыз, исерек башлар! Көне буе эшләгән хатында нинди наз булсын! Хатыннарны эшләтмәгез, шул чак назга тиенерсез! Шиңгән кишерләр!

Аны тынлаучылар көлештеләр. Ирек тагы Даянны һәм яшь механизаторларны сыйлый иде. Карасана, дип уйлады Вәзыйх, колхозчының тормышы житеш була башладымы, әнә байларча наз турында фикер йөртәләр.

Вәзыйх, тиз-тиз чыгып, мотоциклның артына атланды. Шаяз әле генә булып узган Ирек белән чәкәләшеп алу турында уйлап кайта. Ирекне ул күптән белә. Хулиган иде. Мәктәптә укыганда кибеттән сәгать урлап тотылды. Аны ФЗӨгә жибәрделәр. Шуннан—армиягә. Әллә жайлы урынга эләккән, армиядә дәрәжәсе күтәрелә башлады. Баткан жирдән калкып чыккандай булды. Әти-әнисенә командованиедән бер-бер артлы герблы кәгазьгә баскан "благодарность"лар килеп торды. Ике рәхмәт колхоз исеменә дә килде. Нииндидер генерал имзалаган, диделәр. Кайту белән Ирекне иң авыр участокка—фермага фуражир итеп куйдылар. Ә фураж янында урлау, сату, эчү һәм сатылу бик хәтәр иде. Урлаучыны тотар хәл юк—"круговая порука". Ирек шунда үткен булуын күрсәтә. Караклык "чылбырларын" өзгәли. Бу эшкә милицияне дә катнаштыра. Бер-ике атаманның коерыгына басалар. Урлау бетә, Ирекнең булдыклылыгын танымый мөмкин түгел... "Хезмәт батырлыгы" медаленә лаек булуы да бик хаклы...

Ә бит менә Вәзыйх та ихлас күңел белән бирелеп эшли. Ул килгәч, агролаборатория йорты төзеде. Иген кырларының туфрак картасын эшләде. Әмма бүләкләүләр исемлегенең берсенә дә аны кертмәделәр... Астан гына ишетелде: аның фамилиясен районда сызалар, имеш... Мине инде әйткән дә юк...

Авыл башына житкәч, Шаяз матаен туктатты да Вәзыйхны төшерде. Үзе Әлмәткә элдерде. Әйе, миңа гаиләмә, Әлмәткә күчәргә кирәк, дип, Шаяз уйлануын дәвам итте. Болай аеры-чаеры яшәп жан тыныч түгел. Ни өчендер Лениза күчүгә салкын мөнәсәбәттә. Элек кайчан күчәсең, дип тыкырдата иде. Хәзер кинәт кенә кирегә борылды. Язмышны ашыктырырга ярамый, диде. Ни ята бу канун артында? Ул үзенең элемтәләрен эшкә жиксә, Тельман абыйсын шуңа тартса, мине бер матавыксыз күчерерләр иде. Юк, бер дә борчылмыйлар. Нәрсәдер итәктән тота шикелле. Шаяз һаман әйтә: "Сиңа ялгыз гына салкын түшәктә яту күңелсез түгелмени?" "Юк,—ди Лениза, нурлы елмаеп,—мин ялгыз түгел, әнә малаемны кара, ияге, борыны, маңгае нәкъ синеке!.." "Мин жан ялгызлыгы турында әйтәм",—ди Шаяз. "Жаным синең белән тулы, башкага анда урын юк. Аңлыйм, синең күңелеңне кайчак шик кимерә. Мине бер алдадылар. Шуңа һәр ир-атка жирәнү белән карыйм. Син үлемнән коткармасаң, белмим, мин нишләр идем! Неужели мине сиңа хыянәт иттерә алырлар?"—Ленизаның аксыл кабартма битләрендә матур алсулыклар бии иде... "Булмас димә, дөнья бу",—дип куйды Шаяз, уенын-чынын бергә кушып. "Өч-дүрт көн саен очрашабыз,—диде Лениза, үзенекен каерып,—бик житкән, берберебезнән туймас өчен әйбәт. Әнә кемнәрдер көн саен кушылып бер-берсен күрәлмәү хәленә житәләр"...

Шулай да Шаяз күңелендә дәгъвалы хисләр кузгала. Моңарчы ул хәлләргә, кешеләргә буйсынып кына көн күрде. Хәзер исә хезмәтен бәялиләр, үзенең дә абруе үскәннән-үсә бара. Башны күтәребрәк йөрергә дә вакыттыр. Әтисе гаебе белән аңа төшкән авырлыклар бөтенләй бетмәсә дә, инде нык кимеде. Ул аны сизми дә. Идарәдә аның белән санлашалар...

Шул жайларның барсына нисбәтән рәвештә горурлыгы, мин-минлеге баш калкыта. Мин беркемнән дә ким түгел... Ул үпкәсе шешеп больницада ятканда мәскәүле бер профессор белән бүлмәдәш булган иде. Ул Шаязга күп нәрсәләр аңлатты. Адәм баласының мин-минлеге, горурлыгы булмаса, ул кеше түгел. Ул бары кол гына. Ул һәр хәлгә, нәрсәгә буйсына гына белә. Ул, шәхес буларак, үзе юк, башкалар ихтыяры белән генә яши. Алар кушканны гына башкара.

Профессор инглиз китапларын күп укый иде. Ир һәм хатын мөнәсәбәтләре турында да байтак сүз куертты. Рухи ярату, ягъни акыл белән ярату бар һәм тән белән ярату бар. Ирләр күбрәк тән белән яраталар. Иң хәтәр, көчле ярату шул. Аны акыл көче белән җиңеп булмый. Тән үзенекен итә. Ә хатыннар рухи ярату белән көчлеләр. Хатын сине тәне белән яратса, ул тәгәл синеке. Үземнеке дип ышана аласың. Әгәр тәне белән яратмаса, ул әле синеке түгел. Бүтән берәүнең анарда тән яратуы уятуы мөмкин...

Шайтан алгыры, дип Шаязның уйлары дәвам итте. Ниндидер бәйрәмдә Шаязларда мәҗлестә утырганда Рәмисәнең башына китте һәм ул кисәк кенә әйтеп ташлады: Вәзыйх, син мине үзеңнеке итә алганың юк әле,— диде. Вәзыйхның сәрхүшлеге шактый иде, ул башын як-якка чайкап елмаеп кына куйды. Лениза мәгънәле күзләре белән Шаязга карады. Шаяз ул чакта аны-моны аңлап бетмәде. Аңа барсы да соңрак барып җитә... Әйе, менә хәзер үзенең хәле җанын борчый: Лениза аны тәне белән түгел, акылы, рухы белән генә ярата шикелле. Мона мин гаеплеме? Теге мәҗлестә Рәмисә Вәзыйхны гаепләгән кебек әйткән иде. Аларның гаилә хәлләрендә һаман аңлашылмаулар, үпкәләшүләр булып тора. Сәбәбен ачык кына әйтмиләр. Ә бездә әле шөкер, алдагысын белеп булмый. Әллә мин Ленизаны үземнеке итә алмаганга үзе янына кучүне сузамы? Әгәр ул беткәнче минеке булса, минем сүз белән саңлашыр, минем теләк аңа әмер кебек булыр иде. Юк бит! Лениза миңа, шактый тыенкы хисләрне дә ашыктырырга ярамый, безнең алда озын гомер, ди... Мин Ленизаны тән белән дә, аң белән дә яратам кебек. Бала өчен дә яратам, димәк...

Шаяз барып җитеп, тимер гаражга мотоциклын урнаштыра башлады. Юк, бүген күчү турында Лениза белән ныклап сөйләшәм. Нигә мин гидай шикелле алак-шалак йөрергә тиеш? Мин монда чакта авылда бер-бер күңелсезлек эшләп куйган булалар. Гаиләдән алган шатлыгыма салкын су сибәләр.

Ул гараж ишеген ябып маташа иде, кинәт аның алдында эшләпәдән-плащтан киенгән ике адәм пәйда булды. Берсе озын, берсе шактый тәбәнәк. Икесе дә серле елмаялар. Озыны, куен кесәсеннән чыгарып, кызыл кенәгә күрсәтте. Аны ачып Шаязның борынына китереп тераде. Янәсе, фамилияне укы, Шаяз каушаган иде, берни аера алмады, күз алды әлҗе-мөлҗе килеп алды. Ул бу адәмнәрнең кайсы ведомстводан икәнлекләрен шәйләде. Йөрәге дөп-дөп күкрәк читлеген сукканын тойды. Нинди гаебем бар икән, дигән уй җанын кимерә иде. Баш миендә ниндидер "счетчик" гаеп саналырдай эшләрен җиз иләктән үткәрә... Шаяз гараж ишеген калтыранган куллары белән бикләде дә йөзе белән тегеләргә борылды.

—Шамкин, без сине беләбез, син честный кеше,—диде Озын, ягымлы эшлекле тавыш белән, килешле йөзе берни дә белгерми иде.—Син безгә ярдәм итәргә тиеш.

Бу сүзләр Шаязның колагыннан баш миенә менделәр, эшкәртелә башладылар. Нинди ярдәм? Әһә, әһә, болай булгач, минем гаеп юк икән, дип нәтиҗә чыгарды баш. Ничек, ни белән шул тикле кодрәтле оешмага булыша алам? Юк, болар нәрсәдер шантажлыйлар түгелме? Нәрсә дип җавап бирергә? Уйлар тәмам буталып бетте. Җеп очы чуалды...

—Ничек ярдәм итә алыйм мин?—Шаязның тавышы мыгырданып чыкты. Ул каушавын җиңеп, элеккеге хәленә кайтырга кирәклеген тоя. Үзенең бу халәтеннән оялып кызара иде... Ә Озын сөйли, аңлата. Ул Шаязның беләгеннән тотып сөйли-сөйли алга атлады. Алда өчәүләп йортлар

арасыннан урамга чыктылар. Бик эшлекле өчәү әңгәмә корып баралар шикелле иде.

—Безнең белән хезмәттәшлек итү һәр гражданинның иҗтимагый бурычы!—диде Озын.—Аңлашыла торгандыр?

—Колхозда көн-төн эшләү иҗтимагый түгелмени?—Шаязның башы шундый фикер эшләп чыгарды. Шул сүзләр теленнән ычкынгач, Шаяз үзе сискәнеп китте. Болай әйтергә ярый микән соң? Ул Озынның соргылт йөзенә күз төшереп алды. Ниндидер ышанычсызлык, борчылу сизелә. Тәбәнәгенең дә чыраенда каушауга тартым нәрсә бар кебек...

—Ул башка хәл,—диде юан тавышлы Тәбәнәк.—Син ватанны, совет властен яратасыңмы? Әллә юкмы?

—Моңа кире җавап була алмый инде.—Шаяз үз сүзләрен колагы ишеткәч кенә нәрсә әйткәнен абайлады. Юк, болай башы бик начар эшләми шикелле. Мәгънәгә ялгана.

—Шулай булгач, син ватанга һәртөрле булышлык итәргә бурычлы?—дип, Тәбәнәк, Шаязны кыса бара.—Бурычлымы, юкмы?

—Бурычлы, бурычлы,—диде Шаяз, теләмичәрәк. Әчтән аңа уе әйтә: боларның һәр тәкъдимен килешмәсәң дә җөпләп торырга кирәк, ди.

—Безнең белән хезмәттәшлек итсәң, барча эшләрең уңышлы барачак!—диде Озын, хәерхаһ тавыш белән.—Дәрәҗәгә дә тиз ирешәчәксең!

—Ә минем данныйларым рядовойлык кына!—Шаяз каушавын җиңә бара шикелле иде. Шулай да тавышында шуклык сизелде.

—Анысы мөһим түгел,—диде Тәбәнәк, мичкәдән чыккан тавыш белән горгылдап.—Постка җигелгәч, тартасың аны... Ул да Шаяз интересын кайгырткан төстә сөйли иде. Шаяз ни әйтергә белми барды. Алар, шәһәрнең Техник йорты янынннан үтеп, мәйданны аркылы чыктылар һәм иске Әлмәткә аска таба атладылар. Монда әле агач йортлар сүтелмәгән, барысы да элеккечә иде. Биек рәшәткә белән коймаланган бүрәнә йорт янында туктадылар. Тәбәнәк шунда калитка келәсен чыртлатып ачты. Әчкә уздылар. Сүзсез генә өйгә керделәр. Әскәтерсез кәҗүнни өстәл, кара калай белән тышланган галан мич. Тар гына ике тәрәзә. Өстәлнең як-ягындагы урындыкларга урнаштылар.

—Йә, хезмәттәшлек итәргә телисеңме, ә?—Озын һаман Шаязны кайгыртып сөйли төсле,—Без мәҗбүр итмибез. Үз мәнфәгатеңне кара.

—Аңламыйм, мин нишләргә тиеш соң?—Шаязның сүзләре гаҗиз-гозерле чыкты.

—Ризамы, юкмы, шуны әйт?—Тәбәнәк горгылдады. Сүз әйткәндә аның ияк асты казныкы кебек кабара иде.

—Белмичә, ничек әйтим. Сез мине, бәлки, җинаять эшенә этәрәсездер,—диде Шаяз, бик җитди итеп.—Авыз пешкәне бар...

Тегеләр, бер-берсенә карашып, нәрсәдер аңлашалар иде. Берничә минут шулай торганнан соң, Озын сөйләп китте:

—Эш болай,—диде,—Надыйров синең дустың. Менә аны зур постка күтәрмәкче булалар. Ләкин аның карашлары нинди, эчендә ниләр йөртә, шул хакта мәгълүматлар кирәк. Аңлашыламы? Менә син бу мәсьәләдә безгә, икенче төрле әйткәндә, Ватанга ярдәм итә аласың?

—Нинди мәгълүмат сорала соң?

—Надыйровның хәзерге сәясәткә, тормышка карашы ничек? Политбюро әгъзаларына мөнәсәбәте? Русларга ничек карый?—Озынның төсе тәмам әллә кайчангы иптәшләрчә иде. Болар йомшак җәеп катыга утыртырга остарып беткәннәр икән, дип эчке уе аваз салды Шаязның. Нишләргә? Ничек котылырга бу имансызлардан? Юк, котылып, булмаячак! Соң ни әмәл кылырга? Тәбегә эләккән тычкан булдым чистый. Шайкада да башта кечкенә генә эшләр йөкләтиләр, ди. Аннары катлаулы эшкә тарталар. Шуның белән артың пычрангач, гаебең койрык булып тагылгач, теләсә нинди әшәке эшләргә кушалар. Бер пычрангач, үтәми кала алмыйсың. Үтәмәсәң, каты җәза бирелә... Нишләп инде Надыйровның карашлары аларга билгеле булмасын? Аның үзенә генә аерым карашы булуы мөмкинмени? Без

барыбыз да бердәй уй йөртүче, эш, хезмәт белән мәшгуль кешеләр.
—Надыйровнның аерым карашын тойганым юк,—диде Шаяз, бик тыныч һәм эшлекле рәвештә.
—Юк, син ул әйткән җөмләләрне истә калдырып, безгә житкер!—Тәбәнәкнең тамак асты куык булып кабарып куйды.
—Бигайбә, анысы миннән булмый!
—Ни өчен?
—Үзең белән бергә эшли торган иптәшеңне сату була түгелме соң?—Шаязның тавышында әчке нервылану сизелде.
—Юк, ана ярдәм итү була!—Озынның йөзенә катгыйлык чыкты. Өстәл аша Шаязга таба башын сузды:—Димәк, дустына ярдәм итәргә теләмисең?
Аның сүзләреннән Шаяз үзен кысуларын ныграк тойды. Әйбәт сүзләрне начар эшләр эшләтүгә ничек җигәләр, ә? Кешене артында әләкләү дә, ул аның өчен ярдәм була, имеш? Надыйровны җинаятьче итеп күрәләр шикелле? Әтисе кайчандыр әйткән сүз кылт итеп хәтеренә килде: сәяси шикле профессор бер хәчтеруш уголовниктан түбән санала...
Тынлык озакка китте, ә Шаяз куелган сорауга җавап таба алмый изаланды. Тирәнгә китеп буталырмын, дигән үз-үзен саклау инстинкты аны тота иде. Ул башын аска игән килеш, бу эшне күтәрә алмавын йөзенә чыгарып, тынып калды.
—Хәзергә житеп торыр,—дип, Озын урыныннан торды һәм Шаязга китәргә мөмкин дигән ым ясады. Шаяз авыр гына урыныннан кузгалды, саубуллашып башын какты һәм тизрәк ишеккә омтылды.
Урамга чыккач, уф, уф, ди-ди озын-озын сулады. Тегендә тыны кысылган булган икән. Тәмам өнне алдылар юньсезләр! Яхшыга омтылган теләкләргә балта чаптылар. Гаилә белән очрашу өчен тупланган шатлыкны бетерделәр. Ниятләрне, ихлас планнарны юкка чыгардылар. Хәзер нинди йөз белән өйгә кайтып керергә. Минем эчемдәге йөземә чыга. Лениза кыяфәтемнән нәрсәдер сизенер һәм отчет сорый башлар. Шаязның иң яратмаганы—отчет бирү. Чөнки бер дә шыттыра белми. Ничек булган—шулай гына... Чырайны ничек бер хәвефсез очрашу шатлыгына тутырырга? Нормаль хәлгә кайтканчы урамда йөрергәме?.. Шаяз башын күтәреп офыкка күз төшерде. Кояш таулар артына киткән икән инде. Буйдан буйга сыек кан алсулыгындагы озын пәрдә элеп куелган шикелле иде.
Шаяз, кыяфәтен, йөзен-битен нурлы, ягымлы итәргә көйләп, урамда йөрде. Үзен тәмам көйләнгән дип уйлагач кына, өйгә керде. Ясалма елмайды, ясалма шатлану чаткыларын йөзенә чыгарды. Лениза да шатланды, анымоны хәстәрләп, тыз-быз чапты. Шаяз чишенеп, юынып баланы кочагына алды. Аны күтәреп бүлмәдән бүлмәгә йөрде. Баладан кояшта җәйрәгән алма үләнле чирәм исе килә иде. Җанга нинди якын ул, аннан да кадерле берни дә юк!
Әби өчпочмаклар пешергән икән. (Бу төбәктә аны тәкә дип атыйлар. Формасы да бүтәнчәрәк.) Ашагач-эчкәч, әби өчпочмаклар һәм баланы алып, күрше йорттагы ялгыз кызына кереп китте. Шаяз шукланган, көлгән булды. Эчен таракан кырып торуын сиздермәскә тырышты.
Башка вакытта урынга ятуга Шаяз хатынының ак челтәр зинарын ботларыннан шудырып төшерә иде дә, уттай кайнар кочак эченә тизрәк чума иде. Менә хатын күнегеп беткән. Иренең шул хәрәкәтеннән Лениза күп нәрсәләр искәрә: димәк, мине сагынган, мина тугрылыклы булган, "ужым"га кермәгән. Шуннан җаны тынычлана. Яратудан күңеленә килә башлаган шикләр томандай таралып бетә. Үзе дә иренең хисләрен канәгатьләндерү өчен тойгыларны юмарт бирә.
Ләкин бүген алай булмады. Лениза көтеп ятса да, Шаяз теге хәрәкәтне ясамады. Үзе болай кочаклады, кысты, иркәләде. Ләкин шуннан узмады. Нигәдер авыр-авыр сулыш алып, борсаланды. Бу хәлен аңлатты: "Бер ертлач механизатор белән якага-яка килдек,—диде.—Шул эт адәм барча кәефемне җимерде. Түбәнсетә торган сүзләр әйтте. Баш механик урынына тәмгысын сузып яши икән. Әйдә, булсын, мина ни..."

Ул икенче якка борылып ятты. Байтак вакыт йокылы-уяулы ятканнан соң, ул нindидер эчке дулкын кагуыннан уянып китте. Башы сафланган, тән арулары беткән, нindидер җинеллек кергән. Чуалган уйлары да бер киләпкә сарылган шикелле иде. Кичә булган хәлләр исенә килде. Шул мәлдә хәтерендә гүя лампочка кабынды, яктырып китте. Тукта, теге адәмнәрне күргәне бар бит? Әйе, әйе, төгәл күргәне бар. Хәтере ялгышмый... Теләсә нindи дефицит запчасть "кара базар"да бар, билгеле, алтын бәясе. Бүтән җирдән һич табар хәл юк. Нишләргә? Кытлык хәйләгә этәрә. Шаяз да шулай итте. Ленизаның "дәһшәтле власть" документы бар. Ә склад мөдире ул властьтан бик шүрли иде. Шаяз белән Лениза шул "дәһшәтле" кенәгәне склад мөдиренең күзенә терәделәр. Теге коелып төште. Арткы ишеккә алып чыкты да бик дефицит запчастьларны алып бирде. Ян ишек шыгырдаганга Шаяз борылып карады, анда шушы ике бәндә ярыктан гына күзләрен тасрайтып күзәтәләр иде. Шаяз карашыннан кинәт башларын эчкә яшерделәр. Бер тапкыр шулай булды, ике, өч тапкыр... Шаяз сизде: ул тегеләрнең икмәген каерып ала икән. Чөнки Озын белән Тәбәнәк "кара базар" әһелләре. Төп кәсепләре дефицит запчасть. Бу хәлне ничек үчсез үткәрергә мөмкин. "Кара базар". Аларның тормыш чыганагы. Чыганак өчен адәмнәр кан коешалар. Ә болар әнә нindи үтемле чара тапканнар! Мин беркатлы ахмак, ничек башта ук берни чамалый алмадым. Алар бит бик ышанычсыз сөйләшәләр иде. Сөйләү тоныннан нәрсәдер сизәргә булгандыр. Һаман да шул курку, шайтан алгыры!

Алар кабат очрасалар нишләргә? Юк, сүз кушарга ярамый. Танымамышка, белмәмешкә салынырга... Гаҗәп, орган кешеләре булган булып, ничек эз яшерәләр, ә? Һич уйламассың. Әйтәм җирле бик шым гына кыланалар... Болар бик тирән оялаган шайка булырга тиеш. Әгәр бер-бер хәл килеп чыкса, орган кешеләренә сылтарга нindи шома ысул. Ай-һай-һай! Адәм баласы эшләмичә яшәр өчен ниләр генә кыланмый. Исенакылың китәр! Кем белгән, бәлки алар чыннан да "өч хәреф"тә хезмәттәдер. Андыйлар нindи генә һөнәр ияләре арасында буталып йөрми хәзер...

## 15

Вәзыйх, Шаяздан төшеп калгач, ындыр артлап кына Нурмый картка сугылырга булды. Кыштан ук ул аңа тарантас эшләргә заказ биргән иде. Авылда, кырда җигеп йөрергә. Материалларын: тугымнарын, бүкәнлекләрен кайсын кайдан юнәтеп китергән иде. Ләкин карт еш сырхаулау сәбәпле эш озакка сузылды. Бик кирәк чакта җигеп чыгарга тарантас юк.

Нурмый карт үзенә бер төрле зат. Туры сүзле, эчендәге—тышында. Салып алса, кешенең артында гына әйтелә торган нәрсәләрне йөзенә чәпи дә куя. Шуна күрә аны өнәмиләр. Вил Садриевич та аның фамилиясе турына зәңгәр "птичка" куя. Күрсә, йөзе җыерыла. Берәр дөрес сүз ишеттергән, ахрысы? Әллә сәбәп Нурмыйның биографиясендәме? Ул Микулин дигән рус боярында ялчы булып эшләгән. Рус мәктәбендә укыган. 1914 елгы дөнья сугышында ике тапкыр "Георгиевский крест"ка лаек булган. Шуның өчен совет чорында аны читләткәннәр. Грамоталы булгач, баштагы чорда авыл советында эшләгән. Ләкин холкы белән анда да ярамаган. Ул ялганны бер дә күтәрә алмый, икейөзле-монафыйк була белми. Шул сәбәпле төшеп калган. Салгаларга яратуы да комачау иткәндер, билгеле. Властьларга ялагайлана белми, аларның гаделсез эшләрен күрә һәм тиешсез җирдә тәнкыйть сүзләре дә ычкындыра. Чит элемент итү өчен шул да җитә. Гаиләсенең тар-мар килүе дә очраклы булмаса кирәк.

Нурмый уйсыз кеше түгел. Идарәгә килә торган "Известия" газетасын алып укыштыра. Вәзыйх белән сөйләшеп утырганда Столыпин турында да белмәгән нәрсәләр әйтте. Тарихта бу шәхес иң әшәке реакционер итеп күрсәтелә. Юк, хәл бөтенләй башкача, ди Нурмый. Столыпин Россияне ач үлемнән коткарды. Крестьяннарны яңа җирләр үзләштерергә, хуторларга

кучәргә мәҗбүр итте һәм шул чаралар аркасында иген-тарудан зур уныш алуга иреште. Аны революционерлар яратмады. Шулар анын башына житте дә. Әгәр Столыпин исән калса, революция, бәлки, булмаган да булыр иде, имеш...

Вәзыйх анын сөйләгәннәренә ышанып та житми, болай итагать йөзеннән генә тынлап утыра. Үзе күпне белә дип уйлый эчтән генә, ә үзе авылда ин ярлынын берсе. Өе тәмам искереп, яртылаш жиргә сенгән. Матчасына терәүләр куелган. Тәрәзә аслары сипләнгән булган, алары бәсәреп черегән. Өй эчендә зур мичтән һәм сәкедән башка берни юк. Май башында Бөгелмәдән суган сатып эчеп кайта да елый-елый:

—Мин дә яшим—эт тә яши!—дип, күкрәгенә суга-суга зарын түгә. Ике крест өчен ай саен 12 сум алып торырга тиеш идем. Атнын бәясе биш сум вакытта. Иблискә хезмәт итә алмаган өчен шушы хәлгә калдырдылар. Антихристлар!..—ди-ди, каргана икән...

Вәзыйх арткы капкадан ихатага керде. Бәйдәге Муйнак аны таныды, коерыгын болгый-болгый каршылады. Вәзыйх ана, нихәл?—дигән кебек аяк какты һәм лапаска узды. Бәрәч, тарантас әзер дип әйтерлек икән ич! Тәгәрмәчләр шинланган, кыршау, втулкаланып, тимер күчәрләргә кигертеп куелган. Тезмә үрәчәләр арт һәм ал күчәр-мендәрләренә тишеп кертеп тоташтырылган. Алар өстенә читән дә менгереп куелган. Хәзер жик тә кит. Ләкин бу сүз үлчәме өчен шулай әсбапланган. Монын эше күп әле. Нурмый үзенә тиешле эшне башкарып чыккан диярлек. Хәзер эш—тимерчегә. Читәнгә тимер тасма белән кайма тотып чыгарга, үрәчә-тезмәләргә беркетергә, ике якка тимер күтәрмә куярга кирәк әле...Вәзыйх тәгәрмәчләрнен оста һәм матур эшләнешенә сокланып торды да өйгә юнәлде. Картка рәхмәт әйтергә кирәк. Монын колхоз бәясе—шалкан бәясе инде, шушы тикле мастерлыкка оят. Берәүгә дә әйтмичә генә үземнән бер-ике центнер бодай бирермен...

Ләкин өйнен алгы ягында туктап калды. Эчтә бик кычкырып дога укыйлар иде. Вәзыйх шунда гына исенә төшерде: Нурмыйнын хәле авыр дигәннәр иде. Авыл мулласы Галекәй ана ясин чыга түгелме!.. Әшһәде әннә, үлем бар, үлемнән сон терелү бар... Әшһәде... раббил галәмин... Шул мәл Нурмый телгә килде:

—Галекәй, ясинынны чыкмыйчарак тор әле!—диде ул, көчсез аермачык тавыш белән.

—Ә-ә, ярый, ярый, укунын зыяны юк. Терел генә!—дип, Галекәй укудан туктамады, тик пышылдап кына догасын дәвам итте.

—Терелмәсәм, фытырга бирергә шымытырым да юк,—диде Нурмый.— Сина бурычлы булып китәсем килми. Юкса, кыямәт көнендә кулын якамда булыр. Ясинынны туктатып тор!

—Ясин догасы белән мин Газраилне куам бит, Нурмый... Ярый, ярый, мин нәфсехур түгел, якана ябышмам. Нишлисен бит, кордаш, без колхозда барыбыз да трудәтнәгә-бушка эшләп гомер уздырдык. Каян килсен безгә байлык?!

Шулчак өйалды ишегендә авыл фельдшеры—Дамира күренде. Ул Нурмыйга укол салырга килә икән.

Вәзыйхка чыгып китүдән башка чара калмады. Ул, тимерче Малик картка килеп, тарантасны Нурмыйдан бирегә күчерергә һәм тимер лենталар белән читәнен каймаларга сөйләште. Маликка кирәкле металл-материал китерелгән иде. Аннан мәктәпкә таба алымлады. Рәмисә бүген авырган килеш эшенә киткән иде. Хәле ничек икән? Ишегалдында Фаязны очратты. Фаязнын авызында папирос, чырае сытылган, бизенгән кыяфәтле.

—Нихәл?—диде Вәзыйх кул биреп.

—Этемски,—диде Фаяз, кул селтәп.

Вәзыйх:

—Тагы анонимка язганнар диме?—дип, Фаязга текәлде. Фаяз бер күзен кысып, кыек карап дәшми торды. Вәзыйхка серне чишәргә була, анардан ычкынмый. Фаяз шулайрак уйлады һәм тәмәкесен төкереп ташлады да пышылдап кына әйтте:

—Вил Садриевич биш сарык түшкәсен район башлыкларына җибәргән, ди...

Вәзыйх:

—Без идарәдә берни белмибез, ә кешеләр каян күрәләр, ә? Гаҗәп!— диде ул башын як-якка чайкап.—Кайда пес иткәненә чаклы исәпкә алып торалар!

—Кем язганын почерктан белдем,—диде Фаяз.—Ләкин Вил Садриевичка әйтмим!..

—Әйтмә, дөрес!—диде Вәзыйх һәм мәктәпкә кереп китте.

Рәмисә, калын шәл ябынып, укытучылар бүлмәсенең бер почмагында дәфтәр тикшереп утыра иде. Вәзыйх аңа яна чыккан "Цитрамон" дигән дару эчерде. Тегенең кәефе бердән күтәрелеп китте.

Мәктәптән чыккач, медпунктка сугылды. Фельдшердан Нурмыйның хәлен белеште. "Кризис үтте,—диде сестра.—Пенициллин уколы бик килеште, бераздан аякка басар"...

Фаязның кергәнен аяк тавышыннан танып, теге яктан Рабиганың көчсез ыңгырашканы ишетелде:

—Фаяз, тышка чыгарга кысталдым! Әни кая сон?—хатын шундый булуына иреннән ояла, читенсенә. Аны гел әнисе тышка йөртә иде. Әнисе каядыр чыгып югалган, ахрысы...

Фаяз пинжәген салып чөйгә элде дә, аерым бүлеп алынган якка мич аралыгы буенча чыкты. Рабига караватына утырган, йөрми торган аякларын идәнгә төшергән. Фаяз, чүгәләп, аркасын аңа куйды. Рабига аның муенына ике куллап ябышты, аяклары өстерәлеп диярлек бара. Фаяз, селкенеп, аркасын ныграк кочтырды, өскәрәк күтәрде. Бәдрәфкә алып барып, анда махсус ясалган урындыкка утыртты. Комганын янына куйды. Лапаска чыгып, утын әрдәнәләрен өйде. Ярылмый калган ботаклы түмәрләрне ярып маташты.

Аннары Рабиганы арка кочтырып алып керде һәм кухнядагы озын өстәлнең икенче башына үз урынына утыртты. Кайнана кайтып керде дә плитәгә ягып җибәрде. Аш-суны җылытырга куйды. Рабига тузган чәчләрен рәтләштерде. Ябык, саргылт чыра кебек кулларын алга сузды. Әнисе бер савыт белән җылы су китерде, сабын тоттырды. Рабига кулын-битен юып алды. Тәрәзә буендагы сәләмә сөлгегә битләрен сөрттерде. Алдына тәрилкә белән аш китерелде. Кайнана үзенә дә аш салып, өстәлгә утырды. Фаяз, табада калган бәрәңгене җылытып, шуны капкалый, бер дә тамагына үтми шикелле.

—Нигә шул тикле шапырдатып ашыйсың?—Кайнана чыраен чалшайтып, Фаязга шырпыланды.—Кара, ничек менгерә, берәр мәткә тирәсендә чуалгандыр әле?—Кайнана Фаязны пәри урынына күрә иде. Көченнән килсә, кандала сыткан кебек итеп бетерер иде. Эче тулы зәһәр. Шул зәһәрлегеннән кузна борынының яфраклары шәмәхәләнеп тора.

—Әни, житте инде сина!—дип кычкырып салды Рабига.—Кешене бетерәсең бит!

—Көченнән килсә, ул миңа кояш йөзе күрсәтмәс иде,—диде Фаяз, тыштан тыныч булырга тырышып, Шулай да эчке ачуын тешен кысып тыйганда яңакларында "кабыргалар" беленеп китте.

—Әни, нигә син бар ачуынны Фаяздан аласың, ә?—Рабиганың тавышы юмалаган шикелле иде.

—Мин сиңе кайгыртам, Рабига,—диде кайнана, ничектер үзенең хаклы булмавын тойган төстә. Нихәтле ачулы булмасын, кызының сүзләре аны сабырландыра иде.

—Син, әни, Фаязга шырпы кадаудан әллә рәхәт табасың инде?—диде Рабига, тегенең ачуын китерүдән курка-курка.—Шуны онытасың, без Фаяз иждевениесендә яшибез. Ә закон буенча ул безне тәрбияләргә бурычлы түгел. Документлары бар, үзең дә беләсең. Ул намус-әхлаклы булганга безне ташламый. Яхшылыгы аркасында гына...

—Һе, ничек бурычлы булмасын!—диде кайнана, бүртенүдән аның кабартма яаклары күперде.—Син Фаязга барганда янып торган кыз идең!

—Фаязның гаебе юк, әни!—Рабига бик тыныч сөйләнә иде.—Ул булмаса, бүтән булыр иде, барыбер шушы хәлгә калыр идем. Бәләкәй чакта карамагансың, салкын тигергәнсең...

Кызының бу сүзләрен кайнана ишетмәмешкә салынгандай итте. Ул һаман Фаязга һөҗүм итәргә көйләнгән. Эчендә ачу ташудан авызына капкан ризыгы иддңгә төшеп китте.

—Узган ел сыерны нишләтте?—диде, муен тамырларын кабартып.—Ул сыерлар берсе дә чирле булмаганнар, ди. Районның ит заданиесе тулмаганга чирле ясаганнар. Күз буяр өчен берничә активист сыерын иткә тапшырырга риза булган. Фаязга сыердан котылу өчен җай чыккан...

—Юк, үзем тикшердем,—диде Фаяз кызмыйча.—Ике күзен дә аксыл эрен каплаган иде.

—Һаман крестьянны кыршу инде,—дип, кайнана Фаяз сүзләренә ышанмыйча кулын селтәде.—Әнә шул башбаштаклыкны Үзәккә язарга йөриләр, ди.

—Үзең һаман бу сыер бетерә мине, дип зар елый идең, әни,—диде Рабига.—Хәзер нигә кирәгә сукалыйсың? Сыер тоту мең мәшәкать, мең бәла бит?

—Сөте, каймагы үзенә иде,—диде кайнана.—Тилебәрән орлыгы ашаган кебек сөйләнәсең.

—Кәҗә сөте бар, тагы ни кирәк?

—Исен яратмыйм дисең бит?

—Врачлар кәҗә сөте эчәргә кушты...

Алар бер-берсе белән карулаша калды, Фаяз чыгып китте. Дәрескә хәзерләнергә мәктәпкә барырга кирәк иде.

Ул коридорда папирос төтәтеп торганда директор аны үзенә чакырып алды. Карале, Фаяз, диде, генетика бик хикмәтле нәрсә икән, ә? Син беләсең булыр?

—Әз-мәз генә төшенчәм бар,—диде Фаяз.

Терекләкнең нигезе генетика. Нәселдәнлек, уңчу яралгысы генналарда урнашкан. Генетика ысуллары бигрәк тә бөртекләләрнең сортларын яхшыртуда кулланыла. Селекция ул башка. Табигать биргәнне сайлап алу гына. Ә генетика исә табигатькә максатчан тәэсир итү, аны үзгәртү. Ягъни бер сорт серкәләрен икенче сорның җимшәнлегенә сибәләр... Ягъни аталандыралар. Бер яңа сорт чыгару өчен унике ел кирәк, ди. Бездә яңа, уңдырышлы сортларны чыгаручы генетик Вавилов булган. Ләкин аны теге елларда харап иткәннәр. Утыз центнер бирә торган сортлар булса, бездә икмәкне кая куярга белмәсләр иде. Хәзер әнә, алтын биреп, капиталистлардан сатып алалар. Алтын запасы кими, димәк, ил ярлылана. Әнә идеология нишләтә, үзе утырган ботакка үзе чаба...

—Ярар, югарыга таш атма, үз башыңа төшәр,—диде Зәйнагов, сүзне генетикадан башлаганына үкенгән төстә. Бер яңагы җыерылды да уртын суырып куйды.—Теге ни, җәмәгать эшләренә актив катнашасың, укыту-тәрбия эшен дә тел тидерерлек түгел, партиягә оерга теләгең юкмы, диюем иде, ә?

Аның бу сүзләре Фаяз өчен көтелмәгәнрәк булды. Уйлары йөгерешә, Зәйнагов хәйләкәр, усал кеше. Мине сынар өчен, эчендә ни барын белер өчен шулай әйтәме? Әллә бер-бер гаебем өскә калыкканмы? Мәктәпне руслаштыруга каршы чыккач, мине тәрбияләргә задание биргәннәрме? Үзен кайгыртамы, миңа хәерхаһлык эшләргә телиме? Әллә Зөмәрә белән минем мөнәсәбәт турында гайбәт ишеткән дә шуны ачыклыйсы киләме? Яхшы беләм, партиягә керә башласаң, ул әле алмавы да мөмкин. Зәйнагов тегеннән искән җилгә сизгер, бик тиз үзгәрүчән зат. Бүген болай булса, иртәгә—тегеләй.

Озак тынып тору бимазалый иде.

—Неужели мине партиягә яраклы дип уйлыйсыз?—диде Фаяз,

Зәйнаговка текәлеп карап. Анын йөзеннән нindidер мәгънә "укырга" теләде. Тик аның йөзеннән берни белешле түгел иде.

—Нигә алай дисең?—Зәйнаговның йөзендә гаҗәпләнү дә, сәерсену дә юк шикелле.

—Мин кешене җәллим. Минем "болезненный" намус белән соң?

—Әйе, партиягә уйламый гына керергә ярамый,—диде Зәйнагов, сүзнен үзе планлаштырган эзгә төшүенә канәгатьләнгәндәй. Максаты Фаязны партиягә алу да булмаган кебек тоелып китте.—Ул кимчелекләрдән арынырга вакыт, Фаяз! Мин ул химералардан уйсыз яшь чакта ук арындым. Һәм һич үкенмәдем. Тышауларны ташлагач, кыюлык, омтылыш керде. Тоткан җирдән сындыра ала икәнемне күреп алдылар. Партшкола, райбашкарма, райком... Гел җитәкче эштә. Холык-фигыльдән килгән вак тискәрелекләреңнең бугазына баса белсәң, принцип тотсаң, партия кешене күтәрә!..

—Мин бит кырмыска,—дип бүлде Фаяз.—Кырмысканың нинди принцибы? Юк!

—Кырмыскаларның да буйсына торган идоллары була, имеш?—диде Зәйнагов һәм шкафына таба борылды да нидер актара башлады. Фаяз бу сөйләшүдән нинди нәтиҗә чыгарырга белмичә, уй тулы баш белән чыгып китте.

Фаязның өйгә аягы тартмый иде. Шулай да кермичә булмый. Рабига тагы караватында елап утыра.—Ни булды инде, җә?—Фаяз Рабига бүлмәсенә сузылып, ишек яңагына тотынды.

—Фаяз, син яшь гомереңне әрәм итмә,—дип, үксүдән туктады Рабига.—Безне ташла да берәр якка югал. Җылы якта туган тиешлеләрең бар бит! Тәвәккәллә! Без ничек тә яшәрбез. Мин терелә торган түгел. Гомереңне заяга уздырма! Ишетәсеңме, ниһаять, синең яхшылыгын изә мине, намусыма тия. Дөнья бәясе кешегә нинди әшәке язмыш! Бу гаделсезлекне күреп тору мине тәмам бетерә. Син безне ташлап китсәң, миндә бәлки ачу кузгалыр иде. Шул ачу мине, бәлки, аякка бастырыр иде! Юк, мин аек акылым белән әйтәм боларны! Ычкына башлаган дип уйлый күрмә!

—Арыдың инде, ят Рабига,—диде Фаяз, ничектер кырыс булырга тырышып. Ул мәлҗерәүне, үзен җәлләүләрен бер дә өнәми иде.

*Ахыры киләсе санда*



## Газинур Морат

# ВАКЫТ БЕЗНЕ ВАКСЫТМАДЫ БУГАЙ...

### Галәми өн

Айда, диләр, сәер өн бар,
Айда, диләр, шундый хәлләр.
Әгәр Күкләр өнсез торса,
Сәер булыр иде мәгәр.

Әгәр Күкләр өнсез калса,
Туфан кубар иде күптән.
Безгә азан мәкаме дә
Кайтаваздай иңгән Күктән.

Кайтаваздай һәр ярымай
Кунып калган манарага...
Галәми өн мәкаменнән
Ходай бирмеш таң ярала.

Галәми өн мәкаменнән
Яраладыр илаһи моң.
Моң сүрәсе булып иңгән
Һәрбер Сүзе Илаһының.

Айда азан ишетелгән...—
Җирдә йөри шундый хәбәр.
Әгәр Күкләр өнсез торса,
Сәер булыр иде мәгәр...

### Каударланма, каләм...

*Сүз сөйләүдә миңа кыска булырга боерылды.*
Хәдистән.

Дөньяныкы дөньялыкта кала,
Каударланма, каләм, кабаланма,
Кадерен бел Сүзнең...
Болай да бит
Гомеркәйләр—тоташ каралама.

### Ырыс капка

Ырыс капка—урыс капка.
Бар аерма—бер аваз.
Урыс капкалар калыккан,
Ырыс капкалар аугач.

Газинур МОРАТ (1959) — *шагыйрь, публицист; "Мин тынлыкны тынлыйм", "Түбә", "Җәяүле кошлар" һ. б. китаплар авторы. Г. Исхакый исемендәге премия лауреаты. Казанда яши.*

Ырыс капка—урыс капка.
Хәзер инде... җилкапка.
Җил капканы кага-суга
Җил дә сөйли шул хакта.

Урыс капка—ырыс капка...

## Татарча язу

Яугир ирләр тарих яза—
Дәүләт кора.
Төзи кала.
Әтрәк-әләм әләк яза—
Хәрабәләр
аунап
кала...

## Сөләйман патша сүзе

Пакь булса хатыны,
Ире дә ирәер.
Низаглы нигездә
Ятимнәр игәлер.

Хак булса патшасы,
Халкы да исәер.
Гаугалы дәүләттә
Түрәләр ишәер...

## Халыкара хәл турында

Бар дөньясы кабатлыйдыр—
Әйтерсең лә тутый кош:
—Сепаратист...
—Виагра...
—Террор...
—Ислам...
—Путин...
—Буш...

## Яңа эра тарихы

Кайда мәгърип, кайда мәшрикъ—
Беткән дөнья буталып.

Һәр битендә—канлы язу,—
Сөңге белән язылган.

Хач сәфәре көндәлеген
Хәтерләтә бу тарих.

...Тик барыбер калка Кояш,
Калка кыйбла ягыннан.

## Вакыт безне ваксытмады бугай...

Вакыт безне ваксытмады бугай,
Ачыкканда бирде икмәген.
Елмайтты да, елатты да еллар,
Тик барыбер елак итмәде.

Вакыт безне ваксытмады бугай,
Күшеккәндә бирде чикмәнен.
Какса—какты, сукса—сукты еллар,
Тик барыбер сукбай итмәде.

Вакыт алай ваксытмады бугай,
Иманага бирде даланы.
Еллар безне иманасыз итте,
Тик имансыз итә алмады.

Вакыт безне ваксытмады бугай...

## "Антисемит"

Дөнья, бәлки, деңгә керер иде,
Талмуд дигәннәре Күктән иңсә;
Альберт Эйнштейн—эскрипкәче,
Карл Маркс—шагыйрь булып китсә...

## Педант

*Н. Х.*

Баш вәзирдәй вәкарь белән сөйләр,
Вәкарьләнеп сөйләр чак кына.
Чин теледәй безгә читтер дә ул,
Чин теледәй безгә якын да.

Һәрбер сүзе кысаланган булыр,
Ә кысасы булыр... алтыннан.
Латин теле кебек олпат та ул,
Латин теле кебек салкын да.

Алтын кысалы шул сүзе белән
Кертмәк булыр безне ул игә.
Ана теле кебек газиз дә ул,
Ана теле кебек үги дә...

## Иң яманы...

Дус-ишләрнең иң яманы, диләр,
Астыртыны—астан чакканы.

Хатыннарның иң яманы, диләр,
Ир йөзенә кара якканы.

Ир-атларның иң яманы, диләр,
Ата-баба нигезен сатканы.

Бу дөньяда иң яманы, диләр,
Сызып-сызып гомер акканы...

## Минсез генә...

Яши-яши шактый атынылган,
Күккә элеп бишек, таганны.
Үтеп киткән гомер минсез генә,
Ә мин сабый килеш калганмын.

## Биләрдә йөрдек би булып...

*Батуллага*

Каласыннан кисәү калган,
Саласы һаман Биләр.
Биләрдә йөрдек би булып—
Турая төшсен билләр.

Даланың каһаны булдык,
Аллаһның булдык колы...
Кызлар тавы итәгендә
Яшәдек чатыр корып.

Ә тау башында җиде кыз
Сыктыйдыр сыман һаман:
"Сәхтиян кимәс наз идем,
Чабата тапмай барам".

"Һәр кавышмакның соңында
Аерылмак бар икән..."
Шәһит кызларның күз яше
Чишмәләр булып типкән.

Шәһитләр күз яше белән
Сусынны басыйк без дә.
Хуҗалар тавына менеп,
Күз салыйк әргәбезгә.

## Холык

Хозыр карт та үзгәрталмас
Коллык дигән холыкны...
Кеше сөймәс монафыйкълар
"Сөеп яшәр"... халыкны!

## Иясез ияләр

Күңелләргә ят ияләр
Ияләште, димсез?
...Тел иясе телсез калган,
Ил иясе—илсез.

Уйлар бетте уйсызланып,
Уйлар, димсез, котсыз.
Йорт иясе йортсыз калган,
Ут иясе—утсыз.

Каннар, димсез, кансызланды,
Җаннар, димсез, җансыз.
Моң иясе моңсыз калган,
Аң иясе—аңсыз.

Кальбемезгә ят ияләр
Ияләшкән, димәк,—
Төп Нигездә тәүбә кылып,
Коръән чыгу кирәк.

## Кол

Ае—Күк катында.
Уе—Мәккәләрдә.
Иле—йөрәгендә.
Теле—мәхкәмәдә.

## Үрмәләү

Үзән үргә үрмәләр,
Түрә түргә үрмәләр,
Нәфес малга үрмәләр,
Гарьсез данга үрмәләр.
Иблис җанга үрмәләр.

## Дәгъвачы

Әле заманны сүгә ул,
Әле каһанны данлый.
Бер Канатлы Сүз әйтмәгән—
Халык бүләген даулый...

## Дин турында

*Мине игелекле мөселман дип*
*санавыгызны үтенәм.*
Лев Толстой.

Вөҗүдеңә тузан кунса,
Язык, гөнаһ тузаны,
Атакайга зарый кылма,
Күккә сыгын, туганым.

## Көпчәк мәсьәләсе

Тирмәсеннән чыгып кичә генә,
Имла таный башлап көчкә генә,
Тәгәрмәчне "уйлап тапкан" кавем
Патент даулар Тарих көпчәгенә.



## Роза Хәбибуллина

# МИЛӘШ ЕЛЫ

ПОВЕСТЬ

1957 елнең көзе коры һәм салкын килде. Ноябрь башына кадәр җиргә кар төшмәде. Октябрь бәйрәменә көннәр тагын да кырысланды.

Аудитория тәрәзәсенә тиям-тиям дип торган карагайлар иртә яздан йомшак энәләргә яшел болыт булып төренәләр дә көзләрен ут кабынган кебек куе сары төс белән балкыйлар.

Айсылу карагайларны бик ярата, алар аңа сердәшләре булып тоела, менә өченче ел инде, шушы тәрәзәдән аларга караса, чуалган фикерләре ачыла, борчулары басыла.

—Ничә яшь инде сезгә, карагайларым? Бу бинада епархиаль училище кызлары укыганда да шулай тәрәзәдән карый идегезме? Әллә буегыз җитми идеме? Без киткәч, башкалар тагын шулай төбәлеп, сезнең матурлыкка хәйран калырлар. Без китәрбез, сез калырсыз...

Айсылу моңлана. Җәй белән аерылышу аңа һәрчак монсу. Нигә алай икән? Югыйсә, ул җәй кызы түгел, көз кызы. Унберенче ноябрьдә егерме ике яшь тула. Әле моңа кадәр үзенең яше турында артыгын уйланмый иде. Әнисеннән хат алгач кызга уй керде.

"...Фәния Чиләбегә абыйлары янына киткән иде, шунда Расихка кияүгә чыккан",—дигән юлларны укыгач, сәерсенеп китте.

Ничек инде кияүгә чыккан? Ул бит әле миннән өч яшькә кече?!.

"Фәния, ут яктың бит йөрәккә, чукынчык!.."—дип, туганнан туган сеңлесен үзалдына орышып алды. Фәниянең көләч йөзе, кара елтыр күзләре, янып торган иреннәре күз алдына килде. Аның бәхетле булуына Айсылу шикләнми. Расих басынкы, акыллы егет, Фәниянең беренче мәхәббәте.

Айсылу да күңеленнән генә таныш егетләрне барлап, үзенә тиң кеше эзләде. Юк, берәүне дә өзелеп сөйми. Беркеме дә юк... Сөйгәне җанын суытып ташлап китте.

Кызның карашы бер ноктага төбәлде. Ул хәзер карагайларны да, аудитория тулы студентларны да күрми, лекторның тавышын да ишетми.

---

Роза ХӘБИБУЛЛИНА – *РСФСРның мәгариф отличнигы. Безнең журнал укучыларына "Яшьлегем серләре" дигән повесте белән таныш ("К. У." № 4. 2003 ел). Мөгаллимә яши.*

***

Ул аны район бакчасында очратты...
Иртәнге сәгатьтә дусты Зөлфирә килеп житте.
—Малай, су керергә төшәбезме?
—Минем кер юасым бар бит.
—Әйдә, күл буена, икәүләп юарбыз.
Ык буеның яшел болынында рәттән өч күл көзге кебек ялтырап ята. Аргысы Мунчала күле, анда юкә кабыгы батыралар. Кызлар уртадагы күл буенда туктадылар. Чишенеп, күлмәкләрен төреп куйгач, Зөлфирә күл читенә утырып, суда аякларын чәпелдәтә башлады. Бихисап вак бакалар камыш арасына сикерделәр.
—Әлекәем, Айсылу, суның жылылыгын күрсән! Казанга салып жылытканнар диярсен!
—Суны болгатма, юньсез!
Тазларына жылы күл суы алып, яшел үләнгә утырып, кер юа башладылар.
—Минем сиңа әйтәсе яңалыкларым бар, апаем!—диде Зөлфирә.
—Нинди яңалык ул?
—Студентлар кайткан, бүген бакчада танцы була.
—Син безгә киләсеңме? Килсәң, әнкәйдән сорарга жайлы була.
—Ярый, килермен.
Жәйге көн озын бит, Айсылу кичне дулкынланып көтте, бүген нидер булыр кебек тоелды.
Ниһаять, чыгарылыш кичәсенә дип тектергән, кызыл жирлеккә сары өрәнге яфрагы төшкән күлмәген киеп Зөлфирә килде. Ул Айсылуның әнисен юмалады:
—Бану апа, без Айсылу белән танцыга барыйк әле?!—диде.
—Ул нинди көн саен танцы инде? Үзегез институтка керергә телибез дисез, үзегезнең әле кулыгызга китап алып әзерләнгәнегез күренми!
—И, Бану апа, әле яңа гына сынаулардан котылдык бит, әзрәк ял итик инде!
—Әнкәй, бүген генә чыгабыз да, иртәгә иртүк укырга тотынабыз!
—Ярар инде, чыгарсың, түлке озак йөрмә, ишетсен колагың!
Айсылуның бүген кич матур итеп киенәсе килде, тик аның ике ситсы күлмәгеннән башка киеме юк. Ул пышылдап кына әнисеннән сорады:
—Әнкәй, апаның ефәк күлмәген бүген генә киеп торыйм әле?
Әнисе эндәшмәде. Чирәм жирләргә киткән олы кызы нишләптер сандыгында сары ефәк күлмәген калдырган. "Үскәч сеңелкәш кияр".—диде микән?
Айсылу буйга житте, өстен-башын карарга иде дә, каян алсын, ничек акча житкерсен, бер пенсиягә биш тамак... Миңлебану егерме елга якын укытса да, Калморзадан кайткач, мәктәптә аңа дәресләр табылмады, өйдә эшсез утыра.
—Ярар, бүген киярсең,—дип кызына сандыктан күлмәкне алып биргәч, Айсылу сөенеченнән нишләргә белмәде. Мич алдында үтүккә күмер салды, чыра кабызып жибәрде. Күмерләр кызаргач, бармагын төкереклән тидереп карады, үтүк "чыж" итеп алды. Өстәлгә жәймә жәеп, сары ефәк күлмәкнен бихисап бөрмәле гармун итәген үтүкләде. Тырышудан йөзе пешеп, кечкенә борыны тирләп чыкты.
Чаршау артына кереп, күлмәген алыштырып чыккач, Зөлфирә аны күреп "ah" итте:
—Малакаем, сиңа тап-таман бит бу күлмәк!
Күлмәкнең таман икәнен Айсылу күптән белә. Әнисе өйдә юкта ул аны әллә ничә тапкыр киеп карады инде. Сыек сары ефәк елкылдап, болын өсте кебек дулкынланып тора. Жиң очларын сәдәфләп, нечкә билен пута белән кысып куйды. Тасма белән өскә күтәреп бәйләнгән чәчләрен иңнәренә төшергәч, иртә яздан чыга торган сары күбәләккә ошап китте.
—Нәкъ курчак булдың инде!—диде Зөлфирә.—Үзең чандыр булсаң да

күкрәкләрен нинди зур,—дип, дустыннан бераз көнләшеп тә куйды.

Алар бакчага килгәндә танцылар башланмаган иде әле. Уртадагы мәйдан яшьләр белән шыгрым тулган. Сәгать ун дигәндә, керәшен егете Нестор вальс уйнап җибәрүгә, таныш булмаган егет Айсылу каршысына килеп тә басты:

—Сезне чакырырга мөмкинме?

Кыз оялып кына егетнең йөзенә карады һәм шунда йөрәге табан астына төшеп китте. Аның каршында озын буйлы, калын конгырт чәчле, зур күзле, калынча иренле егет басып тора. Айсылу кулын егетнең иненә салды. Егет, аның биленнән эләктереп, түгәрәк уртасына алып чыкты. Айсылу ефәк күлмәк киюенә бик шатланды. Таныш булмаган матур егетнең биюгә чакыруын күлмәк матурлыгыннан күрде.

—Сез Каенлыкүл кызымы?

—Әйе.

—Ничәнче класста укыйсың?

Егет кызның бик яшь икәнен чамалап, "син"гә күчте.

—Мәктәпне быел тәмамладым.

—Шулаймыни? Котлыйм! Хәзер кая барырга исәплисен?

—Пединститутның әдәбият бүлегенә.

—Әйбәт, без коллегалар булабыз икән! Мин университетның филфагында укыйм.

Егет кызны җинел йөртә. Биюдән генә түгел, Айсылуның бит очлары оялудан яна. Танцы беткәч, егет аны урынына озатып куйды, тик үзе китмәде. Алар янына, Зөлфирәне култыклап, уртача буйлы, кара бөдрә чәчле, кәкре борынлы, чырае белән грузинга охшаган егет килеп басты.

—Исәнме, Марс!—дип ул Айсылу янындагы егеткә кулын сузды.

"Марс исемле икән, исеме дә матур!"—дип уйлап куйды Айсылу.

—Исәнме, Госман! Кайчан кайттың?—диде Марс.

—Кичә генә. Авылда быел озак торып булмас инде, хәрби лагерьга барасы бар, каникуллар кыскара.

Егетләр сөйләшкән арада Зөлфирә, Айсылуның кабыргасына төртеп, баш бармагын тырпайтып күрсәтте.

Марс бер минутка да Айсылу яныннан китмәде.

—Син миңа исемеңне әйтмәдең бит әле!

—Сорамадың бит.

—Сорамасам да беләм—син Алтынчәч! Зәңгәр күзле, алтын чәчле кыз.

—Минем күзем зәңгәр түгел! Ә исемем—Айсылу.—Кыз көлеп җибәрде.

—Айсылу!..

Ниһаять, Нестор белдерү ясагандай итте:

—Соңгы вальс!

Соңгы биюдә Марс аның нечкә бармакларын кысып:

—Озатырга рөхсәт итәсеңме?—диде.

Айсылу ризалашып башын какты.

Капкалары янына җиткәч, Марсның кызны җибәрәсе килмәде:

—Әйдә авыл башыннан урап киләбез!

—Озак тормасак кына.

Айсылуның да егетне калдырып кереп китәсе килми иде.

Авыл башы менә генә—алты-җиде өй аркылы.

Алар болынга килеп чыктылар. Егет Ык ярының дымлы җиленә сылтап пиджагын кызның иненә салды.

—Зәңгәр дип ялгышкач, күзләрең нинди соң синең, Айсылу?

—Әйтмим!

—Болай булгач иртәгә иртүк килеп карыйм!

—Ой, килә күрмә, әнкәй ачуланыр! Мин иртүк торып укый башларга сүз бирдем!

—Әзерләнергә вакыт житәрлек. Син кая барасыңны әйтмәдең бит әле.

—Алабугага.

—Ни өчен Казанга түгел?

—Алабуга якынрак бит.

—Юк, акыллым, анда барма, Казанга кил, университетка, икәү бергә укырбыз.

Алар сөйләшеп вакытның үткәнен сизми калдылар. Каршындагы таулар өстеннән яшелләнеп таң сызылгач кына Айсылу һушына килеп сикереп торды:

—Ой, кайтырга кирәк, соңга калдым!

—Тагын аз гына торыйк инде!

—Юк, юк, болай да бик озак тордым, әнкәй ачуланыр!

Кайтканда Айсылу тиз-тиз атлады. Аның әле болай озак йөргәне юк иде.

—Айсылу, иртәгә чыгасыңмы?

—Белмим, рөхсәт итсәләр чыгармын. Хуш!

Егет аның кулын учына кыскан иде, тик Айсылу әкрен генә тартып алды да биксез капканы ачып кереп китте.

Өйалдында ак күлмәктән әнисе басып тора.

—Нишләп бу кадәр соңга калдың? Кайларда йөрдең, Ходаем?—дип пышылдап кына орышты аны әнисе.

Монарчы беркайчан да болай соңга калып кайтмагач, Айсылу ни дип тә әйтә алмады. Мыштым гына чоланга кереп чишенде дә урынына барып ятты.

Кызның күңеле шатлыктан мөлдерәмә тулып ташырга тора. Сөенеченнән аның хәтта елыйсы килә. Өзелеп көткән мәхәббәтен табуына ул шикләнми... Ул нинди сөйкемле! Ул да ошатты! Иртәгә алар тагын күрешерләр...

Иртән ул әнисе чолан ишегеН ачуга уянып китте. Тиз генә торып ишек алдындагы рәшәткәгә эленгән юынгычта юынып сөртенгәч, тирә-якка күз салды.

—Илаһым, нинди матур иртә! Биек чаганнар, тәлгәшләре карала башлаган шомырт куагы, бакча капкасы янындагы ямь-яшел кычыткан, алмагачлар арасында чыр-чу чыпчыклар, капка баганасы өстендә утырган ала мәче—барысы да, кояш нурларында коенып, яшәү бәхетенең чиксез шатлыгын кичерә.

Айсылу кулларын өскә сузып, аяк очларында күккә үрелде. Кайнар кояш нурлары аның йөзен, муенын, беләкләрен кытыклады.

—Нинди матур бу дөнья!—дип уйлады Айсылу.—Бу дөнья минем өчен! Мин синең газиз балаң, дөньям, бердәнбереӊ! Минем бәхетем мәңгелек булсын!

Аның керфек очларыннан саф тамчылар тәгәрәп төште...

Айсылу бер басасы урынга биш басты. Өйдәге эшләрен тиз арада эшләп бетерде: өстәлне җыештырды, идән юды, ике көянтә су алып кайтты. Куллары эштә, уе гел Марс турында булды: “Мине көн яктысында күрсә нишләр микән? Күңеле кире кайтмас микән?” Сынауларга әзерләнәм дип, китаплар алып, шомырт астындагы агач караватка чыгып утырды. Ун параграф укып бетерергә планлаштырып, китап битен алдан ук бөкләп куйган иде, шапылдап капка ачылды. Зөлфирә килгәнне күреп, аңа кычкырды:

—Мин бакчада.

Зөлфирә бакчага керә килешкә үк сөйләнә торды:

—Ай-һай, бүген көн кызу, көчкә килеп җиттем. Их, сезнең өйне безнең очка күчерергә иде!

—Сезгә Ык ерак бит.

—Әйе шул, киресенчә, безнекен сезнең очка күчерергә кирәк икән.

—Әтиеңә әйт, безнең очка яңа өй салсын. Леспромхоз директорына чутмыни ул!

—И малай, киләсе елга монда булмабыз инде, китәбез бит.

—Китәр өчен укырга кирәк. Ничә тема кабатладың?

—Кабатлаган ди! Малакаем, бүген йокыдан көчкә тордым. Кичә Госман белән төне буе утырдык.

—Әниең ачуландымы?

—Юк, ул минем кайчан кайтканны да белмәде, тәрәзәдән кердем. Сез озак йөрдегезме?

—Мин дә таң атканда гына кайттым.

—Ну? Үбештегезме?

—Юләр!

—Без үбештек!

Айсылу ана гаҗәпләнеп карады.

—Шакмакландырма күзеңне! Миннән сорап тормады ул, кочаклады да үпте!

—Кит инде! Беренче күргән кеше белән үбешмәсәң!

—И, Айсылукаем, ул шундый кыю, шундый әрсез, мина ул гомер буе таныш кебек!

—Артык кычкырып сөйләшмә әле, әнкәй шушы тирәдә генә йөри. Әйдә укы.

Зөлфирә китабын ачып та карамады. Карала башлаган шомырт тәлгәшен үрелеп өзде дә, чәйни башлады. Өлгермәгән шомырт авызын бөрештерде, тамак төбенә тыгылды. Чыраен сытып, якында торган чиләктән чүмеч белән алып су эчте. Суның файдасы тимәгәч, түтәлдән суган кыяклары өзеп, авыз тутырып чәйнәде. Суган ачысыннан яшь чыкса да рәхәт булып китте. Бакчада әрле-бирле йөреп туйгач, Айсылу янына килде.

—Әйтим микән, юк микән? Әйтсәм ачуланырсың инде...

Айсылу китаптан башын калкытып, Зөлфирәгә карады.

—Берәр начарлык эшләдеңме?

—Юк ла.

—Алай булгач әйт инде.

—Ачуланмыйсыңмы?

—Юк, ачуланмыйм.

—Мин Госманны су керергә чакырдым, Марска да әйтергә куштым.

—И, чукынмыш, харап иткәнсең икән!

—Ачуланмыйм диден бит!

—Менә хәзер нишләргә инде? Мин яртысын гына укыдым, аннан соң әнкәй ни дияр?

—Кеше барда сүз әйтеп тормас әле, кайткач кына ачуланыр.

—Мин оялам.

—Нәрсәсеннән оялсың? Мона кадәр малайлар белән су кермәгән диярсең!

—Малайлар бит ул, болары егетләр!

—Болар да шундый ук инде, бездән ике-өч яшькә генә зур.

—Минем бит купальнигым үзем теккән генә.

—Булса ни! Бик матур әле, кибетнекеннән ким түгел!

—Сәгать ничәдә киләләр?

—Унбергә.

—Хәзер ничә микән?

—Бар, карап чык.

Айсылу өйгә йөгереп кереп китте. Сәгать унберенче егерме минут иде. Әнисе керосинкага тирән табага каплап тозлы каз ите белән бәрәңге кыздырырга куйды:

—Озакламый ашарга пешәр, ял итәрсез.

Айсылуга унайсыз булып китте. Ял итәрлек арымады шул әле ул.

Урам ягында ир-ат тавышы ишетелүгә Айсылуның йөрәге әллә нишләп китте.

Капкадан таза гәүдәле, ялан башлы, кыска җиңле теннискалар кигән ике егет килеп кергәч, Минлебану аптырап калды. Майлы кулларын тизрәк алъяпкыч астына яшерде.

—Исәнмесез, апа!

—Исәнмесез?! Сез кем малайлары соң?—дип сорады Минлебану.

—Мин Исхаков Гомәр улы,—диде Госман.

—Ә мин Зиннуров Вәлинеке. Кызларны су коенырга чакырып килдек.

—Алай икән,—диде Минлебану.—Кызларның сынауга әзерләнәселәре бар бит, аларга укырга кирәк.

—Без озак тормыйбыз, тиз кайтабыз,—диде Госман.

—Ярар инде, барыгыз,—диде әнисе теләр-теләмәс кенә.

Минлебанунын кире уйлавыннан курыккан кебек, яшьләр ашыга-ашыга чыгып киттеләр.

Әнисе янында Айсылу Марска таба борылмады да, күтәрелеп тә карый алмаган иде. Урамга чыккач кына аның йөзенә күз салды. Көн яктысында егет тагын да матуррак күренде: киң мангаена көнгырт-кара чәчләре таралып төшкән, кашлары карлыгач канаты кебек кыйгач. Ул да Айсылуга текәлеп карый. Гүя, төнге бакчада күргән серле чибәрне кояш яктысындагы кыз белән чагыштыра... Кыз бүген ак якалы, ак бөрчекле зәңгәр күлмәктән. Йөзе алсу атлас кебек чиста, чигәләрендә алкаланып торган алтынсу бөдрә чәчләренең очы кояшта уңып аксыллаңган. Тигез ак тешләрен күрсәтеп елмайганда иреннәре җәя кебек тартылып, йөзенә аңлата алмаслык сөйкемлелек өсти.

Госманның Зөлфирәне биленнән кочып алуын күргәч, Айсылу үзе дә сизмәстән, Марстан кисәк читкә тайпылды. Марс моны күреп елмайды, кызның куркаклыгы ана ошады бугай.

Ык буенда кеше күп иде. Бигрәк тә бала-чага мәж килә. Елга өстеннән күбекләр ага, ара-тирә күбек арасында каз мамыклары күренә. Аръяктагы зәңгәр таулар өстендә рәшә уйный—кайнар һава дулкынланып тора. Яр буендагы шадра комлыкка бассаң табан асты пешә.

Госман сикергәләп гимнастика ясап алды. Аның беләкләрендә, инсәләрендә мускуллары йомрыланып, уйнап тора. Аяклары кавалеристларныкы кебек—кәкрерәк. Тәне кояш күрмәгән. Марс буйга Госманнан калкурак булса да гәүдәсе аныкы кебек түгел, спорт белән шөгыльләнми, күрәсең, мускуллары уйнап тормый.

Алар, киң колачлап, Ык уртасына йөзеп киттеләр дә, бераздан борылып, кызларны чакырдылар. Зөлфирә чишенеп өлгергән: су коена торган киемнәре шәмәхә, тәне ак шалкан кебек. Аны кояш ашамый, никадәр тырышса да, нинди майлар сөртсә дә, тәне каралмый. Айсылу, дустының артына яшеренеп, күлмәген сала иде. "Оялчан бу кыз, әле аны беркем дә үпмәгәндер, пожалуй,—дип уйлады Марс. Айсылуның төз аякларын, нечкә билен, тулы күкрәкләрен күргәч: "Матур бу кыз, килмәгән җире юк",—дип, кабат сокланып алды.

Госман кочаклап суга батыра башлагач, Зөлфирә ике ярны яңгыратып чырылдады да, Госманны үзе белән су төбенә сөйрәде. Марс болай эшләргә батырчылык итмәде.

—Әйдә без аръякка чыгабыз, анда ком чистарак, кеше дә юк,—диде ул.

Алар янәшә йөзделәр. Судан чыгып, кайнар комга сузылып яткач, бераз сүзсез тынлык урнашты.

Марс кыздан күзен алмый, Айсылу аның текәлгән карашыннан унайсызланып, ике алма кебек күкрәген ком белән күмде.

—Айсылу, нигә оялаcың? Син үзеңнең нинди сылу икәненне беләсенме? Кемгә булырсың икән син? Кемне бәхетле итәрсең микән?

Айсылуга мондый сүзләрне әле беркемнең дә әйткәне юк иде. Аңа бик тә рәхәт.

—Карагыз әле боларны, безне ташлап качканнар!—Госман Зөлфирәне житәкләп судан чыкты.

—Уф, үләм, хәлем бетте! Бу шайтан суга чумдыра да чумдыра,—дип, Зөлфирә Айсылу янына ятты.

—Әйдәгез, су коеныйк та кайтыйк,—диде Айсылу, бераз кызынып алгач.

—Ник ашыгасың, әле күп вакыт узмады бит,—диде Зөлфирә. Аның бер дә кайтасы килми иде.

Кабат суга кергәч, Госман Зөлфирәнең кояшта кызарган аркасын зур учлары белән сыйпап юа башлады:

—Дуңгыз баласы кебек пычрангансың бит, матурым.

Зөлфирә аркасы әчетсә дә түзде.
—Синен дә аркана ком ябышкан!—Марс та Айсылуның аркасын юмакчы булган иде—кыз суга чумды, ул калкып чыккач, Марс аны күтәреп алды да, иелеп күзләренә карады.
—Синен күзләр төнбоек яфрагы төсле икән!
—Кайчак юкә яфрагы, кайчак каенныкы төсле!—диде Айсылу көлеп.
Аның егетләр белән беренче мәртәбә үбешүе иде... Хәзер ул үзен бөтенләй башка кеше итеп сизде, гүя иреннәре аларны бер-берсенә мәңгегә беркетте, гомерлеккә ярәшелгән ярлар итте. "Ул минеке!"—дип уйлады Айсылу.
—Синен мина кадәр егетең бар идеме?
Кыз унайсызланып китте.
—Үзебезнең класс малайлары озаталар иде, тик мин беркемне дә яратмадым.
"Ә синен кызларың бар идеме?"—дип сорамады Айсылу Марстан. Ничә ел Казанда укыган егетнең кызы булмый димени...
"Ләкин ул хәзер мине генә ярата!"—дип уйлады, чиксез бәхетле кыз.

***

Айсылу Марс турында әнисенә сөйләргә булды.
—Беләм, Вәли малае, аның әтисен халык дошманы дип атканнар бугай.
Айсылуга бу хәбәр тамчы да тәэсир итмәде, бер колагыннан керде, икенчесеннән чыкты. Әллә кайчан, хан заманында булган эштә аның ни катнашы бар? Марсның бер гаебе дә юк!
Хәрби лагерьга китәр алдыннан Марс Айсылуны үзләренә кунакка чакырды:
—Минем әни белән танышасың киләме? Уфадан апа белән жизни дә кайтты, мин сине кунакка чакырам.
—Ой, белмим шул, оялам мин...
—Син бер дә борчылма, без озак утырмабыз.
Айсылу ак бөрчекле күлмәген юып үтүкләде, чәчен яңгыр суы белән юган иде—алтын бөдрә чәчләре дулкыннар булып кабарды.
Бусагаларын атлап кергәч, исәнләшү минутлары зур сынау кебек булды. Марсның әнисе:
—Әйдә, Айсылу, түрдән уз, кыенсынма, син бит безгә чит кеше түгел, мин әти-әниең белән якыннан таныш,—диде егетнең әнисе.
Марсның апасы Уфада судья булып эшли икән, жизнәсе—инженер. Алар Айсылуга нык ошадылар: бик гадиләр, ачык йөзлеләр.
Кечкенә тәлинкәләр тезелгән өстәлгә зур тәлинкәгә өеп вак-вак өчпочмаклар чыгарып куйдылар. Айсылу оялып кына берсен ашады, ул бик тәмле иде, икенчесен алырга кыюлыгы житмәде.
Чәен эчеп бетергәч, Марска ым какты, тегесе аңлап алды:
—Әни, без китәбез инде, Айсылуны әниләре көтә.
—Ярар, алай булгач барыгыз инде! Бездән әниеңнәргә сәлам әйт, Айсылу!
—Рәхмәт. Исән булыгыз,—дип, Айсылу Марска ияреп чыгып китте.
"Нигә чакырды икән ул мине?"—дип баш ватты Айсылу.
Бәхетле җәй кыска булды. Унынчы июльдә Марс Казан янындагы хәрби лагерьга китте.
—Август аенда очрашырбыз. Син Казанга имтиханнар тапшырырга килгәч, эзләп табармын. Мине көтәрсеңме??
—Көтәрмен.
Марс киткәч бер жирдә дә ямь калмады.
Айсылу әниләренә Казанга барасын китәр алдыннан гына әйтте.
—Кызым, Казан бик ерак, без сиңа ярдәм итә алмабыз, нигә Алабугага бармыйсың?
—Минем университетка керәсем килә.
—Ярар инде алайса, теләсәң нишлә,—диде әнисе, кызының яңа уйларын хупламыйча.

...Утыз беренче июльдә, иртәгә сочинение язасы дигән көнне, Айсылу янына, Гоголь урамындагы тулай торакка, Марс килде. Алар таң атканчы күрше йортның баскыч төбендә утырдылар. Кызның күнеле тыныч түгел, иртәгә булачак имтиханнан курка, Марстан да аерыласы килми.

—Борчылма, Айсылу, мин август азагында кайтам, сентябрьдә очрашырбыз. Имтиханнарга яхшылап әзерлән.

Айсылу тынычлана алмады. Күнеленең бер почмагында җанын борчып, сөйгәне белән янадан кавыша алуына шик туды, соңгы тапкыр очрашадыр кебек тоелды. Марс аны озатып китеп баргач, ул үзен—мәңгегә аерылган кебек хис итте.

***

Иң беренче булып кайгылы хәбәр белән Зөлфирә килде:

—Малакаем, немец телен бирә алмадым! Әллә нинди авыр билет эләкте, гел укымаган нәрсә керде. Җитмәсә файдаланырга сүзлек тә бирмәделәр.

Документларын алып, Зөлфирә берничә техникумга да барып карады, бер җиргә дә керә алмагач, ахыр чиктә Каенлыкүлгә кайтып китте. Алар белән бергә Казанга килгән байтак классташлары үтә алмады.

Айсылу, имтиханнарны биреп, конкурс нәтиҗәләрен көтте. Эленгән исемлектә аның фамилиясе юк иде...

Тормышта очраган беренче җинелү Айсылуга бик авыр булды. Ул фанер чемоданын тотып, мәрхәмәтсез Казан белән хушлашты—кайтып китте. Ай буе беркая чыкмады. Әти-әнисеннән, укытучыларыннан, бөтен кешедән оялып утырды. Мактаулы кыз өметләрен акламады, диде ул үзе турында.

Ул бигрәк тә Марстан оялды. Иртәрәк кайткач, Зөлфирә мәктәпкә пионер вожатые булып урнашып өлгергән. Айсылуга эшне бик кыенлык белән генә таптылар. Ул метеостанциягә синоптик-күзәтүченең өйрәнчеге булып керде. Сентябрь үтте, октябрь дә үтте, Айсылуга Марстан бер хәбәр дә килмәде. Кыз өчен барлык көннәрнен дә кояшы сүнгәндәй тоелды.

Октябрь азагында, төнге сменадан кайткач, Айсылу көзге каршысына килеп басты. Көзгедән аңа кара сырма кигән, сары шакмаклы шәл бәйләгән кыз карап тора... Нигә мине яратсын ул! Яратыр җирем бармыни минем? Казанда матур киенгән шәһәр кызлары барында ник мине искә алсын ул?! Үзәге өзгәләнде, кимсенде Айсылу.

Беркөнне әнисе дә кибеттән борчылып кайтты. Ипи кибетендә Марсның әнисе аңа:

—Нигә кызыңның өстен-башын карамыйсың? Җиткән кыз бит инде ул,—дигән.

Мине шушы сырмадан күргәндер инде, дип уйлады Айсылу.

Айсылу юанычын эшендә тапты. Кабинетта эленеп торган барометр, күзәтү мәйданчыгындагы приборларга бик тиз төшенде. Аның кулына бер китап тоттырдылар, шуны укып, атмосферадагы барлык үзгәрешләрне күзәтергә өйрәнде. Станция начальнигы Минкин һәм аның хатыны Рая искиткеч яхшы кешеләр булып чыктылар. Айсылу Рая апасы белән бик тиз дуслашты. Кечкенә буйлы, бүлтәеп торган зур күзле, симез борынлы бу яһүдә хатын бик тә ачык, бик тә гади һәм киң күңелле иде.

—Айсылу, детка, приходи к нам чай пить,—дип, ничә карасаң чакыра.

Алты почмаклы йортның бер башында алар яши, икенче башында метеостанция конторасы урнашкан.

Рая апасы бик тәмле итеп, куе сөт салып чәй ясый, үзе пешергән ак күмәчне эре-эре телемнәргә кисеп куя.

Метеостанциядә эшнең бер авырлыгы да юк: тәүлек буе—сәгать саен күзәтү алып барасың, приборлар күрсәтүен журналга язасың да, берничә мәртәбә телефоннан почтага сводка бирәсең. Ул телеграмма код белән Куйбышев шәһәренә китә, чөнки Татарстан метеостанцияләренең үзәге шунда.

Калган вакытта Айсылу китап укый. Геройларның бәхетсез мәхәббәтләре

турында укыганда күз яшьләрен түкте, чөнки үзенең язмышы нәкъ аларныкына ошаган иде... Тугыз ай эчендә Айсылу әдәбият буенча филология факультетының берничә курс программасын тәшкил иткән әдәбиятны үзләштергәнен үзе дә сизми калды.

Айсылу төнге дежурда булганда анын янына Зөлфирә килгәли. Жавапсыз мәхәббәт эчендә янган ахирәтен кызганып, Зөлфирә үзенең Госманы турында сөйләргә дә читенсенә, чөнки анын егете Марс кебек вәгъдәсез булып чыкмады, сирәк булса да хат яза.

Ул январь аенда студентларның кышкы каникулга кайтуларын түземсезлек белән көтте. Очрашу кичәсенә Айсылу бик тырышып әзерләнде. Инде үзенең хәләл хезмәт акчасына сатып алган зәңгәр блузкасы өстеннән куе зәңгәр жакетын киде, чәчен чәчәкле кыстыргыч белән өскә күтәртеп куйды. Бу юлы аңа көзгедән укытучы апага ошаган кыз елмая иде.

Марс очрашуга килмәде. Айсылу оялып кына булса да башка егетләрдән сораштырып карады, юк, ул күренмәде, кайтмагандыр, диделәр.

Зөлфирә Госман белән очрашкач та Марс турында белешмәкче иде. Госман нәрсәдер әйтергә теләгән иде кебек, тик янадан кире уйлады бугай.

Айсылуны югары класс укучылары биюгә чакырып йөдәттеләр. Озынрак буйлысы белән танцыга да чыкты.

Егет үзен кыю гына тота. Айсылуга "сез" дип дәшә, оста гына бии, сүзгә дә кесәгә кереп торганнардан түгел. Айсылу бу малайны белә иде.

—Мәктәпнең отличнигы бит әле син, узган ел алдынгыларны фотога төшергәндә бар идең бугай.

—Мин сезнең янга басарга тырышкан идем, булмады...

Айсылу көлеп җибәрде. Кемгәдер кадерле икән бит әле ул! Шушы малайга булса да ошый икән! Айсылу аңа хәтта озатырга да рөхсәт итте. Малайның күп укыганы сизелеп тора, җаен чыгарып, күнелле генә темаларга кереп китә.

Рифгать Айсылу янына метеостанциягә килеп йөри башлады. Аралары бары бер генә яшь булса да, Айсылу үзен аннан ун яшькә өлкән итеп сизә, малайга ул егет итеп түгел, энекәшенә караган кебек карый. Айсылу аңа хәтта үзенең мәхәббәте турында да сөйләп өлгерде. Каникуллар бетеп, студентлар киткәнче Рифгать көн саен клубка барып, кино алдыннан Марсны эзләп йөрде. Айсылуның яшерен үтенечен үтәргә ул биш куллап риза иде.

—Марс күренмәде, Айсылу, ул кайтмаган.

Ә үзе килгән саен Айсылуга ныграк гашыйк була барды. Кыз сиздеме икән, юкмы...

—Син монда бик еш килмә инде, Рифгать, Минкин абыйлар әллә нәрсә уйлар.

—Ни уйласыннар? Гашыйк булган диярләр! Һәм хаклы булырлар!— Күптән әйтәсе килгән сүзен үзе дә сизмәстән ычкындырып, егет Айсылу ни әйтер микән дип көтте.

—Алай димә, Рифгать, шаярма! Син бит минем кемне яратканны беләсен!

—Беләм. Но...

—Юк, юк, безнең арада бер нәрсә дә юк, без синең белән дуслар гына!

Егет пошаманга төшеп, бик озак эндәшмәде.

—Ярар, мин дус кына булырга да риза, син миңе кума гына, килергә рөхсәт ит.

Билгесезлектән, өметсез көтүдән гаҗиз булгач, Айсылу, күзен йомып утка кергәндәй, киенде дә, Марсның әнисе янына китте, ул белми калмас!

Айсылуның яңа пәлтәсен дә күрсәтәсе килгән иде, теләгәнчә булды: Наилә ул чишенгәндә гел ишек катында торды.

—Пәлтәң бик матур булган, котлы булсын, куанып кияргә язсын!

—Рәхмәт!

Кыз пәлтә эченнән әле яңа күлмәген дә кигән иде, чишенгәч бүлмә яктырып киткән кебек булды: алма чәчәге төшкән зәңгәр күлмәк җәйне хәтерләтә иде.

Алар икәүләп чәй эчтеләр. Бу юлы Айсылу уңайсызланмады, баштагы каушавы тиз үтте, ул үзен кечкенә кыз итеп түгел, тормыш тәҗрибәсе туплаган олы кеше итеп тойды.

—Кайтмады шул, Марс улым кайтмады, үзем дә ни уйларга белмим. Хәбәре дә юк, нишләп йөри торгандыр?—дип калды Наилә.

Айсылуга барыбер җинел булып китте, нигә алайдыр—үзе дә аңламады.

***

Марс кабул итү комиссиясе бүлмәсенә кереп, беренче курска кабул ителгән студентларның исемлеген карады. Анда Айсылуның фамилиясен күрмәгәч:

—Начар, бик начар,—диде.—Эх, кызый, булдыра алмагансың икән...

Ул үзен дә бераз гаепле сизде: көн саен килеп, кызга әзерләнергә комачаулады бит, иртәгә имтихан дигән көнне дә таң атканчы кертмәде, тулай торак янында утырдылар.

Марс борчылды. Айсылу аңа бар ягы белән дә ошый иде: матурлыгы, нәфислеге, сафлыгы белән дә. Ул Айсылуны сагынды. Чәчәк такыя кигән, яшел күзле, зәңгәр күлмәкле кызның: "Мин сине мәңге, мәңге яратырмын!"—дигән сүзләре еш исенә төште. Тик Марс хат язарга яратмый. Ул Айсылуга хатны иртәгә язам, иртәгә дия-дия, һаман чигерә килде.

Ноябрь урталарында, университетның Марс яшәгән Гвардейская урамындагы тулай торагында, кичә булды. Радиола колакларны тондырып фокстрот уйный башлагач, Марс залдагы кызларны күзәтте. Якында гына басып торган ике кызның озынрагын Марс танцыга чакырды.

—Сез бездә танцыда беренче тапкырмы, күргәнем юк иде?—дип сорады Марс.

—Әйе,—диде кыз, Марсның күзләренә әрсез карап,—сез бирегә яшисезме?

Марсның университетта укуын, шушы тулай торакта яшәвен белгәч, әлеге кыз кызыксынуын яшерә алмады, кыюлана төште:

—Мин дә университетта укыйм, тик читтән торып. Мәктәптә рус теле укытам,—диде.

Нажия Казаннан ерак түгел бер район үзәгендә яши икән. Озын буйлы, табигый кара бөдрә чәчле, зур кара күзле, кыйгач кара кашлы, кылыч борынлы бу янып торган брюнетка төрек кызларына ошаган, өстендәге кызыл күлмәге тәненә сыланып, нечкә билен, калку күкрәкләрен күрсәтеп, өздереп тора. Ул Марска бик якын килеп биеде, әйләнгән чакта күкрәге белән Марсның күкрәгенә тиеп-тиеп китеп, егетнең канын кыздырды. Нажия чая, әрсез иде. Сүзгә юмарт—чишмә кебек челтерәп кенә тора. Зур күзләрен уйнатып, карашы белән бик күп нәрсә вәгъдә итә иде.

Марс аны озата барды.

Шул кичтән соң Нажия Марс янына тулай торакка килеп йөри башлады. Марс, аны күргән саен, дәрт хисенең колына әверелә барды. Нажиянең калын иреннәре: "Мин сиңа оҗмах бүләк итә алам!"—дип пышылдыйлар кебек. Ул Марсны су сипсәң чыжлар дәрәҗәгә җиткәнче котырта да, соңыннан читкә кага, күсе белән уйнаган мәче кебек, егетнең түземлеген сыный. Һәм ниһаять, түземлеге беткән егет, зөфаф кичәсендә сусавын басты, тик ул кич аңа бәхет бүләк итмәде.

Нажия күзләрен йомар-йоммас ята, сиздерми генә Марсны күзәтә, ни әйтер микән, нинди сораулар бирер икән дип көтә.

—Ник миңа ирдә булганыңны әйтмәдең?

—Минем кияүгә чыкканым юк.

—Кем очлады соң сине? Миңа кадәр кемнеке булдың?

Нажия кызыл иреннәрен турсайтты:

—Нигә кирәк ул сиңа?

—Кирәк! Мин белергә телим!

—И, бәгърем, ярар инде, үпкәләмә, гафу ит! Үпкән-кочкан—җилгә очкан!

Хәзер мин сине генә яратам, беркайчан да, беркемгә дә алыштырмам!

Ул Марска елышты, аның күкрәгеннән алып, аякларына кадәр үбеп төште, иркәләде.

"Бу нәрсә бик тәҗрибәле икән, моның сөяркәсе бер генә булмагандыр, кем олтырагы икән бу? Юк, әллә кем калдыгы белән торырга ярамый, араны өзәргә кирәк!"—дип уйлады Марс.

Иртән ул уянуга Нажия инде торып киенгән, чәй кайнаткан, алсу таң кебек балкып, гүя берни булмагандай, елмаеп тора:

—Хәерле иртә, җаным!

Көннәр үтә торды, Марсның ачуы кими барды. Нажиянең татлы теле ташларны эретерлек иде.

Университетта эшләрен тәмамлап, читтән торып укучы Нажия кайтып китте. Китәр алдыннан, егетнең ризалыгына ирешердәй итеп үгетләп өлгерде:

—Марсик, бәгърем, сессияң беткәч, каникулга безгә кайтырсың яме!

Чынлап та гыйнвар азакларында Марс хатыны янына китте.

Яманаты чыккан кызларының, ниһаять, башлы-күзле булуына Нажиянең әти-әнисе сөенгәннәр иде. Студент кияүне кая утыртырга, ничек сыйларга белмәделәр, кем әйтмешли, өрмәгән урынга гына утыртмадылар. Хатынының ныклы гына семьядан булуы Марска да ошады, ни җитте кешеләр түгел, сүзе үтә торган, мал таба торган кеше икән Нажиянең әтисе—районда зур гына җитәкчеләрнең берсе.

Яшь кияү белән киләш хөрмәтенә туй булмаса да, зур мәҗлес җыйдылар. Өстәл мулдан иде: сый-хөрмәтнең дә әчемлекнең дә исәбе юк. Тик ул мәҗлес күңелсез тәмамланды...

Ашап-эчкәч, ял итеп, биеп алырга дип тәнәфес ясадылар. Һава сулап керергә чыккан Марс ишек алдында киләшен бер ир кочагында күреп, тораташтай катып калды. Хурлыгыннан үлә язып, янадан табынга утырмады да. Юмаларга дип килгән Нажиянең янагына чалтыратты хәтта. Нажиянең әти-әнисе нишләргә белми аптырадылар. Кияүне тынычландырырга тырышып, юатырга керештеләр:

—Кияү, үпкәләмә, ул кеше безгә туган тиешле бит, Нажияне туганы итеп кенә кочаклагандыр...

Моның белән яшәсәм, тәки адәм мәсхәрәсе итәр, кем очраса шуның күңелен күреп йөрер, дип уйлады Марс. Һәм, яшь бикәче белән хушлашып та тормыйча, Казанга китеп барды.

***

Айсылу август аенда Алабуга педагогия институтына укырга керде. Бу шатлык калган борчуларны оныттырып торды. Ниһаять, Айсылу Марс торган биеклеккә менә алды, ул хәзер беркемнән дә ким түгел! Әниләрен шатландырырга Айсылу очып дигәндәй кайтты.

Метеостанциядән азат итүләрен сорап, аннан комсомолдан учеттан төшәргә алар Рифгать белән бергә бардылар. Рифгать мәктәпне тәмамлап, Казан төзүчеләр институтына кереп кайткан. Алар икесе дә бик бәхетлеләр иде, бер-берсен чын күңелдән котладылар.

—Айсылу, син мине малай-шалайга санама, мин үсеп кайтырмын, сине куып җитәрмен!—дип шаяртты Рифгать.

Укырга китәргә бер атна кала, Айсылу әнисенең апаларына кунакка китте, ул кече туганы Фәнияне бик сагынган иде. Фәнияләр урман эчендәге кечкенә бер авылда яши. Аларның бәрәңге бакчалары артында гына җиләклек. Капкаларыннан чыгып, утыз-кырык адым барсаң, тирән яр, текә ярны казып ясалган баскычтан аска төшсәң, агач улактан челтерәп чишмә ага. Чишмә янында чикләвек куаклары, икенче як яр өстендә биек-биек юкәләр үсә. Чиләкне улак башына куеп, куакларны караштырсаң, эре-эре кишәнкеле чикләвекләр табарсың... Табигатьнең иң матур почмагыдыр син, Ташъелга!

Алар икесе көянтәләп чишмәдән мунчага су ташыдылар да, серләшергә урманга шылдылар:

—Әнкәй, без чикләвеккә киттек, син без кайтуга коймак пешер!—диде Фәния.

Алар чишмә тавыннан менеп, куе чикләвек куаклары арасына керделәр. Күпләр чикләвек агачларын сыгып, жыйганнан соң качып калганнарын гына эзләп таптылар, өлгереп, кишәнкесеннән сикереп торган чикләвекне ашый-ашый бер-берсенә серләрен сөйләделәр.

—Расих армиягә китте,—диде Фәния.

—Сагынасыңмы?

—Әллә тагы...

—Яратасыңмы соң син аны?

—Белмим...

Айсылу сенлесенең бу сүзеннән көлеп жибәрде.

—Ничек белмисең? Сез аның белән әллә кайчаннан бирле йөрисез бит инде!

—Ә сез Марс белән татулаштыгызмы?

—Юк, Фәниякәем, очрашмадык та, дуслашмадык та.

—Башка егетең бармы?

—Юк! Мин инде башка беркемне дә ярата алмам! Эх, менә хәзер шушында Марс килеп чыкса... дөньяда миннән дә бәхетле кеше булмас иде!

Агач ботакларының шатырдавын ишетеп, кызлар сөйләшүдән кинәт туктап калдылар. Куаклар арасыннан ак тенниска, кара чалбар кигән бер егет килеп чыкты.

—Исәнмесез, кызлар!

Айсылу үз күзләренә үзе ышанмады: бу мөмкин хәл түгел! Шушы минутта гына өзелеп күрергә теләгән кешесе—менә ул каршысында басып тора!

Марс кызларга якынлашты. Айсылу агач төбендә утырган жиреннән әкрен генә торды, итәгендәге чикләвекләре үлән өстенә коелды.

—Исәнме, Айсылу!

Ул, гажәпләнүен яшерә алмыйча, Марска карап торды, ләкин бер сүз дә эндәшмәде, аңа таба бер адым да атламады.

Фәния аптырашта калган дустына ярдәм итәргә тырышты:

—Әйдәгез кайтыйк, әнкәй көтәдер!

Алар куе булып үскән сәрдә арасыннан, дымлы сукмак буйлап, сөйләшми генә чишмәгә төштеләр, улак астында бит-кулларын юдылар, учлап салкын су эчтеләр.

Капка төбенә житкәч Марс:

—Айсылу, шушында утырып сөйләшик әле,—диде.

Бер ел сагынып, тилмереп көткән булса да, очрашкач, Айсылу күңелендә бушлык сизде. Мәхәббәт ялкыны түгел, хыянәт салкынын тойды. Бер ел буе жыелып килгән газабы зур булып кабарып, ачуга әйләнде.

—Кичә мин сезгә барган идем, әниең сине кунакка китте диде, шуңа бүген монда килдем. Институтка керүең белән котлыйм!

—Рәхмәт.

Айсылу Марсның текәлеп йөзенә карады: аның янында утырган егет нииндидер чит кеше кебек тоелды, йөзендә ят чалым, күзләре кыйналган этнеке кебек. Алар икесе дә бүгенге очрашуларын болай итеп күз алдына китермәгәннәр иде.

—Син мине гафу итмисеңме?

Айсылу эндәшмәде. Бәхетенә, Фәния чыгып чәй эчәргә чакырды.

Айсылу апасының йомырка туглап пешергән тәче коймагын бик яратса да, бу юлы тамагыннан үтмәде.

Фәниянең Марсны күргәне юк иде, ул аны Айсылу сөйләве буенча гына белә. Егете чыннан да матур икән, дип уйлады Фәния, Айсылуның коры торуын аңламады, үзе муенына сарылыр идем диде, ә хәзер нишләп сөйләшми микән, дип аптырады. Яшьләрне татулаштырасы килде.

—Айсылу, минем белән кайтасыңмы?

Кыз икеләнде. Үпкәләве көчле булса да, ят булып күренсә дә, Марс аңа бик якын иде әле.

—Әйдә, кайтсаң минем атка утыр,—дип, Марс коймага сөялгән велосипедын алды.

Юлның йомшак тузанын туздырып, велосипед калкулыктан тәгәри. Айсылуның зәңгәр чәчәкле ак күлмәк итәге җилкән кебек өрелеп бара. Велосипед рамына утырган Айсылуның җилдән сибелеп, таралып торган чәче, кайчак Марсның йөзен иркәләп, кытыклап ала. Аның бу ефәк дулкыннарга йөзе белән чумасы, хуш исен капланып иснисе килә. Кыз тагын да матурланган, тулылана төшкән...

Авылга кергәч тә Айсылу велосипедтан төште, Марс та аның белән янәшә җәяүләп кайтты.

Марс кая гына чакырса да Айсылуның барасы килмәде.

—Айсылу, нишләп син бу кадәр үзгәрдең?

—Мин түгел, син үзгәргәнсең! Син минем Марс түгел.

Байтак кына уйланып барганнан соң Марс авыр сулап куйды:

—Синең күңелең сизгәндер, мин бит өйләндем,—диде.

Айсылу бу кадәрлесен көтмәгән иде. Йөрәге шашып тибәргә тотынды, куллары суынып оеды, җаны чыккан кебек булды. Ул кулларын кысты, бармакларын уды. Шулай да иреннәрен көчкә ачып:

—Котлыйм,—дип әйтә алды.

—Юк, мин хәзер аның белән тормыйм, без инде күптән аерылыштык.

—Миңа барыбер,—диде Айсылу кисә-китә.

—Айсылу, мин сине яратам, гафу ит мине!—дип калды Марс.

Айсылу чоландагы урынына чишенмичә кереп ауды. Моңа кадәр пыскып янган өмете бүген бөтенләй өзелде... Мин аны сагынып, аны гына уйлап йөргәндә ул башка кыз куенында булган, мине онытып, башканы иркәләгән! Минеке булырсыңмы, дигән иде. Үзе кемгәдер ир булган!..

Айсылу хәтта Марсның башка кызны үбүен, кочуын күз алдына китереп карады.

"Эх, шушы минутта юкка чыгарга иде!—дип уйлады кыз.—Миннән дә бәхетсез кеше юктыр".

Айсылу яңадан Марс янына чыкмады. Ул аны гафу итә алмады.

Укырга китәсе көннәре санаулы булгач, Айсылу әнисе янындарак торырга тырышты.

—Нигә син юкка чыктың, Айсылу, гел күренмисең? Кайчаннан бирле килгәнең юк!—дип, дустың битәрли-битәрли Зөлфирә килеп керде.

—Эш күп бит, мәнә юрган сырабыз.

—Әллә миңа әйтмичә генә кияүгә чыгарга җыенасыңмы?

—Кияү ди сиңа! Алабугада тулай торакта юрган әзерләп куймаганнардыр!

—И, малакаем, син киткәч мин нәрсә эшләрмен инде!

—Нигә, син институтка китмисеңмени?

—Мин читтән торып укырга булдым инде, әнкәй авырый бит, аны ничек ташлап китим?

—Әйе шул. Ярар, кайгырма, Алабуга ерак түгел, мин кайткалап йөрермен...

***

Айсылулар группасындагы студентлар Минзәлә, Актаныш, Сарман, Мөслим, Бондюг, Красный Бор кебек Кама аръягы районнарыннан килгән егетләр-кызлар иде. Күбесенең әтиләре сугышта үлгән. Ятим-җилпе, ачлыкта үткән балачакларыннан чыгып, рәхәт тормышны яуларга өметләнгән авыл балалары ни кушсалар шуны эшләргә әзер торалар иде. Аларны сентябрь башыннан ук колхозга эшкә җибәрделәр. Чырай сытучы булмады. Барысы да сөенешеп машинага менеп утырдылар да, Алабуга районының бер керәшен авылына киттеләр.

Сентябрь ае димәссең! Көннәр кояшлы, кызу. Студентлар ындыр табагында ашлык чистарта. Алар кояшта кызардылар, пешteләр, ашлык тузанына батып каралдылар, көлгәндә тешләре генә ак булып ялтырап китә. Аудиториядә өстәл арасында бу кадәр дуслаша алмаган булырлар иде әле, монда бик тиз зур гаиләгә әйләнделәр.

Беркөнне аларны эскерт өяргә чыгардылар. Егетләр берничә ат белән салам тарттыра, икенчеләр астан ыргыта, остараклар өстә алып тора—эскерт ясый.

Ял итәргә утыргач, бер атны тугарып, басу буйлап йөреп карадылар. Егетләрдән соң кызларга чират җиткән иде, китте көлеш, китте чыр-чу!..

Айсылуны гомер эчендә беренче мәртәбә атка атландырганнар иде, бераз гына барды да:

—Ой, төшерегез, зинһар төшерегез!—дип ялына башлады.

Озын буйлы, кара чәчле, кара кашлы, киң маңгайлы бер егет ныклы куллары белән Айсылуны билennән күтәреп, җиргә бастырды.

—Бәрәч, Айсылу, синең сәпсим дә авырлыгың юк икән бит, парень, фәрештә кебек әллә ашамыйсыңмы син? Ындыр табагында үлчәнгән иденме? Ничә кило тартасың?

—Кырык сигез.

—И, парень, хатынлыкка үземә чыгарсың, сиңа расход күп китмәс!

Иптәшләре кычкырып көлештеләр.

—Юк, син лутчы Әлфияне ал. Авылда яшәр өчен Айсылудан әллә ни файда юк, ә Әлфияне җигәргә була!—диде Дусил.

Әлфия группада иң гәүдәле, калынча кыз, ләкин тазалыгы үзенә бик килешә, гел сөйкемле күренә.

Әлфия зур йодрыгы белән Дусилнең аркасына төртеп, эскерт өстеннән тәгәрәтеп төшерде, Дусил аның аягыннан сөйрәде. Болардан күрмәкче башка егетләр кызларны кочаклап, эскерттән тәгәрәшә башлаганнар иде, старосталары килеп җитте:

—Өч тиенлек куян—биш тиенлек зыян! Эшләгән эшегезне юкка чыгарасыз бит, диваналар!

Өс-башларын кагынып, чәчләргә, муенга тулган кылчыкларны чүпләп, янадан эшкә тотындылар. Караңгы төшкәнче эшләделәр, эскертне куеп бетермичә кайтасылары килмәде.

Колхозда эшләүнең шунысы рәхәт: кайтуга ашарга әзер була.

Айсылу фатирга Бондюг кызы Әлфия белән Салагыш кызы Әминә янына урнашты.

Әлфия дә Айсылу кебек укытучы кызы, Алабуга педучилищесын тәмамлаган. Ул группадагы иң матур кызларның берсе: сөт кебек ак йөзендә вак кына сипкелләр, зур зәңгәр күзле, матур туры борынлы, киң ак маңгайлы, нечкә генә туры кашлы. Иреннәре бантик кебек булса да, һәрвакыт каты кысылган, чөнки Әлфия һәрчак диярлек җитди кыяфәттә. Әле күптән түгел генә танышсалар да, Айсылу Әлфиянең холкына төшенде: ул бик җитди, гел зурларча фикер йөртә, акыллы һәм тәвәккәл.

Әминә холкы белән Айсылуга охшаганрак—йомшак күңелле, хыял дөньясына чумып яши, кайчак юк кына нәрсәгә дә исе китә. Аның әтисе сугышта үлгән, әнисе ике баланы бик авырлык белән үстергән. Ул тәбәнәгрәк буйлы, таза тыгыз тәнле, ләкин ятимлектә, ачлыкта үткән балачагының авырлыгын һаман сизеп яши: кызның аяклары кичкә гөбе булып шешеп чыга. Аның үткәннәрне бик исенә аласы килми:

—Без күргәнне эт тә күрмәс... Кар эреп беткәч тә саз ерып басудан черек бәрәңге җыеп йөргәндә аякларга салкын тидердем.

Аның коңгырт күзләре һәрчак уйчан, дуслары белән утырганда да фикерләре белән әллә кайларда була. Ул беркемгә дә күрсәтмичә, шигырьләр яза.

Кызлар фатирдан уңдылар: хуҗаларының килене Люба кладовщик булып эшли, студентлар өчен складтан итнең иң шәп җирләрен генә алып кайта да, күп итеп пешерә.

Башта Әминә дуңгыз итен ашый алмыйча ач калгалады, ипи белән чәй генә эчте. Әлфия белән Айсылу ачуланып та, үгетләп тә карадылар, атеистик темага әңгәмә дә кордылар. Шуннан соң, Әминә иткә кагылмаса да аш ашый башлады. Почмактагы иконага карамас өчен, ашаганда аңа арты белән утыра иде. Әлфия белән Айсылу:

—Христос синең җилкә чокырына гына карап тора,—дип шаярттылар.

—Күләгәз инде, күләгәз. Мин бит курыкканнан түгел, просто тәрене күрәсем килми. Дуңгыз итен дә ашаганым юк, күнекмәгән.

Кызлар эштән арып кайтсалар да, ашап алгач хәл бик тиз керә. Алар һәр көн диярлек авыл клубына чыгалар. Кичәләргә күрше авылда эшләүче физмат егетләре дә килгәли.

Бер кичне клубтан кайтканда аларны чегәнгә ошаган егет озата килде. Өстендә кара пәлтә, аягында зур күнитек, башына кимәгән, бөдрә чәче бүрек кебек кабарып тора, эскерт өйгәндәге Фазылны танырлык түгел...

Капка төбенә җиткәч егетнең кем артыннан кайтканын абайламадылар, хушлаштылар да ул сүз әйтергә өлгергәнче, өйгә шылдылар. Берсенең дә аның янында каласы килмәде.

Егет бераз басып торды да китеп барды.

—Кызлар, теге егет кайсыгызга күз салды икән?—диде Әминә.

—Нигә "кайсыгызга" дисең, "кайсыбызга" диген.

—Мин беләм бит ул егетне, безнең күрше авылдан, Фазыл ул.

—Бигрәк тә чегәнгә ошаган инде, чегән арбасыннан төшеп калган,—диярсең!

—Бик матур җырлый ул.

—Ну борыны мул инде! Ходай материалны җәлләмәгән—калын итеп чәпәгән дә, өстеннән баскалап, кинәйтеп куйган. Харап иткән!

Хуҗалар уянудан куркып, кызлар авызларын томып хихылдадылар.

Фазыл һәр кич килә башлады. Клубның бер почмагына кереп утыра да утлы күзләре белән биюче кызларны күзәтә, үзе беркайчан да биеми. Кемгә гашыйк булганы икенче көнне генә ачыкланды. Ул озатканда Айсылу ягыннан кайтты, килеп җиткәч:

—Айсылу, беразга гына кал әле,—дип кызның кулыннан тотты.

Кызлар кереп киткәч:

—Чәченне кисеп әрәм иткәнсең, исәр! Теге көрән тасма белән өскә күтәреп куйганда сиңа бик килешә иде.

—Син мине каян килеп беләсең соң?

—Алабугада сынау бирә башлаганнан бирле.

—Ә минем сине күргәнем юк.

—Синдәй матур кызларерактан ук күренеп тора шул, карамыйм дисәң дә карыйсы килә.

Егет якынрак елышкан иде, Айсылу күчеп утырды.

—Курыкма, мин сине ашамыйм,—диде Фазыл көлеп,—ә менә урлап алып китәргә могу!

Ул Айсылуның кулына орынды.

—Мондый авыр эш өчен яралмаган шул бу куллар! Син авыл кызына бөтенләй охшамагансың.

—Кемгә охшаганмын соң мин?!

Фазыл пәлтә кесәсеннән нәрсәдер алды да, Айсылуга сузды:

—Менә кемгә ошагансың.

Бу калын гына открытка иде. Айсылу аны күзләренә якын китерде, тик караңгыда бер нәрсә дә күрә алмады.

—Иртәгә иртән карарсың. Мин аны институтның китап киоскасыннан алдым. Синең карточкаң кебек итеп кесәмдә йөрттем. Сиңа охшаган ул охшавын, тик син аннан матуррак.

Айсылу аяк очларына гына басып керде дә, мыштым гына йокларга ятты. Открытканы мендәр астына куйды.

Иртән урын җыештырганда открытка идәнгә төште. Айсылу аны кулына алгач җентекләп карады. Озын көрән күлмәк, ак алъяпкыч, ак чепчик

кигән, кулына вак кына чәшкеләр тезелгән поднос тоткан матур кыз иде ул рәсемдә.

Әминә күреп алды да:

—Карале, гел сиңа охшаган бит бу кыз, билләһи!

Әлфия дә аның фикере белән килеште:

—Охшаган шул, маңгайлары, борыннары гел синеке инде.

Открытканың артында: Жан Лиотар: "Шоколадница", 1745, (Фр.) дип язылган.

Айсылу үзенә охшаган кызның моннан ике йөз ел элек яшәгәне турында уйлап сәерсенде. Француз рәссамы кемгә карап ясады икән бу портретны? Берәр аристократларның хезмәтче кызы иде микән? Киеме матур булса да үзе бик гади. Чәче Айсылуныкыннан караңгырак, куллары авыр эш күрмәгән, бик нәфис.

Кем идең икән син, матур кыз?

Күп очракта рәссамнар үзләренең натурщицаларына гашыйк булалар, Жан Лиотар да бу кызны, мөгаен, сөйгәндер...

Айсылуга нишләптер ямансу булып китте... Киндергә буяу белән ясалган портрет һаман да исән, ә бу кыз да, аның сурәтен ясаган рәссам да инде күптән юк...

Айсылу Фазылның иярләшүеннән курыкты, өметсез яратуның әчесен татыган кыз башка берәүнең шундый кайгыга төшүен теләмәде. Ул берничә кич чыкмады.

Бер кичне кызлар клубка чыкмыйча, киемнәрен юып—үтүкләп йөргәндә, тәрәз артында кемдер бик матур итеп җырлады:

*Башымдагы эшләпәмне*
*Элеп куйдым кыртәгә,*
*Кичә дә кич килми калдың, Нурия,*
*Килми калма иртәгә!*

—Вот это да! Гел романнардагыча бит әле бу! Кызганыч, балкон гына юк, балкон астына басып җырласа шәбрәк булыр иде,—дип көлмәкче иде Әлфия.

Әминә якташын кызганды:

—Бар инде, чык, интектермә мескенне!

—Ошатмасаң ышандырып йөрмә!—диде Әлфия дә.

Айсылу иненә шәл генә ябынды да капка төбенә чыкты. Хәтере калган балага охшап баганага сөялеп торган Фазыл янына килде.

—Син йөрмә инде, Фазыл, минем егетем бар.

Фазыл эндәшми торганнан соң:

—Синдәй чибәр кыз ялгыз булмас,—диде.

Фазыл ике-өч көн генә килми торды да, тагын йөри башлады.

Бер яңгырлы кичтә, шабыр суга батып, саз ярып тагын Айсылу артыннан кайтты.

—Ачуланма инде, Айсылу, мин сине күрмәй түзәлмәем бит!

—Синең йөрүеңдә ни файда? Көн саен ун километрдан килеп ник интегеп йөрисең?

—Мин файда өчен йөрмәем, сине бер күрсәм шул җитә.

Сентябрь азагына көннәр салкынайды. Өй почмагында торган кисмәктәге суның өстендә юка гына булып боз катты. Капка янындагы миләшнең яфраклары кызара башлады, кыраудан соң миләш тәлгәшләре үтә күренмәле булып, авызларга су китереп кызыктырып торалар. Үткән-барган саен кызлар миләшне өзәләр дә, йөзләрен чытып ашыйлар. Миләшнең әчкелтем тәме авызда бик озак саклана... быел миләш елы...

Соңгы көнне кызлар басудан чиләкләп эре-эре бәрәңгеләр алып кайттылар.

—Никадәр булдыра аласыз, шулкадәр алыгыз,—дигән иде колхоз рәисе, чөнки алар студентларга эш өчен бер тиен дә түли алмады. Аның каравы, ай буе тамаклары тук булды, стипендияләре бераз янга калды.

Студентлар клубка соңгы тапкыр җыелдылар. Көтмәгәндә колхоз рәисе

килеп керде. Ул идән уртасынарак басып, яшьләргә карап елмайды.
—Кадерле яшьләр! Сезгә колхоз идарәсе исеменнән, бөтен колхозчылар исеменнән рәхмәт әйтәсе килә! Бик яхшы эшләдегез, тырыш балалар икәнсез! Дөресен әйтергә кирәк, башта болар юньләп эшләрләр микән дип шикләнгән идем. Молодцы, сынатмадыгыз!
Ул бер кәгазь алып укый башлады:
"Игеннәрне урып-җыю вакытында тырыш хезмәтләре өчен Киров исемендәге колхоз идарәсе Алабуга педагогия институтының 13 группа студентларын мактау кәгазе белән бүләкли."
Мактау грамотасын староста чыгып алды.
Студентлар төялгән йөк машинасы җыр белән кузгалып китте, яшьләр авыл урамын җырлап бер әйләнделәр. Капка төпләренә чыккан картлар да, яшьләр дә кул болгап озатып калдылар. Җыр, ераклашканнан-ераклаша барып, бөтенләй ишетелми башлагач, авылда сәер тынлык урнашты. Көләч йөзле егетләр-кызлар киткәч, авылның нуры сүнгән кебек булды.
Айсылу дәртләнеп, яратып укыды. Хәер, уку дәрте группада чиргә әверелде: егерме биш студентның барысының да исәбе дүрткә-бишкә генә уку, чөнки өчле алсаң, стипендия бирмәячәкләр, ансыз егерме бишнең берсе дә укый алмаячак. Беренче сессияне Әлфия дә, Әминә дә, Айсылу да бишлегә генә тапшырдылар, имтиханнар кыен булмады. Кызлар, колхоздагыча, тулай торакка да бергә урнаштылар.
Икенче курс башында, һич көтмәгәндә, Алабугага Марс килеп төште. Айсылу аның белән очрашу турында уйламый да, өметләнми дә иде инде. Марс белән арасы өзелгәч, башта Айсылуга дөнья беткән сыман булды, башы кайгылы уйлардан арынмады. Ләкин гөрләп торган студент тормышы мавыктырып, ул кайгыларны әкренләп куып таратты.
Марс белән янадан очрашканда Айсылуның ачуы басылган, үпкәләве кимегән иде. Алар тыныч кына сөйләштеләр, аралары якынайган кебек булды, тик барыбер яраланган мәхәббәт хисе кабат элеккеге кебек Айсылуны яндырмады, көйдермәде.
Марсның диплом алу елы иде. Киләчәк тормышын яңача кору турында уйлап үзенчә планнар кора, Айсылу белән бергә булса, барысы да яхшы булырына ышана иде ул. Ләкин бу соңгы очрашуда егетнең күңеле кителде: Айсылу үзгәргән, элеккеге кыз түгел, артык исе китмәгәч Марска ниндидер шик төште, башка егете бардыр дип уйлады.
Кышкы каникулда Алабуга институты үзешчәннәре Казанга йомгаклау концертына бардылар. Айсылу да вокаль ансамбль составында иде. Моны ишетеп, "Казан" кунакханәсенә Марс килде.
—Вакытың булса, мин сиңа Казанның музейларын күрсәтермен,—диде Марс.
Айсылуның Казанны юньләп күргәне юк. Теге елны сынаулар биреп, вакыты да булмаган иде.
Алар тарих музеенда булдылар, Кремль буенча озак кына йөрделәр, аннан соң "Блинная" дигән кафега кереп коймак белән чәй эчеп чыктылар.
Концерт көнне Опера һәм балет театрының сәхнәсендә йөзләгән кешене җыелма хорга тезделәр. Айсылуларның ансамблен уртага башлап җырлаучылар итеп бастырдылар. Художник Сперанский ясаган матур табигать күренешләре фонында бу хор гаҗәеп бизәк булгандыр: җырчылар театрның бай костюмнарына төренгән иделәр. Менә хор каршысына дирижер чыгып басты. Алабуга кызлары җырны башладылар, ә кушымтада йөзләгән тавыш килеп кушылды.
Айсылу зур сәнгатькә якынлашуы белән үзен бәхетле хис итте, аның өчен шушы матур бинаның эчендә йөрү дә бәхетнең үзе кебек иде.
Марс Айсылуны озатырга дип килде. Ул Айсылуга Купринның "Гранатовый браслет" дигән повестен бүләк итте.
—Айсылу, мин сине шушы китаптагы герой кебек яратам! Әйт әле, син мине гафу иттеңме?
Марс Айсылуга сөйгәне түгел, туганы сыман тоела башлады. Элеккеге

кебек дөньясын онытып яратмаса да, егет аның күнеленә барыбер якын иде.

—Әйе...

—Хат язарсыңмы?

—Язармын.

Вагонга кереп утыргач, Айсылу тәрәзәдән карады, Марс ана нәрсәдер кычкырды, тик ул ишетмәде, поезд тизлеген кызулатты, вокзал артта калды.

Ансамбль кызлары Айсылуның егете белән кызыксындылар:

—Кайда укый?

—Университетта. Быел тәмамлый.

—Ничек кешенең бәхетенә шундый егетләр очрый микән?! Безнең Алабугада мильтоннан башка кияүгә чыгарлык кеше дә юк!—диде берсе.

—Нигә алай дисең, безнең институтта егетләр беткәнмени?

—Бетмәгән, тик юньлеләренең инде иясе бар...

—Авыз ачып йөрмә, "сайлаган сазга, очраган тазга", ди, күп сайланма! Минә күрерсең әле, син санга сукмаган егетләрнең күбесе мәктәп директорлары, райком секретарьлары булырлар. Ирләр укытучы булып озак йөрми, алар сразы начальник булалар...

Айсылуга бер хат килде.

Конверт калын гына, адресы таныш булмаган кул белән язылган. Конвертны ачкач, аннан бер фото килеп чыкты. Кара бөдрә чәчле, зур күзле, кыйгач кара кашлы, кылыч борынлы бу матур кыз Айсылуга таныш түгел иде. Ул башта аптырап калды, хатны укый башлагач кына аның кем икәнен аңлады. Фотода Нәҗия иде: "Син минем иремне тартып алдың!— дигән.—Безнең семьяны җимергән өчен, мин ректорыгызга язып, үзеңне институттан кудыртам", дип язылган иде анда.

Карточкасының артына берни дә язылмаган, язусыз да аңлашыла: "Синең миннән артык җирең юктыр әле, әнә мин нинди матур!"—дип кычкырып тора.

Айсылу нык кимсенде. Мәхәббәтенә хыянәт итеп, аны Нәҗиягә алыштырып, Марс бер мыскыл итте, хәзер, әнә, элеккеге хатыны янап ята, куркытмакчы була. Гомергә тыныч, басынкы Айсылуның котырып ачуы чыкты, аны мәсхәрә итәргә тырышкан хатыннан да, Марстан да үч аласы килде. "...Мин синең иреңне тартып алмадым, син үзең минем сөйгәнемне тартып алган идең, ник соң аны ычкындырдың?

Миндә эшегез булмасын, үз арагызны үзегез карагыз. Марсның да, синең дә исемегезне дә ишетәсем килми! Аннан башка да миңа монда егетләр море!"—дип җавап язды Айсылу.

Икенче курсны тәмамлагач, студентларны төрле пионер лагерьларына практикага тараттылар. Айсылу үз районнарына җибәрүләрен сорап гариза биргән иде, рөхсәт иттеләр.

"Урман иле" дип аталган бу лагерьдан да матуррак урын юктыр! Юан нарат бүрәнәләрдән салынган биналар куе нарат урманы эчендә. Урман аланнарында каен җиләге, җир җиләге, хәтта нарат җиләге дә очрый.

Айсылуга бала чагында лагерь дигән бәхет эләкмәде, каты сугыш елларында алар күп нәрсәдән мәхрүм калдылар. Кыз әле бүгенгедәй хәтерли: бала чагында тормышка ашмаган хыялы калды—аның пионер булып кызыл галстук тагып йөрисе килде. Галстук булмагач үзеңне пионер дип санап буламыни?! Аның иң кызыкканы галстук иде. Ул әллә нинди корбаннарга да риза: "алмалар-хөрмәләр бирикме, әллә галстукмы?" дисәләр, "галстук" дияр иде, ә бит ул вакытта алма-хөрмә күз күрмәгән, колак ишетмәгән ризык.

Менә хәзер Айсылу муенына бала чактагыча, кызыл галстук бәйләп йөри, тик ул күңел ярасын барыбер басмый.

Айсылу балалар белән кызык уеннар оештырды, ярышлар үткәрде, урманга табигать белән танышу өчен экскурсияләргә алып чыкты. Вожатыйлар лагерь янынnан гына аккан Ык буенда комда кызынып, су коенып, урман һавасы сулап гомергә күрмәгән рәхәтне татыдылар. Шуның

өстенә лагерь пешекчеләре бик оста булып чыкты. Груня исемле керәшен апа көн саен бик тәмле итеп аш, гуляшлар, камыр ризыклары пешерә, мактаган саен ныграк тырыша. Айсылу бар дөньясын онытып эшли, аны балалар бик яраттылар, һич артыннан калырга теләмиләр, сорау артыннан сорау яудыралар, җавап бирергә өлгер генә!

Лагерь ябылырга бер атна кала, көтмәгәндә, Марс килеп төште.

Баштанаяк өр янадан киенгән егет көн буе чабып арыган Айсылу каршысына килеп басты! Кыз үз киемнәреннән оялып куйды: ул бүген, пешекчеләргә ярдәм итеп, кухняда эшләде, шуна күрә өстендә искерәк свитер һәм чалбар, башына ак яулык бәйләгән иде.

—Әле нишләп йөрисең?

—Нәрсә, әллә минем килүем ошамыймы? Күрәсең дә килмиме?

Мондый дорфа тонга Айсылуның исе китте, ул бит бөтенләй башка сүзләр өмет иткән иде.

—Син мине оныттың, хатларга җавап та язмадың, ә бит син: "башка беркемне дә ярата алмам", дигән идең.

—Онытмадым.

—Ник соң хат язудан туктадың?

Айсылу Марсның сүзләрендә үпкә генә түгел, кимсетү ишетте. Егет үзен ничектер һавалы тота, шуна күрә Айсылу аңа Нәҗиянең хаты турында сөйләп тормады.

—Мин Уфага китәм.

Кызның йөрәге өзелеп төшкәндәй булды, шатлыклары болай да бик аз булган мәхәббәтенең тамырына чапкандай тоелды, хат язмавына үкенде.

—Мине дә үзең белән Уфага алып кит!

Марсның йөзе кырысланды.

—Мин синең турыда әллә ниләр ишеттем.

—Сөйлә!

Марсның үзен хөкемдарларча тотуына кызның һушы китте, йомшый төшкән күңеле катты, ачуы килеп сикереп торды.

—Алай икән, син мине хөкем итәргә килгәнсең икән! Кемнең кем алдында акланырга тиеш икәнен оныткансың, ахры! Менә нәрсә, җан кисәгем, юлыңа ак җәймә!!! Хуш! Мине янадан борчыма! Моңа кадәргеләре дә җитәрлек булды!

Кыз тиз-тиз атлап балалар янына кереп китте.

Марс, китәргә дә китмәскә дә белмичә, аптырап торды. Очрашу аңынча барып чыкмады, Айсылу тагын аңа баш бирмәде.

Айсылу, шау-гөр килгән балалар янына кергәч, үзен ниндидер куркынычтан котылган кебек сизде.

Айсылу Марс әйткән сүзләрне берәм-берәм исенә төшерде. Әллә кемнәр белән йөргәнсең, ди. Кемнәр белән йөрдем соң? Танцылардан озатып куючылар күп булды, тик мина берсе дә ошамады, берсен дә яратмадым. Фазыл йөри инде, ике ел буе тынгы бирми...

Быел Фазыл Алабуга бакчаларыннан кочак-кочак сирень ташыды. Кама ярларыннан чыгып, Тойма белән кушылгач, айлы бер кичтә Айсылуны көймәдә йөртте.

Ул ишкәк ишә-ишә җырлап җибәрде:

*Көн аяз, килә яз,*
*Чәчәккә күмелеп.*
*Син дә кил, Сәрвиназ*
*Шатлыклы көн кебек.*

Су өстендә Фазылның тавышы бигрәк тә матур яңгырады...

Айсылуның бирелеп тыңлавын күреп, Фазыл җырлап бетергәч, ишкәкләрен көймә төбенә куйды да, кыз утырган эскәмиягә килеп кулларын аның иненә салды. Айсылу карышмады. Болай итеп мине тагын кем яратыр? Утка кер!—дисәм, уйлап та тормас, минем өчен утка керер, дип юанды кыз.

Уйларын сизгән кебек, Фазыл кочаклады да иреннәреннән үбеп алды.

Ләкин бу үбү Айсылуны тетрәтмәде, кайнар ут булып тамырларыннан йөгермәде, ул үзен-үзе онытып, үбүгә җавап бирмәде.

Ияләнсәм, бәлки мин дә аны ярата башлармын, ди Айсылу. Аның Фазылны яраткан чаклары да була.

Ул аны сәхнәдә вакытта ошата: Фазыл очкынлы күзләре белән залдан Айсылуны эзләп таба да, аннан күзен алмыйча, бөтен барлыгы белән җыр аша мәхәббәте турында сөйли, йомшак тенор тавышы залга тарала.

*...Кара карлыгач микән, сары сандугач микән*
*Аны үстергән әнкәсе...*

Икенче курсны тәмамлар алдыннан Фазыл бик сәер елмаеп:

—Айсылу, әйдә бергәләп Казанга китәек!—диде.

—Нигә?

—Син театр студиясенә, мин консерваториягә керермен.

"Театр" дигәч, Айсылуның күңеле талпынып куйды. Аның дөньяда иң яраткан, иң мавыктырган нәрсәсе—театр. Фазыл физмат кумиры булса, Айсылу филфак "примадоннасы"—аны "безнең актриса" дип йөртәләр.

Айсылу башын чайкады. Юк, бу мөмкин түгел! Аның өендә бер пенсиягә биш кеше яши, ике курс бетергәннән соң институт ташлап булмый...

—Исәр син, Айсылу, исәр! Шундый талантыңны күмеп калдырасыңмы?!

Мәхәббәт булмагач, яратып булмаганын Айсылу аңлады, артык ияләшмәсен дип, Фазылны һаман этәрә торды.

Бер кич, кызлар йокларга яткач, Фазыл бүлмә ишеген шакыды, аннан соң әкрен генә: "Айсылу, Айсылу!" дип, чакырды. Йокламасалар да кызлар "мес" булдылар. Фазыл, кыюлана төшеп, кычкырыбрак эндәште. Бик озак ялынгач, кызлар аны җәлли башлады.

—Бар инде, Айсылу, чык, интектермә!

Айсылуга бик уңайсыз, хәзер дүртенче каттагы бүлмәләрдә кызлар йокламый, Фазылны кызганалардыр, Айсылуга ачулары киләдер...

Шул минутта Фазыл, буш коридорны шаңгырдатып, бар көченә кычкырып җырлап җибәрде:

*Җыйган чәчәкләремә шиңде, ник килмәдең, Зөлфия?*
*Син сөймәсәң мин дә сөймәм, үкенерсең, Зөлфия.*
*Зөлфия, Зөлфия, күңелем сине сөя.*

Монысы инде артык! Айсылу сикереп торды да, халатын эләктерә-эләктерә, коридорга чыкты. Бер бүлмәнең ишеге ачылып ябылды.

—Фазыл, нигә болай кыланасың?! Ник төн уртасында кеше уятып йөрисең? Иртәгә ни диярләр?

—Эх, Айсылу, нишләем соң, сине күрәсем килә бит!

—Мине син көндез дә күрә аласың бит.

—Харап иттең син мине, Айсылу! Синнән башка яшәй алмаем мин!

Ул Айсылуның кулын учына алды, бармакларын иркәләп сыпырды. Аннан аз гына аракы исе килә иде.

Айсылу кулын тартып алмады. Ул Фазылны кызгана, яшьтәш булсалар да Фазылны энесе кебек күрә. Аның әнисез ятим үскәнен белгәч, бигрәк тә нык җәлләде, бала чактан назга сусап яшәгәнгә Фазыл аны үзенчә сөядер дип уйлады. Айсылу янына килгәндә аның күзендә курку катыш ялвару күренә, ул югалып кала, кечкенә ятим малайга әйләнә.

Бу юлы да нәрсә дип тә әйтә алмагач:

—И, Фазыл, әзәрлекләмә мине! Әгәр институтны тәмамлаганчы кияүгә чыкмасам, укып бетергәч тә синеке булырмын,—дип, үзе дә уйламый, егеткә вәгъдә бирде.

Фазылның минем арттан йөрүен Марс кемнән ишетте икән,—дип, аптырады Айсылу. Ни булса да булган инде, кызның әлегә беркеме дә юк, ул—ялгыз...

Өченче курс башында, колхоздан кайткач, Айсылу авырып больницага эләкте. Ангина белән еш авырый башлагач доктор ана операция ясатырга кушты:

—Ангина бик начар авыру, ул йөрәккә дә, бөергә дә бәрә. Теләсәгез операциягә Казанга җибәрәм...

Айсылу риза булды. Казаннын Волков урамындагы клиникасында тамак төбендәге бизне очы кызарып торган электр энәсе белән яндырдылар. Операциядән соң больницага салмадылар, тамак төбегезне чәй содасы белән чайкап торыгыз дип, шул килеш чыгарып җибәрделәр. Авызын ачарга да куркып, классташы Илгизә яшәгән эшчеләр тулай торагына кайтып ятты.

Авыртуга көчкә түзеп, утызлап караватт торган зур бүлмәдә берүзе ята, кызлар барысы да эштә.

Кинәт бик тантаналы тавыш белән радиодан белдерү яңгырады:

“Говорит Москва! Работает все радиостанции Советского Союза! Передаем сообщение ТАСС! Сегодня, четвертого октября тысяча девятьсот пятьдесят седьмого года в Советском Союзе выведен на орбиту первый искусственный спутник Земли!..”

Бу яңалыкка Айсылу таң калды, хәтта тамак төбе авыртуын да онытты. Җирнең ясалма иярченен очырганнар! Фантастика! Фән һәм техника ничек үскән! Нинди талантлы кешеләр бар бу дөньяда! Безне тормышта күз алдына да китерә алмаслык үзгәрешләр көтәдер, дип уйлады кыз. Бу датаны мин гомергә дә онытмам инде, Спутник миңа операция ясаган көнне очты...

Карагайларга карап, Айсылу ике-өч ел эчендә булган вакыйгаларын искә төшерде... Җирдә яшәүче гап-гади кыз баланың гомерендә, ниһаять, үсеш-үзгәрешләр булырмы инде?!.

Әнисеннән хат алгач, Айсылуның сагынуы көчәйде, өйләренә кайтып, барысын да күрәсе, рәхәтләнеп алар янында бер-ике көн торасы килде. Октябрь бәйрәменә өч көн ял туры килә иде...

Кайтасы килүнең бик җитди сәбәпләре дә бар.

Беренчедән, Айсылу авылга язган хатында: “Операция вакытында авыздан тәтеннәр чыкты,—дип, юкка әниләрен борчыганга үкенде, кайтып аларны тынычландырасы килде.

Икенчедән, җәйге стипендия акчасына алган яңа киемнәрен күрсәтеп, әниләрен сөендерәсе килде. Гомумән, кайтасы килү йөрәген ашкындыра.

Иске автобус Затонга барып җиткәндә Кама буенда байтак кешенең басып торганын күрделәр. Камада көзге боз ага, яр буенда ике кеше зур гына көймәне караштыра.

—Ну, кто самый храбрый?! Садитесь с богом!—диде көймәче.

Беренче рейска эләкмәүдән куркып, Айсылу ашыгып көймәгә кереп утырды. Көймәчеләр алты-җиде кеше алып, теге якка ишә башладылар. Суыктан куерган караңгы-яшел елгада эре-эре бозлар ага, инде бозлар көймәгә килеп бәрелде дигәндә генә, көймә башында утырган кеше ишкәген бозга тери дә, бөтен көченә этә, боз юлын үзгәртеп, киткәч, көймәдәгеләр бар да җиңел сулап куя.

“Беттек!”—дигән минутлары әллә ничә булды. Бөтерелеп-ургылып аккан төпсез суга карасаң җаннар өши... Айсылу үкенә башлады: “Юләр, ник Әлфиянең сүзен тыңламадым микән?! Бөтенләй савыкмаган килеш нигә дип юлга чыктым! И, Ходаем, исән-имин генә чыгып җитә алсак иде!”

Көймәдән төшкәндә юлчыларның аяклары камыр кебек, тез буыннары калтырый иде.

Көн уртасы җитте, җил купты, ябалак-ябалак кар явып үтте, машиналар һаман күренмәде. Көн караңгылана башлагач кына бер йөк машинасына менеп утырдылар. Кузовтагы йомшак саламга утыргач кына Айсылу үзенең никадәр арыганын сизде. Көне буе салкын җилдә басып торганга аяклары сызлый башлады. Кыз тезләрен пәлтә итәге белән каплап куйгач тәненә җылы керде.

Машина катканак юлдан сикергәләп бара, тик моңа берсенең дә исе китми, ничек барса да барсын, кайтарып кына җиткерсен!

Юлчылар авыл саен төшеп кала барды. Саклаубашка җиткәч, шофер бер капка төбендә туктады да:

—Мин дальше бармыйм,—диде.

Каенлыкүлгә тагын егерме биш чакрым калды. Каенлыкүлгә алар өчәү кайталар: Айсылу, Җәүдәт исемле урта яшьләрдәге кеше һәм солдат.

Якташлар караңгы урамда басып калдылар.

—Ярар, балалар, бер дә борчылмагыз, хәзер Югары Табынга төшәбез, анда минем сеңлекәш яши, шуларга кереп кунарбыз. Иртәгә тагын юне чыгар әле.

Шундый өлкән кеше белән юлдаш булуына Айсылу бик сөенде.

—Айсылу, бирегез сумкагызны мин тотыйм!—диде солдат.

Җәүдәт аны мактады:

—Вәт маладис, солдат, шулай кирәк! Синең беләктә көч җитәрлек!

—Житә-ә-! Кирәк булса үзен дә күтәреп кайта алам!

Алар көлешеп алдылар. Авылны үткәндә тәрәзәләрдән төшкән яктылыкта баруы күңеллерәк булган икән, басуга чыккач, дөм караңгы булды: күк тә кара, басулар да кара, җитмәсә тирә-якта үлем тынлыгы, эт өргән тавыш та ишетелми.

Кирза итеге белән лап-лоп басып, озын атлап алдан Җәүдәт бара, Айсылу аның адымына иярә алмый. Биек үкчәле бутый эчендә биек үкчәле туфли, аның белән һич озын атлап булмый. Айсылу әллә ничә адымга артка кала, аралары һаман ераклаша, тик кыз борчылмый, чөнки солдат әкрен атлап аны саклап бара. Җәүдәт борылып карый да туктап аларны көтеп ала.

—Биек үкчә юл йөрү өчен түгел инде ул. Вәт чабата белән җиңел ул йөрергә! Юеш булмаса, чабатадан да яхшы аяк киеме юк! Аякны да тирләтми, үзе җиңел, үзе йомшак, чабасың гына!

—Әллә чабатаны сагынасыңмы, Җәүдәт абый?—диде Айсылу, үртәргә теләп.

—Юк, чабатаны сагыналармы соң! Ул хәерче заманнар берүк кире кайта күрмәсен!

Биш-алты чакрым гына дигәч, Айсылу борчылмаган иде, тик бу чакрымнар бик тә озын, бик тә авыр булып чыкты. Кыз шабыр тиргә батты. Бияләй эчендә куллары тирләп чыкты. Арыганын сиздермәскә тырышса да адымнары әкренәйде.

Ниһаять, авылга кереп, бер капка төбендә туктадылар.

—Менә шушында тора минем сеңлем,—диде Җәүдәт.

Ишекне шакуга: "Керегез!"—дигән, хатын-кыз тавышы ишетелде.

Караңгы төннән килеп кергәч, юлчыларның күзе чагылды. Өйдә бик якты. Тигез усак бүрәнәләрдән салынган йортның стеналары ап-ак, гәрәбә төсендәге идәнгә чүпрәктән сугылган буй-буй паласлар җәелгән, түрдәге никель караватбиек итеп җыештырылган, караватөстенә ак казлар кебек зур-зур мендәрләр кунаклаган. Олы як белән кече якны бүлеп, агартылган мич тора. Мич кырында тагын бер бәләкәй генә агач караватбиек.

Кече яктан яшь кенә хатын чыкты.

—Бәрәч, абый, каян килеп чыктыгыз? Исән генә кайттыгызмы?!—дип, кул биреп күреште. Абыйсы артында торган кызны күреп:

—Айсылу түгелме соң бу? Бәй, исәнме, Айсылу?!.

Айсылу кулын сузган иде, Сәвия аны кочаклап ук алды.

—Карале, нинди күңелле очрашу насыйп иткән Ходай! Сине күрмәгәнгә биш былтыр бит инде! Нишләп болай төнгә калып йөрисез?

—Машина Саклаубашка кадәр генә булды. Мин Чаллыдан кайтам, Айсылу Алабугадан, солдат, әнә, гупчым ил читеннән үк кайтып килә. Сез Айсылу белән танышлармыни?—дип җавап катыш сораулы җөмлә белән Җәүдәт сүзгә кушылды.

—Без бик якын танышлар, мәктәптә бергә укыдык, параллель классларда.

—Сәвия классларында иң матур, иң яхшы укучы иде,—диде Айсылу.

—Шулай булгандыр да, түлке синең кебек институтларга керә алмадым инде.

—Ике куянның койрыгын тотып булмый шул, сеңлем,—диде абыйсы,—йә укыйсың, йә кияүгә чыгасың.

—Әйе, бөтен кеше дә институтта укыса, колхоз сыерларын кем савар?—дип килеште Сәвия,—сез ял итегез, мин хәзер аш өлгертәм.

Сәвия кече якка кереп киткәч, Айсылу мич янындагы бала караваты янына килде. Ак мендәрдә җәйрәп йоклап яткан кызчыкны күрде. Тупырдап

торган бәләкәч, алсу бармаклары кыймылдап куйгач, уятудан куркып, читкәрәк китеп басты. Ул Сәвия янына кече якка керде. Сәвия җиннәрен сызганып токмач җәя иде.

—Сәвия, кияүгә кайчан чыктың?

—И-и-и, дускаем, мин укып бетергәнче Мисхәт көчкә түзде. Мәктәпне дә тәмамладым, кияүгә дә чыктым. Кызыма хәзер ике яшь.

—Ирең кайда эшли?

—Колхозда шофер.

—Тату яшисезме?

—Тьфу-тьфу, күз тимәсен! Мисхәт эчми дә, тартмый да. Эштән курыкмый, колхозда да, өйдә дә батырып эшли. Үзем сыер савам.

Сәвиянең яңаклары алсу, кара күзләре көләч, ак маңгай өстеннән күз юлы ачып үрелгән чәчен баш очына урап куйган. Өстенә кигән күлмәге, чәчәкле алъяпкычы үзенә килешеп тора, аягында ап-ак йон оекбаш, башына ак яулык чөйгән.

Айсылу Сәвиянең тормышына кызыгып куйды. Сәвиянең күңеле тынычтыр. Яхшы кешегә кияүгә чыккан, баласы үсеп килә. Аны бернәрсә дә борчымыйдыр...

Ә ул әле үзен нинди язмыш көткәнен белми...

Ирләр дөнья хәлләре турында сөйләшеп утырдылар, Сәвия белән Айсылу икәүләп савыт-саба юдылар, ирләрдән качып кына бер-берсеннән яңалыклар сораштылар.

—Айсылу, синең Алабугада студент егетләрең бардыр инде?

—Егетләр бар инде ул, тик йөргән кешем юк.

—Синең ише чибәр кызга тынгы бирмиләрдер әле.

—Безне яратканнарны үзебез яратмыйбыз, без яратканнар үзебезне яратмый. Шундыйдыр инде ул мәхәббәт.

—Нигә алай дисең?

—Мин хәзер мәхәббәткә ышанмыйм да инде, Сәвия.

—Минем кебек юләр чакта гына җинелдер инде ул, акыл утырткач кияүгә чыгулары кыенрак диләр.

Озатканда Сәвия Айсылуны кочаклап алды, икесенең дә күңелләре йомшап, күзләре яшьләнде.

—Мисхәт МТСка баручы машина белән сөйләшеп куйган, хәзер килә,— диде.

—Сәвия, тигез яшәгез!

—Рәхмәт! Сина да бәхетләр телим, Айсылу! Үткәндә-сүткәндә безгә кер, хәзер инде кайда торганымны беләсең.

Җәүдәт белән солдат Айсылуны кыстый-кыстый кабинага утырттылар, үзләре кузовка менеп, салам өстенә ипләнделәр.

Каенлыкулгә җитеп, МТС янына туктагач, юлчылар үз юлына китәргә тиеш иде. Солдат Айсылудан аерыла алмады.

—Сез кайсы урамда торасыз?

—Нигә? Бакча урамында, базар очында.

—Мин килсәм, ачуланмассынмы, Айсылу?!

Кыз, ниһаять, солдатка беренче мәртәбә егетләргә караган кебек күз төшереп алды: болай, ярыйсы гына, озын буйлы, йөзгә дә чибәр. Ләкин ул Айсылуга малай-шалай кебек кенә тоелды. Егерме ике яшьлек кызга унтугыз яшьлек егет тиң була аламыни?!

—Белмим, үскәнем, мин кайчан китәсемне дә әйтә алмыйм, машина булса, бәлки иртәгә үк китәргә туры килер.

—Алай булгач, Алабугадагы адресыңны бирә алмыйсыңмы?

—Нигә?

—Хат язар идем, беләсеңме, армиядә бик сагындыра, хат килсә, шундый рәхәт була...

Айсылу уйлап-уйлап торды да, кичә солдатның ана булышканы исенә төшеп, адресын язып бирде. Хат язуы кыен эш түгел, җавап бирермен, дип уйлады.

Җәүдәт белән солдатның әле тагын кырыкмаса-кырык чара табып, авылларына кайтып җитәсе бар.

Өйләре якынайган саен Айсылуның аяклары тизрәк атлый. Үз урамнарына кергәч хәтта йөгерәсе килә башлады... Әнә Хәнифә апалар, аннан Гәрәев абыйлар, аннан без...

—Исәнме, әнкәй!

—Исәнме, кызым! Кайттыңмыни?! Октябрь бәйрәме белән котлап открыткаң килмәгәч, тәки кайтырсың дип көткән идем. Ничек болай иртән иртүк кайтып җитә алдың?

—Без Югары Табында кундык, кичә машина булмады.

Минлебану, самавырга күмер өстәде дә, торбасын мич авызына борып куйды. Коры агач алып чыра телде, мичкә ут кабызып җибәрде.

—Әтисе, син ит алып кереп тура, бәлеш салыйк.

Айсылу пәлтәсен чөйгә элде. Әни кеше кызыннан күзен алмады:

—Пәлтәң дә, күлмәгең дә бик матур булган, җылы тәнеңдә тузсын, өстеңнән өстәлсен! Кызым, сәламәтлегең ничек, хатыңны алгач, сине кызганып үлә яздым.

—Үтте инде, хәзер хәлем әйбәт.

—Әтиең миннән дә ныграк борчылды синең өчен, кайтып яхшы иткәнсең. Ичмасам күреп, тынычланып калабыз.

Айсылу әнисен бик яратса да, аның өчен әтисе идеал, ул аны чын коммунист—ленинчы булганы өчен ихтирам итә.

Әтисе Хафиз беренче империалистик сугыштан алып, гражданнар сугышы беткәнче бөтен яшьлеген окопларда, сугыш кырларында үткәреп, биш ел буе үлем эчендә йөргән. Егерме беренче елның август аенда авылына кайткач та шатлык түгел, коточкыч ачлык һәм үлем каршы алган.

Фронттан кайту белән аны Америкадан җибәрелгән азыклардан оештырылган туклану үзәгенә контролер итеп куялар. Монда балаларга кукуруз боткасы пешерәләр, хуш исле какао ясыйлар. Хафиз азыкның читкә китмәвен, балалар авызына керүен күз угында тота. Ул авыл буенча йөреп, балалар санын ала, ятимнәрне барлый, аларны туклану үзәгенә беркетә.

Ул коткарган балаларның килеп, әтисенә рәхмәт әйткәнен Айсылу хәтерли әле:

"Хафиз абый, сина гомер буе рәхмәт әйтеп яшәдек, син коткармаган булсаң, әллә кайчан ачтан үлгән булыр идек... Без, әти-әнисез ятим балалар, бер кисәк икмәккә тилмереп йөргәндә, Хафиз абый, син безне урамнан үзең белән ияртеп алып киттең, ашаттың... кирәкле документларны җыеп, Минзәлә балалар йортына җибәрдең. Менә без синең алда баш иярга, рәхмәтебезне әйтергә килдек!.."

Айсылу әтисен тагын бер нәрсә өчен аеруча ихтирам итә: әтисе белән әнисе гомер буе тату яшәделәр, алар гаиләсендә тавыш-гауга булмады. Хафиз өчен гаилә изге! Аларның татулыгына, бер-берсен олылап яшәүләренә кешеләр соклана.

Бер-берсеннән башка тора алмасалар да, ярату, мәхәббәт дигән нәрсәне алар тышка чыгармыйлар, сиздермиләр, балаларын да ничектер корырак тәрбияләләр. Алар Айсылуны да үбеп-кочып үстермәделәр. Кечкенә чакта йоклаганда гына, әтисенең килеп юрганын төзәтеп, аркасыннан сөеп киткәнен сизә иде ул.

Айсылуның әтисе белән әнисеннән ничек өйләнешкәннәрен бик беләсе килеп, шул турыда сорашканы бар...

—Әнкәй, сез әткәй белән кайда танышкан идегез? Ничек өйләнештегез?

—Безнең заманда танышып өйләнүчеләр сирәк булгандыр, кияүгә димләп бирәләр иде бит. Мин әтиеңне никах вакытында гына күрдем.

—Ничек инде бер белмәгән кешегә бардың?!

—Белмәгән дип, димче аша танышкан идем инде, кем икәнен белдем.

—Ничек курыкмыйча күрмәгән кешегә чыктың? Әгәр ул начар кеше булып чыкса нишләр идең? Әле ярый әткәйгә туры килгәнсең!

—Димчеләр дә юләр түгел инде, тора салып начар кешегә димләмиләр.
—Сине кем димләде соң?
—Безнең авылга Маһира исемле укытучы килгән иде, без аның белән танышып, дуслашып киттек. Мин дә заманасы өчен ярыйсы гына белемле, абыстайга йөреп укырга-язарга өйрәнгән идем. Шул Маһира апа бер тапкыр сүз башлады, минем бик акыллы бер энем бар. Сугышта йөреп, өйләнә алмаган, ана утыз яшь, бик белемле. Сине шуна димләсәм каршы килмәссеңме, диде. Мин шунда әллә нишләдем, үземнең дә укыган кешегә чыгасым килә инде, дигән булдым, әйтерсең үзем бик белемле кеше!..
Миңлебану үз-үзеннән көлеп куйды.
—Шуннан соң Маһира апа минем турыда әтиенә кайтып сөйләгән. Озак та тормый әтиең яучы җибәрде, аннан соң никах укыттылар. Әтиең безгә беренче тапкыр килгәч, мин чаршау артында тордым, күрәсем килсә дә карамадым, карасаң мәхәббәт сүнә икән, диләр иде. Сеңлем Фатыйма чаршау артына кереп юатты, түтәй, киявең бик сөйкемле, курыкма, диде.
Туй көне һич көтмәгәндә бер егет дуслары белән килеп тавыш чыгарды: ярты янак Хафизга Дәүләтша абзыйның чибәр кызын җибәрмибез, исән чакта кайтып китсен, ату үтерәбез, дип кычкырган. Югыйсә ул егетнең минем белән бер нәрсә турында да сөйләшкәне юк иде...
Икәү генә калгач, әтиең елады... Син мине яратмасаң да мин үпкәләмим, син бит фәрештә, диде.
Чыннан да, Айсылуның әтисенең уң янагы эчкә бөрешеп кергән. Сугышта снаряд кыйпылчыгы тиеп, янак сөяген, теш казналарын җимергән. Аның бу турыда Айсылуга сөйләгәне бар иде...
Мичтән бәлеш чыгаруга мунча да өлгергән иде...
Айсылу сеңелләре белән чыр-чу килеп мунча керде. Кызларны ләүкәгә яткырып, кычкырта-кычкырта себерке белән чапты, күбекләндереп чәчләрен юды. Апаларына иркәләнеп, Зөһрә белән Венера юри черелдәделәр...
Аларны юындырып чыгаргач, Айсылу ашыкмыйча гына, тәмен белеп үзе мунча керде. Ул шәһәр мунчасына күнегә алмый, җирәнә, кешеләрнең исен сөйми, үзенә текәлгән карашлардан читенсенә. Менә ичмасам авыл мунчасы мунча ул! Ап-ак итеп юылган идәнендә аяк таймый, ишек ачып керүгә кайнар суда пешкән мәтрүшкәле себерке исе җанны эретә.
Мунчадан соң әнисе Айсылуга карлыган кагы белән чәй эчерде.
Иртән калын ястыкта рәхәтләнеп йоклап ятканда Айсылуның сеңелләре ике ягыннан юрган астына кереп, апаларына сыенып яттылар. Айсылу аларның икесен дә кочаклап алды, аннан соң кабыргаларын санап кытыклый башлады. Кызлар, чыр-чу килеп, юрган астында тәгәрәделәр.
Айсылу институтка киткәндә, Зөһрә белән Венера әле мәктәпкә укырга кереп кенә калганнар иде, хәзер өченче класста укыйлар, буйга да тартылганнар...
Өйдә эшләр беткәч, Айсылу Зөлфирәләргә җыена башлады.
—Апа, кая барасың? Китмә инде!—дип сеңелләре ялына башлады.
—Озак тормыйм, хәзер кайтам,—дип тынычландырды аларны Айсылу.
Тышта салкын, җиргә юка гына булып кар яуган.
Зөлфирә дустының пәлтәсе белән шарфын ишек янына кадакланган болан мөгезенә элеп куйды.
—Пәлтәң дә, күлмәгең дә котлы булсын, малай, үзеңә бик килешә. Өстеңдә тузсын, шуларны киеп кияү куенына кер!..
—Рәхмәт, Зөлфирә.
Зөлфирәләрнең йорты зур, иркен. Түрдә зур агач тәпәндә эре челтәрле яфраклы, үрмә гөл утыра. Зөлфирәнең әнисе ул гөлне "аю табаны" дип атый. Яңгыр явасы булса аның яфрак очыннан су тама. Түбәсе түшәмгә тигән шул гөл артына кереп утырсаң, үзеңне джунглида дип хис итәсең.
—Айсылу, кайчан кайттың?
—Кичә иртән.
—И, шул гомердән бирле нишләп килми тордың?!

—Әнкәйләрдән, сеңелләремнән аерылып булмады. Мәктәптә ниләр бар?

—Элек ничек, хәзер дә шулай. Ике смена укытабыз. Иртән китәм, төнлә кайтам, класстан тыш нинди эшләр бар—һәммәсен миңа өяләр: дояркалар семинарына котлаулар әзерлим, демонстрациягә транспарантлар ясатам, түгәрәкләр оештырам, сборлар, ярышлар оештырам, һәм башкалар!.. Ярар ла, чукынып китсен эше, үзең турында сөйлә әле! Марс белән арагыз ничек?

—Берничек тә түгел, Уфага киткәч, бер хат салган иде. Хат дисәм дөрес булмас, конверт эченә "Кызыл таң" газетасын салган. Аның бик зур бер хикәясе басылган иде. Шул газетада әдәби хезмәткәр булып эшли икән. "Менә күр, мин нинди кеше!"—дип мактанасы килгәндер инде. Мин хәзер аның турында уйламыйм, ничә ел гомерем шуның өчен газапланып үткәнгә үкенәм.

—Чистый юньсез булып чыкты бу Марс! Мин аны болай булыр дип уйламаган идем! Синең кебекне ул үлгәндә дә, ике кулына шәм яндырып эзләсә дә таба алмый!

Зөлфирәнең чын күңелдән өзгәләнеп әйткән сүзләре Айсылуның кәефен күтәрде.

—Госманнан хат киләме?

—Хаты килә, тик язарга мачтыр түгел, хатлары коры. Минем янда үзе бик юхалана, үзе "яратам" дип кенә тора, хатында мәхәббәт турында ник бер сүз булсын!

—Ул бит инде яшь малай түгел, мәхәббәте йөрәгендә булгач, чәчәклечуклы хатлары нигә кирәк? Өйләнешү турында язмыймы соң?

—Ләм-мим. Мин курка башладым инде. Ул Куйбышевта, мин монда. Берәр маржа башын әйләндерсә нишләрсең?

Зөлфирә матурлана төшкән: чәчен кыска итеп кистергән, яшүсмер чактагы тулылыгы кимеп, йөзе озынчаланган, күзләре зураеп, сөрмәләнеп калган. Матур ак кулына маникюр ясаган.

—Бүген клубта бәйрәм кичәсе. Рәхәтләнеп ял итәргә ярый әле бәйрәмнәр бар. Син кайчан китәсең?

—Иртәгә.

—Шулай ук тизмени? Нигә тагын берәр көн тормыйсың?

—Болай да дүрт көн була инде, ике көн юлга китә.

—Син булмагач, миңа бик кыен, дуслашыр кеше юк. Әй, әйтергә онытып торам икән, исеңдәме, безнең класста Хәкимова Илсөяр укыган иде? Шуның абыйсы Илһам безгә хирург булып кайтты.

Айсылуның бу исемне ишеткәне бар иде инде. Әнисе бик мактап телгә алган иде. Кабат ишеткәч әллә нишләп китте. Белгәнен сиздерәсе килмичә:

—Шулаймыни?—диде.

—И кызыкны белсәң! Безнең авыл кызлары аны кулга төшерер өчен әлләни кыланалар, больница кызлары юк сәбәпне бар итеп, атна саен вечер оештырып чакыралар, ди. Илһам белән корреспондент Әпүш дус, шул сөйләде.

Айсылуның йөрәген нидер чеметеп алгандай булды, әллә больница кызларыннан көнләште инде?

—Нишләп шул кадәр исләре киткән, районда башка егетләр беткәнмени?

—Што син! Яшь хирург менә дигән кандидат инде! Газета саен мактап язалар. Кияүгә чыгарга тилмереп йөрүчеләр азмыни?!

Бу сөйләшүдән соң Айсылуның Илһамны күрү теләге тагын да артты...

Кызлар клубның ишеген ачып керүгә, түрдәге өстәл артында шахмат уйнап утыручы егетләр аларга күтәрелеп карадылар. Айсылуның иң беренче күргән кешесе күк костюм кигән, аксыл чәчле бик интеллигент кыяфәтле егет иде. Аның янында утырган Әпүшне таныгач, Айсылу теге егетнең Илһам икәнен шундук аңлады.

Илһам шахмат фигурасын тоткан килеш Әпүштән:

—Бу нинди кыз?—дип сорады.

—Яшел пәлтәлесен әйтәсеңме?

—Шуны инде, шуны!

—Ул Айсылу, студентка. Быел жәй пионер лагерена практикага кайтты. Ну, парень, шәп тә кыз инде! Телисенме, таныштырам?! Ихтимал, сина повезет, мин ул бәхеткә ирешә алмадым...

Чишенеп урындыкларга тезелешеп утырган яшьләр музыка уйнавын көтә. Менә киномеханик, будкасынын тәрәзәсен ачып, радиоланы кушып жибәрде. Музыка уйный, ләкин бер парнын да беренче булып чыгарга кыюлыгы житми тора.

Айсылунын залнын икенче башында утырган Илһамга карап: "чакырсын иде, мине танцыга чакырсын иде!"—дип теләве булды, Илһам урынынан торып, залны кисеп үтеп, Айсылу каршысына килеп басты:

—Сезне чакырырга мөмкинме?

Айсылу елмаеп урынынан торды, кулын Илһамга сузды, икенчесен егетнен иненә салды. Ул, теләге кабул булганга сөенеп, үзен бик бәхетле сизде. Илһамга күтәрелеп карагач, аларнын күзләре очрашты. Илһамнын зур яшькелт-зәнгәр күзләре анын йөзенә төбәлгән, карашы бик житди, ниндидер сорауга җавап көтәдер сыман.

—Сез Айсылу бит, шулаймы?

—Әйе, ә сез Илһам...

—Менә, кечкенәдән таныш булунын әйбәт яклары бар. Мин сине яхшы хәтерлим, Айсылу.

—Ничек исендә калды икән?! Син бит бер дә мина илтифат итмәгән кебек иден.

—Киресенчә, нык истә калган. Син ул вакытта ук бик сөйкемле кыз иден.

Илһам үзен кыю тотса да, Айсылу анын дулкынланганын сизде: танцыга чакырганда куллары хәтта дерелдәп китте, салкынча учлары бераз тирләп чыкты, ул кесәсеннән кульяулык алып, мангаен сөртте. Егетнен бу халәте Айсылуга ошады—димәк, Илһам аны хөрмәт итә, аннан бераз унайсызлана, хәтта ошарга тырышуы да сизелә. Шуна күрә Айсылу үзен бик тыныч тотты. Егетнен кин мангаена төшеп бераз дулкынланып торган чәчләре, грекларныкына охшаган озынча борыны, матур уелган калын ирене, спорт фасоны белән тегелгән күк костюмы—һәммәсе Айсылуга бик матур, бик якын тоелды. Пинжәгеннән сизелер-сизелмәс кенә килгән йод һәм эфир исе кызны бигрәк тә дулкынландырды, егеткә ниндидер сафлык өстәгән кебек булды.

Кызлар белән күп чуалса да, Илһамнын монарчы бу кадәр үк югалып калганы булмады. Бүген ул каушавын яшерә алмады. Айсылу анын бөтен йөрәген, күнелен биләп алды, бу хис шундый көчле, егет үзен исереп киткәндәй тойды. Һәр яңа музыка уйнаган саен, аяклары ихтыярсыз аны Айсылу янына илттеләр. Илһам бер күрүдән гашыйк булды! Ул үзенен хисләренә ышанды: бу кыз анын көткән яры! Алар бүген үк анлашырга тиеш.

Ләкин егетнен бүгенге теләгенә каршы төштеләр...

Ак халат өстеннән сырма кигән хирургия санитаркасы халык арасыннан Илһамны эзләп тапты:

—Илһам Салахович, сезгә хәзер үк килеп житәргә куштылар!

—Ни булган?

—Милиция начальнигы үзенә үзе аткан.

—Исәнме?!

—Юк, шундук үлгән.

—Ярар, мин хәзер барып житәрмен.

Хәвефле урынга чыгып йөгергәнче Айсылу белән саубуллашырлык кына мөмкинлек бар иде әле.

—Унайсыз хәлдә калдым, мина китәргә кирәк, ләкин әйтәсе сүземне әйтми китә алмыйм. Ачуланма, Айсылу, син мина бик ошыйсын! Ошау гына дип тә әйтеп булмый! Әгәр безгә тагын берничә мәртәбә генә очрашырга мөмкинлек булса...

Айсылу мондый ук сүзләр көтмәгән иде. Ул аптырабрак калды. Ни

әйтсен? Беренче танышкан көнне үк вәгъдәләр бирсенме?

—Сина китәргә кирәк... Ярар, Илһам, мин сина бер генә нәрсә вәгъдә итә алам: хат язсаң, җавап бирермен!

—Рәхмәт, миңа хәзер анысы да бик кадерле.

Илһам ашыгып китеп барды. Айсылу Илһамнын аяк тавышлары тынганчы өнсез торды. Ул үзенең тормышында зур үзгәреш буласын анлады.

Йокларга яткач, шушы өч көн эчендә булган вакыйгаларны күздән кичерде... Менә ни өчен бозлы елгалар кичеп, көзге юллардан җәяүләп кайтканмын икән?! Илһам тартып кайтарган! Бу минем язмышымдыр...

***

Ашыга-ашыга милиция начальнигы йортына барганда, Илһам эченнән генә сүгенеп барды: "Тапкан атылыр көн, дурак! Иртәгәгә кадәр генә көткән булса... бәлки атылмаган да булыр иде!.."

Илһам килеп кергәндә, тар гына ишек алдында берничә кеше бар иде. Җирдә яткан гәүдә янында ике кеше басып тора: озын гәүдәлесенең баш врач Смирнов, анын янындагы тәбәнәк юан гәүдәлесе райком секретаре Исмәгыйлев иде. Илһамны күргәч Исмәгыйлев җикеренергә тотынды:

—Кайда йөрисең, молокосос?! Ник чакыргач та килмәдең? Монда синнән важныйрак кешеләр дә момент җыелды.

Илһамның ачуы бугазына тыгылды. Моңа кадәр әле беркемнең дә аны болай мәсхәрәләгәне юк иде.

—Үлгән кешегә врач нигә кирәк, милиция чакырыгыз!

—Молчать!—дип акырды Исмәгыйлев.

Смирнов, яшь врач әллә ниләр әйтеп җибәрмәсен тагын дип, сүзне икенчегә борырга ашыкты:

—Үзенә үзе атуы билгеле инде, шулай булгач мәетне монда яткырмыйк, өенә кертеп салырга кирәк.

Шул сүзләрдән соң гына Илһамга бу ишек алдында нинди фаҗига булганы барып җитте. Ул баскычта әниләренә сыенып өч баланың елап торганын күрде. Аларны кызганудан йөрәге кысылып, авыртып куйды. Ярты сәгать элек кенә бу йортта тыныч тормыш булган, балалар җылы, якты өйдә үз эшләре белән шөгыльләнгән. Пистолет шартлавы аларны мәңгегә ятим иткән. Ни сәбәпле? Ни өчен?

Милиция начальнигының гәүдәсен өенә кертеп салгач:

—Кирәк булсам чакыртырсыз,—дип кайтып китте.

Илһам бик озак йоклый алмый ятты. Бүген кич булган хәлләрне берәмберәм исенә төшерде. Айсылуның нәфис гәүдәсен, сөйкемле йөзен күз алдына китерде...

Бала чагы һәм яшүсмер еллары үткән бу районга яңадан килеп чыгармын дип беркайчан да уйламаган иде Илһам. Ул шушында урта мәктәпне тәмамлаган елны әтиләрен башка районга күчерделәр. Илһам алга таба да укырга керергә җыена иде. Әтисе аңа хәрби училищега керергә киңәш бирде.

—Улым, хәрби училищега керсәң, укуы җинел булыр. Анда киендерәләр дә, ашаталар да, бар да бушлай. Укып чыксаң, тормышың да җинелрәк була, офицерларның зарплатасы зур. Институтка барсаң, мин сине укыта алмыйм, мөмкинлегебез юк.

Бу сүзләрдә хаклык бар иде: алты баланың әле берсе генә үз көнен үзе күрә, Дилфәр апасы медицина институтында укый, калганнары мәктәптә. Бер зарплатага ике баланы институтта укыту мөмкин түгел. Акылы белән аңласа да, Илһамның гомер буе шинель киеп, хәрби кысада ирегеп югалтып, хезмәт итеп яшисе килмәде. Әтисенең сүзен тынламыйча, Казанга, апасы укыган институтка китте. Конкурс зур булса да, имтиханнарны уңышлы тапшырып, керә алды. Әтисе ачуланмады, тик катгый рәвештә:

—Минем сүземне тынламадың, улым, үпкәләмә, ләкин мин сиңа бер тиен акча да җибәрә алмыйм. Гаилә авызыннан соңгы сыныкны тартып

алып булмый. Кергәнсең икән, укы, тик үзең җаең тап!

Илһам моның шулай буласын аңлады, чөнки ул әтисенең үз сүзендә торасын белә!..

Ул тырышып укыды, сәләтле егет тора-бара югары стипендия алды. Студентлар арасында дәрәҗәсе дә зур булды, аны курсларының комсомол оешмасы секретаре итеп сайладылар. Бөтенләй үк ярдәмсез дә калмады, Казанга якын районда яшәгән апасы йә бәрәңге, йә ит җибәреп торды. Райкомда эшләгән җизнәсе, Казанга килгәч, акча да биргәләде.

Илһамның бөтен теләге хирург булу иде, шуның өчен югары курсларда шәһәр больницасына төнге дежурлыкка йөри башлады. Тәҗрибәле врачлар белән бергә операцияләрдә катнашты, алар күзәтүе астында катлаулы булмаганнарын үзе ясады.

Илһамга тормышта гел яхшы кешеләр очрап торды. Фатир хуҗасы тетя Соня шундыйларның берсе иде. Илһам Суконныйда—ярлылар бистәсендә яшәде. Тетя Соня ашханәдә эшли, итләре юнылган сөякләрне күтәреп кайта да, зур кәстрүлдә кәбестә ашы пешерә. Сөякле иттән пешкән аш бик тәмле була. Киң күңелле тетя Соня тирән чәркәгә аш сала да Илһамны чакыра:

—Илюша, иди кушать!

Бу рус хатыны һәрчак шат күңелле, тормыш авыр дип, борынын салындырып утырмый, шаяртырга ярата. Үз улының ашыга-ашыга кәбестә шулпасы чөмергәнен карап тора да:

—Кушай, сынок, кушай!—ди. Аннан соң көлеп:—ну и здоров ты жрать! И учился бы так!—дип, өстәп куя.

Апасы күчтәнәч җибәрсә, Илһам да хуҗаларына өлеш чыгара.

Ярым тук, ярым ач еллар үтеп китте, Илһам институтны кызыл дипломга тәмамлады. Дәртләнеп эшкә китәргә торганда күңелсезлек килеп чыкты: аны бер врачы да булмаган яна участок больницасына билгеләделәр. Егетнең мондый авыл больницасында берүзе генә эшлисе килми, зуррак коллективта эшләү турында хыяллана иде. Операция ясарга бүлмәсе дә булмаган авыл больницасында нәрсәгә өйрәнәсең? Анда белгәнеңне дә онытып бетерерсең...

Август уртасына эшкә чыгарга тиеш булса да Илһам бармады. Ул сәламәтлек министрлыгына китте. Аны министр урынбасары кабул итте.

—Мине нинди дә булса район больницасына җибәрүегезне сорыйм,— диде Илһам.

—Молодой человек, а кто будет работать там, куда вас направили?? Если все будут отказываться, что же получится? Не волнуйтесь, отработаете свои три года, а потом делайте, что хотите. Мы не можем менять решение комиссии,—дип, берәгәйле җавап бирде урынбасар.

Илһам урынбасар кабинетыннан борчылып чыкты, тик барыбер анда китмим, судка бирмәсләр әле, эшне үзем дә табармын, дип, үз-үзен үҗәтләнеп юатты ул.

Коридорга чыккач, аңа озын буйлы, сөйкемле генә бер кеше очрады һәм таныш сыман тоелды.

—Сез Хәкимов түгелме?—дип сорады ул.

—Әйе, мин.—Илһам аны таныды. Бу Каенлыкүл больницасының баш врачы, хирург Смирнов иде.

—Әле монда нишләп йөрисең?

Илһам үзе белән булган хәлне сөйләп бирде.

—Мин хәзер министр янына керәм. Безнең больницага хирург кирәк, министр белән сөйләшәм, син көтеп тор.

Смирнов яхшы хәбәр белән чыкты.

Шулай итеп, Илһам үзе үскән авылга кайтып төште.

Монда килмәгән булсам, Айсылуны очратмаган булыр идем, ди ул. Ярый әле министрлыкта Смирнов очрады...

Тормыш катлаулы: берәүләргә шатлык килә, икенчеләргә кайгы. Илһам милиция начальнигының балаларын күз алдына китерде... Ничек шул яшь кенә хатынын өч баласы белән ятим калдырырга уйлаган, ничек

кызганмаган? Әчкән иде микән? Хатыны белән араларында берәр нәрсә булды микән?.. Үлгән кешегә бернинди ярдәм итү мөмкин түгеллеген белсә дә Илһам өч балалы хатын алдында үзен гаепле итеп тойды, чөнки ул бүген бик бәхетле иде...

***

Алабугага авылдан китүе җиңелрәк. Кичтән әнисе бензовоз шоферына барып белешеп кайтты да, иртән Айсылуны озата чыкты.

Айсылу әче тулы шатлыкны әнисенә чишми булдыра алмады:

—Әнкәй, мин кичә теге яшь врач белән таныштым, хат алышырга сүз бирештек. Аның исәбе бик җитди.

Әнкәсе бер сүз дәшмәсә дә, эченнән шатланды гына.

Машина кузгалып киткәч, әнисе кул болгап калды. Кыз әнисе күздән югалганчы кабина тәрәзәсеннән карап барды. Мамык шәл, йомшак кара жакет кигән, ак йон бияләйле кулын болгап калган әнисе бик озак күз алдында торды... И әнкәем! Күпме шулай озатып калдың син мине!.. Нинди бәхетле идем мин ул чакларда! Син изге җан булгансыңдыр—мина теләгән теләкләрең кабул килде, рәхмәт, газиз әнкәем!... Мин дә үз балаларыма синең кебек изге ана була алсам иде, Ходаем!

Ике-өч көннән Айсылуга әлләни булды: ул Илһамның йөзен онытты. Никадәр тырышса да, ирене өстендәге җәрәхәттән башка бүтән җирен һич күз алдына китерә алмады. Ул Илһамны югалткан кебек тойды, тизрәк нәрсә булса да эшлисе килде. Әллә өйгә кайтып килергәме, дип тә уйлады. Күрәсе килә, ичмасам йөзе күз алдымда торсын иде!..

Көн буе баш катырып йөргәч, кичкә таба нәрсә эшләргә кирәген уйлап тапты. Киенде дә почтага китте. Анда аңа:

—Бүген сөйләшә алмыйсыз, вызовны иртәгә кичке алтыга гына биреп була,—диделәр.

Икенче көнне кичке алтыны түземсезлек белән көтеп алды. Авылы белән элемтәгә кергәнне көтеп тирләде, пеште, йөрәге чабыш атыныкы кебек типте.

—Каенлыкүл!—дигән чакыруга, атылып-бәрелеп кабинага керде.

"Айсылу, синме бу?"—дигән шундый сөйкемле тавышны ишеткәч үк, Илһамның йөзе Айсылуның күз алдына килеп басты.

—Мин бу, мин!

—Бер нәрсә дә булмадымы? Хәлең ничек?

—Яхшы, бик яхшы. Синең тавышыңны ишетәсем килгәнгә генә чакырдым.

—Минем дә синең тавышыңны бик ишетәсем килә иде!

—Синең сүзләрең турында уйлап йөрим.

—Айсылу, мин дә гел синең турыда гына уйлыйм!

—Хат яздыңмы соң әле?

—Яздым, озакламый барып җитәр.

—Озак, монда хат озак йөри, ун көн. Син минем янга үзең килә алмыйсыңмы?

Илһам аз гына эндәшми торды.

—Мин эштә бит, Айсылу. Эш ташлап китү өчен җитди сәбәп кирәк.

—Юк, мин болай гына әйтәм, килеп йөрмә. Озакламый тагын каникуллар җитә, үзем кайтырмын.

—Каникулга ерак шул әле.

—Синең хәлләр ничек соң?

—Минем хәл һәрвакыттагыча: өй—больница, больница—өй, эш күп монда, тере тәнне ярабыз, тегәбез, ямыйбыз. Синең эшләр ничек?

Бераздан ике арада:

"Ваше время истекает, заканчивайте!"—дигән калай тавыш ишетелде.

Салкын һавага чыккач, караңгы күктә җемелдәгән йолдызлар да, томанлы кыршау эчендәге тулган ай да кызның шатлыгын аңлыйлар, ана җемелдиләр,

аңа яктырталардыр, аяк астындагы шыгырдавык карнын бриллиант тәнкәләре анын өчен генә җәймә булып чәчелгәндер кебек тоелды.
Телефоннан сөйләшкәннән соң бер атна үткәч, Нәҗибә бүлмәгә тыны бетеп йөгереп керде:
—Айсылу, бие!
—Кая, хат бармы әллә?!
—Бие, бие, аннан сорарсың!
Айсылу биегән атлы итте һәм түземсезләнеп:
—Бир инде тизрәк!—диде.
Адресы тигез, матур итеп язылган хат Илһамнан иде.
—Тагын бие!—дип, Нәҗибә янә әмер бирде.
—Әллә тагын бар?
—Бар шул, апаем, бие! Яки көзгегә карап өч тапкыр: "Их, мин матур да соң! Их, мин чибәр дә соң!"—диген!
Айсылу көлеп җибәрде. Кызларның көзгегә карап андый тәҗрибә ясаганнары бар: көзге алдында, үзенә теге сүзләрне әйтә алмыйча, дивана кебек көләсең дә көләсең.
—Ярар инде, интектермә, бир хатны! Шуның өчен бүген кичкә тәмле әйбер пешерермен!
—Чынлапмы? Ни пешерәсең?
—Нәрсә ашыйсың килә соң?
—Кыстыбый!
—Ярар, он житәрлек булса пешерермен.
—Житәр, житәр, житмәсә үзем табып бирермен! Мә хатынны!
Айсылу хатны алды да үзенең караватына барып утырды. Хатларның икесе дә Илһамнан иде. Ул кайсын укырга да белмәде, ниһаять, хатларның числосын карап, алдан язганын ачты.
Айсылу, дөньясын онытып, Илһамның хатын укый:
*"Исәнме, Айсылу!*
*Миңа карата мөнәсәбәтеннән яхшы икәнен күңелем белән аңласам да, йөрәгем тыныч түгел. Безнең танышу бик ашыгыч булды, ул арада гына ничек бер-беребезне аңлыйсың да, ничек итеп дуслык ныгып өлгерсен?! Сине югалтудан куркып, күңелемә шик килә, гафу ит!*
*Мин сине үсмер чагыңнан ук беләм. Сеңлем янына безгә килгән вакытта син миңа ничектер кырын караган кебек тоела идең. Без ул чакта үсмерләр генә булсак та, матурлыкны аера белә идек инде. Сине табигать нәфис итеп яраткан. Синең кебек кызны әле минем очратканым юк дисәм, баналь сүз булыр, ләкин ул дөрес. Минем яшьтәге кеше инде тормыш турында уйлый, андый фикер гел синең янга илтә.*
*Ах, шайтан алгыры, тагын чакырып килгәннәр, хатны больницадан кайткач язып бетерермен, хуш!..*
*Гафу ит, кичә язып бетерә алмадым, бик соң кайтырга туры килде... Бүген дәвам итәм..."*
Айсылу хатларны кабат-кабат укыды. Бүлмәдәге кызлар хатның кемнән килгәнен белергә теләсәләр дә, сорамадылар.
Хатларны укыгач, кызның җаны бераз тынычланды. Илһамның аны яратуына, максатының житдилегенә ышанды, шуңа күрә, дуслары белән сөенечен уртаклашасы килеп, серен үзе ачарга булды:
—Кызлар, бәйрәмгә кайткач мин бер хирург егет белән таныштым, бу хатлар аныкы.
—Хирург? Ни исемле?—дип сорады Нәҗибә.
Кызлар, Айсылу янына җыелып, ике караватка тезелешеп утырдылар.
—Илһам исемле. Быел көз безнең районга эшкә килгән.
Әлфия тумбочка өстендәге хатларга карап:
—Мин Марстан килгән дип уйлаган идем,—диде.
Каенлыкүл телефонисткалары—"сер тотмас үрдәкләр" икән, Айсылу белән Илһамның телефоннан сөйләшкәннәрен тыңлап торып, түкми-чәчми, яшьләр арасында артыгы белән тараттылар. Хәтта, "Илһам Айсылуга өйләнә

икән",—дигән сүз дә чыкты. Бу хәбәрне күрше кызлары Уфадагы Марска да язып салды.

Декабрь башларында Айсылуга Уфадан телеграмма килеп төште: "За все прошлое прощаю, если желаешь, вернись!"—диелгән иде анда.

Марсның телеграммасын укыгач, Айсылуның ачуы чыкты. Нинди гаебен кичермәкче икән? Фазыл белән танышуынмы?! Кисәк кенә исенә төшергән, әллә Илһам белән танышканын ишетте микән?..

Айсылуга монсу булып китте. Ничә еллар Марс белән бергә булу турында хыялланып яшәгән иде, менә хәзер ул мөмкинлек тугач, аның никтер, шатланасы килми. Ул үзен мәхәббәтенең кабере янында утырган кебек хис итте.

Телеграммага җавап килмәгәч, Марс Айсылуны телефонга чакырды.

Кыз почтага соңгы сүзен әйтергә дип китте.

"Миңа яңадан телеграмма да салма, хат та язма, сөйләшергә дә чакырма!"—диде Айсылу.

"Кияүгә чыгасыңмы?"

"Сорап килсә чыгам."—Айсылу шат тавыш белән кычкырып көлде.

"Нигә көләсең?"

"Кәефем әйбәт."

"Ә безнең мәхәббәт нишли?"

"Безнең мәхәббәтне син үзең тирән итеп күмдең. Өфе каласында матур башкорт кызлары күптер әле, бер дә аптырамыйсыңдыр!"

"Миңа синнән башка кыз кирәкми."

"Сиңа минем дә кирәгем булмады! Ярар, иске җырларны җырламыйк инде..."

Айсылу телефон трубкасын элеп куйды. Аның күңелендә әрнү дә, борчылу да, үпкә дә калмады. Үзен бер сөеп, бер ташлап, бәгырен корыткан беренче мәхәббәтен ул гафу итте, чөнки ул Илһамга карата булган мәхәббәтеннән үзен бик бәхетле сизә, ә бәхетле кеше киң күнелле була...

Беренче җавап хаты алгач, Илһамның түземлеге бетте, Айсылуны күрәсе килеп тилереп йөрде дә, баш врач Смирнов янына керде.

—Аркадий Александрович! Миңа өч көнгә ял бирегез әле, Алабугага барып кайтам.

Смирнов больницада хатын-кызларның Илһам турында чыш-пыш килеп сөйләшкәннәрен хатыны аша ишеткән иде инде, эшнең нәрсәдә икәнен аңлады.

—Ярар, барырсыз, ләкин озак тормагыз, отчет вакыты житте... Больницада сезне өйләнергә җыенасыз икән дип сөйлиләр. Гафу итегез, бәлки бу минем эш түгелдер, ләкин өлкән коллегагыз һәм шефыгыз буларак, сезгә киңәш бирәсем килә. Сез бер студенткага өйләнергә телисез икән. Ялгышмыйсызмы? Аны бит әле ничә ел укытасыгыз була, аннан соң профессияләрегез дә туры килми. По-моему, сезгә бик пар кыз үзебезнең арада да бар. Зәйтүнә Сөләймановна бик уңган кыз, ул үзе дә сезне ошата бугай...

Тормышына тыкшынып йөрүләренә ачуы килсә дә, Илһам тыныч кына җавап бирде:

—Минем өчен кайгыртуыгызга рәхмәт, ләкин кем кирәген мин үзем генә хәл итим инде.

Алабугада гостиницага кереп, администратордан Илһам бүлмә яулап алды:

—Кеше өйләнергә килгән, понимаешь, сез бөтен шартын тудырырга тиеш!

Телефоннан сөйләшкәч, Айсылу дүртенче катка йөгереп менде:

—Кызлар, Илһам килгән, ул гостиницадан шалтыратты!

Бу хәбәр аяз көнне күк күкрәгән кебек булды, кызларның төрлесе төрлечә юрады:

—Юньлегә килмәгән инде ул.

—Юкны сөйләмә әле!

—Өстенә нәрсә киеп барасың?

Егет белән очрашырга баручыны бүлмәләре белән киендереп озатырга өйрәнгән кызлар, Айсылуның ни киясен, ничек бизәнәсен тикшереп, шаулаша башладылар.

—Лиданың крепдешин итәген сора!

—Ин килешкәне үзеннең йон күлмәген, шуны ки!

—Иренеңә иннек сөрт!

—Сөртмә, Илһамның күлмәген буярсың!

Айсылу үзенең күлмәген киде, мине ул шушы күлмәгемнән күреп яратты,—диде.

Институтның авыр ишеген ачып чыгуга, салкын һава куырып алды. Декабрьнең чатнама суыгы кешеләрне өйләренә куып керткән, автобус тукталышында бары бер генә кеше бөрешеп басып тора.

Салкыннан тәрәзәләре бозланып каткан автобус "эһ" дигәнче ике тукталышны үтеп, гостиница янына килеп җитте.

Ике катлы агач бинаның баскычыннан менгәндә, Айсылуны курку биләде: монда үзен ни көткәнен түгел, кешеләр арасында Илһамны танымыйча хур булырмын дигәнен уйлады ул. Бит аны бары тик бер генә мәртәбә күрде, анысы да кич белән...

Коридорга кергәч, ишек катындагы агач кәнәфигә сыенды. Карангырак коридор буйлап түр якка бер кеше китеп бара. Менә ул ишек ябылуга борылып, Айсылуга таба килә башлады. Караңгы булса да, Айсылу аны танып алды. Илһам Айсылу янына ашыга-ашыга килде дә, кулларыннан тотып, дигәндәй, кәнәфидән торырга булышты.

—Исәнме, Айсылу!

—Исәнме, Илһам!

Бер кешелек кенә кечкенә номер иде.

Алда бер карават, уртада өстәл, ике урындык, почмакта кием шкафы тора.

Илһам Айсылуга чишенергә булышты, киемнәрен шкафка элеп куйды.

Икесе өстәлнең ике ягында торып калдылар. Күзләр бер-берсенә төбәлде.

Илһамның өстендә беренче очрашкандагы костюмы, вак шакмаклы фланель күлмәге.

Айсылуга әйтәсе сүзләрен күнеленнән ничәмә-ничә кат кабатлаган булса да, дулкынлануыннан иреннәре кипшеде.

Илһам ике кулы белән урындык аркасын кысып тотты да, ни булса шул булды дигәндәй, тәвәккәлләде.

—Ну вот, дочь моя, ты звала и я приехал. Согласна ли стать женой уездного костоправа?

Айсылу Илһамның ничек борчылганын тойды, аның дулкынланудан тагын да матурланган йөзенә карап елмайды да:

—Согласна,—диде.

Илһам Айсылу янына килеп, аны кочаклап, кайнар иреннәреннән үпте. Айсылу Илһамның әз генә йод һәм эфир исе килгән иненә башын куйды. Бу күкрәк аны гомер буе тормышның авырлыкларыннан саклаячагына, бер күрүдән кабынган мәхәббәтләренең мәңгелек булачагына ышанды. Ул күтәрелеп Илһамның йөзенә карады: егетнең күзләре сөю ялкынынннан балкып тора.

Илһам бармагы белән Айсылуның тигез ак маңгаеннан, кечкенә төз борыныннан, иреннәреннән матур иягенә кадәр йомшак сызык сызган кебек төште дә, кул сырты белән ияген иплән кенә күтәреп кызның күзләренә карады.

—Айсылу, син мине яратасыңмы?

Кыз көлеп җибәрде.

—Нигә көләсең?

—"Согласна!" дигәч инде, ник кабат сорыйсың?

—Шатлыктан! Мин сине бер күрүдән үк яраттым!

Алар кычкырып көлделәр.

—Чыннан да, беркем дә кем өчен туып-үсәсен алдан белми. Үзенә насыйп ярны бар кеше дә таба алмыйдыр.

—Безнең бәхет бар икән—табыштык бит. Синең әниең минем өчен нинди матур кыз үстергән.

Илһам, Айсылуның яңакларын куллары белән сыйпап, тагын үбеп алды. Айсылу Илһамның кулларын үз куллары белән каплады, үзен иркәләгән йомшак кулны учына алды:

—Синең кулларың шундый йомшак! Минеке дә хәтта болай ук түгел!

—Гиппократ: "Хирургның йөрәге арысланныкы кебек, күзе—бөркетнеке, кулы кызларныкы кебек булырга тиеш",—дигән. Йомшак кулның сере бер генә: көн саен йод һәм спирт белән югач иске тире кубып тора, яңасы чыга тора.

—Йөрәгеңнең арысланныкы кебек икәненә ышандым инде: гомер эчендә бер мәртәбә күргән кызга өйләнергә дип курыкмыйча килгәнсең!

—Мин сине гомер буе беләм! Син үзең дә бик батыр кыз—бер мәртәбә күргән кешегә кияүгә чыгарга риза булдың. Чынлап та син минеке микән?! Төш кенә күрмимме? Тагын бер кат әйт әле, Айсылу, син чынлап та мине яратасыңмы? Без бергәме? Айсылу аның күкрәгенә сыенды да, дулкынланып:

—Каеннарга кадәр бергә!..

Илһам аны аңлады. Ул каеннар әле бик еракта булсалар да, кайчандыр бер аерылырга туры киләчәге йөрәген өшетеп алды. Ул кызны ныгытып кочты, Айсылусыз бер генә көн дә яши алмаячагын тойды.

Алар бер-берсеннән күзләрен алмыйча утырдылар.

—Илһам, без бит синең әти-әниең белән сөйләшмәдек.

—Вакыт бик тыгыз булды, Айсылу, өйләнешкәч хәбәр итәрбез әле.

—Үпкәләмәсләрме соң?!

—Үпкәләмәсләр. Алар мина ышаналар.

Чынлап та, Илһам бу көннәрдә әти-әнисе турында бөтенләй оныткан иде, чөнки бу арада Айсылудан башка кеше турында уйлый алмады.

Алты бала үстерүнең әти-әнисенә нинди авыр булганын уйлап, Илһам картларын сагынып куйды. Ул әнисен аеруча нык сагына. Әнисе исенә төшкәч, бала чагындагы бер дулкынландыргыч вакыйганы өр-яңадан кичергән кебек хис итте.

Кырык дүртенче елның июнь аенда Илһамның әнисе төпчек улын тапты. Каты сугышлар барган вакыт, халык ачлыктан иза чигә. Әнисен больницага алып киткән көннең икенчесендә Илһам иртүк торып, ике кармак алып Ык буена китте. Көн бик җылы, тыныч, җилнең әсәре дә юк. Кешеләр йөрми торган урынгарак барып, кармакларын салды. Озак көтәргә туры килмәде, бер кармакның калкавычы суга чумды. Кояшта кызылканатның көмеш тәңкәләре ялтырап китте. Хәтсез зур кызылканатны Илһам чокырга салып, өстен үги ана яфрагы белән каплап куйды.

Көне туры килгәнгәме, әнисенең бәхетенәме, балык гел эләгеп кенә торды. Күбесе кызылканат. Балыкларын бауга тезеп, кармакларын җыеп, малай йөгерә-йөгерә өйләренә кайтып китте. Балыкны чистарткач, кыздырырга май эзләсә дә, таба алмады.

Күрше хатыны иртән сыерларын савып, сөтне чоланга куйган иде, Илһам сөтнең өстен чүмеч белән җыеп алды да табага салды. Балык кызгач, кетәктән алып кереп табага ике йомырка сытты.

—Гайшәбикә апа, улыгыз сезгә күчтәнәч китергән.—Акушерка таба белән балык кертеп куйгач, Гайшәбикә торып тәрәзәгә килде. Анда уникe яшьлек улының елмаеп басып торганын күреп елап җибәрде.

—Рәхмәт, улкаем! Үзең ашадыңмы соң?

Ашамаган булса да, Илһам әнисенә карап:

—Ашадым!—диде.

—Улым, китми тор, хәзер,—дип, әнисе тумбочкадан малайга берничә коймак алып бирде.

Әнисенең сөенеченнән елавын Илһам беркайчан да онытмый...

Бер тапкыр, прокурор әтисенен өйдә юклыгыннан файдаланып, Илһам анын пистолетын яшергән жирдән эзләп тапты. Илһамнын бик куптәннән чын мылтыктан атып карыйсы килә иде. Сугыш әле яна гына туктаган чак, малайларнын бар уйнаганнары—сугыш.

Илһам, кулына чын корал эләккәч, әллә нишләп китте, нинди-дер батырлык эшлисе, дошманнан үч аласы килде. Ул бүлмә уртасына басып, пистолетны кая төбәргә белми торды да, өстәл янында укып утырган сенлесе Илсөяргә карап:

—Руки вверх! Стрелять буду!—дип кычкырды.

Илсөяр куркуыннан чырылдап елап жибәрде, анын елавыннан үзе дә куркып, Илһам пистолетын икенче якка борып, курокка басты. Каты шартлау белән бергә көзге пыяласы, чәлпәрәмә килеп, вак кыйпылчыкларга әйләнеп коелып төште. Пистолетны корылмаган дип уйлаган малайнын коты очты, коралны ыргытып, өйдән чыгып чапты. Урам аркылы күршеләргә кергән Гайшәбикә, кызынын елавын ишеткәч, нәрсәдер булганын анлап, куркудан хәле бетеп, өйләренә чыкты.

—Ни булды, балам, ник елыйсын?

—Абый мине атып үтерә язды! Көзгене ватты!

Гайшәбикә, ватылган көзгене күргәч, нинди фажига була язганын белде, аякларынын хәле бетеп, урындыкка барып утырды.

—И, Ходаем, баламны саклаганын өчен мен-мен рәхмәт!.. Күнелләрем сизгән икән! Ничә әйттем, коралынны өйдә тотма дип!..

Пистолетны ыргытып, өйдән чыгып качкач, Илһам кая барырга, нишләргә белмәде, әнисе күрмәгәндә печәнлеккә менеп качты.

Икенче көнне әтисе пистолетын милиция бүлегенә илтеп тапшырды.

Ире эшкә киткәч, Гайшәбикә улын эзләп тапты.

Илһам җәй буе печәнлектә йоклаганга, әнисе анын кайда икәнен белә иде. Ул Илһамны әллә ни ачуланмады:

—И, улым, Ходай саклаган инде, сенленне үтергән булсан бу дөньяда ничек яшәр иден?!—диде.

***

Айсылу бүлмәләренә кайтып кергәндә, вакыт сон булса да, кызлар йокламаганнар иде. Ул чишенеп, киемнәрен шкафка элде, озын халатын киеп, караватына утырды. Кызлар яткан урыннарыннан торып Айсылуны чолгап алдылар.

—Кызлар, ул өйләнергә дип килгән!

Әминә елап мендәренә капланды. Айсылу аптырап ана карады.

—Нигә елыйсын?!

—Айсылу, кияүгә чыкма! Мин сине жәллим!

—Карагыз әле бу тилене! Син жәлли дип Айсылу кияүгә чыкмасынмы?—диде Әлфия.

—Без өйләнешәбез инде. Бүген авылга шалтыратам, әти-әни дә белеп торсын...

Кызлар тынып калды. Әлфия дустынын күзенә карап:

—Ә Фазыл нишләр?—диде.

—Ни эшләсә дә эшләр, Илһамга ризалык бирдем инде, кызлар, хәерле булсын.

Әнисе белән сөйләшеп кайткач, Айсылу Илһамны институтка чакырды.

—Илһам, группадашлар синен белән таныштыруны сорыйлар. Бүген анда бәйрәм була, барабызмы?

Илһам кичәләргә йөрүне артык яратмаса да, кәләшенен үтенечен кире кагуны яхшысынмады. Анын, билгеле, Айсылу белән икәүдән-икәү генә каласы килә иде.

Залга үткәндә аларны Әлфия белән Роберт каршы алды.

—Илһам, таныш бул: минем ин якын дустым Әлфия,—диде Айсылу.

—Һәм анын жан сакчысы!—дип, Роберт Илһамнын кулын кысты.

Бу ике пар янына җыелып, бар да яшь кияү белән танышты.

Комсорг—озын буйлы, кара тутлы Илдус шаярып:

—Сез безнең группаның өченче кияве. Кызларыбыз матур булгач, институт бетергәннәрен көтмиләр, берәм-берәм чүплиләр!..

Шул вакытта нәрсәдер булды, Айсылу аңлап өлгергәнче, дуслары Илһам белән икесен чорнап, бөҗра эченә алдылар. Бөҗра артында, кулына кыска пычак тотып, Фазыл тора. Аның чигәннеке төсле кара чәчләре таралып төшкән, күзләре шашкан кешенеке сыман, йөзе агарынган.

Илдус аның пычаклы кулын эләктереп алды да артка каерды һәм баскычтан алып төшеп китте.

Айсылу пычак тоткан Фазылдан курыкмады, ә Илһамнан уңайсызланды. Һәм бу минутта кыз Фазылны үлеп кызганды: нинди хәлгә төшкән, мескен...

Берничә минуттан Айсылулар янына Роберт килде.

—Сезгә китсәгез яхшырак булыр, Айсылу, анда физмат егетләре нәрсәдер эшләргә җыена,—диде ул, алдан ук кисәтергә теләп.

Айсылу белән Илһамны арткы ишектән автобуска кадәр озатып куйдылар.

Айсылу, Илһам үпкәләмәде микән дип, ничек сүз башларга белмәде.

—Илһам, мин теге егетне яратмадым, ул үзе миңа гашыйк иде, институтка кергәннән бирле минем арттан йөрде.

Илһам болай тыныч күренә.

—Мин аңлыйм, аның да яратырга хакы бар. Яраткан булсаң, син дә аны сайлаган булыр идең...

Айсылу тулай торакка соңгы автобус белән кайтты. Бар җирдә тынлык урнашкан иде.

Ул, кызларны уятмаска тырышып, мыштым гына кереп урынына ятты. Шул вакытта, кайсыдыр пырхылдап көлеп җибәрде. Кызлар йокламаганнар иде.

—Без инде сине кайтмассың дигән идек. Тумбочкаң өстендә хат бар.

Ул халатын киеп, хатны укырга коридорга чыкмакчы булган иде, кайсыдыр:

—Ут яндыр, барыбер беркем дә йокламый,—диде.

Хат Зөлфирәдән иде.

Әлфия Айсылу янына килде.

—Фазылның кыланышына Илһам нәрсә диде?

—Бер нәрсә дә әйтмәде, егет кешенең гашыйк булуы гаеп түгел, диде.

—Ярый инде алай булгач, без әле борчылып тора идек. Айсылу, син ничек укырсың микән, заочныйга күчәсеңме?

—Быел укып бетерәм әле, аннан күз күрер.

Айсылу дустының хатын укый башлады. Зөлфирәнең тормышында да үзгәреш булырга тора икән.

*"Айсылу! Синең киңәшең бик урынлы булып чыкты, мин Куйбышевка Госман янына барып кайттым. Госман мин килгәч шатлыгыннан нишләргә белмәде! Өч көн буе мине кунак итте, алып бармаган җире калмады. Илһам белән синең турыда сөйләгән идем: "Наконец, Айсылу үзенә тиң егетне очраткан", диде. Ул Илһамны бик ихтирам итә, алар мәктәптә бергә укыганнар икән.*

*Госманның исәбе өйләнүдә, мине Яңа елга чакыра, барам инде, ул чагында вакыт та иркенрәк була, мәктәптә кышкы каникуллар башлана. Госманның Казанга күчәсе килә, белмим, җибәрерләрме, юкмы..."*

Соңгы көннәрдә гел дулкынландыргыч хисләр кичергәнгә, Айсылу тиз генә йоклап китә алмый ятты, мендәрен әйләндереп, салкынча ягына кайнар янакларын куеп тынычлангач кына йокыга талды.

ЗАГС бүлегенә алар җәяүләп кенә атладылар. Роберт юл буе көлдереп барды.

—Илһам, ныклап уйлап бетердеңме, ирегең кадерлерәк булса, әле соң түгел?!

—Юләр! Уйнап сөйләшсәң дә уйлап сөйләш!—дип, Әлфия егетен орышты.

—Айсылу мина дөньядагы бар нәрсәдән дә кадерлерәк!—диде Илһам, бөтенесе дә ышанырлык итеп.

ЗАГСтагы кыз аларны елмаеп каршылады. Паспортларын алып, документларны тутыра башлады. Роберт бер минут та тик тормады, һаман шаяртты, бүлмәдә гел көлү тавышы яңгырап торды. Бу көнне Айсылу белән Илһамнан башка берәү дә өйләнешергә дип килмәгән иде бугай.

Айсылуның паспорты буенча язып бетергәч, кыз Илһамныкын алды. Айсылу кызның паспортка карап сәерсенгәнен күрде дә, эче "жу!" итте: нәрсәгә исе китте икән бу кызның? Ходаем, әллә Илһам өйләнгән булды микән дип курыкты...

Кыз янә елмаеп Илһамга карады.

—Сез Кама тамагы районының Балчыклы авылында тугансыз икән, мин дә Балчыклы кызы бит!

Илһамның моңа исе китте:

—Авылдашлар икәнбез. Сезнең исемегез ничек?

—Рәйсә.

—Мин Балчыклыда туганмын гына, анда үсмәгәч туганнардан башка кешеләрне белмим.

Айсылуның күңеленнән авыр йөк төшкән кебек булды. Илһамның авылдашы очрау бик изге фал сыман тоелды.

Бу бүлмәдә чәчәк тоткан туганнар да юк, тантаналы Мендельсон маршы да яңгырамады. Өстәл артына басып, бик гади генә итеп, якыннарын котлаган кебек, Илһамның авылдашы аларны тәбрикләп кулларын кысты. Чәчәкләр урынына Роберт бәйләм-бәйләм шаян сүзләр яудырды.

—Карале, Әлфия, әллә без дә сразы язылышып кайтабызмы? Кыз бәясе бик арзан икән бит! Илһам Айсылу өчен унбиш тәңкә генә түләде. Минем, кәнишне, унбиш тәңкәм юк, Илһам биреп торыр әле...

Алар барысы да рәхәтләнеп көлделәр.

Туй мәҗлесе бик кечкенә, ләкин искиткеч күңелле булды. Алар дүртәүләп ресторанга кереп утырдылар, залны шаулатып күңел ачтылар. Кырык кеше җыелган диярсең! Бертуктаусыз көлүдән яңаклары авырта башлады.

Рестораннан чыккач, Әлфия белән Роберт аларны гостиницага кадәр озаттылар.

—Бәхетле булуыгызга шикләнмим,—диде Роберт,—сез шундый пар килгән!—Ул Әлфиягә карап:—Шулай да, Әлфия, өйләнүне озакка сузып булмас, Илһамнар кытыкны китерде...

—Без дә сезгә свидетель булып барабыз,—диде Айсылу.

Бу кичне Айсылу Илһамның законлы хатыны булып аның бүлмәсендә калды...

***

"Без өйләнгәч, төн кыскара,"—дигән сүз дөрес икән... Өйләнешкән көннең икенчесендә, иртән иртүк Илһамның китәсе турында уйлап, икесенең дә үзәкләре өзелде, бер минутка да аерыласылары килмәде. Ләкин китәргә кирәк—Илһам Смирновка вакытында кайтып житәм, дип сүз биргән иде.

Шәмәхә болытлар астыннан томанга чорналып кызыл кояш күтәрелә башлады. Салкыннан тыннар куырыла. Автобусның ишеген ачып, юлчыларны утырта башлагач, Айсылу Илһамның күкрәгенә сыенды, сиздермәскә тырышса да, ихтыярсыз елап җибәрде. Илһам аны үпте дә:

—Хуш, Айсылу, исән бул! Без барыбер бергә! Мин сине өзелеп сөям! Мин сине көтәм!—диде.

—Мин дә синеке генә!

Автобус кузгалып киткәч, Айсылу тагын елады, күз яшьләре битен тундырды. Салкын булса да, Айсылу баскан урынында бик озак торды, сөйгәнен алып киткән автобус инде күптән күздән югалган иде.

Аерылу авырлыгыннан еласа да, күңеле бәхеттән мөлдерәмә тулы, бу

хис шундый көчле, ул күкрәккә сыймас кебек.

Айсылу бүлмәләренә кайтып кергәндә, кызлар лекциягә җыеналар иде.

Әлфия дусты янына килеп утырды да аркасыннан кочаклады.

—Хәлең ничек, Айсылу җаным?

—Дөньяда ике бәхетле булса, аның берсе мин!—диде дә тагын елап җибәрде.

Әлфия дустының елавына гаҗәпләнде.

—Алай булгач ник елыйсың, Айсылу?

—Илһамны сагындым...

—Киткәненә ярты сәгать тә үтмәгән бит әле!—Әлфия көлеп җибәргәч, Айсылу да яшь аша дустына елмайды.

Аның бәгырен искиткеч олы бәхет тә, аерылышу сагышы да телгәли иде.

Ә бу вакытта, кар каплаган нарат урманнары аша ашыккан автобуста, салкыннан бөрешкән юлчылар арасында, Илһам, пәлтә якасына ышыкланып, Айсылуны күз алдына китерә дә Мәҗнүн кебек елмаеп утыра иде. Ул салкынны да, автобусның сикәлтәләрдә бәргәләнгәнен дә сизми, язмышның бәхетне гомер азагына кадәрле җитәрлек итеп биргәненә ышана... Тәрәзә артындагы тоташ аклык аңа ак бәхетләр вәгъдә итә сыман. Бары тик, кошлар карын койган миләшләрнең кызыл тәлгәшләре генә, әлеге ак муллыкны сискәндереп куйгандай итә иде...

---

## *Бер сорауга—бер җавап*



**Алмаз Миргаязов,**
*"TATAR RADIOSI"ның баш мөхәррире.*

**—Алмаз әфәнде, яңа сезонда "TATAR RADIOSI" тыңлаучыларны нәрсәләр белән сөендерәчәк?**

*—Быел да 29 августта безнең яңа сезон башланды. Яңа сезонда тапшыруларда үзгәрешләр шактый күп. Алар—өр-яңа рубрикалар, яңа тапшырулар, шул исәптән "Кызлар күңеле" дип исемләнгән яңа уен. Шулай ук тыңлаучы белән турыдан-туры элемтә урнаштыручы рубрикаларга аерым басым ясадык. Интерактивлык, гомумән, радиога бик кирәкле нәрсә. Интерактивлык—ул радиода билгеле мизгелдә эшләүче алып баручы йөзендә радио белән радиога шалтыраткан яисә эфирга килгән бер тамашачы йөзендә бөтен аудитория белән туры элемтә, дигән сүз. Шушы интерактивлыкны без берникадәр алга чыгарып, берничә рубрика һәм уен уйлап таптык һәм тапшыру җәдвәленә куйдык. Аларның формасы яңарачак, ләкин формасы күпме үзгәрсә дә, яңалык һәр кешене җәлеп итә торган нәрсә булырга тиеш.*

*Берничә төнге программа, шул исәптән "Өч нокта" тапшыруы төшеп калды. Әлеге тапшыруның гомере озын булды, башта Булат Бәйрәмов, сонрак Зөлфәт Зиннуров алып баруында "TATAR RADIOSI"нда ул өч елга якын эфирга чыкты. Аның "пенсиягә чыгуы"ның сәбәбе, тыңлаучысы булмавында түгел, ә өч ел буена берникадәр актуальлеген югалтуында.*

*Юмор өлкәсендә безнең традицион "Тигәнәктә кунакта" дип исемләнгән рубрика хәзер көн дәвамында 15 тапкыр барачак. Юмор, күтәренке кәеф, оптимизм һәм яшәргә көч бирә бит ул.*

*Интерактивлыкның тагын бер чагылышы буларак, 12.15-13.00 арасында "45 минут" исемле көндезге сәлам тапшыруы белән бергә сентябрь башыннан, Интернет сәламнәре һәм SMS-хәбәрләр аша кыска, төгәл һәм күңелле сәламнәр тапшыруы башланачак.*



## Шамил Анак

### ЭҢГЕР ЯЗМАЛАРЫННАН

* * *

*"На первозданном камне музыки*
*поэзия стоит".*
Семен Липкин.

**Юктан бар булган бәндәләр**
**җитди тәс белән, көлмичә,**
**сәер уеннар уйныйлар,**
**хикмәт асылын белмичә:**

**Бу дөньяның тәү ташында**
**шигърият басып тора,**
**беркатлы җыр күлмәгендә,**
**серле йөзен яшереп,**
**хикмәтле уен кора.**

**Сүздән башланган бу дөнья,**
**һәм бетәчәк сүз белән...—**
**Исрафил сурын өргәндә**
**шәфкать белмәс йөз белән...**

* * *

**Бии йолдыз алдында йолдыз,**
**бии ярсу агымда кондыз,**
**бии төнге учакта ут,**
**бии храмда пәйгамбәр Дауыт.**

**Елый канаты сынган кош,**
**елый ана—бәби бишеге буш,**
**елый табан астында каты таш,**
**елый аулакта—алданган туташ.**

**Елый яшь килен—сагына йорт-илен.**
**Елый кыз бала—яшьлеген картлар ала.**
**Елый ир-егет—сөйгәне ятка кала.**

Шамил АНАК (1928) — *шагыйрь, тәрҗемәче; татар, башкорт, рус телләрендә дөнья күргән китаплар ("Гади әйберләргә мәдхия", "Европа уртасыннан репортаж", "Тыйнак табыш" һ. б.) авторы. Башкортостанда яши.*

***

Зәңгәр канатлы, кичке
изгелекле яктылык!
Кабердән карагандай
карап калам артыннан.
Бәлки, бу—иң соңгы кичем,
рәхмәт сиңа гүр картыннан.

Рәхмәт сиңа—һәр йотым,
син биргән тере суың өчен,
рәхмәт—икмәгең, тозың өчен,
рәхмәт—эссе маңгаема баскан
кулың җиләслеге өчен,
талгын искән җилеңнең
җиңел иләслеге өчен,
рәхмәт—тын авазларың
догадай укылган өчен.
рәхмәт—әлпә күлмәгең
җилдән, яңгырдан
тукылган өчен...

***

*"Я то знал, что любая росинка—слеза"*
А. Тарковский.

Колак салып, кырда үләннәрне тыңладым,
һәм үләннәр скрипка кылы кебек чыңлады,
могҗиза күргәндәй табигатьне күзләдем,
җырлаганда үлән арасында нәни чикерткә,
аваз белән төснең тәңгәллеген эзләдем.

Белдем шуны: һәрбер чык бөртеге—күз яше,
күбәләкнең канатында җәйгор җемелди;
дүрт якны да күрә энә бурының челтәр күзе—
һәм барсында яши пәйгамбәрнең утлы сүзе.

Хакыйкать сүзендә күрдем чынлыкның үзен,
ялган, хәйләләрнең ачтым чын йөзен,
ләкин күреп, белеп кирәгеннән дә артык,
бәлки күргән, иштеткәнмендер ярым-ярты.
Аның каравы, кимсетмәдем туган җирне,
таптап сындырып рәнҗетмәдем үләннәрне,
авыр сүз белән искә алмадым үлгәннәрне.

Кабул итеп җирнең икмәген, җирнең суын,
тигез карадым агачына, кошларына,
җирдә яшәгәнемдә, җирдә эшләгәнемдә
иңнәремә ятты әлпә күк гөмбәзе
һәм йолдызлар коелды ачык учларыма.

***

Эссе көндә су коенган сусылу,
су асты патшасының иркә балдызы,
хыялланып утыра таш өстендә
яп-ялангач, япа ялгызы.
Ни гамьнәре бар аның, ник ул моңсу,
җир егетен киләме әллә сөясе?

Агач артына качып, күзли аны
чат мөгезле урман иясе.
Ә сусылу сары чәчен тарый,
елык-елык итә алтын тарагы...
Яңа заманнарны хәтерләтеп,
самолеттай оча
су өстендә энә карагы.

## Авылда

Телем монда гамәлдә әле.
Сүзләр килә борыннан—
тамгалы кыя ташлардан
һәм бабайлар җырыннан.

Сүзләр кануны катгый—
буйсынмыйлар беркемгә:
сүзләр киләләр, китәләр—
бу тик алар иркендә.

Курыкмагыз, тел ул үлми.
Бар шундый тын урыннар—
анда яши әле һаман
иң борынгы ырыннар.[1]

***

Уйлый идем элегрәк: баскычлар
илтә диеп йолдызлы үргә.
Ялгышканмын—илтә икән алар
ай-кояшсыз караңгы гүргә.

Аңлашылмый миңа бу каршылык:
янәш тора биеккә—түбән.
Әйе, аңлау кыен түбәнлекне,
йолдызларга тигәндә түбәң.

Икесе дә бер үк тар баскычта—
үлемсезлек белән ят үлем.
Кем соң белә, бәлки, исмем калыр илдә,
бәлки җилдә очар ак көлем?

Фатиха бирегез, сез, бөекләр,
аяк басам соңгы баскычка—
кулым сузам, куркып һәм тартынып,
үлемсезлек серен ачар ачкычка.

***

Чынлап кына баксаң, гомер ахырында
шул ачыла: без үзебез хакында
ярты сүз дә язмаганбыз икән.
Иң дөресе, үзебезнең чын йөзне
күрсәтергә базмаганбыз икән.

Һәм безгә без булып күренгән нәрсә
без түгел, нибары шәүлә икән.
Инде беләм: аргамаклар көткәнче
әкрен генә үз җаеңа җаяүлә икән!

---

[1] Ырын—ташка чокып язылган борынгы төрки язма. Автор.

**Сәвия Михайлова**

# КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ ИДЕЛ БУЕ ҺӘМ УРАЛ ТӨБӘГЕ ХАЛЫКЛАРЫНЫҢ МӘДӘНИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫНДА ТОТКАН УРЫНЫ

Галим А. Ю. Андреев дөрес билгеләп үткәнчә, университетлар белән Россиянең мәдәни тормышы арасындагы бәйләнешләр дәрәҗәсе турыдан-туры фән үсеше белән генә билгеләнми. Яңа идеяләр башлангычы буларак, мәмләкәт университетлары яшь көчләрне үзләренә тартып килделәр һәм яңа мәдәни-иҗтимагый бәйләнешләр формалашуга уңай йогынты ясадылар *(Андреев А. Ю. Московский университет в общественной и культурной жизни России начала XIX века.—М., 2000.—С. 3-7)*. Бу күзәтүләр Казан университетына карата да дөрес булыр һәм тәңгәл килер иде.

Бөтен XIX гасыр буена Казан университетының күзгә күренеп торган "инновация" функциясе шәһәрнең иҗтимагый һәм мәдәни тормышының төрледән-төрле формаларын җанландыруы белән тәгаенләнә. Ул үзенә күрә "мәгариф культы" рухындагы башлангычларның "инкубаторы" буларак хөкем сөрә. Аның диварларында булып үткән тантаналы актлар һәм вакыйгалар шәһәр халкы арасында билгеле бер күләмдә теләктәшлек таба. Әйтик, университетның тантаналы ачылуы хакында Казан халкына латинча, русча һәм татарча язылган программалар аша хәбәр ителә *(Казанские известия, 1814, N 28)*.




Университетның Актлар залында ел саен үткәрелә торган тантаналы җыелышлар да гомумшәһәр күләмендәге әһәмиятле вакыйгага әвереләләр. Җыелу урынында аны гади генә итеп—"Актлар" дип атыйлар, ә ясалган нотыкларны "актовый" дип йөртәләр. Университет ишекләре ул көнне "җирле халык" өчен дә ачыла торган була. 1822 һәм 1825 елларда И. М. Симонов тарафыннан ясалган "акт" нотыгы Җир шары әйләнәсендә ясалган һәм Антарктиданы ачу белән төгәлләнгән беренче рус экспедицияләренең нәтиҗәләренә багышлана *(беренче нотык "Слово об успехах плавания шлюпов "Востока" и "Мирного" около света", икенчесе "О разности температуры в южном и северном полушариях" дип атала)*. Бу нотык шулай ук чит телләргә дә тәрҗемә ителә.

Акт тамашалары традициясе белән беррәттән университет даими рәвештә әдәби җәмгыятьләрнең җыелышларын үткәреп килә. 1806 елда университетта "Россия телчеәдәбиятчыларының иректә күнекмәләр җәмгыяте" оеша; ул, М. Магницкий попечительлек иткән чорда беразга эшен туктатып торганнан соң, 1834 елга кадәр яши. И. Симонов үзенең "Гомумән диңгездә йөзүдәге уңышлар һәм, аерым алганда, русларның Җир шары тирәли сәяхәтләре турында" дигән докладын укыган Җәмгыятьнең бер утырышында В.П.Молоствов белән Лобачевский да катнаша (1848). Җәмгыять утырышларында И. Симонов үзе иҗат иткән әсәрләрен дә укый (1849). И. Симоновның кияве—синолог (Кытай тарихын, икътисадын, телен, әдәбиятын өйрәнә торган фәннәр белгече) В. П. Васильев әдәбият сөючеләр җәмгыятендә ун ел дәвамында Пекинда яшәгәндә алган хатирәләрен һәм уйлануларын чагылдырган "Көндәлекләр"еннән өзекләр белән таныштыра.



*В.П. Васильев.*

Университетны шәһәр иҗтимагый тормышы белән бәйләп торучы бер күпер булып вакытлы матбугат хезмәт итә. Моның әлгәре—беренче карлыгачлары итеп кульязма басмаларны санарга мөмкин. XIX гасырда Россиянең

студентлары арасында кульязма әдәби журналлар кин таралыш таба. Бу нәүбәттән, әлбәттә, Казан университеты да читтә калмый. Бирелә беренчеләрдән булып балалар өчен "Аркадские пастушки" журналы чыгарыла. Аны "нәшер" итүдә Казан университетынын "беренче студенты" С. Т. Аксаков та кергән гимназистлар төркеме катнаша. 1812 елда дөнья күргән "Смесь" сатирик журналынын да ике дәфтәр-нөсхәсе сакланып калган. Шулай ук 1830 елнын ахырында "Северное созвездие" дигән гомуми исем астында "нәшер ителгән" ике калын журнал да эзсез югалмаган. Аны фәлсәфә факультеты студенты Евлампий Огородников чыгара. Журналнын хезмәткәрләрен, башлыча, студентлар тәшкил итә. Алар арасында көнчыгыш телләре бүлегендә укыган И. Н. Холмогоров та була; сонрак ул атаклы көнчыгыш телләре белгече булып таныла; 1852—1855 елларда Одессанын Ришелье лицеенда эшли. 1963 елдан Казан дәүләт университеты тарих-филология факультетынын профессоры. Хезмәт хакы алмыйча гына фарсы теле һәм әдәбиятыннан дәресләр бирә. 1865 елда Санкт-Петербург университетында "Шәех Мөслихетдин Сәгъди Ширазлы һәм анын фарсы әдәбиятында тоткан урыны" дигән темага магистрлык диссертациясе яклый *(Казанский университет, 1804—2004: Библиографический словарь., Т. 1,—С. 568).*

Анлашылса кирәк, кульязма журналлар ярдәмендә студентлар заманнын танылган әдипләре әсәрләре белән танышалар, аларга ияреп үзләре дә иҗат белән шөгыльләнәләр. Журналларда шулай ук шәрекъ әдәбиятыннан да үрнәкләр урын ала, әйтик, XI гасыр тажик шагыйре Жаминын "Бер матурга" шигыре, VI гасыр гарәп шагыйре Шанфаранын "Касыйдә" әсәренен чәчмәдәге тәрҗемәсе әнә шундыйлардан. Күрәсен, кайбер хезмәткәрләр һәм журналны чыгаручы үзе дә шәрекъ әдәбиятыннан хәбәрдар булганнардыр *(Ильенко Е. М. "Северное созвездие". // Описание рукописной научной библиотеки им. Лобачевского. Вып. XI).*

Казан университеты галимнәренен һәм төбәкне өйрәнүчеләренен вакытлы матбугат белән элемтәсе үзенә бер аерым урын алып тора. Вакытлы матбугат белән хезмәттәшлек итү XIX гасырнын 20-60 елларында төбәкне өйрәнүгә зур өлеш керткән М. Рыбушкин, К. Фукс, А. Артемьев һ. б. эшчәнлеге белән бәйле. "Газета—ул тарихнын караламасы",— дигән америка нашире Грэм. Чынлап та, төбәкнен тарихы күп очракта 1811—1820 елларда университетта нәшер ителгән Россиянен беренче җирле газетасы булган "Казанские известия" газетасы битләрендә яктыртыла.

"Казанские известия" газетасы, М. Пинегин билгеләп үткәнчә, Идел буе һәм Урал төбәге халыкларынын тарихы, географиясе һәм этнографиясе буенча материаллар бастырып, җирле заман тормышынын кайтавазына әверелә. Газетада шулай ук белдерүләр дә урын ала. Әйтик, 1811 елнын сентябрь санында мондый хәбәр басыла: "Казан Император университеты типографиясендә һәм әлеге университетнын комиссионеры Сухановнын китап кибетендә рус телендәге татар грамматикалары сатыла". Газета шулай ук көнчыгыш телләрендә иҗат ителгән кульязма әсәрләрне саклау буенча да күп эшләр башкара. Аерым алганда, 1811 елнын бер санында белдерүләр рубрикасы астында түбәндәге эчтәлектәге мәгълүмат басыла: "Гарәп телендәге кульязмаларга һәм аеруча тарихи истәлекләргә һәм шигырьләргә ия кешеләрнен, шулай ук борынгы көнчыгыш акчаларына ия хуҗаларнын һәм аларны сатарга теләүчеләрнен бу хакта Казан университетынын көнчыгыш телләр профессоры Х. Д. Френга хәбәр итүләрен үтенәбез".

Шунысы игътибарга лаек, газетаны чыгаруда башлап йөрүче һәм беренче мөхәррире—университет адъюнкты И. Запольский аны ике телдә, рус һәм татар телләрендә бастырырга тәкъдим итә, әмма хакимият мона каршы төшә. "Мир новостей" газетасын нәшер итүче *(татар телендә "Әл-бәхр")* профессор М. Никольскийны да шундый язмыш көтә. "Казанские известия" газетасы белән университет профессорлары һәм укытучыларыннан И. М. Симонов, П. С. Кондырев, И. И. Халфин, Н. М. Ибраһимов һ. б. актив хезмәттәшлек итәләр.

Казаннын беренче шәхси журналы булган "Заволжский муравей" М. С. Рыбушкин һәм М. В. Полиновский тарафыннан нәшер ителә—1832—1834 елларда айга ике мәртәбә дөнья күргән бу басма Россиянен ул чактагы эчке һәм тышкы сәяси тормышындагы вакыйгалар турында гына түгел, төбәкнен тарихына, географиясенә, икътисадына караган мәгълүматлар да бастыра. Рус булмаган Идел буе, Урал төбәге һәм Себер халыкларынын көнкүреше, традицияләре һәм тарихы турындагы күпсанлы материаллар аеруча зур әһәмияткә ия. Бу нәүбәттән М. Рыбушкин: "Безнен күздән борынгы ядкярләрнен берсе дә ычкынмый",—дип билгеләп үтә *(Загоскин Н. П. История Имп. Казанского университета 1804—1994. Т. 1 (1804—1814).—Казань, 1902.—С. 22).* Университетнын профессорлары һәм укытучыларыннан Н.Н. Кафтанников, Г.Н. Городчанинов, М.В. Полиновский, Я.И. Ибраһимов (Нигъмәт Ибраһимовнын улы), М.С. Рыбушкин, Ф.М. Рындовский, И.А. Верниковский, Г. И. Солнцев, Ф. И. Эрдман журнал өчен төрле сюжетка корылган очерклар һәм мәкаләләр язалар. Алар Болгар һәм Казан ханлыгы тарихына, Болгар хәрабәләренә, башкорт, чуаш, чирмеш, мордва халыкларынын, Енисей казаклары һәм Турхан күчмәләре көнкүрешенә багышланганнар; болар арасында башкорт халык авыз иҗаты әсәрләре, чуаш халык

жырлары да бар. Беренче шәхси журнал булган "Заволжский муравей" басмасында шулай ук К. Фуксның шәһәр халык сәламәтлеге һәм шәһәрнең экологик торышы турындагы мәкаләләре дә урын ала.

Н.П. Загоскин билгеләп үткәнчә, 1830 еллар уртасына вакытлы матбугат зыялыларның һәм киң массаның бер өлешенең тормышында зур роль уйный. Шуңа күрә дә газеталарның чыгудан туктавы зур югалту буларак кабул ителә һәм бу вакыйга шәһәр халкы тарафыннан билгеләп үтелә.

1834—1837 елларда Казан газетасыз кала. Ә 1838 елдан "Казанские губернские ведомости" газетасы дөнья күрә башлый; биредә XIX гасырның 40-50 елларында җирле төбәкнең тарихына һәм мәдәниятенә кагылышлы университет профессорлары тарафыннан тупланган күп төрле материаллар урын ала. Әйтик, К. Фукс төбәк халыкларының этнографиясе турында мәкаләләр бастыра, рус булмаган халыкларның борынгы ядкярләре һәм көнкүрешенә кагылышлы язмалар белән А. Артемьев, Ф. Эрдман кебек галимнәр катнаша.

Мөхәррир А. И. Артемьев *(1820—1874)* эшчәнлеге аерым игътибарга лаек. Саратов гимназиясен һәм Казан университетын тәмамлаган бу галим көнчыгыш телләре факультетының кытай бүлегендә кандидатлык курслары үтә. "Варяглар славяннарга йогынты ясаганнармы, әгәр ясасалар, ул нидән гыйбарәт?" дигән темага диссертация яклап, Артемьев рус тарихы буенча магистрлык дәрәҗәсенә ирешә *(1845)*. Александр Иванович шуннан соң университетта китапханәче ярдәмчесе буларак калдырыла һәм бер үк вакытта "Казанские губернские ведомости" газетасының мөхәррире итеп билгеләнә *(1844—1852)*. 1850 елда Археология һәм география җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы итеп сайлана.

Эчке эшләр министрлыгының статистика комитетына өлкән мөхәррир буларак хезмәткә күчерелгәч *(Санкт-Петербург)*, "Россия империясенең торак урыннары исемлеге", "Россия империясенең География җәмгыяте хезмәтләренә күзәтү" кебек басмаларны төзүдә катнаша.

Чын зыялылык сыйфатлары, эрудитлык билгеләре Александр Ивановичның "адресатлары" кем булуда да чагылыш таба: ул А. Казымбәк, О. Ковалевский, И. Березин, С. Михайлов кебек танылган галимнәр белән язышып тора. Аның кульязмаларында немец, француз, грек, итальян, кытай телләреннән, латиннан алынган сөземтәләр урын алган. Россия География җәмгыяте каршындагы хезмәтләре өчен ул Кече алтын Константинополь медале белән бүләкләнә.

XIX гасыр Казанының мәдәни һәм иҗтимагый тормышында Казан университеты галимнәренең халык каршында укыган лекцияләре тирән эз калдыра. 1840 елда рус тарихы буенча лекцияләрне Н. А. Иванов укый. Бу башлангыч зур уңышка ирешә; замандашларының күзәтүенә караганда, аның лекцияләренә шәһәрнең барлык катлам кешеләре дә йөри. Тагын дүрт елдан соң профессор "Бөек Петр" турында лекцияләр укый. Аның популярлыгы "Губернские ведомости" хроникаларына үзенең хәбәрен "гыйлемгә мәхәббәт шәһәрнең төрле катлам халкы байлыгы булып тора" дигән нәтиҗә белән тәгалләргә мөмкинлек бирә. Шәһәрдә, Н. А. Иванов эшеннән азат ителгәннән соң, тарих кафедрасын җитәкләгән профессор С. В. Ешевскийның халык алдында укылган һәм университетта дәрес биру лекцияләре зур уңыш казана.

Казан университетындагы лекцияләргә ирекле тыңлаучы сыйфатында төбәкне өйрәнүче атаклы тарихчы Н. Я. Агофонов та йөри. 1872—1874 елларда ул "Камско-Волжская газета"сын нәшер итә һәм редакцияли; рәсми булмаган мөхәррире булып шулай ук Казан университетын тәмамлаган К. Лаврский тора. Газета чын мәгънәсендә төбәкнең үзаңын билгеләүче "көзгегә" әверелә. Аның битләрендә Россия империясенең идарә системасын тәнкыйтьләгән мәкаләләр басыла.




Агафонов "Беренче адым" *("Первый шаг")* дигән төбәк әдәби җыентыгын чыгаруда да актив катнаша. Җыентык драматик сәнгать сөючеләрнең түгәрәген оештыру кирәклеге мәсьәләсен күтәреп чыга. Түгәрәк үз алдына "җирле драма әсәрләренә татар тормышыннан алынган күренешләр һәм типлар да үтеп керсен" дигән бурыч куя. Җыентыкның авторлары алдынгы карашлы әдәбиятчыларның миссиясен театр шундый көчкә әйләнергә тиеш, ул "халык массаларын үзенә тартырга, сыйныфларга һәм, милләткә аерып тормастан, шәһәр халкы арасыннан күп кеше йөри торган тамашачы тупларга тиеш" булуда күрә *(Первый шаг.—Казань, 1876.—С. 991-993)*.

1883 елда башта журнал, соңыннан газета булып чыга башлаган "Волжский вестник" та Россиянең төбәк матбугаты тарихында якты эз калдыра. Басманың күп төбәкләрне

эченә алуы һәм күтәрелгән мәсьәләләрнең диапазоны киңлеге төп үзенчәлек булып тора. "Волжский вестник"та басылган мәкаләләрдә Идел һәм Кама буйларында яшәүче халыкларның этнографиясенә кагылышлы мәсьәләләр күтәрелә. Анда, шулай ук, Кырымда И. Гаспралы тарафыннан нәшер ителгән "Тәрҗеман" газетасыннан да мәкаләләр күчерелеп бастырыла. Табигый буларак, "мөселман" темасына караган мәкаләләр һәм хәбәрләр сәүдәгәр-мөселманнарның менталитеты һәм үз-үзләрен тотышындагы үзенчәлекләр мәсьәләсе күтәрелә. Газета битләрендә "бер төркем татар зыялылары"ның татар телендә газета чыгару идеясе белән янып йөрүләре турында җәмәгатьчелек арасында таралган яңалык зур шатлык белән билгеләп үтелә *("Волжский вестник", 1887, N 13. С. 2)*.

Төбәкнең фәнни, төбәкне өйрәнү һәм иҗтимагый тормышында фәнни җәмгыятьләр әһәмиятле урын алып тора. 1939 елда Н. Лобачевский университет каршында үз уставы булган Икътисади җәмгыятьнең бүлеге оештыра. Аның әгъзалары төбәкнең икътисади эшчәнлеген һәм хуҗалык итү үзенчәлеген генә өйрәнеп калмыйлар, ә бәлки аерым кешеләргә оештыру мәсьәләсе һәм гамәли ярдәм күрсәтеп киләләр. 1847 елда Казан тирәсендә урнашкан Икътисади җәмгыятьнең авыл хуҗалыгы фермасында Дүртенче җир эшкәртү *(агрохимиклар)* училищесы ачыла. Җәмгыять даими рәвештә авыл хуҗалыгы һәм сәнәгать күргәзмәләре оештыра.

1854 елдан 1861 елга кадәр Җәмгыять фәнни-гамәли эчтәлектәге "Язмалар" *("Записки")* нәшер итә. Актуальлеге һәм фәнни дәрәҗәсе ягыннан алар авыл хуҗалыгы мәсьәләренә багышланган "карт" башкала басмаларыннан калышмыйлар. "Язмалар"ны чыгаруда ректордан кала университетның М. Я. Киттары, Н. К. Чугунов, Е. С. Фальков кебек галимнәре дә актив катнаша. Мөхәррир, бер үк вакытта Җәмгыятьнең эзләрен җитәкләүче һәм Икътисади җәмгыятьнең Казан бүлеге сәркәтибе булып Киттари тора. Чыгарылу дәверендә "Язмалар"ның 75 китабы дөнья күрә, аларда 155 автор катнаша.

Журнал битләрендә, гамәли проблемалар һәм мәгърифәтчелек мәсьәләләре белән бергә, инженер-техника, агрономия һәм икътисади фикернең яңа идеяләр турында да сүз алып барыла. Авыл хуҗалыгы һәм икътисади фәннәр буенча яшь кадрлар хәзерләүне күздә тотып, Киттари журнал эшчәнлегенә үзенең укучыларын да тарта. Журналда алдынгы Европа журналларында сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы технологиясе мәсьәләләренә багышланган мәкаләләрнең тәрҗемәләре дә басыла. Казан университеты басмаларыннан 1834 елдан Н. И. Лобачевский башлангычы белән нәшер ителгән "Казан университетының фәнни язмалары" тагын да зуррак әһәмияткә ия.

"Фәнни язмалар"ның беренче китабы басма хезмәтләрнең мәгарифне тарату һәм фәнне үстерү өлкәсендәге урынын билгеләгән ректорның мәкаләсе белән ачыла. Китап басуның әһәмияте турында Лобачевский: "Кичен бер кеше аңында туган фикер иртән меңнәрчә тапкыр кәгазьдә кабатлана һәм аннары кеше яши торган барлык җирләрнең бөтен почмакларына тарала. Бер ноктада кабынган очкын кинәт дөньяга якты нурларын сипкән кебек... фәнгә бирелгән кешеләр дә язу, үзенең ачышларын, карашларын һәм фикерләрен бастырып чыгару теләгенә каршы килә алмыйлар",—дип яза (А.В. Васильев. А.В. Лобачевский.—Казань, 1894.—С. 87-88, 90). Николай Иванович яңа журналны чын мәгънәсендә фәнни тикшеренүләрне бастырып чыгаруга юнәлтә. "Фәнни язмалар"да Лобачевскийның барлык хезмәтләре дә урын ала. 1834 елдан алып 1866 елга кадәр филология, педагогия, механика, физика, астрономия һәм башка фәннәргә кагылышлы мәкаләләрне эченә алган барысы 123 том дөнья күрә. Бу журналны Россиянең бик күп университетлары һәм җәмәгатьчелек китапханәләре алдыра.

Университетның шундый эшчәнлеген үзенә күрә шушы еллар эчендә "Казан әре нәшрият үзәге" дигән исемне аклап килә: аның типографиясендә рус телендә генә түгел, ә көнчыгыш телләрендә дә китаплар һәм уку әсбаплары басыла. Алай гына да түгел, Казан университеты Россиянең һәм дөньяның башка университетлары белән дә күп тармаклы тыгыз элемтә урнаштыра. Әлбәттә, фәнни һәм кадрлар алмашу, шәхси мөнәсәбәтләр урнаштыру буенча Мәскәү университеты беренче урында тора. XIX гасырның 40 елларында Казан университетында Казан һәм мәмләкәт славянлыгын өйрәнү фәненә нигез салучы В. И. Григорович эшли; ул славянлыкны өйрәнү фәне "барлык халыкларның якынаюына ярдәм итәргә тиеш" дигән караш тарафдары була.

Россиянең тарихи чынбарлыгы, мәмләкәт әдәбиятының бәрәкәтле йогынтысы, студентлар даирәсенең демократлашуы 40 еллар башында студент түгәрәкләре оешу феноменын тудыра. "Революцион ферментны" Казанга көнбатыш университетларыннан килгән студентлар тагын да көчәйтә төшә. 1839 елда, мәсәлән, Казанга җибәрелгән студентлар арасында юрист-профессор булып өлгергән А. Г. Станиславский да була. 1847 елда Казанга полиция күзәтүе астында укуларын дәвам итү шарты белән Киевтән Тарас Шевченконың көрәштәшләре, Кирилл—Мефодий җәмгыяте әгъзалары Г. Л. Андрузский һәм И. Пасяда да килеп төшә.

Шушы елларда Казан студентлары Фурье идеяләре белән таныша. Казан студентлары Д. И. Мейер ярдәмендә В. Г. Белинский хезмәтләрен өйрәнәләр. 1849 елдагы үзенең йомгаклау лекциясендә "безнең мәмләкәтнең эчке тормышында тынтәрелеш якынлаша" дип тәкърарларга җөрьәт иткән Мейер тирәсендә Санкт-

Петербургның "петрашевчылары" белән бәйләнгән алдынгы яшьләрнең түгәрәге оеша. 50 елларда исә, студент түгәрәкләренең әһәмияте тагын да арта төшә. Бу студентлар җәмгыяте оешу турында эчке бер "хәбәр" була. В.Г.Белинский мәкаләләрен уку укытучы-доктринерларның "метафизик саташуларын", университет түрәләренең "ахмаклыгын" сүгү—болар барыннан да элек Казан студент яшьләренең фикер юнәлешен билгеләүче яңа күренешләр булып торалар.



*Мөхәммәтгали Мәхмүдов*

Кырым сугышы нәтиҗәсендә туган патриотик хисләр Казанның иҗтимагый тормышына яңа сюжет сызыклары өстиләр. Кырым сугышы барган елларда, мәсәлән, М. Г. Мәхмүдов кече дәрәҗәдәге яралылар фондына матди ярдәм күрсәтә *(ТРның Милли архивы, ф. 92, тасв. 1, сак. бер. 6920)*. 1856 елда ул, О.М.Ковалевский, А. М. Бутлеров һәм Пенза дворяннар институты укытучысы И. Н. Ульянов белән берлектә, 1853—1856 еллардагы сугыш хөрмәтенә бронза медаль белән бүләкләнә.

XIX гасыр уртасында көтелгән университет реформасы турында фикер йөртүләр активлаша. Бу чорда "һәр яңага һәм иреклелеккә яшьләрчә хас омтылыш белән бирелүчән университетның укучы яшь көчләре, табигый рәвештә шул дәвернең ан уяну хәрәкәтенә тартыла һәм үзләренең озак йоклап яткан уй-ниятләрен һәм әхлакый көчләрен зур житезлек белән ача башлый" *(Корсаков Д. А. Былое в жизни Казанского университета 1856—1560 гг.: из воспоминаний о Прошлом.—С. 137)*. Иҗтимагый аңның уянуы, әлбәттә, крәстиән реформасына хәзерлек һәм аны гамәлгә ашыру белән тәгаенләнгән була. Индустриаль җәмгыятьнең массакүләм сәяси культурасы формалашу процессы 50 елларның ахырында, 60 елларның башында башлана. Ул, бер яктан, Россиянең социаль-сәяси тормышындагы гомуми үзгәрешләр белән; икенче яктан, турыдан-туры университетка кагылышлы мәсьәләләр белән аңлатыла: ул әкренләп барлык сыйныфларны да үз эченә ала. 1857—1860 елларда Казан университеты студентларының 63-70 процентын разночинецлар—дворян булмаган сыйныфлардан, вак түрәләрдән чыккан зыялы яшьләр тәшкил итә. Замандашлардан берәү Казан университеты бу елларда, нигездә, ярлы студентлардан тора иде, дип язып калдыра *(Русское слово, 1860, N 3, отд. 2.—С. 38)*. Мәгълүм өченче бүлекнең шефы Бенкердорфның "мәгърифәт белән артык мавыкмаска кирәк" дигән кисәтүендә хөкүмәт алып барган курс чагылыш табуына карамастан, университет студентлары арасында рус булмаган халык вәкилләре дә килеп эләгә. Аңлашылганча, күп кенә университетны тәмамлаучы студентлар төбәкнең рус булмаган халыкларның милли узаны һәм тулаем Россия Көнчыгышының тормышчан проблемалары белән кызыксына башлыйлар.

1861 елның башында Петербург һәм Казан университетларын тетрәндергән студентлар арасындагы чуалышлар хөкүмәт даирәсендә борчылу тудыра. Император хәлиткеч чаралар күрүне таләп итә һәм Мәскәүдә тиешле комиссия дә оештыра. Аның эшчәнлеге җыеннарны һәм студент оешмаларын тыю, университетларга разночинецларның эшчәнлеген авырлаштыручы "Май кагыйдәләре"н эшләүгә китерә. 1861 елның көзендә булып узган чуалышлардан соң, Казан университетыннан, Мәскәү һәм Петербург университетларына караганда да, күбрәк студент куыла.

Хакимият структураларының университетлар өстеннән күзәтчелеге 1863 елдан соң да күпмедер күләмдә саклана. Уставта попечительләрнең хокуклары житәрлек күләмдә тәгаенләнми, студентлар арасында чуалышлар тукталмый. 1863 елның Уставы 60 елларның либераль көчләре агымнары белән университетларда элек хөкем сөргән тәртип арасында "килешү" һәм Петербург бюрократик даирәсенең омтылышы буларак дөньяга килә. Бу бөтен катлауларның да канәгатьсезлеге һәм Уставка үзгәрешләр кертү теләге белән аңлатыла.

Казан студентлары академик иреклелек яулау хәрәкәтендә дә һәм демократия өчен көрәш мәсьәләсендә дә житди роль уйныйлар. Җыеннар уздыру, легаль булмаган әдәбият тарату, Россиянең башка шәһәрендә яшәүче радикаль карашлы яшьләр белән күп кырлы бәйләнешләр урнаштыру кебек студентларның активлыгын чагылдыручы күренешләр 60-80 елларда аеруча киң җәелә. Университет житәкчелеге, Мәгариф министрлыгы күрсәтмәсе нигезендә, Империя хакимиятенә университет студентларының һәм гимназия укучыларының "аңнары хәрәкәт юнәлеше" турында мәгълүмат җибәрә.

Хөкүмәт даирәсендә укучыларның һәм студентларның сәяси карашлары белән кызыксыну, утсыз төтен чыкмаган кебек, юктан гына тумый, әлбәттә.

Хөкүмәткә каршы чакыруларның рус булмаган студентлар арасына үтеп керүе турында мәгълүматлар бар. Әйтик, Казан полицмейстеры карашынча, 1856 елның 2 декабрендә Измаил Салихович Рәҗәпов, университетның Н.М. Соковнин, П.Г.Страден

һәм В.Ф. Понизовский кебек студентлары белән берлектә, хәрби офицерларның намусына һәм дәрәҗәсенә тап төшерлек дорфа кыланыш ясый *(ТРның Милли архивы, ф. 92, тасв. 1, сак. бер. 7163)*. Үз чиратында хәрбиләр дә, түгәрәкләргә берләшмәсен өчен студентлар өстеннән күзәтчелек итеп, полицайларга ярдәм итәргә тиеш булалар.

"Кыланыш ясаучыларның" эш-гамәлләре бик тә гыйбрәтле. Казан университетының табиблык факультеты студенты Рәҗәпов дүртенче курста укучы студент-юрист Н. Соковнин белән эшнәлек мөнәсәбәтенә керә. Соңгысының Сембердә пропаганда түгәрәге оештыруда тәҗрибәсе була. Бу "эш" буенча 13 студент кулга алына.

XIX гасырның 60 елларында татарларның легаль булмаган әдәбиятны таратуда катнашулары тагын да ешрак күзәтелә. Аерым алганда, университет студенты Л. А. Алиев крәстиәннәр арасында "Земля и воля" дигән яшерен оешманың прокламацияләрен тарату белән шөгыльләнә. Бу хакта Казан полициясенең император канцеляриясенең Өченче бүлегенә юлланган "донесениесе" сөйли. Анда Оханск шәһәрендә җирне бушлай тартып алу өчен халыкның бердәм рәвештә патшага каршы күтәрелергә чакырган ун нөсхә ачу кабартырлык характердагы чакыру табылды диелә *(ТРның Милли архивы, ф. 1, тасв, 2, сак. бер. 1883)*. "Эш" буенча кулга алынган Илья Пономарев күрсәтелгән нөсхәләрне "Казан университеты студенты Иван Яковлевич Орловтан алганлыгын", "идән асты" әдәбиятын тарату үзәгенең Казанда урнашуын, чакыруны "оешманың тугрылыклы кешеләре аша таратучы Үзәк комитет булуын" бәян итә. "Ачу китергеч" прокломацияләр тарату турында яшерен сорау алулар "бу эшкә студентлардан Павел Орлов, Жеманов, Бирюков, Алиев һәм Лаврскийның катнашы барлыгын" раслый *(Шунда ук, Л. 118)*.

Полиция "күзенә" төрле милләт студентлары эләгә. Юк кына гаепләре өчен төрлечә хезмәт дәрәҗәсендәге һәм белемдәге 22 кеше полиция күзәтүе астында торучы һәм "Молодая Россия" кульязмасын таратуда гаепләнүче Петров, Травин, Васильев кебек студентлар исемлегенә берләштереләләр *(ТРның Милли архивы, ф. 1, тасв. 2, сак. бер, 1854)*. Элеккеге студентка Чернышевскийның көрәштәше, Себергә сөрелгән Михайлов белән бәйләнештә тора дигән гаеп тагыла. Н. Беневитский Бездна җеназасында катнашуда гаепләнә, ә студент Николай Шефнерга "рус императорларының самодержавиесе хакимияте—халык бәхетсезлегенең төп сәбәбе", "безнең ватанны әлеге кутырыннан бары тик конституция кабул итү генә коткара ала" дигән белдерүе өчен җинаятьче ярлыгы тагыла *(ТРның Милли архивы, ф. 1, тасв. 2, сак. бер. 1764)*. Шул ук исемлеккә Казан университеты студенты Сәлахов Сергач өязе укытучысы Курбаковский белән язышып торганы өчен килеп эләгә *(ТР ның Милли архивы, ф. 1, тасв. 2, сак. бер. 1856)*. Язышуның эчтәлеге безнең көннәргә килеп җитмәгән, әмма Курбаковскийның карашлары "Современник" һәм "Колокол" журналының йогынтысы нәтиҗәсендә формалашуы мәгълүм.

Курбаковский студентларның болганышларында катнашканы өчен Казан университетыннан куылгач халык укытучысы булып китә. Шул рәвешле, Казан университеты илдә башланган җәмәгатьчелек активлыгыннан читтә калмаган, дип әйтә алабыз. Оппозициядә тору төрлечә чагылыш таба—үз-үзенне тотуның өстән билгеләнгән кагыйдәләрен бозудан алып, сәяси оппозиция платформасында оешуга кадәр... Түрәләргә тәлинкә тоту һәм конформизмнан арыну процессы сизелерлек җанлана. Студентларның психологик төс-кыяфәте үзгәрә: әле күптән түгел генә сәясәттән ерак торган "инфантиль" яшь кешенең карашларында тәнкыйди башлангычлар пәйда була һәм ул үзенең дәрәҗәсен ачыктан-ачык яклый башлый. Укыту системасына һәм формасына мөнәсәбәттә дә тәнкыйди карашлар көчәя: инде студентлар өстеннән каравыллап тору үзенең нәтиҗәләрен бирми башлый һәм студентлар суды әкренләп эшкә керешә.

XIX гасырның 50 елларында очрашуларны яклауның отышлы формасы булып Җыеннар тора. Анда студентлар башка университетлардагы иптәшләренә теләктәшлек күрсәтәләр, хөкүмәтнең сәяси курсына протест белдерәләр. 1861 елның 12 апрелендә Бездна авылы крәстиәннәрын аттырудан башланган җыен университет һәм шәһәр тормышында зур "резонанс" ала. Ул чакта Рухани академия һәм университет студентлары Арча кырындагы зиратта аттырылган крәстиәннәр рухына багышланган җеназа үткәрәләр. Җеназада университет тарихчысы А. П. Щапов хөкүмәткә каршы юнәлтелгән нотык белән чыгыш ясый. Ул крәстиәннәрне баш күтәрүгә "котырткан" крәстиән Антон Петровны пәйгамбәрләр рәтенә кертә, шулар "исемлегеннән" Иисус Христосны да искә алырга онытмый. Аттырылган крәстиәннәрне Щапов сәяси ирек өчен газап чигүчеләр дип атый. Әлеге дә баягы Куртин җеназасында катнашучылар, шул исәптән Щапов та, эзәрлекләнүгә дучар ителәләр *(Вульфсон Г. Н. "Глашатай свободы".—Казань, 1984)*.

1861 елда Петербург һәм Казан университетларын биләп алган студентлар чолганышы хөкүмәт даирәсен куркуга сала. Әйткәнебезчә, Мәскәүдә бу мәсьәлә буенча махсус комиссия төзелә, аның нәтиҗәсе җыеннарны һәм студентлар оешмасын тыючы "Май кагыйдәләрен" эшләү белән тәгалләнә. Университетка "түбән" булмаган

катламнан чыккан яшьләрнең әләгүе читенләшә. Ә 1887 елда В. Ульянов та катнашкан мәгълүм студентлар җыены "баш күтәрүнең" югары ноктасына әйләнә.

Сәяси карашларда радикальлек көчәю белән бергә, Казан университеты Казакъстан, Урта Азия һәм Себер халыклары өчен фәнни һәм мәгариф үзәге буларак "изге миссиясен" башкарып килә.

Көнчыгыш "компоненты" Казанның сәяси даирәсендә дә ачык чагыла. Моны XIX гасыр азагында Казанда булып киткән кешеләр дә билгеләп үтәләр. 70 елларда Казаннан үтеп киткән Г. Потанин дигән берәү, мәсәлән, шәһәр "татар кешесен очратырга мөмкин булуы белән игътибарга лаеклы" дигән нәтиҗәгә килә. Ул: "Татар базары, татар мәчетләре, татар типографиясе, гарәп теле белгечләре түгәрәге—барлык бу үзенчәлекләр Идел буеның башка шәһәрләрендә очрамыйлар",—дип яза үзенең язмаларында *(Потанин Г. Путевые заметки из Новочеркасска до Казани. // Первый шаг: Провинциальный литературный сборник.—Казань, 1876.—С. 331).* Гарәп теле белгечләре дигәндә, Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең эшчәнлеге күздә тотыла. 1878—1917 еллар эчендә аның составына Урта Азиядә—аерым алганда, Ташкентта, Чимкентта, Тургай өлкәсендә яшәүче галимнәр керә; болар—В.В. Сапожников, В.Н. Скопин, Н.П. Остроумов, Г.И. Подягин; Себердән—А.Е. Алекторов (Омск), Г.Н. Потанин (Томск), Н.Ф. Катанов. Юридик факультетта укыган казакъ студентлары С.Сыздыков белән Б. Каратаев та шулай ук җәмгыять эшчәнлегендә катнашалар. Казакъстаннан килгән танылган тарихчы һәм фольклорчы А. Диваев та җәмгыять әгъзасы булып тора. Үзләренең "Хәбәрләр"ендә Җәмгыять әгъзалары Казакъстанның мәдәнитенә һәм тарихына караган кырыкка якын фәнни хезмәт бастыралар. Болар этнография, археология, тарих турындагы һәм Идел буе, Себер, Урта Азия халыкларының милли азатлык хәрәкәтләрен тасвирлаучы хезмәтләрне, халык авыз иҗаты әсәрләрен, рус булмаган халыкларның сүзлекләрен үз эченә алалар. Шулай ук "кыргыз халык иҗаты ядкярләре" дигән баш астында төрки халыкларның фольклорына багышланган материаллар да дөнья күрә.



*Николай Федорович Катанов. 1862-1922.*

Җәмгыятьнең басмалары "Материаллар" (археология, тарих һәм этнографиягә караган хезмәтләр), "Музеография", "Корреспонденцияләр" төрләренә бүленәләр. Алар Иркутск, Красноярск, Минусинск, Тубыл, Якутск һәм башка шәһәрләрнең төбәкне өйрәнү музейлары һәм фәнни оешмалары белән бәйланышлар урнаштырылганлыгын искәртеп торалар. Җәмгыятьнең рәисе булып Н. Ф. Катанов торган чорда (1893—1914) "Хәбәрләр"дә казакъ халкы тормышына һәм мәдәниятенә багышланган 26 дан артык хезмәт бастырыла. Күп кенә мәкаләләрнең мөхәррире һәм тәрҗемәчесе Катанов үзе була. 1895—1996 уку елында Мәгариф министры рөхсәте белән Катанов университетта казакъ теле курсын алып бара. Аның 1890 елның 12 февралендә укыган "Кыргызлар: аларның үткәне һәм бүгенгесе" дигән лекциясе казакъ мәдәниятен өйрәнү буенча үзенә күрә бер этап булып тора.

"Хәбәрләр"дә Казах училищесы юнкеры М. Бекимов та үзенең хезмәтләрен бастыра. Ул "Казакъча—русча сүзлек"не төзүче буларак та мәгълүм шәхес. Биредә, шулай ук, география җәмгыятенең Себер, Оренбург, Төркестан бүлекләре хезмәтләре дә урын ала.

Шул рәвешле, XIX гасыр дәвамында Казанның иҗтимагый һәм мәдәни тормышы торган саен "цивилизациялерәк" төсмер ала бара, ул Россиянең Идел буе һәм Урал төбәкләренең матбугаты, гомум Россия һәм дөнья күләм әһәмияткә ия булган хезмәтләр туу учагына әверелә. Гасыр уртасыннан башлап академик рухтагы мәкаләләр университет тормышының нигезләрен үзгәртеп кору проблемалары белән алмашына, студентлар чыгышларының төп өлешен сәясәт мәсьәләләре алып тора башлый.

## КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫ: СЕБЕР ТӨБӘГЕ, КАЗАКЪСТАН ХАЛЫКЛАРЫН АГАРТУ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

"Россия Себер хисабына үсеш алачак!" дип әйтүе белән М. В. Ломоносов Себер төбәгенең чәчәк атуына зур өметләр баглый. Шушыңа охшаш фикерләрне Д.И. Менделеев белән А. И. Герцен да әйтеп калдыра. Мондый гоманлаулар мәгариф үсешен гамәлгә ашыру белән тәгаенләнә. Шуна да карамастан, асылда XVIII гасыр ахырыннан алып XX гасыр башына кадәр, Себер дөньясы мәктәпләрнең аз санлы булуы, аларның матди

яктан начар жиһазлануы, хәзерлекле кадрларның житешмәве, мәктәп яшендәге балаларның аз санлы булуы белән аерылып тора. Бу унайдан уянып килүче Себер ижтимагый фикеренең күренекле вәкиле, Себер "өлкәчелеге" идеясенең танылган тарафдары Н. М. Ядринцев болай дип язып калдыра: "Ике йөз ел дәвамында Себер мәгариф мәсьәләсендә бөтенләй ташландык хәлдә иде. XIX гасыр башына кадәр һәм әле аннан соң да мәгариф мәсьәләсендә тәмамсы онытылган һәм ул тулы мәгънәсендә ин артта калган һәм кыргый бер өлкә иде" *(Потребность знаний на Востоке.) 1875, октябрь.—С. 34).* Гражданлык мәктәпләре биредә эре шәһәрләрдә XVIII гасырның икенче яртысында пәйда була. 1789 елда төп халык училищелары Тубылда, Иркутскида һәм кечесе Томскида ачыла. Рус булмаган халыклар өчен оештырылган халык мәгарифе челтәре дә бик зәгыйфь була. Алар өчен миссионерлык мәктәпләре ачу омтылышы зур каршылыкларга очрый һәм Тубылда, Байкал арты төбәгендә, Камчаткада, Иннокентьевскида, шулай ук Ачинскида оештырылган миссионерлык училищелары мәгариф мәсьәләсендә "юк" дәрәжәсендә әһәмияткә ия булалар. Үз дини мәктәпләре булган татар мөселманнары арасында исә укымышлылык шактый дәрәҗәдә югары була.

Казан университеты Себер мәктәпләренә химаячелек күрсәтүне С. Я. Разумовский попечительлек иткән чордан алып, ягъни 1805 елда Иркутски гимназиясендә якут мәктәпләрендә укытучылар хәзерләүгә рөхсәт алганнан соң башлый. Мондый мәктәпләрне ул дәвердә фидакарь-укытучылар башлангычы белән ачылуга да керешелә. Университет Советына Себердән мәктәпләр ачу һәм яшәп килүче мәктәпләргә укытучылар жибәрүне сорап күп санлы мөрәжәгатьләр килеп төшә. Себернең генерал-губернаторы И. Б. Пестельнең мөрәжәгатенә таянып һәм университетның турыдан-туры ярдәме аркасында 1811 елда Троицк-Савск кальгасында, Туруханскида, Ачинскида, Канскида, Минусинскида һәм Тарада өяз училищелары ачыла.

Күп кенә Себер кешеләре мәктәпләрне финансларга теләкләре барлыгын белдерәләр. Алай гына да түгел, кайбер укытучылар да хезмәт хакларының бер өлешен мәгариф хажәтләре өчен тотарга риза булалар. XIX гасырның 20 елларында Россиядә "үзара" укыту методы киң жәелә башлый. Ул укытучыга күз уңында берьюлы күп укучыны тотарга мөмкинлек бирә. Андый мәктәпләр Себердә дә барлыкка килә. Казан университеты алар өчен укытучы кадрлар сайлауда катнаша, финанслау буенча башлап йөри, матди ярдәм күрсәтүләрен үтенеп жирле халыкка мөрәжәгать итә. Себернең үзендә кадрлар хәзерләү максатыннан чыгып, университет Югары Себер училищесы ачарга кирәк дигән карарга килә, анда төрле катлам вәкилләре белем алырга тиеш була. Училищега кабул ителгән студентларны башта өяз училищеларында, аннары гимназиядә, соңыннан гына Югары Себер училищесында укыту карала. Югары училищеның укыту программасына көнчыгыш телләрен кертү дә көн тәртибенә куела. Әмма эш шуннан ары китә алмый: хөкүмәт әлеге проектны расламый.




Укытучылар итеп хәзерләү һәм татар телен өйрәнү максатыннан чыгып, Тубыл һәм Томск губерналары губернаторы 1822 елда мәгариф министры А.Н. Голицынга Омск Азия мәктәбенең алты укучысын һәм Казан хәрби-ятимнәр бүлегенең унике контонистын Казан гимназиясенә укырга бирүне үтенеп мөрәжәгать итә. Мондый адымны ясарга, әлбәттә, Казан гимназиясендә танылган татар теле укытучысы Хәлфин житәкчелек иткән татар классы булу да этәрә *(ТР Милли архивы, ф. 92, тасв. 1, сак. бер. 1977).*

Ике ел үткәннән соң губернатор шундый ук сорау белән министр А.С. Шишковка да мөрәжәгать итә. Үтенеч канәгатьләндерелә. Азия училищесының алты укучысыннан икесе мөселманнар була һәм алар христиан динендәге укучылардан аерым урнаштырыла. Хәлфин исә, шактый авыр шартларда яшәвенә дә карамастан, Айса Бикмаев белән Курбанаков дигән укучыларны үзенә урнаштыра. Хәлфин житәкчелегендә укып-белем алып, аларның икесе дә университетка укырга керәләр.

Укытучы, табиб һәм түрә кадрлар житешмәү сәбәпле Петербург Себердән килгән укучылар өчен Казан университетында уку дәверендә махсус егерме стипендият билгели. Курсны тәмамлаганнан соң, укучылар билгеләнгән урында ким дигәндә ун ел эшләргә тиеш булалар. 1855—1861 елларда Мәскәү, Петербург һәм Казан университетларында барлыгы 132 себер егетләре һәм кызлары белем ала, шуларның 87 се Казан университетында тупланә *(Михайлова С. М. Казанский университет в духовной культуре народов Востока.—Казань, 1991).*

Танылган җәмәгать эшлеклесе һәм галим П. А. Словцовның тормышы һәм

эшчәнлеге Казан университеты белән тыгыз бәйләнә. Иркутск училищесында директор булып торган дәверендә ул университет Советы аркылы гимназиядә музыка дәресләре алып баруга рөхсәт ала, ә 1817 елдан бер чит ил дәресләре урынына өстәмә рәвештә рус теленнән сәгатьләр алуга ирешә.

Университет Словцовка Казаннан алып Томскига кадәрге биниһая киң өлкәдә урнашкан уку йортларын тикшереп тору бурычын йөкли. Шушы хәлләрдән соң ул Казан уку округына кергән училищеларның инспекторы итеп билгеләнә. Словцов администратор гына булмый, ә бәлки үзен төбәкне өйрәнүче галим итеп тә таныта, ул Себернең күп санлы курганнарын "буддизм, сәнгатьчелек, сугышчанлык һәм байлык" эзләрен саклаучы ядкярләр дип атый *(Мирзаев В. Историография Сибири.—М., 1968, Т.II; Окладников А.П. История и культура Бурятии.—Улан-Удэ, 1976)*. Үләренә бер ел кала Словцов Тара училищесына шәхси китапханәсен бүләк итә, ә Себернең тинсез минераллары һәм үсемлекләре коллекциясен Казан университетына тапшыруларын үтенә.

XIX гасырның икенче яртысыннан якут мәктәпләре челтәре шактый киңәя: 1871 елдан башлап якутлар өчен Ачинск һәм Сунгур училищелары ачыла, Чурапча һәм Югары-Вилюй олыс училищелары эшли башлый. Мондый уку йортлары тирә-юньдә яшәүче халыклар тарафыннан финанслана. Ләкин аларда якут телендәге дәреслекләр "юк" дәрәҗәсендә аз була. Жирле халык хокуксыз була һәм изелгән хәлдә яшәргә мәхкүм ителгән була, аның каравы старосталар, писарьлар һәм старшиналар ни теләсә шуны эшлиләр. Якутлар тормыш-көнкүрешен күзәткәннән соң, Чернышевский: "Алар киң күнелле һәм анлы кешеләр, бәлки әле Европалылардан сәләтлерәктер дә (мәктәпләрдә якут балалары русларга караганда яхшырак та укыйлар дип сөйлиләр). Ләкин алар мескен вә хәерче кыргыйлар, дөньяда алардан да кызганычрак кешеләр юк... Аларның ничек яшәгәнен күрсән, күнелләр болгана" *(Чернышевская Н.М. Повесть о Чернышевском.—Саратов, 1971.—С. 188-189)*.

Бурятия иганәчеләре хисабына далада урнашкан җәйләүләрдә һәм управаларда берничә рус-бурят мәктәбе ачыла. Алар тәрҗемәчеләр һәм вак түрәләр хәзерләп чыгаралар. 1872 елда бурят-монгол мәктәпләрендә дәресләрне туган телдә алып баруны рөхсәт итүен үтенеп, бер бурят кешесе халык исеменнән патшага гозер тапшыру өчен Петербургка юл тота *(Эфиров А. Ф. Нерусские школы Поволжья, Приуралья и Сибири.—М., 1948.—С. 83)*. "Бурятлар Читада күп чыгымнар тотканнан соң пансион ачылуын зур шатлык белән каршы алдылар",—дип хәбәр итә "Вестник Европы" *(Из истории просвещения сибирских инородцев. //Вестник Европы, 1901, Т. IV—С. 183-1900)*.

Казан университетын тәмамлаучылар Тубылга, Томскига, Иркутскига һәм башка төбәкләргә мөгаллимлек итәргә юнәләләр. Аларның таралу кинлеге Казан укыту округына бирелгән гозернамәләрдә дә ачык чагыла; округка җитәкчелек иткән Казан университеты исә гимназияләрне һәм өяз училищеларын укыту-методик әсбаплары белән тәэмин итеп тора. Мөгаллимнәрнең эше турында университет Советына баштарак Тубыл гимназиясе, сонрак Тубыл училищелары директоры булып эшләгән А. Н. Арнольд һәрдаим рапортлар җибәреп тора. Университет Советы аның эшчәнлегеннән канәгать була, замандашлары да аның тырышлыгын унай яктан бәяләп үтәләр.

Казан университетының Себер һәм Россиянең Көнчыгышы өчен нинди әһәмияткә ия булуын аны тәмамлаган В. Оков бик калку итеп сурәтләп бирә: "Казан университеты рус университетлары арасында аерым урын алып тора,—дип яза ул.—Россиянең көнбатышында һәм көньягында берничә университет һәм лицей тупланган, ә Россия Европасының көнчыгыш өлеше һәм бөтен Себернең биниһая кинлекләрендә бары тик берданбер—Казан университеты гына бар һәм ул Казан, Түбән Новгород, Пенза, Әстерхан, Саратов, Сембер, Самара, Пермь, Вятка губерналары гимназияләрен мөгаллимнәр белән тәэмин итеп торып, Рус патшалыгының бу өлешендә яшәүче яшь буынына югары белем бирә. Себердәге табиблар, бөтенләе белән дип әйтерлек, Казаннан. Дөрес, Россиянең көнчыгыш өлкәләре һәм Себер алып торган биләмәләрдән чыккан студентларның чагыштырмача аз булуы бу төбәктә мәгарифнең торышы турында унай тәэсир уятмый, ләкин бу өлкәнең зур кинлекләргә җәелүе һәм ярлы катламнан чыккан яшьләрнең университетта күренмәве, чит төбәкләргә китәргә мөмкинлеге булмау белән анлатыла" *(Отчет о состоянии Имп. Казанского университета за 1858—1859 академический год.—Казань, 1859.—С. 3-4)*.

Казан университетының мәмләкәтнең көнчыгышы өчен нинди социокультура миссия башкаруы турында Н. Чернышевскийның һәм Н. Добролюбовның фикердәше Н. Шелгунов сонрак "Себер Казанда интеллектуаль үзәк булдыры" дип язып билгеләп уза. Ул: "Себернең Казанга тартылуы сәбәпләре бик гади—Казанда университет бар, ул Себердә юк... Казанда бөтен рус Көнчыгышының органы булган "Камско-Волжская газета" чыгарыла",—дип исәпли *(Дело, 1873, N 10.—С. 93)*.

1875 елда Себердә биш гимназия, өч реаль училище һәм дүрт рухани семинария эшләп килә. Казан университеты тырышлыгы һәм җитәкчелеге белән төзелгән мәктәпләр әкренләп мәгърифәт учакларына әвереләләр. Троиц-Савск кальгасында оештырылган рус-бурят мәктәбен әнә шундыйлар рәтенә кертергә мөмкин. Мәктәпнең иң сәләтле укытучыларыннан саналган Галсан Никитуев хәтта көнчыгыш телләрен

өйрәнсеннәр өчен үзенең Д. Буянтуев, Ц. Чимитов, Г. Будаев һәм Д. Банзаров кебек укучыларын Казанга илтеп куя.

Казан университеты студентларыннан А. Иконников, Ф. Некрасов һәм бертуган Знаменскийлар фәнни экспедиция вакытында Тубылда укуларын дәвам итәргә теләгән укучылар өчен иганәчелек җәмгыяте оештыралар. Березов шәһәренә сөрелгән университетның ирекле тыңлаучысы А. Иконников анда әдәби кичәләр оештыра. Кайбер Казан университетын тәмамлаган себер студентлары да төбәкнең тарихи сәхифәсендә якты эз калдыралар. Әйтик, Казан якшәмбе мәктәпләренең баш эш йөртүчесе булып себер стипендиаты, Тубыл гимназиясе укучысы һәм Казан университетын тәмамлаган профессор А. К. Чугуков тора. Ул университет каршында эшләп килгән Казан икътисад җәмгыятенең сәркәтибе була, шул ук вакытта "Казан биржа листогы"ның нашире һәм мөхәррире вазифаларын башкара. Казан университетының редакторы булып торган Рим хокукы профессоры Н. А. Кремлев та Себер якларыннан—ул үз вакытында Тубыл гимназиясен тәмамлаган булган.



*Д. Банзаров.*

Себердә университет ачу идеясенең озын тарихы бар. Әле 1821 елда инспектор булып торган П. А. Словцов Казан укыту округы попечителенә "Себер училищеларының максаты турында бер фикер"ен житкерә. Бу ватанпәрвәр һәм энтузиаст шәхес Себер үз өйрәнүчеләрен көтеп ятучы бай тарихлы төбәк дигән караштa тора: "Себер, зур вакыйгалар алдында торуына һәм Кытай белән күкрәккә күкрәк терәп яшәвенә карамастан, гимназияләрдә ни Себер, ни Кытай тарихын өйрәнүне кирәк тапмый..." Словцов шул хәтле байлыгы һәм табигать серләре булган Себер өчен башлангыч һәм урта мәктәпләр системасы бик тә аз дип икърар итә. Димәк, югары уку йорты—университет ачарга кирәк! Словцовның "Фикере..."нә таянып, попечитель Магницкий "Себердә укыту өлкәсе булдыру турында" проект эшли. Казан университеты Советы исә Барнаулда бер бүлеге булган "Югары Себер училищесын" ачарга кирәк дигән карар кабул итә".

Шушы ук вакытта Көнбатыш Себернең генерал-губернаторы Канцевич та университет ачарга кирәк дигән башлангыч белән чыга. Университетлар ачу турындагы проектлар уңышсызлыкка очрагач, себерлеләргә югары белем алу өчен (кайчак җәяүле килеш!) Казанга табан юл тотарга туры килә *(Манассеин В. С. Возникновение и развитие идеи учереждения Сибирского университета.—Иркутск, 1924.—С. 14, 30).* Һәр ел саен Себер өчен утызга якын студент кабул итеп, Казан университеты Себер мәктәпләре өчен үзенә күрә укыту-административ үзәк вазифасын башкара. Бу вакытта Мәскәү, Петербург һәм Казан университетларында барысы 289 себер студенты белем ала *(Оксенов А. М. История просвещения Сибири и университетский вопрос).*

Себердә университет кирәклеге турындагы карашларның һаман саен ныгый баруы турында 1863 елның декабрендә Н. М. Ядринцев һәм кадет корпусы офицерлары тарафыннан Омскида үткәрелгән кичәнең зур яңгыраш алуы да ачык сөйли. Бу кичәдә Ядринцев Себер университетын ачуга багышланган мәкаләсен укый. Мондый гомуми рухи күтәрелеш эзсез үтми, әлбәттә: шулай итеп 1878 елда Томск университеты бинасының беренче ташы салына, ул 1880 елда ачыла. Беренче Себер университеты ул чакта бердәнбер—медицина факультетыннан гына тора. Бу мәсьәләне обер-прокурор К.П. Победосцев кире яктан бәяли: "Безнең университетлар тәмам ярлыланган һәм түбән тәгәрәгән бер вакытта Себердә университет ачу турындагы фикерне мин баштан ук уңышсызлыкка очраячак һәм ялган дип атадым... Томскидагы җәмәгатьчелекне теләсә нинди әтрак-әләм тәшкил итә: аның университетка нинди йогынты ясаячагын күз алдына китерү кыен түгел" *(Письма К. П. Победоносцева к Александру III.—Т.2.—М., 1926.—С. 99—100).*

Мондый кискен карар чыгаруның һәм обер-прокурорның мәгърифәтнең көченә ышанмауның урынсыз икәнлеген раслау өчен беренче Себер университетын ачу өчен 360 мең сумнан артык иганәчелек акчасы җыелу да ачык дәлил булып тора *(Краткий очерк Имп. Томского университета.—Томск, 1913.—С. 3).*

Томск университеты өчен кадрлар хәзерләү үзәге вазифасын Казан университеты башкара. Әйтик, 1888 елда бирегә минералогия кафедрасына гадәттән тыш профессор сыйфатында танылган химик Александр Михайлович Зайцевның туганы Алексей Михайлович Зайцев күчерелә. Алексей Михайлович Казан университетын 1879 елда физика-математика кандидаты дәрәҗәсен алып тәмамлый. 1887 елда исә минерология һәм геодезия докторы дигән дәрәҗәгә ирешә.

Казан профессоры В.М. Флоринский Томск университетының төзелеш комитеты составына керә. Беренче Себер университетын ачылуы белән котлаучылар арасында аның "Казандаш туганы" да була *(Первый университет в Сибири.—Томск, 1889.—С. 14).* Шул рәвешле, Казан университеты Себер халыклары арасында мәгърифәт нурлары тарату

өлкәсендә генә түгел, җәмгатьчелек аңы үсешендә дә мөһим эшләр башкара.

Казан университетын тәмалаучылар җирле халыкка медицина хезмәте күрсәтү буенча да өлгерлек күрсәтәләр. Аннары, башка Казан уку йортларында белем алучылар белән бергә, Казан университетын тәмамлаучылар 1917 елга кадәр вакыт эчендә казакъ зыялыларының төп өлешен тәшкил итә. Казакъларга Казанга юл алу 1877 елдан соң гына мөмкин була, ник дигәндә, 1863 елга кадәр юридик киртәләр яшәп килгән була. Университет белән казакъ далаларында беренче рус-казакъ мәктәбен оештыручы Буки Урдасы ханы да (1824—1845) бәйләнештә тора. Европага белемгә һәм дәүләт эшлеклесе карашларына ия булган хан Казан университетына тугыз данәдә көнчыгыш кулъязмасы тапшыра. Үз акчасына ул А. Казымбәкнең "Мюхтесергюльвигкает" дигән зур әһәмияткә ия булган хезмәтен бастырып чыгара. Ханның канцеляриясе белән Казан университетын тәмамлаган Г. Матвеев житәкчелек итә *(Кенжетаев Б. Л, Казанские учебные заведения и процесс формирования казахской интеллегенции в середине XIX—начале XX вв.—Казань, 1998.—С. 26-28).*



*Ал. К. Казембәк.*

Беренче казакъ мәктәпләрен ачу да казакъ тамырлары белән Казан университетына килеп тоташа. Мондый мәктәпләр турында үз проектын Оренбург чик буе комиссиясендә эшләгән Хәлфиннең шәкерте Айса Бикмаев та тәкъдим итә *(Воспоминания об И.А. Алтин-Сарине Н. Ильминского.—Казань, 1891.—С. 47).*

1877 елдан алып 1917 елга кадәр Казан университетында 37 казакъ студенты белем ала. Нигездә алар генерал-адъютант Н.А. Крыжановский исемендәге стипендия хисабына укыйлар *(стипендия 1875 елда аның Оренбург генерал-губернаторы вазифаларын башкаруына ун ел тулу уңаеннан билгеләнә).* Казакълардан беренче булып хокук белеме кандидаты дәрәҗәсенә ирешкән кеше *(1882)*—"Дала өлкәләрендә яшәп килүче идарә итү алымнары" дигән хезмәтнең авторы солтан Ж. Чуваков була. Әйтергә кирәк, Себердә эшләүче табиблар арасында поляклар күп була. Медицина факультетын тәмамлаган П.А. Бальбуциновский баштарак Верненск хәрби госпиталендә эшли, аннары Чимкентта, Ташкентта һәм Төркестан далаларында авырулар дәвалый. Аңа ярдәм сорап, хәтта мөселман хатын-кызлары да мөрәҗәгать итә торган була. Бальбуциновский кулдан килгән чаралар ярдәмендә җирле халыкны дәвалый алырлык күләмдә башкорт, казакъ һәм татарлардан табиб-шәкертләр хәзерли. Хезмәттәшләре аны төбәкнең иң яхшы табибларыннан берсе дип исәплиләр. 1873 елда ул Казан университетында докторлык диссертациясе яклый.

Холерага каршы иң актив көрәшчеләрнең берсе Казан университетын тәмамлаган Б.М. Мариупольский була. Медицина факультетын тәгәлләү белән ул Петропавлоск шәһәренә эшкә җибәрелә, "хезмәт хакы алмыйча" гына авыру ярлыларны дәвалый; бер үк вакытта педагогик эшчәнлек белән дә шөгыльләнә—шәһәр хатын-кызлар гимназиясендә медицина буенча дәресләр бирә. 1898 елда Мариупольский үзәк фельшерлык мәктәбенә житәкчелек итә. Анда укып чыккан татарлар, башкортлар һәм кыргызлар (казакълар) Себернең һәм Казакъстанның иксез-чиксез киңлекләрендә авыруларны дәвалыйлар.

Себердә ветеринария белемен таратуга профессор, Варшава ветеринария мәктәбе вәкиле, Казан университеты составыннан аерылып чыккач, Казан ветерианария институтының беренче директоры булып торган Петер Зейфман күп көч куя. Профессор-офтальмалог Е. В. Адамюкның киң абруй казануы хакында шул нәрсә дә сөйли: халык арасында күз табибларын "адамюклар" дип атап йөртә башлыйлар. Бу нәүбәттән, "Волжский курьер" газетасы 1905 елда: "Россиянең Көнчыгыш халыклары арасында Адамюктан да шөһрәтлерәк башка табиб юк иде",—дип язып чыга.

Вильнодан Казан университетына укырга җибәрелгән Г. В. Гонсевский соңрак Себердә мөгаллимлек итә башлый. Себер кадетлар корпусында ул биргән тарих дәресләре укучылар арасында киң казаныш таба. Көнбатыш Европа дәүләтләре тарихын яхшы белүче бу галим тынлаучыларына Шандор Петефи, Жан-Поль Марат, Джузеппе Гарибальди кебек мәшһүр шәхесләр турында кызыклы мәгълүматлар җиткерә; аның чыгышлары гражданнарның тигезлегенә корылган республика тибындагы идарә итүнең өстенлекләрен бәян итүче фикерләр белән өртелгән була. К.К. Гутковский белән берлектә ул мәгърифәтче Чокан Вәлиханов карашлары формалашуга зур йогынты ясый. Вәлихановның сайланма әсәрләренә язган кереш сүзендә Г. Потанин болай дип искәртә: Гонсевский белән алып барган әңгәмәләр барышында Чокан "ул вакытта ук иптәшләре өчен, шул исәптән минем өчен дә, ябык китап булган сәяси карашлар белән таныша... Бу Европага уелган тәрәзә иде" *(Валиханов И.И. Сочинения. Т. IV.—С. 310, 311).*

Реформага хәзерлек чорында Себер өлкәчелеге идеясе пәйда була. Аның тарафдарлары—Г.Н. Поганин һәм Н.М. Ядринцев—күп кенә унай тезислар күтәреп чыгалар: алар Себер өчен, жинаятьчелек сөргене урыны вазифаларын башкаруы, һәлакәтькә тин булуын татуга кайтып калалар; шулай ук Себер икътисади мәнфәгатьләренен Мәскәү мануфактура базарына буйсынуына каршы фикерләр белдерелә. Тезисларнын тарафдарлары Себернен үзендә Себер мәнфәгатьләрен кайгырта алучы зыялыларнын булмавын зур ачыну белән билгеләп үтәләр. Аларның программасы жинаятьчел сөргенне юк итү "метрополиягә" каршы көрәштә ирек яклау хәрәкәтенен башлангычы; Себерне Россиянен Европа өлешеннән икътисади яклап азат итү; Себердә университет ачу яшьләрне рухи таркалудан саклап калу юлында беренче адым булыр иде дигән пунктларны да үз эченә ала.

Өлкәчелек идеяләрен хәзерләүгә 1860—1861 елларда Казан университетында укыткан тарихчы—Себер тарихы турында хезмәтләр авторы А. П. Щапов зур йогынты ясый. Ул—нигезен халыкчанлык һәм өлкәчелек принциплары тәшкил иткән тарихи-социологик концепцияне эшләүче. Щапов, рус жирләре белән ирекле үзидарәчелек вакытларынын позитив һәм перспективалы күренеш дип билгеләп үтеп, Россиянен үзәкләштерелгән чорына тискәре караш ташлый. Анын Россиядә өлкәчелек үзидарәсен кертү кирәклеге турындагы нәтиҗәләре, шулай ук Себердә формалашкан рус халкынын яна этнографик тибы барлыкка килүе турындагы гипотезасы өлкәчелек тарафдарларына Себерне аерып алуны аклау өчен теоретик аргумент булып хезмәт итә *(Сесюнина М.Г., Г. Н. Потанин и Н. М. Ядринцев—идеологи сибирского областничества.—Томск, 1974.—С. 44-52).* Бу унайдан хәтергә төшерик: XIX гасырнын 70 елларында Г.Н. Потанин белән Н.М. Ядринцев К. Лаврский нәшер иткән "Камско-Волжская газета" белән актив хезмәттәшлек итәләр.

Шул рәвешле, Казан университетынын Себер һәм Казакъстан халыклары язмышындагы урыны күп кырлы. Анын берсе, сәясәт нигезен дә кертеп, Европа культурасы белән таныштырудан гыйбарәт. Анын ижтимагый идеяләрне, шул исәптән төбәк үзидарәсен оештырудагы ролен дә инкарь итеп булмый.

## КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНЫҢ ТАРИХИ УРЫНЫ (XX ГАСЫР)

Казан университеты галимнәренен Россия һәм дөнья фәне үсешенә керткән өлеше зур һәм күп төрле; безнен галимнәрнен фундаменталь хезмәтләре кешелек акылы ирешкән бөек ачышлар тарихына алтын хәрефләр белән язылган.

XIX гасырда һәм гасырлар чигендә университетта мәшһүр математиклар, физиклар, химиклар, ижтимагый һәм гуманитар фәннәр вәкилләре ижат итә.

Казан галимнәренен—неевклид геометриясенә нигез салучы мәшһүр Н.И. Лобачевскийнын, дөньяда беренче булып нитробензолдан ясалма анилин синтезлаган һәм шунын белән сәнәгать органик синтезнын принципиаль яна мөмкинлекләрен ачкан Н.Н. Зининнын, яна химик элемент ачкан (ул ана "Рутений", ягъни "Российский" дип исем куша) К.К. Клауснын казанышлары кабатланмас дәрәжәдә уникаль булып тора. Әлеге күренекле химикларнын шәкерте А.М. Бутлеров органик матдәләр химик төзелешенен теориясен эшли. Үз чиратында Казан химикларынын казанышларын В.В. Марковников, А.Н. Попов кебек А.М. Бутлеровнын шәкертләре һәм анын эшен дәвам итүчеләр тагын да үстерә төшәләр. Фән өлкәсендә астрономнар И.М. Симонов, М.А. Ковальский; математиклар Ф.М. Суворов, А.Ф. Попов, В.Г. Ишменецкий, П.С. Назимов, П.С. Порецкий; механиклар П.И. Котельников, Н.С. Громека; физик һәм химик А.Я. Купфер; геологлар Н.А. Головкинский, А. А. Штукенберг; биологлар А.О. Ковалевский, С.И. Коржинский, М.М. Усов һәм башка физика-математика һәм ижтимагый фәннәр вәкилләре зур уңышларга ирешәләр.

XIX гасырнын беренче яртысында Көнчыгышны өйрәнү буенча Европанын эре үзәгенә әверелгән "көнчыгыш юнәлеше"—Казан университетынын горурлыгы булып тора.

Казан ориенталистлары О.М. Ковалевский, А.К. Казымбәк, И.Н. Березин, П.Я. Петров, Ф.И. Эрдман, Х.Д. Френ, И.И. Халфин һ.б. үзләренен тикшеренүләре белән Көнчыгыш халыкларынын мәдәнияте һәм тарихы турында дөнья фәне ирешкән чикләрне шактый киңәйтеп җибәрәләр. И.А. Бодуэн де Куртенэ башта Казан, аннары Петербург лингвистик мәктәбенә нигез сала, ә В.И. Григорович Казан славянчылыгы мәктәбе башында тора.

XIX гасырда—XX гасыр башында Казан табиблар мәктәбе зур уңышларга ирешә. Әле 50 елларда ук Е.Ф. Аристов, баш мие төзелешен аңларга омтылып, күп кенә кызыклы тикшеренүләр үткәрә. Анатомия кафедрасында П.Ф. Лесгафт, В.И. Тонков кебек танылган галимнәр эшли. Фәнни медицина мәктәбе клиницист Н.А. Виноградов, нейрогистолог К.А. Арнштейн, физиологлар Ф.В. Овсянников, Н.О. Ковалевский хезмәтләре аша формалаша. Профессор Е.В. Адамюкнын фундаменталь хезмәтләре

асылда рус афтальмологиясен тудырырга ярдәм итәләр. Университетта психофизиология лабораториясе оештырган В.М. Бехтерев Россиядә эксперементаль психология фәненә нигез сала. Физиология өлкәсендә профессор Н.А. Мисловский, электрофизиология өлкәсендә профессор А.Ф. Самойлов тарафыннан тирән ачышлар ясала (ул йөрәк һәм үзәк нервсистемасы эшчәнлеген тикшерүдә электрофизиология методын киң куллана).

Аңлашылса кирәк, XIX гасыр ахырында—XX гасырның беренче яртысында Казан университеты галимнәренең казанышлары нәтиҗәсендә университетлар өчен традицион исәпләнгән һәм күп төрле тармакларга ия булган яңа фәнни мәктәпләр һәм юнәлешләр барлыкка килә; бүгенге көндә аларның күпчелеге дөньякүләм танылу алды яки ала килә.

Казан математика һәм механика мәктәбе үсешенә А.В. Васильев, Н. Н. Парфентьев һәм аларның замандашлары Д.Н. Зейлигер, А.П. Котельников, И.М. Синцов, Е.А. Болотов зур йогынты ясыйлар. Казан физикларыннан Н.П. Слугинов, Д.А. Гольдгаммер, В.И. Ульянин һ. б., химиклардан А.М. Зайцев, Ф.М. Флавицкий һәм аларның укучылары, барыннан да элек А.Е. Арбузов хезмәтләре (Зайцев вафатыннан соң ул органик химия кафедрасының экстраординар профессоры итеп сайлана) киң таралыш таба.

Казанның башка фәнни мәктәпләре—шул исәптән геология (П.И. Кротов, М.Э. Ноинский, М. Э. Янишевский, Ф.Ф. Розен), география һәм этнография (П.И. Кротов, Б. Ф. Адлер), биология (В.В. Заленский, А. Я. Гордягин, В.В. Лепешкин, А.П. Пономарев, Э.К. Мейер, А.А. Остроумов, М. Д. Рузский, Н.А. Ливанов), физиология һәм медицина (А.В. Вишневский, Н.А. Миславский, Л.О. Даркшевич, М.Н. Чебоксаров, В.С. Груздев һ. б.) мәктәпләре дә уңышлы үсеш чорын кичерәләр.

XIX гасырның икенче яртысы—XX гасырның башы—Казан гуманитар фәннәренең үсеш чоры. Бу дәвердә тарихчылар Д.А. Корсаков, С.М. Шпилевский, Н. Фирсов, М.М. Хвостов, Н.П. Грацианский, Ф.А. Курганов, К.В. Харлампович, И.М. Смирнов, рус әдәбияты тарихчысы Н. Н. Булич, славян филологиясе галимнәре А.С. Архангельский, Н.В. Крушевский, А. И. Александров, М.П. Һәм Н.М. Петровскийлар, А.М. Селищев, Е.Ф. Будде, антик дөнья белгечләре Ф.Г. Мищенко, С.П. Шестаков, Д.И. Нагуевский тарафыннан фундаменталь тикшеренүләр үткәрелә.

XX гасыр башында Казанда ориенталистика фәне үсүен дәвам итә. Көнчыгыш телләрен өйрәнү буенча, атаклы татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйри белән хезмәттәшлек иткән тюрколог Н.Ф. Катанов зур ачышлар ясый. Университетта финн-угор халыкларының тарихын, телен һәм мәдәниятен М.П. Веске, Н. Андерсон кебек галимнәр өйрәнә һәм укыта.

Университет галимнәре арасында философлар И.И. Ягодинский, Н.А. Васильев, А. О. Маковельский, дәүләт төзелеше белгече һәм Россия сәяси социалогиясенә нигез салучыларның берсе В.В. Ивановский, күренекле цивилист Д.И. Мейер мактаулы урын алып торалар; хокук тарихы һәм теориясе буенча Н.П. Загоскин, Г.Ф. Шершеневич, җинаять хокукы буенча А. А. Пионтковский, хокук философиясе буенча А.Г. Станиславский зур уңышларга ирешәләр.

Башка карт университетлар кебек үк, Казан университеты да фән һәм мәдәният казанышларын популярлаштыру буенча киң колачлы эш башкара. Белгәнебезчә, Россия төбәкләрендә китап һәм вакытлы матбугат бастырунын башында нәкъ менә университетлар тора; алар массакүләм лекцияләр уку традициясенә дә нигез салалар. Казан университетында язучылардан С.Т. Аксаков, Л.Н. Толстой, П.Н. Мельников-Печерский, В.В. Хлебников композитор М. А. Балакирев, рәссам В.И. Якоби белем ала.

В.И. Ульянов-Ленин, А.И. Рыков кебек эре дәүләт эшлеклеләре дә Казан университеты студентлары.

Мәгълүм булганча, Казан университеты профессорлары һәм аны тамамлаучылар мәмләкәтнең яңа университетларын формалаштыруда үзләреннән зур көч куялар. Мәсәлән, медик-профессор В.М. Флоринский 1885 елда Көнбатыш-Себер уку округын җитәкли, ә 1888 елда Томск университетын ача. Медицина факультеты профессорлары В.И. Разумовский һәм Н.Д. Бушмакин Саратов, Тифлис, Баку һәм Иркутск университетлары "башында" торалар, ә механик-профессор С.Ф. Сайкин Чуваш университетының беренче ректоры була (әйтергә кирәк, аның белән бергә Казан университетының башка галимнәре дә эшли).

Ул гына да түгел, Казан университеты күп кенә Казан югары уку йортларына "яшәү көче" бирә: аннан ветеринария, медицина, химия-технология, авиация, финанс-экономика, урман хуҗалыгы (соңрак Мари политехника) кебек тармак институтлары аерылып чыга.

Бөек Ватан сугышы елларында Мәскәүдән һәм Ленинградтан күп кенә күренекле галимнәр Казанга эвакуацияләнә һәм алар Казан галимнәре белән берлектә университетта эшлиләр: болар—академиклар А.Н. Крылов, А.Ф. Иоффе, П.Л. Капица, Л. А. Орбели, О. Ю. Шмидт, И. М. Виноградов, С. И. Вавилов, Е. В. Тарле һ. б.

Шушы елларда бирелә дөньяда иң куәтле турбина, минаны ерактан торып шартлату аппаратурасы, самолетларны бозланудан саклаучы прибор төзелә; хәрби оптик приборлар житештерүдә кулланыла торган көчле флуоресценция һәм куәтле "йоту" көченә ия булган махсус препарат—диаминофталимид уйлап табыла.

Сугыштан соңгы елларда университетта нефть геологиясе, радиофизика, синтетик каучук химиясе кебек яңа тармаклар үсеш ала. 1952 елда исә университетка факультет хокукларында Казан юридик институты килеп кушыла. 1953 елда химия уку корпусы төзелә. 1958 елда университет нәшрияты эшли башлый.

Без—яшь буын галимнәр—үзләренең талантлары һәм хезмәтләре белән уникаль фәнни, уку-укыту һәм мәдәният үзәге буларак университетны данга күмгән атаклы галимнәрне зур хөрмәт белән искә алабыз: болар—математик-механиклар Н.Г. Четаев, Н.Г. Чеботарев, П.А. Широков, А.З. Петров, А.П. Норден, В.В. Морозов, Г.Г. Тумашев, М.Т. Нужин; астрономнар А.Д. Дубяго, Д.Я. Мартынов; физиклар Е.К. Завойский, электрон парамагнит резонанс күренешен ачкан С.Л. Альтшулер, Б.М. Козырев; химиклар А.Е һәм Б.А. Арбузовлар, Г.Х. Камай; геологлар Б.П. Кротов, В.А. Чердынцев, Е.И. Тахвинская, М. Миропольский; биологлар В.И. Баранов, М.В. Марков, А.М. Алексеев, В. А. Попов; этнограф Н.И. Воробьев; юрист Д.И. Фельдман һ. б.

1980 еллар башына Казан дәүләт университетында укучы студентлар 10 меңнән артып китә; алар 9 факультетта белем алалар. Университетта 69 кафедра, ике фәнни-тикшеренү институты (Н.Г. Чеботарев исемендәге математика һәм механика, А.М. Бутлеров исемендәге химия институтлары), 8 проблемалы (радиоастрономия, бионика, химия мономерлары, термография һ. б.) лаборатория барлыкка килә. Шушы вакыт эчендә ике биек катлы корпуслар—физика һәм икенче уку корпуслары төзелә, ә 1989 елда УНИСК концерт-спорт комплексы бинасы сафка баса.

1996 елда Россия Федерациясе Президенты указы нигезендә университет Россия Федерациясе халыкларының аерача кыйммәткә ия булган Дәүләт объекты исемлегенә кертелә.

Казан университетын тәмамлаучылар күп кенә югары уку йортлары һәм академик институтлар белән житәкчелек итәләр, мөһим дәүләт һәм хөкүмәт урыннарында эшлиләр. Алар арасында РФ Президенты Аппаратының җаваплы хезмәткәрләре, РФ хөкүмәте, РФ Югары Арбитраж суды, РФ Конституция суды әгъзалары, Дәүләт Думасы депутатлары, РФ Генераль прокуратурасы хезмәткәрләре, РФ Эчке эшләр министр-лыгының идарә һәм бүлек начальниклары бар. Казан университетында белем алган галимнәр Россия Фәннәр Академиясе институтлары һәм башка шундый фәнни учреж-дениеләр һәм оешмалар белән житәкчелек итәләр. Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының күп кенә әгъзалары, Татарстан хокук саклау органнары житәкчеләренең күпчелеге, республиканың эре ведомстволары, оешмалары һәм учреждениеләре "башында" торучылар да кайчандыр Казан университетында белем алганнар.

Бүгенге көндә Казан дәүләт университеты Россиянең иң эре фәнни-мәгариф комплексы булып тора. Аның составына 17 факультет, тел институты, ике филиал (Чаллы һәм Яшел Үзәндәге филиаллар), фәнни-тикшеренү химия институты, Н.Г. Чеботарев исемендәге математика-механика фәнни-тикшеренү институты, В.П. Энгельгардт исемендәге Астрономия обсерваториясе, Ботаника бакчасы, проблемалы лабораторияләр, культура социалогиясе үзәге, Фәнни-технологик парк, Хисаплау техникасы үзәге керә. 1998 елда КДУ бөтендөнья INTERNET челтәренә тоташтырылды. Хәзер университет 3 канал буенча 300 терминалга тоташтырылып, INTERNET ка чыгучы 14 локаль челтәрдән файдалана; университетның һәм факультетларның дисплей классларында 800 дән артык компьютер хисаплана.

Казан дәүләт университетында идарә итү һәм бизнес югары мәктәбе, тел институты, квалификацияне күтәрү факультеты, кадрларның белемен күтәрү факультеты, абитуриентларны алдан хәзерләү бүлеге, нәшрият, оператив полиграфия лабораториясе, спорт-сәламәтләндерү лагеры һәм башка подразделениеләр эшләп килә. 2003 елда "Казанский университет" (элеккеге "Ленинец") газетасы үзенең 75 еллык юбилеен билгеләп үтте.

Россиядә иң эре һәм өлкәннәрдән саналган Н. И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханә университетның горурлыгы булып тора. Анда 5 млн.га якын китап, журналлар һәм башка төр басмалар һәм документлар хисаплана; китапханәнең 1170 урынга исәпләнгән 11 уку залы, бик күп (шул исәптән электрон) каталоглары бар. Китапханә фондында 30 меңнән артык иске кулъязмалар (иң борынгысы IX гасырга карый), шулай ук сирәк очрый торган басмалар-инкунабуллар, палеотиплар, иске ысул белән басылган китаплар, әдәбият классиклары үзләре исән вакытта дөнья күргән басмалар саклана. Казан университетының фәнни китапханәсендә Идел буе һәм Урал төбәге югары уку йортлары китапханәләре өчен Методик үзәк, Европа союзының Мәгълүмат һәм документлар үзәге эшләп килә. Укучыларга хезмәт күрсәткәндә заманча мәгълүмати технологияләр кулланыла.

Студентларның театр, бию, жыр, музыка һәм башка сәнгатьне сөючеләр иҗат коллективлары анда шөгыльләнергә теләүчеләрне бик теләп каршы ала һәм алар

студентлар арасында зур уңыш казанып киләләр. Фестивальләрдә, смотрларда һәм күргәзмәләрдә катнашып, халык капелласында һәм Татар халык хорында шөгыльләнеп, студентлар буыннан-буынга үзләренең иҗади ихтыяҗларын канәгатьләндереп киләләр.

Казан университеты Россия югары уку йортлары арасында бердәнбер төрле профильдәге уникаль музейлар системасына ия: болар үткәннәрнең якты истәлеге турында сөйләүче ядкярләр генә түгел, ә бәлки бүген дә фәнни тикшеренүләр алып бару өчен фәнни база да булып торалар.

Алар арасында Казан университеты тарихы музее (ул 20 меңнән артык экспонатны берләштерә), Археология музее (50 мең экспонат), Ботаника музее (90 мең экспонат), Зоология музее (6 мең экспонат), Геология-минерология музее (150 мең экспонат), Этнография музее (6 мең экспонат) бар; университет музейларында җәмгысы 330 меңгә якын экспонат саклана, алар, әйтергә кирәк, фәнни уку-укыту һәм мәгърифәтчелек максатларында һәрдаим файдаланып килено. Университетның фәнни-укыту базалары Казан шәһәреннән тыш та урнашкан: болар—Татарстанда урнашкан Биология, Геофизика, Зоология станцияләре, "Эколог" базасы, нефть һәм газ геологиясе фәнни-укыту базасы; Уралдагы Ильинск тыюлыгы биләмәсендә урнашкан Магнит обсерваториясе һәм Геология станциясе; Ак дингездәге Биология базасы; Төньяк Кавказдагы Зеленчук астраномия станциясе. Төркиядә бердәм яңа астрономик обсерваторияне файдалануга тапшыру төгәлләнеп килә, ул диаметры 1,5 метр булган көзге белән җиһазландырыла.

Аңлашылса кирәк, университет үткәннең иң яхшы традицияләрен саклап калырга һәм үстерергә омтыла. Россия үз тарихында авыр дәвер кичерүгә карамастан, фәнни мәктәпләр үсеш ала, яңа белгечлекләр, кафедралар һәм факультетлар барлыкка килә, фән казанышларына һәм яңа технологияләргә таянып укыту процессы камилләшә бара, университет кешеләрнең иҗтимагый аңы үсешенә торган саен ныграк йогынты ясый төшә. Бүген Казан дәүләт университетында 270 фәннәр докторы һәм 800 гә якын фәннәр кандидаты, Россия һәм Татарстан Фәннәр Академиясенең 17 академигы, 8 мөхбир әгъзасы, башка дәүләтләрнең хакыйкый әгъзалары эшли; 43 укытучы Россия Федерациясе Президентының стипендиясен ала.

Хәзерге вакытта университетның 99 кафедрасында фундамаенталь фәннәрнең барлык тармакларын да үз эченә алган 40 белгечлек буенча 16 меңнән артык студент белем ала. Педагогик эшчәнлек белән 1 меңнән артыграк укытучы шөгыльләнә, шуларның икесе РФАның академигы, өчесе мөхбар-әгъзасы; 300 гә якыны профессор һәм 500 е доцент.

Югары квалификацияле белгечләр хәзерләү аспирантура (77 белгечлек буенча) һәм докторантура (8 белгечлек буенча) аша алып барыла. Соңгы биш елда Казан университеты аспирантурасын 654 кеше тәмамлады. Университетта шулай ук 18 кандидатлык һәм 10 докторлык диссертация Советы эшләп гаилә; ел саен уртача 25 докторлык һәм 200 кандидатлык диссертациясе яклана.

Казан университеты эзлекле рәвештә дөньяның бик күп университетлары белән халыкара багланышлар урнаштыру сәясәтен гамәлгә ашырып килә; әйтик, ел саен 300 гә якын белгечләр белән алмашу үткәрелә икән, бу үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли. Чит илләрдә, табигый буларак, безнең физика, химия, математика, лингвистика, биология мәктәпләре зур кызыксыну уята. Соңгы елларда юристлар, икътисадчылар, социологлар, политологлар да торган саен ныграк халыкара багланышлар урнаштыра башладылар. Казан университетын Гиссен (Германия), Кентс (Бөекбритания), Лювенск (Бельгия), Синьцзян (Кытай Халык Республикасы), Каназава (Япония) һ.б. университетлары һәм башка бик күп фәнни үзәкләр белән үзара хезмәттәшлек "җепләре" берләштерә. Кыскасы, Казан университеты эре мәгърифәт, фән һәм культура үзәге дигән тарих олуг миссиясен уңышлы үтәп килә; иншалла, өченче меңъеллыкта да бу шулай булыр дигән өмет бар.

Рафаэль
Хәким

# КАЙДА БЕЗНЕҢ КЫЙБЛА?

## ЕВРОИСЛАМ МАНИФЕСТЫ

***“Дәһи Аллаһ алдына үз гөнаһын йөкләп баручы кеше башка һичбер кешенең гөнаһын йөкләп бармас” [17:15].***

Цивилизацияле җәмгыятьтә йолаларның мәгънәсе үзгәрә. Хатын-кызларга яулык бәйләргә, ир-атларга сакал үстерергә ярый. Бу аларның шәхси эше, бу—тышча, аның эчендә диндарлык та, шулай ук Аллага ышанмау да яшеренергә мөмкин. Исламның асылы анда түгел.

Мөселман дин белгечләре *хиҗаб* киюне кешенең, ягъни ир-атның начар табигате белән аклыйлар. Рукайя Максуд язганча, мөслимәләр “тыйнак киенүне өстен күрәләр, ачык һәм заманча киемнәр ирләрнең түбән инстинктларын аздыра дип саныйлар, чөнки, алар фикеренчә, мондый киемнәр ирләрнең хатын-кызларга җәмгыятьнең тигез хокуклы һәм бәйсез әгъзалары буларак түгел, ә “женси теләк объекты” буларак карашын ныгыта. Алар ир-атлар игътибарын иң элек хатын-кызның тәненә түгел, акылына һәм холкына юнәлдерүен телиләр”[1]. Мондый мантыйк хәтта гаҗәп кенә дә түгел, чөнки тормыш бит женси мөнәсәбәтләрдән генә тормый, ә ир-атларны үз-үзен кулда тота алмый торган хайваннар рәвешендә күзалларга ярамый. Барлык ирләр дә азгын түгел, һәм азгын хатын-кызларның да телгә алырлык дәрәҗәдә күп түгеллеге көн кебек ачык. Хайвани инстинктлар мантыйгын ислам принципы дәрәҗәсенә күтәрергә ярамый.

Татар хатын-кызлары арасында *хиҗаб* кию һәм паспортка яулык бәйләп фотога төшү хокукы өчен бөтен бер хәрәкәт барлыкка килде. Аларның моңа хокукы бар һәм дәүләт аларны чикләмәскә тиеш. Ләкин аларның ныклыгы, үзсүзлеге, ихтирамга лаек булса да, файдалырак кулланылыш таба алыр иде. Әгәр дә инде алар шулкадәр тәкъва икән, димәк аларга, “Әхзаб” *сүрәсенең*:“Вә өйләрегездә торыгыз” дип әйтелгән 33 нче *аяте* нигезендә, судларда йөрергә ярамый. Димәк, алар өйдә генә торырга тиешләр. Алар чит ирләр белән бары тик пәрдә аша гына аралашырга тиеш [33:53] һәм фатирларының хатын-кызлар ягында гына яшәргә тиешләр. Кайчандыр татар хатын-кызлары мөселман Көнчыгышында иң гыйлемле һәм иң алга киткән хатын-кызлар булып саналганнар. Бүген исә алар моның киресен исбатларга телиләр, күрәсең.

Урта гасырларда хатын-кызга милек итеп караганнар һәм аларны, милек буларак, кул сузулардан саклаганнар. Коръән буенча ир кешегә үзенең кол хатын-кызлары

[1] *Рукайя Максуд.* Ислам. – М., 2001. – С.276.

*Ахыры. Башы 10 санда.*

беләи ләззәт алу гөнаһ түгел, моны чит хатыннар белән эшләргә ярамый, чөнки чит хатыннар аның милке түгел. Шәригать буенча, әхлак бер генә хатынга тугры булуда түгел, ә чит хатынга кагылмауда. Шәригатьтә урлашуның һәм зина кылуның бер төр җинаятькә—*хөддәгә* каравы очраклы түгел. Милек—җәмгыятьнең какшамас нигезе булып санала, ана беркем дә кул сузарга тиеш түгел. Шул рәвешчә, җәза катылыгы да урланган әйбернең кыйммәтеннән түгел, урлашу фактының үзеннән чыгып билгеләнә.

Кием, үзенең көнкүреш функциясеннән башка, әле матурлык чагылышы булып, кешенең эчке дөньясын, аның фантазиясен дә күрсәтеп тора. Бу—матди әйбергә рух өрү, матди *дөньяны* җинеп чыгу шикелле дә хәтта. Матурлык Коръән таләп иткән тыйнаклыкка һич каршы тормый. Пәйгамбәр раславынча: “Аллаһ Тәгалә матур һәм ул матурлыкны ярата”. Татар хатын-кызлары арасында хәтта иң “исламлы заманнарда” да, примитив *хиҗаб* кию гадәте булмаган, чөнки мода һәм дин—мөстәкыйль күренешләр. Мәдрәсәдә, чиста мөселман кануннары буенча тәрбияләнгән әбием татарлар өчен ят булган әлеге киемне бервакытта да кимәде. *Хиҗабның* барлыкка килүе гарәпләрнең этник традицияләре аркасында килеп чыккан, ком бураннары уйнаган чүлләрдә аларга андый кием унайлы булган. Турысын гына әйткәндә, *хиҗаб*—бернинди зәвыксыз тегелгән ямьсез кием. Ул татар хатын-кызларының традицион милли киеме яки хәзерге заман модасы белән чагыштырып караганда, берәүгә дә бернинди дә өстенлек бирми. Хәер, бу да үзенчә мода һәм теләсә нинди мода шикелле яшәргә хаклы. Кем өчендер пәрәнҗә—дин символы, ә кемдер—нудист. Аларның кайсысы җәннәткә керер? Күпчелек беренчесе дияр. Ләкин мондый хөкем чыгарырга кемнең хакы бар? Әйтелгән: “Ии, сез, ачык дәлилләрне ригая кылмаучы кире кешеләр, диндә дәлилсез низагълашуларыгызның хөкеме Аллаһуга кайтарылыр, Ул үзе хөкем итеп аерыр: кемнеке—дөрес, кемнеке—ялган, шунда мәгълүм булыр”[42:10]. Сабыр бул һәм гафу итә бел, шул вакытта сина да Аллаһ рәхмәте төшәр.

Әлбәттә, кешеләр өчен символлар да мөһим. Алар—таяну нокталары. Казан Кремлендә Кол Шәриф мәчетен торгызуның зарурлыгы турында фикер алышканда, бу изге эшкә мин дә үземнең тыйнак өлешемне керттем. Россия ислам университетын оештырганда миңа Татарстан мөфтие Госман хәзрәт Исхаков һәм мөфти Равил хәзрәт Гайнетдин имзалары белән рәттән кул кую бәхете насыйп булды, әмма йолаларга мин аеруча шәхсән, хәтта яшерен эш, күнел эше дип карыйм, аны кешегә күрсәтеп эшләргә кирәкми дип уйлыйм.

Кешелек үзенең үсешендә озын юл узды һәм бу вакыт эчендә кешенең табигате дә үзгәрде. Ул гарәп чүлләренең кыргые түгел инде хәзер. 1400 ел эчендә ислам кеше табигатенә файдалы тәэсир ясый алмаган, аның инстинктларын яхшырта алмаган дип фаразлау исламның көчсезлеген тануга тиң булыр иде. Мөселман хатын-кызлары ир-атларга бозык хайваннарга караган кебек түгел, кешеләргә караган кебек карасалар, күп кенә традицияләрнең искергәнлеген күрерләр иде. Ир-атларга да хатын-кызга биек койма артында чит күзләрдән яшереп сакланырга тиешле милек итеп түгел, ә тигез хокуклы шәхес итеп карау зыян итмәс иде.

Хатын-кызга икенче сортлы зат кебек караш исламга иудаизмнан һәм христианлыктан үтеп кергән. Европа әкренләп моннан ераклашты, ә мөселман илләре әле һаман да бу карашка ияреп баралар. Хатын-кызга иң беренче гөнаһ кылучы итеп карарга ярамый. Коръән буенча Иблис Адәм белән Хауваны бер үк вакытта аздырган: “Иблис бу агач җимешен ашасагыз, җәннәттә мәңге каласыз, дип аларны алдады, алар, Иблис сүзенә ияреп, җимешне ашап алдандылар. Иблис аларны җәннәттән чыгарып, андагы нигъмәтләрдән аерды” [2:36]. Алай гына да түгел, “Та Һа” *сүрәсендә* нәкъ менә “Адәм Раббысына гөнаһлы булды, дошманының ялган сүзенә ияреп, максатына ирешүдән коры калды” диелгән. [20:121]. Ахыр чиктә, ир-ат һәм хатын-кыз беренче гөнаһны кылуда бертигез җаваплы.

Коръәннең “Хатын-кызлар”, “Нур”, “Әхзаб” *сүрәләрендәге аятьләре* хатын-кызның тигезсезлеген ныгыталар. Алар Мәдинә чорында язылганнар. Әлеге чорга кадәр шәригатьнең хатын-кызларга карата кагыйдәләре дөньяда иң алдынгы закон булган. Ләкин ул чорлардан соң цивилизацияле илләр бик алга киттеләр, ә шәригать һаман бер урында таптана. Хәйдәр Баш хатын-кызлар хокукы турындагы мәсьәләне тикшерүне мәгънәсез дип исәпли. “Көн тәртибенә хатын-кызларның хокукы, ана хокуклар бирү кебек проблемаларны кую—тамырдан ук дөрес түгел, чөнки хатын-кызга хокукларны бирәү дә бирә алмый, ул барлык хокукларга ия булып туа. Теләсә

кем тумыштан ук яшәүгә, милеккә, намуска хокуклы".[1] Яхшы әйтелгән, ләкин, Коръән буенча, коллар да булырга мөмкин. Алар кешеме яки кеше түгелме? Шәригать буенча, алар дөя белән бер дәрәҗәдә милеккә тиңләштерелгән. "Һәркем тумыштан ук ирекле" дигән принципның аларга да кагылуы мөмкинме? Кайбер дин галимнәре уйлаганча, шәригать гади нәрсә түгел. Хатын-кызлар хокуклары мәсьәләсен тикшерүнең мәгънәсе бар. *Иҗтиһад* кирәк.

Ирләрнең һәм хатын-кызларның хокуклары төрлелеген яклау өчен китерелә торган тагын бер аргумент—аларның җәмгыятьтәге функцияләре аерымлыгын, димәк, хокукларының да төрлелеген билгеләүче физиология. "Хатын-кызны һәм ир-атны тигез дип санау, асылда, алма белән армутны (груша) тиңләштерү белән бер,—дип дәвам итә Хәйдәр Баш.—Бу исә әйберләрнең табигатенә каршы килә, чөнки хатын-кыз һәм ир-ат психологик яктан да, физиологик яктан да тигез түгелләр. Үз табигатьләре буенча төрле булган кебек, алар бурычлары һәм җаваплылыклары буенча да бер-берсеннән аерылып торалар".[2] Ир-атларның үзләре турында ук шулай әйтергә мөмкин—алар да физик мөмкинлекләре һәм интеллектлары буенча бер-берсеннән аерылалар.

Физиология мирас, аерылышу яки башка хокуклар мәсьәләсен хәл итүдә нигез булып тормый. Кеше кеше инде ул. Ни өчен бер ир кеше шаһитлегенә каршы ике хатын-кыз шаһитлеге таләп ителә соң? Моны хатын-кыз табигате буенча йомшак күңелле, кызганучан һәм гаделлек таләпләреннән читенүе мөмкин дип дәлилләр.[3] Әмма бу—субъектив фикер. Хатын-кызның катылыгына һәм үз сүзендә нык торучанлыгына да һәм, киресенчә, ир-атның йомшаклыгына да меңләгән мисал китерергә мөмкин.

Ислам бурычларының берсе дөньяны гаделрәк итүдән гыйбарәт. Полигамия хатын-кызга карата гаделлек чагылышы булып санала. Йосыф әл-Кардави бу хакта болай дип яза: "Шәригать ирнең барлык хатыннарына да ире тарафыннан тәрбиягә, торакка, киемгә тигез хокук гарантияли. Полигамиягә бәйле гаделлек шушы була инде. Чынлап та, кайбер ир-атлар Аллаһ аларга бурыч итеп биргән гаделлекне үтәмиләр. Ләкин начар кулланылыш принципларны нигездә гамәлдән чыгару дигән сүз түгел".[4] Полигамия, мирас хокукы яки аерылышу процессы кебек үк, хатын-кызны ир-ат белән тигезсез хәлгә куя, ә хокук тигезлегеннән башка гаделлек була алмый. Әгәр кешеләрнең хокуклары тигез түгел икән—дөньяда гаделсезлек, димәк, динсезлек саклана. Барлык кешеләр дә тумыштан ирекле һәм тигез. Биредә физиологиянең яки нәселнең, расаның яки телнең, диннең яки илнең катнашы юк. Бөтен кешене дә бертөрле итеп булмый, әмма бөтен кешенең дә хокуклары тигез булырга тиеш.

Йосыф әл-Кардави дәвам итә: "Табигате буенча, хатын-кыз үзен саклый, яклый, кулында тота торган ир-ат кайгыртуында булырга тели"[5]. Коръәндә ир-атның хатын-кыздан өстенлеге ир-ат хатын-кызның иминлеген тәэмин иткән һәм тәрбия иткән очракта гына танылa [4:34]. Әлеге функцияләрне җәмгыять үз өстенә алган һәм хатын-кыз икътисадый яктан бәйсез булган илләрдә исә андый өстенлеккә нигез калмый.

Хәзерге заманда хатын-кызлар еш кына ир-атлар белән бер үк дәрәҗәдәге җаваплылык йөген тартып баралар. Бу хәзер нормага әйләнде. "Хатын-кызның ир-ат эше башкаруын һәм аның җилкәсенә ир-атка тиеш йөк салынуын хокук дип атарга ярыймыни?"—дип яза Хәйдәр Баш.[6] Европа илләре тәҗрибәсе мондый дәлилләрне һәр адымда кире кагып бара. Авыр физик хезмәт ир-ат җилкәсенә салынган урта гасырларда гына хатын-кыз кайгыртуга мохтаҗ иде һәм бу гадел хәл иде. Бүген хезмәт рәвеше үзгәрде, ул күбрәк акыл хезмәтенә әверелеп бара. Мәсәлән, табиб, укытучы кебек һөнәрләрне ир-ат һөнәрләре генә дип әйтеп булмый. Мондый хезмәт хатын-кызны кимсетергә мөмкинмени? Әлбәттә, юк. Бу—игелекле хезмәт, ул кешеләргә иминлек, сәламәтлек, белем китерә.

Хакыйкать шунда ки: хатын-кыз хокуклары буенча тарихи шәригать бүгенге көндә кулланыла алмый, чөнки ул башка аудиториягә—Мәдинә җәмгыятенә юнәлдерелгән. Мәккәдә язылып бөтен кешелеккә һәм мәңгелеккә бирелгән *аятьләрдә*

---

[1] *Хайдар Баш.* Права женщины в Исламе. – Казань, 2001. – С.16.
[2] *Хайдар Баш.* Права женщины в Исламе. – Казань, 2001. – С.17.
[3] *Хайдар Баш.* Права женщины в Исламе... – С. 22.
[4] *Юсуф аль-Кардави.* Современный иджтихад... – С.61.
[5] *Юсуф аль-Кардави.* Современный иджтихад... – С.65.
[6] *Хайдар Баш.* Права женщины в Исламе. – С. 15.

хатын-кыз һәм ир-ат арасында аерымлыклар юк. Бу—XXI гасыр шәригатенең төп принципы булырга тиеш. Муса Бигиев язган: "Хатын-кызларның хокуклары никадәр камилрәк, аларның абруйлары никадәр югарырак булса, җәмгыять системасы шулкадәр көчлерәк булачак". Ә мөселман җәмгыяте көчле булырга тиеш.

***"Янә әйт: "И-й, кешеләр! Ошбу Коръән Раббыгыздан килгән хак сүзләрдер, туры юл, вә гадел хөкемнәрдер, теләгән кеше Коръән белән гамәл кылып мөэмин булсын вә теләгән кеше Коръән белән гамәл кылмасын да кяфер булсын!"[18:29].***

Пәйгамбәр әйткән: "Бөтен дөнья дога кылу урыны итеп яратылган". Өенең бер бүлмәсендә яки почмагындамы, хәтта компьютер алдында, фәннәр белән шөгыльләнгәндәме—теләсә кем теләсә кайда Аллаһ Тәгалә белән аралашу урыны таба ала. Һәркем Аллаһ Тәгаләгә мөнәсәбәтен үзе билгеләргә иректә.

"Аллаһ Тәгаләдән башка тәңре юк, Мөхәммәт—Аллаһның пәйгамбәре" дигәнне таныган кеше динле кешегә әйләнә. Йолалар һәм гореф-гадәтләр динне билгеләми, алар диннән килеп чыга. Алар икенчел. Әбү Хәнифә болай дип язган: "Динле кешеләрнең дога кылырга, зәкәт түләргә, ураза тотарга, хаҗга барырга, Аллаһны истә тотарга теләгән аларның Аллага ышануы тудыра, киресенчә түгел: дога кылу, зәкәт түләү, ураза тоту, хаҗга бару аркасында Аллаһка ышану теләге тумый. Бу—шулай, чөнки алар иң элек Аллаһка ышандылар, аннан соң гына гамәлләргә тотындылар. Дини бурычлар Аллаһка ышануга түгел, Аллаһка ышану аларны дини бурычларны үтәргә өндәде".[1] Берәү дә кешене хөкем итә, син шундый булырга тиеш дип күрсәтмә бирә алмый, бигрәк тә, син мөселман түгелсең дип әйтә алмый. Әбү Хәнифә язган: "Кешеләр дингә ышануда бер-берсенән аерылмыйлар, бер-берсеннән яхшырак була алмыйлар, алар үзләренең кылган гамәлләре буенча бер-берсен узып китәргә һәм дини бурычларын үтәү буенча бер-берсеннән аерылырга мөмкиннәр".[2]

Хакыйкать шунда ки: динлелек һәм динсезлек мәсьәләсен Ходай Тәгалә бары тик үзе генә хәл итә. Бу мәсьәләдә арадашчылар булу мөмкин түгел. Хакыйкатькә таба юлда руханилар автомобиль юлындагы күрсәткеч такталар функциясен үтиләр, әмма алар "ятып торучы полицейскийлар" ролендә булмаска тиеш.

Ислам белгечләре дини белем алырга ярдәм итә алалар, ләкин һәркем дингә юлны мөстәкыйль рәвештә үзе үтәргә тиеш. Ахыр чиктә, Ходай Тәгалә безне үз янына алганда, янибызда имам да, мөфти дә, дини бергәлек тә булмаячак. Анда адвокатлар булмаячак.

***"Һәм куркыгыз кыямәт көненнән, ул көндә һичбер зат икенче затка бер эш белән дә ярдәм итә алмас! Ул көндә шәфәгать итү кабул ителмәс һәм газабтан котылу өчен һичнәрсә алынмас"[2:48].***

Кыямәт көнендә хөкем кылу хокукы бары тик Ходай Тәгаләгә генә бирелгән. "Аларга анда Аллаһудан башка хуҗа һәм шәфкать итүче булмас"[6:51]. Янында атаң да, анаң да, остазың да булмас, чөнки ул—Кыямәт көне. Берәү дә чит кеше гөнаһларын үзенә ала алмас, һәркем үзе өчен генә җавап тотар: "Һәрбер кеше ни кылса да үзе өчен генә кыладыр һәм гөнаһ йөген йөкләүче кеше башка һичбер кешенең гөнаһ йөген йөкләп алмас"[6:164]. Шулай булгач, нишләп бу тормышта адвокатлар булырга тиеш ди?

Аллаһ бөтен кешене дә диндар итә алыр иде. Аның кодрәте киң. Әйтелгән: "Әгәр Аллаһ теләгән булса иде, әлбәттә, барчагызны бер диндә кылыр иде"[16:93]. Ләкин Ул алай эшләмәгән. Ул кешеләрне хак юлга бастырыр өчен пәйгамбәрләр сайлаган, ә кешеләрне үз ихтыярларына калдырган.

Кешеләр тәкъдир коллары түгел. Ходай Тәгалә кешегә туганда ук динсез булырга дип язып куя алмый, ул һәркемгә сайлау мөмкинлеге калдыра. Кеше динле яки динсез, мөселман яки башка дин кешесе булырга яки йолаларны үтәмәскә мөмкин. Җәза бирү яки бүләкләү—Аллаһ кодрәтендә. Тәкъдирнең хак юлны сайлау хокукына катнашы юк. Кеше, үлеме кайда булса, шунда үлә, ләкин гомерен ничек үткәрүе һәм үлемгә ничек әзерләнүе аның үзеннән тора.

[1] Абу Ханифа Нугман ибн Сабит. Трактаты... – С.44.
[2] Абу Ханифа Нугман ибн Сабит. Трактаты... – С.98.

***“Әгәр Раббың теләсә иде, әлбәттә, жир йөзендәге кешеләр барчалары иман китерер иделәр. Ә син Мөхәммәд г-м, барча кешеләрне ышандыру өчен аларны көчләр иденме?”[10:99].***

Ходай Тәгалә дингә пәйгамбәрләре аша өнди, ләкин ул дингә көчләми. Ул игелекле булу зарурлыгы турында бары тик кисәтә генә: “Тәхкыйк Нухны каумена пәйгамбәр итеп жибәрдек, ул кауме эчендә аларны дингә өндәп тугыз йөз илле ел торды, кауме исә иман китермичә залим булдылар һәм аларны Туфан суы тотты” [29:14]. Кешеләрне тәкъва итәр өчен Нухка мең ел вакыт та җитми һәм кешеләргә җәза бирелә. Алар коткарылмый, алар батырып үтерелә. Әйтелгән: “Аларга пәйгамбәрләре могҗизалар вә ачык аңлатмалар белән килделәр, Аллаһ аларны золым итмәде, ләкин алар Аллаһуга каршы барып үзләренә золым иттеләр” [30:9]. Ходай Тәгалә аларны коткара алмый, ләкин аларны батырганнан соң яңа буыннарны тудыра ала. “Сонра алардан соң башка каумнәрне чыгардык” [23:42]. Ходай Тәгалә кодрәтендә аларга җәза бирү, әмма аларны көчләп дингә китерү түгел. Ходай Тәгалә пәйгамбәрләр сайлап алып, аларга хакыйкатьне ачкан. Калган нәрсәләрне ул һәркемнең үз ихтыярына калдырган.

Исламда мөселманнарны Аллаһудан һәм Кыямәт көненнән куркырга тиешле Алла коллары дип атау кабул ителгән. Әйтелгән: “Аллаһудан куркыгыз, миңа итагать итегез” [26:126]. “Кол” “габд” *(`абд)* һәм “куркыгыз” дигән сүзләр һәрбер *сурәдә* диярлек очрыйлар. Ләкин аларның туры мәгънәдә аңларга тырышу берни дә бирми. Сукырларча табынуның мәгънәсе юк, сайлап алу хокукы кешенең үзенә бирелгән, ә ирекле ихтыяр һәм коллык—бервакытта да бергә сыеша алмый. Коллык—ул кешенең ирекен инкарь итә һәм аны көчләүне таный, әмма әйтелгән бит: “Дингә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар. Ясалма, ялган, батыл диннән Аллаһ тәзегән хак дин ачык аерылды” [2:256].

“Габд” (*`абд)* “кол” дип тәрҗемә ителә. Әмма фигыль төрле мәгънәгә ия. Гыйбадәт (`Ибадат)—Ходайга хезмәт итү, шуңа күрә “габд” (*`абд)* “кол” түгел, ә Аллаһның “хезмәтчесе” мәгънәсенә ныграк туры килә. “Дини контекстта,—дип яза Сәед Мөхәммәд Нәкыйб әл-Әттас,— `*abd* термины үзенең Ходай алдындагы бурычының абсолютлыгын таныган хәлдә, моңа риза булып, үзен Аңа хезмәткә багышлаган кешене тасвирлый”.[1] “Ходайга хезмәт итү *(khidmah)* концепциясе,—дип дәвам итә ул,—үзенең хезмәтен тәкъдим итүченең, вассал түгел, ә “ирекле”, “үзенә үзе хуҗа” икәнлеген күз алдында тота”.[2] “Аллаһу колы” дигән сүз Коръәннең кешене ирекле итүгә юнәлдерелгән рухын бозып күрсәтә.

Иң мөһиме—курку түгел, сайлаган юлыңнан тайпылмыйча бару. Аллаһтан куркыгыз дию ул аның каршында калтырап торыгыз дигән сүз түгел, моның мәгънәсе башка—диндар булыгыз, игелекле булыгыз, яманлыктан ерак торыгыз, гөнаһлардан сакланыгыз дигәнне аңлата. Башкача әйтсәк, “куркыгыз” дигән сүзне минем арттан барыгыз, мине тыңлагыз, инаныгыз һәм дин тотыгыз дип аңларга кирәк. Һәм “кол” дигән сүзнең мәгънәсе башка контекстка ия, ул—Аллаһның “дәвамчысы”, үз хуҗасының артыннан ияреп баручы “хезмәтчесе” дигәнне аңлата, ул мәет юучылар кулындагы мәет тә, хуҗаның тимер кулындагы таяк та түгел.

Коръәннең мәгънәсе буенча, тәкъва кеше Аллаһның колы була алмый, чөнки аның сайлап алу хокукы булганлыктан, ул әлеге юлны үзе сайлап алган һәм ул аңлы рәвештә табына, бу эшкә хезмәт итә, ислам кануннарын үти. Ул Аллаһны чиктән тыш яратырга мөмкин, ләкин ул кол түгел. “*Гыйбадәт*,—дип яза Сәед Мөхәммәд Нәкыйб әл-Әттас,—аңлы рәвештә һәм теләп кылынган, бары тик Аллаһка гына багышланган, Аның тарафыннан хупланган хезмәт итү гамәлләрен, мәҗбүри табыну йолаларын аңлата”.[3] *Гыйбадәт*—ул хезмәт итүнең бар җыелмасын үз эченә алучы бик тирән мәгънәле термин, ә “үзенең ахыргы, иң югары стадиясендә *гыйбадәт (`ibadat)* “белем”—*мәгърифәт (ma`rifat)* мәгънәсенә ия була”.[4] Шул рәвешле, әлеге сүзне табыну йолаларына гына кайтарып калдыру дөрес булмас иде.

Сәед Мөхәммәд Нәкыйб әл-Әттас дин кагыйдәләрен, йолаларын үтәү белән бәйле тышкы игелекне һәм “йөрәк хәрәкәтләренә бәйле”[5] эчке, яшерен игелекне аерып күрсәтә. Биредә күңелгә шик төшә. Игелек тышкы һәм эчке була алмый,

---

[1] Сейд Мухаммад Накыб аль-Аттас. Введение... – С.59.
[2] Сейд Мухаммад Накыб аль-Аттас. Введение... – С.59.
[3] Сейд Мухаммад Накыб аль-Аттас. Введение... – С.59.
[4] Сейд Мухаммад Накыб аль-Аттас. Введение... – С.70.
[5] Сейд Мухаммад Накыб аль-Аттас. Введение... – С.111.

әйтик, кешеләр өчен—бер кыяфәттә, үзе өчен—икенче төрле. Йолаларны үтәү кешенең үзенә кирәк, алар дөньяны яхшыртмый, ә шәхеснең эчке халәтен үзгәртә:ул үзенең вазифасын да, яхшылык белән яманлык арасыннан берсен сайлап алу зарурлыгын да ачыграк аңлый башлый, ә игелек исә җәмгыять тормышын яхшыртуга, халыкны үстерүгә, кешелекне коткаруга юнәлдерелә.

> ***“Сезләрдән һәрбер җәмагать өчен шәригать төзедек һәм диндә ачык юллар күрсәттек. Әгәр Аллаһ теләгән булса, әлбәттә, бөтен дөнья кешеләрен бер диндә, бер юлда һәммәсен бер җәмагать кылыр иде, ләкин сезгә биргән нигъмәтләре һәм индергән Коръән хөкемнәре белән Аллаһ сезне сынап карарга теләде. Шулай булгач, алданмагыз, гөнаһлардан саклануда һәм савабны кәсеп итүдә ярышыгыз һәм ярышта алга чыгыгыз!!! Бит кайта торган җасгыз Аллаһу хозурында, анда сезгә Аллаһ дөньяда вакытларыгызда Аллаһ хөкемнәрендә ихтилаф кылышуларыгыз белән хәбәр бирер” [5:48].***

Ходай Тәгалә безнең барыбызның да кол булуын теләсә, төрле диннәр һәм халыклар булмас иде. Ислам—ирекле кеше дине, ул—азатлыкка юл. Бер үк вакытта кол да, мөселман да булу мөмкин түгел, бу—мәгънәсезлек. Җәннәттә күндәм ялчылар төркеменең керәге юк. Галәм иҗат кешеләренә мохтаҗ.

XX гасыр тормышка җитди үзгәрешләр кертте. Кешеләр милли киемне түгел, модалы һәм уңайлы киемне өстен күрәләр. Тормышның тышкы иҗтимагый нормалары эчке дәлилләргә алмашынды. *Җәмәгать* кеше алдында чигенеп куйды. Шәхес үзе җәмгыятькә тиңләште. Дин үзе дә чиркәү тамашасыннан, социаль феноменнан интим, рухи, бик шәхси нәрсәгә әверелә башлады. Кешеләр үз тормышларына тыгылганны һәм нәрсәнедер көчләп тагуны яратмыйлар, үзләре теләгәнчә сайлап алуны өстенрәк күрәләр.

Ислам—мәңгелек хәрәкәт, һәрдаим икеләнү һәм туктаусыз эзләнү ул. Катып калган—димәк, үлгән дигән сүз. Ислам баш өстендә эленеп торучы гильотина түгел, ул—моңарчы күрелмәгәнне эзләүгә этәргеч. Мөхәммәт Икбал әйткән: “Хәзерге заман мөселманы үз халәтенең кадерен белсен, үзенең иҗтимагый тормышын югары принциплар нигезендә үзгәртеп корсын һәм исламның моңарчы өлешчә генә ачылган максатыннан исламның олы максаты булган рухи демократияне үстереп җибәрсен иде”.[1]

*Бидгать...* Бу сүз авыздан бик җиңел очып чыга түгелме икән? Гадәти булмаган берәр нәрсә килеп чыкса, ана шунда ук *бидгать* дигән ярлык тагалар. Кайбер сөнниләр өчен шигыйлар—диннән язган мөртәтләр, кайбер шигыйлар өчен, киресенчә, сөнниләр—диннән язучылар. Мондый мантыйкка иярсәң, тегеләрен дә, боларын да үлем җәзасына тартырга була, гәрчә бу хәл Коръәннең дин тоту иреге турындагы *аятьләренә* каршы килсә дә.

Фән дөньясында бәхәсләр гадәти күренеш булып санала һәм хәтта бер-береннең хатасы да хакыйкать эзләү кебек кабул ителә, ә исламда исә теләсә нинди яна фикернең тыелуы мөмкин.

Идрис Шах болай дип яза: “Кеше йә дин тотучы, йә дин тотмаучы, йә, ихтимал, агностик булырга тиеш дип уйлыйлар һәм моны бик еш кына аксиома итеп саныйлар. Әгәр кеше дин тота икән, ул, үз фикеренчә, үз ихтыяҗларын канәгатьләндерә алучы динне яки системаны кемнендер күрсәтеп бирүен көтәчәк. Әмма бу ихтыяҗларның нидән гыйбарәт икәнен, ихтимал, үзенең дә аңлап җиткермәвен аның үзенә күрсәтеп бирүчеләр аз булыр”[2].

Мәңгелек хакыйкатьләрне беләсе килә, әлбәттә, ләкин алар юк, күрәсең. Яхшылык һәм яманлык—катып калган категорияләр. Алтын кагыйдә бар: “Һәркем үз-үзен, башкаларның үзенә карата ничек булуын тели, шулай тотарга тиеш”. Бу кагыйдә христианлыкта да, исламда да, конфуцийчелектә дә бар. Кытайның бер акыл иясе моны Насретдин муллага әйткәч, мулла болай дип җавап биргән: “Бер кош үзенә бер дә зарары тими торган агулы җиләкләр ашап яши. Бервакыт ул бу җиләкләрне җыя да үзенең дусты атка ашата, шул рәвешле, иртәнге аш корбан китерүгә әйләнә”. Шул рәвешчә урта гасырларда яхшы хезмәт иткән шәригать нормаларының XXI гасырга яраксыз булулары мөмкин.

[1] *Мухаммад Икбал.* Реконструкция религиозной мысли в исламе. – М., 2002. – С.166.
[2] Идрис Шах. Суфизм. – М., 1994. – С.59.

***"Вә дәлилең, белемең булмаган нәрсәгә иярмә"[17:36].***

Ислам үз заманы өчен дөньяга иң алга киткән караш булган. Ул ачыктан-ачык прогресс сыйфатында барлыкка килгән. Тәкъвалык илгә һәм халыкка өстенлек биргән, ул кешеләрне акыллы, булдыклы иткән, җәмгыятьтәге ызгыш-талашларны туктаткан. Ислам аркасында Көнчыгыш югары дәрәҗәдәге белем һәм зирәклек тупланышына әверелгән. Мөселманнар Мәккәгә карап дога гына кылмаганнар, Көнчыгыш культурасына йөз дә тотканнар.

Аннан соң мөселман дөньясы йокыга талган һәм хәзерге көнгәчә үзенең артта калганлыгын бетерә алмый. Самолетлар, автомобильләр, космик станцияләр, азмыкүпме житди ачышлар Көнбатышта ясала. Сәйид Котб раславынча, "кешелек ялгыш юлдан бара"[1]. Ул болай дип яза: "Көнбатыш цивилизациясенең рухи асылын аның барлык доктриналары һәм тәртипләре белән бергә тутык ашый бара... Матди житештерү күләменең зурлыгына, фән һәм техниканың югары күтәрелүенә карамастан, ана регресс һәм кырылып бетү куркынычы яный."[2] Ләкин күзгә ташланып торучы нәрсәләрне күрмәү мөмкин түгел. Көнбатышның өстенлеге кешелекнең иң югары казанышларын үзләштерүгә нигезләнгән. Чынлап [медицина, которая лечит] дәвалаучы медицина, кешеләрне баетучы технологияләр, халыкны туендыручы һәм хәерчелекне бетерергә ярдәм итүче заманча агрокультура, тигезлеккә һәм гаделлеккә омтылу—Коръән өнди торган бар нәрсәләр нәкъ менә Көнбатышта гамәлгә ашырыла. Көнбатышның "наданлыгын" аңлатырга тырышып, Сәйид Котб болай дип яза: "Без самолетлар, ракеталар ясаган, атомны таркаткан, водород бомбасы уйлап тапкан, табигать законнарына төшенеп, аларны үзенең эшчәнлегендә файдаланучы акыл шулай ук кешелек тормышының "строен", күзаллауларга һәм инандыру концепциясенә кагылышлы кагыйдәләрне, әхлак нигезләрен булдыру мәсьәләсен дә хәл итәргә сәләтле дип хыялга китерәбез".[3] Югары үсешкә ирешкән җәмгыять строе, ана тәнгәл әхлак, хезмәт күнекмәләре булдырмыйча самолетлар һәм ракеталар төзеп булмый. Башкача фикерләү—үзүзеңне алдау ул.

Бөек Низами болай дип язган: "Юлда йокыга киткән кеше йә бүреген, йә башын югалтыр".

Гарәп илләре колониаль бәйлелектә булган чакта барысына да дөнья империализмын гаепләргә була иде, әмма аннан соң да үз юлының сайлар өчен житәрлек вакыт узды инде. Мөселман илләренең үсеш модельләре әллә ни искитәрлек түгел. Иранда, Пакистанда "саф ислам" илләре төзергә тырышу исә аларны тагын да артта калуга, сәяси тотрыксызлыкка, эчке сугышларга һәм ислам дәүләтләре арасында сугышларга китерде. Хәзер инде артта калу сәбәпләрен тыштан түгел, эчтән эзләргә кирәк.

Инде ихластан танырга кирәк—ислам дөньясы нигездә чимал белән сәүдә итә һәм көнбатыш товарлары сатып ала. Анда фәннәр һәм технологияләр үсми. Ислам дөньясы кешелек үсешенең төп юлларыннан читтә калды.

Артта калганлыкны тәкъвалык белән акларга ярамый. Әгәр мөселманнар тәкъва икән, алар нигә артта калганнар соң? Коръәннең вазифасы башка—мөселманнарны планетада иң алга киткән кешеләр итү иде.

Пәйгамбәрнең фикердәшләре исә һәрбер галим Коръәнне мөстәкыйль өйрәнә һәм үз фикерен—*иҗтиһадны* булдыра ала дип санаганнар. Яшь ислам гамәли проблемаларга җавап биргән. Гарәпләр Борынгы Грециядән башлап төрле культураларның казанышларын үзләренә йотлыгып сеңдергәннәр. Хәлифләр борынгы яһүдләрнең, византиялеләрнең, фарсыларның, шулай ук грекларның һәм буддачыларның җирләренә хуҗа булганнар, яулап алу походлары белән Франциянең көньягына, Испаниягә, Һинд үзәннәренә кадәр барып житкәннәр. Ислам башка традицияләргә ачык булган. Аның өстенлеге дә шунда булган. Фикер хөрлеге һәм ачыклык исламны көчле иткәннәр. Европа гарәп фикер ияләреннән күп нәрсәгә өйрәнгән. Әбүгалисинаның "Әл-Канун" дигән медицина трактатыннан Европада XVII гасырга кадәр файдаланганнар. Европа Ибн Рушдины йотлыгып укыган, ә Әл-Хәрезми язмалары аша "гарәп" цифрлары һәм алгебра (*әл-җабр*) белән танышкан. Әл-Хәрезми дигән ялгызлык исем "алгоритм" дигән терминга әйләнгән. Аверроэс идеяләре Европада XII гасырдан алып XVI гасыр ахырына кадәр өстенлек

[1] Сейид Кутб. Будущее принадлежит исламу. – М., 1993. – С.88.
[2] Сейид Кутб. Будущее принадлежит исламу. – М., 1993. – С. 57-58.
[3] Сейид Кутб. Будущее принадлежит исламу. – М., 1993. – С.90-91.

иткәннәр. Евгений Бертельс болай дип язган: "Европа культурасы тарихында IX–XIII гасырлар чоры бик каты төшенкелек вакыты икәнен искә төшерсәк, Европа халыкларын тупиктан чыгарып алга таба үсү юлын нәкъ менә көнчыгыш философларының хезмәтләре күрсәткән диган нәтиҗәгә килмичә мөмкин түгел".[1] Әмма шуннан соң ислам фикере схоластикага чумган һәм шуннан чыга алмый, күрәсең.

Тәкъвалык һәм арттa калганлык бер-берсе белән сыеша алмый. Әгәр синең халкың алга бармый икән, әгәр мөселман дөньясы христиан дөньясыннан артта кала икән, тәкъвалыкның мәгънәсе нидә? Фәхеш йортлары булмауда һәм шәраб эчмәүдәме? Шәраб эчүне һәм комарлы уеннарны тыю халык алга китсен өчен кертелгән, ләбаса!

Культураның узган замандагы бөеклеге XXI гасыр өчен дәлил була алмый. Узган заманга сокланып, үз-үзеңне юатып утырырга ярамый. Бүген телефон һәм компьютер кулланалар, самолетларда очалар, ә гарәпнең чабыш атларына ипподромнарда гына сокланалар. Көнчыгышның бөтен культурасы, саф токымлы гарәп аты сыман, хуҗалык өчен файдасы аз нәрсә—соклану предметы гына булып калды. Ул күбрәк ачык һавадагы тере музейга охшап бара. Ислам хәлифәтләре дәверен Ататөрек бетермәде,[2] ислам дөньясын традицияләргә сукырларча ияреп бару (*тәкълид*) какшатты.

Дин галимнәре исламны яңартудан куркалар, динне юкка чыгарачак дип санап, рациональлектән куркалар. Сәйд Мөхәммәт Нәкыйб әл-Әттас танып белүнең иң югары формасы итеп тоемлауны *(интуиция)* саный. "Кеше аңының иң югары баскычында пәйгамбәрләр һәм изгеләр ирешә торган тоемлау дәрәҗәсе чынбарлык табигатенең тирән катламнарын күрергә мөмкинлек бирә".[3] Автор, җәмгыять күбесенчә надан булганлыктан, тоемлау нигезендә исламны шәрехләү—сайлап алынганнар, изгеләр тәкъдире һәм гади кешеләргә берничек тә рөхсәт ителми торган гамәл дип саный.[4] Шунысын истә тоту зарур: Пәйгамбәр халыктан бер дә читләшмәгән, киресенчә, ярлылар һәм эзәрлекләнүчеләр белән теләп аралашкан. Бүген исә *сәетләр* халык төркеменнән өстәрәк торуны мәгъкульрәк күрәләр һәм яңа пәйгамбәрләр роленә диярлек дәгъва кылалар.

Йосыф әл-Кардави, үзе *иҗтиһадка* өнди, үзе болай дип яза: "Теләгән һәркем иҗтиһадка катнаша ала торган вәзгыятьне шул хәлендә калдырырга ярамый, чөнки бу анархиягә һәм гыйсъянга китерәчәк". [5] Ул *иҗтиһадка* лаеклылар һәм лаеклы булмаганнар бар, дип саный. "Лаеклылар" төркемен кем билгеләр икән соң?

Дин галимнәре исә урта гасырларда *иҗтиһадка* хокукы булган кешеләр төркемен чикләгән күренекле акыл ияләренә таяналар. Бусы аңлатырлык хәл. Ул заманда халыкның белем дәрәҗәсе шундый булган: дини темаларга фикер йөртүне бар кеше дә булдыра алмаган. Бүген исә бар кешенең дә белеме һәм югары белем алу мөмкинлеге булу вәзгыятьне үзгәртте. Һәркем Коръәнне мөстәкыйль рәвештә, хәтта ана телендә өйрәнә ала.

Йосыф әл-Кардави *иҗтиһадка* башка төр чикләнмәләр дә куя: "Мөселманнар өчен уразаның мәҗбүрилеге, шәраб эчүне яки дуңгыз ите ашауны тыю, рибачылыкны тыю яки караклыгында бернинди дә шик булмаган очракта каракның кулларын кисү бурычы ... кебек катгый мәсьәләләрдә иҗтиһадка урын юк. Шулай ук мәрхүм атаның балалары арасында мирас бүлешү—өстәвенә аның улларына кызларына караганда ике тапкыр күбрәк мал тияргә тиеш—кебек мәсьәләләр һәм Коръәннең, һәм чын Сөннәтнең бөтен Өммәт тарафыннан кабул ителгән башка кагыйдәләре Өммәтнең идея һәм иҗтимагый бердәмлегенә терәк булган дини догмалар булып торалар да инде".[6] Коръәндә тыелган нәрсәләргә карата бик зирәк формула бирелгән *аятьләрне* табарга мөмкин. Әйтелгән: "Иман китереп, изге гамәлләр кылып, мөселман булган кешеләргә әүвәлдә эчкәннәре өчен гөнаһ юк, әгәр янадан эчүдән саклансалар, иманнарын куәтләп изге гамәлләр кылсалар, соңра саклансалар, янә иманнарын тазартып тәкъвалек кылсалар һәм изге гамәлләрне—яхшы эшләрне эшләсәләр. Бит Аллаһ яхшы эшне кылучыларны сөя" [5:93]. Мондый *аятьләр* заманча шәрехләүгә мохтаҗ.

[1] Суфии. Собрание притч и афоризмов... – С. 496.
[2] *Сейид Кутб.* Будущее принадлежит исламу... – С.5.
[3] *Сейд Мухаммад Накыб аль-Аттас.* Введение... – С.138.
[4] *Сейд Мухаммад Накыб аль-Аттас.* Введение... - С.24,37.
[5] *Юсуф аль-Кардави.* Современный иджтихад... С. 67.
[6] *Юсуф аль Кардави.* Современный иджтихад...- С.72.

Коръәндә кяферләрне үтерү турында күп *аятьләр* табарга була. Әйтелгән: "Әгәр сугыш хәрам булган айлар үтеп китсә, мөшрикләрне кайда тапсагыз, шунда үтерегез..." [9:5]. Әйтергә кирәк, кайбер дин галимнәре тарихи шәригатьне үтәмәгән барлык кешеләрне дә мәҗүсиләр дип аңлыйлар. Сәйид Котб яза: "Аллаһ сызган юлга тәнгәл яшәүче кешеләр—мөселманнар, ә теләсә нинди башка юлдан баручылар—мәҗүсиләр, аларны бу дин танымый".[1] Коръәндә исә христианнар һәм яһүдиләр турында, алар мәҗүсиләр түгел, алар *китап бирелгән кешеләр* дип әйтелгән.

Алга таба мондый *аятьләр* табарга мөмкин: "Аллаһуга вә ахирәт көненә иман китермәгән кешеләр белән сугышыгыз вә Аллаһ һәм Аның рәсүле хәрам кылган нәрсәләрнең хәрамлыгына ышанмаган вә хак дин—исламны дин итеп алмаган кешеләр белән сугышыгыз! Алар китап бирелгән кешеләрдер, кимсетелгән халдә үз куллары белән җәза-түләү биргәнчегә чаклы алар белән сугышыгыз!" [9:29]. Шул ук вакытта башка бер *аять* ул кадәр үк катгый түгел: "Раббыңның юлы булган ислам диненә кешеләрне чакыр, вә чакырыгыз Коръән дәлилләре белән, дәхи тәэсирле яхшы вәгазьләр белән, дәхи кешеләргә хаклыкны төшендерү өчен алар белән тартыш вә көрәш иң күркәм юл белән!" [16:125].

Пәйгамбәргә әйтелгән: "И-и, Мөхәммәд г-м! Кяферләр һәм монафикълар белән сугыш кыл вә аларга катылык, гайрәт күрсәт!" [9:73]. Ә Пәйгамбәр үзе болай дигән: "Дөрестән дә, Аллаһ игелеклелек, бар гамәлләрдә дә йомшак мөгамәлә ярата". Без бер үк мәсьәләгә карата төрле күрсәтмәләр күрәбез. Яки әйтелгән: "И-и, мөэминнәр! Үзегезгә якын кяферләр белән сугыш кылыгыз! Алар сездә куәт вә катылыкны тапсыннар өчен..." [9:123]. Әмма Пәйгамбәр: "Диндә чамасызлыктан сакланыгыз",—дип кабатларга яраткан. *Мәзһәбләр* бу кагыйдәләрне каттый дип шәрехлиләр. Бүген мондый каттыйлык үз-үзен берничек тә акламый.

***"Әгәр Аллаһ теләсә ки, бөтен дөнья кешеләрен һидаяткә салыр иде..."[13:31].***

XVIII һәм XIX гасырлар чигендә татарлар арасында *җәдидчелек*[2] хәрәкәтен башлап җибәргән Габденнасыйр Курсави, халыкларга: "Сез хак вә тәкъва мөселманнар түгел. Сез Аллаһуның Коръәненнән һәм Пәйгамбәрнең сүзләреннән читкә тайпылдыгыз",—дигән өндәмә белән мөрәҗәгать итә. Ул Изге китапның үзен укырга һәм гамәлдәге традицияләрне тәнкыйди бәяләргә чакыра.

Бохарада булган вакытта ул Ходайның *сыйфатлары* турында фикерен белдерә. Ул чакта дин галимнәренең бер төркеме Ходайның сыйфатлары җиде, ә икенче төркеме—сигез дип исәпли. Курсави раславынча, җиде дип тә, сигез дип тә әйтеп булмый, чөнки Коръән сыйфатлар санын берничек тә билгеләми. Әлеге мәсьәлә буенча Бохара әмире катнашында уздырылган *голәмаләр* мәҗлесе *фәтва* чыгара, аның буенча Ходайның җиде яки сигез сыйфатын танымаган теләсә нинди мөселман мөртәт дип санала һәм аңа үлем җәзасы бирелергә тиеш була. Курсавины төрмәгә ябалар, әмма аңа үлем җәзасы бирелми кала—аны элеккеге остазы, бик абруйлы шәех Ниязкули яклап чыга. Курсавины үзенең сүзләреннән ваз кичәргә мәҗбүр итәләр һәм аның язмаларын халык алдында яндыралар. Шуннан соң ул Бохарадан туган иленә кача.

***"Әгәр сине ялганчы дисәләр, бу кәферләрдән элек Нух кауме Нухны ялганчы диделәр, вә Гад кауме Гадны, Сәмуд кауме Сәмудны ялганчы диделәр. Намруд кауме Ибраһимне, Лут кауме Лутны. Мәдйән кауме Шөгаебне ялганчы диделәр, вә Муса да ялганга тотылды" [22:42-44].***

Курсави яшәгән елларда Бохараның коллар базары Иран шигыйлары белән тулган була. Традиция буенча алар *кяферләр* булып саналганнар, шуңа күрә *"көлли мөслим хөрр" (һәр мөселман ирекле)* дигән принцип аларга кагылмаган. Ләкин Коръәндә дә, Сөннәттә дә *кяферлекнең* төгәл аңлатмасы юк. Әгәр алар моңа хаклары булмаган килеш башкаларны кяферлектә гаеплиләр икән, алар бер-берсеннән ни белән яхшы? "Аларның мәзһәбе, сезнеке кебек үк—һәвәслек *(һава)* ... Сезнең сыеныр урыныгыз—Аллаһ җитәкчелеге һәм Сөннәт юлыннан бару",—дип язган Курсави.

Коръәнгә һәм Сөннәткә мөрәҗәгать итү чынлыкта теләсә нинди *мәзһәбне* инкарь итә. Замандашлар күз алдында *тәкълид* котылу ысулы булмаган, мөстәкыйль эзләнү—

---

[1] *Сейид Кутб.* Будущее принадлежит исламу... – С.9.

[2] Җәдидчелек – татарлар арасындагы иҗтимагый-дини хәрәкәт. Бу термин *әл-җәдид* дигән гарәп сүзеннән килеп чыккан, ул яңарыш, реформа дигәнне аңлата.

*иҗтиһад* кирәк булган. Бирелә Курсави өчен җәмәгатьчелек фикере хакыйкать билгесе булып тормаган. Аныңча, үз фикерләренең хаклыгына, аларның "тугры юлга" тәңгәллегенә инанган галим үзе үк *җәмәгать (мөселманнар җәмгыяте)* булып санала ала, шуңа күрә ул, хәтта үз гамәле күпчелек тарафыннан хөкем ителсә дә, үз ихтыяры буенча эш итәргә хаклы. Хакыйкатьне яклаган кеше җәмгыять белән тигез дәрәҗәдә бөеклеккә ия. Бу—теологиядә революция булган. Курсави идеяләрен татар дин галимнәренең иң яхшы төркеме күтәреп алган.

Курсавиның беренче тәнкыйди фикерләре барлыкка килгәннән бирле инде ике гасыр вакыт узган, әмма ул күтәргән проблемалар тирәсендәге бәхәсләр һаман дәвам итә. Хәйдәр Баш болай дип яза: "*Мәзһәбләр* һәм *мәшрәбләр* принципларын кире кагып, турыдан-туры Коръәнгә һәм Сөннәткә, *Сәгадәт Гасыр* дәверенә мөрәҗәгать итәргә өндәү үзе үк Коръән һәм Сөннәт тарафыннан билгеләнүче *иҗма-и өммәтне*[1] һәм *кыяс-и фикъһәне*[2] инкарь итүне аңлата... Ә *Әхл әс-Сөннәт мәзһәбләре* һәм *мәшрәбләре* барлык дини проблемаларга иң дөрес принциплар нигезендә анализны күптән ясадылар бит инде"[3]. Гүя вакыт туктап калган да, шуңа күрә барлык проблемаларны да хәл ителгән дип санарга була, диярсең... Хәйдәр Баш дәвам итә: "*Өммәтнең* гасырлар буе бернинди шик-шөбһәсез *мәзһәбләргә* һәм *мәшрәбләргә* таянып эш итүе, *мәзһәбләр* һәм *мәшрәбләр* имамнарының гасырлар буе бәхәссез авторитетлар булып калуы—*мәзһәбләр* һәм *мәшрәбләр* карашының төпле булуын һәм һәрвакыт хакыйкатьне чагылдыруын тарихи дәлилләп тора"[4]. Әгәр дә кешелек шушындый ук мантыйкта фикерләсә, кояш системасының төзелеше хәзергә кадәр Коперник буенча түгел, Птолемей буенча аңлатылыр иде.

*Мәзһәбләрне*, һәм тулаем *тәкълид* принцибын, шулай ук *иҗмагъны* ялкынланып яклау астында бер гади фикер ята—теләсә нинди мөселман уйламый-нитми үз остазы артыннан барырга тиеш. "Хакыйкать җенсен өчен, дин тотучылар күндәм булырга, үз тирәлекләрендәге абруйлы үзәккә *итагать* күрсәтергә тиешләр. Бу күндәмлек (*итагать*)—Аллаһ Тәгаләгә һәм Аның Илчесенә күндәмлекнең (*итагатьнең*) бер өлеше..."[5]. Абруйлы үзәкнең Ходайны һәм Аның Пәйгамбәрен вәкиллек итү функциясен үз өстенә алырга ни хакы бар?! Фәрит Исак дөрес яза: "Исламда демократияның булуы мөмкин түгел, бөтен хакимият—Ходайдан дигән идеяне яклап, үзләрен Ходай вәкилләре югарылыгына күтәреп, калганнарны гади башкаручылар дәрәҗәсенә төшергән кайбер дин лидерларының демагогик сафсатасыннан башлары әйләнгән кешеләрне дә телгә алып үтәргә кирәк",[6]—дип яза ул. Һәркемнең хакыйкатькә үз юлы бар, бу юлны бернинди остаз да, имам да алыштыра алмый. Дин хезмәтчеләре, үзләре дә *тәкълид* тозагында булмаган очракта, хакыйкатьне эзләргә ярдәм итә алалар.

Мөхәммәт Пәйгамбәр әйткән: "Хактыр, Аллаһ һәрбер йөзьеллык башланганда *өммәткә* динне яңартучы кеше җибәреп торыр". Пәйгамбәр дин яңарту астында нәрсә күздә тоткан соң? Коръәнне шәрехләүнең үз заманына һәм билгеле шартларга туры килергә тиешлеген, күрәсең. Ислам—дөньяга караш, ул һәрдаим үсештә. Аның көче шунда. Коръәнне сүзгә-сүз уку аның мәгънәсен тәгәл бирә алмый, чөнки аның принциплары шушы урында, шушы заманда, шушы кешеләр өчен яраклы булырга тиеш. Вакытлар узган саен, нормалар үзгәрә, ләкин Коръәннең рухы үзгәрми. Габдулла Буби болай дип язган: "Әгәр дә без гел иске тәфсирләргә генә мөрәҗәгать итсәк, бу Коръәннең чиклелеген һәм бетүен, ә Пәйгамбәр сүзләренең ялганлыгын аңлатыр иде". Чыннан да, хәтта бик абруйлы булсалар да, аерым кешеләрнең сүзе Коръәннән өстен була алмый. Хакыйкатькә дәгъва кылырга беркемнең дә хакы юк, хакыйкатьне танып белүгә юл гына күрсәтергә мөмкин.

Габдулла Буби, *мәзһәбләрнең* чамадан тыш табынуы "ислам халыкларының ләгънәтенә" әйләнде дип әйткән. Ә бит *мәзһәбләргә* нигез салучылар үзләре мөселманнарны төрле мәктәпләргә бүләргә уйламаганнар да. Әбү Хәнифә кисәткән: "Минем дәлилләремне белмәгән кешеләргә минем сүзләремә таянып, карарлар—*фәтвалар* чыгару тыела". Ул үзенең урынын һәм вазифасын яхшы аңлаган, ләкин аның дәвамчылары үз остазларын аңламаганнар.

Без хәзергәчә, татарлар—хәнифи агым мөселманнары дип кабатлыйбыз. Бу

[1] Абруйлы мөселман галимнәренең теге яки бу мәсьәлә буенча карар чыгарулары.
[2] Кайбер мәсьәләләрне хәл иткәндә аларның аналогияләре белән чагыштыру.
[3] *Хайдар Баш.* Макалат... — С.160-161.
[5] *Хайдар Баш.* Макалат... — С. 199.
[6] *Фарид Исак.* Быть мусульманином... — С.157.

сүзләрнең мәгънәсе нидә? Әбү Ханифәгә ияреп, йөклелекнең вакыты ике ел дип санавыбыздамы? Яки хакыйкатькә бердәнбер юл тапканбызмы? Әлла без Коръәнне ин дөрес шәрехләүчеләрме? Бәлки без дөньяви дәүләттә мөмкин булмаган тарихи шәригать кертергә телибездер? Нинди дә *мәзһәбкә* иярү, турысын гына әйткәндә—Коръәнне кысага кертү дигән сүз ул. Әмма барлык *мәзһәбләрне* бергә алып карасаң да, Изге китап—алардан кинрәк, тирәнрәк. Һәм һәрбер яңа буын аннан яңа фикерләр ала. Әлеге процесс Коръәннең мәңгелек зирәклеге кебек үк чиксез.

Бөек Сәгъди сораган: "Йокыдагы кеше үзе шикелле башка бер йоклаучыны ничек уята ала?"

Исламның татар халкын саклап калудагы роле чагыштыргысыз зур. Христианлаштыру чорында тел, культура һәм дин халыкны ассимиляциядән саклап калганнар. Ислам татарларны җәмгыятьләргә берләштереп үзара ярдәмләшү механизмы булдырган. Ул, традицияләрне туплап "катырып" куеп, этник үзенчәлекләрне саклаган. Әмма XIX гасырда безнең халык алдына башка бурыч килеп баса: сакланып калу түгел, үсешкә ирешү. Туплап "катырып" саклау бу мәсьәләне инде хәл итә алмый, киресенчә, киртәгә әверелә һәм мондый хәлдән чыгу юлын табуда җәдидчелек ярдәмгә килә.

Җәдидчелек хәрәкәте чагыштырмача артта калган Көнчыгышны тиз үсә торган Көнбатыш белән чагыштырудан килеп чыккан. Җәдидчеләр үсешнең төп юлын заманча белем алуда һәм башка халыкларның культура казанышларын файдалануда күргәннәр, алар Европадан өйрәнергә өндәгәннәр. Татарларның иң яхшы мәдрәсәләре җәдид мәдрәсәләре булган.Татарның XIX-XX гасырдагы күренекле фикер ияләре, язучылары, җәмәгать эшлеклеләре нәкъ менә шул тирәлектән чыкканнар.

XX гасыр башына кадәр татарлар өчен күп кенә һөнәрләргә, дөньяви университетлар оештыруга һәм икътисади эшчәнлеккә чикләүләр яшәп килгән. Православиелеләр ачыктан-ачык өстенлекләрдән файдаланганнар. Шуңа да карамастан, исламны яңарту аркасында татарлар конкурентлыкка сәләтле булганнар һәм культура өлкәсендә бик зур сикереш ясаганнар. Татарларны традицияләрне "катырып" саклап кую түгел, ә нәкъ менә исламны яңарту ныгыткан.

Гасырлар буе торгынлык кичергән Көнчыгышка җәдидчелек идеяләрен кабул итү катлаулы булган. Муса Бигиевнең хезмәтләре госман мөселманнары башлыгы тарафыннан сафсата дип аталган. Муса Бигиев Советлар Россиясенән качып китәргә мәҗбүр булган.

> ***"Әгәр бер шәһәр халкына газаб белән куркытучы пәйгамбәр җибәрсәк, ул шәһәрнең нигъмәт эчендә булган хуҗалары, без сез китергән дингә ышанмыйбыз, дип җавап бирделәр"[34:34].***

Мөхәммәт Пәйгамбәр заманыннан соң күп нәрсәләр үзгәргән. Бик тиз үсүче фәнни мәктәпләр, заманча технологияләр һәм техника искергән традицияләргә урын калдырмыйлар. Кайвакыт дин һәм фән параллель рәвештә яши яки фән динне кысрыклый сыман тоела. Чынлыкта исә, фәнни фикерләү исламга каршы тормый, чөнки ислам ул—бер үк вакытта ышану да, белем дә, боларның икесен дә үз эченә алучы культура. Мөхәммәт Пәйгамбәр: "Кем башкаларны өйрәтү максатында күпме булса да фән өйрәнә—шуңа Аллаһ Тәгалә җитмеш изгенең котылу чарасын бирер",—дип кинәш иткән. Димәк, фәннәр исламның табигый өлешен тәшкил итә.

Кайбер дин белгечләре Коръәннән иң яңа фәнни ачышларга дәлилләр эзлиләр. Дөрестән дә, анда Галәмнең кинәюе теориясен яки атомның бүленешен раслаучы юллар бар, ләкин Коръән конкрет белем энциклопедиясе түгел, ул иң яңа ачышлар каршында "аклану"га мохтаҗ түгел. Галәмнең төзелеше яки кеше эволюциясе мәсьәләләрендә Коръәнгә йөз тоту сәер булыр иде. Анда иң гомуми һәм якынча мәгълүматлар бирелгән. Фәннең вазифасы да галәмнең тулы картинасын ачыклаудан гыйбарәт.

Хак мөселман—ул фәннәрне ихтирам итүче, фәннәргә тәшенүче, белемле кеше. Мөхәммәт Пәйгамбәр әйткән: "Белем алу—мөселманның иң төп бурычы". Бу—катгый таләп. Үз-үзеңне, тирә-ягыңдагы дөньяны, Галәмне танып белергә омтылу—хакыйкатьне, димәк Аллаһ Тәгаләнең үзен аңлау дигән сүз. Әйтелгән: "...Вә тәхкыйк Аллаһуның һәрнәрсәне белем белән әйләндереп алганлыгын белүегез өчен" [65:12]. Ул барысын да үз эченә ала, чөнки Ул—Галәмнең үзе. Теләсә нинди фән, теләсә нинди белем—Аллаһка таба бер адым, ул сукырларча табынуны түгел, кеше

эшчәнлегенең файдасын күтә. Аллаһ житмеш изгедән дә өстен күрсен өчен, жәмгыять файдасына тотылган аз гына белем дә житә. Пәйгамбәр шулай дип әйткән.

***"Аллаһ жирдәге, вә күкләрдәге яшерен нәрсәләрне, һичшиксез, беләдер"[49:18].***

Дин тотучыларның кайберләре могжиза һәм күрәзәчелек таләп итә, ә дин белгечләре Коръәннән һәм Пәйгамбәр тормышыннан моңа дәлилләр эзли. Ләкин могжиза—бала-чагалар һәм беркатлы кешеләр өчен уенчык ул. Табигать—үзе могжиза. Могжиза Жирнең тарту көчен жиңеп галәмгә очкан кешенең мөмкинлекләрендә. Табибларның кешене клиник үлемнән соң терелтергә өйрәнүләре—могжиза.

Ватиканда булган чакта миңа Татарстан мөфтие белән сөйләшеп алырга кирәк булды һәм мин аңа үземнең кәрәзле телефонымнан шалтыраттым. Ул бу вакытта Жиддәдә булып чыкты. Без бер-беребездән меңәрләгән чакрым ераклыкта торып та сөйләшә алдык. Жирнең ясалма иярченнәре кешелекне элемтә пәрәвезенә чорнап берләштерәләр. Күп гасырлар буена кешеләр үзара элемтә чаралары булдыруга ирешкәнәр—почта, фельдъегерь элемтәсенә меңләгән атчабарлар хезмәт иткән, аннан соң автомобильләр, очкычлар барлыкка килгән, ниһаять, телеграф, чыбыксыз элемтә уйлап табылган. Бүген исә электрон һәм мобиль элемтә системасы чыпчын могжиза кебек, ә спутниклар бик биектә планета гакылының нерв жепселләрен тотып торучы фәрештәләр кебек тоела.

Наданлык могжиза таләп итә, ә белем моңа мохтаж түгел. Белем могжизаны үзе тудыра. Кеше даһилыгы бары тик бер буын эчендә, без яшь чакта фантастик романнардан гына укып белгән техниканы һәм технологияне тудырды. Аңлатып булмый һәм безнең акыл чикләренә сыймый торган нәрсәне эзләргә кирәк микән? Аңлатып булмый торган нәрсәгә ышанырга кирәк микән соң? Киресенчә, табигатьтә, ихтимал, чиксезлектән башка, бар нәрсәнең дә аңлатмасы табылырга тиешлегенә ышанырга кирәк.

Цивилизациягә ирешкән бар дөнья мәгариф мәсьәләләрен сүздә генә түгел, гамәлдә дә иң беренче урынга куйды. Алга киткән илләр бюджетында чыгымнарның беренче маддәсе мәгарифкә бирелгән. Бәлки хак мөселманнар Суданда түгел, әнә шул илләрдә яшидер? Пәйгамбәр әйткән: "Бөтен нәрсәгә дә аерым юл бар. Жәннәткә юлны исә гыйлем ача".

Дөнья ашкынып үзгәрә. Көнчыгыш, Европаны һәм Американы сүгеп, үзенең вазифасы турында уйланып торганда, Көнбатыш үсеш юлыннан алгарак китә бара.

Кайда безнең кыйбла?

Көнбатыш чамадан тыш рациональ, артык индивидуальләшкән—Көнчыгыш шулай дип саный. Моңа үпкә белдерергә ярамый, бу—объектив вәзгыять. Заман таләбе шундый. Конкуренция исә алга киткән, аңлы, киң белемле шәхесләр тәрбияләүне таләп итә. Масса яки коллектив белән нинди дер күренекле уңышка ирешү кыен.

XXI гасырны XX гасырдан аерып торучы нәрсә—мәгълүмат өстенлеге. Форд уйлап тапкан конвейер XX гасыр символы булса, яңа дәвернең символы—компьютер, Интернет һәм элемтәнең яңа технологияләре. Белем исә житештерү ресурсларының иң мөһименә әверелде. Моның белән бергә кешенең роле дә үзгәрә, аның өчен иң мөһиме—ижади фикерләү.

Ислам реформаторларының берсе Гамәл әд-Дин әл-Әфгани "интеллект һәм культураны рациональлек һәм дөньяви кыйммәтләрдән саклап калып, замана цивилизациясенең технологияләрен һәм эш коралларын үзләштерергә кирәк"[1] дигән фикергә инанган булган. Кулланучы күзлегеннән караганда, әлеге принципка иярергә мөмкин, ләкин техниканы һәм технологияне үстерергә тырышсаң, рациональлектән башка берни эшли алмыйсың.

Көнбатышның характеры фәнни-техник прогресс һәм ижтимагый тормышның алга киткәнлеге белән билгеләнә. Индивидуальлеккә бергәлекне һәм коллективны каршы кую, рациональлекне инкарь итү—үзенне артта калуга күрәләтә дучар итү дигән сүз.

Жәмгыятьтәге йогынтысын саклап калырга теләсә, ислам заман таләпләренә жавап бирә белергә тиеш. Хикмәт Көнчыгышка арка белән борылып, Көнбатышка

[1] *Сухейль Фарах.* Христианство и ислам (опыт секуляризации). – Н.Новгород, 1999. – С.73.

йөз тотуда түгел, ә дөньядагы барлык әһәмиятле нәрсәләрне үзләштерүдә. Инде бүгенге көндә АКШ, Европа һәм Көньяк-Көнчыгыш илләре бик тиз үсәләр икән, димәк алардан өйрәнергә кирәк. Белем алырга шунда барырга кирәк.

Мөселман илләрендә күпләр Көнбатыш үрнәкләрен үзләренә турыдан-туры күчерә башладылар. Муса Бигиев моны "яна *тәкълид*" дип атаган. Ул болай дип язган: "*Мәзһәбләрнен* берсен "ихтирам итү" турында фантазияләргә ярарга тырышып исламны һәм шәригатьне аларга корбан итү берничек тә риза булырлык нәрсә түгел. Хәтта моннан да зуррак һәм аныбызны зарарлаган тагын бер кимчелегебез—хурлыклы һәм кимсеткеч нео*тәкълид*. Традицион *тәкълид* шәригатьне *мәзһәбләр* изгелегенә табыну юлы белән корбан итүдән гыйбарәт булса, искә алынган заманча *тәкълид* исә Көнбатыш цивилизациясенә һәм анын сәяси казанышларына сокланудан килеп чыккан кимсенү җирлегендә исламнан баш тарту һәм мөселман *өммәтен* корбан итү булып тора" [1].

Көнбатышны Көнчыгышка күчерә алмыйсын. Анда җирлек башка. Көнчыгыш либеральлекне чиста рәвештә кабул итми. Ул аны үз традицияләре аркылы үткәрергә тиеш. *Тәкълид* Көнчыгышныкы булса да, Көнбатышныкы булса да—яраксыз, чөнки ул исламнын рухына каршы килә, ә Көнчыгышны Көнбатышка либераль фикер йөртүнен башлангычы булган *иҗтиһад* якынайта. Әгәр дә ирекле шәхес белемгә һәм фәнгә тартыла, прогресска омтыла икән, бу—көнбатыш культурасына да, ислам культурасына да яраклы.

> ***"Ул үлемне һәм тереклекне халык кылды, йөкләмәләр йөкләп сезне сынамак өчен, кайсыларыгыз яхшырак гамәлле икәнлеген белмәк өчен..."[67:2].***

Мөселманнар һәрбер эшне: "Бисмилләһир-рахмәнир-рахим" *(мәрхәмәтле һәм рәхимле Аллаһ исеме белән)* дип башлый. Бу нәрсәне анлата? Ана омтылырга, анын өчен яшәргә дигәннеме? Гади сорау, әмма ана җавап бирү катлаулы... Әйтелгән: "Без җирне һәм күкләрне, вә аларнын арасында булган нәрсәләрне уйнап-шаярып бушка гына халык кылмадык... Зекер ителгәннәрне һәммәсен фәкать хаклык илә халык кылдык, ләкин имансызлар Безнен хак эшебезне белмиләр"[44:38-39]. Табигый законнар буенча яшәүче һәм мәгънәгә ия Галәм үзе хакыйкать булып тора да инде. "Ул—Коръән, барча галәм халыкларына вәгазьдер, кирәк эшләрне исләренә төшерүчедер, вә кешеләргә иманны, динне, һидәятне һәм тәрбияне кәсеп итә торган ин туры юлдыр. Сезләрдән туры юлга күнелергә теләге булган кешеләргә вәгазь һәм туры юлдыр. Юк, туры юлга күнелүне тели алмассыз, мәгәр барча галәмнәрне тәрбия итүче Аллаһу Тәгалә теләсә генә" [81:27-29]. Коръән "бөтен дөнья кешеләре өчен вәгазь" [6:90], Җирдә яшәүчеләргә алдан искәртү, ә Галәмнен Алласы—яшәү мәгънәсе, башкача әйткәндә, матдәнен рухы, галәмнен тәүге һәм ахыргы мәгънәсе, ул бар нәрсәне тәртипкә салучы, пространство һәм вакыт чиксезлеген кысаларга кертүче. Бу мәгънә "Китаплар анасында" буыннар тәҗрибәсе, кешелек тарафыннан даими тулыландырылып торучы галәми акыл сыйфатында тупланa. "Китаплар анасы"—үлемсезлек серe.

Сәйд Мөхәммәт Нәкыйб-әл-Әттас: "Үзенен табигате (*fitrah*) буенча баштан ук камил булганлыктан, дөнья үсә-үзгәрә алмый"[2] дип саный. Ул "Аллаһ анында үзгәрмәс нигезләр сыйфатында" яшәүче "идеаль чынбарлык дөньясы" дигән төшенчәгә таяна. Болай шәрехләгәндә дөнья үз камиллегеннән ялтырап катып калган кебек күзаллана. Әмма биредә автор Алланы миф яки символ дип түгел, чынбарлык дип атый. Вакытлар узу белән үзгәрми торган чынбарлыкны тану кыен. Мөселман берлегенен башта Мәдинә белән чикләнеп, алга таба Гарәбстанга кадәр киңәюен, ә Мөхәммәт үлгәннән сон исламнын кыска гына вакыт эчендә дөньянын дисталәгән зур илләрен үз эченә алуын искә төшерү дә җитә. Ислам дөнья күренешен үзгәртте. Кешелек тарихында бары тик Чыңгыз ханнын Азиядән Европага ыргылышы гына ислам хәрәкәтеннән тизрәк һәм киңрәк булгандыр.

Ходай Тәгалә—үзен Галәмдә чагылдыручы чынбарлык. Әйтелгән: "Кояш, Ай вә йолдызлар Аллаһ әмере буенча йөриләр, әгаһ булыгыз! Халык кылмак, һәр эшкә әмер бирмәк Аллаһ эше түгелме? Барча галәмне тәрбия итүче Аллаһ бәрәкәт иясе булды" [7:54]. Ул җирдәге тормышта, һәм әлбәттә, кешенен үзендә гәүдәләнә.

---

[1] Муса Джаруллах. Мой взгляд на исламский шариат // Иль.—1913.—№3 (Петербург).

[2] *Сейд Мухаммад Накыб аль-Аттас.* Введение...—С.27.

Пәйгамбәр әйткән: "Үз-үзен танып белгән кеше, үзенең Аллаһын да танып белгән". Болар барысы да—һәрдаим үзгәрештә һәм үсештә булган билгеләр. Мөхәммәт Икбал бик дөрес яза: "Коръән буенча дөнья үсешкә дучар ителгән. Бу—үсә торган дөнья. Ул күп гасырлар элек Тәңре кулы калдырган һәм хәзерге көндә, вакытлар узу белән берничек тә үзгәрмәгәнгә бернәрсәдән дә гыйбарәт булмаган үле матдә массасы кебек галәм һәм вакыт эчендә җәелеп яткан әзер продукт түгел".[1]

Галәм үзе дә планеталарның һәм йолдызларның катып калган өере түгел, ул үсеп-үзгәреп тора—яңа планеталар һәм йолдызлар барлыкка килә, аларның кайберләре сүнә бара. Астрономнар Галәмнең киңәюен исбатладылар. Коръәндә дә шул турыда әйтелә: "Ягъни китеп-килеп, күренеп һәм күренмичә йөрүче йолдызлар белән ант итәм" [81:15-16]. Әгәр дә галактикалар, җирдәге тормыш, кеше акылы һәм җәмгыять тә үзгәреш кичерәләр икән, ни өчен әлеге хәрәкәтне билгеләүче үзе дә үзгәрмәскә тиеш? Үсеш—абсолют, чөнки Алла үсеш кичерә, аның белән бергә яңа хакыйкатьләр барлыкка килә. Катып калган нәрсә үле дигән сүз.

Яшәү ни өчен һәм үлем ни өчен бирелә? Әйтелгән: "Барча кеше үлем ачысын татучыдыр, Без сезне сырхау, ачлык кебек яманлык илә вә сәламәтлек, байлык кебек яхшылык белән сыныйбыз, яки саваб белән гөнаһ арасында сезне сыныйбыз, боларны сезгә фетнә кылып сынау йөзеннән, соңра хөкем ителергә Безгә кайтырсыз" [21:35]. Ни өчен яманлык һәм яхшылык белән сынарга кирәк соң?

Кешенең вазифасы үле материягә рух кертеп, шул рәвешчә фани, матди *дөньяны* җинүдән гыйбарәт. Аннан читләшү түгел, аңа рух өрү. Кеше таштан храмнар төзи, металл аппаратларны очарга мәҗбүр итә, планетаның тиз артучы халкын туендыру өчен яңа үсемлекләр китереп чыгара. Ул байлыкны кешеләргә хезмәт иттерә. Яхшылык һәм яманлык белән сынау киләчәк буыннарга кирәкле тәҗрибә туплар өчен кирәк. Кыямәт көнен—Планетаның һәлакәтен нәкъ менә шулай гына кичектерергә мөмкин.

> ***"Кайчан күк ярылса. Вә йолдызлар чәчелсә. Вә дәрьяләр агып бергә кушылсалар. Вә каберләр актарылып үлекләр терелеп чыксалар. Шул вакытта һәркем үзеннән элек ахирәткә җибәргән һәм үзеннән соң калдырган эшләрен белер"[82:1-5].***

Бүген сәнәгать эшчәнлеге нәтиҗәсендә климатның үзгәрүе, кешеләр барлыкка китергән корал, табигатьтән тиләләрчә файдалану планетаны һәлакәткә китереп, тирә-юньне җәһәннәмгә әйләндерергә сәләтле. Бу турыда Аллаһ Тәгалә дә кисәткән: "Әгәр җир каты тетрәү белән тетрәсә. Вә Раббыңның әмере килсә, вә фәрештәләр саф-саф булып килеп бассалар. Вә ул көндә җәһәннәм китерелсә, менә шул көндә, адәм баласының исенә төшәр, алданганын белер, вәгазьләнергә бик теләр, ләкин эш узган булыр, кайда инде аңа хәзер искәрү, уяну файда бирсен? Эш узганнан соң адәм баласы әйтер: "Әйе, мина үкенеч, кәшки дөньяда чагымда дини гыйлем өйрәнеп, ахирәтем өчен изге гамәлләр кылган булсамчы",—дип [89:21-24]. Җәһәннәм—гөнаһ ияләрен яндыра торган физик ут түгел, җәһәннәм—рухи бушлыкны аңлау, кылынган яман эшләр өчен намус газабы—кеше фани дөньяда качарга тырышкан, ләкин киләчәктә кача алмаган нәрсә, байлыкның, артык муллыкның, ялганның һәм кеше үтерүләрнең, вакытны һәм көчне шәхси ихтыяҗларга сарыф итүнең мәгънәсезлегенә төшенү. Ә намус газабы физик уттан куркынычрак. Әйтелгән: "Кыямәт көнендә залимнәрне эшләгән кабахәт эшләрнең газабыннан куркучы күрерсең, нәфескә, шайтанга ияреп Аллаһ динен бозучы залимнәргә бармыйча, кемгә булсын чәчләрен агартып, йөзләрен каралтып, өннәрен ала торган төрле куркынычлы газаблар? Вә ул куркынычлы газаблар аларны каршылап кочаклап алыр" [42:22]. Теге дөньяда физик утлы җәһәннәмнең булуы мөмкин түгел.

Әгәр дә Җирдә экологик һәлакәт яки атом-төш сугышы килеп чыкса, моның нәтиҗәләре Коръән *аятьләрендә* сурәтләнгән җәһәннәм күренешләреннән бик күпкә куркынычрак булачак.

Кыямәт көне—тәкъдир дә, Хөкем көнен билгеләү дә түгел, бу—кисәтү. Әйтелгән: "Кешеләрне Коръән белән вәгазь кыл, гафләттән уят, әлбәттә, син фәкать Аллаһ хөкемнәрен сөйләп ирештерүче генәсен. Син аларга ирекле түгелсең һәм аларның

[1] *Мухаммад Икбал.* Реконструкция... – М., 2002. – С.68.

теләкләренә дә хужа түгелсен"[88:21-22]. Бу—булуы ихтимал һәлакәт, "таулар тетелгән мамык кебек һавада очканда..." "күк ярылганда...". Әгәр кешеләр акылга каршы эш итсәләр, әгәр алар арасындагы каршылыклар өстенлек алса, һәлакәт котылгысыз булачак. Кеше табигать һәм башка кешеләр белән гармониядә яшәргә, шул рәвешчә Кыямәт көне килүне булдырмый калырга тиеш.

> ***"Кяферләр синнән кыямәт кайчан була, дип сорыйлар. Кыямәтнең кайчан булачагын әйтүдә сиңа ни файда? Әйтсәң дә фәкать көферлекләрен арттырачаклар. Кыямәт вакытының ахыр чиге Аллаһуга хастыр"[79:42-44].***

Коръәндә күрсәтелүче җәннәт образы күбесенчә беркатлырак, ул, әлбәттә, салкынча күләгә һәм ясалма сугару турында хыялланган чүл кешеләренә исәпләнгән. Әйтелгән: "Әмма иман китереп, Коръән тәгълимате белән изге гамәлләр кылган кешеләрне тиздән асларыннан елгалар агучы җәннәтләргә кертербез, анда мәңге калганнары хәлдә аларга җәннәтләрдә пакь, гүзәл хатыннар булыр һәм аларны рәхәтлек күләгәсенә кертербез" [4:57]. Тагын бер урында әйтелгән: "Аллаһ, иман китереп, изге гамәлләр кылган мөэминнәрне асларыннан татлы елгалар агучы җәннәтләргә кертер, алар анда алтын беләзекләр вә энже ташлары белән бизәнерләр вә киемнәре яшел ефәктән булыр" [22:23]. Төньякта исә сугаруның андый зур әһәмияте юк, чөнки анда болай да эзлекле төстә яңгыр явып тора, ә кеше анда, бәлки, салкынча күләгәдән бигрәк кояш турында хыялланадыр. Ачык ки, пәйгамбәр хакыйкатьне үз халкына аңлаешлы телдә житкергән.

Гомумән әйткәндә, кайбер илләрдә комфорт җәннәттәге уңайлыкларга бик якын, хәтта алардан узып та киткән, шуна күрә күпләрне Коръәндәге җәннәт рәхәтлекләре кайчандыр Гарәбстан чүлендә кәрваннар йөрткән гарәпне кызыктырган кадәр кызыктырмый да. Тәкъва кешене җәннәттә көтеп торучы келәмнәр һәм яшел мендәрләр белән бүген беркемне дә шаккаттыра алмыйсың. Җәннәт рәхәтлекләрендә хур кызлары белән әңгәмә корып яшәүне дә мәгънәле дип әйтеп булмый. Интеллектка ия замана кешесенә рухи сусауны басу физик ләззәтләр алуга караганда шактый әһәмиятлерәк. Цивилизацияле кеше өчен "яхшы диваннарга таянганнары хәлдә, жимешләрнең һәм эчемлекләрнең төрлесеннән сорадылар" [38:51] дип тасвирланган мәңгелек сурәте үз мәгънәсен югалта. Аллаһ Тәгаләнең кешелек өчен ахырда мондый язмыш ниятләве мөмкин түгел. Коръәндәге җәннәт күренеше исә мәҗүсилектән биздерү зарур булган урта гасыр кешеләре өчен язылган, ләкин ул үсешкә ирешкән, рухи бай кешеләргә яраклы түгел.

> ***"Мәгәр Аллаһуның ихлас колларына газаб булмас, җәннәт нигъмәтләре булыр. Аларга җәннәттә теләгәннәре чаклы һәм алар теләгән вакытта төрле ризык булыр. Ул ризыклар төрле жимешләрдер һәм алар җәннәттә хөрмәтлеләрдер. Нигъмәтләр белән тулган җәннәтләрдә сыйланырлар. Яхшы диваннарга бер-берсенә каршы утырып рәхәтләнерләр. Хезмәтчеләр аларга савыт белән хәмер китерерләр, ул хәмер җәннәттә елга булып агар. Ул хәмер сөттән ак булып, эчүчеләргә ләззәтледер. Ул җәннәт хәмерендә акылны җибәрмәк, вә башны авырттырмак юктыр, һәм аны эчеп дөньядагы кебек исермәсләр дә. Вә яннарында хатыннары булыр, алар күзләрен үз ирләреннән алмаслар, башкага карамаслар, ул хатыннарның күзләре зур һәм матурдыр. Ул хатыннарның йөзләре аклыкта тәвә кошының йомыркасы кебек, анда аз гына сарылык булып иң матур төстер. Ул ләззәтле эчемлекләрне эчкәндә әйләнеп бер-берсеннән сорашырлар"[37:40-50].***

Җәһәннәмне һәм җәннәтне жирдәге куркынычлар һәм кеше сөенечләреннән торган матди картина итеп күзалларга кирәкми, асылы кешенең аң-белем чикләренә сыешмый торган символик билгеләр, образлар итеп аңларга кирәк.

Гомәр Хәйям язган:

*Хөҗрәдә, синагогада, монастырьда*
*Кемдер курка җәһәннәмнән, кемдер җәннәт өмет итә.*
*Тик илаһи сергә төшенгәннәр йөрәгендә*
*Юктыр урын андый уйдырмага.*

Эшлекле кеше буш әңгәмәләр корып вакыт үткәрә торган җәннәт турында

хыяллана алмый. Шуңа күрә Аллаһ Тәгалә җәннәткә башка билгеләмә биргән: җанын ни тели шунын булуы, "мәңгелек йорт"та хисапсыз бүләкләр. "Коръән юлы илә изге гамәлләр кылучы хак мөэминнәр, җәннәт бакчаларында нигъмәтләр эчендә булачаклар, аларга Раббылары хозурында ни теләсәләр шул булыр, бу нәрсәләр аларга Аллаһунын олугъ юмартлыгыдыр" [42:22]. Җәннәт—ул фани дөнья тәҗрибәсеннән торган рухи дөнья. Җәннәт—җирдә үткән юлыннын мәгънәле булуына ләззәтләнү.

"Кыямәт көненә ышанып яхшылык эшләгән кешене Аллаһ бүләге көтә"—Коръәндә шулай диелгән. Бу уңайдан сатулашып тору кирәк микән соң? Әгәр дә мин, инанып, кагыйдәләрне үз теләгем белән үтим икән, яхшылык өчен бүләкләү нигә кирәк? Игелек бу дөньяда да, теге дөньяда да бүләккә мохтаҗ түгел. Ул—үзе бүләк. Әйтелгән: "Аллаһ үзе теләгән бәндәсен хисапсыз ризыкландырыр" [2:212]. Өстәвенә, һәркемгә үзе аңлаган һәм үзе көткән бүләкләр бирелә. Болай булгач, тәкъвалыкнын мәгънәсе нидә? Җәннәттәге бүләкләргә омтылунын да, җәһәннәм утыннан куркунын да әһәмияте булмаса, тәкъва тормыш нигә кирәк? Мәгънә башкада. Әйтелгән: "Алар җәннәттә буш сүзләрне, вә гөнаһлы сүзләрне ишетмәсләр. Мәгәр сәлам бирешкән тавышны гына ишетерләр" [56:25-26]. Шушы хакыйкатькә төшенү, рухият кертү һәм планетаны һәлакәттән коткару—тәкъвалыкнын мәгънәсе нәкъ менә шушында инде.

***"Бер өммәткә дә әҗәле вакытыннан элек килмәс һәм вакытыннан кичекмәс"[23:43].***

Һәр илнең, һәр халыкнын үз тарихы, үз вазифасы бар. Әйтелгән: "Җирне халыклар өчен төзеп куйды" [55:10]. Аллаһ Тәгалә халыкларны бер генә итә алмаганга түгел, яхшылык эшләүдә бер халыклар икенчеләрен узып китсеннәр өчен төрле итеп яраткан. Шәхсән миңа үз халкымнан башка яшәвемнең мәгънәсе юк. Аллаһ Тәгалә, теләсә, барлык кешене дә гарәп итәр иде һәм барысы да гарәпчә сөйләшер иде. Әмма ул телләрне күп төрле итеп яраткан. Галәм—төрле культуралы яңадан-яңа буыннарнын тәҗрибәсен үзенә сеңдереп баручы илаһи гакылнын һәм ихтыярнын гәүдәләнеше ул.

Географик яктан гына түгел, культура ягыннан да Көнбатыш һәм Көнчыгыш чигендә торган татарлар үзләренең субцивилизациясен тудырганнар. Россиядә шәригать гамәлдә түгел, халыкнын күпчелеге православие вәкилләре. Мөселманнар тормышнын шушы рәвешенә яраклашырга тиешләр. Мөселманнар өчен Россиядәге шартлар читтән дә кертелмәгән, көчләп тә тагылмаган—татарлар шушы илдә туган, алар аны чит түгел, үз иле дип саный. Бу ил мөселман дәүләтләреннән яхшырак та түгел, начаррак та түгел, ул—башка. Безнең язмышыбыз һәм безнең вазифабыз—шушы шартларда хак юлдан бару тәҗрибәсе туплау. Бездән Согуд Гарәбстаны ясап булмый һәм без, мөгаен, христиан Европасы да була алмабыз. Без ничек бар—шундыйлар. Россия җирендә хөрмә пальмасы үсми.

Россиядә миллионлаган мөселман үзләренең дөньяви илдә, анын гасырлардан килгән культурасы белән санлашып яшәргә тиешлегенә инанып үскән. Мөселман илләренең дин белгечләре безне яшәргә өйрәтә алмый, Согуд Гарәбстанында укып, андагы остазларына сукырларча ияреп баручы имамнар безнең тормышта каршылыклар һәм гауга гына китереп чыгарачак. Алар урта гасыр шәригатен катгый үтәргә өндәячәкләр, анын күпчелек нормалары һәм принциплары Россиядә үтәлә алмый.

Европа мөселманнары да шуңа охшаш шартларда яшиләр. Алар христиан дөньясындагы утраучыкларга тиң.

Дөнья катнаш була бара һәм Татарстанда "саф ислам"нан читкә тайпылу кебек кабул ителгән вәзгыять киләчәктә күпчелек илләрдә норма булачак. Ислам хәлифәтләре чоры узды инде. Дөньяда бертөрлелек юк, бар нәрсә бер-берсенә бәйле була бара. Беркем дә бер читтә аерым тора торган "саф ислам" тирәлеге булдыра алмый. Мондый "идеал"га омтылунын хаҗәте дә юк, чөнки ислам христианлыкны яки башка халыкларнын тормыш рәвешен инкарь итми, ислам алар белән уртак тел табарга өйрәтә.

Татарстан югары технологияле продукция житештерә, бу исә үз фәнни мәктәпләрен һәм югары белем системасын үстерүне таләп итә. Без ясаган вертолетлар, йөк машиналары, самолетлар көнбатыш фирмаларныкыннан начаррак булырга тиеш түгел, шунын өчен безгә Европаныкына якын стандартлар кертергә

кирәк. Юкса, без конкурентларыбызга оттырачакбыз. Бездә Исламның европалашуы котылгысыз. Тормыш мона мәҗбүр итәчәк.

Чынлап та, безгә кайсы якка юнәлеш алырга соң? Судангамы, Пакистангамы, Ирангамы, Согуд Гарәбстанынамы? Ил никадәр артта калган булса, тарихи шәригатьне шулкадәр күбрәк кертә. Алар үзләренә мондый экспериментлар рөхсәт итә алалар, ә татарлар өчен артта калу—үлеп бетү юлы. Хәзергә исә мөселман илләре вертолетларны һәм авыр йөк машиналарын Татарстаннан сатып алалар, һич тә киресенчә түгел. Шулай булгач, алар безне Көнбатышка конкурент булырга ничек өйрәтә алалар соң? Халык яшәешенен мәгънәсе—тәкъва мөселманнар булып үлеп бетүдә түгел, ислам тамырларын югалтмыйча, алдынгы халык булу ысулларын табуда.

Хәзерге заманның кайбер дин белгечләре прогрессның әһәмиятен аңлыйлар һәм Көнбатыш йогынтысыннан курыкмыйлар, шуна күрә глобальләшү проблемасына шактый сабыр карыйлар. Мәсәлән, Фәрит Исак болай дип яза: "Берәүләр *мөнбәргә* күзәтчелек иткәндә, икенчеләр үз максатларында Интернеттан һәм телевидениедән файдалана алалар. Бүгенге көндә телевидениене кайвакыт барыбер *хәрәм (тыелган)* дип белдерсәләр дә, без беләбез: әле кайчан гына, *азан* авазын көчәйтә торган репродукторларны да *хәрәм* диләр иде. Димәк ки, тиздән "шайтан әрҗәсе" дә яхшы нәрсә дип белдереләчәк".[1] Беренче карашка, бу бик алга киткән позиция булып күренә, чөнки ул традицион позициядән нык аерылып тора, ләкин, асылда, бу фикергә кимлек төсмере салынган инде—ислам прогрессның койрыгында. Әгәр дә без яңа техниканы һәм технологияне үзебез үк уйлап тапмыйбыз икән, бервакытта да мул тормышлы халык була алмыйбыз. Согуд Гарәбстаны нефть исәбенә көн күрә, ә без бары тик белем һәм яңа ачышлар исәбенә генә яши алабыз. Без үзебездә ваһһабичылыкккa яки исламның башка төрле искереп беткән радикаль юнәлешләренә юл куя алмыйбыз.

Замана вәзгыяте шундый: бик теләсән дә дөньядагы тенденцияләрдән читтә яши алмыйсың. Глобальләшү яңа технологияләр алып килә һәм тормыш рәвешен үзгәртә. Бүгенге көндә үз культураңны шушы процессларга яраклаштыру ысулын табу зарур.

Дөньяда шулай ук ислам глобальләшүе дә бара, ул Көнчыгышны гына түгел, Көнбатышны да колачлап килә. Европа үзәгендә мөселманнар халыкның шактый зур өлешен тәшкил итә. Франция, Германия, Бөекбритания, Голландия, Швейцария һәм Италия үсә баручы мөселманнар берлеге белән санлашырга мәҗбүрләр. Шул ук вакытта Европа берлегенә, андагы ислам элементын көчәйтеп, көньяктан Төркия омтыла. Көнбатыш глобальләшүе дөньяда каршылык тудыра, әмма ислам глобальләшүе дә күпләрне куркыта. Алар дөньяда гармония ясап бер-берсенә кушылырлармы яки бәрелешерләрме—барысы да безнең үзебездән тора. Гәрчә террорны ислам тудырмаса да, террорның, гомумән, дине булмаса да, 11 сентябрьдән соң дөньяда исламофобия арта бара.

Дөнья христианнарга, яһүдләргә һәм мөселманнарга бүленде, алар арасында упкынга әйләнүе ихтимал булган ярыклар хасил булды. Алар кешеләрнең җаннары аша узып кешеләрне хәвефләндерәләр һәм куркыталар. Дөньяны яңа кыйммәтләр генә берләштерә ала. Алар чиста либераль да була алмыйлар һәм традицион ислам кыйммәтләре дә түгелләр.

> **"И-и, мөселманнар, ошбу Ислам милләте бер шәригать булганы хәлдә сезнең динегездер, төрле юлга бүленмәгез, вә Мин сезнең Раббыгызмын, Миңа гына гыйбадәт кылыгыз!" [21:92].**

Коръән буенча, Ходай бер генә, әмма диннәр төрле. Коръән вәхиләренең Мәдинә чорын исәпкә алмасаң *(ул чорның үзенчәлеге дошмани тирәлектә яшәүгә сәләтле ислам берлеге булдыру мохтаҗлыгыннан килеп чыга)*, калган урыннарында Коръән башка барлык диннәргә һәм яхшылык кылучы барлык кешеләргә карата түземле. Әйтелгән:"Дөреслектә, гамәлсез коры ышанучылар һәм яһүдиләр, һәм насаралар, һәм ай, йолдызларга табынучылар—алардан Аллаһуга һәм ахирәт көненә ышанып, Коръән өйрәтүе буенча изге гамәлләр кылганнарына ахирәттә газаб куркынычы булмас, һәм алар көенмәсләр" [5:69]. Кайбер тәфсирләр бу аятьне, сүзгә-сүз, тексттан читкә тайпылып шәрехлиләр. Мәсәлән, Коръәнне "ал-Мөнтәхәб" *(сайланма рәвештә)* тәфсирләүдә ул мондый мәгънәгә ия булган: "Аллаһуга

[1] *Фарид Исак.* Быть мусульманином... – С.340.

ышанучыларга, яһүдләрнең һәм төрле нәрсәләргә табынучыларның Мусага ияреп, насараларның Исага ияреп бер Ходайга, Яңадан туу һәм әҗер алу көненә ихластан ышанганнарына һәм Ислам шәригатьләрен үтәп яхшылык кылганнарына газаб булмаячак, ә Яңадан туу көнендә хозурлык булачак".[1] Чынлыкта исә, Коръәндә сүз мөселман булмаганнарга шәригатьне үтәү таләбе турында бармый, анда аларга карата төп таләп—игелек кылу.

> ***"Берәү явыз эш кылса, кылган явызлыгы хәтле генә җәза кылыныр, берәү мөэмин булганы хәлдә кирәк ир булсын, кирәк хатын булсын, гөнаһлардан сакланган хәлдә изге гамәлләр кылса, андый мөэминнәр җәннәткә керерләр, вә анда яхшы ризыклар илә хисапсыз ризыкланырлар" [40:40].***

Ходай өчен тәкъва булу өстенрәк, ләкин катгый таләп түгел. Кешеләргә игелек кылу—Аллаһ Тәгаләнең төгәл күрсәтмәсе, чөнки әйтелгән: "Гамәлсез генә ышанучылардан, вә яһүдләрдән, вә насаралардан һәм төрле нәрсәләргә табынучылардан берәү Аллаһуга иман китереп Коръән, сөннәт дәлилләре белән изге гамәлләр кылса. Андый мөэминнәрнең кылган әҗере Раббылары хозурында, аларга курку һәм кайгы булмас" [2:62].

Барлык диннәр дә яхшылыкка өнди. Яһүд, буддачы, христиан яки башка берәү: "Улым, Ходай хакы өчен игелекле бул",—дип әйтә икән, димәк аның йөрәгендә кешеләрне төрле юллар аша хакыйкатькә илтүче Аллаһ Тәгалә бар дигән сүз.

Ходай бер генә, әмма диннәр төрле һәм аерымлыклар күбрәк йолаларда, гореф-гадәтләрдә күренә. Әйтелгән: "Дин тотучыларның һәр фиркасы өчен шәригать кылдык, һәрберсе үз динен тотар..." [22:67].

Мөхәммәт Пәйгамбәр яңа дин алып килдем дип расламаган. Ул монотеик *(бер аллалы)* традицияне дәвам иткән һәм башка дин вәкилләренә ихтирам уяткан. Ислам бер генә халыкны да кимсетми. Ислам динендә илаһи игелекләр бары тик аның дәвамчыларына гына булачак дигән дәгъва юк. Алар бернинди искәрмәләрсез барлык халыкларга һәм барлык кешеләргә җибәрелгән, чөнки Аллаһ Тәгалә мәрхәмәтле һәм рәхимле. Шуңа күрә Муса Бигиев: "Бәхетсез адәмнәрнең берсе дә бу чиксез мәрхәмәттән мәхрүм булмасын өчен һәм кешеләр алдында Аның чиксез рәхимлегенең киң ачылган капкасы ябылмасын өчен, мин бөтен кешелек коткарылачак дип белдерәм. Әлеге мәсьәләдә минем иманым шул",—дип раслаган. Ул "Ходай рәхмәтенең абсолютлыгы" дигән теорияне эшләгән, бу теория буенча Ходай рәхмәте тормышта нинди динне тотуларына карамастан, Ходай үзе бар иткән бар нәрсәгә кагыла. Әйтелгән: "Һәм әйтерләр: "И-и, Раббыбыз, Синең рәхмәтең, вә Синең белемең һәрнәрсәне сыйдырды..." [40:7]. Әлеге *аятьтән* күренә ки: Ходай мәрхәмәте мөселманнарга гына түгел, һәрбер кешегә насыйп нәрсә. Мәңгелек белән чагыштырганда, безнең гомер бары тик бер генә мизгел. Әгәр дә Аллаһ Тәгалә мөселман булмаганнарның барысын да, ягъни кешелекнең күпчелек өлешен мәңгелек газапка дучар итсә, илаһи нәфрәт илаһи мәрхәмәттән күпкә өстен булып чыгачак.

> ***"Минем мөэмин бәндәләремә әйт: "И-и, бәндәләрем, гөнаһ кылып үзегезгә зарар иткән булсагыз, Аллаһуның рәхмәтеннән өмет өзмәгез, чөнки тәүбә итеп төзәлгәндә, Аллаһ гөнаһларны ярлыкаучыдыр, Ул—Аллаһ ярлыкаучы, вә рәхимледер"[39:53].***

Җәза котылгысыз, ләкин ул мәңгелек түгел. Муса Бигиев раславынча: "җәһәннәм юкка чыгачак", чөнки Ходайның рәхмәте чиксез. Ходай Тәгалә кыска гына фани тормыштагы гөнаһлар өчен кешенең җанын мәңгелек җәзага дучар итә алмый. Муса Бигиев болай дип язган: "Үз рәхмәтенең чиксез дәрьясын күрсәтер өчен һәм аны мәңгеләштерер өчен Аллаһ Тәгалә бар кешеләргә дә уртак рәхмәтен биргән. Аның чикләре юк һәм ул мәңгелеккә калачак. Кешеләрне фани дөньяда ялкаулыктан һәм вакытны бушка сарыф итүдән коткару һәм яман гамәлләрдән тыю өчен белдерелгән аерым рәхмәтне Ул игелек кылган, тәкъва һәм игелекле яшәгән, тирә-юньдәге кешеләргә зыян салудан тыелган һәм камилләшү юлыннан барган кешеләргә бирә".

[1] Аль-Мунтахаб фи Тафсир аль-Кур'ан аль-Карим. – Казань, 2001.

Кешелек, барлык эчке каршылыкларга карамастан, уртак бергәлек—*өммәт* тәшкил итә, анда мөселман һәм башка төрле берлекләр дә, дингә ышанмаучылар да бар. Әгәр алар игелек кылалар икән, Ходайга шулай кирәк дип санап, аларны дошман дип атарга ярамый. Чынлыкта исә бу Коръән *аятьләренең* тирән мәгънәсенә төшенмәгән экстремистларга кирәк. Ходай Тәгалә игелек эшләгән кешене кабул итә. Әгәр дә инде ул шул ук вакытта дин дә тота икән, ул Ходайга тагын да яраклырак.

> ***"Аллаһ—безнең Раббыбыз, һәм сезнең Раббыгыздыр. Безгә—безнең гамәлләребез, сезгә—сезнең гамәлләрегез. Безнең илә сезнең арала хосумәт вә низагъ юктыр. Аллаһ кыямәт көнне барчагызны да бер урынга жыяр, вә ахырда кайтмак Аллаһугадыр, дип"[42:15].***

Ислам Жиргә кешене коллыктан һәм бәйлелектән коткаручы прогресс сыйфатында жибәрелгән, ул—гаделлекнең, рух хөрлегенең, белемгә омтылышның үзе. Ислам сабырлыкка өнди һәм көчләүгә каршы чыга.

Кайчандыр сугышчанлык барлык диннәргә дә хас сыйфат булган. Мөселманнар хәлифәтләрне кылыч тотып төзегәннәр. Европа христианнары тәре походлары оештырганнар. Католиклар һәм протестантлар бер-берсе белән рәхимсез сугышканнар. Ләкин кылыч кынысына салып куелган инде. Безнең дәвердә аны кире чыгаруның кирәге юк, чөнки ул кылыч иясенең үзенә каршы юнәлергә мөмкин. Һәрбер дин яхшылыкка һәм шәфкатькә өнди, кешелекне нәкъ менә шушы хәл бер *өммәт* итә дә инде.

> ***"Китап әһелләре белән низагълашмагыз, мәгәр күркәм юл белән сөйләшегез, әгәр алар нинди юл белән булса да золым итсәләр, ул вакытта аларга катылык кылыгыз, әгәр алар сезнең белән әрепләшсәләр, әйтегез: "Аллаһудан сезгә һәм безгә иңгән китапларның һәммәсенә иман китерегез, сезнең һәм безнең Илаһыбыз бер генә Аллаһдыр, без Ул—Аллаһуга итагать итәбез"[29:46].***

Эзләнүчән һәрбер кешенең хакыйкатькә үз юлы бар. Һәрбер халыкның үз вазифасы бар. Татарлар өчен котылу юлы үткәндә түгел, киләчәктә, безнең прогресска юлны жәдидчеләр салган, алар Пәйгамбәрнең васыятьләрен үтәп, ислам реформасын башлаганнар. Без аны кешелек тудырган хәзинәләргә юнәлеш тотып дәвам итәргә тиеш.

Европа безнең өчен һәрвакыт зирәклек һәм белем чыганагы булды. Ул хәзер дә шулай булып кала. Безнең бурыч—татарларны башка халыклардан аерып торучы киртә төзү дә, ясалма этноконфессиональ резервациягә йомылу да түгел, ә төрле диннәр арасында, исламны төрлечә шәрехләүләр арасында, ислам һәм христианлык арасында күперләр салу. Безнең миссия бар кешелекне уртак төеннәр белән бергә бәйләргә ярдәм итүче үзара аңлашуны жәелдерүдән гыйбарәт.

> ***"Тәхкыйк Аллаһ бер каумгә биргән нигъмәтен үзгәртмәс, хәтта ул каум үз хәлен үзгәрткәнгә чаклы..."[13:11].***

Кешеләр үз тормышларын үзләре үзгәртмәсә, Аллаһ Тәгалә бу тормышта бернәрсәне дә үзгәртми. Пәйгамбәр әйткән: "Үз өстегезгә кулыгыздан килерлек эшләрне генә алыгыз, чөнки сез үзегез алардан туймас борын Аллаһ Тәгалә алардан туймас..." Миннән мөселман йолаларының барысын да үтәүне таләп итәргә кирәкми, мин үз өстемә үземнең көчем житәрлек нәрсәләрне генә—фәннәрне өйрәнүне һәм кешеләргә хакыйкатькә якынаерга булышуны гына алам, ә Пәйгамбәр: "Кем башкаларны өйрәтү максатында күпме булса да фән өйрәнә—шуңа Аллаһ Тәгалә житмеш изгенең котылу чарасын бирер",—дигән. Минем котылу чарам төрле конфессия һәм төрле культура вәкилләренең үзара аңлашуына ярдәм итүдән гыйбарәт. Мин беләм, бу фикер дин әһелләренең күбесенә ошамаячак. Мәгълүм ки, хурлаганда түгел, мактаганда яшәү жиңелрәк. Ләкин әйтелгән: "Эшләрегездә Аллаһ боерганча туры булыгыз!" [11:112].

Шушы фикерләремне язып мин кемнедер гаепләргә, нәрсәнедер инкарь итәргә теләмәдем. Мин бары тик хакыйкатькә юл эзлим. Пәйгамбәребезнең исламны яңарту турындагы сүзләрен тотарга кирәклегендә шигем юк. Бу бүгенге көндә иң мөһиме, чөнки без яңа гасырга аяк бастык.

Мин язганнарны *бидгать* дип атау—иң жиңел эш. Ләкин Пәйгамбәр сүзләрен истә тотарга кирәк: "Үз хаталарыгызны карагыз. Бу сезне башкаларның хаталарын

эзләүдән тыяр. Бервакытта да башка кешеләр эшеннән хата эзләмәгез, чөнки үз хаталарыгыздан арынмас борын башкаларның хатасын күрсәтү—гөнаһ".

> ***"Гыйбадәт кылырга яраклы һичбер зат юк, мәгәр Аллаһ үзе генә, Ул һәрвакыт тере, бөтен нәрсәгә хуҗа булганы хәлдә һәрвакыт бар. Аны ару, талу һәм йокы тотмас, җирдә һәм күкләрдә булган нәрсәләр анныкыдыр. Ахирәттә Аллаһ хозурында кем кемгә шәфәгать кылыр? Юк, шәфәгать кылучы булмас, һичкем үз теләге белән һичкемгә шәфәгать кыла алмас, мәгәр Аллаһ рөхсәте белән генә шәфәгать кылучы булыр. Аллаһ кешеләрнең үткәндәге барча эшләрен һәм алдагы барча эшләрен белер, кешеләр Аллаһ белеменнән һичнәрсәне чолгап ала алмаслар, мәгәр Аллаһ белдергәнне генә белерләр. Аллаһуның бушлык урыны җирне һәм күкләрне сыйдырды, Аллаһуга җирне һәм күкләрне саклау авыр түгел, ул Аллаһ дәрәҗәдә бик бөек һәм бик олугъ. Дингә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар. Ясалма, ялган, батыл диннән Аллаһ төзегән хак дин ачык аерылды."[2:255-256].***

Борынгы заманнарда да, хәзерге тормышта да Аллаһ Тәгалә кешене рухи һәм югары кыйммәтләрне, мәңгелекне һәм игелекне эзләүдә, галәм һәм вакытның чиксезлеген, материя һәм рух катлаулыгын аңларга омтылышында үз ярдәменнән ташламаган. Әгәр дә котылырга телисең икән, яшәүнең мәңгелегенә ышаначаксың. "И-и, каумем, бу дөнья тереклеге тиз бетәчәк, бик аз нәрсәдер, әмма ахирәт исә мәңгегә бетми торган карарланачак яхшы урындыр" [40:39]. Дин кеше җанын югары идеал белән рәттән куя, гадәти игелекләрдән югарырак күтәрә, яхшырак тормышка омтылыш тудыра.

Дингә ышану символы гади сүзләрдән гыйбарәт: "Аллаһтан башка тәнре юк һәм Мөхәммәт—Аның пәйгамбәре". Шушыны әйткән кеше—мөселман. Моны инкарь итүче—динсез, ә кешенең җанын бары тик Аллаһ Тәгалә генә күрә ала һәм кешеләрнең тәкъвалыгына бәя бирергә бары тик аның гына хакы бар.

Үзенә 950 яшь тулгач, Нух, көрсенеп, болай дигән:

—Йә Ходам, гомер шундый кыска! Адәм баласы туарга да өлгерми, инде үләр вакыты җитә!

Без барыбыз да Юлда һәм калган гомеребездә күп яхшылыклар эшләп калырга кирәк.

*Дискуссия: "Безнең заман герое"*

**Рифат Сверигин**

## ЯҢА ЗАМАНА, ЯҢА ГЕРОЙЛАР

"Бар булган гомеремне ил бәхетенә багышладым, кешелекнең якты киләчәге өчен көрәшеп яшәдем" дип горурланучы картлар әйләнә-тирәбездә әле бүген дә очраштыра. Болар—соңгы оптимистлар, элеккеге совет бакчасында житешеп, инде көзге кыраулар төшсә дә, әле коерылырга өлгермәгән соңгы жимешләр. Мин аларга сокланып та, кызганып та карыйм. Хәлләренә керәсе иде аларның... Ул гына да түгел, үзем дә шундыйларның бер вәкиле түгел микән, дигән тыйнаксызрак бер уй да үтеп китте күңелдән. Һәм... шул катламның бер әдәбият сөючесе дип исәпләп, сүз аласы иттем. Бу очракта сүз дигәнебез журнал битләрендә бара торган кызыклы әңгәмәгә катнашуга кайтып калыр ахрысы.

Әлеге катламны күп михнәтләр кичергән, алданган, адаштырылган буын—мескеннәр, бәхетсезләр, дип күрсәтергә яраталар. Татар әдибе бу парадоксның искиткеч төгәл атамасын да тапты—"Бәхетсезләр бәхете" (Ф. Садриев).

Хәзер инде ничек кенә сайрасаң да, дөресендә, гомере буе иленә, ватанына хезмәт иткән буынның бүгенге көндә хәерчелек халәтенә төшерелгәнлеген танымый мөмкин түгел. Алар бүген һәм рухи, һәм жисми яктан фажига кичерәләр. Шушы шартларда да Кеше булып кала алган бу Хикмәтне, ягъни Феноменны ясауга, рәсми вәзгыятьтән тыш, заманында классик реалистик әдәбият һәм совет әдәбияты нык булышканнар иде. Чыннан да, Гоголь, Пушкин, Чехов, Горький, Тукай, Әмирхан, Камаллар әсәрләре белән рухланып: "Кеше—горур янгырый бу исем" дигән олы төшенчәне үзләренең яшәү девизы иткәннәр аз булдыlармыни?!.

Әйе, совет вәзгыяте классик реалистик әдәбиятның кешелекле, ягъни гуманистик карашларын яклап чыкты, дөрес, болар янына аскетлык, гражданлык, дәүләтенә күндәм генә баш иеп яшәү идеяләре дә бик мулдан өсталде. Һәм озакламый, болар бөтенесе кагылгысыз-үзгәрешсез норма-кагыйдә дәрәжәсенә житкерелде. Реаль тормышның үзе белән һич тә тәңгәл килә алмаган, рәсми идеология коралына әверелдерелгән әдәбият арасындагы аерма, ераклык жәмгыятьтәге яңа үзгәрешләр заманында да кимемәде, юкка чыкмады һәм, ниһаять, егерменче гасыр ахырында теге упкынның коточкыч икәнлеген тойган әдип башка жырлар жырлый башлады, элеккеге хакимият һәм цензура басымыннан котылганлыгын төшенгәч, ил, халык, жәмгыять белән бергәләп үткән юлны, аның этапларын һәм геройларын каһәрләргә, тәнкыйтьләргә, көйдерергә керешә... Сүз уңаенда, татар әдәбиятында, бигрәк тә прозасында, бу эшнең бүген дә бик теләп башкарылуын әйтергә кирәк.

Заманалар нык үзгәрде: ил байлыгын тудырган асыл затларга *(болар рәтеннән совет чоры эшчеләре, крестьяннары, хезмәткәрләренең бик күбесен күрсәтеп булыр иде)* дивидентлар тәтемәде, булганнары да, алар өметләнгәнчә, гаделлек кануннары буенча уларына-балаларына, онык-онықчыкларына күчмәде. Тормыш мәйданында елгыр эшкуарлар, житез жилкуарлар, моннан да, тегеннән дә умыра белүчеләр ат уйната башлады, терсәк сугышы белән барын да хәл итеп була торган замана килде... Әлбәттә, бу соңгыларына идеаллар да, геройлар да кирәк түгел. Наданнар һәм

умырып яшәүчеләр тантанасына карап, җүнле адәмнәр өчен ахырзаман житте бугай дигән шомлы уйлар да күңелгә керә башлады.

Тик, барыбер, каһарманнар, кумирлар, ягъни миллионнар табынырдай шәхесләр, күңелләрне сокландыргыч йолдызлар да кирәк бит! Акыллы, менә дигән яшьләребез үсеп килә. Аларныниләр кызыксындыра? Виртуаль кино, телевидение, музыка сәнгатенең яңа техник җайланмалары, электрон чараларның искиткеч алга китеше һәм күптөрлелеге, интернет һ. б.лар яшьләр күңелен көннән-көн күбрәк били бара. Дөресен әйткәндә, матур әдәбият китаплары укып утырырга аларның вакытлары да, теләкләре дә юк.

Ә татар әдәбиятының, аеруча прозасының, үзенең могтәбәр салмаклыгы белән әкрен генә яшәп яткан  көне. Саллы-саллы романнар калын журналларның бер санынннан икенчесенә күчәләр. Карт авторлар, иң зур өлеше инде узган гасырда калган гомерләрен искә төшереп, моңаялар, алардан бераз яшьрәкләре, ягъни тоталитар режим галәмәтләрен татырга-сиземләргә өлгереп кенә калганнары, җыела башлаган ачуларын күптән тәхет-кәнәфиләреннән тәгәрәп төшеп, исемнәре тарих буразналарында аунап ятучы элеккеге түрәләргә юнәлдерәләр, заманында колхоз хәрәкәтендә башлап йөрүчеләрне кансыз җәлладлар итеп күрсәтәләр.

Социалистик реализм әдәбиятында сурәтләү фокусы райком, колхоз, завод житәкчеләрен күтәрүгә, мактауга юнәлтелгән булса, хәзер ул тарих тәгәрмәче астында калып, изелеп йолкынса да, турая алган, якыннары, балалары хакына дип тормышның иң кырыс, иң рәхимсез шартларына җайлаша белгән, шунда да кешелек сыйфатларын саклап кала алган затларга күчерелә. Монысы да әдәбият функциясе—ул изелгән-рәнҗетелгәннәргә миһербанлылык, шәфкать, теләктәшлекне яклаучы. Мәгълүм ки, унтугызынчы гасырда искиткеч камил, шул ук вакытта гади һәм һәркемгә аңлаешлы әдәби чаралар ярдәмендә Н. В. Гоголь, Ф. М. Достоевский тарафыннан укучыга житкерелгән бу караш рус әдәбиятын дөньядагы иң алдынгы әдәбиятлар дәрәҗәсенә күтәргән иде.

Шушы урында без төп мәсьәләгә—әдәбияттагы заман герое мәсьәләсенә якынрак килә алабыз. Кем соң ул бүгенге заманның герое? Һәм, гомумән, әдәбият-сәнгатьтә генә түгел, хәзерге тормышта андый геройлар бармы соң? Әллә алар тарихыбызны героика белән бәйләп караган чорларыбызда югалып калдылармы? Әлбәттә, эзләгәндә аларны тарихтан бүген дә табып була. Тик табу белән генә дә эш бетми бит. Тапкан очракта да, аны әдәби чаралар ярдәмендә укучыга якынайтырга, аны "үзенеке" иттерергә кирәк. Ә рус әдәбиятының Көмеш гасыры дәрәҗәсендә торырдай әсәрләр иҗат итерлек, киң демократик карашлы, үткен һәм оста каләмле акыл ияләребез, әдипләребез кайда? Әллә безгә: "Кая безгә аларны куып житү"? дип һаман да кул кушырып, гасырларга сузылган тыйнаклык рәвешебез белән горурланып утырыргамы?

Күрәсез, яңа якларына орынган саен, мәсьәлә житдиләшә генә бара. Шулай да күңелебезне төшерергә, артык боекланырга кирәкмәс кебек. Милли әдәбиятыбызда да кыю авторлар, үз-үзләренә таләпчәнлекне беркадәр арттыра төшкәндә һәм аларны күрсәтә һәм яклый белгәндә, зур биеклекләр яуларлык гаярь егетләребез бар. Мәсәлән, әле генә илле яшен тутырган Вахит Имамов "Тозлы яра" исемле романы белән укучыга зур яңалык китерде. Әсәрдәге геройлар—тормыштагы катлаулы борылыш чоры кешеләре, ә төп геройның прототибы—Әмир Нәгыймов—авторның үз бабасы һәм, аңа карата унай мөнәсәбәт үзеннән-үзе аңлашыла булса кирәк.

Әмма әдипнең төп максаты шәҗәрә барлау яисә узган гомерләрне искә төшереп, күңелләрне кузгатып алу түгел. Герой, барыннан да бигрәк, әр-яңа иҗтимагый яссылыкта, реаль тормышчанлыгында һәм тарихи җирлектә ачыла. Вахит Имамов бер үк дәрәҗәдә әдәбиятчы да, тарихчы да. Аның художестволы иҗаты да халкыбызның тарихын дөрес яктыртуга нигезләнә, һәм, әйтергә кирәк, болар барысы да хакыйкатьне, гаделлекне табу һәм раслау максатында башкарыла.

Әмирҗаннар фаҗигасенең бер башлангычы—андыйларның гел кешелекле булып калырга тырышуларында. Алар бу дөньяда һәр нәрсә кешеләрне кайгыртуга юнәлгән, башкаларга җил-яңгыр тидермәслек итеп, кушканны карусыз үтәп, тәртипле, итагатьле, намуслы яшәеш кенә була ала, дигән карашка инанып, күңегеп беткәннәр. Әмма көчләү һәм буйсындырылуга корылган системаның Әмир Нәгыймов кебекләрнең уйларында, карашларында һәм, гомумән, гади халык язмышында эше юк. Ул алар белән исәпләшеп тә тормый. Система җәмгыятьнең "бәхетле киләчәгенә" таба миллионнарны мәҗбүр итеп алып бара. Әмир дә шушы "изге эшне"

башкаручылар рәтенә басып, авылдашларын "якты киләчәк"кә юнәлдерергә тиеш була. Тик ул якташларының бүгенге яшәеше, бүгенге хәлләре хакында да уйламый, борчылмый, кайгыртмый булдыра алмый. Ә система бүтән карашта: янәсе, бәхетле ерак киләчәккә фәкать бүгенге корбаннар бәрабәренә генә барып була. Әнә шулай, бу әсәрдә кешелекнең бүгенгесе белән киләчәге үзара каршылыкка керәләр. Герой каршына да альтернатива, ягъни сайлап алу мәсьәләсе килеп баса. Нәкъ әкияттәге юл чаты кебек: хакимиятне тыңласаң, авылдашларың кыерсытыла, авылдашларыңны кайгыртсаң, үзеңне хакимият җәзалый. Фаҗига котылгысыз—ул сина ике яктан да яный—чөнки тоталитарлык җәмгыятендә ике нәрсә—кешечә яшәү омтылышы һәм хакимият максатлары бер яссылыкта һич тә тыныша алмыйлар.

"Тозлы яра" романында шушы хакыйкать эзлекле тәртиптә һәм ышандырып күрсәтелә, исбат ителә. Әмир Нәгыймовлар—кешелексез режимның телсез корбаннары—алар ике тегермән ташы арасындагы бөртек яисә тимерче сандалы белән чүкече астында калган бер җисем шикелле ләр. Әнә шундыйларны—язмыш ике яктан китереп кыскач, җәберләнеп, газиз гомерләре вакытсыз өзелгәннәрне дә, ягъни шуларның образларын заман геройлары дип санарга мөмкинме? Безнең карашыбызча, алар—явызлыкка, тираниянең нык уйланылган машинасы, системасы белән көрәшкә күтәрелердәй хәлдә булмасалар да, үзләре шул тираниянең винтикларына әвереллдерелгән бу карусыз шәһитләр—дәһшәтле һәм канлы егерменче гасырның иң фаҗигале геройлары һәм алар дөньяда хакимлеккә дәгъва иткән илләрдә меңнәрләп кенә түгел, миллионлап исәпләнәләр. Шушы мәгънәдә, без язучы Вахит Имамовның Әмирен зур гомумиләштерү көченә ия булган тирән мәгънәле типик герой дип бәяли алабыз.

Ачы язмышлардан сабак алып, кешелек дөньясы ялгышларны кабатламаска тиеш иде дә бит... Әмма... Әмма... "Аяныч нәрсә бар: тарих кабатлана диләр. Йөрәккә шом сала торган сүзләр бу... Әйе... Бүген татар әдибе үзенең төп бурычларының берсе итеп халкыбыз, аерым кешеләр кичергән гыйбрәтле хәлләр хакында язуны саный. Бу—аның намус эше, бурычы. Бар курыкканым—тарихның кабатланырга сәләтле булуы. Татарга кабатланган тарих, югалткан дәүләтчелеген дә, ирек кояшын да алып килмәс шул инде, бәла-казалар гына өеп китерер кебек..."

Әлеге юлларны "Саташып аткан таң" романының авторы Факил Сафин язган. Өч өлештән торган бу зур әсәр—әдипнең ун елга сузылган эзләнүләре нәтиҗәсе. Эше барышында ул шактый каршылыклы уй-хисләр өермәсе эчендә дә калгалаган икән: "Аңнарлармы мине укучылар? Без тиз онытырга күнектерелгән халык бит. Хәтерсез халык—хәтәр халык, хәтерсез кавем—мескен кавем... "Ул елларны кат-кат искә төшерү ник кирәк?"— дип чәчрәп чыгучылар да булгалап тора" дип яза ул.

Әмма халык язмышындагы фаҗига беркайчан да искерми шул. Автор "үткәннәрне искә төшереп, киләчәкне искәртеп куярлык" (Туфан Миңнуллин сүзләре) яхшы әсәрен уңышлы гына тәмамлап чыга алган. Монда да яшьтән инкыйлап өермәсе үзенә ияртеп киткән, шул чор идеяләре белән адарынып, "яңа тормыш төзибез, бар халыкны бәхетле тормышка чыгарабыз" дип ялкынланып-янып йөргән Әхмәтсафа Дәүләтъяров, инкыйлап үзе үк барлыкка китергән репрессия тегермәне астында калып уала, һәлак була.

Мәгълүм ки, совет чорында, бигрәк тә шәхес культы хөкем сөргән елларда кеше хокукларының бозылуы яисә бөтенләй юкка чыгуы турында узып киткән гасырның алтмышынчы-сиксәненче елларында бик күп язылды: Варлам Шаламов, Анатолий Рыбаков, Василий Гроссман, Александр Солженицын һ. б. ш. әсәрләренең, "Тәүбә" кинофильмының тәнкыйди рухы милли әдәбиятка да күчеп, "Тайгак кичү" (Ибраһим Салахов), "Афәт" (Гурий Тавлин), "Каргышлы этаплар" (Рәфкать Кәрами), "Йөгез, бер дога" (Аяз Гыйлаҗев) кебек әсәрләр аша күңелләрне тетрәндереп, айкап узган иде. Ринат Мөхәммәдиевнең "Сират күпере" романында исә әлеге тема күренекле тарихи шәхес—Мирсәет Солтангалиевнең фаҗигале көрәше рәвешендә документаль җирлектә яктыртылды.

Инде егерме беренче гасырга кергәндә, шушы типтарак эшләнгән тагын бер әсәр—Факил Сафинның "Саташып аткан таң" романы барлыкка килде. Бу әсәр композицион төзелешенең җентекләп уйланылган төзеклеге, үзәккә куелган характерның документаль тормышчанлыгы һәм сюжетының фаҗигалелеге белән дә күңелне җәлеп итә. Гомеренең иң соңгы минутларына кадәр гаделлекнең җиңәчәгенә өметен һәм кешелек сыйфатларын җуймаган олы шәхес—Әхмәтсафа Дәүләтъяровка аеруча җылы теләктәшлек мөнәсәбәте бик ачык сизелеп тора.

Татарстанның халык комиссарлары советы житәкчесе дәрәжәсенә күтәрелгән бу олы затның язмышын сурәтләгәндә әдип үзенең сәнгатьчә уйлап чыгару сәләтенә дә, тарихи фактларның дөреслегенә дә бер үк дәрәжәдә таянып эш итә. Болар янына укучы күңеленә тәэсир итүнең эмоциональ чараларын зәвык һәм чама хисен үлчәп-исәпләп бирелүен дә кушкач, романның укучыларның күпчелеге тарафыннан җылы кабул ителәчәгенә шик калмый.

Бер яктан халыкның тормыш-яшәү дәрәжәсе, шәхеснең җәмгыятьтәге урыны һәм икенче яктан иҗтимагый тәртипләренең гаделсезлегеннән разый булмау егерменче йөз башы татар әдәбиятында, прогрессив язучылар иҗатында ачык чагылган иде. Бу конфликт шәхес һәм социаль тирәлек, шәхес һәм җәмгыять арасындагы мөнәсәбәтләргә дә күчте. Йөз елдан соң әлеге көрәш янадан кабатлана. Әмма башка күләмнәрдә, башка масштабларда. Тик фарс халәтенә генә төшмәскә иде... Интеллигенциянең бу могтәбәр вәкиленә караш-мөнәсәбәт бүген Пушкиннар, Толстойлар, Горькийлар, Фадеевлар, Такташлар, Җәлилләр заманындагыдан бик кайтыш—аның үз авторитеты-абруе да бик әлләкем түгел. Хәзерге этапта югарыда санап үткәннәргә тиңләшерлек асыл затлар барлыкка да килә алмый торганнардыр, чөнки җәмгыять укымышлыларга һәм талантлыларга зур ихтыяҗ да, кирәксенү дә тоймый. Монысы инде җәмгыятьнең чирле икәнлеген раслаучы шактый шомлы дәлил.

Элеккеге Россиядә капитализм, һәм бераз соңрак, социализм шартларында хөкемдарлар әдәбият-сәнгать чараларының халыкка тәэсир итү көченең зур булуын яхшы аңлаганнар: әдип-художникларны ничек тә үз якларына тартырга, үз идеологияләренә хезмәт иттерергә тырышканнар. Бүген исә иҗатчылар хезмәтенә салкын мөнәсәбәт, битарафлылык иҗатчыларны һәртөрле дотацияләрдән, дәүләт ярдәменнән мәхрүм итү—зур һәм төзәтә алмаслык хата.

Бүгенге художник, әлбәттә, хакимият басымыннан азат—ул аның кулына карап түгел, ә халыкка, укучыларына, тамашачыларына карап иҗат итә. Димәк, иң алгы планга халык ихтыяҗлары, халык таләпләре мәсьәләсе килеп баса. Монда халыкның югары зәвыклы булуы да бик әһәмиятле—һәм моңа омтылу әдәбият-сәнгать әһелләренең изге бурычларының берсе дип элек-электән саналып килде. Ә гамәлдә без нәрсә күрәбез?

Бүген ил күләмендә әдәбият-сәнгать белән алыш-биреше булмаган, әмма шуна охшатылган, якынайтылган бик күп төрле чаралар аша ("сары" матбугат, суррогат "әдәбият", шоу-кичәләр) укучыны, тамашачыны зәвыгыннан яздыру өчен бик күп эшләнә. Ягъни халыкны зәвыксызландыру сәясәте үткәрелә—электрон каналлар аша аңа сугыш, үтереш, суеш, авыз-борын җимерү, көчләү, әхлаксызлык, тотнаксызлык, порнография күренешләрен күпләп күрсәтеп, боларның барысы да гадәти хәл дип кабул итүгә күнектерәләр.

Ә зәвыксызлар өчен чын әдәбият, югары сәнгать дигән нәрсәләрнең бөтенләй кирәге дә калмый. Тик бер генә таләпләре бар аларның авторларга: безне башка дөньяга алып китегез, көндәлек тормыш мәшәкатьләреннән арындырыгыз, уйлатмагыз, көлдерегез дә ял иттерегез... Һәм авторларыбыз шуларга бик тә ярарга тырышалар... Шулай булгач, кем кем артыннан бара соң? Кем кемне тәрбияли?

Инде саннары азаюга йөз тоткан югары сыйфатлы әсәрләр иҗат итүчеләргә килсәк, алар бүген тәрбия фронтының иң соңгы позицияләрен саклап, чигенүче солдатлар кебек арьергард сугышлары алып барырга гына дучар ителгәннәр. Күрәбез ки, монысының элеккеге гуманистик әдәбиятка хас булганча, алгы сызыкка басып, яхшылык, гаделлек өчен көрәшкә чакыру яисә көрәшү идеаллары белән әлләни уртаклыгы юк. Бүген безне ике генә нәрсә борчый: канлы тарих янадан кабатланмасын да, милләт инкыйразын ничек тә кичектерәсе иде...

Ә сез геройлар дисез!? Юк, бүген без, әдәбиятчылар, әлегә, ышыккарак барып, яраларны ялаштырып, ямаштырып ятучылар хәлендә...

"...Яраларны ямаштырып ята идем далада..." (Х. Туфан)

"Кайт!" дип язган хатлар да юлга чыкмаган әле...

Шулай да актык өметләребезне өзеп үк бетермәскә иде. Тагын шул прозабызга әйләнеп кайтыйк. Бу өлкәдә бик тә эзлекле эшләп, нәкъ үз сүзен әйтергә теләүче һәм әйтә дә белүче әдипләребез алай да бар әле. Язучы Тәлгат Галиуллин яшәешебезнең кайсы якка табан кыйшаюын, көнкүреш нормалары-тәртипләренең кай тарафларга авышуын, шуларның эчке механизмын бөтен нечкәлекләрендә тоя һәм бу турыда гыйбрәтле, мавыктыргыч, тәэсирле итеп яза да белә. Ул әле генә

криминаль дөньяның күп серләрен ачкан трилогиясен тәмамлады ("Тәүбә", "Элмәк", "Төнге юллар").

Адәм баласы якты дөньяга җинаятьче булып тумый. Әмма әйләнә-тирәбездә аны бозык, тайгак юлга алып керердәй күренешләр тулып ята. Башка шартларда кеше булып китәрдәйләр дә җинаять җәтмәләренә уралып, йә кешелек сыйфатларын югалтып бетерәләр, яисә үзләрен якты дөньядан мәхрүм итәләр. Бу әсәрләрдә дә адәм баласы чыга алмаслык капкыннар тозагында кала. Җинаятьчелек даирәсенең серләрен, тәртипләрен яхшы белеп, күпләрне үз көенә биетеп, аларның көчле һәм зәгыйфь якларыннан оста файдаланучы Сәет Сакманов та киллер пулясыннан дөнья куя. Кыек, төнге юлларда йөрүчеләрнең һәммәсе дә, иртәме-соңмы хәйләкәр исәп-планнары чәлпәрәмә килгәч, ярык тагарак алдында утырып калалар. Мәңгелек табигатьнең мәһабәт бөеклелеге каршында кешеләрнең алдашуга корылган ыгы-зыгылары мәгънәсез, кирәксез һәм буш булып тоела:

"Сирәк болытлар аша шадра күренгән ай җир балаларының кыланышларына исе-акылы китеп, күктә йөзүен дәвам итә. Айга ни, ул—мәңгелек, ә нәзберек күбәләктәй адәм балаларына гомер бер генә бирелә, азгынланып, явызланып, гөнаһлы пычракка батып, шул кыска тормышларын матур итеп уздыра да белмиләр. Адәм телен белсә, ай кинәшләрен бирер иде дә, нурга коендырудан үзгә һөнәре юк шул аның".

Башлыча реаль, рациональ һәм төгәл тасвир тарафдары Тәлгат Галиуллинның зур әдәби хезмәте аның әнә шундый лирик-фәлсәфи, хәтта кайберәүләр әйтмешли, экзистенциаль рухына тиешле нокта куючы аккорд белән тәмамлана. Шулай итеп, бу трилогиядә адәм баласының барыр юлларындагы тагын бер тупигы ягъни, килеп терәлгән, чыга алмаслык почмагы күрсәтелә.

Әлбәттә, һәр даирә, һәр төркемнең, һәр катламның үз каһарманнары яисә шуңа дәгъва итүчеләре була. Әдәбият дөньясында андыйларны да заман геройлары дип атарга мөмкинме икән соң? Заманасы шундый булгач, мөмкиндер, мөгаен. Тик әле без караган очракта мондый персонажларга мөрәҗәгать итү герой проблемасын чишәргә омтылудан бигрәк, нигездә иҗтимагый яшәеш халәтен, заман сурәтен, төсмерләрен, билгеләрен ачу, күрсәтү функциясен башкара булса кирәк. Анысы да бик кирәкле әйбер...

Ни өчендер, Тәлгат Галиуллин әсәрләре белән танышканда үзем шәхсән сәеррәк, уңайсызрак тойгылар эчендә калгалыйм. Бу икейөзлелек, алдашу, эгоистлык күренешләреннән туеп бетәм, китапны бер якка ыргытып, тизрәк яктырак, сафрак дөньяга чыгып китәсе килә башлый. Юк шул. Котылып булмый. Китап битләрендә генә түгел, чынбарлыкта да шулай икән бит. Кая таба тәгәри бу җәмгыять? Тәлгат Галиуллинның әсәре әнә шул бозыклыкны, чиреклекне күзләребезгә төртеп күрсәтеп кисәтүе белән дә әһәмиятле.

Бу авторның иҗат мөмкинлекләре һич тә детектив, маҗаралы, криминаль романнар кысаларына гына сыймаганлыгы яхшы билгеле. Тема, жанр кысаларының, мәйданның тарлыгын язучы үзе дә тоя. Менә шуңа күрә дә әсәрдә урыны-урыны белән сүз уйнатуга корылган гаҗәеп эпизодлар, лирик яисә фәлсәфи гомумиләштерүләр, юморга бай гыйбарәләр балкып ала. Әмма әдип күңеленә дә хуш килгән мондый мизгелләрдә ул озак юанып тора алмый, жанр таләпләренә буйсынып, янадан детективлык сукмакларына кереп китәргә мәҗбүр була.

Мәкаләбезнең бу төшендә без тирән фикерле һәм сәләтле прозаигыбызның амплуасы маҗаралылык белән генә чикләнмәвенә ишарә ясарга һәм алга таба аның таланты прозаның башка өлкәләрендә дә тиз арада ачылачагына өметебез һәм ышанычыбыз зур икәнлеген дә искәртеп үтәргә теләдек.

Мәгълүм ки, галәмдә кеше яралганнан бирле аның җаны, аның күңеле дигән мәйданда бер яктан золым, явызлык һәм икенче яктан яхшылык, игелеклелек арасында аяусыз көрәш бара. Бу мәңгелек бәхәс, мәңгелек бәрелеш әле Чынның, әле Ялганның вакытлыча җиңүенә китерә. Көрәш сүнми дә, тукталмый да. Тик Тукайлар заманында да, безгә мәгълүм чорларда да Ялганның күбрәк тантана итүен күреп, күңелләр әрни. Бу хәл хәзерге әдипләр күңелен дә сызлата. Шагыйрьләр, драматурглар турында әйтеп тә торасы юк (алар турында башкалар язарлар әле), прозаикларыбыз да гаделсезлек күренешләренә һич тә битараф түгелләр. Миргазиян Юныс, Зәки Зәйнуллин, Айдар Хәлим, Рабит Батулла, Фәүзия Бәйрәмова, Вахит Имамов, Факил Сафин иҗатларында милләтпәрвәр рухлы персонажлар байтак очрый. Кеше күңеле өчен көрәш эпизодлары Мәдинә Маликова ("Алтын ятьмә"),

Нәбирә Гыйматдинова ("Икебезгә дә авыр"), Зиннур Хөснияр ("Терсәк сугышы"), Азат Вергазов ("Йөрәк жыр сорый") кебек язучылар ижатында да чагылып үтә. Исемлек тулы түгел. Болары—әлегә күземә ташланганнары гына.

Теләк-дәгъваларыбыз да бар. Бәлки прозаик-әдипләргә инде замана сукмакларында адашып, тилмереп йөрүчеләрне сурәтләүдән арынып, көчле рухлы, яхшылыкка таба әйдәп баручы геройлар турында яза башларга вакыт килеп житкәндер? Вәзгыятебезнең бүгенге халәтендә мескеннәрне кызганудан, адашканнарны яклаудан да бигрәк актив, көчле герой концепциясе кирәгрәк иканлеген әдипләр үзләре дә анларга тиешләр. Үз халәтебезгә сукранып, зарланып, "йоклаганбызмы, үлгәнбезме?" дип утырыр чаклар узган бит инде...

Укучы яхшы хәтерли торгандыр: үз вакытында совет әдәбияты хезмәт каһарманнарына дан жырлау, ил, халык мәнфәгатьләренә багышланган хезмәтне олылау белән нык шөгыльләнде. Хәзер ни өчендер бу тема ижатчылар өчен кызыксызга әверелде, хәтта аны көн тәртибеннән бөтенләй төшерделәр ук шикелле... Юк, ялгышканбыз—реалистик традицияләрдән көч һәм дәрман алып, әдәбиятта үз ижат стилен, үз юнәлешен эзләүче әдипләрнең китапларына гына мөрәжәгать итәсе икән. Камил Кәримов әсәрләре безне аеруча шатландырды—"Ком сәгате" һәм "Сакау күке" романнарыннан торган дилогиясен күздә тотабыз.

Бу әсәрләрнең түрендә нәкъ менә үз профессияләренә мөкиббәннәр, тормышның бөтен матурлыгын, ямен фәкать үз һөнәрләрендә генә таба алучылар утыра. Болар—жир катламнарын тишеп, бораулап, артезиан коелары ясап, халыкка чиста, саф, тәмле су эчертүчеләр. Әдәби сүзнең, телнең, жөмлә, фразаларның яңгырашына гаять сизгер Камил Кәримов теманың колачы, тормыш материалының әһәмиятеннән тыш сүзнең ассоциатив күпмәгънәлелеге, символ төсмерләренә байлыгы кебек мәсьәләләрне дә истән чыгармый. Сунын чисталыгы, мөнәсәбәтләрнең гүзәллеге, әхлакый сафлык—бу янәшәлекләр әсәрнең идея-эстетик үйланышында һәм эшләнешендә нык сизелә, һәм автор, әсәр барышында әнә шул гүзәллек тойгысын даими һәм тигез саклый, бар бөтенлегендә һәм камиллегендә сурәтли алган.

Әсәр үзәгендә торучы Фазыл образында заманыбыз героеның, дөресрәге, кешесенең бик күп характер билгеләре һәм сыйфатлары чагылып уза. Күпләр биредә үзләрен, үз хәлләрен, көнкүрешләрен дә танып алырлар, мөгаен. Таркалган гаиләләр, йорт-жирсез көн итүләр, эш урынында кагу-суккалаулар—әйтегез, боларны кемнәр кичермәгән дә, кемнәр башыннан узмаган мондый хәлләр?!.. Халкыбызның күркәм бер сыйфаты—аны эт типкесенә калдырсалар да, беркайчан да күңелен төшермәс, үз жаен үзе көйләп, ситуациянең ниндилегенә карамыйча, тормышның кайсы да булса, бер ягыннан ямь-тәм табып, һәрбер яңа туган көнгә куанып яши бирер!

Фазыл да шундыйлар токымыннан. Аның иң гүзәл сыйфатларының берсе—үз һөнәренә—артезианчылыкка бирелгәнлеге. Кое бораулаучылардан калган тәгәрмәчле вагоны барында Фазыл югала торган кеше түгел. Әкәм-төкәм кабырчыгын хәтерләтүче шушы оясында ул гомер буе рәхәтләнеп яши алыр төсле. Ул биредә үзен хужаларча иркен һәм ирекле хис итә. Бу символик һәм шул ук вакытта тормышның үзеннән алынган сурәтне әдипнең уңышлы бер табышы дип билгеләргә мөмкин булыр иде. Әмма әсәр белән якыннанрак танышканда мондый мәгънәле бизәк-сурәтләргә шактый еш юлыга башлагач, татар прозасында кабатланмас яңа бер стиль барлыкка килгәнен күреп сөенәсең.

Камил Кәримов сюжет вакыйгалары артыннан куып, бар булганын рәткә тезеп, кабаланучылардан түгел. Ул һәр эпизод, һәр күренешнең, ситуацияләрнең оригиналь, кабатланмас сурәтен таушалмаган жөмләләр, ачык буяулар белән сурәтләргә ярата. Әсәрләрендә кат-кат кайтып, әйләнеп укырлык сәхифәләр, сурәтле картиналар очрап тора. Кайберәүләргә алда китереләчәк чагыштыруым бәлки артык купшы, бөек һәм пафослы булып тоелыр—әмма мин соклануымны яшерә алмыйм: безнең Камилебез дөнья һәм рус әдәбиятындагы күренекле сүз осталары Ярослав Гашек, Илья Ильяф, Евгений Петров, Юрий Олеша, Исаак Бабель, Андрей Платоновлар сызган юллардан атларга омтыла. Бу, әлбәттә, әлеге авторыбыз шул шәхесләр дәрәжәсенә инде күтәрелеп житте, дигән сүз үк булмаса да, тәэсирле сурәт төзү алымнарында, жөмлә-фразаларның рельефлы, калку, үтемле сурәтлелегендә, нечкә, нәзакәтле юмор үрнәкләрендә ниндидер уртаклыкны сизми мөмкин түгел.

Чыннан да, "һәр чагыштыру аксый" дигән акыллы гыйбарәне дә истән чыгарырга ярамый торгандыр, тик әдәбиятны аңлаучылар мәгълүм шартлылыкка да юл куючан

булалар. Ярый, алай булса, күз житмәс биеклекләрдән аз гына түбәнрәк төшкәндәй итик. Хәзер ике авторның әсәрләреннән ике өзек китерәбез—игътибарлы укучы алар арасындагы бәйләнешне, якынлыкны бәлки үзе үк чамалар:

"Авыл кышка әзерләнде. Язгы сулар идән астына төшмәсен өчен өй тирәли казыла торган ерганакларны тирәнәйтеп, урам ягындагы базларны томалап, абзар коймасы белән кәрниз арасындагы ярыкларга абага тутырып, туфраксаларга балчык өстәп, яна өйләрдә икенче кат тәрәзәләр куеп, искеләрендә рам араларын сылап, халык үзеннән-үзе әкрен генә кышка кереп бара иде. Өлкәннәрнең төрле ырымнарга карап, гел раштуа суыкларыннан гына торган кырыс кыш вәгъдә итүе елдан-ел кабатланса да, авыл әзерлек чараларын киметми, кар яуганчы ук итекләр бастыра, озын балтырлы йон оеклар бәйли, затлы шәлләр өчен Ырымбур кәҗәләреннән таралган мамык эрли".

Һәм тагын бер өзек:

"Кышның беренче ае терлекләрне тинтерәтә торган салкын жилләре, явымсыз-чәчемсез кырыс болытлары белән крестьянны тәмам аптыратып узганнан соң, январь башыннан кинәт карлы-буранлы, сулышка жинел һәм күзнең явын ала торган йомшак кыш керде. Чана юллары тәмам утырды, кешеләр барасы жирләренә гамьсез чыгып китә башладылар".

Тормышның рәтен белеп, халык тәжрибәсен үз акылына кушып көн итүче татар крестиәненең холкы-карашыннан язылган мондый охшаш сурәт-картиналардан замандашыбыз Камил Кәримовның кем традицияләренә табынуын, яки, һич булмаса, кем эзеннән атларга тырышуын тиз шәйләп була торгандыр. Өзекләрнең беренчесе—аның үзенең "Сакау күке" әсәреннән алынган булса, икенчесе мәшһүр әдип Фатих Хөснинең "Утызынчы ел" романыннан китерелде.

Әлбәттә, биредә сүз турыдан-туры иярү яисә бер-береңне кабатлау хакында бармый. Шулай ук, охшашлыкны аерым алымнар, язу үзенчәлекләренә генә дә кайтарып булмый торгандыр. Мәсьәләнең үзәге—геройлар сайланышында, хәтта милли геройның характерында дисән дә була. Кайчагында беркатлылык кебек тоелган гадилек, эш-хезмәт дип жан ату, башкалар мәнфәгатен дә, үзеңнекен дә истән чыгармау, булдыра алганча, ил-көн каршында абруй саклап, гаилә иминлеге, тигезлеге дип тырышкан булу—мондый сыйфатлар бу ике язучының төп геройларын бер-беренә шактый якынлаштыра. Һәм, әлбәттә, китерелгән текстлардан күренгәнчә, бигрәк тә хужалык мәсьәләләрендә алдан хәстәрлек, табигать-ананың жаеннан торып, анысының капризларына да көйләнеп, Нужа бабайның теләсә нинди кискен кыланышлары каршында да югалып калмыйча, бары үзен дөрес дип тапкан сәясәтенә тугрылык саклау—күркәмлекләреннән бигрәк, халкыбызны гасырлар аша исән-имин үтәргә ярдәм иткән һәм бүгенге көнгә китереп житкергән, аны саклап калган сыйфатлар иде. Әмма мондый рухи ныклыкка һәм гармониягә һәркем ирешә алмый шул. Шул исәптән Фатих Хөсни һәм Камил Кәримов әсәрләрендәге конкрет геройлар да. Тормыш, язмыш дигәннәрен гел алар уйлаганча гына бармый. Һәртөрле язылган һәм язылмаган тәртипләр, әйләнә-тирәдәге хәлләрнең тискәре йогынтысы, язмыш мажаралары аларны төрлечә талкый, тукмый һәм... ахыр чиктә адәм баласы ялгыша, егыла, сына. Азмы-күпме булган өметләр, идеалларын, сызган планнар һәм тормышындагы тигезлек, гармония юкка чыга. Мондый фажигаләр хакында язарга да әдипләрнең тулы хокуклары бар...

Әнә шул рәвешчә, без фараз иткән уртаклыкны, ике чорның ике әдибенең ижатларында шактый ачык итеп күреп була икән. Үзара уртаклыкны Фатих Хөснинең дә, Камил Кәримовның да реалистик детальләргә үтә дә игътибарлы мөнәсәбәтләрендә, халкыбызның тел жәүһәрләрен, байлыгын кадерли, хөрмәтли белүләрендә, жанлы юмор, жор күңеллелекне яшәү-көнкүрешнең жанлы өлеше итеп санауларында да табарга мөмкин. Шөкер, шушында без татар реалистик прозасының бер юнәлеше генә булса да, ышанычлы кулларга күчеп баруын күреп, сөенә алабыз.

Ә инде проза дингезебезнең башка төпкелләрендәге казанышларны—Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал, Фатих Әмирхан, Әмирхан Еники, Рафаил Төхфәтуллин, Әхсән Баянов, Мөхәммәт Мәһдиев, Айдар Хәлим кебек мөхтәрәм әдипләрнең стильләре рухындагы гүзәл әсәрләрне дә кадерләп, үз матурлыкларында өйрәнергә, бәяләргә, аларны милләтебез рәвеше-яшәешенә чит-ят булган һәртөрле агымнар белән буташтырмыйча, шулар халәтенә төшермичә, әрәм-шәрәм итеп бетермәскә иде.

Безнең инануыбызча, татар әдәбиятынын, аерым алганда, әле генә тәмамланган гасырның икенче яртысында ирешелгән казанышлары тарихта үз урыны, үз вакыты булган ирреалистик импрессионизм, экспресионизм, экзистенциализм, неореализм кебек агымнар белән бәйләнмәгәннәр, ә милли реалистик күренешләр җирлегендә үсеп чыкканнар. Дөнья әдәбиятындагы саташу, сызлану, эшсезлектән һәм үз-үзенне кая куярга белмичә, гел илаһи серлелеккә омтылып, тормышның үз хакыйкатеннән һәм реальлегеннән ваз кичкән хыялый геройлар җиргә береккән татар укучысын бүгенге көндә кызыксындыра да, шатландыра да алмыйлар. Ничек кенә булмасын, реалистик нигезендәге әдәбият заман укучысы өчен якынрак булып кала бирә, һәм бу әдәбиятның да үз яңалыклары, үз ачышлары, үз табышлары бар, тик аларның исемнәрен, атамаларын, категорияләрен әллә каян читтән түгел, ә милли әдәбият-сәнгатьнең үз җирлегеннән табасы иде. Шулай ук бу урында мөгътәбәр әдәбият белгечләренең кайбер хезмәтләрендә авангардизм әсәрләрен әдәбиятның гел гүзәл казанышлары рәвешендә тәкъдим итү, күнелдә, ким дигәндә, гаҗәпләнү һәм сәерсенү уята.

Шуның белән бергә, бүгенге заманда әдәбиятыбызда модернистик рухтагы әсәрләр туа алмый, дисәк, без дә хаклы булмас идек. Заманалар болганган чакларда адәм баласы авырлыктан, михнәтләрдән котылу, чыгу юллары эзләп, мистикага, илаһилык, сихерчелек галәмәтләренә килеп сыена, газиз җанын тынычландырырлык кайбер факторларны шулардан эзләп тапмакчы була. Мәсәлән, язучы Зөлфәт Хәким "Гөнаһ" дип исемләнгән романында "зур җинаять кылдым, дустымның һәм гаепсез кешенең үлемнәренә сәбәпче булдым", дип гомер буе гасабиле, үкенечле уйлар эчендә интеккән героеның эчке халәтен, күнел тыпырчынуларын дөнья әдәбиятында киң таралган экзистенциализм дип йөртелүче агымга хас алымнар,—кабатланучан эчке монологлар, кайтып-кайтып искә төшерүләр, сюжетның үзенчәлекле корылышы ярдәмендә уңышлы хәл иткән. Шул ук авторның "Курку" исемле повесте да шушы тезисны раслап тора.

Язучы Әхәт Гаффар да күп еллар дәвамында модернизм юнәлешендә кызыклы эзләнүләр алып бара. Аның "Язлар моңы" драмасы, "Олы юлның тузаны", "Бодай бөртеге һәм тегермән ташы", "Богау" романнары, хикәяләре һаман да ирреалистик әдәбиятның нечкә төсмерләрен аңлый һәм аңлата-анализлый белүче әдәбият белгечләренең игътибарын көтә. Андый белгечләр бездә бар. Мәсәлән, әле күптән түгел генә шушы юнәлештә актив эшләүче галимәләребездән Дания Заһидуллина мистика һәм мифология элементлары катнаштырып язылган бер әсәргә—Галимҗан Гыйльмановның "Албастылар" исемле яңа повестена—журнал битләрендә шактый этрафлы, кызыклы анализ ясаган иде.

Шунысын да әйтергә кирәк, модернизм күренешләрен бәяләүгә, яна модага санап кына, аның асылына, философиясенә төшенеп җитмичә, алынырга ашыкмаска кирәк. Моны әнә шундый, сәләтле, вәкаләтле белгечләр генә эшли ала. Гомумән, тышкы бизәкләр, очраклы детальләр, элементлар буенча гына һәртөрле агымнарның әдәби процесстагы әһәмиятен, урынын объектив бәяләү, билгеләү мөмкин түгел. Мәсәлән, Марат Әмирхановның "Тояк эзе" исемле яңа романында төп геройның саташулы һәм юрасаң юш килә торган төшләре бирелгән икән—бу факт үзе генә әлеге роман авторының реалистик прозадан читләшүе хакында сөйләми. Бу—очраклы бер бизәк кенә. Ягъни стиль, метод, агым кебек катлаулы категорияләргә әсәрнең яисә әсәрләрнең барлык параметрларын искә алып, комплекслы анализ ярдәмендә генә якынлашып һәм аларга дөрес бәя биреп була икән.

Шулай да бүген безне тикшеренү—өйрәнүнең юнәлешләре, ракурсларыннан да бигрәк, әдәби процесска илтифатсызлык, битарафлык борчый. Нәтиҗәдә бик күп иҗади ачышларны, аларның кыйммәтен, әһәмиятен әдәби җәмәгатьчелек һәм китап сөючеләр белмичә-сизмичә дә калалар. Ә үзебез яңалыклар көткән булабыз... Заманалар үзгәрә-үзгәрә ди торгач, үзебезнең холык-фигыльләребез дә алышынып, үзгәреп, бозылып бетте бугай инде, һәр туар көн бер-бер яналык китермәсә, нәрсәдер җитмәгәндәй, Ходай бирмеш көн бушка узып киткән сыман тоела... Ә бит дөресендә, өстәп-өстәп өелгән үзгәрешләр, яңалыклар тормышыбызга да, күнелебезгә дә гел шатлыклар, бәхетләр өстәп кенә тормый,—киресенчә, үзебезгә калганда, түгәрәк дип санап йөргән дөньяларыбызның бу үзгәрешләрдән әле бер чите, әле икенчесе кителеп төшкәнлеген күреп, уфтанырга гына кала...

Әдәбият дигән өлкәдә дә хәлләр шундыйрак. Монда да яналыкка кытлык юк. Заманаларыбызның рухы шундый—хәзерге укучы сенсацияләр, табышмаклы сюжет,

мистик сурәтләр, үтә жете бизәкләр ярата ул, дигән булып ижат итүче каләм әһелләре күбәя бара. Һәр заманның үз чире дигәндәй, бу хакыйкатьне юкка чыгарып та, андыйлар белән кирәкмәс бәхәскә кереп тә булмас ахыры.

Тик шулай да күңел элеккеге әдәбиятны, салмак, талгын агышлы, ихлас әсәрләрне, итагатьле, тыйнак һәм шау-шусыз яшәү гадәтләренә күнеккән геройларны сагына икән. Бәхетебезгә күрә, әле мондый әдәбият күренешләренең дә бетеп житмәгәнлеген ачыкладык. Мәсәлән, язучы Әмиржан Моталлапов—әнә шул классик типтагы реалистик проза тарафлары. Кайберәүләргә бу исем бәлки бигүк таныш та түгелдер. Автор үзе Актанышта яшәп ижат итә. Беренче хикәяләре дистә еллар элек пәйда булып, "Казан утлары", "Аргамак" журналларында дөнья күрсәләр дә, ничектер, әдәби җәмәгатьчелек күзеннән читтәрәк торып калганнар иде. Ә инде гасыр бусагасыннан Әмиржан Моталлапов хәйран ук саллы әдәби багаж белән килеп керде. Соңгы өч ел эчендә генә дә ул "Без—Актанышлылар" дигән очерклар китабын һәм "Үзеңнеке—үзәктә", "Яшьлегем кайтавазы" исемле повесть җыентыкларын бүләк итте.

Әмиржан Моталлапов—җир кешесе, авыл кешесе. Геройлары да гадиләр, гадәтиләр. Андыйларны ул туган якларында—гүзәл Актаныш, Агыйдел буйларында очраткандыр, бәлки табигать төбәгенең гүзәллеге, җанлы шигърияте дә шушы прозага сеңгәндер. Әсәрләр белән танышканда шул кешеләрнең олпат сабырлыкларын да, хис-куәтләрен, шашкын йөрәк хисләрен, вакытында тыеп, тыйнак һәм мәгърур булып кала белгән гали затларның олылыгын, мәнле мәгънәлелекләрен дә тоясың. Алардан үз күңеленә дә яшәү шатлыгы ингәндәй була: тормыш юлларын узганда җаваплылык, аның мизгелләренең кадерен-кыйммәтен белү, башкаларны да хөрмәт итү, кайгырту кирәклеге хакында да уйлана башлыйсың.

Әдип үзенең геройларын артык катлаулы, мажаралы хәлләргә куймый да сыман, әмма аларның тормышларындагы, язмыш сукмакларындагы мизгелләргә карасаң, күңелдә байтак кына гыйбрәтле уй-фикерләр, нәтиҗәләр туа. Бу хәлиткеч мизгелләргә геройлар бөтен узган гомерләре тәҗрибәсе, сабаклары аша киләләр икән. "Яшьлегем кайтавазы" дигән повестьта карт профессор Ниязның поезд вагоны купесында үткәргән берничә көне һәм шунда яшьлеге елларының шаһите, элеккеге студенты Нурия белән очрашуы икесенең дә алдагы язмышларын бәхетле якка борып, хәл итеп куя. Сәләтле, хезмәт сөючән, яхшы күңелле бу затларга язмыш гел елмаеп кына тормаган: гаилә бәхетләре дә тулы булмаган, ә хәзер инде бөтенләй ялгыз, ярдәмчесез калганнар. Шулай да инде өметләрне өзеп, картлык халәтенә аяк басып, инде гомерләрне булганынча түгәрәкләп, йомгаклап куярга дип торганда Язмыш дигән нәрсә үземе, әллә авторның геройларына теләктәшлеге бик көчлегә күрәме, тегеләр, сынарлыктан котылып, Золушка әкиятендәгечә, кинәт кенә башлы-күзле булалар да куялар. Мондый могҗизага ни әйтәсең? Бер карасаң, әлбәттә, җитмеш яшьлек галимнең һәм илледәге проводница ханымның шулай бер-берсен тиз аңлап кавышулары әлләни гаҗәпләндерми дә. Тик шулай да бу төштә төп хикмәт авторның иҗади карашлары янсә, тагын да зуррак итеп әйтсәк, кредосы белән бәйләнгән сыман: Бәхеткә лаеклылар бәхетле булсыннар, яхшы кешеләрне бәхет кошы читләтеп үтмәсен.

Әйе, тормыш көзләренең дә отышлары була...

Бүген зур һәм әһәмиятле темалар бар. Киләчәгебез өчен борчылучы әдипләр өчен иң зур тема—ул, әлбәттә, балалар һәм яшьләр күңеле. Заманында, бер акыл иясе ата-аналарга карап, болай дип язган: "балаларыбызны, сабыйларыбызны артыграк сөеп, бозабыз бугай, дип хафаланмагыз—сез аларны алда ниләр көткәнлеген белмисез бит" дигән. Шушы гаять тә тирән мәгънәле сүзләр язучы Рәшит Бәшәр әсәрләрен кулыма алгач, искә төште. Ни кызганыч, гаять тә үзенчәлекле стиль иясе, балалар дөньясын үз матурлыгында ача белүче бу әдипнең иҗаты әдәбият галим-голәмәләре кермәгән өлкә булып кала бирә. Әле дә ярый, укучыларына игелекле, әдәбият әһелләрен пропагандалауда үтә эшлекле "Мәйдан" журналы бер рәткә тезеп, Рәшитнең 8 повестын бастырып чыгарды: "Ачык капка", "Миләш", "Яшел поезд", "Акбалык", "Иртәгә дә яшисе бар", "Бер өйдә җиде кеше", "Минем әтиемне сугышта үтерделәр", "Адашкан кош тавышы".

Шушы тупланма белән танышып чыккач, шактый катлаулы һәм каршылыклы уйлар өермәсе астында калдым: иң беренчесе—ничек соң мона кадәр бу кызыклы да, кайчагында көлкерәк тә һәм шулар янында ук тетрәндергеч, авыр, фаҗигале хәлләрне дә сыйдырган иҗат дөньясыннан нәмәгълүм булып йөрдем икән? Хәер,

монысына җавапны шактый тиз таптым—ул, укымышлы булып саналсак та, бетмәстөкәнмәс наданлыгыбызда һәм, гел үзебез, дип кенә йөреп, яныбызда гына күкрәп үсеп килүче бай иҗат үсентеләрен, шулардан мәгърур күтәрелгән иҗат биеклекләрен, киңлекләрен күрмичә, санламыйча, битараф калуыбызда. Монысын кимчелегем дип үз өстемә генә алсам да, әйләнә-тирәмдә дә "мин беләмлек дәгъвасы ун-унбиш склад" икәнлеген күргәч, Рәшит Бәшәр кебек талантларның җәмәгатьчелек игътибарыннан бер читтә, күләгәдә калып килүе бигүк гаҗәпләндерми дә башлый. Әдәби күренешләргә бәя биргәндә һаман да элеккеге идолларга табыну өстенлек итә.

Күңелсезрәк уй-хисләрне кайчак башкалары алмаштыра—болары чын әдәби хәзинә белән танышканда гына була торган ләззәт, шатлык һәм канәгатьлек хисе. Рәшит Бәшәрнең иҗат дәрьясына чумгач, хатирәләр, истәлекләр яңарды, яшьлегем, балачагым елларына, элеккеге дусларым янына кайткандай булдым. Гәрчә үземнең дөньяга күзләрем бераз башкарак чорда ачылса да... Ә Рәшит Бәшәр күбрәк узган гасырның илленче, алтмышынчы, җитмешенче елларындагы татар авыллары күренешләрен, кешеләрен сурәтләргә ярата. Әмма бу күренешләрне гомумкешелек проблемалары яктылыгында ачарга тырыша.

Рәшит Бәшәр язмаларыннан тагын шул аңлашыла: ул әдәбият дигән олы кыйтганы тагын да вакларга, төрле өлешләргә, кисәкләргә, темаларга, жанрларга бүлгәләп, аннары үз кишәрлеге яныннан, үз ызаныннан гына атларга теләми—әдәбият аның өчен үзенне Кеше, Шагыйрь һәм Рәссам икәнлегенне белдерү, раслау чарасы. Әмма бу әдип, иң беренче нәүбәттә—балалар язучысы. Ул балалар дөньясын искиткеч яхшы белә—аның әдиплек таланты, әйткәнебезчә, нәкъ шушы сфератирәлектә калку ачылып килә. Әмма иртәгә Рәшит Бәшәр башка өлкәләргә күчеп, мәсәлән, олылар тормышының җитди, әхлакый, фәлсәфи мәсьәләләрен чын художникларча күтәреп чыга икән, моңа гаҗәпләнмәскә дә була—чөнки бу иҗатның нигезенә гаять зур көч салынганлыгы сизелеп тора. Һәм ул иң изге максатларга юнәлдерелгән: мөнәсәбәтләрдә гаделлек, яхшылык, аңлаша, килешә белү, табигыйлек элек-электән халкыбызда яшәп килгән сыйфатларны торгызу, җәмгыятьтә көннән-көн ныграк тарала баручы икейөзлелек, явызлык, рәхимсезлек күренешләреннән арыну...

Әйе, "әдәбиятта герой проблемасы" дигән зур мәсьәләгә заманның һәм җанлы әдәби хәрәкәтнең агышын, йөрәк тибешен, зур һәм кечкенә борылышларын, унышачышларын, табыш-югалтуларын искә алмыйча кагылырга мөмкин түгел икән. Тик зур казанышлар турында сөйләшергә иртәрәк әле. Бүгенге хәлләребез, эшләребез Габдулла Тукай әйткән замандагы кебегрәк:

*Бара милләт зәгыйфь, абныр-абынмас,*
*Сүнә яшьләрдә ут кабныр-кабынмас...*
*...Сатучылык итә бездә мөхәррир,*
*Әдип исме аңар таглыр-тагылмас.*

Мәкаләбез рухына якынрак туры килә төшсен, дип "милләт", "мөхәррир" кебек атамаларның мәгънәләрен бүтәнчәрәк—кинәйтебрәк яисә тарайтыбрак аңлаткан булып кыланасы да юк.Әле шагыйрьдән дә туры, үткен һәм күзеңә карап дөреслекне әйтүче тумаган.

Шулай шул: әгәр дә милләт үзе салмак атлый икән, аның әдәбияты-сәнгате дә шуннан артыгын тизләнә алмый. Ә артыгына әдипләр үзләре дә дәгъва итмәсәләр, өмет тулы күзләребезне кемгә төбәргә кала?

# ШАГЫЙРЬНЕҢ КУЛТАМГАСЫ

Еллар үткән саен каләм ияләренен Ватан сугышы турындагы истәлекләре кадерлерәк була бара. Авторларнын бик күбесе якты дөньяда юк инде. Исән калганнарынын да байтагы кырык белән илле яшьләр арасында дөнья куйды. Алар өчен—иҗат иткән әсәрләре, фронтларда чыккан газит битләре, язган хатлары, архивларда сакланган документлар сөйли.

Әнә шул буыннын бер вәкиле булган Шәрәф Мөдәррис 1941 елнын каһәрле июнен Белоруссия читендә постта торганда каршылый. Фашист козгыннарынын мотор тавышларын, бомбалар ярылуын, яраланучыларнын җан авазларын шунда ишетә, дөрләп янган йортларны, беренче корбаннарны шул иртәдә күрә. Йөрәккә кан саудырган хурлыклы чигенү, Смоленск өчен барган сугышта каты яралану, госпитальдәге кичерешләр һәм янадан фронтка кайту—егерме бере тулып кына узган солдатны чын мәгънәсендә ир-егет итә, сугышчан рухын ныгыта. Шул вакытта "Минем антым" дигән шигырен яза. Әйтергә кирәк, бу антына ул фронтта да, тыныч тормышта да хыянәт итми.

1942 елда сугышчылар өчен, һәр миллэтнен үз ана телендә, газитләр басыла башлый. Редакцияләрдә эшләү өчен ут эчендә йөргән солдат һәм командирлар арасыннан язучыларны, журналистларны эзләп ала башлыйлар. Төньяк-көнбатыш фронты сугышчылары өчен русча "За родину" газите каршында, татар телендә "Ватан өчен" газите чыга башлагач, шунда эшләүче язучы Хатыйп Госман, кыр почтасы аркылы эзләп, Шәрәф Мөдәррисне редакциягә алып кайта.

Эш урыны Валдай шәһәре янындагы нарат урманы эченә яшерелгән бер эшелон була. Типография дә, редакцияләр дә шунда. Рус, татар, латыш, литва, үзбәк, казах газитләренен барысына бер вагон, һәр редакциягә аерым бер купе. Редакцияләрне фашист козгыннарыннан яшерә алсалар да журналистларнын хәле алгы сызыктагы сугышчылар кебек үк, хәтәр була. Шул ук бомбалар шартлавы, артиллерия, миномет, пулемет утлары астында калу... Шәрәфнен сөйләгәне әле дә истә: ...юлда очраган поездга утырып китә ул. Тиешле урынга житәрәк, поезд барган көйгә сикереп төшеп кала. Торып басса, каршында "ахтунг минен" дигән язулы такта күрә. Мина кырына төшкән икән.

Менә шулай йөреп эзләп тапкан хәбәрләрне, тизрәк кайтып, газиткә эшләп бирәсе дә бар бит әле. Шәрәф турында Хатыйп абый язган истәлекне укыйм. "...ул ишек катындагы почмакка посып утыра да, тезенә каты нәрсә куеп (бусы—"өстәл"), язарга керешә. Проза язса, мыштым гына эшли. Шигырь булса, пышылдый. Ул кайчак шулай сәгатьләр буе үз зиһене, үз күнеле белән сөйләшеп утыра, ара-тирә каләмен тез өстендәге кәгазьгә төрткәләп ала. Ул үзе дә, без дә монар күнеккән, безнең исне китәрми. Анар, әлбәттә, вагон коридорына чыгып пышылдарга булыр иде. Ләкин анда да буш түгел. Анда, гайрәте кузгалган бер җанвар яки арслан кебек, юри калынайткан тавышын гөрелдәтеп, Михаил Матусовский, менә инде бер сәгатьтән бирле, салмак кына атлап, арлы-бирле йөреп тора. Мин чатыр-чотыр машинкада басып утырам. Шәрәф үз почмагында пыш-пыш килә."

Әнә шулай, кулларына әле автомат, әле каләм алып, фашистларны җинеп бара-бара, герман җиренә килеп житәләр. Редакцияләре Штеттин шәһәренә урнашкач, Шәрәф бер немец гаиләсендә фатирда яши һәм шунда ярыйсы гына аларча сөйләшергә өйрәнә. Ә Жину көнен Берлинда каршылый. Рейхстаг стенасына "Татар солдаты, шагыйрь Шәрәф Мөдәррис" дип, култамгасын язып калдыра. 1946 елны демобилизацияләнеп Казанга кайта.

Сугышның беренче көннәрендә куен дәфтәренә:

*Минем илһам канлы тартышулар,*
*Бәрелешләр өчен сакланды.*
*Ни бар миндә бүген—барсы шуңар,*
*Җырга да бит сынау башланды,*

дип язып куйган Шәрәф—дәһшәтле сугышта сынатмаган совет солдатлары турында, окопларда, блиндажларда "сукыр лампа" яктысында иҗат иткән өч поэма, күп санлы шигырьләр калдырды. Гомере кыска булды аның. Шундый ук матур таңда, Бөек җиңүнең 18 еллыгын бәйрәм итәргә йөргәндә, йөрәге тибүдән туктады.

Исән булса, бу елда аңар 85 яшь тулган булыр иде. Шул унайдан мин аның фронт юлларында язылган шигырьләреннән сайлап, берничәсен "Казан утлары" укучыларына тәкъдим итәргә булдым.

**Ләбибә ИХСАНОВА**

---

# Шәрәф Мөдәррис

## Минем антым

**Мин ант иттем халкыбызга күзем төбәп,**
**Сүзем биреп, имзам салып каным белән,**
**Куркынычта калтырамас түзем йөрәк,**
**Чиста намус, камил аң һәм җаным белән.**

**Яклап чыктым туган-үскән җирләремне,**
**Утлар сарды һәм су басты алдым-артым.**
**Барды әйдәп уй, гакыл һәм хисләремне**
**Бу хак антым—кабул иткән Хәрби антым.**

**Мин ант иттем көрәшләрдә җиңелмәскә,**
**Саклаганда туган илнең мәнфәгатен,**
**Артка табан бер адым да чигенмәскә,**
**Тапламаска сугышчының мәртәбәсен!**

**Яклап чыктым гаделлекне, тугрылыкны,**
**Дошманнарга "үч!" дип сусап, ярсып аттым;**
**Сугышларда һәркайда да булды ныклы**
**Бу хак антым—кабул иткән Хәрби антым.**

**Мин ант иттем туган ил һәм халкыбызга:**
**Калды сүзем каным белән беркетелеп,**
**Яудашларым, якташларым каршысында**
**Чагылдырып вөҗданымны көзге кебек.**

**Яклап чыктым кешелекнең идеалларын,**
**Партиямнән аң, сәләт һәм ялкын алдым.**
**Бирде һаман минем җанга илһамнарын**
**Бу хак антым—кабул иткән Хәрби антым.**

*Июнь, 1941*

## Парчалар

(өзек)

Үстем синең юмарт кулларыңда,
Туган илкәй, минем хисем пакь.
Әткәм, бабам йоклый туфрагыңда,
Иң гадел хак җирдә—синең хак!

Сугыш дулый иркен күкрәгеңдә,
Елый кырда кышкы буран, җил...
Ут бар җанда, яшь бар күзләремдә,
Әй газиз җир, минем туган җир!

Күп булса да йөрәк ялкыннарым,
Чит-ят җиргә чәчәр җылым юк.
Үтсәм дә мин кургаш яңгырларын,
Сыкранырга туган җырым юк!

Килде-китте җилдә тирбәлергә
Думбрамда артык кылым юк.
Көрәш дәрте ярсый хисләремдә,
Сызланырга туган җырым юк!

*Февраль, 1942*

## Партизан

Биш юл чатында, нидер хәтерләп,
Күңелдә киңәт уйлар калкалар.
Каршыда—кабер, шунда хәрефләп,
Чокып язылган мүкле таш та бар.
Талам шушында гаҗәп бер моңга,
Җилдә чайкала серле карт имән.
"Күмелде,— дигән,—бер герой монда,
Исемсез герой, данлы партизан".
Ак болыт агыла, ярсып, тулганып,
Ак сөт шикелле томан таралган...
Килә күк шунда, ямьгә нурланып,
Сугышта үлгән илдәш каһарман.
Каласың кинәт хисләргә чумып,
Күңелдә—кайгы, зур ул һәм тирән,
Тора күк шунда, нурлы сын булып,
Исемсез герой—үлмәс партизан.
"Исемсез герой"—борын-борыннан
Бу сүз экияттә, җырда ядланган.
Андый кабергә төрбә корылачак,
Ихтирам яуган бөтен яклардан...
...Булса да бу бер билгесез кабер,
Белә бар халык, ядлый бар җиһан.
Шунда мәңгегә дан белән калыр
Исемсез герой—үлмәс партизан.
"Исемсез герой"—беләм мин моның
Бөеклек серен, мәңгелек көчен,—
Һәм күрәм анда, көрәш символын,
Шуның мәһабәт халыкчыл төсен!
Биш юл чатында нинди моңлы чак!
Җилдә чайкала серле карт имән...
Төбендә—кабер, шунда—соңгы кат
Җиргә сыенган үлмәс партизан...

*Декабрь, 1943*

## Сөеклемнең алтын балдагы

Сагынганда карап шатланырга
Бүтән бер дә ядкарь калмады...
Калды фәкать минем бармагымда
Сөеклемнең алтын балдагы.

Болыт-болыт пушка төтеннәрен—
Килде дә җил, кырга каулады...
Кичте миндә сугыш гөрелдәвен
Сөеклемнең алтын балдагы.

Мин ут ачсам, аткан вакытларда
Бер пулям да читкә таймады,
Минем белән чакма басышканга
Сөеклемнең алтын балдагы.

Капма-каршы килеп сугышканда
Һич вакыт та кулым талмады,
Җанга илһам биреп булышканга
Сөеклемнең алтын балдагы.

Килер ул көн, дөнья тынычланыр,
Тынып калыр сугыш шаулавы...
Бармагымны һаман кысып калыр
Сөеклемнең алтын балдагы.

Нурын сибәр көрәш мәйданында
Җиңеп барган фронт байрагы;
Җем-җем итәр минем бармагымда
Сөеклемнең алтын балдагы!

*Май, 1944*

## Чәчәк үскән

Китте сыман хисне ялкын басып,
Савыкканда соңгы ярамнан...
Үттем шулай иртән, ялгыз башым
Сугыш узган таныш яланнан.

Таныш нарат. Ул да яргаланган,
Өсләреннән сагыз саркыла...
Таныш канау. Шул ук янган амбар...
Чү, ни күрәм кинәт каршымда?—

Язгы көндә соңгы сусыл карга
Минем каным аккан урыннан,
Ядкарь булып канлы сугышларга,
Нурлы булып факел утыннан,

Тамырланып чәчәк күтәрелгән,
Кызыл канга ошап, кызарып,
Тимер-томыр, күмер түтәленнән
Якты көнгә башын чыгарып.

...Утырганмын шунда төшкә хәтле,
Китәр чакта бетте түземем:
Чүгеп тезем, үптем гөлчәчәкне,
Булды моңсу, тулды күңелем...

...Эх, мин һаман алга омтылырмын
Канат итеп илнең җиңешен,
Истә тотып йөрәк орлыгымның
Бу нәни һәм җанлы җимешен!

*Берлин—Штеттин.*
*Июнь, 1945*

Адлер Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ИСЛАМ һӘМ ЖЫР-ШИГЫРЬ, МУЗЫКА*** — Шигырь сөйләү, музыка коралларында уйнау вә боларны тыңлау хакында Ислам галимнәре арасында фикер берлеге юк икәнен әйтергә кирәк. Берәүләр бу эшләрнең һәммәсе дә харам диләр, икенче берәүләре исә коралларда уйнау харам, ә аннан башкалары мөбах дип саный. Мотлака, ягъни абсолют мөбах диючеләр дә бар. Ләкин шул ук вакытта бу эшләрне мөбах түгел, бәлки мөстәхәб (гүзәл) дип санаучы галимнәр дә булган.

Әлбәттә, "Йәсин" (36) сүрәсенең 69 ичы аятендә: "Без Мөхәммәд галәйһиссәламгә шигырь өйрәтмәдек һәм аңа шагыйрь булу дөрес тә түгел" дигән ачык сүзләр бар, ләкин алар әле шигъриятне кире кагалар дигән сүз түгел, чөнки үзенең ритмикасы, үлчәмлелеге, аһәңле яңгырашы һәм сурәтле чагыштырулары белән Коръән тексты үзе шагыйрьләр өчен үрнәк һәм өлге булырлык.

Әгәр дә әшәке вә фәхеш, көлкеле вә сүгенү сүзләре булганлыктан, шигырь сөйләү вә аны тыңлау харам була икән, гомумән сүз сөйләшми тору лязим булып чыга, чөнки шигырьләргә караганда гади сөйләм телендә, нәсерләрдә мондый әшәкелек күбрәк очрый. Шагыйрьләрнең тәржемәи хәлләре гүзәл булмау да аларның шигырьләрен гаепләргә нигез була алмый. Коръән-Кәрим үзе бик күп урында кяфирләрнең кеферле сүзләрен искә ала. Ә шигырьдә әдәп вә хикмәт, фазыйләт вә гыйбрәтләр дә булырга мөмкин.

Дөрес, Коръән Кәримдә шагыйрьләр зәмм кылынган *(хурланган)*, ләкин шул зәмм кылынганнар җөмләсеннән изге гамәл кылучылар вә Аллаһы Тәгаләне зикер итүчеләр аерып алынганнар.

Рәсүлулланың шигырьне хурлау сүзләре генә түгел, мәдех кылган сүзләре дә бар. Мәсәлән, "Бакай сәгадәт" касыйдәсен укыган вакытта Рәсүлулла мәҗлестә булганнарга "Тыңлагыз" дип боерган. Аның шагыйрь Кәгаб ибн Зөһиргә Пәйгамбәр хөрмәтенә чыгарган мәдхиясе өчен ябынча — "бурда" бүләк иткәнлеге мәгълүм. Бу ябынча Исламның кадерле ядкярләреннән берсе хисаплана. Исламның шигырьгә карашы нинди генә булмасын, Шәрыктә югары катлау, ил башында торучы хәлифәләр һәм солтаннар үз яннарында җырчылар һәм шагыйрьләр тотканнар, күңелләренә хуш килгән шигырь чыгарганнары өчен шагыйрьләрне бүләкли торган булганнар. Хәтта, документлардан билгеле булганча, аеруча матур шигырь әйткән шагыйрьнең авызына алтын акчалар, асылташлар тутыру гадәте яшәп килгән. Мәс., солтан Мәхмүд Газнавид (998 — 1030) әмере буенча сарай шагыйрьләре башлыгы Унсуриның (1039 яки 1049 елда вафат) авызына өч тапкыр энҗе тутырганнар.

Чыннан да вәзенле һәм көйле нәрсәне сөйләү харам була торган булса, сандугач вә тургай тавышларын тыңлау да харам дигән сүз. Сәхәр вакытында кошларның сайравын шагыйрьләр Аллаһыны мактап тәсбих уку белән чагыштыралар.

Мөшрикләр каршында исламиятне һәм Рәсүлулланы яклап күп чыгышлар ясаган шагыйрьләрдән Хәсән ибн Сабитны, Габдулла ибн Руахны, Кәгъбу ибн Маликны күрсәтергә мөмкин. Хәсән исемле шагыйрьнең аеруча әче телле булып, мөшрикләргә нык тәэсир итүе турында сөйлиләр. Сөнгатулла Бикбулатның "Хәзрәт Мөхәммәд" китабында Мөхәммәд Пәйгамбәрнең җефете Гайшәне зина кылуда гаепләүче кешеләр арасында шушы Хәсән ибн Сабит та булган.

"Саутелмәлаһи фисык, вәттәләззез биһ кефер", ягъни "музыка тавышы — бозыклык, аның белән ләззәтләнү — кефер" дигән сүз бар.

Ләкин шәрыкнең күренекле затлары Әбү Наср әл-Фараби һәм Әбү Гали Ибне Сина музыканың адәмнәр өчен файдасы турында язганнар. Әл-Фараби музыка сәнгатенең төгәл теориясен төзегән ("Китабел мусики әл-кәбир" — "Музыка турында зур китап").

*Дәвамы. Башы журналыбызның 2004 елгы 1нче санында башлана.*

Ибне Сина "Рисаләтүн фи гыйльмел мусики" исемле хезмәт язган, аның "Китаб утшифа" исемле китабында музыкага багышланган аерым бүлеге бар.

Югарыда әйтелгәннәрнең күбесе — күренекле галимебез мөфти Ризаэддин Фәхреддиннән. Хәер, аңардан элегрәк Шиһабетдин Мәрҗани бу мәсьәләне күтәреп чыккан инде. "Музыкадан төп максат, — дип язган ул, — төрле тавыш һәм көйләрне бер-берсенә яраштырып, күркәм һәм матур итеп тезү аркылы җанга рәхәтлек бирү, кеше рухын сафлык һәм пакьлек дөньясына этәрү... Бишектәге бала хуш авазга юанып җылаудан туктый һәм игътибарын шул авазны тыңлауга юнәлдерә. Дөя, аңгыра булуына карамастан, хуш аваздан әсәрләнеп, авыр йөкләрне дә җиңел күтәрә һәм ерак юллар да аңа якын тоела. Яз һәм аның чәчәкләре, музыка һәм аның хуш авазы бер-бер кешенең йөрәген хәрәкәткә китермәсә, аның табигате бозык, аңа дару юк дип, шуның өчен әйтелә".

860 нчы елда вафат булган суфи язучысы Дхул Нун түбәндәге сүзләрне язып калдырган: "Музыка илаһи тәэсир итеп, кальбләрне Аллаһка омтылырга чакыра. Рухи колак белән тыңлаучы Аңа якынлаша, хисси колак белән тыңлаучы — бидгатькә бата."

Коръән вә сөннәттә музыка коралында уйнау вә уен тавышларын тыңлау хәрам булу хакында ачык бәян ителгән сүз юк. Рәсүлулла хәзрәтләренең гает көннәрендә, туй вакытларында уен уйнаудан тыймаганлыгы билгеле. Мондый уен тавышлары инсаннарның кайгыларын киметәләр, җаннарына рәхәтлек вә сабырлык бирәләр.

"Көйләр инсаннарны үзләренә җәлеп итәләр, халыкларны ерак җирләрдән сөйрәп китерәләр. Ислам дөньясы шушы эшне әхлак төзәтү вә гыйффәт тарату хакында васила кылырга тиешле иде", — дип яза мәшһүр галимебез Ризаэддин бине Фәхреддин. Тукай да шул фикердә: "Зинага чакыра торган музыка хәрам булса да, алга китәргә, тәрәккыйга чакыра торган музыка мөстәхәб, хәтта вәҗиб уктыр", — ди ул.

Әйе, зинага чакыра торган музыка да бар. Музыкадагы билгеле бер тактлар, мәсәлән, секундка бер ярым тапкыр кабатлансалар һәм үтә түбән ешлыктагы көчле тавыш басымы белән үрелеп барсалар, кешедә экстаз *(җәзеб)* халәте китереп чыгарырга мөмкин. Секундка ике тапкыр кабатланган такт исә шул ук тавыш ешлыкларында кешене наркотик матдә тәэсир иткән кебек бию трансына төшерә. Сексуаль биюләр, йола буенча үтерүләр менә шундый музыка тәэсирендә эшләнә. Музыканың мондый тәэсирен шаманнар *(камнар)*, сихерчеләр, борынгы вакханкалар яхшы белгәннәр һәм аңардан файдаланганнар. Шушы ук нәрсә "әйләнчек дәрвишләр" биюендә *("ракс")*, шигыйларда шәхсәй-вәхсәйләр шашынуында да чагылыш таба. Кыскасы, исламның музыкага мәгълүм дәрәҗәдә сак мөнәсәбәте күп яктан аклана да. Бүген рок-концертларны тыңлаучыларда күзәтелә торган психик һәм нерв өянәкләрен искә төшерик. Адәм психикасы гына түгел, башка җан ияләре, хәтта җансыз нәрсәләр дә рок-музыка гөрелтесенә түзми. Мәс., "Пинк флойд" группасы ачык һавада концерт биргән вакытта якындагы күлдә балыклар миңгерәүләнеп, өскә калкып чыкканнар. Ә 1979 елда Пол Маккартни Венециядә концерт куйганда агач күпер җимерелеп төшә, инде телгә алынган "Пинк Флойд" группасы исә Шотландиядә бер күперне җимерүгә "ирешә" һәм бу факт документта теркәлгән.

Шул ук вакытта музыка белән дәвалау ысулы билгеле. Мәс., чеченнәрдә халык табиблары авырту-сызлауларны басу өчен музыкадан файдаланганнар.

Әйтик, бармак шешкән вакыттагы сызлауны балалайкада махсус музыка уйнау юлы белән җиңеләйткәннәр. Бу музыканың көен композитор А.Давиденко нотага язып алган һәм аны "Кулдагы шеш сызлавын баса торган көй" дип атаган. Аның нота язмасы 1927 елда басылып та чыккан. Безнең көннәрдә дә бу өлкәдә тикшеренүләр үткәрелә. Германиядәге Франкфурт-Майн шәһәре университет клиникасы профессоры Дитфрид Пехль бу мәсьәләне җиде ел буе тикшергән һәм чыннан да авыруларны "музыкаль группа"да дәвалауның нәтиҗәлелеге югарырак булып чыккан. "Известия" газитенең 1985 ел 25 июль санында "Музыка астында операция" дигән мәкалә басылган иде, анда көнбатыш Германия табибларының кайбер операцияләр вакытында авыртуны дару ярдәмендә басу урынына тыныч музыка кулланулары турында хәбәр ителә.

Күрәбез ки, чечен табиблары авырту-сызлауны җиңеләйтүнең оригиналь ысулын галимнәрдән шактый элек тапканнар икән.

Төркиләрдә, шул исәптән татарда да, музыканың нык таралган булуын телдә музыка терминнарының муллыгыннан күрәбез (мәс., әдәбиятта очрый торган музыкага нисбәтле

кайбер сүзләр: *аргу*—тамбурның бер төре; *әргән*—орган (гармун мәгънәсендә); *бәрбат*—лютня (*"лютня"* сүзе гарәпчә *"әл-гуд"* тан алынган, агач мәгънәсендә), *быргы, сур*—труба; *гөслә; гыжек*—скрипка; *дәф*—тамбурин, бубен, ягъни шөлдерле уен коралы; *думбра (тамбур* белән уртак чыгышлы); *дум-думбак*—барабан; *кубыз (кызлар уйнаган авыз кубызы, кулда уйнала торган кыл кубыз, кул кубыз)*; *курай*; *кус*—зур барабан; *мотриб*—музыкант, җырчы; *най (нәй)*—курай; *нәкарә*—литавр; *саз; сорнай*—зур быргы яки кыллы курай; *таб(е)л* (тубал)—барабан; *төнер*—шаманнар кага торган түгәрәк барабан; *чалгы*—көй коралы; *чәмбал*—цимбалга (бу атама гарәпчә *"табел"*га барып тоташа) охшаган уен коралы; *чәң*—арфаның бер төре; *чәрләлек* (?)

Һади Килдебәкинең (1881—1943) "Ислам һәм музыка" исемле китабы бар.

***ИСЛАМ ҺӘМ РӘСЕМ-СЫН СӘНГАТЕ***—Мәгълүм булганча, шәригать җан ияләренең сурәтләрен ясауны тыя. Шуның аркасында электә кеше рәсемнәре төшерү, хәтта фоторәсемгә төшү дә нәшәргый гамәл исәпләнгән. Ш.Мәрҗани моны түбәндәгечә аңлата: "Пәйгамбәр заманында кешеләр сурәткә табына торган булганнар. Шуңа күрә рәсем ясау гомумән тыелган. Ә хәзер андый куркыныч юк. Шулай булгач, тыюның сәбәбе бетә һәм тыюның кирәге калмый". Мәрҗани берничә тапкыр үзенең фоторәсемен алдыра, Истамбулда Мөниф паша йортында үзе күргән хатын-кыз скульптурасы турында һичбер тартынмый, шелтәләми яза *(Х.Хисмәтуллин)*. Белгәнебезчә, хәзерге вакытта мөселман илләрендә басылган төрле китап-дәреслекләрдә рәсем-сурәтләр булмыйча калмый, ләкин гадәттә рәсемнәрге кешеләр мөмкин кадәр схематик һәм яссы итеп сурәтләнәләр. Ләкин киләчәктә мондый тыюлар тагы да йомшый төшәр дип көтәргә кирәк.

Безнең көннәрдә Ислам һәм сынлы сәнгать мәсьәләсе тагын бер куерып алды. Билгеле булганча, татарның күренекле улы Шиһабетдин Мәрҗанинең сынын Кабан күле буендагы Мәрҗани урамына һәйкәл итеп кую планы бар. Күп кенә дин әһелләре моңа каршы күтәрелеп чыктылар. "Әүвәл Татарстан Диния нәзарәте олуг галимнең сынын һәйкәл итүгә каршы махсус карар чыгарды. Соңра Согуд Гарәбстанында укып яткан шәкертләрнең бер төркеме Шиһаб Мәрҗанинең сынын кую Ислам диненә ни дәрәҗәдә афәт икәнлеге турында "Иман" газите аша мөрәҗәгать белән чыкты" *(Харис хәзрәт Салихҗан.)* Алар үз фикерләренә дәлил итеп Коръән-Кәрим кәлимәләрен китерәләр. Чыннан да Изге Китапта: "Ий мөэминнәр! Исерткеч эчемлекләр һәммәсе дә, отыш уеннарының һәртөрлесе дә, сыннарга табыну, гыйбадәт кылу, шулай ук ырым һәм багучылык—болар барысы да шайтан гамәлләре. Бу гамәлләрдән качыгыз. Сакланыгыз, шаять һәлакәттән котылырсыз,"—диелгән. Ләкин монда сүз сыннарга табыну турында бара. Әгәр табыну юк икән, бу эшнең гөнаһы юк. Әфганстанда тауташта Будданың борынгылар уеп ясаган мәһабәт сынын талибаннарның шартлатып юк итүләрен дә берничек аклап булмый, моны фәкать вәхшилек дип кенә бәяләргә мөмкин.

Татар дөньясында мәгарифкә әүвәл башлап адым салган Шиһабетдин Мәрҗанигә ватанында һәйкәл кую—безнең изге бурычыбыз.

***ИФРАТЧЫ*** *г.*—Радикал, кискенлек тарафдары *("ифратчы" сүзе Фатих Әмирханда очрый)*.

***ЙАРАК*** *тар.*—Тимер бөҗраларданһәм таңкәләрдән торган сугыш киеме. Идел буе болгарлары X—XIV гасырларда вак пластинкалы йараклар кулланганнар, XII—XIII гасырларда эре пластикалылары күбрәк кулланылган.

*Йарук* язылышы да очрый *(русча "латы" мәгънәсендә)*.

***ЙАХШЫЛАР***—Изгеләр. *//Астана тип йахшылар яткан урынга әйтәләр (Д.С.Тумашева. Словарь диалектов сибирских татар)*.

***ЙОГУРТ***—Әчегән сөттән ясалган продукт, катыкның бер төре. Хәзерге татарча чыганакларда күбесенчә *йогырт* дип язалар. *Йогурт* сүзе Мәхмүд Кашгарыйның "Диване лөгатет-төрк" сүзлегенә (XI гасыр) дә теркәлгән, шуңа күрә аны Дунай болгарларыннан килгән сүз дип санау дөрес түгел, язылышын да курыкмыйча борынгы "йогурт" рәвешендә алырга мөмкин.

***ЙӨРМӘ ТАУЛАР***— Дюналар (бу атама инкыйлабка кадәр "Мәдрәсәи Мөхәммәдия"нең уку программасында телгә алына).

***КАБА ЙЕГАЧ*** *бор.*— Борынгы төркиләрдә нәсел шәҗәрәсе, нәсел агачы ("Биек агач" мәгънәсендә). Кайчагында *шәҗәрә агачы* дип тә әйтәләр, ләкин монысы тавтологиядән гыйбарәт була ("агач агачы").

***КАВӘСЕ КОЗӘХ*** *г.*— Салават күпере. Борынгы төрки телдә *солан* сүзе дә кулланылган. Халыкта салават күперен *"чәчүрмә"*, *"килен тастымалы"* дип тә атаганнар. Күктә салават күпере пәйда булгач: "Сөңге юлы калыкты", "Тәңре тастымалын киптерергә элде",— дигәннәр. Төрле сөйләшләрдә салават күперен *"күк дугасы"*, *"күк җәясе"* дип атау да очрый. Борынгы төркиләр салават күперен *янгылыч/ янгалыч* (яң *"җәя"*+ *"кылыч"*, ягъни җәя кебек бөгелгән кылыч) дип тә йөрткәннәр *(Г.Саттаров)*. Гомумән, "салават күпере" дигән термин татар теленә соңрак кергән булса кирәк.

Тагын кара: ***САЛАВАТ КҮПЕРЕ.***

***КАДӘР*** *г.*—Куәт; язмыш, тәкъдир, фәләк. Дөньядагы барлык вакыйгаларның һәм адәмнәр кылган эшләрнең Аллаһы тарафыннан алдан ук билгеләп куелуы турындагы принцип.

Тулаем алганда, чыганакларга карасак, тәкъдир мәсьәләсе төп өч сорауга кайтып кала:

1.Кеше үзенең кылган кылыкларында ирекleме?

2.Кеше үзенең эш-гамәлләрендә Аллаһыга буйсына икән, кешенең кылган кылыклары өчен әхлакый җаваплы булуын моның белән ничек яраштырырга?

3.Аллаһының җир йөзендә барлык яхшылыкларга һәм андагы барлык яманлыкларга юл куюын ничек аңлатырга?

Коръән белән Сөннәдә бу сорауларга катгый җавап юк.

Коръән-Кәримдәге кайбер сүрәләр кешенең бөтен нәрсәдә Аллаһ иркендә булуын кистереп әйтәләр.

Мәсәлән, Коръәндә (3:145/139) үлем сәгате турында: "Бернинди зат та Аллаһ тәгаен иткән вакыттан башка вакытта үлмәс, мәгәр һәркем Аллаһ билгеләгән вакытта үләр",— диелгән. Дөньядагы бәла-казалар да Аллаһ иркендә, шуңа күрә адәмнәргә Аллаһ билгеләгән юлдан бару тиеш. Коръәндәге 16:9; 76:3; 4:49 аятьләр дә алдан ук билгеләнгән язмыш турында сөйлиләр.

Икенче төрле аятьләр исә кешенең теге яки бу гамәлне кылуы тулысынча үз иркенә бәйле дип раслый. Мәсәлән, "Аңлатылды" сүрәсенең 17 аятендә: "Әмма Сәмуд каумена һидәятне ачык бәян иттек, алар исә иманлы булудан кяфир булуны артык күрделәр, аларны кәсеп иткән явызлыклары сәбәпле хур итүче каты газап тотты",— диелә. 17:84; 18:28-30; 4:101 аятьләр дә шул турыда.

Өченче төрле аятьләр кылган явызлыклары өчен кешенең Аллаһы тарафыннан котылгысыз җәзага тартылачагын хәбәр итәләр. Мәсәлән, 4:123 аятьтә: "Берәү явыз эшләр кылса, ягъни Аллаһыга итагать итмәсә, шул явызлыгы белән җәза кылыныр, Аллаһыдан башка аңа вәли һәм ярдәмче табылмас",— диелгән.

Бу мәсьәләдә Исламияттә дә, башка диннәрдә дә бәхәсләр барганлыгын әйтергә кирәк. Яһүдиләрнең талмуды, мәсәлән, фатализм белән сугарылган. Талмудчы Элеазар Каппор: "Шуны бел, бөтенесе — хисапта, кылганнарың чамасында булыр; сиеныр җирем гүрдә дип үзеңне юатма, чөнки син үз ихтыярың белән тумадың, үз ихтыярың белән яшәмисең, үз ихтыярың белән үлмисең һәм патшалар патшасына, изгегә үз ихтыярың белән хисап бирмәссең",— дип өйрәтә.

Югарыда әйтелгәнчә, Коръәндә кешенең Аллаһ хөкемендә генә булуын раслый торган аятьләр белән бергә, кешенең үзе кылган эш-гамәлләре өчен җавап бирәчәген кисәтүче аятьләр дә бар. Шуңа күрә бу мәсьәләдә галимнәр, философлар, шагыйрьләр берсен берсе инкяр итә торган фикерләр әйтеп чыкканнар. Гомәр Хәййям, мәсәлән, мондый дәгъва белдерә:

*Яратдың да, ходай, минем җисемне син,*
*Язып куйдың эшләячәк эшемне син.*

*Үзен язган гөнаһларны кылган өчен,*
*"Җәһәннәмгә, кеше, син кер!—дисеңме син!"*

Сәгыйть Рәмиевнең язмыш турындагы фикере Гомәр Хәйямгә авазлаш:

*Бетте баш, кипте яшь, китте бар рәхәт,*
*Бетсен, ни күрсәм мин күрермен!*
*Язмыш ни язгандыр белгән бер әхад,*
*Аңар буйсынар да йөрермен.*
*Азармын, тузармын, шулай мин йөреп,*
*Язмышның бурычын үтәрмен...*

Насыйр Хөсрәү Аллаһы әмере белән гүзәллеккә сәҗдә кылуын акларга тырыша:

*Гүзәлләрнең гүзәлләрен бу дөньяга*
*Синең әмерең белән бирә Болгарстан.*
*Әйтче, раббым, минем нинди гаебем бар соң,*
*Шундый тиңсез гүзәллеккә сәҗдә кылсам!?*

Ә Габдрахман Җами фаталист түгел, ул кеше ихтыярының әһәмиятен таный, алдан ук язып куелган ләүхелмәхфуз идеясе белән туры бәхәскә керә:

*"Тормыш, —диде бөекләрнең берсе миңа, —*
*Язылмаган, ап-ак, керсез дәфтәр синә.*
*Бәхетле син—гүзәллекне, бөеклекне*
*Аз булса да яза алсаң әгәр шуңа."*

Кадәр белән кеше ихтыяры арасындагы каршылыкны Дәрдмәнд тә тоя:

*"Күңел һәр җирдә гөл эзли,*
*Кадәр һәр җирдә тикән төзли."*—ди ул (тикән—тигәнәк).

Аңа кадәр күп элек Аллаһияр да:

*"Хәрәм эштән ләкин тыйды ул безне,*
*Бирде ихтыярый өлешебезне.*
*Хода риза булмас гөнаһ эшләргә,*
*Ризалыгы Аның яхшы кемнәргә,"*—дип язган.

Әл-Әшгари сөнниләрнең язмыш турындагы догматын могтәзиләләрнең кеше ихтыярының ирекле турындагы тәгълиматы белән килештерергә омтыла һәм абсолют тәкъдир тарафдарлары *(җәбрийәләр)* белән кешенең ихтыяр ирекле тарафдарлары *(кадәрийәләр)* арасында урта бер позициядә тора: кешенең гамәлләрендә *(кәсебендә)* ихтыяр ирегенең дә беркадәр катнашуын таный. Әшгаричә кәсеб ул хәрәкәт итү мөмкинлеге белән башкарылган хәрәкәт арасындагы бәйләнеш, ләкин беренчесенең икенчесенә эчке йогынтысы тудырган нәтиҗә түгел. Мөмкинлек, хәрәкәт һәм кәсеб кешедә турыдан-туры Аллаһы тарафыннан бар ителгән, кеше фәкать үз эченә сыйдыручы бина *(мәхәл)*, субстрат кына булып тора. Шуның белән бергә, әшгаритләр кешенең кылган эшләре өчен җаваплы булуын да таныйлар

Могтәзиләчелеккә нигез салган Васил бин Гата *(700—749)* тормышның тышкы хәлләрен Аллаһы җибәрә, ә үзенең гамәлләрен кеше үзе кыла дип саный. Икенче бер могтәзилә Ән-Нәззам Басри *(845 елда вафат)* кеше үз ихтыярында тулысынча ирекле дип раслый. Әбү Хозәйл әл-Галлаф *(849 елда вафат)* адәмнәр дөньялыкта гына ирекле, ә ахирәттә алар Аллаһы ихтыярында дигән фикерне үткәрә.

Мәшһүр суфи әл-Хәллаж *(858—922)* үзенчәлекле тәгълимат белән чыга. Ул ике башлангыч бар: яхшылык кылырга кушкан мәңгелек әмер һәм Аллаһы тарафыннан тудырылган ихтыяр, бу соңгысы кешегә яман эшләр кылырга юл куя.

"Аллаһы Тәгалә һәрбер нәрсәне вә һәрбер эшне булмастан борын үзенә мәгълүм булган рәвешчә тәкъдир кылып куймышдыр". "Бәндәләр һәрбер кылган фигыльләрен үз ихтыярлары илә кәсеп кылсалар да, аларга куәт бирүче Аллаһы Тәгаләдер." Болары—Ризаэддин Фәхреддиннән.

Күренекле татар галиме һәм мәгърифәтче Шәмсетдин Күлтәси табигать үз кануннары буенча үсә, Аллаһы дөнья эшенә катнашмый дигән фикердә тора, ягъни деизм позицияләрендә була.

Бүгенге татар авторларыннан Нурулла Мөфлихун Арыслани хәзрәттән бер өзек китерик: "Әмма кешенең ихтыяри эшләгән эше һәм кылган гамәле, — яхшы булса да, яман булса да, — ул тәкъдир түгел, бәлки кешенең үз эше. Кешенең ышанмавы, динсез булуы, хәмер эчүе, зина кылуы, кеше үтерүе һәм башка бозык эшләре ничек тәкъдир, ничек Аллаһ эше булсын? Боларны тәкъдир дисәк, ул эшләрне Аллаһ эшләгән дигән сүз була. Кеше эшли торган яман эшләрне, әлбәттә, Аллаһ эшләми, киресенчә, Аллаһуга каршы барып кеше эшли." Бу сүзләрдән күренгәнчә, автор кешенең ихтыярга ия булуын һәм ихтыяри гамәлләре өчен аның Аллаһы каршында җаваплы булуын таный.

Фикер иясләре арасында тәкъдир үзе дә *әсбабе әсире*, ягъни сәбәпләрнең колы дип санаучылар булган. Ягъни дөньяда сәбәп — нәтиҗәләр чылбыры өзелмичә дәвам итә, һәр вакыйганы китереп чыгарган әүвәлгерәк вакыйгалар була дигән сүз.

Татарлар арасында борынгыдан ук киң таралган "Шараитүл иман" китабында *иман мөфассал (тулы иман)* догасы тәкъдирнең Алладан иңгән булуын иман шартларының берсе итеп ала: "Мин Аллага һәм аның фәрештәләренә, һәм аның китапларына, һәм Аның рәсүлләренә, һәм ахыргы көнгә, һәм *яхшылык белән явызлыкның тәкъдир булып Аллаһы Тәгаләдән иңүенә*, һәм үлгәннән соң яңадан терелүгә ышанам."

Мондый каршылыкны ерып чыгу өчен аерым кеше ихтыярын Аллаһы ихтыярына каршы куймыйча, аны Аллаһы хөкеменең бер өлеше, кисәкчәсе дип кабул итү зарур. Димәк, хәлифәләрне һәм хакимнәрне Аллаһының җирдәге күләгәләре дип "бөекләштереп" әйтүдә мәгълүм дәрәҗәдә хакыйкать элементы бар. Ләкин, әлбәттә, хәкимнәр генә түгел, һәрбер зат Аллаһының "күләгәсе" булырга тиеш. Монда, ихтимал, күләгә сүзе урынына киңрәк эчтәлекле проекция сүзе куллану тиешледер. Яки Аллаһыны абсолют зат дип алып, ул хәлык кылган башка барлык нәрсәләрне — Аның голограммасы дип карау хакыйкатькә тагы да якынрак тора торгандыр. Яисә безне әйләндереп алган өч үлчәнешле дөньяны дүртенче үлчәнеш итеп вакыт категориясен дә алган галәмнең чиксез күп санлы геометрик аркылы киселешләреннән берсе генә дип фараз итеп, галәмнең үзен мәңгелек Зат сыйфатында кабул итү кирәктер. Болай фараз иткәндә Аллаһы — һәркемнең күңелендә, чөнки ул үзен аның бер кисәкчәсе дип санарга мөмкин. Мондый дуализм фәнгә күптән билгеле. Мәс., фәнни экспериментларда элементар кисәкчекләр *(әйтик, электроннар)* кайчагында үзләрен җисми кисәкчек итеп, кайчагында исә дулкын *(кыр)* сыйфатында тоталар һәм бүгенге физикларны бу хәл гаҗәпләндерми инде. Югарыда кулланылган *яки* һәм *яисә* сүзләре шикләндермәскә тиеш, чөнки сүз бара торган феноменны адәми терминнарда аңлату мөмкин дә түгел, моның өчен безнең гадәти өч үлчәнешле дөньядан читкә чыгу сорала.

Мондый фикер төптә яңа түгел. Мәс., суфичылыкта *Зыйлле мәгъбуд* — Алла күләгәсе дигән төшенчә бар. Ә бер кабер ташындагы язуда *"Зыйл-луллаһи лил-галәмәйни"* — "һәр ике дөньяда Аллаһының күләгәсе" дигән сүзләргә тап булабыз. Ләкин еш кына моны Аллаһыга шәрик кушу дип, күп аллалык була дип бәяләгәннәр. Хәлбуки монда шәрик кушу юк, чөнки, математикада күплек *(множество)* үзенең бер өлеше белән тигез куәтле була алган кебек, Аллаһының голограммасы да бер үк вакытта аның үзенә бәрабәр һәм голограммасының ирке Аллаһының үз ихтыярына тиң дип карарга мөмкин. Шуны да әйтик, могтәзиләләр арасында да яраткучы зат *(Аллаһы)* белән яратылмыш затлар арасында аерма юк дип санаучылар булган, ләкин шул ук вакытта алар кеше ихтыяры тулысынча ирекле дип тә ышанганнар, ягъни аларның фикере капма-каршылыклы.

Камиллекнең өченче баскычы булган мәгърифәттә суфи аулакта уйга чумып, дөнья тәэсиреннән арынып, хакыйкать белән берләшергә омтыла. Дүртенче баскычта, хакыйкать дәрәҗәсендә, суфи өчен Аллаһы Галәмнән тыш зат түгел, ул суфиның үзендә яши, суфи үзен Аллаһының бер кисәкчеге итеп тоя. Бу баскычка ирешкән суфи өчен дөньяда капма-каршылыклар калмый, уңай яки тискәре дигән нәрсәләр булмый, яхшы белән яманга бүленеш тә юкка чыга. Суфичылыкның күренекле вәкиле Руми әйткәнчә, "хода зыйд нәдарәд", ягъни "алланың киресе юк". Хакыйкатькә ирешкән суфи Ислам дине мәрасимнәрен үтәмәскә дә ирекле, чөнки аның өчен гөнаһ төшенчәсе юк, аның изгелегенә берничек тә зыян килми. Шул рәвешле, тәкъдир мәсьәләсендәге күбәүләрне аптырашта калдырган капма-каршылык та юкка чыга. Кеше ихтыяры һәм аның гамәлләре Аллаһы тарафыннан программалаштырыла дияргә мөмкин.

**КАЕК** – Бу сүз гадәттә "көймә" мәгънәсендә кулланыла. Ләкин "Көймәле килсә, каеклы качар", "Каекчы көймәчегә юл бирер" дигән мәкальләргә караганда, көймә каектан зуррак һәм "дәрәҗәлерәк" *(камилрәк)* булган дип уйларга туры килә. Ихтимал, алар арасындагы төп аерма беренчесенең төбе "көймәләп" эшләнгән булудадыр. "Каек" сүзе күп кенә телләрдә очрый. Мәс., эскимос телендәге "кайак" рус теленә дә кергән *("каяк")*.

**КАЗАК** *тар.* – **1.**Казан ханлыгында махсус хәрбиләр, гвардия; ялланган гаскәри *(С.М.Шпилевский)*. Шулар киеп йөри торган хәрби форманы *казаки, казакин* дип атаганнар *(Н.К.Дмитриевтән – Р.Әхмәтьянов буенча)*. "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге"ндә казаки – "тегелеше белән озын камзулга охшаган, ләкин җиңле һәм кечерәк кенә утыртма якалы өске кием." **2**.Казан ханлыгы егылгач, рус дәүләтенә хәрби хезмәткә күчкән югары катлау татар феодаллары төркеме. Казакларның бер өлеше ясаклы крәстияннәр арасыннан да җыелган. Ш.Мәрҗанидә: "Авыл халкының исә асыл затларыннан башкалары ике төркемгә бүленә һәм берсе – "казак", икенчесе "ясаклы" исеме белән атала. Ясаклылардан бары имана алынып, чиргә бару хезмәтеннән азат ителәләр, "казак" җәмәгатенә исә кирәк чакта чиргә бару бурычы йөкләнә." Мәс., Оренбург якларында язып алынган бер бәеттән күренгәнчә, мондый казаклар "тарих мең дә тугыз йөздә ундүртенче милади" елында да булган әле. Сугышка чакыру хәбәрен казакларда "кызыл флаг" белән белдергәннәр. Чиләбе нагайбәкләре фольклорындагы "Казак озату", "Казак көе" кебек җырларда казак итеп алынган нагайбәк яшьләренең казак тормышына иләнә алмыйча җәфа чигүләре чагыла.

Татарлар арасында очрый торган *Казаков* фамилиясенең килеп чыгышы шушы "казак" төшенчәсенә бәйле.

*Казак* һәм *казакъ, казах* сүзләре бер үк тамырга кайтып калалар. Борынгы мәгънәсендә казак дип кар тибеп үлән ашап кышлый торган ярым кыргый атка әйткәннәр. Андый ат көтүеннән аерылып киткән. Шуннан инде кабиләсеннән аерылып үзбашка яши торган кешеләрне дә казакъ *(качак)* дип атаганнар һәм бу сүз рус теленә дә барып кергән *(Р.Әхмәтьянов)*. Чыннан да рус казаклары алпавыттан качып киткән кешеләрдән торган. Төрки казакларны үзәкләшкән дәүләткә *(Урдага, Хәрәзмгә h.б.)* буйсынмыйча, далада качып йөргәннәре өчен шулай атаганнар. Татар телендә *казак яту* – эзәрләүдән далага качу. Рус телендәге әдәбиятта *киргиз-кайсак* термины нәкъ менә качак кыргызлар мәгънәсендә кулланылган *(гадәттә хәзерге казах / казакъларның элгәрләренә карата)*. Л.Н.Гумилев бу мәсьәлә белән нечкәләп кызыксынган. Христианлык кабул иткән кыпчак чыгышлы Запорожье *(бусага арты)* һәм слобода *(бистә)* казакларының хәзерге фамилияләрендә гадәти булган төрки "енко" кушымчасы *(Иван+енко)* рус фамилияләрендәге "ов"ны *(Иван+ов)* алмаштырган дип яза ул.

// *Казак киту* – качак булып киту.

Тагын кара: ***ТАТАР КАНТОНИСТЛАРЫ.***

**КАЗЫЯ** *г.* I – **1.**Хәл итәсе, чишәсе мәсьәлә. // *Вә ләкин тугры фикер киләчәктә була торган эшләрнең казыясене күңелдән тәртип идеп, бер тугры нәтиҗә чыгарадыр.* Г.Г.-Чыгтай. **2.**Теорема; тезис. **3.**Җөмлә, хәбәр.

**КАЗЫЯ** *г.* II – Татарча китапларда "казый" сүзенең мөәннәс *(хатын-кыз җенесе)* формасы буларак та кулланылган. Мәс., 1917 елда Русия һәм Себер мөселманнарының Диния нәзарәте җыелышында татар хатыны Мөхлисә Бубия ханым казыя итеп сайланган.

**КАЙ** *бор.* – Эчтән сөйләү *(чревовещание)*; тамак төбе тавышы, тамак белән җырлау. Элекtә төрки шаманнар *(камнар)* кай тыйлемен камил белгәннәр. *Кай* мәҗүси җеназа мәгънәсендә йөргәнлектән, муллалар аны оныттырырга тырышканнар *(Р.Әхмәтьянов)*. Башкорт якларында тамак белән җырлауның җирле атамалары: *өзләү, кайлау, тамак-курай.*

*Дәвамы киләсе санда*

# "...МӘҢГЕЛЕК ДИП ГҮЯ ПЫШЫЛДЫЙ"

Язучылар арасында шундый бер кыйсса йөри. Рафис Корбанның яна гына Казанга укырга килгән елында ул тулай торакта Хәйдәр дигән озын гына бер егетнең күршесендә яшәгән. Хәйдәр көн саен стена аша ишетелерлек итеп, "Кор-ба-нов!" дип кычкырып, Рафисны бүлмәсенә чакырып кертә икән.




Бәләкәй генә, буе жирдән метр ярымнан чак кына өскәрәк күтәрелгән Рафис курка-курка гына монын бүлмәсенә керәп:

—Нәрсә бар, Хәйдәр абый?-дип сорый.

—Дөньяда барлыгыңны гына белергә телим. Берни дә юк, бар, бар, дәресеңне әзерлә,—ди Хәйдәр.

Әмма бер мәлне... Әмма бер көзне Хәйдәр дигән әлеге егетебез тәмам хәйран кала. Сентябрь башы, студентларның әле генә авыллардан килгән чагы була бу. Элекке гадәтенчә күрше бүлмәгә карап боерган тавыш белән аваз сала Хәйдәр:

—Корбанов!

Көтә Хәйдәр, әмма жавап юк. Тагын бер мәртәбә кабатларга туры килә моңа:

—Корбанов дим мин!

Һаман тынлык—ым-шым ишетелми. Тик тагын бераздан гына Хәйдәрнең ишеге ачылып китә дә, бусагада бер пәһлеван гәүдәсе пәйда була:

—Кем шаулый анда?!

Хәйдәр ишектән керүче бу егетне күргәч телсез кала! Чөнки... Чөнки ишек авызында бер җәй эчендә великандай үсеп, имәндәй калынаеп киткән, тавышына ирләр ныклыгы ингән Рафис Корбан басып тора!

Бу кыйсса чыккан еллардан соң инде әллә никадәр вакыт узды, тормышлар да байтак яктан үзгәрде, өметләребез дә бер янарды, бер сүрелде, әдәбият мәйданында да шактый гына кызыклы яналыклар булып алды—ләкин теге яки бу унайдан "Рафис Корбан" дип әйткәндә әлеге кыйсса килә дә төшә, килә дә төшә искә!

Чыннан да, хәзер безнең әдәбиятыбызда да әлеге кыйссадагы кебек бер күренеш күзәтелә түгелме соң? Без күп еллар буена "сәләтле балалар шагыйре" дип йөрткән Рафисыбыз соңгы чорда үз иҗатында җитди үзгәрешләр кичереп, чын шагыйрь булып үсеп җиткән түгелме соң?!! Тәмам "пешеп", өлгереп җиткән түгелме соң ул?! Аның Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан "Яра" исемле шигырьләр җыентыгындагы әсәрләр белән танышу миндә әнә шундый тәэсир калдырды.

Шагыйрьнең кемлеген,ниндилеген яхшырак аңлар өчен, әйдәгез, иң еш кабатланган темага—Сабан туе темасына язылган шигырьгә мөрәҗәгать итик:

*Соңгы көрәш менә, ләкин билдән кысып*
*Алучы мин булмасам да һич көрсенмим.*
*Шул батырны, сокланып көч-кодрәтенә*
*Зурлап күккә чөйгәннәрнең бит берсе—мин!*

Рафис Корбан. Яра.—Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2004 ел.

Менә шушы дүрт юлда Рафис Корбан шигъри "мин"енең характеры, табигате шактый ук ачык чагыла. Дөрестән дә, ул сикереп алга, уртага чыгарга бик үк яратмый, әмма аның йөрәге, күнеле һәрчак көрәшчеләр янында, көрәш мәйданында! Равил Фәйзуллин да үзенең бер шигырендә әнә шундый нечкә, әмма тирәндәге бәйләнеш турында болай дип язган иде бит әле:

*Куллардан бигрәк, җан белән*
*бәйләнгән без балачакның*
*әйлән-бәйләннәренә.*

Шунын шикелле, Рафис Корбан да җаны, йөрәге белән һәрчак көрәшчеләр, тынгысызлар, фидакарьләр арасында яши. Ә бу шигырь исә безгә үзенә бер төрле әхлакый сабак та бирә кебек. "Син үзеңнен көрәшчеләренне гел күз уңында тот, аларның кадерен бел, аларга тиешле хөрмәтен дә күрсәтеп бар",— ди кебек ул. Татар халкының соңгы гасырлардагы таркаулыгы һәм иң мөһим чорларда бердәм була алмавы турында уйлаганда мондый фикер тагын да актуальләшә төшә. Бу шигырьнен лирик герое исә мәйдан тоткан көрәшчегә сокланып карый, аның белән горурлана. Кайберәүләр кебек ул кеше унышына көнләшми, көенми. Яшьләребезне дә менә шушындый матур үрнәкләр яктылыгында—киң күнелле итеп тәрбияли алсаң, бәлки киләчәктә безнең татар милләте дә тар күнеллелектән, хөсетлектән арынып, үсеп, күтәрелеп китәр әле дигән оптимистик уйлар туа бу шигырьне укып чыкканнан соң хис-кичерешкә бирелеп утырганда.

Әйе, бу китаптагы иң мөкатдәс, иң житди уйлар—халык, милләт турында. Казан Кремлендә йөргәндә Рафис Корбан болай уйлана:

*Ачсаң монда ишекләрне*
*Ханнар чыгар күк килеп.*

Ә хәзерге Татарстан картасын ул менә мондый сүзләр белән күзли:

*Һай кысыла, кысыла йөрәгем,*
*Кысылгандай синең чикләрең.*
*.....................*
*Татарстан—йөрәк ярам минем*
*Төзәтергә сине юк чарам.*

Бүгенге чынбарлык, милләтнең хәзерге яшәеше китапта күз алдында калырдай күренешләр булып җанлана. Бер яктан: "Бишек җыры—иң бөек жыр жирдә, Гомерләрне башлый безнең ул", ә икенче яктан исә чиркәү чаңы гел яңгырап тора:

*Ил өстендә бүген ачы көлү!*
*Чикләр дә юк аңа, кирта дә.*
*Бүген ул—чаң... матәм маршы булып*
*Ул яңгырар сыман иртәгә...*

Әнә шундый киң масштаблы сәяси һәм социаль күренешләр белән бергә китапта гап-гади эпизодлар да урын ала, әмма шунысы мөһим: шагыйрь боларыннан да тирән фикер, зур мәгънә чыгара ала:

*Мин дә эти синең арттан барам,*
*Уйлый күрмә туктап калырга.*

Яисә менә мондый строфа:

*Ә бер көнне арып, хәлдән таеп*
*Кайтып аусак туган нигезгә,*
*Салмак кына Ашыт агып ята,*
*"Ашыгып ни кырдың?"— дип безгә.*

Мәхәббәт турында язганда да шагыйрь үзенең төп холкына хыянәт итми.

*Һаман да шул мин, кыюсыз.*
*Ләкин кайбер кыюлар*
*Сөю юк, дип кычкырганда,*
*Кабатлыйм:*
*Бар сөю, бар!*

Биредә дә без чын ир-ат холкына хас булган сабырлыкны, түземлекне, әмма принципиаль сүз яки бәхәс чыккан очракта иң әһәмиятле саналган үрләрне яклап көрәшә, сугыша алырдай затны да күрәбез. Р. Корбанның мәхәббәт лирикасында аеруча истә кала торган шигъри табышлар да бар. Менә шулардан берсе:

*Яшь идем туган ягымда мин*
*Тыныч кына үскән тал кебек.*
*Талга оялаган сандугачтай,*
*Күңелемә урнаштың кереп.*

*Нурга тулы, моңга тулы хәзер*
*Минем өчен таңнар-иртәләр.*
*Кешеләр дә миңа карап, гүя,*
*Сандугачлы тал, дип үтәләр.*

Кеше күнеленә оялый торган сөю, мәхәббәт хисе әнә ничек матур итеп әйтеп бирелгән шигырьдә! Әсәрдә кулланылган шигъри детальләр, образлар барысы да бик табигый һәм нәкъ үзебезчә: талы да—ягымлы һәм назлы, иркә бер агач; оясы да күп мәгънәләр сыйдыра торган үтә шигъри төшенчә; ә инде сандугачы турында әйтеп тә торасы юк! Нәтиҗәдә, гашыйк

егет турында "сандугачлы тал" дигән бик тә тәэсирле, образлы һәм шигъри сурәт пәйда була. Әле бит ул, җитмәсә, халкыбызның менәр еллык шигъри фикерләү, тоюына, сиземләвенә нигезләнгән авыз иҗаты традицияләренә дә бик органик рәвештә тоташып, ялганып китә. Шулардагы моң, хис ташкыны белән кушылып тагын да көчәя, тулылана.

Бу китапта әнә шундый матур шигъри табышларны шактый еш очратасың. Бер шигырендә шагыйрь:

*Үргә акмаса да инеш*
*Барыбер коя Иделгә!*

—дип зур гомумиләштерүләрне үзенә сыйдырган, киң ассоциацияләр тудыра торган шигъри күренешне бирсә, икенче әсәрендә исә үзенең гашыйк булу халәтен болай дип белдерә:

*Әйтерсең лә яшен суккан*
*Агач кебек кабындым.*

Шулай ук көчле һәм зур тәэсир куәтенә ия чагыштыру түгелмени?! Мәхәббәт әнә шундый була бит инде ул!

Янсә менә мондый юллар:

*Казан!*
*Мин бит син кайнасын өчен*
*Учагыңда утын икәнмен!*

Ә фаҗигале рәвештә һәлак булган дусты, "Идел" журналының баш мөхәррире Фәез Зөлкарнәй турында шагыйрь болай дип әйтә:

*Кораблары сайга утырмасмы?—*
*Бер маягы сүнде Иделнең.*

Үзенә исә ул менә мондый бер караш ташлый:

*Мин—бердәнбер пуля мылтыкта,*
*...............*
*ул иң соңгы чиккә җиткәч кенә,*
*кирәк чакта гына атыла.*

Янсә:

*Әле бер тауга әйләнеп*
*Болытка тия түбәм.*
*Йә бер шарлавык булам да*
*Ташланам таудан түбән.*

Күрәсез, шагыйрь зур төшенчәләр, олы мәгънәләр белән эш итә һәм аларны белдерү өчен шулай ук калку, шундук истә кала торган детальләр, образлар *(яшен суккан агач, кораблар, пуля, тау, шарлавык һ. б.)* куллана.

Тулаем алганда да шагыйрьнең бу яна китабы безнең чорыбыз, язмышында хәлиткеч борылыш кичерүче милләтебез, кешенең күңел халәте һәм аңа тәэсир ясаучы җитди мәсьәләләр турында тирән уйлануларга бай булып чыккан. Алда китерелгән күпсанлы мисалларга таянып һәм китапта урын алган, чын шигърият үрнәге булган уңышлы әсәрләр нигезендә без бу җыентыкны Рафис Корбанның иҗади үсеш баскычында игътибарны җәлеп итәрдәй биеклек дип әйтә алабыз.

Шул ук вакытта, биредә безне икенчерәк юнәлештә уйландыра торган яклар булу турында әйтмичә узарга ярамас, мөгаен. Аларның иң беренчесе һәм соңгы еллар шигъриятенең үзенә бер төрле чиренә әйләнеп бара торганы, ул—озынга сузылган, эчтәлек ягыннан шактый ук көпшәк әсәрләр. Китапның 24-битендә урнаштырылган "Зират" шигыре, мисал өчен, 60 юлдан тора. "Сабан туе" дигәне исә хәтта 171 гә үк сузылган. Шулай ук "Казан кирмәне" (57 бит), "Ризамын" (73 бит), "Сабакташларыма" (103 бит), "Яшьлегем" (124 бит) кебек әсәрләрне дә нәкъ менә тиешле күләмдә язылган диеп әйтүе кыен. Менә шушындый артык озынга сузылган шигырьләр унаеннан матбугатта соңгы елларда шактый ук күп күренә башлаган поэмалар да искә төшә. Гадәттә, алар да гап-гади шигырь була, ләкин аларның авторлары ни өчендер туктый алмыйча үз әсәрләрен бик озынга сузалар да аңа һич тә тартынмыйча "поэма" мөһерен сугып та куялар! Бу китабында Рафис Корбан андый адымны атламый атлавын—монда поэмалар юк, ләкин озын шигырьләр үзләре дә шактый ук "тешкә тия".

Аннары шагыйрь кайсыбер әсәрләрендә кабатланып куя. Китапның 45-битендә урнаштырылган "Җыен" шигыре, "Мин бер генә яшим дөньяда (100), "Синең күзләр" (154), "Онытмам" (167), минемчә, әнә шундыйлардан.

Без моңа кадәр сүз йөрткән әсәрләр китапның баштагы ике бүлегендә урын алганнар. Ә җыентыкның өченче бүлеге исә җыр сүзләреннән тора. Без хәзергә тикле "балалар шагыйре" дип йөрткән Рафис Корбан байтак кына билгеле җырларның авторы да икән бит әле! "Уян, татар!", "Татарстан гимны", "Мәңгелек мәхәббәт", "Калыр сөю йөрәктә", "Онытма", "Кайларда йөрисең сөйгән яр"—әнә шундый әсәрләрнең кайберләре генә.

Китапның соңгы бүлеген тәрҗемә

әсәрләр тәшкил итә. Без соңгы елларда тәрҗемә эше һәм тәрҗемә ителгән әсәрләр турында бөтенләй дә диярлек сөйләми, язмый башладык. Әлбәттә, моның бер яктан караганда объектив сәбәбе дә бар: чөнки, хәзер милли яшәеш һәм милли әдәбият мәсьәләләре үзәккә чыкты. Ләкин нәкъ менә шул милли әдәбиятны үстерү ихтыяҗыннан чыгып караганда да тәрҗемә эшенә игътибарны арттыру кирәклеге сорала түгелме соң?! Аерым алганда, милли әдәбиятыбыз җәүһәрләрен дөньяга таныту сорала түгелме? Татарстанны һәм татар халкын икътисад ягыннан гына: КамАЗлары һәм нефте белән генә түгел, ә әдипләре һәм башка сәнгатькәрләре аша да белергә тиеш бит дөнья.

Шулай ук бүтән халыкларның әдәбият үрнәкләре белән танышу кирәклеге дә бәхәс уятмыйдыр. Алар безнең дөньяга карашыбызны киңәйтә, рухи яшәешебезне баета, иҗат мөмкинлекләрен үстерергә ярдәм итә ич.

Рафис Корбан исә биредә тәрҗемә өчен С. Капутикян, Н. Шәмсетдинов, Р. Кутуй һәм Сәгъди әсәрләрен сайлаган. Аларның күбесе безнең татар теле стихиясенә органик рәвештә ялганып китә, үзебезнеке сыман кабул ителә, күңелне дә кузгата. Мәсәлән, атаклы шагыйрә Сильва Капутикянның Рафис Корбан йөрәге һәм каләме аша узган түбәндәге юллары кемне генә битараф калдырыр икән:

*Шаулап урман, мең кулларын сузып,*
*Авыр сулап дәшә—килсәнә.*

*Кайнап-кайнап дәрьяларга аккан*
*Язгы сулар дәшә—килсәнә!*

*Мең авазлы җиһан бердәм булып*
*Кабатлый бер сүзне—килсәнә!*

Яисә менә Себердә яшәүче милләттәшебез Николай Шәмсетдиновның "Болан" дигән шигыреннән бер строфа:

*Чапты хайван, өркеп, әсәә килгән*
*Үлем машинасы—вертолеттан.*
*Һәм дөньяга чиксез курку акты*
*Күзләренә тәшкән кызыллыктан.*

Биредә, безне әсәрдәге драматизм да, аның татар телендә адекват бирелеше дә җәлеп итә, күңелдә канәгатьлек хисе тудыра.

Шулай ук Рөстәм Кутуйның тирән һәм шул ук вакытта катлаулы лирикасын да Рафис Корбан үзебезчә уңышлы "сөйләштерә".

Ә менә атаклы Сәгъди әсәрләре тәрҗемәсендә мин ни өчендер кытыршы урыннарны ешрак тойдым. Анда хәтта менә мондый сәер юллар да очрый:

*...Хәтта богаулы килеш тә*
*якын җанга дусларың,*
*Гөлбакчада булуыңнан,*
*йөрсә янда дошманың.*

Биредә нәрсәдер төшеп, бер шигъри юл онытылып калган, ахрысы.

Китаптагы әсәрләрне укып бетереп соңгы битне ябып куйгач, янадан аның исеменә игътибар итәсең—"Яра". Әйе, соңгы елларда кешелек тормышында яралар һаман күбәя бара шул. Һәм алар тирәнәя, җитдиләнә дә. Әнә шуларның фаҗигаи халәтен тоеп, сизеп торган укучы Рафис Корбанның китабына исем биргән "Яра" шигырендәге түбәндәге юлларны йөрәгенә аеруча якын кабул итә:

*Йөрәгемдә әрни күптән*
*Иске бер ярам.*
*Басылмасмы дип шул ярам,*
*Җырлар чыгарам.*

Чыннан да, шагыйрь язганча, бәлки әле киләчәктә безнең дөньябызда да техника һәм аның җимергеч тавышы түгел—ә бәлки җыр-моң һәм гармония тантана итәр?

Без кешелек җәмгыятенең матур киләчәген күрергә теләп, табигатьнең исән калуына, җирдә гармония югалмауга өметләнеп, кешеләрнең кешелеклелеге артачагына ышаныч баглап, Рафис Корбан китабындагы түбәндәге юлларның чынга ашуын ихластан телибез:

*Ә каләмем миңа, синең гомер*
*Мәңгелек дип гүя пышылдый.*

Яралар күп һәм җитди булса да тормышның һәм яшәүнең мәңгелегенә ышаныйк әле без!

**Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ.**

## *Хатлардан юллар*

* * *

Бик җентекләп укып чыктым мин Солтан Шәмсинең "Казан утлары"ның 7, 8, 9 номерларында дөнья күргән "Күк капусы ачылса" дигән фәнни хезмәтен. Уку барышында аңым ачыла барып Галәм киңлеге уч төбендәгедәй төсмерләнде. Рәхмәт шундый тирән әсәрләр белән безнең ише авыл агайларын Хакыйки гыйлем юлына аяк бастырганыгыз өчен. Авылда чакта ук мин кайдадыр чын гыйлемнең иң югары баскычында торучы кеше барлыгын сиземли идем. Шуларны эзләптер инде Туфан ага Миңнуллинга, Фәнис иптәш Яруллинга хат юллаганым да булды. Казанга килгәч, Равил Фәйзуллин әйткәндәй: "көндез фонарь тотып Бауман урамында кешеләрнең йөзләрен яктыртып" йөргән беренче кеше дә мин идем. Күп кенә академиклар, язучылар белән кул бирешеп сөйләшергә дә насыйп итте Ходай. Ләкин күңел дәфтәремә Зөлфәт Хәкимнән башка исем язылып куелмаган...

Үземнең мәкаләләремне чыгарган басмаларга гына язылу гадәте бар миндә. Июль аенда нигәдер (?) "Казан утлары" журналын киосктан сатып алдым. Күзгә бер якты йөз чалынды. Солтан Шәмси икән. Һәм шунда ук авторның: "Рухи күтәрелеш юлына аяк баскан кешеләргә кирәкле материалларны Тәрбиячеләребез үзләре китереп бирә..." дигән юлларны укып киткәч журналны ни өчен сатып алганлыгыма төшендем.

Мин үзем фәрештәләр дип аталган ниндидер илаһи көч булышлыгында яшәгәнемне тоемласам да, "татар тотып карамыйча ышанмый" дигән принциптан чыгып, аларны һәрвакыт күз алдыма китерергә тырышып карадым. Ирешелгән мәгълүматләр аша аларны канатлы бала формасында да, кояш нуры итеп тә күрмәкче булдым. Илаһиебезнең "Казан утлары"н кулыма китереп тоттыруы минем икеләнеп торган фикерләремне куәтләү йөзеннән булган икән...

Бу әсәр мине Коръән тәгълиматларыннан тагын да өскәрәк күтәреп дөньяга яңача карарга ярдәм итте.

**Назыйфҗан ХӘМИТОВ,**
*Казан.*

* * *

Хөрмәтле "Казан утлары"!

Мине бу хатны язарга нәрсә этәрде соң? 2004 елгы "Казан утлары" журналының 3 нче санында басылып чыккан "Япон татары" повестен укыдым мин. Ул, белгәнегезчә, безнең Салагыш авылы турында язылган. Әллә үзем Әгерҗе районы Салагыш авылында туып-үскәнгәме, бу әсәр миңа бик авыр тәэсир итте. Аны бик күпләр укыгандыр. Салагышлылар да укымый калмагандыр. Белмим, кем ничек кабул иткәндер, ләкин мин бу әсәрне укыганнан соң, үземне ниндидер бушлыкта кебек хис иттем. Күңелдә бик авыр тойгылар калды. Нәрсәгә нигезләнеп язылды икән "Япон татары" повесте? Анда язылганнарны дәлилли торган фактлар каян алынды икән автор тарафыннан? Шулай ук начар микәнни соң безнең авыл, аның кешеләре? Вахит ага Имамов мине гафу итсен, ләкин мин аның белән килешеп бетмим.

Авылда мәчет төзелгән, ачылган елларда мин Салагышта яши идем әле. Мәчет ачылу тантанасында мин дә катнаштым. Анда "япон татары" Таминдар әфәнде үзе килмәгән иде.

Ә повестьта "хаҗи мәчетне күргәч, йөрәгенә ябышып" егылды диелә. Безнең авыл мәчетен мин бер дә ямьсез димәс идем. Ул клуб каршында түгел, авыл уртасындарак— үзәк урамда иман нуры сибеп тора. 1992 нче елда ук ачылган булса да, бүрәнәләре бүген дә өр-яңа буранныкы кебек, сап-сары, тип-тигез. Манарасы да кыек түгел, бик матур, ерактан сәлам биреп тора.

Дөрестән дә, Таминдар әфәнде мәчет төзетергә дип җибәргән акча бик күп булган. Ләкин ул акча турыдан-туры Салагышка түгел, Алабугага күчкән һәм, акчаны үзвакытында ук ала алмаганлыктан, аның бәһасе төшкән. Ул сумманы күчү белән үк ала алган булсалар, мәчет төзергә генә түгел, авылга юл салдырырга да җиткән булыр иде, дип сөйләделәр авылда. Алабугадан акчаны күчерү артыннан йөргән кеше хәзер инде мәрхүм, шуңа күрә мин сезгә үзем белгәнне генә әйтә алам.

Мәчет ачылу тантанасына килгән кешеләрне дә бик ямьсез тасвирлаган автор. Анда дуңгызлар ияртеп чыккан исерекләрнең булганын хәтерләмим мин.

...Бәлки, бүгенге татар авылларындагы әшәкелек, әчкечелекне күрсәтергә теләгәндер Вахит ага. Чынлап та, хәзер татар авылында да дуңгыз асрау, эчүчелек баткагына кереп чуму күренешләре бар. Моны берничек тә кире кагып булмый. Шулай булса да, иманым камил, татар булган кеше мәчет ачылу тантанасына исерек хәлдә чыкмас.

Әдәбиятта "гротеск" бар инде, язылганнар беркадәр "күпертелгәндер". Ничек кенә булмасын, бу әсәр миндә начар фикер калдырды. Гафу итегез, ләкин аны бик күп кешеләр укыгандыр, аларда безнең авыл турында нинди тәэсир туганын чамаларга була. Минем бер хезмәттәшем дә миннән: "Шул повестьта язылганнар дөресменi?" дип сорады. Әллә авылдан читтә яшәгәнгәме, үз туган авылыңны бер дә начар итеп күрсәтәсе килми икән. Андый ук начар түгел ул безнең Салагыш.

Ярый, хатымны тәмамлыйм. Ачуланмагыз, бу сүзләрне сезгә җиткермичә кала алмадым. Хатымны Вахит агага укытырсыз дип ышанып калам. Әгәр теләсә, ул миңа җавап язсын. Мин түземсезлек белән аннан хат көтәм.

**Рәйсә ФАРРАХОВА,**
*Әгерҗе, Девятерня.*

---

## *Котлыйбыз!*

**Фәния Гайнанова**—үзенең бөтен тормышын китап, матур әдәбият белән бәйләгән шәхес. 1929 елның 15 ноябрендә Арча районының Олы Әтнә авылында туган кызны Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә дә китапка булган ярату, хөрмәт алып килгәндер, мөгаен. Университеттан соңгы хезмәт юлы да турыдан-туры әдәбият дөньясына барып тоташа. 1951 елны укуын тәмамлап, берничә ай университетның Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә эшләгәч, ул 1952 елның февралендә Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясенә эшкә күчә, һәм редактор буларак, татар язучыларының әсәрләрен дөньяга чыгаруда үзеннән зур өлеш кертә.

Күрәсең, озак еллар буе матур әдәбият белән эш итү, телне, әдәбиятны нечкә тоемлый белү аның үзендә дә каләм тибрәтү хисен уята. Бик күп татар балалары И. Тургеневның "Язгы сулар", И. Гончаровның "Гыйбрәтле язмыш" повестьларын, Ж. Верның "Капитан Грант балалары"н Ф. Гайнанова тәрҗемәсендә укып танышa алдылар. Татар әдәбиятының тәрҗемә өлкәсендә Фәния Гайнанова авторның язу стилен, тел-сурәтләү чараларының образлылыгын саклап, эмоциональ көчен ана телебездә камил дәрәҗәдә бирә алучы тәрҗемәче буларак урын алып тора. Әлеге хезмәтләре өчен Ф. Гайнанова хөкүмәтебезнең күп кенә бүләкләренә, мактаулы исемнәргә лаек була.

Ул—1980 елдан СССР Язучылар союзы члены.

**Редакция коллективы юбилярны олуг бәйрәме белән котлый, озын гомер, иҗат уңышлары тели.**

✦

*«Казан утлары» архивыннан*



*Тоткынлыкта Муса Җәлилнең "Моабит дәфтәре"н саклап калган Бельгия гражданины Андре Тиммерманс (уңнан икенче) Казанда. 1966 ел.*



*Композитор Арслан Батыршин һәм җырчы Нәҗия Теркулова. Узган гасырның 70 нче еллары.*



*Язучыларыбыз Идел буенда. Сулдан уңга—Р. Кәрами, Г. Ахунов, казакъ язучысы С. Саинбаев, Ш. Максудова, Л. Хәмидуллин, пропаганда бюросы вәкиле Д. Хәмидуллина. 1979 ел.*



*Академик Мирза Мәхмүтов "Казан утлары"нда кунакта. Сулдан уңга—Н. Гамбәр, Р. Гаташ, М. Мәхмүтов, Р. Фәйзуллин. 2000 ел.*




*Татарстан делегациясе вәкилләре Төркиядә, Гаяз Исхакый кабере янында (Истанбул). Сулдан уңга—Н. Бакиров, Р. Вәгыйзов, Ф. Фәтхелисламов, Р. Вәлиев, М. Хәсәнов, Р. Миңнуллин. 1994 ел.*



*Татарстан китап палатасы директоры Харис Әшрәфҗанов. 1997 ел.*

*Безнең календарь*

## Нур Гайсинның тууына 90 ел

Нурулла Әхъяр улы Гайсин 1914 елның 2 ноябрендә Уфа губернасының Әхмәт авылында туа. Җиде яшендә тулы ятим калган малай туганнары тәрбиясендә үсә. 1930 елда ул авыл мәктәбен тәмамлап, Уфага телеграфистлар курсына укырга керә. Аны тәмамлагач, Баймак районында телеграфист һәм Зилаир орлыкчылык совхозында элемтә бүлеге мөдире булып эшли.

1933 елда Зөя (Свияжск) шәһәрендә төзелеш институты рабфагында укый. Шунда укыганда Н. Гайсин иҗат эше белән шөгыльләнә башлый.

Әдәбият дөньясына якынрак булу өчен, 1934 елда ул Казанга килә. Башта су юлы инженерлары әзерли торган институт рабфагында, аннары Казан дәүләт педагогия институтының әзерлек курсларында укый. Педагогия институтында укыган елларында яшь шагыйрьнең "Ватаным өчен", "Яшьлек таңы" исемле беренче шигырь җыентыклары басылып чыга. Институтны тәмамлагач, ул Ютазы районы Кәрәкәшле урта мәктәбендә укытучы булып эшли.

Бөек Ватан сугышы елларында һава оборонасы гаскәрләрендә взвод һәм батарея командиры булып хезмәт итә.

Сугыштан соң Уфада чыга торган "Кызыл таң" газетасында әдәби хезмәткәр, соңрак Казан татар театр училищесында уку-укыту бүлеге мөдире һәм укытучы булып эшли. 1952-53 елларда ул янадан Совет Армиясе сафларында хезмәт итә. 1955 елдан ул язучылык эше белән генә шөгыльләнә.

Шагыйрь Нур Гайсин әдәбият сөючеләргә барлыгы ике дистәдән артык китабын бүләк итте. Алар: "Айлы кичтә", "Тайгада очрашу", "Җир чәчәктә", "Өмет тулы хыялым", "Минем туганнарым", "Таныш моң" һ. б. китаплар. Нигездә ул балалар өчен язды: шигырьләр, пьесалар, хикәяләр, әкиятләр, мәсәлләр... Алар арасында "Таза Мортаза" поэмасы, тәрҗемәи хәленә нигезләп язылган "Кызыл ыштанлы малай" исемле повесте бар... Аның шигырьләре мәктәп дәреслекләренә кереп, ничә буын укучылар күнелендә калды.

Нур Гайсинның яшьләргә багышланган "Давыллы көннәрдә", "Айсылуның мәхәббәте", "Ялгышу", "Югалган макет" кебек драма әсәрләре дә бар.

Нур Гайсин 1995 елның 1 декабрендә вафат булды.

### БӨТЕНДӨНЬЯ ЯЗУЧЫЛАР КОНГРЕССЫ ЯКЛАВЫ

Норвегиянең Тромсе шәһәрендә язучыларның 70 нче Бөтендөнья конгрессы булды. Аның эшендә 73 илдән килгән вәкилләр, шул исәптән Гәрәй Рәхим, Газинур Морат, Әхәт Мушинский һәм Борис Пантелеевтан торган Татар ПЕН-үзәге делегациясе дә катнашты.

Конгрессның девизы "Әдәбият дәүләте—дәүләт әдәбияты" кебек сүзләрдән гыйбарәт иде. Утырышларда "Язучылар—төрмәләрдә", "Аз санлы халыкларның телләре язмышы" темалары игътибар үзәгендә булды.

Моннан ике ел элек Халыкара ПЕН-клубның Македониядә үткәрелгән 68 нче конгрессында татар язуын латин алфавитына күчерү эшенең федераль үзәк тарафыннан туктатылуына бәйле рәвештә протест йөзеннән резолюция кабул ителгән иде. Әлеге проблема быелгы конгресста да каралды. Бу уңайдан Франция, Россия, Финляндия, Норвегия, Португалия, Бельгия һ. б. илләрдән килгән делегатлар үз фикерен белдерде, һәм лингвистика комитеты РФ Конституция судына хат җибәрергә карар кылды. Анда мондый сүзләр бар: "Әлеге мәсьәләне гадел рәвештә чишү өчен, иң беренче чиратта, дөнья күләмендә танылган халыкара хокук нормалары һәм лингвистик стандартларга таяну зарур. Без бу проблеманың асылда хәл ителәчәгенә ышанып калабыз..."

Язучыларның Бөтендөнья конгрессы делегатлары ассамблеясе үзләренең лингвистик комитеты инициативасын бертавыштан яклады һәм, 68 нче конгресс резолюциясен, шулай ук Бөтендөнья лингвистик хокуклар декларациясен дә өстәп, Халыкара ПЕН-клуб президенты Иржи Груша имзасы белән РФ Конституция судына хат юллады.

### 1000 ЕЛЛЫК МЕДАЛЕ

Башкалабызга 1000 ел тулу уңаеннан Россия Федерациясенең "Казанның 1000 еллыгына истәлек" дигән юбилей медале эшләнә. Әлеге бүләк Казан шәһәре үсеше өчен зур өлеш керткән, аеруча мөһим хезмәт башкарган, Бөек Ватан сугышында катнашкан һәм тылда фидакарьлек күрсәткән казанлыларга бирелер дип көтелә.

Хәзерге вакытта медальнең һәм аның таныклыгын бизәү, ясау эшләре алып барыла. Бүләккә тәкъдим ителәчәк кешеләрнең исемлеге барлана.

### ФИЛАРМОНИЯ ПӘРДӘСЕН АЧТЫ

Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе быел 67 нче сезонын ачып җибәрде. Хәзер бирелә бөтен илгә танылган 4 зур иҗат коллективы эшләп килә: ТР дәүләт симфоник оркестры, ТР дәүләт халык уен кораллары оркестры, опера һәм камера музыкасы бүлеге, ТР дәүләт фольклор музыкасы ансамбле. Быелгы сезонга алар өр-яңа идеяләр белән керә.

Сентябрь ахырында С. Сайдаш исемендәге Зур концерт залында да дәүләт симфоник оркестры катнашында "Дөньяның алтын тангосы" дигән концерт булды. Аның дирижеры—Эстониядән килгән Петер Сауль. Сентябрьнең 26 сыннан "Орган янында якшәмбе кичләре" дип аталган үзенчәлекле программа башланып китте.

Тамашачыларны бу сезонда тагын бер яңалык сөендерде: Казанның 1000 еллыгына багышланган "Тамырлар" кантатасы сәхнәгә менде. Аны композитор Роза Мөхетдинова Җәүдәт Сөләймановның тарихи-фәлсәфи шигырьләренә нигезләп язган. Әсәрне "La Primavera" Казан дәүләт камера оркестры, "Хыял" камера хоры, Идрис Газиев, Резеда Галимова, Рамил Миндияр, "Фәридә+Алсу" дуэты, нәфис сүз осталары Айрат Арсланов, Наилә Гәрәева, Илдус Әхмәтҗанов, Фәнис Җиһанша башкара. Режиссеры—Фәрит Бикчәнтәев.

Сезон башында ук дәүләт симфоник оркестры Көньяк Корея шәһәрләре буйлап 50 көнлек гастрольгә чыгып китәчәк. Георгий Ибушев, Резеда Галимова, Ки-

рам Сатиев Төркиягә Гаяз Исхакый иҗатына багышланган кичәгә барачак.

Шулай итеп, филармония Казан тамашачыларын гына түгел, чит илдә яшәүче милләттәшләребезне дә концертлары белән шатландырачак.

### МӨГАЛЛИМНӘР КИҢӘШӘ

13 октябрьдә Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе концерт залында мәдәният һәм сәнгать уку йортлары җитәкчеләре һәм мөгаллимнәренең республика киңәшмәсе үтте. "Татарстан Республикасында сәнгать белемен үстерү мәсьәләләре һәм перспективалары" темасына багышлап ТР мәдәният министры Илдус Тарханов доклад ясады. Шулай ук Н. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе проректоры Вадим Дулат-Алеев мәдәният һәм сәнгать уку йортлары мөгаллимнәре арасында үткәрелгән методик эшләр буенча республика нәтиҗәләре белән таныштырды. Киңәшмәдә район һәм авыл мәдәният йортлары өчен кадрлар әзерләү, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә милли белем бирү, сәнгать уку йортлары өчен кадрлар әзерләү, аның матди-техник базасын ныгыту, яшь талантларны табу һәм аларны үстерү, белгечләренең белемен күтәрү кебек мәсьәләләр дә тикшерелде.

### МӘСКӘҮ ТУКАЙЛЫ БУЛМАГАЕ

Мәскәүдә бөек татар шагыйре Габдулла Тукайга һәйкәл куелачак. Бу турыда Мәскәү шәһәр думасы каршындагы шәһәр монументаль сәнгать комиссиясе утырышында карар кабул ителде.

Комиссия рәисе, архитектор Сергей Петров белдерүенчә, һәйкәл Кече Татар тыкрыгындагы татар мәдәни үзәге каршында урын алырга тиеш. Ул Мәскәүнең татар җәмәгатьчелеге җыйган акчага куелачак.

Якын киләчәктәге бөек татар шагыйренә куелачак һәйкәл проектына конкурс игълан ителәчәк.

### КИНО БӘЙРӘМЕ БУЛАЧАК

Казанның 1000 еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә башкалабызда төрки халыкларның Беренче халыкара кинофестивале булачак. Анда Россиянең төрки телле республикалары, Әзәрбәйҗан, Урта Азия илләре кинофильмнары күрсәтеләчәк. Шулай ук Иранга, Төркия, Согуд Гарәбстаны һәм Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә дә чакыру җибәрелгән.

### ЖУРНАЛИСТЛАР БҮЛӘГЕ

ТР Премьер-министры урынбасары—авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры М. Әхмәтовка журналистларның "Бәллүр каләм" республика конкурсы бүләге һәм дипломы тапшырылды. Ул "Массакүләм мәгълүмат чаралары белән файдалы хезмәттәшлек өчен" номинациясендә җиңүче дип табылган иде. М. Әхмәтовны конкурста җиңүе белән "Татмедиа" массакүләм коммуникацияләр агентлыгы генераль директоры вазифаларын башкаручы Ф. Шаһиәхмәтов тәбрик итте.

М. Әхмәтовны журналистлар исеменнән Татарстан Журналистлар берлеге рәисе, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р. Ратникова котлады.

### ИДАРӘ КАРАРЫ

Татарстан Язучылар берлегенең балалар әдәбияты өлкәсендәге А. Алиш исемендәге бүләкне быел шагыйрәләр **Мәрзия Фәйзуллинага, Йолдыз Җамалетдиновага** һәм "**Мәгариф**" нәшриятына бирергә дигән карар кабул ителде.

### ТҮБӘН НОВГОРОДТА КИҢӘШМӘ

Түбән Новгород шәһәрендә Идел буе федераль округына кергән республика һәм өлкәләрнең язучылар оешмалары рәисләре киңәшмәсе булды. Анын көн тәртибенә "Россия Федерациясенең гомуми мәдәниятен үстерүдә әдәбиятның урыны" дигән мәсьәлә куелган иде.

Федераль округ үзәгенең Әдәбият музее бинасында үткән әлеге киңәшмәдә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин катнашты һәм чыгыш ясады.

### "ЯСНАЯ ПОЛЯНА" ЯЗУЧЫЛАРНЫ ҖЫЙДЫ

Ясная Полянада—Лев Толстойның музей-тыюлыгында һәр елның сентябрендә Россия, БДБ илләре һәм ерак илләрнең күренекле каләм әһелләре җыела. Әлеге очрашуларның быелгысына Мәскәү, Санкт-Петербург, Екатеринбург, Краснодар, Красноярск, Орел, Тула шәһәрләреннән, шулай ук Италия, Испания, Германия, Грузия, Украина, Беларуссиядән прозаиклар, шагыйрьләр һәм әдәби тәнкыйтьчеләр килде. Әлеге халыкара җыенда, "Ясная Поляна"ның саклаучысы, бөек әдипнең туруны В. Толстой чакыруы буенча Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис та катнашты.

Әдип утарына җыелган каләм ияләре берничә көн дәвамында кайчандыр Лев Толстойны борчыган һәм бүген дә актуаль саналган әдәби, фәлсәфи, социаль һәм дини мәсьәләләр турында фикер алыштылар.

## ТЮРКОЛОГЛАР ЖЫЕНЫ

6-9 октябрьдә Көньяк Казакъстанның Төркестан каласында, Әхмәт Ясәви исемендәге халыкара казакъ-төрек университетында дөнья тюркологларының II конгрессы булды. Тюркология фәненең мөһим мәсьәләләренә багышланган бу халыкара мәҗлестә төрки республикалар һәм дәүләтләр галимнәре белән бергә Россия, Япония, Венгрия, Польша, Кытай, АКШ һәм кайбер башка илләрнең күренекле галимнәре дә катнашты.

Татарстан галимнәреннән Хатыйп Миннегулов, Фәһимә Хисамова, Рафаил Бәзертдинов нотыкларын халык зур кызыксыну белән тыңлады. Конгресста тюркологларның халыкара ассоциациясен оештыру турында карар кабул ителде. Аның президиумы составына республикабыздан КДУның татар әдәбияты кафедрасы мөдире Хатыйп Миннегулов сайланды.

## ФИНЛЯНДИЯДӘ РӘШИТ ВАҺАПОВ ФЕСТИВАЛЕ

Рәшит Ваһапов исемендәге татар җыр фестиваленең чираттагы бәйрәме Финляндиядә үткәрелде. Татарстан Республикасыннан фестивальне оештыру комитеты рәистәше, "Татарстан" журналы баш мөхәррире Рифат Фәттахов житәкчелегендәге иҗат делегациясе Хельсинкида булды.

Фестиваль концерты Финляндиянең Татар җәмгыяте йортында гаять зур уңыш белән узды. Анда Казаннан килгән мөхтәрәм сәнгать осталары—Татарстан һәм Россиянең халык артисты Зилә Сөнгатуллина, Татарстанның халык артисты Рафаэль Ильясов, Татарстан җыр һәм бию ансамбленең сәнгать җитәкчесе Ринат Вәлиев белән берррәттән, Раиф Низаметдин, Хәмидә Чәйдәм, Җәмилә Низаметдин кебек фин татарлары вәкилләре дә катнашты. Кичәдә Рәшит Ваһапов үзе яратып җырлаган җырлар башкарылды, мәшһүр җырчы турында шигырьләр укылды, истәлекләр сөйләнде.

Фестиваль кысаларында Рифат Фәттаховның "Рәшит Ваһапов. Заман. Иҗат. Шәхес" исемле китабы тәкъдир ителде. Фестивальдә Финляндия татарлары гына түгел, Төркия, Швеция, Эстония һәм Россиядән килгән милләттәшләребез дә катнашты. Ә 91 яшьлек Шәмсия Апакай махсус рәвештә шушы кичәгә АКШтан килде.

Финляндиядәге татар җәмгыяте җитәкчесе Окан Таһир соңыннан: "Рәшит Ваһапов фестивале фин татарларының рухи тормышында Татарстан белән Финляндия арасындагы күпкырлы һәм үзара файдалы хезмәттәшлекне үстерүгә зур өлеш керткән тарихи вакыйгага әверелде",—дип белдерде.

## МИЛЛИ ТЕМАГА 150 ФОТОСУРӘТ

2 октябрь көнне Казанның Халыклар дуслыгы йортында "Националь" мәгълүмат-нәшрият йорты фотографларының 150 ин яхшы эше кергән "Милли фотография" фотокүргәзмәсе ачылды.

Күргәзмәдә тәкъдим ителгән эшләрнең барысы да диярлек милли темага төшерелгән сирәк кадрлар. Биредә мәгълүмат-нәшрият йорты фотографлары күзлегеннән Зимбабве һәм Балидагы йолаларны, Гыйракның кабатланмас буяулар чагылышын, соңгы вакыттагы сугыш һәм милли низагларны күрергә мөмкин. Каракалпакстан, Татарстан, Кырым, Грузия, Бурятия, Балтыйк буе, Молдова сурәтләре һәм күренешләре бар биредә. Аерым стендта ерак урнашкан җирләрдән милли темаларга ак-кара фотосурәтләр тәкъдим ителгән.

Эшләрнең авторлары—халыкара конкурслар лауреатлары, фотографияләр дөньясында танылган кешеләр: Наталья Медведева, Юрий Феклистов, Сергей Подлеснов, Евгений Кондаков, Сергей Воронин, Дмитрий Донской, Рифкать Якупов, Игорь Скобелев, Фәрит Гобәев һәм башкалар.

## РЕЖИССЕР ИСЕМЕНДӘГЕ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында режиссер Дамир Сиражиевны искә алу кичәсе узды. Кичәдә Дамир Сиражиев исемендәге бүләкләр дә тапшырылды. Татар театр сәнгатен югары квалификацияле кадрлар белән тәэмин итүдәге казанышлары өчен Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты ректоры Р. Йосыпов, Татарстанның халык рәссамы Сергей Скоморохов, Башкорт дәүләт академия драма театры артисты И. Сәитов, Россия театр сәнгатендәге казанышлары өчен "Кураж ана һәм аның балалары" спектаклендә Кураж ана ролен уңышлы башкарган Татарстанның атказанган артисты Р. Хәйруллина, А. Гыйлаҗевның "Яра" спектаклен сәхнәгә куйган режиссер Р. Фазлыев, рәссамы Б. Ибраһимов, "Татарстан яшьләре" газетасының әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөхәррире Ф. Низамова әлеге бүләкнең ияләре булды.

## ДУСЛЫК КҮПЕРЕ НЫК БУЛСЫН

Марсель Сәлимовның Казандагы "Идел-Пресс" нәшриятында өч телдә басылган "Бөргәләп көлик" исемле китабын тәкъдир итү кичәсенә журналистлар һәм язучылар җыелды.

Уфада яшәп татарча да, башкортча да иҗат итүче милләттәшебез—Марсель Сәлимовка карата мактау сүзләре дә, төрткеле шаяртулар да әйтелде бу кичәдә. Үзара китаплар бастырышу ике тугандаш республика халыкларын тагын да ныгытачак, диделәр чыгыш ясаучылар. "Безгә бергә-бергә эшләве дә, замана жилләренә каршы торуы да җинелрәк",—диде хезмәттәше турында ТР Журналистлар берлеге рәисе, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова.

Марсель Сәлимов, шулай ук, Азнакай шәһәрендә дә китап сөючеләр белән очрашты. Яңа чыккан китабының 100 данәсен район китапханәсенә бүләк итте.

**ГАЛИМ ИСТӘЛЕГЕНӘ**

Габдулла Тукай музеенда этнограф, археолог һәм тарихчы Михаил Худяковның 110 еллыгына багышланган укулар узды. Худяков—Киров төбәгендә туып, урта белемне Казанда ала. Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый. 1922 елда "Казан ханлыгы тарихыннан очерклар" дигән монографиясе басыла. Әдипнең хезмәтләрендә чагылган карашлары ул өлкәдә рәсми эшләүче галимнәр тарафыннан уңай кабул ителми. Шуңа да ул Ленинградка күчеп китәргә мәҗбүр була. М. Худяковның 50 дән артык эше дөнья күрә. Алар арасында "Татар сәнгате", "XVI йөздәге Казан рәсемнәре..." кебек хезмәтләре дә бар. 1936 елда докторлык диссертациясен яклый. 40 нчы елларда хөрмәт казана, тик фаҗигале рәвештә һәлак була.

Укуларда катнашкан галимнәр М. Худяков хезмәтләренә югары бәя бирделәр.

**ЮБИЛЕЙ КҮРГӘЗМӘСЕ**

Рәссамнар берлеге күргәзмәләр залында Татарстан халык рәссамы, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Казан дәүләт төзелеш-архитектура академиясе профессоры Искәндәр Рафиковның 75 еллык юбилеена багышланган күргәзмәсе ачылды. Анда рәссамның 500 дән артык картинасы урын алды. Ачылу тантанасында Татарстан мәдәният министры Илдус Тарханов катнашты.

**КОТЛЫЙБЫЗ!**

Күп еллар буе нәтиҗәле эшләгәне өчен "Идел-Пресс" "Полиграфиянәшрият комплексы" дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры **Ислам Галиәхмәт** улы **Әхмәтҗанов** Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә "Ватан алдындагы хезмәтләре өчен" II дәрәҗә ордены медале белән бүләкләнде.

**КИТАПЛАРНЫ—ПОЧТА АША**

"Мәгариф" нәшриятында янаданяңа китаплар басылып тора. Яңа гына "табадан төшкән" китапларны үзегездә булдырырга теләсәгез, әллә кая барып йөрисе дә юк. Бары тик нәшрият адресына, кирәкле китап исемен, авторын күрсәтеп, хат кына язып җибәрегез. 10-12 көн эчендә теләгән китабыгыз сезгә почта аша килеп ирешер. Ләкин почта аша китап алу якынча ике тапкырга кыйммәтрәк булуын искәртергә кирәк. Почта аша алырга мөмкин булган китаплар янына нәшрият бәясе куелган.

"Мәгариф" нәшриятында чыккан китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып ала аласыз:

**Әмирхан урамы, 17 нче йорт;**

**Сул Болак урамы,42/2 нче йорт;**

**Зур Кызыл урам, 68 нче йорт** *("Аист-Пресс" Сәүдә йорты кибетләре)*;

**Кремль урамы, 21 нче йорт** *("Книгомир" кибете).*

Нәшрият бәясе белән китапларны турыдан-туры "Мәгариф"тә, ягъни Бауман урамындагы матбугат йортының 3 нче катындагы 24 нче бүлмәдә сатып алырга мөмкин.

Хат язу өчен безнең адрес:

**420111, Бауман урамы, 19 нчы йорт, а/я 447.**

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Табигатьнең серле почмагы». Рәссам **Р. Кәримуллин** эше.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Гөлчәчәк Галиева.**

# ЯҢА КИТАПЛАР




Равил ФӘЙЗУЛЛИН. **Гыйбрәтләр алырлык үткән юл.** Фәнни-публицистик язма.—Казан: "Идел-Пресс" нәшр., 2004.—152 б. Тиражы—2000 данә.

Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллинның бу хезмәте Татарстан Язучылар оешмасы төзелүенә 70 ел тулу уңаеннан язылган. Автор, нигездә, XX гасыр татар әдәбиятына гомумкүзәтү ясап, аерым чорларга, үсеш-янару тенденцияләренә, әдипшәхесләргә мөнәсәбәтен белдереп, әдәби хәрәкәтнең тулы бер панорамасын тудырган.

Мәгълүмати фактларга бай бу китапта 150гә якын фотосурәтләр урнаштырылган. Арада матбугатта беренче тапкыр дөнья күргән уникаль фотодокументлар да бар.

Китапның редакторы—Марс Шабаев.




Нурмөхәммәт ХИСАМОВ. **Хәтер сагында.** Әдәби-фәнни мәкаләләр, иҗат портретлары һәм публицистика.—Казан: "Мәгариф" нәшр., 2004.—641 б. Тиражы—1000 данә.

Китап—галим иҗатын билгели торган төп мәкаләләрне эченә ала. Аларда автор әдәбият тарихының урта гасыр, XX йөз башы кебек мөһим дәверләренә кагылышлы концептуаль-теоретик мәсьәләләр күтәрә. Аерым гасырларда әдәбият үсешенең контекстын барлый, иң күренекле шагыйрьләрнең иҗат үзенчәлекләрен анализлый. Китапның публицистикага караган икенче бүлеге җәмһүриятнең мөстәкыйльләшүе чорында актуальләшкән тема һәм мәсьәләләрне күтәрә.

Басма филолог галимнәргә, мәктәп укытучыларына, матбугат хезмәткәрләренә, иҗат кешеләренә, аспирантларга һәм студентларга, киң катлау зыялыларга адреслана.



Гөлчәчәк Галиева

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)